# Казан утлары

10.1997



# 15 ОКТЯБРЬ — ХӘТЕР КӨНЕ




**Менә байтак еллар инде халкыбыз һәр елның 15 октябрендә Хәтер көнен билгеләп уза.**

**Яралы хәтер тарихтагы канлы сәхифәләрне хәтердә яңарта... 1552 елда яулап алынганнан соң Казан җимерелә, халык кырыла. Нәкъ менә шушы көннән соң татар халкы өчен берничә гасырга сузылачак икътисади, сәяси, мәдәни һәм демографик геноцид башлана! Дәүләтчелеген югалткан халыкны тез чүктерү өчен алга таба иң явыз һәм астыртын алымнар эшкә җигелә.**

**Безнең өчен менә нинди олы фаҗига ул — Казанның яулап алынуы.**

**Яулаучылар гына түгел, ул чакта Казанны соңгы тамчы канына кадәр саклаучылар да булган, билгеле. Җиңүче илбасарларга һәйкәл бар шәһәрдә, ә саклаучыларга юк. Чөнки, ни кызганыч, тарихны җиңүчеләр «яза».**

**Хакыйкать барыбер үзенекен итә. Ниһаять, 1552 елда Казанны саклаучылар истәлегенә тиздән Кремль эргәсендә һәйкәл куелачак. Бу — яулап алу сугышлары булмасын өчен, тарихи гыйбрәт өчен кирәк.**

**Хәтереңне югалтсаң, телеңне дә, илеңне дә югалтырсың. Дөньяда хәтердән дә көчле нәрсә юк. Хәтер җебе өзелә икән, кодрәтле Вакыт чылбыры да шартлап өзеләчәк.**

**Хәтер көне... Асылда — Матәм көне бу. Без аны, кемнәрнеңдер ачуын кабартмас өчен генә, шулай йомшартыбрак әйтәбез, ахрысы.**

**Хәтер көне бер көн белән генә бетми. Ул безнең күңелләрдә, милләтнең җанында-рухында ел буе дәвам итә.**

Р. НИЗАМИ тексты, М. ШАКИРҖАН фотосы.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**10**

**(900)**

**1997**

КАЗАН

## *Бу санда*

Безне котлыйлар ... 3

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

И. ЮЗЕЕВ. Мин дә тибрәндем үз гөлемдә. *Шигырьләр* ... 7
М. ЮНЫС. Соңгы сулыш. *Юльязма* ... 11
Б. РӘХИМОВА. Әйтү кирәкме?.. *Шигырьләр* ... 54
Р. ВӘЛИЕВА. Юлга чыктым... *Шигырьләр* ... 59
К. ТИМБИКОВА. Нәфесле Нәфисә. *Хикәя* ... 63
Я. ИГӘНӘЙ. Соңгы шигырьләреннән ... 99
Ә. САФИУЛЛИН. Үкенү. *Хикәя* ... 104

ДУСЛАР ҖЫРЫ

Н. НӘҖМИ. Җаваплылык тойгысы ... 75
Х. НАЗАР. Кардәшлек. *Шигырьләр* ... 75

ЮНЫС САФИУЛЛИНГА 50 ЯШЬ

А. ГЫЙЛӘҖЕВ. Пакъ кеше, ак кеше ... 81
Ю. САФИУЛЛИН. Йөзек һәм хәнҗәр. *Фаҗига, ике пәрдәдә* ... 82

ПУБЛИЦИСТИКА

Ә. ГАЛИ. Кизләү. *Очерк* ... 113

ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН

Г. ГАЗИЗ. Эчке эмигрант ... 122

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Р. НИЗАМИ. Проза турында сөйләшү ... 128

ҖАМАЛ ВӘЛИДИНЕҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

М. ГАЙНЕТДИН. Батыр яуда беленә ... 131
Җ. ВӘЛИДИ. Әдәби Мәсәхәбә ... 132

МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Р. ӘМИРХАН. Казанлы Әмирханнар ... 137

ХӘТЕР

Ә. ЕНИКИ. Гөмбәгә бару ... 156
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВНЕҢ МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВКӘ хатлары ... 166

ХАЛЫК ИҖАТЫ

А. САДЫЙКОВА. Җан авазы. *(Мөнәҗәтләргә бер күзәтү)* ... 176

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

Б. СОЛТАНБӘК. Каһәрле карарлар ... 182

Латин имласында уку үрнәкләре ... 187
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ... 189

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Нәҗип Бакиров**
**Хәлим Гайнуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Салих Маннапов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Нажар Нәҗми**
**Рашат Низамиев**
**Булат Солтанбәков**
**Камил Сәгадәт**
*(җаваплы сәркатип)*
**Ренат Харис**
**Розалина Шаһиева**
**Харрас Әюпов**

Б е з н е ң  а д р е с: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Т е л е ф о н н а р:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 43-56-12,
бухгалтерия — 43-56-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Нас поздравляют с 75-летием журнала.
«Поэзия и проза»: окончание документальной повести М. Юнуса «Последнее дыхание», рассказ К. Тимбиковой «Жадная Нафиса», рассказ А. Сафиуллина «Покаяние»; стихи И. Юзеева, Б. Рахимовой, Р. Валеевой, Я. Игеней.
«Песни друзей»: стихи поэта Башкортостана Х. Назара.
«К 50-летию Юнуса Сафиуллина»: трагедия «Перстень и кинжал».
«Публицистика»: очерк А. Гали «Родник».
«Из сокровищницы татарских рассказов»: Г. Газиз «Внутренний эмигрант».
«Литературная критика»: Р. Низами «Разговор о современной прозе».
«К 110-летию Джамал Валиди»: статья М. Гайнетдин «Герой познается в битве». Дж. Валиди. «Литературное собеседование».
«К истории культуры»: статья Р. Амирхана «Казанские Амирханы».
«Память»: А. Еники «Поездка за грибами»; письма А. Гилязова, адресованные М. Магдееву.
«Народное творчество»: статья А. Садыковой «Крик души».
«Из страниц истории»: статья Б. Султанбека «Проклятые постановления».
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Память» — картина художника Х. Шарипова; поэт Гарифзян Мухаметшин.

## IN OUR ISSUE

We are congratulated on the 75 th anniversary of the magazine.
«Prose and Poetry»: the end of M. Yunusov's documentary narrative «Last Breathing»; K. Timbikova's story «Mean Naphisa», A. Saphiullin's story «Confession», the verses of I. Yuziev, B. Rakhimova, R. Valieva, Ya. Igenei.
«Friend's song»: the verses of Bashkortostan poet Kh. Nazar.
«Commemorating the 50 th Anniversary of Yunus Saphiullin»: the tragedy «The Ring and the Dagger».
«Publicism»: A. Gali's sketch «The Spring».
«From the Treasure-House of Tatar stories»: G. Gaziz «The Inland Emigrand».
«Literary Critigue»: R. Nizami «The Talk about Moderh Prose».
«Commemorating the 110 th Anniversary of Jamal Validi»: M. Gainetdin's article «Hero is getted to khow in battle». J. Validi «Literary Interview».
«To the History of Culture»: R. Amirkhan's article «Kazan Amirkhans».
«Memorry»: A. Eniki «Coing Mushrooming»; A. Gilyazova's letters to M. Magdeev.
«Folk and Amateur Arts»: A. Sadikova's article «A Cry from the Heart».
«From the Pages of History»: B. Sultanbek's article «Accursed Resolutions».
The diary of social and cultural life.
In our covers: Kh. Sharipov's picture «Memorry»; the poet Gariphzyan Mukhametshin.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* Тәслимә Сибгатуллина, Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

Производствога бирелде 29.08.97 ел. Басарга кул куелды 17.09.97 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 $^1/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 12 190. Заказ Н-507.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1997 ел.

# БЕЗНЕ КОТЛЫЙЛАР

**Журналның чыга башлавына 75 ел тулу уңаеннан редакциябезгә төрле оешмалардан, иҗат коллективларыннан һәм аерым кешеләрдән күпсанлы котлаулар, телеграммалар килде. Аларның кайберләрен укучыларыбызга да тәкъдим итәбез.**

* * *

Хөрмәтле «Казан утлары» журналының укучылары, авторлары, дуслары!

Хөрмәтле редакция хезмәткәрләре!

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты исеменнән сезне әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге күпкырлы, нәтиҗәле эшчәнлеге белән абруй казанган, үзенең даими укучыларын тапкан «Казан утлары» журналының 75 еллыгы белән кайнар котлыйм!

«Казан утлары» журналы узган 75 еллык юл — тарихыбызга кереп калачак юл. Ул һәрвакытта да вакыйгаларның алгы сызыгында булды, әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси журнал буларак татар халкының тугры юлдашына һәм киңәшчесенә әверелде.

Кадерле дуслар!

Шушы олы юбилей көннәрендә халкыбызның тарихи-мәдәни һәм рухи-әхлакый мирасы өчен бүгенге һәм киләчәк буыннар алдында җаваплылык тоеп эш итүегез, милли яңару, гореф-гадәтләребезне, ата-бабаларыбыз мирасын кире кайтару юлында армый-талмый эшләвегез өчен сезгә тирән рәхмәтебезне җиткерәм.

Сезнең барыгызны да мөхтәрәм журналыбызның юбилее белән котлап, иҗади табышлар, кыюлык телим. Каләмегез һәрвакыт үткен дә, фәлсәфи дә булсын, абруйлы исемегезгә лаек булып эшләгез. Сәламәт һәм бәхетле булыгыз!

**Татарстан Республикасы Премьер-Министры Ф. МӨХӘММӘТШИН**

* * *

Казан... «Казан утлары»... Гаять матур һәм тирән мәгънәле исем! Казан бит ул Татарстанның гына түгел, язмыш тарафыннан илнең байтак төбәкләренә, дөньяның шактый кыйтгаларына сибелеп яшәгән бөтен татар халкының да рухи мәркәзе.

Башкалабызда бу көннәрдә үтә торган II Бөтендөнья татар конгрессы — әнә шуның ачык чагылышы. Әлеге туплану һәм берләшүгә башкалабыз Казанның да, аның исемен йөрткән «Казан утлары» журналының да керткән өлеше гаять зур.

Нинди генә исемдә дөнья күрсә дә, журнал һәрвакыт алдынгы иҗтимагый-сәяси фикернең мөһим чыганагы булып торды. Журнал — татар әдәбиятының, гомумән, мәдәниятебезнең җанлы тарихына, елъязмасына әверелде. Татар әдипләренең егерменче гасырда язылган, гомумкешелек рухи хәзинәсенә өлеш керткән күренекле әсәрләре укучыга иң элек «Казан утлары» журналы аша барып ирешә.

Төрле елларда без бу журналда күп кенә күренекле язучыларыбызның һәм шагыйрьләребезнең яңа әсәрләрен күрә алдык. «Казан утлары»нда эшләгән һәм әсәрләре басылган барлык олуг шәхесләрнең исемнәрен телгә алып булмаса да, танылган әдипләребез Галимҗан Ибраһимовны, Сибгат Хәкимне, Гомәр Бәшировны, Хәсән Туфанны, Әмирхан Еникине, Гариф Ахуновны, Рафаэль Мостафинны, Илдар Юзеевны һәм башкаларны аерып, әйтеп китәсе килә.

«Казан утлары» журналы редакциясе хезмәткәрләрен, аның күпсанлы авторларын һәм укучыларын журналның 75 еллыгы белән котлыйм. «Казан утлары»ның киләчәктә тагын да көчлерәк балкуын, аның битләрендә

әдипләребезнең тагын да гүзәлрәк әсәрләре барлыкка килүен телим. Журнал һәм аның хезмәткәрләренең иҗат гомере озын, киләчәге якты, башкарган эшләре бәрәкәтле булсын. Яңа уңышлар һәм бәхет телим сезгә — дуслар!

**Казан шәһәре администрациясе башлыгы**
**К. ИСХАКОВ**

* * *

Сафларында 100 дән артык ил вәкилләрен берләштергән Бөтендөнья ПЕН-клубы җитәкчелеге татар халкының төп әдәби журналы булган «Казан утлары»н 75 еллык юбилее белән котлый. Журналның талантлы төп активының ПЕН-үзәк әгъзалары булуы безнең өчен аеруча куанычлы. Татарстан Республикасына суверенлыгын тагын да үстерүен, ә язучыларга илһам, рухи ныклык, талантлы һәм кешелекле китаплар, XXI һәм аннан соңгы гасырларда цивилизацияле дөньяда лаеклы урын алуларын телим.

**Бөтендөнья ПЕН-үзәге президенты Рональд ХАРВООД.**

## Син кирәк

*Кадерле журналыбыз «Казан утлары»ның 75 еллыгы уңаеннан*

Каршыдагы караңгыны җиңеп,
алтын учак булып талпындың.
Рәхмәт сиңа!
75 ел яндың
адаштырмас өчен халкыңны.
Чакырдың син,
чарладың син безне,
кылыч иттең сүзне, фикерне...
Бәйсезлеккә алып чыгар юлның
Капкасына хәтле китердең.
Ә капкасы бикле, биге — хәйлә:
тозак төсле, ятьмә төслерәк.
Бу хәйләне ятыртырга кирәк!
Яндырырга кирәк!
Син кирәк!

**Татарстан язучылары**

* * *

75 еллык олы бәйрәмегез белән котлыйбыз. Киләчәктә дә яраткан журналыбыз элеккеге кебек ук иң укыла торган һәм популяр булып калсын. Олуг халык мәхәббәте сезгә.

**Мәдәният министры М. ТАИШЕВ.**

* * *

Хөрмәтле «Казан утлары»

Сезнең 75 яшьлек юбилеегыз — төрле кыйтгаларга сибелгән гыйбрәтле халкыбызның зур бәйрәме ул. Татарстан нефтьчеләре сезне шул уңай белән чын күңелдән тәбрик итә. Без милләтебезнең «Казан утлары» кебек мәртәбәле журналы булуы белән горурланабыз. Талантлы каләм ияләренең шигырь-поэмалары, повесть-романнары, проблемалы мәкаләләре татар халкына үз асылын аңларга һәм дистә еллар буенча кыйбласын югалтмый саклап барырга ярдәм итте. Киләчәктә «Татнефть» һәм нефтькә кагылышлы мәсьәләләр, танылган кара алтын чыгару осталарына багышланган материаллар да журналда ешрак күренер дигән өметтә калабыз.

Редакция хезмәткәрләренә һәм аның авторларына илһамлы озын гомер, сәламәтлек телибез. Тынгысыз каләмегез армасын.

**«Татнефть» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Р. ГАЛИЕВ.**

* * *

«Казан утлары» — татар телендә чыга торган абруйлы, иң өлкән әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси журнал. «Казан утлары» җитмеш биш ел дәверендә татар халкының бердәнбер калын әдәби-мәдәни журналы булып килде һәм бүген дә иң мәртәбәлеләр рәтендә йөри. Үзенең төп мәсләгенә һәм укучыларына тугрылык саклап, ватандарлык һәм халыклар дуслыгы идеяләрен раслап, талантлы әдипләребезнең иң яхшы яңа әсәрләрен меңнәр-миллионнарга җиткереп бара.

Тагын шунысы шатландыра, журналны дистә еллар дәвамында җитәкләүче талантлы шагыйрь Равил Фәйзуллинны безнең төбәк биргән бит. Без аның белән дә нык горурланабыз!

Әдәбиятыбызны пропагандалау, тарихыбызны һәм күренекле шәхесләребез язмышын яктырту, Татарстанның мөстәкыйльлеген ныгыту кебек иң актуаль темаларны укучыларга җиткерү ниятендә, «Казан утлары» киләчәктә дә үзеннән зур өлеш кертер дигән өметтә калабыз.

Хөрмәтле дуслар! Сезгә нык сәламәтлек, бәхет, иҗатыгызда якты сәхифәләр һәм тагын да биегрәк үрләр яулавыгызны телибез.

Балык Бистәсе районы хакимият башлыгы Х. ГАЗИЗОВ.

* * *

Хөрмәтле Равил Габдрахманович!

Сезне һәм Сез җитәкләгән коллективны яраткан журналыбызның данлы 75 еллык юбилее белән чын йөрәктән котлыйм. Татар әдәбиятын үстерүдә иҗади уңышлар телим. Журнал мәңге яшь булсын һәм иҗат кешеләренә якты рух өстәсен, укучыларын яңа әсәрләр белән даими сөендереп яшәсен.

**Менделеев районы хакимият башлыгы В. ВАХИТОВ.**

* * *

Журнал коллективын данлы юбилей белән чын күңелдән котлыйм. Барыгызга да сәламәтлек, бәхет һәм иҗат уңышлары телим.

**Кайбыч районы хакимият башлыгы А. ХӘНИФӘТУЛЛИН.**

* * *

75 ел — зур вакыт аралыгы. Шушы чорда колхозлашу, дәһшәтле Бөек Ватан сугышы, илне төзекләндерү еллары һәм башка тетрәнү — тарихи борылышлар да булды. Әмма журнал редакциясе изге кыйбласына хилафлык итмәде, үзенә йөкләнгән изге миссияне намус белән үтәде, халкыбызга җиңү яулашты. Нәкъ менә әлеге басма битләрендә Галимҗан Ибраһимов, Кави Нәҗми, Мирсәй Әмир, Муса Җәлил, Хәсән Туфан кебек, милләтебезнең йөз аклыгы булган әдипләребез тәүге әсәрләрен бастырдылар. 75 ел эчендә «Казан утлары» елдан-ел үсә, ныгый барып, меңнәрчә укучыларыбызның яраткан журналына әверелде.

Кадерле дуслар! Сезне «Казан утлары»ның 75 еллык бәйрәме белән ихлас котлыйбыз. Яраткан басмабыз редакциясе киләчәктә матур традицияләрне тагын да ишәйтер, халкыбызны әхлакый сафландыруда, яшь иҗат көчләренә канат куюда көчен кызганмас, дип ышанабыз. Саулык-сәламәтлек, иҗат уңышлары, бәхет телибез!

**«АлАЗ» берләшмәсе генераль директоры Р. ЗАРИПОВ.**

* * *

Хөрмәтле «Казан утлары!»

«Татспиртпром» хезмәтчәннәре данлы «Казан утлары»н 75 еллык бәйрәме белән чын күңелдән тәбрик итә.

Яраткан журналыбыз кабызган утлар күңелләребездә мәңге сүнмәс. Сезгә яңа уңышлар һәм киләчәктә тагын да яктырак балкуыгызны телибез.

**«Татспиртпром» берләшмәсе генераль директоры Р. ШӘЙХЕТДИНОВ.**

* * *

Халкыбызга яктылык нуры, җылылык сибүче хөрмәтле «Казан утлары» журналы. Юбилеегыз мөбарәк, киләчәк юлыгыз тагын да яктырак, киңрәк булсын. «Казан утлары»ның барлык хезмәткәрләренә тазалык, саулык, бәхет кояшы теләп

**Яшьләрнең «Сәләт» фонды.**

* * *

Мөхтәрәм баш редактор!

Сезне һәм бердәм иҗат коллективыгызны олуг юбилеегыз белән тәбриклим.

«Совет әдәбияты» журналы белән элемтәм әле солдат елларыннан ук башланды:

Бир урныңны
ерак Атаудагы
Солдат хисләренә, Казаным!

һәм 1945 елның җәендә «Атаудагы хисләр» поэмасы журналда дөнья күрде. Минем өчен зур бәхет иде бу.

Ходайга шөкер, элемтәбез ярты гасырдан соң да дәвам итә.

«Казан утлары» журналы татар әдәбиятының көзгесе, йөзек кашы ул. Рухи яктан һаман байый, тирәнәя, яратып укыла.

Изге хезмәтегездә яңа иҗат уңышлары юлдаш булсын!

Барчагызга да сәламәтлек, бәхет, шатлыклар теләп, тирән ихтирам белән — авторыгыз **Әдип МАЛИКОВ.**

* * *

Хөрмәтле дустыбыз!

Син бүген журналыбызның 900 санын кулыңа алдың. 75 елдан артык гомердә халкыбыз хозурына 900 том энциклопедик басма тапшырылган диган сүз бит бу. Шушы тупланмаларда — тарихыбыз, мәдәният-сәнгатебез, сәясәтфән дөньябыз, күңел көзгесе булган әдәбиятыбыз. Берничә буын милләттәшебез шушы журнал битләрен укып үзенә рух алган, иман-идеалын ныгыткан, тормыш кичкән. Киләчәктә дә журналыбыз тагын да камилләшә барыр, мәгънәви тирәнәеp, күңел дөньябызга яңа матур тойгылар иңдерер; алдагы гасырларда да күп меңләгән укучыларының рухи юлдашы булып калыр дип ышанабыз.

***Редакция.***



# Илдар Юзеев

## МИН ДӘ ТИБРӘНДЕМ ҮЗ ГӨЛЕМДӘ...

### Татар шагыйрьләренә

«Яшәгез озак!» дигән шикелле
Сайрый кошлары, исә җиле дә...
Китмәскә иде, китмәскә иде
Тукай шикелле егерме җидедә.
Яшәргә иде гомер озайтып,
Ут-ялкын биреп җаны утсызга...
Китмәскә иде, китмәскә иде
Такташ шикелле бары утызда.
Җыр-каләм белән җиңеп дошманны,
Башны имичә коллыктан соң да...
Китмәскә иде, китмәскә иде
Җәлил шикелле кырыктан соң да.
Атарга алып чыкканнан соң да,
Түзәлмәс газап чиккәннән соң да...
Китмәскә иде, китмәскә иде
Туфан шикелле сиксәннән соң да.
Һич тә тукталмый барасы иде
Туган тел белән Җыр дәшкән чорга...
Яшәргә иде, яшәргә иде
Кол Гали сыман мең яшьтән соң да!

### Киләчәк кызына хат

Килеп җитте Кандалыйның
Сөю хатлары.
Гашыйк кызлар шигырьләрен
Сөеп ятлады.

Күп кызларны сөю — гөнаһ
Саналмый кебек.
Мин дә бик күп гашыйк булдым
Кандалый кебек.
«Җырың яшәр» диеп күңел
Алдалый кебек.
Юкса мин дә янып яшим
Кандалый кебек.
Ышанам һәм өмет баглыйм
Шигырь-җырларга.
Хатым китсен сез яшәгән
Ерак елларга.
Сөю яшәр, хис тә яшәр,
Сизәм: алар нык!
Тик калырмы татар кызы
Мине аңларлык?
Җаныгызда бу хатыма
Табылса урын,
Сөенечтән сезне кочып
Еласын җырым.

## Эш ташлаган шагыйрь дустым хикәясе

Холкым минем бик хәйран икән:
Халык эшли, мин бәйрәм итәм.
Үзгәрәлмим бер дә, йә, нишлим?
Халык бәйрәм итә, мин эшлим.
Завод эш ташлаган, кем эшли?
Ә мин — язам. Болай килешми.
Булдым, ахры, мин дә эш аты.
Шигырем бит мине ашатмый.
Чыктым хәзер тәмам чыгырдан.
Китим микән әллә Шигырьдән?
Шигырь язып килми акча да.
Адәм яши — Җырдан башка да...
Баш миенә тутырып хисләрне,
Ташладым да киттем өстәлне.
Синең җырың кемгә, ник кирәк?!
Ипи кирәк безгә, сөт кирәк!
Сафлар арасына бастым да
Кушылдым да киттем ташкынга.
Барган булам мин дә эш кырып:
«Акча! Акча!» диеп кычкырып.
Шул чак, ни бу? Бер җыр ишеттем.
Кушылмыйча түзим ничек мин?
Бу ни хикмәт, тукта, ни эш бу?
Үзем язган, минем Җыр ич бу!
Гаҗәпләнеп калдым тукталып,
Үз җырымнан үзем рух алып.
Әйтте берәү: «Шагыйрь, бирешмә!
Бар, кайт өстәлеңә, син — эшлә!
Ап-ак кәгазь булсын алдыңда,
Соңгы өмет — Җырсыз калдырма!».
Таш урамда калдым тукталып,
Үз Җырымнан үзем рух алып.

Йөрәгемә җыеп хисләрне,
Кайтып кочакладым өстәлне.

* * *

Карап торасың син: «Кагылмаса
Ярар иде» дигән шик белән.
Синең белән көрешүгә кадәр
Кулларымны юдым чык белән.
Тормышыңда кемгә очрарсыңдыр,
Син бит көйсез язмыш иркендә.
Кулдан төшеп китсәң бәллүр сыман,
Җыеп ала алмас беркем дә.
Синең фәрештәгә тиңлегеңне
Белми дисең мәллә, бик беләм.
Сөенечтән битләремне юдым
Керфек очындагы чык белән.

* * *

«Туры сүзне әйтүләре җиңел...
Кабул итү — авыр».
Дуслар миңа дөрес киңәш бирә:
Булалмадым сабыр.
«Акыллылар түзем — әйтми калып
Юаналар гына.
Туры сүзне сөйләп йөри бит ул
Диваналар гына.»
Гадел сүзне кабул итә идем
Мин анадан гына.
Хәзер мин дә тыныч тыңлый алам
Диванадан гына...

* * *

Узды яшьлек. Һаваланмыйм.
Масаймыйм. Эреләнмим.
Табигать улы булсам да,
Язларын бөреләнмим.
Табигатьнең сый-хөрмәтен
Җәйләрендә мул алдым.
Әллә инде мәңге узмас
Кышларыма юл алдым?
Кышның салкын күләгәсе
Ике күземдә генә.
Саргайсам да, мин — җимешле
Юмарт көземдә генә.

* * *

Сандугач буласың килсә
Шигъриятнең талында,
Моң чишмәсе ургып торсын
Нәни йөрәк-җанында.

Сайравыңа карурманнар,
Чишмәләр таң калсыннар,
Тибрәтмәсәң күңелләрне,
Кунма талга, тал сынар.

* * *

Тормыш ул — ике актлы
Кыска драма сыман.
Бу әсәргә фаҗига да,
Уен-көлке дә сыйган.
Берәүләр үз драмасын
Бик оста язып куя.
Үзен ике актның да
Герое итеп тоя.
Кайберәүләр икенчегә
Бик җиңел күчеп китә.
Иң-иң кызык урынында
Каләме төшеп китә.
Мин дә хәзер драмамның
Икенче актында,
Әсәремнең чишеләсе
Хәл иткеч вакытында.
Ахырына якынлашам.
Әле ноктаны куймыйм.
Драмам тәмам булганда,
Кул чапмассыз дип уйлыйм.

* * *

Милләтемнең моңнар бакчасында
Мин дә тибрәндем үз гөлемдә.
Минем тавышым да калыр, бәлки,
Мәңгелекнең бер мизгелендә?!

*1996—1997*



## Миргазиян Юныс

# СОҢГЫ СУЛЫШ

ЮЛЪЯЗМА

Төн. «Таң кояшы» иле йоклый. Экипаж да йоклый шикелле. Салонга, ашханәгә, кызыл почмакка кереп чыктым. Коридор буш. Ялгызлык хисе чорнап алды. Сөйләшәсе, эчкә җыелганнарны бушатасы килә иде. Кемгә керергә? Аскы палубаның коридорын урап чыктым. Басынкы гына сөйләшкән тавышлар ишетелеп ала. Әнә, Непейвода яши торган каютада хатын-кыз чыелдап алды. Ирина тавышы. Машина сатып алганнан соң аш бирүче хатынга ярдәм кирәк була башлады. Ирләр ярдәме. Түләр мөмкинлеге бар. Төн кунып чыгуы катлаулымени? Хәзер ул Непейводаны сатып алган иде. Бәлки, киресенчә, Непейвода аны сатып алгандыр? Бартер атала бу ысул: син — миңа, мин — сиңа. Татар әдәбиятында да күптән кулланылып килгән алым...

Спардекка мендем. Бер тын туктап, тыңлап торганнан соң Рәиснең ишеген шакыдым.

— Да-а.

— Хәерле кич.

— Хәерле кич. Әйдә, түрдән узыгыз, Габдрахман абый.

Җылы. Иллюминаторларның пәрдәләре төшерелгән. Диван өстендәге бра гына яна. Рәис китап укый. Урыныннан торды, ванна бүлмәсенә кереп китте, чәй кайнаткыч алып чыкты. Суыткычын ачып, тутыкмый торган корычтан ясалган су савытын алды. Капкачын ачып карады. Су бозга әйләнгән. Озын отвертка белән бозны тишеп туңмый калган суны кайнаткычка агызды. Кораб танкларында озак сакланган су сасый башлый. Рәис кулланган юл белән генә суны сихәтләндереп була. Су кайнап чыкты. Рәис чәй пешерә. Һәр хәрәкәтендә көчле ихласлык, ритуал саклау, ата-бабадан калган гореф-гадәтләрдән тайпылмаска тырышу сизелә.

Рәис чәй пешергән арада мин аның китабына күз төшерәм. Стендаль, «Пармская обитель». Китапны да сайлый белә бу татар! Зәвыклы шәхес. Рәиснең кем икәнлеген аңлатыр өчен «шәхес» сүзе дә җитә торгандыр. Мөстәкыйль күзаллый, мөстәкыйль фикер йөртә белмәгән зәвыксыз бәндә шәхес була алмый бит ул.

Ниһаять, чәй эчәбез. Рәхәт тә инде! Тост әйтәсе юк, димәк, күз буйыйсы, юхаланасы, ялагайланасы да юк.

— Икенче бөтендөнья сугышында японнарның шәһәрләрен җимереп бетерделәр. Халкын кырдылар. АКШ япон утрауларына гаскәр кертеп, оккупацион тәртип урнаштырды. Марксизм-ленинизм тәгълиматы бу очракта Япония нәкъ безнең Татарстан шикелле коллар иленә әверелергә

---

Ахыры. Башы 8—9 нчы саннарда.

тиеш дип аңлата бит. Нишләп японнар экономиканың күп өлкәсендә иң алдынгы капиталистик илләрне артта калдырдылар?

— Җирләрен басып алсалар да, японнарның куллары үзләрендә калды шул. Шуңа күрәдер ул? — Бу сорау Рәиснең күптәнге уйларын җанландырып җибәрде булса кирәк. Ул хәтта, чәй эчүдән туктап, җилкәсен кашый башлады.

— Татарларның да бит куллары үзләрендә калды. Нигә соң без японнар шикелле, башка илләрне куып җитеп, алардан узып китә алмадык?

— Без бит Рәсәйгә тулысынча буйсынганбыз.

— Япония АКШка буйсынмаганмени?

— Сез нәрсә, сугышта җиңелүне японнар файдалана белделәр, дип әйтмәкче буласызмени? Әгәр ул сугышта безне немесләр җиңсә, без бит фашистлар олтаны астында кала идек.

— Японнар Америка агрессорлары олтаны астында калмадылармени?

— Мин бу турыда күптән баш ватам, — дип башладым. — Син укымый калмагансыңдыр. Гитлерны бит хакимият башына Сталин утыртты. Тельман, Сталин боерыгын үтәп, социал-демократлар белән бергә эш итәргә теләмәде.

— Сугышта немесләр җиңгән булса, татарларга мөстәкыйльлек бирерләр идеме соң?

— Белмим, — дидем мин. — Җиңә алмадылар бит. Нигә бу турыда баш ватарга? Ә японнарны җиңделәр. Аларның көлләрен күккә очырдылар. Бер генә исән калган шәһәрләре юк иде япон утрауларын америкалылар басып алганда. Завод-фабрикаларының эзе дә калмаган иде. Ә хәзер, күрәсең бит, ничек яшиләр. Яшиләр генә түгел, радиоаппаратура, автомобиль белән дөньяны күмеп ташладылар.

Моңа кадәр Рәис бу турыда уйламаган, күрәсең. Ул чәй эчүдән туктады. Чыннан да, җиңелгән, җиренә дошман басып кергән илне буйсындыручыларның колониясенә әйләнеп, дәүләт булудан туктап, әкренләп юкка чыгуын гына белә идек без. Әнә Рәсәй яулап алган илләр: Казан ханлыгы, казахлар, кыргызлар, Бохара, Коканд ханлыклары, ниһаять, Литва, Латвия, Эстония. Аларның язмышы бит тулысынча Мәскәү кулында. Чыннан да, Рәсәй ач-ялангач диярлек яшәгәндә аның кулы астындагы берәр халык японнар шикелле кыланып карасын әле...

— Урыс бит ялкау. Урыс эчә. Ә власть алар кулында. Бәлки, шуңа күрә аның кулы астындагы халыклар мантымый торгандыр?

— Ә нигә ялкау? Нигә эчә? Бу хакта уйлап караганың бармы синең? Эчә генә түгел, ул бит урлаша да бит әле. Әнә, җир йөзендәге иң алдынгы, иң прогрессив идеология — марксизм-ленинизм тәрбияләгән совет моряклары төннәр буе японнарның чүплекләрен тазартып йөриләр.

— Юк, алкашлыкны, урлашуны мин бер урыска гына якмас идем. Татарлар да шундый ук түгелмени? — Гаделлек саклау Рәиснең битен яктыртып җибәрде. Ул урыныннан торып чәйләрне кайнарлап килде.

— Сәрхүшлек ягыннан да, урлашуда да бәлки без, татарлар, урыслардан калышмыйбыздыр? Без бит аларның иң гадел, иң тырыш шәкертләре. Шулардан гел үрнәк алып, гел шуларга охшарга, ошарга тырышып яшибез. Тырышу белән генә чикләнмичә, без искиткеч зур тизлек белән урыслашып та барабыз.

— Анысы миңа аңлашыла. Мин хәзер туган телендә сөйләшкән татарны да сирәк очратам. Бусы бөтенләй башка нәрсә. Нишләп соң сугышта җиңелгән, җирләре тулысынча дошман кулына эләккән японнар безнең шикелле колга әйләнмәгәннәр? Моны бит берничек тә аңлап булмый.

— Безнең Япониягә килүебезгә өченче атна бит инде, әйеме? Өч атна буена мин гел син биргән сорауга җавап эзлим. Японнарның колониаль илгә әйләнми калуларының сәбәпләре күп булса кирәк. Алар бит җир

йөзендә иң милләтче, чиктән тыш милләтче халык. Японнар арасында башка халык вәкилләре яши алмый. Монда яшисең килсә, рәхим ит, японлаш. Японлашасың килми икән — дүрт ягың кыйбла.

— Урыс та шундый түгелмени?

— Юк, түгел. Алар безгә, татарларга, карата гына шулай аяусыз. Әрмәннәрне генә ал. Бүгенге көндә Горбачевның барлык киңәшчеләре диярлек әрмәннәр. Георгий Шахназаров — шул чыгара барлык карарларны. Михаил Сергеевич имзасын гына куеп тора. Президентыбызның сәяси киңәшчесе Андраник Мигранян, икътисад буенча — Абель Аганбенян, чит ил мөнәсәбәтләре буенча — Юрий Циторян. Ничә министр әрмән, ничәмә илче, газета-журналларда, телевидениедә да алар — әйтеп тә торасы юк. Урыс шуңа күнеккән, түзә, чөнки алар җайлаша белгәннәр. Ә бит алар үзләре Әрмәнстанга урысларны кертмәгәннәр. «Аргументы и факты» бирде шикелле бу мәгълүматны. Башка халыкларны тулысынча урыс белән болгатып сыеклап бетергән чорда Әрмәнстанда бары тик ике генә процент урыс керә алган. Беләсеңме аларны нинди эштә кулланганнар?

— Җитәкчелектәме?

— Туксан тугыз бөтен уннан җиде процент җитәкчелек әрмәннәрнең үз кулларында калган. Урысларны Үзәк Комитетның икенче секретаре, өлкә комитетында икенче секретарьлек һәм канализация чистартуда кулланганнар. Әрмәннәр искиткеч пассионар халык. Алар әле безнең Татарстаныбызга да ябырылачаклар. Акча исенә искиткеч сизгер аларның борыннары.

— Мин инде егерме ел диңгез флотында. Матрос булып эшләгән әрмәнне корабта беренче очратуым. Мурман пароходчылыгында әрмәннәрдән әллә ничә капитан бар. Безнең Адамян да азык-төлек биреп торуга кызыгып кына матрослыкка риза булган. Ул бит кара эшне үлеп яратмый. Юк, без бит японнарның ничек мөстәкыйльлекләрен саклый алуларын ачыклый алмадык әле. Бәлки, американыларның колонизаторлыкка сәләтләре юктыр?

— Буйсындыру өчен сәләт кирәкме икән, әллә көч кенәме? Тукта әле, без синең белән, ике татар зимагуры, урыс колонизаторлары таптанган язмышыбызны нигә японнар җиренә килеп ачыклыйбыз соң?

— Японнарны күргәч кенә аңлый башлыйсың икән шул. Нигә без сынганбыз, алар сынмаганнар? Японнар бит җирләрен басып алгач та үзләрен саклый алганнар. Аларга нәрсә ярдәм иткән?

Кораб дер калтырап алга шуыша. Тышта карлы яңгыр. Диңгез шаулый. Без җылы, тыныч каютада чәй эчәбез. Яңгыр көчәйде булса кирәк, кораб томан гудогы бирә башлады: у-у-у а-у у-у-у! Күңелгә шом йөгерде. Без, татарлар, аңлыйбыз бу тавышны. Без бит адашып калган ялгыз торналарга охшаганбыз. Таралганбыз. Таркалганбыз. Җиребезне килмешәкләр баскан. Ә үзебез әллә кайларга китеп, чит җирләрдә, ялгызлыктан туган җиребезне сагынып кан елап, тамыр җибәрергә җирлек эзлибез... Ата-бабаларыбызның сөякләре күмелгән җирдә килмешәкләр без... Японнарның исә тамырлары шулкадәр тирәнгә киткән, тоташ таш кыялардан торган утрауларга алар шулкадәр беркеп утырганнар, оккупантлар аларны урыннарыннан кузгата да, куптара да алмаганнар.

— Алар бит кырык биш ел гаскәр тотуга, корал ясауга, сугыш уты кабызуга бер тиен түләмиләр. Бар тапканнары тормышны яхшыртуга, сәнгатьне үстерүгә китеп тора, — дидем мин.

— Хатинохеда торганда мин көне буе аларның зиратларын, гыйбадәтханәләрен карап йөрдем. Алар үзләренең борынгы йолаларына тешләре-тырнаклары белән ябышып яталар икән.

— Нигә ябышмасыннар, — дип өстәдем мин. — Әгәр иске гореф-гадәтне йолкып ыргытсаң, аның урыны бетәшә, яңалыкны шул урынга үлсәң дә урнаштыра алмыйсың. Киресенчә, искелек белән яңалык очрашканда, аларның кайсы яшәеш өчен кулайрак, шунысы җиңә. Җиңелгәне исә

ашламага әверелеп, гореф-гадәтне үстерергә ярдәм итә. Японияне килеп күрмәгән булсам, мин шушы хакыйкатьне аңлый алмас идем.

— Сез миңа, японнар ике дин тоталар, дидегез. Ул ничек соң, алар бер-берсенә зыян китермиләрме?

— Белмим, сезнең күзәткәнегез бармы икән? Ислам диненең кануннары бер, ә һәр мөселман өммәте динне үзенчә тота. Берәүләр диннең йолаларын беренче урынга куялар. Ураза тоталар, хәер өләшәләр, матур итеп дини бәйрәмнәрне уздыралар. Икенчеләр күбрәк намаз укуга, коръән чыгуга, догаларга әһәмият бирә. Кайбер мөселманнар Аллаһы Тәгаләгә инануны, савап эшләүне, игелектә яшәүне урында тота. Минемчә, аларның барысы да хаклы, барысының да урыннары җәннәттә булачак. Японнарның диннәре, чыннан да, икәү. Синто — пакьлеккә, матурлыкка, төгәллеккә омтылу. Бусы аларга тормыш-көнкүрешне матур итеп корырга, шатланып яшәргә ярдәм итә. Буддистлык рухият өлкәсенә бәйләнешле. Бу дингә алар афәт килгәндә, кайгы-хәсрәткә юлыкканда мөрәҗәгать итәләр. Бала туганда синто кануннары белән бәйрәм итсәләр, мәетне будда законнарына таянып соңгы юлга озаталар.

— Фамилиясен хәтерләмим, ул үзе татар булса кирәк. Урысча яза. Ул да бит, мөселман динен христиан дине белән берләштереп икесен дә тотарга кирәк, дип яза. Бәлки, чыннан да, шулай кирәктер?

— Диас Вәлиевне укыгансыздыр сез. Ул, чыннан да, ике динне берләштереп яңа дин төзү турында пропаганда алып бара. Фәндә ул экуменизм атала. Евроцентризм шартларында, бигрәк тә Рәсәйдә, власть христианнар кулында булып, хөкүмәт ассимиляция сәясәтен алып барганда Диас Вәлиевнең утопиясе носарилар җиңүе, ислам динен юкка чыгару белән бетәчәк.

Без әле Рәис белән тел турында, татар теленең юкка чыгуы турында бик озак сөйләштек. Халыкның тарихи хәтере, аның рухи байлыгы, өмет-багланышларының егәре телгә кереп оялаганны ачыклаганда «Таң кояшы иле»ндә таң беленә башлаган иде инде. Яңгыр туктаган. Дулкын басыла төшкән. Корабның сул як бортыннан аксыл томанга төренгән диңгез күренә.

Иртәнге чәйгә кереп тормыйча, мин каютама кайтып йокларга яттым.

* * *

Караватыма аугач та мин бик озак йокыга китә алмадым.

Автомобиль заводларында эшчеләр сигез сәгать эшлиләр. Төшке аш вакытында бер сәгать ял, һәр ике сәгать саен ун минутка туктап кофе эчеп, бутерброд ашап алалар. Еллык ялны бездәге кебек 24 көнгә сузмыйлар. Япон чиясе, сакура чәчәк атканда — 5 көнлек ял. Августта заводны туктатып эшчеләрне 9 көнгә ялга җибәрәләр. Раштуа вакытында тагын 9 көнлек бәйрәм. Барлык эшчеләрнең ялга бер вакытта китүләре күмәк экскурсияләр оештырырга, бергәләп бәйрәм итәргә мөмкинлек бирә. Соңгы елларда чит илләргә сәяхәт кылу буенча японнар беренче урынга чыктылар.

«Ниссан» заводларында яңа эшкә урнашкан яшь эшчегә 120—130 мең тирәсе, яшь инженерга 140—150 мең иен эш хакы түлиләр. Эш хакы ел саен арта тора. Өйләнгән эшчегә дә акча өстәлә, бала тугач кабат эш хакы үсә. Йорт салучыга фирма ярдәм итә. Озак еллар яхшы эшләп килгән эшче-ветеран елына уртача 5—6 миллион иен акча ала. Завод директорының хезмәт хакы, билгеле, эшченекеннән дә, гади инженерныкыннан да зуррак, ләкин бездәге шикелле күпкә түгел. Аннан соң директорлар бездәге шикелле эшчеләрдән аерым, үз ишләре арасында, җитәкчеләр элитасында яшәмиләр. Япон директоры эшчеләр белән бер ашханәдә ашый, аның йорты да эшчеләр поселыгында, нәкъ эшчеләрнеке

шикелле һәм ул ялын да эшчеләр белән бергә үткәрә. Шушындый тыгыз бергәлек директорга эшчеләрнең мохтажлыкларын, аларның мөмкинлекләрен һәм теләкләрен аңларга ярдәм итә.

Япониядә айлык эш хакыннан тыш елына ике тапкыр, июньдә һәм гыйнвар аенда, акчаны күпләп (уртача 5—6 айлык зарплата) түлиләр. Бусы инде яхшы эшләгән өчен бүләк тә, фирманың хәле әйбәт икәнлеген күрсәтү өчен дә. Нәкъ шушы ярты еллык эш хакы түләнгән чакта японнар үзләренең тормыш шартларын яхшырталар. Машина сатып алалар, йорт салалар, затлы йорт җиһазларына ирешәләр.

«Таң Кояшы иле»нең алга китүе, билгеле, иң беренче чиратта хезмәтне оештыра белүгә, хезмәт ияләренең сәләтләрен, талантларын мөмкин булган кадәр мулрак эшкә җигүгә бәйле. Мәсәлән, японнар заводта эшләнгән әйбернең сыйфатын бездәге шикелле махсус тикшереп торучы ОТК карамагына тапшырмыйча, эшчеләрнең үзләренә йөкләүләре игътибарга лаек. Һәр бригада иң тәҗрибәле һәм абруйлы эшчене сыйфатны яхшырту комиссиясенә билгели. Завод администрациясе аларга махсус бүлмә, киръксә, приборлар, хәтта станоклар бирә. Бу бүлмәгә җитәкчеләрне кертмиләр. Сыйфат ягын кайгырту эшчеләр производствога бәйләнешле күп мәсьәләләрне, шул исәптән, эшләнеп чыгарылган продукциянең конкурентлык ярышында, җиңә алуын, эш шартларын яхшыртуны, эшләнешне тизәйтүне һәм башка мәсьәләләрне хәл итәләр. Рационализаторлык тәкъдиме җитлегеп беткәннән соң завод җитәкчеләренә тапшырыла. Җитәкчеләр исә аны мөмкин кадәр кыска вакыт эчендә гамәлгә ашырып, проектның күпме файда китерүен эшчеләрнең үзләренә белгертәләр һәм шундук акчасын да түлиләр.

Японияның шулкадәр кыска вакыт эчендә алга китүен, бик күп өлкәдә дөнья күләмендә беренче урынга чыгуын эшчеләрнең тырышып эшләүләре, менеджерларның оештыра, җитәкли белүләре белән генә чикләнеп калмый, билгеле. Бу илнең алга китүенә иң беренче чиратта Японияның Икенче бөтендөнья сугышында җиңелүе, корал ясау өчен бер тиен акча исраф итмәве, яшь буынны хәрбилеккә, кан коюга каршы тәрбияли алуы ярдәм итте.

Бу юлларны мин үземнең туган җиремдә, район үзәге Баулыда язам. Һәм бүгенге көндә мондагы эш тәртибе, яшь буынга тәрбия бирүне японнарныкы белән чагыштырып карыйм. Чагыштыру миңа шуны сөйли: бездәге томаналыкның иге-чиге юк, аның тиз генә бетүе, безгә акыл керүе күренми дә әле.

## 7

Туган телне югалтуның фаҗигаләре турында сөйләп арыдым да шикелле инде. Җәмгыятьтәге хәрәкәтнең кануннарын аңлавы шактый катлаулы. Шунысы бәхәссез: урыныннан бер кузгалып киткәч, җәмгыять инерция буенча бик озак бер якка тәгәри. Татар җәмгыятенең юнәлеше инкыйразга, юкка чыгу ягына караган. Әлегә без шактый зур тизлек белән шул якка таба шуышабыз. Һәм юкка чыгу, урыслашу хәрәкәтенә үзебезнең җитәкчеләр дә зур өлеш кертәләр.

Мин Баулыга июльнең 12-сендә кайттым. Татарстанда нефть чыга башлауның 50 еллык юбилеен каршыларга мәш килеп әзерләнәләр иде. Юбилей хөрмәтенә Баулы йортларының тышларын агарттылар, зур стадион, ябык бассейн, мәдәният сарае (икенчесен) һәм мәчет салдылар. Үзәк урамга асфальт түшәделәр һәм Куйбышев урамындагы скверга яңадан сузылган ике тасма итеп тротуар җәйделәр. Нәкъ Борынгы Мисыр пирамидаларын салучы коллар шикелле эшләде баулылар. Администрация башлыгы эшчеләрне туктаусыз камчылап торды. Районның барлык оешмаларында эшләүче чиновниклар, мәктәп балалары, пенсионерлар — кемнәр генә катнашмады шушы «Потемкин авылларын» төзүгә.

Бәйрәм каршыларга президент Шәймиев үзе килер дип көткәннәр иде. Аның урынына Фәрит Мөхәммәтшин, премьер-министр килде. Дүрт йөз миллион акча түләп, шуңа кыйммәтле бүләкләр дә өстәп, Мәскәүдән җырчы Леонтьевны чакырдылар. Әллә нинди парадлар, күргәзмәләр, ярышлар нәрсә генә булмады бәйрәм иткәндә. Бары тик бер генә нәрсә юк иде юбилей тантанасында — тамашачыларның күңелләрендә бәйрәм тойгысы. Һәр чыгыш, һәр мероприятие (бу сүз тәрҗемә ителми) катгый рәвештә, өстән төшерелгән боерык нигезендә оештырылган, җептән тартып хәрәкәткә китерелгән иде.

Баулыга бик күп кунаклар килгән иде. Шуларның берсе генә булса да шәһәр үзәгенә куелган һәйкәлләр турында район администрациясе башлыгына әйттеме икән? Юк, әйтмәгәннәрдер...

Узган елны чиксез күп көч түгеп, зур чыгымнар ясап, Баулы эшчеләр поселыгының үзәгенә өч һәйкәл куйдылар: 122 миллиметрлы туп-гаубица, МиГГ-15 истребителе һәм Т-62 танкы. Һәр эшнең, һәр гамәлнең максаты була. Һәйкәлләрне дә монумент сурәтен, шул сурәттәге идеяне мәңгеләштерү максаты белән куялар. Әйтик, бу өч гайрәтле корал Бөек Ватан сугышы дип аталган бәрелештә катнашканнар, ди. Бу очракта, чыннан да, аларның һәйкәллеккә лаеклы булуларын тартып-сузып булса да исбатлап булыр иде. Истребитель МиГГ-15 Корея сугышы чорында 1950—1953 елларда барлыкка килде. Ул, чыннан да, Корея сугышына катнашты. Шул самолетка утырып хәрби заданиега очкан, өч тапкыр Герой Иван Кожедубны америкаdebug гади очучылары бәреп төшерделәр. Бу хакта Көнбатыш илләренең газеталары шактый озак шаулап алдылар. Бәлки, шул Корея сугышындагы җиңелүгә багышлап куйганнардыр Баулыдагы һәйкәлне? Мисыр белән Израил арасындагы сугышка да катнашты бу истребитель, Вьетнамдагы кан коюга да, Әфганстандагы каһәрле кан коюга да. Ул сугышларның берсе генә дә безнең файдага булмады.

Т-62 танкы да Ватан сугышына катнашмады. Шул танклар белән 1967 елны Прага урамнарында балаларны, хатын-кызларны таптатып йөрделәр. 1989 елда Бакуда безнең дин вә кан кардәшләребез әзәрбәйҗаннарның эчәгеләрен танкларның гусеницаларына ураттылар. Тбилисидәге кан коюны, Вильнюстәге җинаятьләрне дә нәкъ шушы танклардан атып җимерделәр. Менә шушы вакыйгалар хөрмәтенә минем туган районымның үзәгенә һәйкәл куйганнар...

Баулының үзәк урамында торган танк һәйкәлен күрү белән минем кәефем кырыла. Бу һәйкәл минем үзем эшләгән җинаятьләремне дә исемә төшерә. Диңгезчелек чорында кайларга гына ташымадым мин шушы танкларны. Кубага һәм Вьетнамга, Анголага һәм Хәбәшстанга, Мисырга һәм Ливиягә, Гыйракка һәм Никарагуага. Димәк, Җир шарында коелган каннарга мин дә күпмедер дәрәҗәдә өлеш керткәнмен. Баулыдагы һәйкәл минем җинаятемне исемә төшереп, йөрәктәге җәрәхәтләремне әрнетеп җибәрә. Тагын бер нәфрәтем бар минем Баулы һәйкәленә. Корабка кертеп тутыргач, танкларны палубага чылбыр белән тарттырып беркетеп куялар. Рачаглы йозак белән, урыныннан купмаслык, шторм вакытында кораб тышын ертып чыгып, экипажны батырмаслык итеп. БМП, БТР шикелле машиналар бәйдән ычкына алмыйлар. Танк бит ул каһәрле корал. Ул бит җир йөзендәге кан коюларда күпме йортларны җимергән, күпме бәндәләрнең башларына җиткәндер? «Кайнар нокталар» дип аталган СССР оештырган кан коелган җирләргә корал ташыганда танкларның бәйдән ычкынуы аркасында ничә кораб һәлак булды. «Механик Герасимов» аталган Балтик диңгезе пароходчылыгы ролкеры Төньяк Атлантикада батып үлгәннән соң гына танкның кораб өчен куркыныч нәрсә икәнлеген аңлый алдылар. Чокырлар, сикәлтәле җирләр аша үтәрлек итеп эшләнгәнлектән, танкларның рессорлары чиктән тыш сыгылмалы була. Чайкалу вакытында танк талпына башлый да чылбырыннан ычкынып китә. Кораб әүмәк-тәүмәк килгәндә

танк әрле-бирле йөри торгач, теплоходның корпусын бәреп тишеп чыга да, үзенә ияртеп, экипажны да батыра. Адәм баласына һәлакәт китерүче коралны Баулыда һәйкәл итеп куйганнар әнә.

Тупны һәйкәл итеп кую — бусын ничек аңларга? Артиллериядә хезмәт итүчеләр коралга, бәлки, ихтирам белән карый торгандыр? Туп көпшәсен күрү белән исемә Кубага, Вьетнамга, Гыйракка корал ташыган чаклар искә төшә. Сугыш уты кабызу нияте белән шул илләрне коралландыра башлагач, АКШ безгә протест белгерде. Әле дә хәтеремдә, Куба кризисы башланыр алдыннан Американың хәрби кораблары безне каршы алалар иде. Каршы алалар да, борылып, безнең белән янәшә бара башлыйлар. Крейсерларның барлык туплары безгә таба борыла. Якынрак киләләр. Туп көпшәсенең авызыннан ялкын күренеп китәр дә, снаряд корабыбызның корылмасын җимереп ыргытыр дип көтәсең. Мәкерле көпшә авызы һаман сиңа төбәлгән. Һаман ут күренми. Бер мәлне нервалар киеренкелеге шул хәлгә җитә ки:

— Ат инде, сволочь, нигә газаплыйсың?! Тизрәк атып үтер, собака! — дип кычкырганыңны сизми дә каласың.

Хәзер инде аң керде миңа. Алар түгел, без сволочь идек. «Без» дигәнне татарлар дип аңлый күрмәгез тагын. «Совет кешесе» аталган урыслар, дөресрәге урыс хөкүмәте турында сүз бара. Алар чын, йөз процентлы сволочьлар иде. Американың крейсерлары илләренең иминлеген саклый иде. Алар ташымады коралны безнең чигебез кырыена, без ташыдык. Кубага урнаштырган безнең ракеталар АКШ иленең касыгына кереп утырган. Куба Америкага һөҗүм итү, аны куркытып тору өчен шундый шәп, шулкадәр кулай плацдарм иде. Куба манзарасы шуның белән тәмамланды. Без Николаев янындагы Балабановкадан ташыган ракеталарны кире алып кайттык. Бу мәсхәрәне бездән башка барлык илләр белде. Без, совет кешеләре генә, озак еллар буе бу хакта белми тордык.

Тукта, мин бит Япония, аның халкы турында язам. Нигә соң әле кинәт Баулыдагы танк, пушка, истребитель һәйкәлләре турында сөйли башладым? Һәйкәл яшь буынга тәрбия бирү өчен куела. «Менә ул сезгә үрнәк булырлык шәхес, үрнәк булырлык вакыйга, үрнәк булырлык символ»,— дип, һәйкәл һәр яңа буынга сөйләп торырга тиеш. Югыйсә, һәйкәлгә киткән акчаны ашарга бәрәңге, малга ашатырга печән сатып алу өчен тотсак, күп мәртәбә файдалырак булыр иде.

1904 елдагы сугышта японнар бөек Рәсәй империясенең көлен күккә очырдылар. 1940 елны Перл-Харборга урнашкан АКШ флотына һөҗүм итеп, аны да юкка чыгардылар. Икенче бөтендөнья сугышы вакытында Кытайның көнчыгыш өлеше, Кореянең бер кисәге, Ерак Көнбатыштагы күп утраулар, шул исәптән Сингапур, Гонконг японнар кулында иде. Димәк, японнарның да җиңүгә, көчкә хәрбилеккә багышланган һәйкәл куярлык горурлыклары җитәрлек. Нигә соң алар сугышка багышланган һәйкәлләрне Хиросимада атом бомбасы яндырган йорт сурәтендә, радиациядән һәлак булган балаларның истәлегенә торна сурәтендә куялар? Икенче бөтендөнья сугышында җиңелгәннән соң японнар яшь буынны сугышка, хәрбилеккә каршы нәфрәт тотарлык дәрәҗәдә тәрбияли алдылар. Шул ук хәл немецләрдә, итальяннарда һәм Германия фашистлары ягыннан сугышкан башка илләрдә дә булды. Нәтиҗәдә, сугыштан соң башланган хезмәт ярышында җиңелгән илләр җиңеп чыкты. Җиңүчеләрнең дә АКШ, Англия, Франция дәрәҗәсендәгеләре Советлар Союзы кабызып җибәргән «салкын сугыш»ка каршы торырга мәҗбүр булсалар да, сугышка катнашучыларга алмашка килгән буыннардан сугыш чукмарлары ясап, аларны туп ите булырга әзер итеп тәрбияли алмадылар. СССРда исә милитаристик тәрбия әле нык дәвам итте. Рәсәй — сугыштан яралган, яулап алу белән көн күреп яшәгән империя. Ә нигә соң без, мөстәкыйльлек игълан иткәч, Явыз Иван тарафыннан канга батырылган халык, яшь буынны танк һәйкәленә табынырга өйрәтәбез? Моны ничек

аңларга? Казан каласын алып, ир затыннан булганнарны тураклап бетереп, татар хатыннарын көчләп мәсхәрә иткәндә кулланган коралның оныгы бит бу танк. Казан Кремленең диварларын җимергән тупның варисы, шуның оныгының улы түгелмени Баулының үзәк урамына һәйкәл итеп куйган 122 миллиметрлы гаубица? Безнең балаларыбыз шул коралларга табыналар. Казан урамнарыннан кан елгалары агызган, татар халкын колыкка дучар иткән кабахәт көчтән Алла ясау бит бу. Нишлибез без, җәмәгать? Түп итте хәзерлибез бит газиз балаларыбыздан. Улларыбызны Рәсәйнең колониаль сәясәтен кан коеп саклаучы аяклы корал, кеше үтерүче ерткыч итеп тәрбиялибез бит без. Японнар искә төшкән саен шушы газаплы сораулар утлы күмер булып бәгыремне яндыра, газаплый башлый...

## 8

Хәзер мин үз каютамда йоклыйм. Двигатель эшләмәгәндә эсселек ул кадәр түгел. Йоклап та булыр иде, ләкин төне буе коридорда, өске палубада ыгы-зыгы. Экипаж вак төркемнәргә бүленеп корабтан чыгып китә дә таң атканчы шәһәрдән әйбер ташый. Көндез разведкага йөриләр. Шәһәр чүплекләрен, иске машиналар зиратын, ташландык йортларны карап кайталар да караңгы төшү белән «эшкә» керешәләр. Экипаж әгъзаларының каннарындагы ушкуйниклык уянды. Аларның ерак бабалары Шәһри Болгарны, Биләрне, Идел ярларына урнашкан татар авылларын, Алтын Урда калдырган байлыкларны талап йөргән булсалар, хәзер урыс колонизациясе вакытында бөлеп хәерчеләнгән халыкларның талап алыр нәрсәләре калмады. Японидә әйбер шулкадәр күп, шуны күрү белән урысның нәсел геннарына оялаган борынгы гадәт үзенең исән икәнлеген күрсәтә башлый. Япон утрауларында җир никадәр әз, торак салырлык урын никадәр тар булуына карамастан, японнар күп катлы биек йортларны өнәмиләр. Күп анда утызар, хәтта йөзәр катлы йортлар. Японнар 1000 метр биеклектәге йортлар салырга җыеналар, 2025 елны Токий култыгына тутыкмый торган корычтан субайлар кагып, 100 квадрат километрга җәелгән, миллион кеше сыйдырышлы шәһәр салырга җыеналар. Шуңа карамастан, япон кешесе кечкенә генә, җыйнак, бер катлы йортта яшәргә ярата. Өске каттагы кешеләр аның түшәменә басып йөрүне өнәми «Таң кояшы иле»ндә яшәүчеләр. Ашъяулык чаклы гына булса да аның үз чирәме, үз кулы белән утырткан агачлары, күреп ләззәтләнер өчен үзе үстергән чәчәкләре, яланаяк басып йөрергә үзенең туган туфрагы булсын. Шулар булганда гына бәхетле япон кешесе. Санап бетермәгәнмен икән әле. Басып йөрергә үз туфрагы гына түгел, ихатасы өстендәге күк йөзе дә аныкы булырга тиеш. Диңгездән искән дымлы җиле дә, куе болытлардан коелып калган яңгыры да, тәрәзәсенә томырып киткән буран кары да. Үзенеке. Бары тик аның үзенеке! Японны көчләп колхозга кертсәң, ул яшь алмас, азатлыкка, ирекка сусап үләр иде. Чыннан да, Икенче бөтендөнья сугышында әсир төшкән японнар СССРның концлагерларында тулысынча диярлек үлеп беттеләр. Японнарның психологиясен, аларның ирек сөюенең көчен, чиксезлеген белмәгән галимнәр әсир төшкән японнар урыс ашамлыгына, Себер суыгына түзә алмыйча үлде, дип аңлатмакчы булалар. Юк, алар үз илләрендәге ирек, шәхес булып, гореф-гадәтләр шифасында яшәү мөмкинлеге булмаганлыктан кырылдылар.

Күп катлы торакта йорт астындагы җир синеке түгел. Идән дә тулысынча синеке түгел. Үзеңнеке санар идең, идәннең аскы ягы аста яшәүче гаиләнең түшәме. Димәк, түшәмең яртылаш кына синеке. Хәтта диварларның да эчке ягы гына синеке санала. Шул ук дивар теге яктан караганда — күршенеке. Менә шушы хәлгә түзә алмый япон кешесе. Алар безнең шикелле манкорт түгел. Социализм, колхоз, күмәк тормыш, ирек

дип аталган ирексезлек, хокук дип аталган хокуксызлык безне котүдә йөргән сарыкка әверелдергән. Без мөстәкыйльлекнең нәрсә икәнлеген генә төгәл аның төмен дә, исен дә онытып бетергәнбез. Ә япон андый була алмый. Аның һәр нәрсәсе үзенеке, үзенеке булмаганда башка шәхеснеке булырга тиеш. Ирек, азатлык шартлары тәрбияләгән шәхеслек, мөстәкыйль фикер йөртү аларны шундыйга әверелдергән.

Убэ шәһәрен күзәтеп йөргәндә экипаж әгъзалары бер ачыш ясаганнар Японнарның йортлары арасында койма юк. Нәрсә чикли күршеләрнең арасын? Җитмеш-сиксән сантиметр киңлегендәге чирәмлек. Бу нейтраль зона, читләштерү ызаны (полоса отчуждения). Менә шул беркемнеке дә булмаган җирдә суыткычлар, кер юу машиналары, телевизорлар, магнитолалар, радио-комбайннар, әллә нәрсәләр тулып ята. Шушы хәлне инглиз, яисә итальян диңгезчесе күрсә, карар иде дә тыныч кына узып китәр иде. Совет диңгезчесе бит колхозда яисә социалистик шәһәрдә туып үскән. Аңа «все кругом колхозное — все кругом мое». «Русь» сүзе борынгы норманнар телендә «көймәче баскын»ны аңлата. Ушкуйниклыкның тамырлары менә кайларга, Киев каласының норманнар (варяглар) кулында булган чакларына барып тоташа. Совет чорында ушкуйникларны «несун» (күтәреп алып китүче) дип атап йөртә башладылар. Асылында ушкуйниклык та, несунлык та шул ук клиптомания авыруына, урлашмыйча, кеше өлешенә кермичә яши алмау хастасына барып тоташа. Димәк, психологик яктан норман баскыннары чорыннан буыннан-буынга тапшырылып килгән психологик сыйфатның бары тик исеме генә үзгәреп торган. Басып алу, талап-тартып алу, әсир-ганимәт итеп алу, колхоз чорында «күтәреп алып китү» — боларның барысы да бер үк гамәл — ушкуйниклык (диңгез юлбасарлыгы).

Япон йортлары арасындагы нейтраль зонага өеп куйган әйберләрне күреп кайткач, кичке чәйдән соң «бишенче почмак»ка җыелып диңгезчеләр бик озак бәхәсләштеләр. Бәхәснең темасы: «Хуҗасы бармы шул нейтраль ызанга өеп куйган әйберләрнең, әллә алар автомобиль каберлекләрендәге машиналар шикелле ташландыкмы?»

— Кирәкмәгәнгә шунда ыргытканнар инде аларны,— диде Валерий Суповецкий — яртылаш югары белемле электрик.

— «Ыргытканнар» булгач, ул әйберләр чүплекләрдә ятарга тиеш иде. Нигә соң алар ике йорт арасындагы ызанда? — диде минем якташым Петр Сидоров.

— Макакалар алар, самурайлар, шуңа күрә ызанда яталар. Чүплек башына илтеп ыргытыр өчен аларны биш машинага төяргә кирәк, бензин яндырырга, илткәч бушатырга. Ташландык нәрсәне илтеп йөргән өчен аларга кем эш хакы түли? Макакалар безнең шикелле бушка эшләргә күнекмәгәннәр, шуңа күрә ул әйберләр ызанда череп яталар. Алып киткәнне күрсәләр рәхмәт кенә әйтәчәкләр, күрерсез.— Моторист Непейводаның карары шушындый иде һәм шушы карар өстенлек алды. Икенче төнне японнарның ике йорт арасындагы ызанда яткан әйберләре бер-бер артлы безнең корабка күчеп килә башладылар. «Капитан Нугай» Япониядә эшләп чыгарылган тормыш-көнкүреш техникасының музеена әверелде. Тегү машиналары, бәйләм бәйли торган приборлар, микродулкынлы мичләр, ясалма климат аппаратлары, тагын әллә нәрсәләр. Кичә Непейвода мельхиордан ясалган бер нәрсәкәйне күтәреп кайткан. Борынгы мисырлылар табуты — сакофагка охшашлы нәрсә. Эченә кеше кереп ятарлык кына. Бик озак тикшерделәр. Бөтен кеше карап чыкты, ләкин нәрсәгә яраклы булуын ачыклый алмадылар. Бүген иртән докерлар эшкә килгәч, стивидорны чакырып сорадылар. Стивидор эчләрен уа-уа көлде. Непейвода алып кайткан нәрсә, чыннан да, гроб булып чыкты. Җитмешенче елларда бер мода чыккан иде. Имеш, киләсе гасырның галимнәре үлгән кешене терелтергә өйрәнәчәкләр. Галимнәр ярдәмендә терелеп теге дөньядан кире кайтырга теләүчеләрне, имеш, туңдырып күмәргә кирәк. Мәетнең тәнен кортлар ашап бетермәсен. Шул мода вакытында

японнар киләчәктә терелергә теләүчеләр өчен табутлар ясап чыгара башлаганнар. Ашыкканнар самурайлар. Мода тиз үткән! Киләчәктә теге дөньядан кире кайту мөмкинлеген онытканнар. Гроблар сатылмыйча калган. Шуларның берсен чүплек башыннан корабка Непейвода табып алып кайткан. Иптәшләре көлкегә күтәргәч, моторист табутны чыгарып ташлар, дип уйлаган идем. Ташламады:

— Әйбәт металлдан ясаганнар,— диде ул.— Хуҗалыкта андый нәрсә дә кирәк була. Кирәк булса, сатармын.

## 9

Узган төнне ушкуйниклар автомашиналар төзәтә торган эшханәнең ишек алдына җыелган автомобильләрне чишендерделәр. Бу хакта миңа доктор Потрасов сөйләгәч, барып күрәсем килде.

— Күрсәт әле миңа шул эшханәне,— дидем мин Олег Васильевичкә.

— Төне буе ташыдылар андагы әйберләрне. Анда хәзер Сталинград сугышыннан соң җимерекләр генә.

— Барыбер күрәсем килә. Әйдә, барып карыйк әле,— дидем мин.

Ялынып сорый торгач, докторны күндердем. Шәһәргә чыгып киттек. Машиналар төзәтә торган эшханә порттан шактый ерак иде. Челтәрле койма белән уратып алынган шактый иркен ишегалдында авариягә эләгеп имгәнгән машиналарны тутырганнар. Шактый яңалар. Япониядә җиңел машинаның гомере — сигез ел. Сигез ел тотканнан соң техосмотр үтү өчен шактый күп механизмнарны алыштырып яңаны куярга кирәк. Әгәр шул шартны үтәмәсәң, рөхсәт бирмиләр. Сигез елда исә машина модадан чыга, карт санала башлый. Шуңа өстәп, «тачка» хуҗасының социаль статусы да үзгәрә. Әйтик, ул хәзер эш хакын күбрәк ала башлый, балалары үсеп җитә, гаиләсе ишәя. Шунлыктан, сигез ел хезмәт иткән машинага күнегелгән булса да, ул аны ташларга тиеш. Искергән машинага яңа механизмнар алганчы яңа машина алу һәр яктан отышлырак. Менә шундый сигез яшькә җиткән «тимер ат»ны йә автомобиль каберлегенә илтеп ташлыйлар, яисә чиктән тыш арзан хакка совет диңгезчеләренә сатып җибәрәләр.

— Кичә бу урынны Җирән Остап тапты,— дип аңлатты доктор.— Төнлә ике тапкыр монда килеп киттеләр. Әнә, күрәсезме чалкай яткан кызыл машинаны? Кичә көндез мин караганда ул әнә теге аксыл зәңгәр машина өстендә иде. Тәгәрмәчләрен салдырып алганда шуышып төшкән булса кирәк. Әнә, машиналарның күбесе көпчәксез. Машинаның кузовын, моторын, утыргычларын алып булмый. Тәгәрмәчләрен салдырып алалар. Бик күп аккумулятор алып кайттылар, тормоз системасын, радиоалгычлар, магнитофоннар, һава чистарта торган фильтрлар, свечалар, әллә нәрсәләр. Безнең егетләр белән Ирина да барган иде, утыргычларга җәя торган затлы келәмнәр алып кайткан.

Безне күрепме, остаханәнең хуҗасы килеп чыкты. Яныбызга килә башлаган иде, кинәт туктады. Күз карашында шундый нәфрәт. Кашлары җимерек. Йодрыклар кысып йомарланган. Аңлый бит ул безнең ушкуйниклар корабындагы диңгезчеләр икәнлегебезне. Остаханәсен басучылар да без, совет моряклары, икәнлеген белә. Нигә соң полиция чакырмый? Нигә корабны килеп тентемиләр? Нигә төнлә саклап торып ушкуйникларның арт сабакларын укытмыйлар? Бу сорауларга дөрес җавап бирү өчен японнарны белергә кирәк. Алар пычранудан, дан чыгудан куркалар. Чит ил каракларын тоту белән полициягә белгертергә кирәк. Полиция шундук СССРның илчелегенә мөрәҗәгать итәчәк. Гауга шәһәр эчендә генә кала алмыйча, дөньяга таралачак. Шул гаугалы вакыйгага аша эш өчен җанын бирергә әзер бәндәнең даны чыгачак. Журналистлар килеп төпченә башлыйлар. Газета укучы бит ул талымсыз. Кем урлашкан? Кемнекен урлаганнар? Кем-кемне рәнҗеткән, кем-кемнән рәнҗегән — бу

мәсьәлә икенче урында, кулләгәдә кала. Беренче чиратта урлашу, талау. Шушы вакыйгага исеме эләккән кеше пычрана. Японнар пычранудан куркалар. Шуңа күрә инде менә ничәмә еллар аларны урыс совет ушкуйниклары талыйлар...

Убэ портыннан таң атканда кузгалып киттек. Порт белән саубуллашырга палубага чыктым. Яныма радиостанция начальнигы Шәрифуллин килеп туктады.

— Карагыз әле, Габдрахман абый,— Рәис миңа причалдагы җыйнак алюмин будкага төртеп күрсәтте. Будканың ишеген каерып ачканнар. Йозак сала торган элмәк умырылып чыккан. Будкада йөк төягәндә кирәк була торган ремонт кораллары саклана иде. Электордрельләр, электропычкылар, күтәреп йөрерлек җиңел, җыйнак электросварка аппараты. Төнлә шуларны урлаганнар.

— Мин, Габдрахман абый, кем урлаганын да беләм. Үтерсәләр дә әйтмим. Алардан капитан үзе дә курка. Безнең экипаждагы бандитлар пароходчылык җитәкчеләре белән бәйләнештә. Алар таможенникларны, кирәк булса милицияне, хәтта прокурорны да сатып алалар.

Кораб порттан чыкты. Убэ портының төркем-төркем торган алюмин торбалары һаман ерагаялар. Ниһаять, каланың төтен юллары офык артына кереп чумды. Тынлык урнашты. Өч тәүлек эчендә кинәт баеп киткән ушкуйниклар бәхетле минутларын кичерәләр иде. Корабка ташыган малны хуҗалары эзләп килмәделәр. Бәлки, ул әйберләр японнарга кирәк тә түгелдер. Алар бай бит. Советлар Союзында ушкуйниклар җыйган маллар ифрат кыйммәт.

Өч тәүлек японнар җирендә. Шушы өч түлек күзәтүдә минем күзем ачылды. Шушы җитмеш ике сәгатьне мин тарихыбызның чал бер чорында яшәп алдым. Идел Болгарстаны чоры иде бу. Федор Пестрый җитәкчелегендә килгән урыс ушкуйниклары Шәһри Болгарны талыйлар. Ташыйлар малны, көймәләре суга бата башлаганчы, төйиләр. Һәм Федор Пестрыйың ерак оныклары бүген дә шул ук эшне дәвам итәләр. Егерменче гасырның азагында, малны эшләп табар өчен шундый зур мөмкинлекләр ачкан чорда.

Колонизаторлар тырнагына эләккән халык бер без генә түгел. Азиядән, Африка илләреннән колонизаторларны куып җибәрделәр. Кууга иң кансыз, иң әшәке колониаль империя СССР да катнашты. Әмма татарларның язмышы Африка негрларыныкыннан аянычлырак. Без бүгенге сәяси ушкуйникларның дагалы итекләре астында яшибез.

## 10

Кабат диңгез кочагында без. Кораб ашыга. Диңгезчеләрнең төннәр буе ташландык әйберләр җыеп йөргән җиреннән тизрәк олагырга, еракларак китәргә, шул мәсхәрәле гамәлне тизрәк онытырга тырыша теплоход. Ул бит йөзәр өчен, давыллар белән көрәшер өчен, ерак кыйтгаларны мәрхәмәтле гамәлләр белән тоташтырыр өчен яралган. Киңлек чорнап алды корабны. Әнә, «Капитан Нугай»га акчарлаклар көтүе тагылды. Алар безне озатып киләләр. Күңелемдә газаплы сораулар. Нинди мәкерле көч, нинди каһәрле сәбәп мине шушы мәңге хәерче, мәңге кан коючы, мәңге туймас тамак империягә богаулап куйган? Кемгә бирим мин бу сорауларымны? Акчарлакларгамы?

Галәмдә Хакыйкатьне, ялганнан, Игелекне әшәкелектән аера белүче бер бөек Илаһи зат бар. Шул гына дөрес бәяли адәм балаларының гамәлләрен. Мин шуңа бирәм газаплы сорауларымны. Ул дәшми. Мин беләм — аңлый Ул.

Кораб салмак кына чайкала. Иллюминатордан диңгез җиле бәреп керә. Әйтерсең, мин кабат бишектә, әйтерсең чайкалу түгел бу, ә газиз әниемнең тирбәтүе. Тукта... Бишек җыры түгелме бу?

... Таныш төш иде бу. Мәгарәне хәтерләткән караңгы бер бушлык. Һава мине салмак кына алга таба суыра. Парашют белән самолеттан сикергәннән соң тоясың шушы халәтне. Аяк-кулларың белән тирә-якны капшап карыйсың. Бушлык. Кулларыңны сузып шул бушлыктан тотыныр нәрсә эзлисең. Юк бер нәрсә дә... Тирә-юньдә, өстә дә, аста да, бары тик ачык һава. Бушлык...

Ниһаять, алда тычкан уты шикелле генә бик зәгыйфь, бер яктылык күземә чалынды. Мин шуңа таба очам. Шул яктылыкны күргәч, күңел бераз тынычлангандай булып китте. Кышкы буранда адашып йөргәндә күренгән яктылык сиңа шулай җан өрә, көч кертеп җибәрә. Тукта, нинди тавыш бу?.. Җил сызгырамы, әллә кемдер әкрен генә, тавыш чыгармаска тырышып кына җир сузамы? Кеше тавышы иде бу. Кемдер мөнәҗәт әйтә. Әйе, мөнәҗәт. Тукта, әниемнең тавышы түгелме бу? Йотлыгып тыңлыйм. Сүзләрен аңларга тырышам...

Хәдисе Корьәннең ирлән гамәл кыйлмак иман әһле,
Рәхәт яшәр бу дөньяда хәмде әйтәм сиңа йаһу.
Хосусән ахирәт көнне котылыр мәңге газаптан,
Ирешер бакый рәхәткә, хәмде әйтәм сиңа йаху...

Әниемнең мөнәҗәтләре иде бу. Дөньяга килгән көннәрдән бирле таныш авазлар. Әле тереклек кенә чакта кеше булуга өндәгән тәрбияви бөек, изге сүзләр. Ай нурына охшашлы шәүләле сыек яктылык эченнән ак тукымага төренгән бер сын барлыкка килде. Ул да миңа таба якынлаша, мин дә әкрен генә очып баруымны дәвам итәм. Акка төренгән адәм затының битен күрергә, төсмерләргә тырышам. Битен дә, шәүләнең сынын да ак тукыма каплаган. Менә ул туктады, мине көтеп тора башлады. Мин дә килеп җиттем. Ерактан күрмәгәнмен икән — арабызда чыбылдык. Үтә күренмәле ефәк тукымага охшашлы юка бер пәрдә. Алга таба сузган кулларым барып тигәч кенә арабызның бүленүен аңлап алдым.

— Әнием, синме бу?

— Әйе, мин. Нишләп йөрисең монда адашып? Нигә туган авылыңа кайтып төпләнмисең?

— Адашып йөрмим мин, әнием. Монда үз иркемнән, үзем теләп килдем. Туган авылыма кайтып булмый шул.

— Нишләп булмый? Хатының җибәрмимени?

— Анысы да бар инде. Төп сәбәбе анда түгел. Туган авылыбыз минем бәләкәй чактагы син белгән авыл түгел инде. Кайтсам, анда яши алмам дип куркам.

— Нәрсәсеннән куркасың? Бәрәңге утырта алмам, мал асрарга көчем җитмәс дип куркасыңмени?

— Юк, аннан түгел. Соңгы кайтуымда җентекләп тикшереп йөрдем. Авылыбызның горурлыгы — чишмәбез чыкмый башлаган. Нефть эзләүчеләр чишмә тирәсендә җирне бораулап тишеп йөргәннәр. Шул чакта газиз чишмәбезнең тамырын тишеп үтергәннәр, күрәсең. Чыкмый хәзер чишмә, аның чылтырап аккан көмеш авазы мәңгегә тынып калган.

— Безнең Караярда бит башка чишмәләр дә бар. Авыл башыннан инешнең югары ягына барсаң, элеккеге буа янында ничә чишмә чыгып ята? Кайтырга теләмәвеңнең сәбәбе башкада түгелме?

— Дөрес, башка сәбәпләр дә бар, яшерә алмыйм. Эчкечеләр күбәйгән. Хатын-кызлар эчеп-исереп йөри башлаганнар. Шул хәлне күрү миңа шулкадәр авыр булды, гомер буе сагынып, җирсәп йөргән авылкаем өчен гарьләндем. Аннан соң авылны әрмән баскан.

— Нинди әрмән? Син әллә теге кумыкка охшаган җәнлек әрләнне «әрмән» дисеңме?

— Юк, мин ялгышмыйм, әнием. Әрмән — милләт ул. Син бит беләсең, милләтләрнең яхшысы-начары булмый. Әрмәннәр Кавказда үз җирләрендә яшиләр. Бик борынгы халык. Арада сәләтлеләрәге күп, галимнәре, шагыйрьләре, җыр чыгаручылары. Син теге дөньяга киткәч, әрмәннәр

безнең дин кардәшләребез әзериләрне канга батырып ташладылар. Кайбер авылларын, мәсәлән, Хаджалы аталган бер авылдагы барлык бала-чаганы, карт-корыны, хатын-кызны суеп чыктылар. Бер генә җан иясен дә калдырмыйча үтереп киттеләр.

— Безнең Караярда әрмәннәрнең ул ерткычлыкларын ишетмәделәрмени?

— Ишетсәләр дә әһәмият бирмәгәннәрдер. Анда хәзер битарафлык шул дәрәҗәгә җиткән ки, кайберәүләрне аракыдан башка бер нәрсә дә кызыксындырмый. Әрмәннәр ирләрне юри эчертәләр, хатын-кызларны пычратып йөриләр. Авылда эшсезләр арткан. Авылдашларга эшләгән өчен акчаны чеметеп кенә бирәләр, кай чакларда айлар буе акча бирмичә бушлай эшләтәләр, Әрмәннәргә исә акчаны кочагы белән өләшәләр. Хәзер инде алар безне кешегә дә санамый башладылар. Авылдашларыбыз әрмәннәр белән пычранган өчен хатыннарын тотып кыйныйлар, пычратучыларны кыйныйсы урынга. Хатыннары исә, әрмәннәрне чакырып ирләрен кыйнаталар. Шуңа барып җитте безнең авыл халкы.

— Председател юк мени хәзер? Райкум начальникларе кая карый? Бу бит инде бер Караярга гына түгел, тулысынча халкыбыз өчен бик тә әшәке, бик тә оят мәсхәрә. Дөресен сөйлисеңме соң син, улым?

— Сиңа ялган әйткәнем булдымени минем? Дөрес, авылда әле һаман әйбәт кешеләр юк түгел. Игелектә, итагатьле, дин тотып, шәригать кануннарында яшәүчеләр бөтенләй бетте дисәм, дөрес булмас иде. Күпчелек шул әрмәннәрнең олтырагына әверелде.

— Син боларның барысын да үз күзең белән күрдеңме соң? Нинди чара күрдең? Начальниклар белән сөйләштеңме бу турда? Гәҗиткә язарга кирәк иде шушы әшәкелекләр турында. Авыл картлары белән сөйләшергә кирәк иде.

— Шул начальниклар чакырып китерделәр инде әрмәннәрне. Начальникләргә әрмәннәр белән эш итү зур файда китерә. Аларга күпме акча түләгәнне халык белми.

— Мәчет картлары нәрсә карыйлар?

— Юк ул Караярда мәчет. Барлык күрше авыллар диярлек мәчет салып бетерделәр, Караярда мәчет урынына Кызыл Армиягә багышлап сын ясатып куйдылар. Шул сынның янында ут янып тора. Теге носариләрнең потлары астында янып торган лампада утын күргәнең булдымы синең?

— Юк, күргәнем булмады.

— Менә...

Тавыш каршымда басып торган ак шәүләгә килеп бәрелде: «У-у-у-оу-у...»

Кулымны сузып капшап карыйм. Каютамның стенасы... Әнә, иллюминатордан сыек яктылык саркып керә. Корабның иң көчле кыңгыравы аврал уйный. Кыңгырауның аяусыз шалтыравына өлкән штурманның тавышы кушылды:

— Команде аврал! Шватовому расписанию по местам стоять!

Киенеп палубага чыктым. Кораб Тиба портына кереп килә иде. Порттан каршыбызга, үзара ярышып, ике буксир ашыга. Әнә, сыек томан артыннан әкрен генә, кайберләре безгә туры карап, икенчеләре кырын-кырын, үзара узышып, корабка таба шәһәр йортлары, болытларга тиеп торган завод торбалары якынлаша. Бусы да Япония, өстәвенә җир йөзендәге «иң-иң-иң-иң... иң» үзенчәле башкала — Токионың чиге шушы портка килеп терәлә.

1988 елның кулланмасына карыйм. Токионың үзендә генә дә 12 миллионнан артык кеше яши. Башкала Канагава, Сайтама, Тиба шәһәрләрен инде тулысынча йотып бетергән. Шушы өч шәһәрдә яшәүчеләр килеп кушылгач, башкалада яшәүчеләр саны 30 миллионга килеп җиткән. Моның белән генә чикләнеп калмаган җир йөзендәге «иң-иң-иң-иң... иң» шәһәр. Токио култыгына урнашкан зур шәһәрләр Кавасаки белән

Йокогама»—башкалага тоташып беткәннәр. Аларны хәзер «йокы калалары» дип атап йөртә башладылар, чөнки башкаланың үзендә эшләүчеләр шушы шәһәрләрдә яшиләр. Әгәр Йокогама белән Кавасакида яшәүчеләр санын башкалага китереп кушсаң, Япониянең 125 миллион кешесенең яртысы шушы үзара укмашып беткән алты шәһәрдә яшәгәнлеге мәгълүм була. Гомумән, Япония турында язганда аның уңышларын исбатлау өчен санга, цифрга мөрәҗәгать итүдән сак булырга кирәк. Андагы күплек безнең Татарстаныбызны таптап торучы Рәсәйдәге күплеккә китереп тондыра, андагы муллык СССРдагы муллыкның касыгына бәрә.

Әнә, швартов бауларын ике катер ярга таба сөйрәп алып киттеләр. Иртәнге чәйне тизрәк эчеп чыгарга да берәр төрле җай табып, башкаларны карап кайту җаен хәл итәргә кирәк.

Аллаһы Тәгалә үзенең барлыгын, мин фәкыйрь турында даими кайгыртып торуын ничәмә тапкырлар исбатлаганы бар. Бүген менә үзенең барлыгын, бәндәләре турында туктаусыз кайгыртып торуын кабат белгертте. Капитан Гречаный белән кают-компаниядә сөйләшеп утырганда Тиба партының агенты Тэдзука-санның яныбызга килеп керүен, урыс теленә тәрҗемә итәргә игълан бирүен башкача ничек аңлатып булсын? Тәрҗемә, билгеле, миңа эләкте. Тәрҗемә өчен түләнгән илле доллар да минем кесәмә керде.

— Баш тартмыйм,—дидем мин Тэдзука-санга.— Токио шәһәренә барыр өчен каян акча табарга дип баш ватып утыра идем.

— Мин сезне машина белән илтә алам,—диде агент япончa елмаеп.— Сәгать ничәдә машина җибәрергә?

— Юк, рәхмәт,—дидем мин татарча елмаеп.— Мин җәяү йөрергә, күргән нәрсәләремне кулым белән капшап карарга яратам. Машинада йөргәндә бер нәрсәне дә юньләп күреп булмый.

— Барганда юньләп күренмәс, туктап карарга кирәктер. Мин шулай уйлыйм,—диде агент тагын да җылырак, мөлаемрак елмаеп. Мин аңа кабат татарча елмаеп җавап бирдем. Каршыңда көзге булмагач, елмаюымның балкышын күрүдән мәхрүм идем. Шулай да аңладым: японнар безгә караганда матуррак елмая беләләр иде. Бу инде табигый. Татар тарихында елмайтырлык вакыйгалар чиктән тыш сирәк, җылытырлыклары, йөрәк ярырлыклары, киресенчә, биниһая. Бәлки, киләчәк, әгәр без мөстәкыйльлеккә ирешә алсак, елмаю мизгелләрен бүләк итәр әле?

Тәрҗемә белән шөгыльләнгән арада доктор Потресов шәһәргә чыгып киткән. Шәрифуллин корабтан чыга алмый—пароходчылыктан сводка аласы бар. Башкаларга ялынып тормадым, барыбер чабата туздырып йөрүдән баш тартачаклар. «Нигә кирәк ул Токио? Аны бит барыбер күтәреп пароходка алып кайтып булмый...» Кычкырып әйтмәсәләр дә, күңелләрендәге җавап шундый булачак.

Аллага тапшырдым. Бер үзем китәм—буленгәнне бүре ашаса да. Шәһәргә чыгу өчен киенү дә җитә. Сәяхәткә баручы һәр очракта экипировка дигән нәрсәне онытмаска тиеш. Ботинкам кысмый, Аллага шөкер. Дөрес, шактый иске. Иске дуслар һәм иске аяк киеме—менә кемгә ышанырга була. Чалбар алама түгел. Свитер—әнием эрләгән йоннан, Хозыр-Ильяска тиң юлдаш була алырлык. Башымда—берет. Де Голь, маршал Монтгомери нәкъ шушындый берет кияләр иде. Марсель портында алган идем, җил-яңгырдан саклый башымны. Ике телем ипи салдым кесәмә. Кульяулыкка төреп. Ипекәйсез кем юлга чыга? Көзгекаршына килдем. Елмайдым. Юк, барыбер японнарча елмаеп булмый. Күнегелмәгән. Шулай да елмаюны да алдым. «Таң иле»ндә бит мин. Елмаю—бу илдә мандат та, пропуск та, паспорт та. «Үзгәртеп кору...», «Комплекслы тәрбия бирү...», «Яңача фикер йөртергә өйрәнү (новое мышление)». Бүгенге «Немытая Россия»не (Лермонтов сүзе) иң беренче чиратта. Петр Беренче ысулында, мылтык түтәсе белән кыйнап, елмаерга өйрәтергә кирәк иде. Өйрәнгәннәрдән сынау (госэкзамен) алу өчен япон-

нарны чакырырга. Менә кайдан башларга кирәк булган СССРдагы «үзгәртеп кору»ны!

Бисмиллаһи...

Трапны матрос Петренко саклый иде. Шул булса кирәк. Әллә Сергеенко инде? Җирән Остап белән Кузьмичтән башкаларын бутыйм, чөнки барысы да нәкъ бер төсле сүгенәләр, киемнәре дә гел бер төрле.

— Сез, Габдрахман Бакирович, компьютерның төзекме, түгелме икәнлеген тикшерә беләсезме?

— Әллә компьютер алып кайттыгызмы?

— Сез алып кайтмадыгызмени?

— На какие шиши?

— Әнә, порттан чыккач йөз генә метр. Өелеп ята. Непейвода белән Хитрый Әрмән бишенчесенә киттеләр.

Бәлки, чыннан да, компьютер алып кайтырга кирәктер? Мин бит барыбер Токионы күтәреп алып кайта алмаячакмын. Юк, алачакмын. Күтәреп түгел. Билгеле, күңелемә тутырып. Токионың сурәтләрен хәтеремә яшереп алып кайтачакмын. Алла боерса...

Тибаның вокзалы портка якын булып чыкты. Аның кайда икәнлеген сорап та тормадым, порт эченә кергән рельслар буйлап шәһәргә таба юл тоттым. Як-якта тигезләп киселгән тәбәнәк куаклар. Японнарны чисталыкка табына торган халык дип атап йөртсәләр дә, монда да җитәрлек иде. Вокзалга барып җиткәнче куак астына ташлаган дистәдән артык мотоцикл, берничә мотороллер, ике-өч дистә велосипед күреп алдым. Ташландык магнитофоннар, минем аягымдагыдан яңарак та, затлырак та аяк киемнәре дә мине озатып калдылар. Диңгезчеләрнең ушкуйниклыкларын тәнкыйтьләргә бераз ашыкканмын икән. Минем үземдә дә юл буенда аунап яткан велосипедны торгызасы, шуңа утырып корабка кайтасы килү шактый көчле иде. Үземне җиңдем.

Ниһаять, вокзал. Яшькелт таштан салган көрән чирәп түбәле җыйнак кына бина. Пыяла ишек үзеннән-үзе ачылды. Мәскәүнең кайбер аптекаларында очрый мондый чисталык. Ишек тоткалары, касса каршындагы турникетлар, уң як стенага тезеп куйган уен автоматлары — барсы да нур таратып, балкып торалар иде. Бина буш. Кассир кыз елмаеп каршы алды.

— Бер билет. Токиога кадәр,— дидем, илле долларымны касса аппараты янындагы чынаяк тартмага салып.

— Сибуя? Синдзюку? Тиба-Токио-Тиба?

Бер тын җилкәне кашып торгач, «Синдзюку» сүзен көч-хәл белән авызымнан сыгып чыгардым. Шуңа «Тиба-Токио-Тиба» сүзләрен өстәдем. Касса аппараты, бал корты тавышы чыгарып, әз генә выжылдап алды. Кулымда кош теле чаклы гына зәңгәр каты кәгазь һәм 17 мең япон акчасы — иена. Перронга чыгып, поезд көтә башладым. Монда да Аурупа илләрендәгечә икән — поезд килергә биш минут кала халык җыела башлады. Рәсәй чынбарлыгында вакыт дигән нәрсә, нәкъ адәм баласының көче, аның таланты, сәләте шикелле бер тиен тормый. Шуңа күрә, вокзалларга поезд килер алдыннан, ким дигәндә ярты сәгать алдан җыелалар. Эшкә дә шулай. Аермасы шунда, эшкә алданрак та, соңгарак та калып килергә була, чөнки эш бит ул поезд түгел — беркая китми, бер урында гына тора.

Ниһаять, поезд килде. Кишер төсле аксыл-саргылтка буяганнар. Кереп утырдым. Вагон идәнендә бер генә тәмәке төпчеге, сыңар гына төкерек, олтаннан кубып калган бер мәте булса икән! Кая төкерәләр икән бу японнар? Әллә аларның авызларында төкерек юкмы? Мин дә бит Мәскәүдән бакчама электричкага утырып йөрим. Идәнгә әһәмият бирмим. Утыргычларга да. Дөрес, кайбер утыргычларны ярып, эчендәге поролонын алган булалар. Урын булмаганда андый урынга утырасың инде, нишлисең бит... Ә менә Мәскәү вокзалларыннан төрле якка йөрүче электричкаларның тәрәзәләре пычрак булуы барганда ак каеннарның,

мәгъруур иманнарнең күренмәве — бусына мин күнегә алмам инде. Беркайчан да күнегә алмам. Япон вагонының тәрәзәсендә пыяла юк шикелле иде. Капшап карадым. Бар икән...

Каршымда япон кызы. Бәлки, ялгыша торганмындыр? Күзәтеп йөрим, монда илле яшьлек хатынны егерме яшьлек кыздан аеруы шактый катлаулы. Японнарның җәлпәк битләренә җыерчык чыкмый. Алар нишләптер юанаймыйлар да, корсак та үстермиләр. Әллә гел ашамыйча, ач яшиләр инде? Белмәссең... Кызның тезендәге ап-ак талчыбыктан үргән кәрзиннән башын тыгып көчек баласы миңа карап утыра. Минем янымда утырган японга карамый. Көчеккә чит ил кешесе кызык тоела, күрәсең...

Бездәге (СССРдагыны «бездәге» дим инде) электричкаларда вагон эчендәге барлык кеше уч төбендәгедәй күренеп тора. Япон вагоны аерым купеләргә бүлгәләнгән. Без дүртәү. Бер-берең әякынрак утырсаң, алты да, хәтта сигез кеше дә сыярлык аерым бүлек. Миңа янәшә бер каршы якта — икенче ир. Икесендә дә карасу-соргылт җилетлы яңа костюм, зәңгәр күлмәк, акка зәңгәр борчак төшкән затлы галстуклар. Костюмнарында бер генә җыерчык, бер генә салынкы җир булсын икән! Тезләрендә атташекейс, битләрендә елмаю. Киенә белүнең бер сере бар: чамадан тыш пөхтәлек адәм баласын затлы карачкыга, балавыз сыннар музеендагы экспонатка әверелдерә. Киемдә тырнак очы хәтле булса да кимчелек булырга тиеш. Шул очракта гына ул синә хезмәт итә.

Күршеләремнең костюмнарын «тикшергән» арада поезд вокзалга килеп тә җитте.

## 12

Вокзал түгел иде бу. Иге-чиге булмаган бер универмаг. Муеннарына тартма асып җаның теләгәнне сатып йөрүче кырык тартмалылар әрле-бирле йөриләр. Иге-чиге булмаган товарлар арасында киосклар, лавкалар, белешмә будкалары, постта торучы полицейскийлар, дулкын-дулкын булып өскә, пыяла түбәгә үрмәләгән гөлбакчалар. Адым саен кафе, пиво саталар, балалар уйный торган җыйнак мәйданчыклар. Пассажирларны ишеккә махсус дөмбәсләп тутырып торучылар ярдәмендә шыгрымланган поездлар «йокы шәһәрләре» Йокагама, Кавасакига кеше ташыйлар. Дүрт тимер юл, берничә метро тармагы, дистәләгән автобус маршрутлары Синдзюкуга көн саен 2,7 миллион кеше ташый.

Минем авылдан киткәнемә ярты гасыр. Яшәгән җирем — башкала. Синдзюку вокзалында мин авылдан килеп беренче тапкыр паровоз күргән юеш борынлы чабаталы малай шикелле югалып калдым. Кайнап тора иде монда кеше боткасы. Туздырылган кырмыска оясын хәтерләтә иде бу вокзал. Белмим, нигә аска төшеп киткәнмендер? Ярты сәгать чамасы җир асты гаражларында адашып йөргәннән соң өскә менә башладым. Юк, җәяү менгәндә бер тәүлек эчендә дә менеп җитәрлек түгел иде. Мин лифт эзләп таптым һәм, биш минут үттеме икән, болытларга тиеп торган яссы түбәгә утырткан бакчаның агачлары арасында идем инде. Калкурак җирне сайлап алдым да японнарның изге тавы Фудзияманы эзләргә тотындым. Ул моннан караганда төньяк-көнбатыштарак булырга тиеш иде. Юк, күренмәде. Шәһәр өстендә соргылт томан — машиналар өргән газлар, меңләгән завод торбаларыннан бөркелгән чистартылган төтен эленеп тора иде. Тирә-юнь чакыра сине. Кер, коч шуларны, ал теләгәнеңне, син бит бу дөньяда бер генә яшисең!.. Яшәеш кыска. Гомер тиз үтә. Ләззәтлән. Шәрә хатын тәне — бармы бу дөньяда аннан да көчле хозурлык?

Тизрәк качарга, таярга кирәк моннан. Кире якка борылдым. Ләкин мин тар, кысынкы тыкрыклар лабиринтында адашкан идем инде. Берберсенә янәшә диярлек урнашкан ак ишекләр. Һәр ишек янында беләк мускулларын биетеп, керпе чәчле яшь егетләр басып тора. Су чапыл-

даган, вәсвәсәле итеп хатын-кыз көлгән, чыелдаган тавышлар ишетелеп китә. Исемә Гамбург порты, портка янәшә урнашкан гөнаһ кварталы — Реепербанн (диңгезчеләр телендә «Триппербанн») килеп төште. Монда секс бизнесе японнарга хас нечкәлек белән, сәнгати бизәкләргә төренгән иде.

Ниһаять, кечкенә генә мәйданчыкка килеп чыктым. Ике дистәгә якын кинотеатрның ишекләре чыга иде шушы мәйданга. Стеналарга ябыштырылган рекламаларда шул ук шәрә тәннәр, женси көчәнүләр. Мәйданда «ауга» чыккан яшь җарияләр үтеп баручыларны ымсындырып йөриләр.

Мин урамнан агылучы ташкынга каршы бара башладым. Бераздан тагын бер мәйданга килеп чыктым. Мәйдан уртасында җиздән ясалган эт сыны басып тора иде. Бу эт турында укыган идем. Хати исемле этнең хуҗасы эштән кайткан чакта юлда йөрәге ярылып үлә. Хати хуҗасын һәр көнне вокзалга килеп каршы ала торган булган. Хуҗасы вафат булган көнне төнгә кадәр көтеп утырган да кайтып киткән. Икенче көнне тагын хуҗасы эштән кайта торган минутта вокзалга килгән. Ун ел буена һәр кичне бер үк вакытта хуҗасын каршыларга килеп йөргән тугрылыклы Хати. Мескен этне кемнәр генә ияләштерергә, үзләренеке итәргә тырышып карамаганнар. Хуҗасын каршыларга соңгы килүендә, ниһаять, этнең дә йөрәге чыдамаган. Эт үлгән урынга японнар шушы җиз сынны утыртып куйганнар. Ялгышмасам, бу — юбашкаларның яшьләре җыела торган урын иде.

Чыннан да, гел унҗиде белән егерме биш арасындагылар кайнаша иде бу төбәктә. Көләч йөзләр, көмеш кыңгырау тавышлары чыгарып яңгыравыклы көлүләр. Үземнең дә кәефем күтәрелеп китте. Яшьләр төркем-төркем җыелып сөйләшәләр, кофе эчәләр. Безнең татарның сабантуен хәтерләтә. Әгәр безнең милли бәйрәмнән картларны куып җибәреп, партия хакимияте чорында гадәткә кергән көчләп оештыруны алып ыргытып үзара, күңелләр үзара тоташып беркөне генә калдырсаң, бездә дә бәйрәм итү кире борынгы сыйфатына кайтыр иде. Авыз ачып карап йөри торган җыен гына түгел, һәркем үзе белән алып чыккан, йөрәгендә кайнап ярсыта, илһам бирә торган бәйрәм иде бу.

## 13

Мин, ниһаять, аңладым: япон яшьләре җыела торган урын — Сибуя иде бу. Яшьләр тормышын, аларның зәвыкларын, көн уздыруларын япон язучысы Танака сурәтләп күрсәтте. Бу язучының «Пыялага әверелүчеләр» («хрустальгә әйләнеп беткәннәр» дип тәрҗемә кылу дөресрәк булыр иде) дигән китабы бик күп чит ил телләренә тәрҗемә ителде. «Пыялаланган» яшьләрнең күбесе — икътисади күтәрелеш елларында баеп китүчеләрнең балалары. Әти акчасына иң соңгы модадагы машина сатып алу, өскә гел чит илдә тегелгән кием киеп йөрү, китап урынына комикс уку, иң беренче булып Голливуд боевигын күреп өлгерү, вакытны рестораннан-ресторанга, бер түшәктән икенче түшәккә күчеп йөреп уздыру, жаргон телендә сөйләшү, ниһаять, сәясәткә, тормыш-көнкүрешкә тулысынча битарафлык — «Пыялаланып беткән» яшьләрнең яшәү кануннары шуннан гыйбарәт. Пыяла бит үзе яктыртмый, яктылыкны чагылдыра гына. Язучы Танаканың китабында сурәтләнгән яшьләр нәкъ шундыйлар. Аларны танырга миңа әдәбият ярдәм итте.

Тагын бер төркем янымнан үтеп бара. Болары бөтенләй башка төрле иде. Кызларның өсләрендә күзеңнең явын алырлык чуар кием, аякларында «адидас»ның иң соңгы модасы. Битләрдә елмаю. Елмаюы гына күренә, кашлар, керфекләр, бит алмалары буяу астында калып югалган. Үзләре суытма ашыйлар. «Ашыйлар» сүзе аңлата аламы икән кызларның суытма суыру ләззәте эченә кереп эреп бетүләрен? Менә, дәррәү көлә

башладылар. Хәзер алар көлүгә әверелеп беттеләр. Японнармы соң болар? Алар бит, гадәттә, пышылдап диярлек кенә сөйләшәләр. Кая соң боларда япон тыйнаклыгы? Танаканың китабын кабат исемә төшерергә тырышам. Тукта әле... «Пыялаланып беткәннәр»дән тыш, Танака башка төркемнәрне дә искә ала. Әйе, болары — «бурикко», мәктәпне бетергәннән соң вузга керә алмаган, эшкә урнашып өлгермәгән, кияүгә эзләп йөрүче яшь кызлар төркеме. «Бурикко»ны японнар «егерме плюс-минус дүрт» тә дип атап йөртәләр.

Көнбатыш өйләнүне, кияүгә чыгуны мәҗбүри санамый. Европа илләрендә шактый гына хатын-кыз һәм ир-ат гомерләрен ялгызлыкта үткәрәләр. Ялгыз дип ялгыш әйттем — гаилә кормыйча, теләгән кешесе белән очрашып, дуслашып, якынаеп... Япон кызы кияүгә чыгарга тиеш. «Таң кояшы» илендә гаиләсез яшәү яшәүгә саналмый. Кешелек сыйфатлары, гореф-гадәтләр бары тик гаилә шартларында гына саклана, дип ышана японнар. Бала үстерү бит ул чиктән тыш җаваплы вазифа. Бала үстерү ул киләчәк буынны тәрбияләү. Японнарда гаилә кануннары искиткеч катгый. Аларны гаилә тәрбияли. Хезмәт коллективы, җәмгыятьтәге яшәү кануннары японнарда гаиләдә тәрбияләнә. Япон, әгәр аны башка дәүләтләр белән чагыштырсаң, 120 миллион бердәм әгъзадан торган зур бер гаилә. Шуңа күрә кияүгә чыгу, өйләнү — ир хатыны булу, хатын ире булу чиктәш тыш җаваплы, катгый кануннарга буйсынган вазифа. Нәкъ менә шуңа күрә «бурикко» кияүгә чыкканчы күңел ачып, иректә ләззәтләнеп калырга ашыга.

Кызларга гына түгел, егетләргә дә — гаиләнең һәр әгъзасына семьяның катгый законнарын тайпылгысыз үтәп бару зарур. Ир гаиләнең иминлеген саклый, мал таба. Хатын гаилә учагының җылылыгын саклый, яшәү өчен иң кулай, иң рәхәт шартлар тудырып тора. Картларның вазифалары искиткеч җаваплы. Алар яшь буынга гореф-гадәтләрне, борынгыдан килгән яшәеш кануннарын тапшырып, шуларның төгәл үтәлешен тикшереп торалар. Белмим, тагын нинди халыкларда бар икән мондый җаваплылык? Японнар гаилә тормышына җиңел карый белмиләр.

Гаиләдәге иң җаваплы эш — бала тәрбияләү. Баланы биш яшькә кадәр сөяләр, назлыйлар. Ул нәрсә тели, шуны бирәләр, нәрсә сорый — алалар. Тыймыйлар баланы. Бишкә кадәр бала ирекнең нәрсә икәнлеген тоярга тиеш. Ирек тоймаган, ирек яратмаган кеше шәхеслеккә ирешә алмый. Биш яшькә кадәр бала сорый икән — баш өсте: тели икән — вата, көйсезләнә икән — рәхим ит. Син ирекле, син бар нәрсәне дә татырга, кичерергә тиеш. Мөстәкыйльлек тәрбиясе шушы шартларда башлана. Сөю, назлау — без баланы аздырудан куркабыз. Японнар курыкмыйлар. Бу фикер безгә урыстан йокkандыр дип уйлыйм мин. Урыс солдат тәрбияли. Буйсыну беренче урында... Сөю, назлау, яратуны даими белгертеп тору сабыйның рухи дөньясын киңәйтү, ихтирам әлифбасына өйрәтү аның башкаларга кирәклелеген, кадерле булуын аңлату, аңына җиткерү өчен кулланыла. Биш тулгач, таләпләр үзгәрә. Ул хәзер җәмгыять кануннарына буйсынырга тиеш. Тәртипле булу, өлкәннәрне ихтирам итү, аларның сүзен тыңлау, көче җиткән кадәр гаиләнең иминлегенә өлеш кертү — биш яшьтән узган балага куелган шушы таләпләр тайпылгысыз үтәлеп барырга тиеш. Таләпләр сүздә генә калмый. Япон кешесе буйсына да белә, буйсындыруда ул каты куллы. Ул беркайчан да максатына ирешмичә туктамый. Ә инде ун яшькә җиткән балага бернинди ташлама бирелми. Өлкәннәргә нинди таләпләр куелса, аларга да шундый ук таләпләр. Ул хәзер тулы хокуклы гражданин, хәзер ул семья эшенең берсеннән дә читкә тайпылып кала алмый. Кадими чорда татарда да баланы нәкъ шушы ысулда тәрбияләгәннәрдер. Без бит советлашу дәверендә урыслаштык.

Татар хатыннарын ике нәрсә аздырды. Шуның берсе, революциядән соң «хатыннар ирләр белән тигез» хокуклы булырга тиеш дигән пробле-

маны юридик өлкәдән аерып, эш, хезмәт өлкәсендә куллану. Тигезлек көрәше нәтиҗәдә иң кара, иң авыр эшкә хатын-кызны җигеп куйды. Икенче ялгышлык — татар тормыш-көнкүрешендә урыс гореф-гадәтләре өстенлек алуы. Урыс гасырлар буе сугышты. Ирләр яуда, басып алуда. Хуҗалык — хатын-кыз җилкәсендә. Менә шушы шартларда марҗа ир хатыны булуга, гаилә җылылыгын саклауга, бала тәрбияләргә юнәлтә алмыйча, әкренләп ирдәүкәләнеп бетте. Японнар күп гасырлар үзләренең атауларына бикләнеп яшәделәр. Башка илләр белән аралашу 1853 елда Йокагама ярларына коммодор Перри Америка флагы астында йөзүче эскадраны алып килеп тупка тота башлаганнан соң гына җайга салынды. Бүгенге көндә, башка илләр белән гаҗәп тыгыз аралашучы Япониядә кадими гореф-гадәтләр гаҗәп төгәл сакланган.

Японка — иң беренче чиратта ир хатыны. Америка язучысы (исеме онытылган) бер японның бизнес өлкәсендә партнеры белән сатулашуы турында сөйли. Бизнесмен ара-тирә читтә, бер почмакта сүзгә катнашмыйча гына утырган хатынына күз сирпеп ала, дип яза американы. Килешергә кирәк икәнлеген белгертеп, хатыны сиздермичә генә ымлап ала, килешмәскә тиешлеген күрсәткәндә башын селки. Хакны күтәрергә кирәк чакта бармакларын өскә таба күтәрә, төшерергә кирәклекне аска таба бөгелгән бармаклар белән күрсәтә. Килешү тәмамлану белән япон хатыны кухняга кереп чәй әзерли башлады, дип яза Америка язучысы. Димәк, бу илдә хатын-кыздан тыйнаклык, иренең абруен саклый белү, житәкчелек кылган очракта да иренең гаиләдә хуҗа булуын, аның ирегетлегенә җил-яңгыр тидермәү таләп ителә. Японнарда «тройка белән кайту» дип аталган бер мәзәк гадәт яшәп килә. Ир кеше теге «түләүле мәхәббәт» йортында кирәгеннән артык исереп, чамадан тыш изрәп киткән очракта хуҗа хатын аны озатырга ике проституткаңы җибәрә. Алар ирне өенә хәтле култыклап илтәләр дә хатынына тапшыралар. Япон гадәте буенча, хуҗабикә аларны якты йөз белән каршы алырга, чәй эчереп җибәрергә тиеш. Әйе, хатын җарияләрне шулай хөрмәтләп озатырга тиеш. Бу гамәл иренең чын ир булуын, үз йортында хуҗа икәнлеген исбатлау өчен кирәк. Теге хатыннар киткәч, хуҗабикәнең иренә карата нинди чаралар күрүе, нинди җәза бирүе — бусы инде аның үз эше. Бәлки ул аны икенче көнне үк өеннән куып чыгарыр, кем белә? Ә кеше алдында ире шушындый җинаять эш башкарган очракта да хур итәргә, аның абруена кагылырга япон хатыны җөрьәт итә алмый.

Менә шушындый җаваплы эшкә тотыныр алдыннан, ягъни кияүгә чыкканчы, япон кызы иркенлекне татып калырга тиеш. «Бурикко» аталган төркем шундыйлардан тора. Алар күңел ачалар. Туйганчы суытма ашыйлар, кино карыйлар, арзанлы кафеларга кереп тукланып чыгалар. Нәкъ бездәге шикелле, аларның да яраткан артистлары, баш игән җырчылары, кумирлары бар, шуларга табынып ләззәтләнәләр. Ә инде кияүгә чыккач, мондый мавыгуларга урын калмаячак. Япон хуҗабикәсенә карата таләпләр чиктән тыш катгый, чиктән тыш кырыс. Кияүгә чыккач, ул картаеп үлгәнче гаилә учагын җылытып, ирен карап, балаларын тәрбияләп яшәргә мәҗбүр булачак. Японнарның катгый, тайпылгысыз үтәлергә тиешле бер кануннары бар. Бу канун — гаилә иминлеген туктаусыз кайгыртып тору. Юк, хатын вә балалар белән генә чикләнеп калмый бу кайгырту. Япониядә һәр җәмгыять берәмлеге — шул ук гаилә. Урыс матрешкасын күрмәгән кеше дә юктыр? Япония нәкъ шул матрешканы хәтерләтә. Иң тышкысы — дәүләт, аның эчендә утрауның берсе, утрауны ачкач өлкә килеп чыга, өлкә карнында — шәһәр, шәһәрдә аерым сәнагать берәмлеге, аның эчендә цех, иң үзәктә шуларның барысына да җан өреп, системаның иминлеген саклап торучы төп, үзәк берәмлек — гаилә. Бу схеманы мин аңлаешлы булсын өчен генә тезеп күрсәттем. Бу илдә җәмгыять төзелеше шундый тоташ, үзара нык береккән. Аларны берберсеннән кубарып алып булмас та иде. Рәсәйдәге шикелле җае чыгу белән аерылып китәргә өметләнеп яшәгән милли автономияләр юк анда.

һәм Япониянең бары тик бер генә милләттән торуы үзе бер көч, зур таяныч. Шушы үзара нык, ышанычлы береккән тоташ гаиләнең җаны — япон хатыны. Ул эшчән. Ул тыйнак. Ул семья мәсьәләсендә чиктән тыш җаваплы һәм кайгыртучан. «Таң кояшы иле»ндәге хатын иренә: «Я тебе сказала!», «Сам дурак!» — дип бүксә киереп кычкыруны күз алдына да китерә алмый. Ничек инде гаилә башлыгына, ир кешегә шул сүзләрне әйтеп булсын? Әйткәч, ничек шундый ир белән яшәп булсын? Хатыныннан шундый сүз ишетергә лаек ир — юк, япон хатыны мондый хәлнең булуына ышана алмаячак...

Фәлсәфәбезне тәмамлап, Токионың Сибуя мәхәлләсенә, «бурикко» кызлар янына кайтыйк...

## 14

Уналты белән егерме дүрт яшь арасында япон кызы үз иркендә яшәп кала ала. «Ирек» сүзен һәр халык үзенчә аңлый. Урыска бу сүз ни теләсәм, шуны эшлим, пошли вы на... мәгънәсендә аңлашыла. Татар инде «ирек» сүзенең мәгънәсен дә онытып бетергән. Хәтта аның тәме дә югалып өлгергән. Иң зур афәте, куркынычы шунда ки — без инде ирекка омтылмыйбыз да, ирекнең нәрсә икәнлеген белергә дә теләмибез. Без үзебезнең кол булып яшәвебезгә канәгать һәм шул канәгатьлеккә теш-тырнак белән ябышканбыз. Ирекка чыксак, безнең хакта кем кайгыртыр, Алла сакласын, ачка үлеп бетәрбез, дип куркабыз без. Җир каның, нефтебезне суыртып алып китүләре дә безгә табигый тоела. Күнеккәнбез.

Японнар исә чиктән тыш милләтчел халык. Аларның гореф-гадәтләренә җил-яңгыр тимәгән. Дин исән, көчле. Дин һәм гореф-гадәтләр тормышның җанын, иманын тәшкил итәләр. Җан һәм иман иминлеге. Менә шушы шартларда ят милләт японнар арасында үзенчә яши алмый. Ул йә японлаша, яисә моннан китә.

Янымнан узган «бурикко» төркеме икегә бүленде дә янәшә урнашкан ике концерт залының икесенә таба агылды. Мин юлымны дәвам иттем. Каршымда бакча. Челтәрле тимер койма эчендә бары тик «Таң кояшы иле»ндә генә очрый торган тәрбияле агачлар. Мине башта паркның коймасы җәлеп итте. Чуеннан коелган матур челтәр. Безнең Баулыга да электе андый чуен челтәрләр. Ләкин культурасызлык, зәвык булмау, каныбызга сеңгән «совок»лык катнаш манкортлык чуен рәшәткәләрне ал һәм ак төскә буятты. Искиткеч килбәтсезләнде алга буялган чуен. Монда чуенны ком белән шомартып ялтыратканнар да тигез итеп лакка катырганнар. Исләрең китәрлек матур күренә койма. Бигрәк тә яшел ылыслар, чия-көрән яфраклар янәшәсендә.

Токио каласының картасын сатып алмыйча мин зур ялгышлык эшләгәнмен икән. Күз яшенә тиң валютаны саклап тотмакчы идем. Берәр искә алырлык сувенирга җитмәсме дип сакладым инде. Дөрес, Тиба шәһәреннән Токиога бару һәм кайту өчен бергә алып бераз экономия ясадым. Һәр урам чатлыгында меңләгән ымсындыргыч сувенирлар белән юл йөрү кулланмасы (путеводитель) саталар иде. Арзанлырагын сайлап алдым. Калган акчам нәрсәгә җитәр икән? Юк, баемыйча торып, мин башкача Япониягә килмәм. Баю мөмкинлеген миңа Аллаһы Тәгалә бирмәгән. Димәк, минем монда соңгы килүем. Әйе, соңгы. Ә күпме соң ул бездә Японияне күрүчеләр?

Ниһаять, картадан торган урынымны эзләп таптым. Йойоги аталган парк иде бу. Император Мэйдзи (японнарның Петр Беренчеләре) сараеның бакчасы шушы паркка килеп терәлә иде. Тукта әле, бу бит дөнья күләмендә данлыклы бакча. Императорга бүләк итеп японнарның барлык атауларыннан иң матур агачларын шушы бакчага китереп утыртканнар. Монда «Таң кояшы иле»ндәге иң матур хризантемаларны (татарчасы кайчандыр булган, билгеле, хәзер онытылган) җыеп күргәзмә ясый-

лар. Гомумән, Мәйдзи гыйбадәтханәсенең бакчасындагы чәчәкләрне күрер өчен генә дә монда җир шарының иң ерак почмакларыннан киләләр. Мин инде шул бакчаны, император сараен, андагы мәшһүр гыйбадәтханәне карарга җыенган идем. Агымны полицейский туктатты. Парк коймасы буеннан узган асфальт юлны кешеләрдән әрчергә тотындылар. Шоссе бушау белән шул урынга өсләренә кара күн куртка, кара күн чалбар кигән, чәчләрен чигәләреннән кырып алып, баш түбәсендә керпеләнеп торган юл калдырган егетләр ургылды. Аларга ияреп ботларын кысып торган алсу чалбар, зәңгәр чәчәкләр төшкән киң блузка кигән кызлар полиция әрчегән урынга агылдылар. Унар-унбишәр кешедән торган төркемнәргә бүленгән иделәр бу сәер бәндәләр. Барысы да яшьләр, кыланышлары шундый, әйтерсең, психик атакага баралар.

Һәр төркем үз магнитофонын алып килгән иде. Зур, тавышы ераклар-га яңгырый торган көчле магнитофоннар. Фәрман яңгырады. Магнитофоннар уйный башлады, елкылдап торган күн киемгә төренгән егетләр, Борынгы Рим гладиаторларына охшап, хәрәкәткә килделәр. Мәйданда минем яшьлегем музыкасы рок-н-ролл яңгырый иде. Һәр магнитофонның үз көе, һәр төркем үзенчә бии, ләкин бер-берсен басарга, үзара ярышырга җыенмадылар.

## 15

Кинәт Мәскәүдәге Измаил паркы, андагы татарлар җыела торган мәйдан, шушындагы кебек әллә ничә дистә төркем, һәрберсе үз көенә, үзенчә биеп күңел ачулар искә төште. Измаил паркына туган җирләрен сагынып җирсегән татар яшьләре җыела иде. Сугыштан соң Мәскәүдә төзелеш башлангач кара, авыр эшкә Татарстаннан татар яшьләрен ташыдылар. Бу эш татар милләтен «сыеклау», тоташ татарлар яшәгән җиргә төрле төбәкләрдән әтрәкәләм туплау максаты белән эшләнде. Һәм Измаил бакчасындагы биеп-җырлаулар шул астыртын эшләнгән кара җинаятькә протест булып яңгырый иде. Ә япон яшьләренең болай ярсып биюләренең сәбәбе нидән икән? Мин шуны аңларга тырышам. Кабат команда тавышы яңгырады. Дәррәү биюдән туктадылар. Магнитофоннар да тукталды. Ял итәләр. Чирек сәгать чамасы ялдан соң кабат команда. Кабат җир тетрәтеп бию башланды.

Юк, бу биюдә күңел ачу, атна буе гел бер төрле хәрәкәтләнеп арыганнан соң тән язылдыру гына яшеренеп ятмый иде. Бию бит ул әллә нинди катлаулы тойгыларны,яшерен теләкләрне, сүз белән аңлатып булмаслык омтылышларны сурәтләп күрсәтә. Без, татарлар, Рудольф Нуриевне аңлый алмадык. Безнең наданлык, коллык томаналыгы комачаулады гасырга бары тик бер генә тапкыр туа алган шәхеснең кылган гамәлләрен. Рудольф Нуриев нәкъ Тукай башкарган вазифаны кабатлады. Габдулла Тукай аша татар халкының дүрт гасыр коллыкта кичергән кимсенүләре бәреп чыккан булса, Нуриевның биюендә безнең теләкләребезгә, омтылышларыбызга салган богауларны өзеп ташлап иреккә, мөстәкыйльлеккә омтылулар сурәтләнгән иде. Ә без, татарлар, шуны аңлап, татар халәтен бөтен дөньяга аңлатырга теләгән милләттәшебезне тиешенчә зурлый белмәдек.

Белмим, дөрес аңладыммы икән мин бу япон гладиаторларының биюләрен? Әйе, Япония — җир шарындагы иң куркыныч ил. Япон утраулары тирәсендә әле сүнмәгән, бер-бер артлы уянып торган җитмеш җиде янар тау урнашкан. Һәр елны «Таң кояшы иле»ндә меңнән артык җир тетрәү булып ала. Аларның кайсыларын сейсмик станцияләр генә сизеп кала, кайберләре искиткеч зур афәт ясап китә. 1703 елда булган җир тетрәү вакытында 200 мең кеше һәлак булган. 1792 елда — 15 мең. 1923 елдагы зилзилә 140 мең кешене теге дөньяга алып киткән, 284 меңне гарипләндергән.

Тарихта беренче тапкыр атом бомбаларын Хиросима һәм Нагасаки шәһәрләренә ташладылар. 1945 елның 6 августында атом төше гасыры башланды. Хиросима шәһәренә ташлаган бомба шартлагач, 80 меңнән артык кеше көлгә әйләнеп юкка чыкты. Дүрт айдан соң үлгән кешеләр саны 140 меңгә житте, 1950 елны радиация чаткысыннан үлгән кешеләрнең саны 200 меңнән арткан иде инде. Юк, икенче бөтендөнья сугышы японнар өчен шушы корбаннар белән генә чикләнмәде. 1945 елның 10 мартында 300 «оча торган кальга» дип аталган B-29 бомбардировщиклары Токио шәһәрен бомбага тоттылар. Бу турыда француз журналисты Робер Гилэн болай дип язган иде: «Бомбалар шартлый башлау белән японнарның агачтан һәм кәгазьдән ясаган йортлары тоташ учакка әвереләп яна башладылар. Көчле давыл һавада дөрләп янган такталарны, йорт җиһазларын очырып йөртә башлады. Урамга йөгереп чыккан кешеләрнең өстендәге киемнәре дөрләп януы йөгереп йөргән шәмнәрне хәтерләтә иде. Бомбадан куркып базга яшеренгән кешеләр кергән җирләрендә әзер кабер таптылар». Шул 1945 елның 10 мартындагы бомбага тотуда гына 197 мең кеше һәләк булган, гарипләнүчеләрнең саны 300 меңнән артык иде, дип язды чит ил газеталары.

Сугыш вакытында япон шәһәрләрен туктаусыз бомбага тотып тордылар. Сугыш туктаганда Токио шәһәре Явыз Иван басып алган Казан каласын хәтерләтә иде. Исән калган биналар бөтенләй юк, дип яздылар 1945 елның сентябрендә Япониянең башкаласын күрүчеләр. Япон яшьләре шушы афәтне каһәрләп бииләр иде. «Әйе, без тиз арада, бик тиз арада баедык. Безнең илебездә ясалган һәр машина, без ясап суга төшергән һәр кораб, без теккән кием-салым, без тукыган тукымалар дөнья базарында иң затлы, иң үтүчән. Элек без сугыш осталары саналсак, хәзер без дөнья күләмендә иң оста һөнәрчеләр, иң сыйфатлы әйбер ясаучылар. Тырышып эшләсәң, бездә акчаны күп түлиләр. Яхшы эшләгән кеше турында завод-фабрика хуҗалары кайгырталар. Безне хезмәт сөйгән, эшли белгән өчен ихтирам итәләр»,— дигән фикерне сурәтли биючеләрнең хәрәкәтләнүләре. Адәм баласын эшли белгән өчен генә ихтирам итү — дөресме соң бу? Кеше бу дөньяга бәхет өчен килә. Бәхетле булу өчен, ирек өчен, мәхәббәт өчен. Ә без көне-төне эшлибез. Дөрес, эш, бигрәк тә бездәге шикелле сыйфатлы, зур керемнәр бирә торган эш, адәм баласын баета. Баю, кыйммәтле машиналар, затлы йорт җиһазлары, муллык — шуның өчен генә киләмени адәм баласы бу дөньяга? Байлык өчен яшәүне без инкяр итәбез. Хезмәт өчен генә яшәүне дә без инкяр итәбез. Адәм баласы бәхетле булырга тиеш. Ә бәхеткә ирешү өчен ирек кирәк. Бәхетле булу өчен тынычлык кирәк. Мәхәббәт — менә нәрсә кирәк безгә. Мәхәббәт нурларына коенып яшәмәгән бәндә бәхетлемени? Ниһаять, табигать. Үзен таш корылмалар эченә бикләгән кеше никадәр тырышмасын, күпме генә көч түкмәсен, барыбер бәхетле була алмый...

Яшьләрнең биюе миңа менә шуны аңлатты.

Бик озак карап тордым мин япон яшьләренең дөньяларын онытып, гәүдәләрен җимерер, имгәнер хәлгә җитеп биюләрен. Моңа кадәр минем сәхнәдәге биюгә дә, балетка да болай карый алганым юк иде. Сихерләде мине япон яшьләренең биюе. Токиога килер алдыннан мин төне буе йоклый алмыйча план корып яттым. Минем планымда танылган сәүдә кәгъбәсе — Гиндзаны, андагы данлыклы универмагларны, бары тик товарны төрер өчен генә дә елына 280 миллион иена чыгым корбан итүче «Такасимая» сәүдә үзәген күрү куелган иде. Унике миллионлы шәһәрне туйдырып торучы мәшһүр базар Цукидзины да күрмәкче идем. Мин корган планда һәр кварталы үзенең борынгыдан калган гыйбадәтханәсе белән горурланып яши торган Асакаса районын күрү дә бар иде.

Элек Токио Эдо аталып йөргән. Асакуса районында, шул чордан калган гадәтләр буенча, бер яисә ике катлы чын японнар архитектурасында салынган йортлар сакланган. Мине шул башкаланың иң милли, японнарча җыйнак төбәген барып күрү ымсындыра иде. Яшьләрнең

биюләрен карап торганда мин боларның барысын да оныткanмын. Биючеләр таралганда көн кичкә авышып бара иде. Мин кайту ягына ашыктым. Һәм башка бер генә илдә дә очрамый торган яна могҗизага юлыктым.

Зәңгәрсу чынаяк плитәләр җәйгән перронда космик корабльга охшаган ак көмеш сигара — «Токио» поезды тора иде. Янәшә алты-җиде кеше керерлек киң ишекләргә халык ташкыны агыла. Ишекнең як-ягында соргылт униформа кигән таза ирләр поезд эченә керүчеләрне ике куллап этеп, дөмбәсләп тутырып торалар. Дөмбәсләп торучылар да елмая, алар кулына эләккән «корбаннар» да. Арттан китереп кысуны тойган алдагылар да елмаюдан туктамыйлар. Минем ихтыярсыз рәвештә «пик сәгатьләрендә» Мәскәү метросына керүчеләр сурәте күз алдыма килеп басты. Мәскәүдә бик күп милләт вәкилләре тупланган. Урыс иленең башкаласы булганлыктан, чит ил кешеләре мәскәүлеләрне «урыс» дип атыйлар. Менә шул урыс аталган Мәскәү милләте «пик сәгатьләре»ндә елмаюын гына түгел, адәмиләргә хас башка сыйфатларын да югалта. Метро вагонына керүчеләрнең күзләре акая, битләреннән кан кача, авыз кыйшая, нервлар кысылган пружина киеренкелегендә. Шундый чакларда сине алда торучыга китереп сыласалар, ул кеше мизгел эчендә сиңа ташлана. Ничә тапкыр шундый хәлгә юлыкканым бар: әгәр сине ябык, күз аслары кара көеп чыккан хатынга китереп кыссалар, ул чыелдап җибәрә дә тырнакларын синең битеңә батыра. Юан хатыннар ни сәбәптер түземрәк булалар. Белмим, бәлки кысылганда аларның тәннәре алай ук авыртмый торгандыр? Әллә, гомумән, ябык хатыннарны тормыш туктаусыз дөмбәсләп торганга, ташкында сыта башлагач, аларның түземнәре шулай тиз югаламы?

Ниһаять, перрон бушап калды. Көмеш сигара салмак кына урыныннан кузгалды. Көпчәкләр шыгырдавы, вагоннарның бер-берсенә бәрелеп шакылдавы — мондый тавышлар ишетелми иде. Бертавышсыз урыныннан кузгалды Токио поезды һәм икенче мизгелдә ул торган урын буш иде инде. Мин гади поездга утырып Тиба шәһәренә кайтып киттем.

Икенче көнне иртән без Тиба портыннан кузгалып Касима портына таба юл тоттык. Касимадан соң Хатинохе, аннан соң Акита. Без алып килгән йөкне бушатып бетерергә тиеш. Йөкне бушатып бетергәннән соң Кытайга, аның Ксинанг исемле портына кузгалырга тиеш идек. Моторист Петровның хәле көннән-көн авырая. Аны Япониядә калдырырга рөхсәт итмәделәр. Әгәр Петровны Владивостокка илтсәк, Ксинанг портына кадәр корабның ягулыгы җитмәячәк. Димәк, без Владивосток белән Ксинанг арасындагы берәр портка кереп, ягулык алып чыгарга тиешбез. Бу турыда әле беркем белми. Ягулыкның әз булуы турында миңа өлкән механик сер итеп әйтте. Кайсы портка керербез икән? Ягулык алып чыгар өчен иң уңайлы порт — Гонконг. Минем шушы көнгә кадәр Гонконгны күргәнем юк. Аны да күреп чыгарга насыйп булса? Белмим инде, бу сәяхәт миңа бик күп яңа күренешләр бүләк итте. Комсызланмаска кирәк...

Палубадан кораб артыннан калган кильватер агымына карап торам. Башымда катлаулы уйлар. Күңелемдә тынгысыз тойгылар кайный. Кемдер минем беләгемнән тотты. Борылып карадым. Янымда корабның аш пешерүчесе Мария Петровна Иванова басып тора иде. Сәер булып китте. Шушы көнгә кадәр бу кызны палубада күргәнем юк иде әле. Көне буе камбузда эшли. Эше бетү белән каютасына чума. Беркем белән аралашмый да шикелле. Нишләп йөри икән төн уртасында кораб палубасында?

— Сез бит, Габдрахман Бакирович, корабка килгән японнар белән гел сөйләшеп торасыз, әйеме?

— Гел дип инде, җае чыкканда сөйләшкәлим. Аларның бит күбесе үз теленнән тыш башка бер тел белми.

— Мин сезгә бер үтенечемне әйтсәм, экипажга сөйләп йөрмәссезме? — Маша якынрак килеп басты. Як-ягына каранып калды. Тыңлап торучыны күрмәгәч, дәвам итте. — Японнар ошый миңа. Гел елмаеп

йөриләр. Яшәүләре дә бик тә бай шикелле. Докерлар арасында өйләнмәгәннәре булса... әгәр урыс кызы белән... никахлашасылары килсә... мин риза.

— Туктагыз әле, Мария Петровна,— дидем мин тәмам югалып калып.— Соң бит сез япончa бер генә сүз дә белмисез.

— Яши башлагач, кирәк булса, өйрәнермен әле. Ир белән хатын арасындагы эшне телсез дә башкарып була бит аны,— Маша кеткелдәп көлде.

— Ә нигә соң үзебезнең кешегә, урыс диңгезчесенә чыгарга теләмисез?— дидем мин әле һаман төшенеп җитә алмыйча.

— Безнең диңгезчеләргәме? Спаси бог! Күрмисезмени аларның нинди икәнлекләрен? Алар бит дөнья көтүнең нәрсә икәнен дә белмиләр. Аларга,— Мария Петровна бугазына чиертеп күрсәтте,— шушы булсын да бер тапкыр кереп чыгарга итәк асты булсын. Бездә бит гаилә йөген гел хатыннар сөйри. Әниемнең гомер буе исерек ирен туйдырып, шуны карап кара гүргә утыз тугыз яшендә керүен мәңге онытачагым юк. Әни мәрхүмә, әти саналган шул сәрхүшне өйгә сөйрәп алып кайта иде, чишендереп яткыра иде. Икенче көнне йокыдан уяну белән баш төзәтергә аракы тыкырдата башлый. Без җиде бала, барыбызны да әни ашата, өстебезне дә ул карый. Каян алсын ул акча? Үзен сатсынмени? Утыз яшендә мәрхүмәнең тешләре коелып бетте. Аны инде кем сатып алсын? Акча бирмәгәч, алкаш тәресе әниемне кыйнарга тотына. Шул гына кыйнап үтерде инде мескенкәемне. Ә үзе әле исән. Үзен инде бишме, алтымы хатын куып чыгарды. Хәзер безнең теңкәбезне корыта акча сорап. Үлми дә ичмасам. Ә сез нигә урыска гына чыкмыйсыз дип сорыйсыз. Я их в гробу видела в белых тапочках. Спаси бог. Гомергә ир күрмәсәм дә урыска чыгасым юк.

Мария Петровнаның зары аңлашыла иде. Чыннан да, эчкечелек, беренче чиратта, гаиләне, семья җылысын, аның күркәмлеген саклаучы хуҗабикәне аяктан бәреп ега. Һәм сәрхүшлекне туктатырга бернинди чара юк. Беренчедән, урысның гореф-гадәтләре аракыга чыланган. Икенчедән, милексез коллыкта, крепостнойлыкта яшәү аракыга тотынырга мәҗбүр итә. Өченчедән, урыс язмышының яулап алуларга, сугышка, хәрбилеккә беркеп бетүе. Урыс империясе — ул тоташ бер казарма, бу шартларда айнык яшәү мөмкин дә түгел диярлек. Дүртенчедән, совет чоры һәр эшне, һәр гамәлне аракыга бәйләп эшләттерде. Эшкә урнашасың килсә — урнаштыручыны чакырып, аның белән эчәргә кирәк. Урнашкач, үзеңнең коллективны ихтирамлавыңны исбатлау өчен эчәргә. Туган-тумачаны хөрмәт итүеңне күрсәтер өчен — кабат аракы. Әйбер табу — шул ук аракыга бәйләнгән. Атлаган саен шуңа килеп юлыгасың... Ул әле урысларга җиңелрәк. Аларның мең еллык тәҗрибәләре бар. Аларда иммунитет барлыкка килгән. Татарларның хәле бигрәк тә авыр: без бит революциягә, хәтта колхозлашуга чаклы да бик сирәк эчкәнбез. Бездә әле иммун системасы барлыкка килмәгән, шуңа күрә, безнең өчен аракының куркынычы чиктән тыш зур.

— Соң бит, Мария Петровна, урысларның йөз проценты да алкашлар дисәк, ялганчы булырбыз. Очрамыймени егетләрнең эчми торганнары?

— Андыйлар да бар. Сез дөрес әйтәсез. Эчми торган юньлерәк егетләрне безнең Ирина шикелле проституткалар эләктереп торалар. Монда эләккәнче без бит Ирина белән бер корабта эшләдек. Аның йөзү эшенә урнашуына күп дигәндә ел ярым чамасы. Эшли башлады, буйдак диңгезчеләрне җентекләп тикшереп чыкты. Арада иң әйбәтенең астына кереп ятты. Башта бала ясатты. Шуннан соң, өйләнмәсәң, асылынып үләм, ни өчен асылынуымны язып калдырам, дип куркытты. Өйләнде инде мескен, нишләсен? Экипаждагы иң әйбәт егет иде. Мәскәүдән. Өстәвенә, Ирина киявенең әтисе-әнисе әллә нинди мәшһүр кешеләр. Ә хәзер күрә торгансыздыр инде? Һәр төнне үзен берәрсенә сата.

Тирә-юньдә дулкыннар шаулый. Кэраб сизелер-сизелмәс кенә дерелди. Винт болгаткан су өскә кайнап чыга да күбекләнгән аксыл юл булып сузылып кала. Аш пешерүче белән сөйләшә башлагач, диңгез шаулавын тыңлап торуның тәме бетте.

— Мария Петровна, японнар белән сез ботка пешерә алмассыз дип куркам. Алар бит чиктән тыш көчле милләтчеләр. Гореф-гадәтне саклау аларда шулкадәр көчле, шундый катгый. Юк, минемчә, алар ят милләткә, бигрәк тә урыс кызына, өйләнмәсләр.

— Алай булгач, бер генә минут көтеп торыгыз әле. Мин сезгә бер кәгазь күрсәтәм. Шуны укып чыгып, төзәтеп бирә алмассызмы икән? Мин сезне буш калдырмас идем.

— Кәгазьдәге язуны төзәтү генә булса, нинди «буш калдырмау» инде ул. Әйдәгез, күрсәтегез.

Мария Петровна ун минут чамасы югалып торды да миңа букчага салынган хат тоттырды:

— Укып карагыз да ялгыш урыннары булса, рәхим итеп, төзәтегез. Иртәгә миңа кире бирерсез.

Бер-беребезгә тыныч йокы теләп, саубуллаштык.

## 17

Хат урысча язылган иде. Адресатның исемен уку белән мин бу хатның җавапсыз калачагын аңлап алдым.

*«Привет из Мурманска!*

*Ален, ты мне обещал написать, а сам не пишешь. Ты тогда просто обманул или болеешь? Когда получишь это письмо, обязательно ответь и в письме обязательно пришли вызов. Теперь нам разрешают ехать в гости за границу, так что обязательно в письмо вложи вызов.*

*Мои данные для вызова. Родилась в 1958 году в селе Тарасовка Житомирской области, образование 10 классов. Член ВЛКСМ. Не судимая. Родственники за границей не проживают. С 1979 года работаю в Мурманском пароходстве поваром. Неоднократно поощрялась, ударник комтруда.*

*Ален, когда я у тебя была в Бордо, ты мне показал дом, сад, хозяйственные построения. Я увидела много того, что ужасно запущено. Работать я люблю, если ты доверишь мне, я все приведу в порядок; так что после не пожалеешь, что меня вызвал к себе во Францию.*

*Жду письмо и вызова. Целую тысячу раз, Мария.»*

Кызганыч булып китте. Өч хатын-кыз арасында, минемчә, иң тырышы, иплесе иде. Сәяхәтнең башында диңгезчеләрнең күбесе аның тирәсендә йөреп карадылар да, бу кызны җиңел генә аздырып булмаслыгын аңлагач, тәртәләрен бордылар. Аш пешерүче чиста яшь иде. Җыйнак, зәвык белән киенә. Чибәрлеге дә җитәрлек. Буй-сыны исә кием күргәзмәләрендә мода яңалыкларын күрсәтеп йөрергә ярарлык иде. Нишләп бу кыз шушы көнгә кадәр үзенә тиңне таба алмаган, дигән соравыма Мариянең Бордо портындагы стивидорга язган хаты җавап бирде. Урыс егетләрен чыннан да, өнәми иде аш пешерүчебез. Ул инде сәрхүшлекнең куркыныч бер каза икәнлеген аңлаган, аннан саклану мөмкинлеге булуына ышанмый башлаган. Хәтта эчми торган егеткә чыксам да әкренләп ул да эчә башлар, безнең ил егете белән гаилә кору мөмкин түгел дигән нәтиҗәгә килгән иде бу тырыш кыз.

Хатны мин кабат укып чыктым. Ален, французларга хас хатын-кыз белән аралашуга җиңел карашлы, нечкә сыйраклар белән мавыгырга күнеккән бер бәндә кебек тоелды миңа. Ул инде кызны үзенең өенә үк алып барган. Совет кешесенең кытлыкта яшәвен белеп, кызны байлыкка кызыктырып «эшкәртү» иде бу. Француз егете теләгәнен ала алмаган, күрәсең. Ул инде Марияне күптән оныткандыр. Аш пешерүче исә француз фраерының йорт-җирен күрсәтеп йөрүен үзенчә аңлаган. Мин аңа

ошыйм булса кирәк, бәлки ул миңа өйләнергә тели торгандыр, диган нәтиҗә чыгарган Мария Петровна. Һәм менә француз егетенә хат яза.

Соңгы елларда совет илендә туып-үскән кызларның чит ил кешесенә кияүгә чыгарга омтылулары миңа мәгълүм иде. Морадларына ирешүчеләр саны да инде шактый иде. Берәүләр чит илләргә укырга китәргә тырыша. Икенчеләр, үзләрендә талант икәнлеген аңлаганнан соң, СССР шартларында Алла биргән бу кыйммәтле бүләкнең кирәксезлеген аңлап, ничек булса да чит илгә таярга тырышалар. Кайбер кызлар башта валютага эшли торган проституткалыкны сайлый. Шул эштә тәҗрибә туплый да ачыграк авызлы чит ил кешесен камытлап, шуның чанасына хуҗабикә булып менеп утыра. Бу ысул — иң отышлысы.

Мария Петровнага ярдәм кулы сузарга кирәк иде. Мин аның хатын үзгәртебрәк язарга ниятләдем. Ул бит, мескен, Франциядә коммунистик хезмәт ударнигының сукыр бер тиен тормаганлыгын, ВЛКСМ әгъзасы булуның кияүгә чыгу өчен ярдәм итмәвен, туганнарының чит илләрдә булмавы нигә кирәк икәнлеген — боларның берсен генә дә аңламый иде. Мескенкәй, виза ачтыру өчен күп тапкыр анкета тутырган. Шул анкетага кергән сорауларга җавап язу чит ил егетенә хат язганда да кирәк дип ышанган инде бичара. Хатны тулысынча үзгәртергә туры килде.

*«Хөрмәтле Ален,— дип башладым мин.— Сез бәлки онытып та бетергәнсездер инде? Бордо шәһәрендә очрашып танышу ни сәбәпледер әле һаман минем күз алдымда тора. Минем шушы көнгә кадәр сезнең шикелле культуралы, шаян табигатьле егетне очратканым юк иде. Бәлки, шуңа күрә онытa алмый торгандыр?*

*Әгәр шул очрашу хәтерегездә сакланган булса, сез мине онытмаган булсагыз, тагын бер тапкыр очрашырга теләсәгез, мин каршы килмәс идем. Чакыру кәгазе җибәрергә теләсәгез, мин Бордо шәһәренә барып кайта алам. Телисез икән, мин үзем сезне чакыра алам. Советлар Союзын күреп китәрсез, теләсәгез Кырымга, Кавказга барып кайтырбыз. Сезне Совет иле белән таныштырырлык мөмкинлекләрем бар минем. Кунак итәргә дә кулымнан килер дип өметләнәм. Теләгегез булса, миңа хат языгыз. Кирәк тапсагыз, чакыру кәгазен дә җибәрә алам. Әгәр инде башта үзегез мине чакырырга теләсәгез, рәхим итегез. Мин әзер. Бордо миңа ошады. Ул шәһәрне кабат күреп кайту миңа шатлык кына китерәчәк. Мин 1958 елда туганмын (француз хатын-кызы үзенең ничә яшьтә булуын әйтми, ялгышмасам). Тулысынча исем-фамилиям — Иванова Мария Петровна. Мурман шәһәрендә үз квартирамда ялгыз яшим. Чакыруны СМурман шәһәре, Совет урамы, 17, 42 квартира адресы белән җибәрсәгез, хат килеп җитми калмас.*

*Әйе, кисәтергә оныткaнмын икән. Мин Бордога барсам, сезнең йортта яшәргә җыенмыйм. Әгәр миңа якын-тирәдән берәр бүлмә әзерләсәгез, рәхмәт белдерер идем. Сез Мурманга килсәгез, мин сезгә андый бүлмәне алдан әзерләп куярмын. Эш менә нәрсәдә, бездә, Совет илендә, егет белән кыз никахтан соң гына бергә яшиләр. Бу катгый, һичшиксез үтәлергә тиешле гадәт.*

*Сезне сагынып калучы Мария Ивановна.»*

Хатның үзем язган вариантын мин аш пешерүчегә иртәнге чәйдән соң камбузга кереп тапшырып чыктым. Шул көннән башлап, кают-компаниягә соңгарып калып килгән чакларда минем өстәлемдә кимерергә зур сөяк, тәмле итеп кыздырылган бер бөтен балык була башлады. Утыз елдан артык әдәбият белән шөгыльләнеп, минем әле бу кадәр «гонорар» алганым юк иде. Чыннан да, кешегә кирәкле темага язу синең үзеңә дә зур файда китерә икән. Моңа кадәр хакимияткә мәдхия җырлаучылар гына матди файдага ирешә дип ышанып йөрүем тулысынча дөрес булып чыкмаган, күрәсең...

## 18

Кичә агент миңа хат китерде. Кызымның хаты. Сингапурга язган. Без киткәч, кемдер шул хатны монда, Японияга җибәргән. Хат мине Акита портында куып җитте. СССРдагы хат йөреше белән

чагыштырам. Мин элек Восьмая Соколиная урамындагы җиденче йортның 43 квартирында яшәдем, шуннан 131-нчегә күчтем. Хат шул квартирага килә һәм югала. Кырык өченче фатирның хуҗасы белән сөйләшәм, ул әйтә: «Мин сезнең хатларыгызны ташырга ялланмадым, адресын дөрес язсыннар»,— ди. Почтага барам. Гариза калдырам. Вәгъдә бирәләр һәм оныталар. Хат кына түгел, җибәргән китаплар, бандерольләр юкка чыкты. Берни эшләп булмый — Рәсәй, «уртак аршын белән үлчәп булмый торган ил...»

Кызым язган:

«У нас все в порядке, тьфу-тьфу. Мы с мамой работаем. На работе все хорошо, хотя ее и много, но главное — спокойно: милые доброжелательные люди, теплая атмосфера... Кстати, мой бывший начальник Р. Т. тоже ушел в январе из «Литературной России» — и теперь, говорят, третье лицо в КПК при ЦК КПРФ...

Периодически звонит Юра Амбернади, интересуется, как твои дела и как мы зимуем без тебя. И еще очень много народу звонит тебе, все просят передать привет...

В продуктовых магазинах ситуация все та же, поэтому с марта в Москве вводят карточки: на мясо, масло, колбасу, крупу и спиртное — минимум, а остальное — по коммерческим ценам. Но нам обещали, может быть, прибавить зарплату.

Мы с мамулей всем съестным обеспечены — благодаря заказам. Писателям все время подбрасывают то колбасу, то сосиски. Так что все в порядке, не волнуйся.

А как там наш Колумб Исергаповский? Надеемся, что доволен жизнью, что путешествие пойдет тебе на пользу. Очень ждем письма — из Вентспилса дошли только два, то, о котором ты писал, что оно было написано в плохом настроении,— не получили.

Дядюшка мой пишет, что у него все в порядке, твой племянник тоже процветает. Передает тебе приветы.

Не знаю, дойдет ли это письмо до Сингапура. Во всяком случае, надеюсь. Очень любящая тебя и скучающая по тебе дочь».

Минем балам. Бар микән шуның белән чагыштырыр нәрсә? Сөйгән ярың чиктәш тыш газиз сиңа. Әкиятләрдә, борынгы әдәбиятта, урта гасырларга кадәр адәм балаларын үзара мәхәббәт һәм гади ярату бәйләп торган. Мәхәббәт, «Илиада» аңлатуы буенча, сугыш башлануга сәбәп булган. Таһир һәм Зөһрә», «Ләйлә һәм Мәҗнүн», «Тирстан һәм Изольда»,— һәр әдәби әсәрнең үзәгендә элек мәхәббәт тирәсендә барлыкка килгән коллизия — мөнәсәбәтләрнең кайнар төене яткан. «Мәхәббәт эшен» ничек башкарырга кирәклеге турында кулланмалар язып, аны гади бер көндәлек гамәл итеп куллана башлагач, әдәбият аптырашта калды. Яңа әдәбият сюжет корганда мәхәббәткә артык ышанып бетми, шуның аркасында авангард ысуллары — андерграунд, детектив, башка төрле алымнар барлыкка килде. Ә менә бала мәсьәләсе кеше анадан туып, гаиләдә тәрбия алган очракта, беркайчан да бәгырьләрне тетрәндереп торудан туктамас шикелле тоела.

Бер яше тулган көнне кызымны әнисе Одессага алып килде. Хатынымның кулында авыр чемодан, кызымны стюардесса күтәргән. Стюардесса аны миңа бирде. Бала әнисенә карады:

— Курыкма, кызым, әтиең бит бу. Әттәң,— диде хатыным миңа күрсәтеп. Бала бер генә мизгелгә икеләнеп торды да, еламады, гәүдәсе белән миңа сырышты. Күп, бик күп еллар үтте шул мизгелдән соң, баламның сабыйларча йомшак сырышуын күкрәгем әле дә тоя.

Без икебез дә Одессаны ярата идек. Без ул чакта Зур Фонтан линиясенең Өченче станциясендә, җиденче поликлиника янында тора идек. Мин ялда. Социалистик системада ашыйсы килгән кеше эшләргә тиеш иде. Мин әле һаман хәтерлим Нобель бүләге лауреаты Иосиф Бродскийны эшкә йөрмәгән өчен (тунеядство) суд ясап төрмәгә ябуларын.

Социализм бер яшьлек балаларны эшкә җикми иде. Бакчага йөри башлаганчы аларга идеология йөген дә көчләп такмыйлар иде. Иртәнгелекне ашагач, кызымның йокыдан уянганын көтеп утырам. Баланы ашатабыз. Әнисе аның колготкасын, күлмәген алыштыра. Кызымны җиңел коляскага утыртам. Без сәяхәткә чыгып китәбез.

Минем чордашым, хәзер инде татар әдәбиятының классигы Мөхәммәт Мәһдиев, кара «Волга» ярата иде. Зигмунд Фрейд һәм Эрих Фромм системасында психоанализ Мөхәммәтнең кара «Волга» яратуының асылында нәрсә, нинди психологик доминанта ятканлыгын җиңел аңлата. Ә без яшәешнең икенче адымына аяк баскан кызым белән трамвай ярата идек.

Тукталышка чыгабыз. Олы фонтанның Уналтынчы станциясе ягыннан унсигезнече трамвай килә. Алгы ишектән кызымны, һәм коляcканы күтәреп трамвайга керәм. Балалы иргә урын бирәләр. Кызым тәрәзәдән Олы фонтанның йортларын карап бара. Мин одесситкаларның сөйләшкәннәрен тыңлыйм. Белмим, элеккеге СССРның кайсы шәһәрендә шулай трагико-комик ысулда сөйләштеләр икән? Одесситлык бит ул беренче чиратта яшәү ысулы, шушы шәһәрдә яши алу бәхетенә ирешү белән горурлану һәм бүгенме, иртәгәме, һичшиксез, моңа кадәр тарих белмәгән бер бөек могҗиза булыр дип өметләнеп көтү. Бәлки, шуңа күрә, мин шушы көнгә кадәр Одесса чорын Эрнест Хемингуэй үзенең Парижда яшәвен тоташ бәйрәм итеп тойган шикелле шул заманның хәтирәләре белән сабыйларча куанып йөрим.

Куликов поле. Унсигезенче трамвайның соңгы тукталышы. Тимер юл вокзалы, өлкә комитеты, хәрби округ биналары урнашкан бу мәйданны нигә «Куликово поле» дип атап йөртүләренең серенә мин шушы көнгә кадәр төшенә алмыйм. Алтын Урда чорында һәм Кырым ханлыгы көчле чакта Одесса Хач-бәй исемле зур татар авылы булган. Бу җир төрекләр кулына күчкәч, портка әверелгән урынны Хаҗи-бәй дип атап йөртә башлаганнар. Әби патша чорында Хаҗи-бәйне урыслар басып алган, ләкин урамнарга, мәйданнарга урыс исемнәре кушып бетерсәләр дә, Одесса үзенең Урта диңгез һәм Якын Көнчыгыш культурасы салган оеткыдан арына алмаган. Төрек-грек-итальян-еврей-француз культураларының йогынтысы тудырган интернациональ кала. Монда диңгезчеләрне ачыктан-ачык, синең үзеңә сиздереп яраталар иде. Диңгезчеләргә карата булган ихтирам җир шарының башка кайсы портында, бәлки Сингапурда, яисә диңгезчеләр каласы Порт-Сәгыйтьтә саклангандыр?

Куликов мәйданындагы барлык күгәрченнәр белән исәнләшеп чыккач, вокзал каршына киләбез. Ике аягы сугышта өзелгән моряк-инвалид «Братишка» янына тукталабыз. Ул безгә Одессаның соңгы яңалыкларын сөйли. Без аның белән илле бишенче еллардан бирле дуслар. Братишка (аның инде исеме дә булгандыр, әмма Одесса бу гаҗәеп шәхесне шушы исем белән генә белә иде) кызыма үзе сата торган уенчыклар арасыннан иң матур сызгыра торган балчык (керамик) сыбызгыны сайлап бирә. Шуны сызгырта-сызгырта Одессаның данлыклы базары Привозга таба юл тотабыз. Базар капкасы төбендә боз сатучы еврей Ефим Самуилович елмаеп каршы ала.

— Фима, бозың күпме тора?

— Нынче лед подорожал,— дип башлый ул сүзен. Бу кеше сатарга да оста, яһүдләр турында анекдот сөйләргә дә. Анекдотны мин башлыйм. Ул дәвам итә. Өч-дүрт яңа анекдот ишеткәннән соң базар эченә кереп карт яһүдәләрнең тавык алганда сатулашуларын тыңлыйбыз кызым белән. Бу турда сөйли башласаң озакка китәр иде. Исән булсам, хикәя итеп сөйләрмен әле бу хакта. Тавык сата торган җирдән җимешләр рәтенә киләбез. Кызыма иң затлы, иң кыйммәтле виноград сайлап алам. Күбрәк «кызлар бармагы» аталган сорт туры килә. Без аны базар читендәге кранга барып әйбәтләп юабыз. Башта кызыма күкрәкчә киге-

рәм һәм виноградны кулына тоттырам. Ул аны ашыкмыйча гына, кош баласына охшатып суыра башлый.

Мин хәзер троллейбуска да, трамвайга да утырмыйм. Пушкин проспектыннан җәяү китәм. Алдан коляскага утырган кызым. Мин арттан. Урамның як-ягына утырткан чинар агачларының ботаклары өстә тоташ гөмбәз ясап, үзара тоташып беткәннәр. Яктылык яфраклар аша гына саркып керә. Салкынча. Франциядәге Бордо урамын хәтерләтә бу урам. Йортлар Одессаның мэры кардинал Ришельеның энесенең малае де Ришелье чорында салынганнар. Аларның архитектурасы шундый төгәл, соңгы чор классик ысулы шулкадәр мул, тулы иҗатланган, кайбер йортлар янына туктап туйганчы карап торабыз. Белмим, яшь ярымлык бала мин сөйләгәннең эчтәлеген аңлый идеме икән? Аңламаса, ул нигә шундый зур дикъкать белән тыңлап йөрде икән? Икебезгә дә рәхәт иде ул чакта. Ул чор яшәвемнең иң бәхетле, тоташ канәгатьлектән, саф шатлыктан торган чоры иде.

Де ибас урамына җитәргә ике мәхәллә кала. Одесса чорында Пушкин яшәгән йортка, «Моряк» редакциясенә керәбез. «Моряк»ның редакторлары шактый еш алышынып торды. Җаваплы партия эшендәге түрә берәр ялгышлык ычкындыра, яисә өстәрәк утыручыларның сүзен колак салып тыңламый башлый. Аны газетага редактор итеп утыртып куялар һәм чираттагы янган кеше килеп утырганчы эшләтәләр. Җаваплы сәркатиб Косоногий газетада озак эшләде. Бервакыт мин шактый еш мәкаләләр язгалап алдым һәм кыска хикәяләр конкурсында беренче урынны алганнан соң туктадым.

Косоногий минем кызымны мактый. Бу инде минем күнелемә бал да май. Ниһаять, уртак фикергә киләбез: акыллы булачак. Һәм инде унынчымы, унҗиденче тапкырмы җаваплы сәркатиб минем «Железный слон»га беренче урынны бирер алдыннан булган мәрәкә турында сөйли:

— Жюри әгъзалары бер авыздан бирмик беренче урынны, хикәя авторның үзенеке түгел, каяндыр күчереп алган дигән карарга килделәр. Мин әйтәм, «каяндыр» дәлил түгел. Әйтегез каян икәнлеген. Ә мин аның үзе язганын тулысынча дәлилли алам. Беренчедән, вакыйга авторның үзе эшләгән «Чолым» пароходында бара. Икенчедән, хикәягә редакциягә килгәндә ул пароход, чыннан да, Александриягә Херсоннан бодай ташый иде. Өченчедән, стиль дигән нәрсәне сез аера белмисезмени? Мин сезгә аның «Моряк»та басылган мәкаләләрен күрсәтә алам — нәкъ шушы стильдә язылган.

Безнең икебезгә дә рәхәт. Миңа — конкурста җиңү ләззәте, Косоногийга әдәбиятның нечкәлекләрен белү.

Җаваплы сәркатип конкурста икенче урынны алган «Аркадий Гайдар» теплоходының икенче механигы Аркадий Хасинның нәшриятка китап чыгару өчен кульязма тапшыруын белгертә. Мине дә үгетли, яңа хикәяләр язарга, җыентык әзерләргә куша. Мин тыңлыйм. Рәхмәт әйтәм. Хикәяләрем «Совет әдәбияты»нда, «Ялкын»да басыла башлавым турында сөйләмим, ояләм. Ул чакта татарча язу минем өчен ифрат авыр иде. Тел онытылган. Татарча сөйләшеп йөрмәгәч, телнең музыкасын, моңын тоя алмыйсың. Язар өчен шул музыка кирәк. Ә мин язарга тырышам. Иҗат минем өчен гыйбадәт кылуга тиң иде. Бәлки, шул иҗат эше саклап калгандыр манкортлашудан?

Татарчага күчә башлавымны яшерәм сәркатиптан. Милли хис бит ул мәхәббәт тойгысына тиң. Аны теләсә кемгә сөйләп булмый. Ул чакта мин Гомәр агадан, Хәсән Туфаннан, Фатих ага Хөснидән фатиха алган идем инде. Сибгат ага Хәким белән бераз соңрак таныштым...

Иҗатның иң татлы чоры иде алтмышынчы елның урталарында. Татар язучылары белән тыгызрак аралаша башлагач ачылды минем күзем. Минем буын әдипләренең күпчелеген әдәбиятка күренеклелеккә омтылу теләге камчылап китергән. Ә инде тәхеткә үрмәләп, әдәбият

дилбегәсен эләктерүгә ирешкән урта кулларны дан гына канәгатьләндерми. Алар, әдәбиятның җилкәсенә атланып, байлык тупларга керешәләр.

## 19

Редакциядән чыккач, без Одессаның Морозли сараена урнашкан Көнбатыш сәнгате музеена керәбез. Революциягә кадәр бу шәһәрдә байлар күп булган. Дөнья күләмендә мәшһүр опера театры, ул чорда СССРда дан тоткан оперетта, филармония һәм ике консерваториянең берсе сугыштан соң гына ябылды. Шуңа өстәп, Гнесиннар мәктәбе белән ярышып эшләүче Столярский исемендәге музыка мәктәбе, зур, бай картина галереясы, диңгез музее, археология музее. Кызым белән без аларның барысын да төпчелләп карап чыктык. Көнбатыш сәнгате музеенда минем балама нидерланд һәм фламанд сәнгате ошый иде. Утыз ел чамасы вакыт үтте, рәсемнәрнең исемнәрен тулысынча хәтерләмим. Геда, Лиотар, Снейдерс, Иорданс һәм Рубенс — бу авторларның эшләре бар иде анда. Пыяла вазага салып өстәлгә утырткан җимешләр ымсындыргыч матур. Кызым бармагы белән төртеп күрсәтә:

— Мәм-мәм...

— Әйе, мәм-мәм шул,— дим баламның зирәклегенә сокланып. Озаклап карап йөрибез дә минем иң яраткан экспонатым, борынгы җизгә көмеш бизәкләр төшереп эшләнгән фарсы калканы, ияре һәм корыч җепләрдән үрелгән көбә янына туктап ләззәтләнәбез. Ничә тапкыр карадым икән мин шул урта гасырларда фарсы осталары иҗат иткән бөек матурлыкны? Калькуттаның Милли музеенда Бөек Моголлар династиядән булган ханнарның кораллары саклана. Искиткеч тәэсирле, ир-егетлек хисләре уята торган кырыс матурлык балкыта Дәмәшкъ, Самсун, Тәһран осталары ясаган салкын кораллар. Алардан балкыган матурлык әле һаман миндә саклана...

Кызыма биш яшь булгач, мин аны Мәскәүдәге Пушкин музеена йөртә башладым. Бер баруда бары тик бер генә илнең сәнгатен карый идек. Борынгы Бабилдан, Шумердан, Борынгы Мисырдан башлап һәр илнең, һәр чорның сәнгатен без кабат-кабат карап чыктык. Өлкән классларда укыганда кызым миңа әйтте:

— Борынгы тарихны үткәндә, әтием, мин ул чорның шәхесләрен, шул заманның тормышын бик җиңел күз алдыма китерәм. Әйтерсең, мин ул чорда яшәп караганмын...

Музейдан чыккач без Дерибас урамы белән Собор мәйданына кадәр менәбез дә, граф Воронцовка куелган һәйкәл янында футбол фанатикларының бәхәсләрен тыңлап торганнан соң, опера театры каршындагы эскәмияләргә утырып бер тын ял итәбез. Кузгалгач, Одессаның иң матур бинасы саналган Өлкә башкарма комитеты сараен карыйбыз. Колясканы берәр балалы хатын карамагына тапшырып, комитетның буфетына кереп кызыма виноград суы, пирожное алам. Үзем Таһиров исемендәге шәраб фәнни институтында ясалган бер стакан коллекцион вино эчәм. Шуннан соң без мәшһүр Диңгез буе бульварына чыгабыз.

Монда һәр көн бәйрәм. Ял итүчеләр социалистик мәҗбүри ярыштан өч атнага булса да азатлыкка чыгу шатлыкларын алып киләләр. Туристлар Рәсәй крепостнойлыгыннан аерылып торган шәһәр белән очрашу куанычын, диңгезләр күп айлар ялыгып дулкыннар өстендә чайкалганнан соң туган туфракка басу рәхәтлеген алып киләләр. Башта без инглиз корветы «Тигр» бортыннан алынган туп янына киләбез. Яшь ярымлык кызым сугыш коралының «бу-бу» икәнлеген, аның кешеләргә үлем китерүен аңлый башлаган иде инде. Бик озак аңлатырга туры килде. Әнә, сабый балалар туп көпшәсе өстенә үрмәләп менәләр дә атланып утыралар. Шатланалар үзләре. Туп янына басып чибәр кызлар егетләренә сырышып фотога төшәләр. Сугыш коралы шулай куркыныч булгач, аны

нигә шулай яраталар соң? Туптан соң Пушкин һәйкәле. Балага бөек шагыйрьнең берничә шигырен укып күрсәтәм, ә үзем соңгы күрүдә туган фикеремне тикшереп карыйм. Бөек урыс калкулыгыннан ерагайган саен Пушкинның кыяфәтендәге хәбәшлек көчәя бара. Одесса — Пушкин яшәгән һәм аның шатлыклы көннәр кичергән урыннарның берсе. Сынчы бөек шәхесне урысайтуны максат итеп куймаган. Бу һәйкәлдә урыс гениенең шагыйрьлеге шулкадәр мул чагылган.

Пушкин һәйкәле янынннан Потемкин баскычы каршындагы Ришелье монументы янына туктыйбыз:

— Бабай! — ди кызым бармагы белән төртеп күрсәтеп.

Белмим, совет чорында ничек исән калды икән бу һәйкәл? Воронцов һәйкәлен Пушкинның эпиграммасы саклап калган. Дюкны (одессалылар аны шулай атыйлар) көчле фидакарьлек белән генә саклап кала алганнар. Әле узган елны гына Одессадан килгән кунаклар сөйләделәр: шәһәр башлыгы бу шәһәрдәге Ленин һәйкәлләрен бер бинага җыеп музей ачкан. Биш меңнән артык һәйкәлне бергә туплау — бу инде гаҗәп акыллы гамәл.

Диңгез буе бульварының азагына кадәр барып, Воронцов сараена керәбез. Шәһәрдәге иң матур сарайларның берсе бу. Без ишек алдыннан узып яр өстендә ярым түгәрәккә тезелгән ак колонналардан торган пропеллеяларның очына чыгып портка карыйбыз. Причалда йөзләгән кораблардан йөк бушаталар, төйиләр, зур, көчле краннарның уклары яр белән трюм арасында туктаусыз хәрәкәтләнеп тора. Дулкынваткычның аръягында ачык диңгез, зәңгәрсу-күкшел чиксезлек. Тышкы рейдтагы кораблар озын, ялыктыргыч юлдан соң йокымсырап, портка керергә чират көтәләр. Мин кызыма диңгез турында сөйлим. Тыңлаган жиреннән сабый кинәт кычкырып җибәрә һәм миңа бармагы белән пропеллеяның соңгы колоннасына төртеп күрсәтә. Колонна төбенә акчарлак килеп кунган. Диңгез кошы очып арыган, ял итә. Без дә ял итәбез. Диңгезгә ярдан карап утыруы шулкадәр рәхәт. Диңгез сине күп тапкырлар кыйнаган, давыл вакытларында үлемгә китереп терәгән. Шуңа карамастан, син диңгезгә рәнҗи алмыйсың. Диңгезнең холкында бер генә тамчы да вакчыллык, үч алу, махсус сиңа, гомумән, кешелек дөньясына карата әшәкелек булмый. Аның холкы шундый. Ул гаҗәп киң күңелле. Яратса, чын күңелдән ярата, ярсый башласа, дөньяның астын өскә китермичә туктый алмый. Әнә, ул нинди шәфкатьле, көләч йөзле, мәрхәмәтле.

Өйгә без яр буеннан кайтабыз. Порттан соң кораб ремонтлау заводы. Заводтан соң мәшһүр Ланжерон ярлары. Монда хәзер ял бакчасы. Бакчада без төрекләрдән калган таш диварны эзләп табабыз. Бәлки, бу диварны төрекләргә кадәр, Одесса урынында татар авылы булган чорда ук салганнардыр? Татарның язмышы гына түгел, тарихы да, бүгенгелеге, хәтта киләчәге дә хәрабәләр астында калып сытылган. Эре таштан мәңге чыдарлык итеп салынган стенага карап торганнан соң шушы фикергә киләсең. Татарның мәчетләрен, мәшһүр сарайларын гына түгел, яулап алучылар аның бердәмлеген, горурлыгын да җимереп ыргытканнар. Мескенлек баскан күпчелекне һәм аумакайлык. Буыннан буынга керәшчеләрне кыра торганнар. Керәшчеләр әзәйгән саен мескеннәр, аумакайлар күбәя торган.

Ял бакчасыннан соң санаторийлар, ял йортлары башлана. Яр астындагы комлыкта кояшта кызынучылар. Диңгездә ак канатлы яхталар, су өстен телгәләп йөрүче скутерлар. Унынчы станция траверсында ерак океаннардан килгән кораблар лоцман сорап гудок бирәләр. Кызым арып йоклаган. Мин аны күкрәгемә кысып кочаклаганмын. Һавада тоз исе, суүсемнәре исе. Диңгез буенда яшәү одессалыларның йөзләрендә һәм табигатьләрендә. Одесса империянең читенә урнашкан. Казан шикелле империянең арт саны астына эләккән шәһәр белән чагыштырып булмый бу каланы. Меңләгән диңгезчеләр чит илләргә йөргәндә ирек сулышын

татып яшәгәннәр. Монда яшәүчеләргә ирек турында диңгез дулкыннры сөйләп торган.

Без кайтуга төшке аш пешкән була. Бала йоклавын дәвам итә. Төшке аштан соң, баланы «Чолым» пароходының капитаны хатыны Елена Ивановнага калдырып, су коенырга китәбез.

Кызымның Сингапурга җибәргән хаты шушы хатирәләрне уятып җибәрде. Унбер елга сузылган Одесса тормышы көләч бәйрәм булып минем күңелемә кереп урнашкан да һаман яши бирә.

## 20

Ике көннән йөкне бушатып бетерәчәкләр. Японнарның эшләүләрен күзәтәм. Алар үзләре күренми диярлек. Тыныч. Күптән көйгә салынган, бернинди ашыгусыз, ыгы-зыгысыз йөгерек салмаклык. Оештыруны мөнәсәбәтләр хәл итә. Чыннан да бит оештыру урыслардагы ашыктыру, камчылап куу, план тутыру түгел. Японнар зур дикъкать белән, төпчелләп эш урынын әзерлиләр. Эш барганда кешеләр бер-берсенә комачаулык китермәсеннәр. Көч мөмкин кадәр әз түгелсен, хәрәкәтләр әз ясалсын, бер тапкыр башкарылган эшне кабат башкарырга туры килмәсен. Кеше башкарган эшен яратырга тиеш. Шул яратуның асылында нәрсә ята? Эш башкаручыга авыр булмасын. Аны ничек җиңеләйтергә? Эш коралы. Япон коралын кулыңа алсаң, куясы килми. Ул корал синнән башка да эшне үзе башкарып чыгар шикелле тоела. Адәм баласы эшләгән эшен күреп куанырга тиеш. Гаҗәп зур, сиңа канатлар үстерә торган куаныч ул башкарган эшеңнең нәтиҗәсен, аның сыйфатын, матурлыгын күреп соклану. Ниһаять, без егерменче гасырда яшибез, күмәклек чорында. Димәк, эш вакытында кешеләр бер-берсен ихтирам итәргә, яратырга тиешләр. Нинди очракта тормышка ашырып була бу максатны? Кешене көчләп яраттырып буламы? Бу сорауга җавап биреп торасы да юк. Диктаторны яраттырып була, юлбашчыны, сәясәт кәнтәен, мәдәният халтуршигын, урта кул язучыны. Популизм атала бу ысул — халык алдында көн-төн сөйләнү, аның салпы ягына салам кыстыру. Ә менә гади халыкны, бигрәк тә аның колга әверелгән өлеше вәкилләрен бер-берсен яратырга, ихтирам итәргә күнектерү — бу искиткеч авыр, катлаулы эш. Ялланып эшләүче хуҗага кулын һәм баш миен генә сатмый. Ул аңа үзенең шәхеслеген, намусын да сата. Кол колны ярата алмый, чөнки үзе белән бергә бил бөгүчегә карап социалистик кол үзен күрә. Ничек яратып булсын шундый ялагай, куркак, хөсет бәндәне? Тормышта идеалсыз яшәү яисә көчләп таккан кәҗүннәй идеалга табыну — бу хәл һәр очракта битарафлыкка, манкортлашуга ирештерә.

Японнар бу фаҗигане яхшы аңлаганнар булса кирәк. Алар шәхесләрнең бер-берсен яраттыру ысулын тапканнар. Алар ял көннәрен төркем-төркем җыелып япон чиясе — сакураның чәчәк атуын карап утыралар. Аларның күңелләре матурлыкка таба ачылган һәм алар үзара тоташкан. Күңелләре, яратулары аша. Хәзер алар бер-берсенә туганнар. Матурлык ул яшәргә көч, югалып калып, адашып йөрүчегә кыйбла күрсәтә. Матурлык бит ул зур, бик зур көч. Менә шушы урында югалып калдым: матурлыкның нindие? Үктәбер рвәлүтсиясенең җитмеш җиденче еллыгына әзерләнгәндә урам тутырып элгән кызыл комач лозунглар, политбюро әгъзаларының портретлары матурлык түгелмени? Ул да берләштерә бит. Чыннан да, берләштерә — тышкы яктан. Японнар эчке яктан күңелләре, зәвыклары белән берләшә алганнар. Аракы да берләштерә, түрәләрнең чыбыркысы да, хәтта безнең манкортлашу да. Әмма боларның барысы да көтүдәге сарыкларга хас берләшү, социалистик күмәклек, совоклык китергән берләшү. Әнә, японнар бәйрәмнәрне үзләре белән

алып чыгалар, ә без бәйрәмне, хужа малга салган салам шикелле, җитәкчеләрдән алабыз...

## 21

Куркыттымы мине Токио, әллә андагы катлаулыкларны аңларга минем зиһенем җитмәде? Гомеремдә беренче тапкыр зур шәһәрләр — мегаполислардан өркә башладым. Җир кыйммәт булганга, Токио йортларын һавага сала башлаган. Юлларны йә җир астына төшереп җибәргән, яисә һавага асып куйган. Озакламый японнар утрау сала башлаячаклар. Юк, алар инде күптән бу эшне алып баралар. Токио култыгының яртысы диярлек коры җиргә әверелде. Кала диңгезгә һөҗүм итә. Диңгез чигенә, шәһәр һаман алга, штурмга бара.

Убэ. Тиба. Касима. Хатинохе. Шушы шәһәрләрнең тирә-ягын җентекләп карап чыктым. Япон җирен «кыр», «ялан» сүзләре белән сурәтләве чиктән тыш авыр. Юк монда безнең Татарстандагы шикелле киң, иркен үзәннәр, аңгыра океан дулкынына охшашлы сөзәк калкулыклар. Таулар да монда бөтенләй икенче төрле. Утрау бит ул тирә-ягын диңгез урап алган коры җир генә түгел. Утрауда син, телисеңме-юкмы, диңгезнең якында булуын тоеп торасың. Син генә түгел, мондагы җир дә, ташлар да, мондагы агачлар да, хәтта үлән бөртекләре дә материктан еракта, су сәхрасында бүленеп яшәүне тоеп торалар шикелле. Океан японнарның гадәтләрендә. Алар шуңа күрә чиктән тыш җаваплылар.

Японияда моторист Филиппов авырый башлады. Аның хәле һаман начарлана иде. Доктор Потрессв аны изоляторга салды. Үзе Филиппов яныннан чыкмый да диярлек. Шәрифуллинның эше тыгын. Корабта шулардан башка серем сыярлык кеше, бәлки, булгандыр да. Башкаларны эзлисем килмәде. Бүген Японияда соңгы көнебез. Иртәгә кузгалабыз. План буенча моннан туры Кытайга Европа илләренә кайтарыр өчен жмых (укучыдан гафу үтенәм, татарчасы мамык төбе) — мамык орлыгын кысып маен чыгарганнан соң калган өлешен мал симертү өчен кулланалар) төяргә тиеш идек. Филипповның хәле начарлана башлагач, аны Владивостокка кертеп калдырырга рөхсәт килде. Урысларның «нет худа без добра» дигән әйтемнәре бар. Владивостокка кереп чыкканнан соң ягулык Кытайга барып җитәрлек калмаячак. Без Гонконгка кереп ягулык алырга тиеш. Җир шарындагы Сингапур белән ярышучы иркле порт Гонконгны кабат күрү минем өчен тагын бер язмыш бүләге, кабат бер зур бәйрәм булачак.

Порт күздән югалды. Юл читенә килеп кулыма бер учлам туфрак алам. Кызыл балчык, таш валчыклары, тузан. Караярымның кара туфрагы исемә төшә. Картлар горурланып: «Безнең туфрак бит ул борып борынына тыгарлык, исерек маржа ашарлык», — дип мактаналар иде. Японның бакчасындагы туфракка карыйм. Танырлык түгел. Бу сыйфатка житкерү өчен ашлама бирү, эшкәртү, тырмалап тору гынап җитми. Җирне күпереп торган кызгылт-кара мамыкка әверелдерү өчен ярату белән дә сугарып торырга кирәк. Көчле, ихлас ярату белән. Шул чакта җир дә сине ярата башлый һәм ул сиңа түккән көчләреңне тапкырлап кайтарып та бирә...

Йортларга карамаска сүз биргән идем. Тыела алмадым. Туктадым. Ишегалды чирәмен кыска итеп кырыкканнар. Яшел келәм шундый тыгыз, шундый тигез, төсе — чиста зөбәрҗәт. Урам яктан тәбәнәк чылтәр. Түрдә, бөдрә наратлар астында, япон йорты — глазурь йөгерелгән чирәп белән каплаган түбәләр гаммасы. Чирәмлекне өч яктан тоташ алсу чәчәкләргә баткан куаклар каплаган. Чирәм белән куаклар арасында чуер ташлар түшәгән таш сукмакны йорт каршындагы җәлпәк ташлар тезмәсе дәвам итә. Ишек каршындагы куаклар өч катлы булып үскәннәр. Кыркып матурладыларммы икән аларны, әллә

үзләре шундыймы? Куаклар ирләр кулы тимәгән яшь кызлар күкрәгенә охшап үскәннәр. Куаклар белән ярышкандай, йортның түбәләре дә кат-кат булып болытларга таба карап канат җәйгән. Япон йорты җиңел, җыйнак, талпынып очып китәргә әзерләнгән кошка охшаган.

Йорт каршына тезгән җәлпәк ташларга карыйм. Җан бар бу ташларда, мәҗүсилек тылсымы бар. Арып эштән кайткан хуҗаларны ташлар баш иеп каршы алалар. «Бас миңа,— ди япон ташы.— Көч ал. Мин бит мәңгелектән килдем һәм мәңгелеккә карап яшим. Миңа баскач, син газиз япон җиренә тоташасың. Онытма, шушы җирнең куенында сиңа каның тапшырып мәңгелеккә юнәлгән җитмеш җиде буын аталар, күкрәк сөте белән сугарган аналар... Соргылт ташлар, кызгылт-көрән сукмак, алсу куаклар, зөбәрҗәт чирәмлек — менә кем тәрбияли япон зәвыгын. Җир хосусый. Хуҗаның һәр күзәнәге шушы җиргә килеп тоташкан...

## 22

Япон йортларын, бакчаларын күрмәс өчен аяк астыма карап барам. Онытырга кирәк, кайткач беркемгә сөйләмәскә. Ялган дәлил табып юана белергә кирәк. Сталин золымында, Брежнев торгынлыгында без японнардан ким яшәмәдек. Алар хезмәт, ял, көнкүрешләренең муллыгы, рухи киңлек белән ләззәтләнсәләр, безне киләчәктәге җәннәт тормышы ымсындыра иде. Коммунизмның инде авыл артына диярлек килеп җитүен тоеп шатлану, бер күнеккәч, шундый мул хозурлык биреп тора иде безгә. Әнә, безнең Караярдан өч кенә чакрым Бакалы урысларының бәдрәфләре дә юк иде. Өйләренең нигезенә тәрәзә төбе биеклеге итеп тирес өеп куйганнар. Июль челләсендә аякларында киез итек; башларында колаклары асылынып төшкән малахай, көмешкә парларына изрәп шундый рәхәт итеп утыра беләләр иде. Телебез бетеп, гореф-гадәтләр тулысынча онытылып, манкортлашуыбыз йөз процентка җиткәннән соң безгә дә шулай рәхәт булачак. Төкерергә кирәк япон бакчаларына, аларның йортларына, алар эшләп чыгарган телевизорларга, радио-электроник товарларына. Һәм мин барган җиремнән лач итеп япон җиренә төкердем. Һәм шул төкерек айнытып җибәрде мине.

Тар гына урам — ничек сыйдырганнар моңа өч төрле юлны. Уртада машина юлы. Як-якта тагын икешәр сукмак, җәяүлегә һәм велосипедка атланып йөрүчегә. Җиргә шул кадәр кытлык бит монда, шуңа карамастан, «макакалар» (диңгезчеләр шулай атыйлар) шушы тар урамга өч төрле юл сыйдыра алганнар. Күңел киңлеге, адәм баласының иминлеген кайгырту биргәндер инде бу мөмкинлекне? Япон кешесе эшкә генә машинасына утырып бара. Эштән кайту белән ул велосипедына атлана. Сәламәтлегем өчен шулай кирәк дип ышана ул.

Урамның очына килеп җиттем. Әнә, канауның теге ягында кырлар башлана. Соңгы йортны үтеп бара идем инде тавык кытаклаганны ишеткәндә. Нәкъ безнең Караяр тавыгына кешелек дөньясына бер йомырка бүләк итүен сөрән салып белгертә. Башымны күтәреп тавыш ишетелгән якка карадым. Бернинди кетәк күренми якын-тирәдә. Чәчәкләргә күмелгән ишегалды. Куаклар. Келәмеңне көнләштерерлек чирәм. Һәм тоташ пыяладан корылган оранжерея. Оранжерея эчендәге һәр куак, һәр сабак, урам ягындагы кызара башлаган помидорлар, үзенә тартып тора.

Яшелчәләрне утырту тәртибе җәлеп итте мине. Якынрак килеп күзәтергә тотындым. Бер рәттә помидор һәм янәшә рәтләрдә кыяр, баллы борыч, бадамҗан, тагын әллә нинди мин белмәгән яшелчәләр. Мин торган яктагылары инде тәмам өлгергәннәр, теге башта әле яңа утыртылганнары. Ничек итеп утырткан бит самурай тәре! Бу куактагы яшелчәне ашап бетерүгә икенчесе, аның артыннан өченчесе өлгереп тора. Һәр көнне яңа пешкән помидор ашый, собака. Шулай өч айны, ярты елмы

һәр көнне әле яңа сабагыннан өзеп алып кергән яшелчә ашый оранжерея хуҗасы.

Мин шушы турда баш ватып торганда сул як почмакта бер лампочка кабынып китте. Бераздан сүнде. Мин торган җиргә якын лампочка кабынды. Бусы озаграк янды, сүнгәч, уртадагы лампочка кабынып китте. Нәкъ шушы мизгелдә бызылдап электромотор эшли башлады, помидорлар рәтенә су парлары бөркелде. Яшелчә утыртылган тартмаларга идәннән пластик көпшәләр килеп тоташа. Болары ашлама ташыр өчен куелган булса кирәк. Әнә, түбә читенә урнашкан вентилятор эшли башлады. Оранжерея эченә саф һава суыра. Кирәк кадәр суырып алгач, ул да туктады. Тынлык урнашты. Ярты сәгатьтән артыграк карап торганмындыр? Шул арада әллә ничә тапкыр лампочкалар кабынып сүнделәр, әллә ничә мәртәбә яшелчәләр өстенә пошкырып өреп алдылар. Компьютербатрак япон крәстиәненә яшелчә үстерә иде. Күпме ашлама, күпме дым, ни хәтле җылылык, ни кадәр саф һава һәм сырхаулана башлаган яфракларга дару кирәк, компьютр һәммәсен чутлап чыгара, нәкъ кирәк чагында үлчәп тәэмин итеп тора. Оранжерея эченә кирәгеннән артык углекислый газ җыела икән, аны тизрәк ачык һавага очырта.

Безне бит җир йөзендә яшәүче ике аяклылар эксплуататорларга һәм эксплуатация михнәте күрүчеләргә бүленә, дип житмеш ел тәкъбир урынына кабатлап тордык. Кем соң оранжерея хуҗасы — изүчеме, изелүчеме? Ә социаль чыгышы ягыннан кем, крәстиәнме, галимме? Боларның берсе дә түгел яшелчә үстерүне компьютрга тапшыручы япон кешесе. Хуҗа бу. Кем соң ул хуҗа? Хуҗа ул бер үк вакытта обком секретаре дә, колхоз рәисе дә, Гонолулуга, яисә Флоренциягә турист булып барып йөрүче дә, сайлау алдыннан булачак президент кандидатының андый җаваплы эшкә яраклыкмы, түгелме икәнлеген ыштанын салдыру хәленә җитеп тикшерүче дә. Оранжерея хуҗасы, әгәр Зюгановны сайласак пенсиябезне күтәрер, аракының бәясен төшерер, дип совок томаналыгы белән чиновник кимереп ташлаган сөякне көтеп тилмереп утыручы түгел. Ул үз тамагын үзе туйдыра, өстен үзе карый һәм тормыш-көнкүрешен үз кулы белән төзегәннән соң аяк терәп әйтә: «Мин сезгә, чиновник әфәнделәр, салым түләп, тамагыгызны туйдырып торам, сез минем иминлегемне, илдәге тынычлыкны, гражданнарның мөмкинлекләре тигезлеген сакларга тиешсез. Саклый алмыйсыз икән, пошли вы...» И вчү!

Партия ыргыткан сөякне кимерергә өметләнеп яшәүче татар манкорты әйтәчәк: «Мин дә беләм яшелчәне ничек үстерергә. Андый оранжерея корыр өчен бир миңа акчасын. Мин аны японныкыннан да камилрәк итеп корып җибәрә алам». Әйткәнемчә, Баулы дип аталган райүзәкнең иң матур урамында танк һәйкәле тора. Әгәр шул танкка тотылган акчага оранжерея ясасалар, минем туган авылым Караярдагы сиксән колхозчыны пыяла түтәл белән тәэмин итеп булыр иде. Ә инде Баулыдагы самолет, пушка һәйкәлләренә тотылган акчаларны да өстәсәң, Караярның һәр хуҗалыгында пыяла оранжерея булыр иде.

Туктыйсым калмаган икән пыяла бакча янына. Һәр күргән нәрсәне мин үземнең туган җиремдәге әйберләр белән чагыштыра башлыйм да, йөрәк әрнүенә юлыгам.

## 23

Аллага шөкер, йортлар артта калды. Борылып карамаска тырышам. Каршымда калкулык. Машина юлы калкулыкны урап уза. Мин юлдан чыгып калкулык итәгеннән өскә алып менә торган сукмактан атлый башладым. Сукмакка да асфальт җәйгәннәр. Бераздан таш басмалар күренде. Сыртка менеп җиткәч, шәһәргә карадым. Һәм карашымны тизрәк шәһәр читендәге машиналар каберлегенә күчерергә ашыктым. Ялтыравыклы лакка катырган чирәп түбәләр, бөдрә нарат-

лар, зәңгәр күккә карап елмаеп утырган күперенке чәчәк куаклары биектән караганда тагын да гүзәлрәк күренәләр иде. Мәскәүнең егерме биш елдан җимерелә башлаган хрущевкалары арасында йөргәндә бу күренеш искә төшеп кабат җанымны көйдереп алыр. Һәр йортның диярлек түбәсендә ак шар — спутник ярдәмендә тотыла торган программаның антенналары да кәефемне бозды. Әле бит Баулы юньләп Казанны да карый алмый, карарлык нәрсә булмаса да... Акитада шул ак шарлар ярдәмендә Америка программаларын, теләсәләр Австралия тапшыруларын рәхәтләнеп карап утыралар, күрәсең... Рекламаларнымы? Алла сакласын! Америка телевидениесында махсус мәдәният казанышларына, фәнгә, табигатькә, географиягә багышланган каналлар бар. Японнар чиктән тыш тәҗрибәле халык, шул каналларны карый торганнардыр?

Каршы яктан калкулыкны урман каплаган иде. Шуңа карап юл тоттым. Урман читендәге уйсулыкта ниндидер сәер нәрсәләр җирдән башларын тыгып миңа карап торалар иде. Туктап күзәтә башладым. Якыйнайгач ачыкланды, кабер ташлары. Бер-берсенә терәлә язып утыртылган әрвахларга куелган таш һәйкәлләр. Шул меңләгән кара ташларның арасында үзара охшашлы, бер калыпта эшкәртелгән ике генә таш та юк иде. Һәркемнең үз тәкъдире, үз тарихы, тарихка батып югалган тормыш юлы. Монда куелган ташлар шуны аңлаталар иде. Аларны нигә шулай бер-берсенә якын, тыгыз куйганнар икән? Кинәт хәтерләдем. Японнар мәетне яндырып аның изге көлен генә җиргә күмәләр. Япон кешесе җир шарының кайсы гына почмагында вафат булмасын, аның көлен туган җиренә җибәрәләр. Хәтта бу яклары белән дә японнар бездән аерылып торалар икән. Туган җирнең изгелегенә, аның газизлегенә сырышып үз туфрагыңа, ата-бабаларың янына кайтып яту.

Кырыс, тетрәндергеч тегәллек һәм мәңгелекне аңларга ярдәм итәрлек планетар материал — ташлар дөньясы иде монда. Һәйкәлләрнең күбесе түгәрәк багана рәвешендә иде. Шулар арасында японнарның милли ритуал әсбаплары саналган таш фонарьлар саклыйлар мәңгелек куенына кереп сыенган хуҗаларын. Ара-тирә кеше кулы тимәгән, җил-яңгыр, зилзиләләр генә эшкәрткән ташлар да очрап куя. Финнәргә һәм японнарга хас ташның җанын, әйтмичә эчендә саклаган серен белү зиратның мәңгелек китапханәсенә әверелдереп бетергән иде.

Беренче тапкыр редакция ихтыяҗы белән Чиченстанга баруым исемә килеп төште. Аэропортта мине яшьләр газетасы редакторы Яхъяев (исәнме икән бу әйбәт кеше?) каршы алды. Табын янына утырып якынлаштык һәм редактор сорады:

— Кая барасыгыз, нәрсә күрәсегез килә?

— Гадәттә, мин танышуымны зираттан башлыйм,— дидем, ил буенча кылган сәяхәтләремне искә төшереп.

Яхъяевның башы иелде. Күзеннән ике яшь бөртеге тәгәрәп чыкты да иренена җитеп туктады.

— Юк безнең зиратларыбыз,— диде редактор.— Без сөргендә чакта кабер ташларын ваткалап урамнарга җәйгәннәр. Зират өсләренең күбесендә дуңгыз абзарлары, чүплек базлары.

Кырымда да шул ук хәл иде. Ярый, безнең манкортлыгыбыздан файдаланып, кырым татарларын бездән, Идел-Урал татарларыннан читләштергәннәр. Ә бит без — бер ана балалары, тамырларыбызда бер төрле кан ага...

Япон зираты янында мин озак, бик озак тордым. Минем өчен ят күренеш, аңлашылмас диярлек серле мохит иде. Күп еллар казарма, кораб каютасы шартларында югалып бетмичә сакланган догаларымны укыгач, якындагы урманга таба юл тоттым. Япон зиратын аркам белән сизеп тора идем. Бу изге урын шушы көнгә кадәр минем тешем үтмәслек тылсым булып калды.

Безнең комсызлыклар... Кол булып яшәү бездәге ике генә сыйфатны исән калдырган, тез чүгеп буйсыну, көчсезрәкне буйсындыру. Тагын бер сыйфат — үз кирәгеннең әсире булып яшәү. Бүгенге көннең прагматигы урманның утынын, суның балык тотарлык тугаен, тауның гараж салырлык урыннарын гына күреп йөри. Мине ят бер күренеш каршылады. Бу күренеш япон урманы иде. Урманның күп серләрен агачлар үзләре генә аңлый алалар. Агач яфракларының серләшүен, мәсәлән. Күпме моң, ни хәтле сер, нинди шатлык-хәсрәтләр яшеренгән шушы тылсымлы яңгырашка!

Япон урманын күрү белән бер манзара исемә төште. Узган җәйне Мәскәү янындагы Истра елгасының плотинасын ремонтлап алдылар. Шул чакта сусаклагычның төбе ачылды. Су төбе репрессия корбаннарының сөякләре белән түшәлгән, дип аңлаткан иде плотинаны төзүдә катнашкан Сталин-Берия тоткыны. Шул сөякләр турында уйлап баргангамы, ләм өстеннән калкып чыккан могҗизаны күргәч, чәчләрем үрә торды. Плотинаны ябар алдыннан су астында калачак урманны аударып ташлаганнар, шуларның төпләре су астында калган. Су туфракны җебетеп юа торган, агач тамырлары тулысынча ачылганнар.

Динозаврлар, дию пәриләре, өрәкләр бер-берсенең бугазларыннан алып сугышалар һәм шул сугышка аждаһалар көтүе, елланнар, жираф скелетлары килеп кушылган тоелды беренче карауга. Әнә, янәшә утырган ике имән төбенең тамырлары бер-берсенә сырышып, үзара кочаклашып үскәннәр. Бусының тамырлары күршесенә һөҗүм итә, күршесе исә тамырларын дошман килгән яктан җыеп, элдертә, кача. Һөҗүм итүче качкан тамырларны эзәрлекләп тормаган, капыл гына борылган да икенче агачка ташланган. Болары үзара чәкешергә тотынганнар. Йа хода, җир астындагы тамырлар дөньясында сугыш һәм дуслык, батырлык һәм куркаклык, күрше җиренә басып керү хөкем итә дип кем уйлаган?

Агачларның җир өстендәге өлеше сабыр гына үсеп утыралар. Ызгыш та, талаш та юк үсемлекләр дөньясында. Җир астында да бар андый үрнәкләр. Әнә, мәгърур имән тамыры янындагы нәни зелпе тамырын ничек назлап үстергән. Киресенчә, сабыр каен мыштым гына күршесе шомыртның канын эчеп корытып бетергән. Җир асты. Караңгылык. Бу дөнья мине тетрәндерде. Агачларның җир астындагы өлешләре кешелек җәмгыятендә булган барлык мөнәсәбәтләрен аңлаталар иде. Шул мөнәсәбәтләрне мин япон урманының читендә үк күрдем. Монда туфрак катламы юка булса кирәк. Тамырлар җирне тишеп өскә чыкканнар. Һәм шуларның үзара көрәшеп, дуслашып, бер-берсен яклап һәм җәберләп яшәүләре күзәтә белгән кешегә күпне, бик күпне сөйли иде.

Тамырлар өстеннән атлап урман эченә кердем. Аларны монда ел саен коела килгән яфраклар каплап бетергән. Һәм мин агачларның өске өлешләрен күзәтергә керештем. Япон урманы безнекеннән башка, аның исе дә бөтенләй икенче, яфракларның сөйләшүе безнең урманнардагы тавышка якын да килми иде. Мондагы үзгәлекне аңлар өчен озак баш ватарга туры килмәде — бамбук.

Бамбук урманын минем Батум янындагы Яшел борында да күргәнем бар иде. Андагы бамбук бары тик кунак, утырмага килгән кыз хәлендә генә иде. Бәлки шуңа күрә мин ул урманның серен аңлый алмаганмын? Япон бамбугы табигый шартларда үсә. Ул монда туган, мең, миллион еллар монда яшәгән һәм японнарның тормышларына тәэсир иткән.

Буын-буын булып үскән яшькелт сары трубаны агачка санайсы килмәгәнне, моны кемдер кулдан ясап, махсус утыртып киткәндер дип ышануны көчкә җиңәсең. Бамбукның тәне сөяктән дә каты. Бигрәк тә кипкәч. Аны, гомумән, эшкәртеп тә булмый. Затлы лакка катыргандай ялтырап торган яшькелт сары кәүсәнең буыннарыннан тырпаеп чыккан

яфраклар туп-туры өскә күтәреләләр дә, аларның очлары гына бераз бөгелеп, читкә таба янтая. Шушы тар, озын, кыштырдап торган үсентене яфракка саныйсы килми. Аларның җил искәндә сәер тавыш чыгарып кыштырдаулары сине шомландырып, туган җиреңнән еракта, чит җирләрдә йөрүеңне аңлатырга теләп, ишарә ясый шикелле тоела. Чагыштыру мөмкинлеге тапмыйча күп нәрсәне аңлап булмый. Ык буендагы түгәрәк күлләр тирәсендә үскән камышлар искә төшкәч, күзәтүем җиңеләеп китте. Әгәр шул камышларны мең тапкыр юанайтсаң һәм мең тапкырлар озынайта алсаң, шушы бамбукка охшашлы үсемлек барлыкка килер иде. Билгеле, бамбук үзе түгел, аңа охшашлы нәрсә генә.

Бамбук урманы якты. Агачларның бер-берсенә терәлә язып үскән куелыкка да кояш нурлары үтеп керә. Аяк асты коры. Атлап йөргәндә аяк астындагы коры яфракларның уалып тузанга әйләнүен сизеп торасың. Шуңа күрә исләр җете, борын эчен рәхимсез кытыклап торалар. Әйтерсең, кемдер самолеттан урман өстенә борыч сибеп киткән.

Яссылыкның читенә килеп җиттем, чокырның кырыенда җир астыннан чыгып торган кыялар күренде. Кыялар арасындагы ачыклыкта яшел ефәк тышлы зур сырма ята иде. Якынрак килдем. Мамык белән сырган, эченә кереп йокларга көйләнгән махсус капчык. Молнияне ачканнан соң юрган итәргә, салкында халат урынына ябынып йөрергә дә көйләнгән. Шактый яңа. Аяк белән читкәрәк этеп җибәргән идем, сырма астыннан кәлтә еланы килеп чыкты. Читкәрәк тайпылдым. Кәлтәнең күзләре миңа текәлгән, тамак асты мылт-мылт килеп калтырап тора. Кем белә, бәлки, чага торган агулы кәлтәдер? Чигенергә туры килде. Япон фарфорыннан ясалган озын муенлы зәңгәр ваза. Аяк очы белән әйләндергәләп карыйм. Матур, шәйтан алгыры, һәм зәңгәр эмаль өстенә алтын белән аждаһа сурәте ясаганнар. Әллә алырга инде. Юк, тыелырга кирәк. Әгәр култык астыма шушы матур вазаны кыстырып кайтсам, биш минуттан кораб эченә гайбәт таралачак. Безнең пассажир да чүплек башында казынып йөри булса кирәк, бүген япон вазасы күтәреп кайтты. Акча юклыгы харап итә. Әгәр кесәмдә акча булып, кибеттән әйбер алып кайтканымны күрсәләр, вазаны төрергә кәгазь табуы катлаулы булмас иде. Юк, ярамый, нәфесне тыярга, абруйны сакларга кирәк...

Кайту ягында, минем комсызлыкны сынар өченме, юл буена ташлап киткән ымсындыргыч әйберләр очрый башлады. Өр-яңа булмаса да, шундый җыйнак кызыл велосипед һәм ике магнитола. Бераз читтәрәк таушала гына башлаган ике пар кроссовка. Йа хода, көч бир пычранмаска! Шулкадәр аласы килә. Юлымны дәвам итү өчен аякларымны көчкә җирдән куптарып алам. Сузылмасыннар өчен кулларымны чалбар кесәсенә батырып куйдым һәм — Аллага шөкер, җиңдем нәфесемне, узып киттем.

## 25

Урманга илтеп ташлаган әйберләрне күтәреп кайтудан бамбук турында уйлану коткарды булса кирәк. Бәлки, чыннан да, Аллаһы Тәгалә минем ялварып теләвемне ишеткәндер?

Көпшә агач — бамбук. Менә нәрсә юл салды японнарның зәвыкларын аңлау тарафына. Бамбук урманында йөргәнгә кадәр мин японнарның күп сыйфатларын аларның иероглифләре белән бәйли идем. «Таң кояшы иле»нең архитектурасын аларның хәрефләре белән чагыштырып карагыз. Язу билгесе иканлеген белмәгән кешегә иероглифнең йорт салыр өчен ясалган сызым булып тоелуы мөмкин. Ә япон рәссамнәренең графикасы? Графиканың нигезендә шул ук иероглиф. Һәр халыкның үзенә генә хас тантана билгесе бар. Аны без европача «триумфаль арка» дип атарга өйрәнгәнбез. Борынгы римлеләрнең шундый капкаларын дикъкать белән

карагыз, французларныкын һәм Әндәлүс хәлифлеге чорында чәчәк аткан маврита ысулындагы капкаларны.

Татарда да булган тантаналы җиңү билгесе. Без аларны өстебезгә мәсхәрәле җиңелүләр өелгәч кенә оныткамбыз. Соңрак, бигрәк тә совет чорында, урысларның җиңүен үзебезнеке итеп кабул итәргә күндергәннәр. Без бит күндәм — күнеккәнбез. «Урыс капкасы» атала татар йортының йөзе, аның горурлыгы. Безнең триумфаль аркабыз шул. Каян килеп чыкты икән бу исем? Башта таларга, аннан соң басып алырга, ниһаять, чукындырырга урыс ябырыла башлагач, сакланыр өчен ясаганнармы икән «урыс капкасы»н? Капка да коткара алмаган безне. Без әле озак еллар җиңелгәч тә баш бирмичә яшәгәнбез. Соңрак, бигрәк тә милләтләргә каршы «халыклар дуслыгы» аталган корал һөҗүм итә башлагач, кылычтан да, туптан да, хәтта атом бомбасыннан да көчле корал уйлап тапканнар совет чоры урыслары. Телне юкка чыгару. Шушы корал водород бомбасы эшли алмаган җимерүне гамәлгә ашырган. Гасырлар буе туктаусыз көрәшеп, җиңәчәгенә ышанып яшәгән халык үзеннән-үзе юкка чыккан.

Япон гыйбадәтханәләре каршында ике багана өстенә утыртылган дүрт кырлы өрлек. Өрлекнең башлары дугаланып өскә таба каерылып тора. Гаҗәп матур, тантаналы күренә аларның «триумфаль арка»лары. Шушы гап-гади корылма японнарның иероглифләрен хәтерләтә. Бу бик күптәннән килгән борынгы билге. Борынгылык — матурлыкның нигезе нәкъ шунда.

Урыслар 1905 елдагы сугышта япон утрауларын яулап алган булсалар, аларның иероглифләрен юкка чыгарып, телләреннән яздыра алырлар идеме икән? Бик озак баш ватам мин бу турда. Ниһаять, аңлыйм. Йөз ел, мең, биш мең ел бу утрауларны колонизаторлар итеге таптаса да, «Таң кояше иле» кешеләре телләрен, гореф-гадәтләрен барыбер саклап калырлар иде. Искиткеч тирәнгә, каннарына, күзәнәкләренә, әллә кайларга кереп урнашкан японнарның японлыгы... АКШ гаскәрләре японнар җирен басып алганга ярты гасыр. Баш бирәләрме соң японнар? Алар, киресенчә, җиңелүләреннән файдаланып, америкалыларны японлаштыралар...

Япон иероглифен үзләштерергә безнең көчебез җитәр идеме икән? Чиктән тыш ялыктыргыч, авыр эш бит бу. Тырышлык белән генә дә җиңеп булмый, әгәр шуңа өстәп синдә Прометей түземлеге, Сократтагы хәтер, ихтыяр көче, күзәтүчәнлек һәм рәссамлек сәләтләре булмаганда. Әгәр синдә бу сыйфатлар булмаса, син надан калырга тиешмени? Без нәкъ «Тан кояшы иле»ндәге кешене япон итә торган мәсьәләгә килеп төртелдек. Әгәр япон баласында бу сәләтләр тумыштан булмаса, ул аны тырышлык белән, остазлар ярдәмендә әкренләп үзләштерергә тиеш. Менә шушы иероглия һәм белем, тәртип һәм тырышлык, төгәллек һәм камиллек үзләштерү дәверендә японнардагы кешелек сыйфатлары чарлана, әкренләп гадәткә әверелә.

Бамбук урманында йөргәндә мин япон иероглифының каян килеп чыгуын ачыкладым. Хәреф ясарга бу халыкны бамбук өйрәткән. Дөрес, иероглиф японнарга Кытайдан килгән, димәк, кытайлылар өчен дә бу үсемлек өлге булып хезмәт иткән.

Урманнан чыгып китәр алдыннан мин көрәккә охшашлырак тимер табып бамбук агачының төбен чокып карадым. Вак таш һәм кызыл балчык. Каян ашлама аласың икән син, мескенкәем? Японнар үзләре дә коры таш кыялардан торган атауларда яшиләр. Бәлки алар синнән өйрәнгәннәрдер иң кырыс, иң кыргый шартларда да төшенкелеккә бирелмичә тормыш корырга?

Япон җирендә истәлеккә нәрсәдер калдырырга кирәк иде. Тигр белән Ефрат кушылган җиргә мин пәкемне ыргыткан идем. Бәлки, бамбук агачы төбенә пәкемне күмеп калдырырга кирәктер? Чалбар кесәсеннән пәке чыгардым. Юк, калдыра алмыйм мин Барселонадагы

дустым Педро Гонсалесның бүләгән. Кульяулыкны? Тукыма бер-ике елдан череп юкка чыгачак. Сәгатемне? Сәгать юнәлтә алырлык акча таба алырмынмы икән? Куртка кесәсен актара башладым. Каләм килеп чыкты. Паркер. Кызганмаска кирәк. Китапларым чыкмый башлады. Бөтендөнья язучылар конгрессына багышланган язмаларымны башта «Казан утлары», аннан соң «Казан» дигән журнал басмады. Каләмне Хонсю утравындагы бамбук төбенә күмәргә дә язудан туктарга кирәк. Безгә алмашка башка төрле язучылар килә башлады. Әдәбият өлкәсендә базар мөнәсәбәтләре урнашу белән безне барыбер кысырыклап чыгарачаклар.

Каләмемне кулъяулыкка төрдем, бамбук төбендәге чокырга салдым һәм өстенә яссы таш ябып куйдым. Күмә башладым. Ялыктыргыч уйланулар, сагынулар, өмет-багланышлар, йокысыз төннәр һәм йөрәк көче калды туфрак астында. Бер тын нәни кабергә карап тордым да кайтыр юлга чыктым. Урман читендәге иң юан бамбукны кочакладым, битемне агачның шома кайрысына терәдем. Агачның тәне салкын иде. Рәхәт булып китте. Сафлык, эчкерсезлек исе аңкый иде яфраклардан. Каным, күзәнәкләрем таный иде бу исерткеч татлы исне. Кылган. Кыпчак далалары. Алтай таулары. Без — кардәшләр, агач мине аңлый алачак...

## 26

— Мин татар,— дидем бамбукка.— Ишеткәнең бармы? Син белергә тиеш бу милләтнең Тын океан ярларыннан Карпат тауларына кадәр җәелгән киңлекләрдә яшәгән халыкны. Хубилай хан хәтта сезнең утрауларны яулап алмакчы булган. Япон алласы җибәргән илаһи җил — Камикадзе челпәрәмә китергән Хубилайның корабларын. Шуңа күрә сез колониаль коллыкның нәрсә икәнлеген белмисез. Хоккайда атавына якын бер бугазны «Татар бугазы» атап йөртәләр. Ул исемне японнар кушканнар, чөнки татарларның җирләре шул бугазга килеп терәлә торган булган. Хәзер без, татарлар, Идел буенда яшибез. Кырымдагы кан кардәшләребезне сөргенгә кудылар. Бары тик татар булган өчен генә. Аларның күбесе шунда кырылып бетте. Идел буе татарларын да кудылар. Бер юлы түгел, әзләп, әкеренләп куа торып, җиребезгә әтрәкәләм китереп тутырдылар. Хаҗитархан татарларын нугай дип рәсмиләштерделәр. Себер татарларының саны шул кадәр әзәйде, аларны бәлки тиздән бөтенләйгә бетерерләр? Без әле һаман чәчелүне, таралып таркалуны дәвам итәбез. Син мине, бамбук, аңлыйсыңмы?

Дымлы океан җире бамбук яфракларын җиңел генә селкетеп куйды.

Рәхмәт сиңа, аңлыйсың икән. Тыңла, мин әле сөйли генә башладым. Татар халкының киләчәген мин японнарның тормыш-көнкүрешен, аларның яшәеш ысулларын күргәч кенә аңлый башладым. Син бит бу илнең халкында зәвык тәрбияләгән агач. Японнарның ничек яшәүләрен, аларның өмет-багланышларын сиңа сөйләп торасы юк, аларны син миннән яхшырак беләсең. Минем халкым милләтне саклый торган күп, бик күп сыйфатларын югалтып бетергән. Ул сыйфатлар урынында бушлык булыр иде, әгәр шул бушанган җиргә искиткеч әшәке сыйфатлар бәреп кермәгән булса. Колониаль шартлар нинди сыйфатлар тәрбияли, беләсеңме? Син белмисең, чөнки японнар иректә, мөстәкыйльлектә яшиләр. Колониаль шартларда иң беренче ялагайлык үсеп чыга, аннан соң битарафлык һәм бер-береңне күрәалмау, хөсетлек. Ул сыйфатларның барысын да саный башласаң, озакка китәр иде, шуларның бары тик берсенә, телсезләнүгә тукталыйк...

Син, бамбук, японнарның туган телләрен күз карасыдай саклауларын беләсең инде. Иң борынгы, мәҗүсилек чорындагы сүзләре дә исән килеш сакланган. Японнар аңлый алганнар: тел эчендә милләтнең җаны, аның

иманы, соңгы чиктә, аның язмышы яшеренеп ята. Туган телдә милләтнең дистәләгән гасырларга сузылган үткән юлы, тарихка тупланган вакыйгалары, киләчәккә илтә юлның маяклары, борылмалары, сикәлтәләре. Бары тик туган тел исән-имин сакланган очракта гына милләтнең юлындагы куркыныч упкыннарны урап узарга була. Японнар телнең халыкта өч тапкыр зуррак икәнлеген беләләр: телдә тарих, бүгенгелек һәм киләчәк. Без, татарлар, шул үзебездән өч тапкыр зуррак байлыкны совет чоры пропагандасына алданып юкка чыгарып бетерә яздык. Аңлыйсыңмы син безнең нинди хәлдә икәнлегебезне?

Аңлыйсың, билгеле. Син бит җир йөзендәге иң тырыш, иң эшчән, иң зәвыклы милләтне тәрбияләп кеше иткән агач. Менә тыңла. Мин сәяхәткә чыгып киткәндә, татар хыялыйлары Татарстанны башка республикалар белән тигезләү өчен көрәш башлап җибәргәннәр иде. Эчем сизә: безне җиңәчәкләр. Беләсеңме нигә? Татарларда милләт мәнфәгате өчен көрәшүчене халык дошманы итеп күрсәтү бер тиен тормый. Беренчедән, бездә Алла урынына түрә. Икенчедән, без, татарлар, «халыклар дуслыгы» дип аталган агитроп уйдырмасын өлкән абыйларга буйсыну дип кабул иткәнбез. Хәтта без дагалы итек белән җаныбызны, изгеләребезне таптаган чакта да елмаеп, «мижнәтсиянәлни кәнфликет» чыга күрмәсен дип авызыбыздагы канны йота-йота елмаеп ятабыз. «Әгәр сез, татарлар, урыс сүзен тыңламый башласагыз Карабах башланачак»,— дип тукып торалар безгә, һәм без искиткеч самими томаналык белән шуңа ышанабыз.

Мин моны синә генә сөйлим, бамбук, чөнки син безнең бу фаҗигабезне аңлый аласың. Без, татарлар, сугыш карында «арысландай батырбыз» дип, гасырлар буе шапырынып килдек. Без, чыннан да, туп ите булуда искиткеч батырлыклар күрсәтеп яшәдек. Кем файдасына китте ул батырлык? Урыс империясен ныгыту, аны саклау файдасына. Һәм шул батырлык безнең иң яхшы, иң олпат ирләребезне кыра торды. Татар җәмгыятендә ирләр бетте диярлек. Безнең җәмгыять — хатыннар, колхоз эшендә күзләрен салам тузаны баскан хатын-кыз җәмгыяте. Японнарда исә, син беләсең, ирләр җәмгыяте. Бездә тынычлык елларында да ирләр туктаусыз кырыла тордылар. Аларны урыс алып килгән аракы кырды. Кырылу дәвам итә. Аңлыйсыңмы, дәвам итә татар инкыйразы!

Бусы — зарымның төп өлеше. Тыңла әле дикъкать белән, бамбук дустым. Сугыш кырында татар арысландай батыр булса, җәмгыятьтә ул куяннан да куркак, бигрәк тә чиновник каршында. «Мижнәтсиянәлни кәнфликет»не урыс өлкән абзыкайларга сүзсез буйсыну дип аңлый. Без, татарлар, урыс түрәләренең, аларның барлык чиновникларының күңелен күрү дип кабул иткәнбез. Мең татар җыелган җиргә бер урыс килсә, без өлкән абыйлар телендә сөйләшә башлыйбыз. Алар татар телен ишетү белән читкә борылалар. Һәм алар хаклылар. Урыслар үз телләреннән оялып йөрсәләр, без дә «великий, могучий»га төкерер генә идек...

Кайтыйк әле минем Караярыма, бамбук дус.

Коры яфраклар бер-берсенә ышкылып, кыштырдап алдылар. Баш тартасыңмыни? Нигә? Караярның чишмәсен туктатканга мы? Кое казырбыз. Әрмәннәр? Нигә куркасың алардан? Эшләргә киләләр бит алар, ярдәм итәргә. Эш майтаручылар артына яшеренеп кигән мафиозилар? Шулар куркытамени сине? Син дөрес аңлыйсың. Кемдер оештыра минем туган төбәгемдә булачак Карабахны. Син белмисеңме? Төрки халыкларны, мөселманнарны юкка чыгарырга тырышкан әрмән экстремистларымы? Бер алар гына түгелмени? Яңа Лубянка да катнашамени бу кара эшкә?

Бамбук дус, тыңла мине. Кайтыйк без Караярга. Аңлатыйк минем авылдашларыма. Халыклар дуслыгы ул татар мәкалендәге «бәйрәм ашы — кара каршы». Барып карасыннар әле минем авылдашларым шул кавказ халкының яшәгән җиренә. Алар татарларны җирләренә аяк та бастырмаячаклар. Куып җибәрәчәкләр алар караярлыларның мөселман икәнлекләрен белү белән. Ярый әле үтереп ташламасалар...

Эчәләр дисеңме минем авылдашларымны? Дөрес, эчәләр. Нишләсеннәр, мескеннәр, эшсез утыралар бит. Алар башкарасы эшне әрмәннәргә бирәләр...

Син миңа нинди киңәш бирәсең, акыл агачы? Аңлатырга? Аңламыйлар алар. Алар сукыр хәзер. Күзләре — җитәкчеләрдә. Алар ишетмиләр. Колаклары да җитәкчеләрдә. Алар фикер йөртә, уйлый, чынбарлыкны аңлый да белми башлаганнар, чөнки инде менә алтмыш җиде ел минем авылдашларым өчен председатель аталган җитәкче үзе генә уйлый. Дөресен әйткәндә, ул да уйламады, өстән бирелгән боерыкны кабатлап торды ул. Әле һаман шулай. Хокуклары кая дисеңме? Юк аларның хокуклары. Җирләре дә колхозныкы, куллары да, хәзер инде әкеренләп хатыннарын да югалта башладылар. Теге читтән килгән кара кешеләр пычрата аларның хатыннарын. Куып җибәрергә? Әйттем бит аларның хокуклары юк дип. Председатель аларның хокуклары.

Баш ватмыйк, бамбук дус. Үз күзең белән күрмәгәч, анда яшәмәгәч, син барыбер аңлый алмассың. Син миңа шуны әйт, әгәр мин авылдашларымны әйдәп шушы утрауга алып килсәм, аларга урын табылырмы икән? Юк, монда калырга түгел, японнарга карап гыйбрәт алыр өчен генә. Монда килергә минем авылдашларыма өлкән абыйлар рөхсәт итмәс дисеңме? Дөрес, татарлар солдатча буйсынудан арына алмаячаклар. Урыс империясен алда бик зур, бик тә катлаулы фаҗигаләр көтә. Империя таркала башлау искиткеч әшәке куркынычлар китерәчәк. Алар үзләре әллә аңламыйлар, дөресрәге, аңларга теләмиләр. Дөнья күләмендә иң бөек, иң көчле ил ничек юкка чыксын инде, дип юаналар алар. Тарих шаһит, нәкъ иң зур, иң көчле илләр юкка чыга килгәннәр. Империяләрнең юкка чыгу сәбәбен сиңа сөйли башласаң, озакка китәр иде. Әнә, син, бамбук, тәрбияләгән японнар юкка чыгудан котылу юлын тапканнар. Урыслар исә бу юлга баса алмаячаклар. Гөнаһлары чиктән тыш зур аларның, алар түккән каннарны, урыс койган күз яшьләрен җир шары күтәрә алмый башлады. Империя, һичшиксез, юкка чыгачак. Без, татарлар да, юкка чыгачакбыз, әгәр урыслашудан туктый алмасак. Юкка чыгып бетә дә яздык инде. Белмим, туктала алырбызмы икән. Их, минем милләттәшләремне шушы утрауларга алып килеп японнарның нинди юл белән инкыйраздан котыла алуларын күрсәтеп булса иде. Гади халыкны чит илләргә йөртмиләр шул...

Бамбук туган, мин сиңа серләремне сөйләдем. Рәхмәт сиңа зарларымны дикъкать белән тыңлавың өчен. Бу безнең тәүге һәм соңгы күрешүебез. Үс, ныгы, тамырларыңны тирәнгә җибәр. Мин сине онытмам. Мөмкин булса, син дә мине сирәк булса да искә ал. Сау бул, бамбук! Бәхилләмине, япон агачы!

## 27

Иртәнге алтыда аврал уйнадылар. Йөкне бушатып бетергәннәр. Хәзер без Владивостокка кереп авыру мотористны калдырып китәргә тиешбез. Ул мескенне Япониядә дә калдырып китәрлек иде. Монда аны тизрәк тә терелтерләр иде. Валюта түлиселәре килми. Ә бит авыру диңгезчене кораб белән Владивостокка илтеп тапшыру йөз тапкыр кыйммәтрәк төшәчәк. Кораб чыгымына хисап бирү җиңелрәк.

Владивостоктан соң Гонконгка кереп ягулык алырга тиешбез. Ә нигә Владивостокның үзендә генә алмаска? Мурман пароходчылыгының Владивостокта лимиты юк. Гонконгтан соң Кытай портлары. Без анда йөк төяргә тиешбез. Кытайдан соң кабат Сингапур, аннан соң Сүәеш каналы. Португалиянең башкаласы Лиссабон. Анда без йөкнең бер өлешен калдырырга тиешбез. Лиссабоннан соң Дания. Бу илнең кайсы портларына тукталуыбыз билгеле түгел әле. Минем Копенгагенны күрәсем килә. Андерсен әкиятеннән туган Русалка сыны белән кабат очрашасы иде!

Чиктән тыш көчле теләк тормышка ашмый кала. Тәкъдиребез җиденче кат күкләр кулында...

Матрослар швартов бауларын палубага сөйриләр. Корабның машинасы эшли башлады. «Капитан Нугай» калтыранып алды. Коерык астында су кайный. Ачык диңгездә шторм. Хәзер ул безне чайкалдыра, дулкыннар корабны кыйнарга тотыначаклар. Әгәр Көньяк Кытай диңгезендә тайфунга юлыксак, исән котыла алырбызмы? Мин хафаланам. Хафаланырга хакым бар минем. Корабта бер карыш запас бау калмады. Авария вакытында кулланыр өчен генә тотылган запастан бау кисеп алып боцман үз машинасын, капитанныкын, өлкән штурманның «тойота»сын палубага беркетеп бәйләп куйды. Машина көпчәкләре урыннарыннан кузгалмасын өчен авария вакытында гына тотыла торган агач брусларны кисеп тәгәрмәчләр астына куйды. Калган машиналар шторм вакытында диңгезгә коелып бетсенмени? Экипаж әгъзалары машиналарын палубага беркетү өчен авария запасыннан бау, агач брус, агач чөйләр урлый башладылар. Запас юкка чыкты. Зур җинаять иде бу. Куркыныч җинаять. Корабның иминлеген тәэмин итү өчен капитан чара күрә алмады. Аның кулы пычранып, арт саны тизәккә батып өлгергән иде инде.

Карынына илле җиде мең монна йөк сыйдыра алган зур океан лайнеры Рәсәй империясен хәтерләтә иде. Аның иминлеген сакларга тиешле диңгезчеләр, үз машиналарының иминлеген кайгыртып, корабның язмышын куркыныч астына куйдылар. Рәсәйдә дә нәкъ шушындый урлашу, җәмгыять милкен талау, үзләштерү бара иде. Белмим, без әйләнеп кайтканчы СССР дип аталган җир йөзендәге иң зур, иң пычрак һәм иң канлы империядә сугышлар кузгалып ахырзаман башланмасмы икән?

* * *

Сәяхәтнең икенче яртысында Кытай, Гонконг, Португалия, Дания, Мурманга әйләнеп кайткач күргәннәрне дә укучыга сөйләргә кирәк иде. Аларның барысы да көндәлеккә теркәлгәннәр. Белмим, сөйли алырмынмы икән?...

*1991—1997 еллар. Мәскәү — Баулы.*

# ШИГЪРИЯТ



## Бикә Рәхимова

### Әйтү кирәкме?..

Чирмешәннән күптән сулар алмыйм,
Чумылдырып зәңгәр чиләкне,
Ярларына чыгып шомырт җыймыйм...—
Хатирәләр эзләү кирәкме?

Сулар кермим, баштүбәнгә чумып
Чирмешәнем яры өстеннән...
Балачагым, яшьлек хатирәсе
Еллар ялкынында өтелгән.

Әкиятләрдә түгел, чында иде
Бер чиләкләп җиләк җыюлар.
Капчык-капчык чикләвекләр җыйдык,
Булса да бу эшкә тыюлар.

Мич башында кибә алтын чики,
(Чуерташтай!) алтын гәрәбә...
Җылы куеныңнан балаң читкә
Тәгәрәде, әнкәй, әрләмә...

Батаганның урыслары чыгып
Юлбасарлык итеп торалар,
Җыйган чикләвекне чәлдерергә
Җыйнаулашып мәкер коралар.

Әнкәй кайта тулы капчык белән —
Туры юлда тора караклар,
Әйләнечтән унар чакрымнарны
Әнкәй бәгърем ничек ул атлар...

Әйләнечтән атлый халкым һәрчак,
Керәшеп атлый, әмма ук сына...
Каракоштан чукылганнар шулай
Гомере буе ирек юксына...

Яшьлегемнең — яшьнәвемнең минем
Ялкыннары өтә йөрәкне...
Хатирәләр — безнең бүгенгебез,
Хәлебезне әйтү кирәкме?..

## Казанда Хәтер көне

*15 октябрь, 1996.*

Хәтер көненә җыелдык,
Мең кешелек булыр төркем,
Казанлылар битарафмы,
Килеп кушылмасмы беркем?

Суык, салкын. Җиле салкын,
Усал эттәй килеп тешли.
Бу гулянье түгел, кабәм,
Чәй кайнамый, ите пешми.

Миллион ярым кадәр кеше
Яши булыр башкалада,
Татар диеп шул бер меңне
Күрсәтәбез башкаларга.

Ачу катыш яшьне йотам,
Шуннан ары әмәл бармы?
Үз халкыма үпкәлимен,
Аннан авыр хәлләр бармы?

Керәшеп үлгән бабайлар
Япь-яшь егет, агай чакта,
Хәтерләре ялтырап ята
Ак болытта, яшьле чыкта.

Ак болытлар килә, китә,
Кадаклап туктатып булмый,
Ярамыйдыр Хәтер итеп
Бер такта булса да куймый.

Такта түгел, мәһабәт бер
Сын-һәйкәлгә лаек алар,
Карап Хәтер җыяр иде
Рухи сәрхүш, лаякыллар.

...Яр Чаллылар килеп керде
Кырык тугыз автобуста,
Яшьләр булып җиргә тамды
Күңелдәге боз да, тоз да.

Сафлар китте Ханмәчеткә,
Кушылдылар үткән-сүткән.

Ишле янына куш килә —
Бу хакыйкать инде күптән.

## Әткәй, хатларың...

Әткәй, бәгърем, хатларыңны укыйм,
Бар язганың без ул — балалар,
«Бәрәңгегез бармы язга кадәр?
Килмәсен лә берүк бәлаләр».

Әйтерсең лә ут эченә түгел,
Киткән бары бераз читкәрәк,
Бар кайгысы: йөрәк парәләре,
Үзенекен сөйләү иртәрәк.

Хат саен да сөекле зәүҗем[1],
Әүладларым (без ул, балалар!)...
Ни бер сүзе булсын — җәһәннәмдәй
Сугыш-яуда ничек соң — алар...

«Углым Госман, суны үзең ташы,
Җик үгезне, яисә этнеме...
Әниеңә авыр китермәгез...
Миңлебикә тәпи киттеме?..

Әрбәлектән печән ташыганда
Салуланып чана аумасын...
Эчендәме утның дип сорыйсыз,
Улым, әдрис әйтер кайдасын.

Габбас углым, хатны частырак яз,
Хатлар белән сагыну аткарам,
Әнкәң хатын бергә кушып җибәр,
Хат килгәндә төштә ат күрәм...»

Ленинград дип аталган икән
Әткәй кичкән утлы фронтлар.
Кайтмады шул әткәй, кайткан кеше
Бер аяктан да ул тыраклар...

Ә син, әткәй, яралы аягың
Төзәлгәнен тагы көтмичә,
Ут эченә кереп өтелгәнсең,
Ут туктамый күмер итмичә...

Татар сөякләре Петербурның
Нигезенә шыплап түшәлгән...
Империяне терәтеп, әткәй,
Синең сөякләрең өстәлгән...

[1] Хатыным.

## Жиңеләбез...

*Жиңеләбез. Әйе, чигенәбез.*
Рәфыйк Юныс.

Жиңелү — чигенү дип кенә
Йөрәккә бәлзәмнәр ягылмый...
Дошманың асылын яшереп,
Тиренең ниндиен ябынмый.

Чигенү чирүең булганда
Ышаныч калдыра «бәлки»гә...
Борынгы Болгарым жирендә
Ялгызым калдым мин Әлкидә...

Кем бар соң татарда туктаусыз
Азатлык байрагын тотучы
Нәкъ бүген! — иртәгә, димичә,
Ашкынып ут-ялкын йотучы?

Чигенү!..
Бу хәтле өметле ул сүзне
Әйтсәң дә — бәхеткә ышану?..
Бар халкың бер йодрык булмагач,
Нишлисең, аптырап бушану.

Ни жиңү, һичьюгы чигенү
Бизәми без килгән юлларны,
Без кемнәр дигәндә — Тарихның
Тузгыган иярчен йоннары.

...Тузгыган йоннан да кайчакта
Сугалар келәмнең матурын —
Албасты туфанын аралап,
Төзиләр дәүләтнең татуын.

## Яфрак-гөлгәдер...

Кар да шулай тоташ ишеп яумый,
Ява алмый айлар буена,
Йолдызлар да атылмыйлар учлап,
Берләп атыла, чумып уена.

Бер ай буе сары яфрак ява,
Ничек түзә яфрак йөрәге,
Куырылып калтырана яфрак —
Куа аны үлем өрәге.

Күк биеклегендә йөзгән яфрак —
Күк иде лә аның мөнбәре.
Ята әнә сүнгән яшел йолдыз,
Яфрак хәзер жирнең мендәре.

Озын-озак йокыларга китәр
Яфрак-мендәрендә Жир-ана,

Бөгәрләнеп яткан җайлы-ипле,
Тук сыердай күши, күр әнә.

...Бу дөньяның гарасаты-уты
Нечкә күңел яфрак-гөлгәдер,
Дөрли-яна, бәргәләнә бирәү,
Битарафлык кылә кемгәдер.

## Аурупада

*— Альп таулары дигән сүз ни мәгънә белдерә?*
*— Зур таулар дигәнне аңлата.*
(Аустрия чигендә сөйләшүдән)

Мендем Алып тауларының башына,
Карадым үзәннәр төбенә:
Елгачыклар ага, исме, бәлки,
Кайсы Зөя, кайсы Гөбенә?..

Төрки бабам булган, исме аның
Җиһанда бер яугир Атилла,
Яуларының кайтавазы калган —
Төркичәләп таулар атала.

Гел таныш та кебек бу тирәләр:
Баштан-башка тоташ болынлык,
Кичү белән Әлки[1] арасыдай,
Яшел җәйгән хозур бер тынлык.

Уйламыйсың Үзәк Аурупаның
Нәкъ уртасы диеп бу җирләр,
Технократик җәннәт корсалар да,
Табигатьне саклый чын ирләр.

Хушбуй сипкәнмени, тәмле һава,
Йә Ходаем, әйтмим көнләшеп,
Кодрәтеңдә бар — Үз Иркеңдә,
Без дигәнчә булмый өләшеп.

Өләшергә... ул сәдака түгел,
Ходай биргән түгәрәк бәхет.
Тик шулай да үзләренә булсын,
Туган җир — безгә алтын тәхет.

[1] Болгар ягы Әлки районы авыллары.



# Резеда Вәлиева

## Юлга чыктым, кыен юлга, авыр юлга...

Юлга чыктым, кыен юлга, авыр юлга,
Атлый бирәм карамыйча уңга-сулга.
Бу юлны бит инде күпләр таптап үткән,
Атлаулары нигә болай авыр икән?

Җилләр бәрә әле уңнан, әле сулдан,
Чык син тизрәк, дигән кебек, чык бу юлдан.
Әле усал бүре булып улый алар,
Әле угры-карак булып сызгыралар...

Тик мин һаман үҗәтләнеп атлый бирәм,
Чөнки шул мин бер нәрсәне яхшы беләм:
Кыен булган саен юллар кадерлерәк,
Бер кызыксыз җиңел юллар нигә кирәк?

Авыр булсаң авыр бул син әйдә, юлым,
Эштән генә арып талмас ике кулым.
Сәламәтлек-саулык бирсә газиз Аллам,
Авыр диеп юлларымнан туктап калмам.

Киртәләрне үтә-сүтә атлап киләм,
Юл очымда илаһи бер балкыш күрәм.
Күз буучы ялган мираж — балкышмы ул?
Хыялый бер хыялмы ул, ялгышмы ул?

Ни булса да җаным һаман шунда тарта,
Барган саен күңелем үсә, көчем арта.
Бу сихерле, серле көчтән ничек китим,
Хыялый шул бу җан гынам, ни хәл итим?..

## Йөрәгемә куштым башка сине яратмаска...

Йөрәгемә куштым башка сине яратмаска,
Синең зәңгәр күзләрең дип җан атмаска.
Юк, кирәкми зәңгәр күзләр, ялган күзләр,
Сине күрмичә дә түзәр җаным, түзәр, түзәр.

Акылым белән аңа барын аңлатырмын,
Хыянәтче күзләр алар, дип әйтермен.

Җаным минем сизгер бит ул, ул тиз сизәр,
Ул яратмас башка сине, сүнәр, бизәр...

Син дип инде мин аһ орып ут йотмамын,
Хыянәтең мәңге-мәңге онытмамын.
Зәңгәр күзләр хыянәтче була икән.
Юк, кирәкми, сөймим сине, сөймим бүтән,

Әй, Ходаем, ышаныплар куймас микән?..

## Ялгыз итмә мине, Ходаем...

Күңелләрем тулы моңдыр бүген —
Ялгыз каршыладым май аен.
Ялгызлыклар авыр җаннарыма.
Ялгыз итмә мине, Ходаем.

Ризыкларым тәмсез, өем ямьсез,
Күңелемнең тапмыйм бер җаен.
Каралмасын күңелем көзгеләре,
Ялгыз итмә мине, Ходаем.

Кояш көлә, кошлар оя үрә,
Бәйрәм итә җирдә яз ае.
Язлар булсын һаман күңелемдә,
Ялгыз итмә мине, Ходаем...

## Яшә, сөю

Йөзләремә салкын җилләр исә иде,
Гомер юлым сүлпән генә үтә иде,
Тәүге кырау күргән моңсу чәчәк кебек
Күңелем инде килер көзен көтә иде.

Кинәт кенә син чыктың да юлларыма,
Кулларымны алып назлы кулларыңа,
Шундый сөю белән бактың күзләремә,
Гүя кояш нур сирпеде йөзләремә.

Нур сирпеде, гүя гөрләп язлар килде,
Кояш көлде, галәм көлде, дөнья көлде.
Кыялардан бәреп төшкән ташкын кебек
Гомер юлым тетрәтерлек сөю килде.

Сөю килде, гүя яшьлек кайтты кабат,
Сүнеп барган күңел яшьнәп ярды канат,
Ярды канат, очты зыңлап ерак-ерак,
Очты биек, карлыгачтай уйнап-уйнап.

Сөйде күңел, сөйде янып, сөйде шашып,
Упкыннарга убырылып, күккә ашып.
Моң көзләрдән шат язларга дәшә-дәшә,
Яшә, сөю, яшә яшьнәп, мәңге яшә!

## Дүртьюллыклар

* * *

Әле җырлыйм, әле елыйм, әле көләм,
Тормыш дигән олы юлдан шулай киләм.
Ялгыз түгел, ләкин кайгы-шатлыкларда:
Ни күрсәм дә бергә күрәм халкым белән.

* * *

Өзгәләнмә, дустым, яшьлек үтә,
Бусагада картлык көтә, дип.
Картлык шатлык түгел, тик шулай да...
Тик шулай да ул да үтә бит...

* * *

Йөрәк белән акыл озак талаштылар,
Бер көн килеп килештеләр, яраштылар.
Акыл, алып дилбегәне үз кулына,
Ярды мескен йөрәгемне, ярды гына.

* * *

Бу дөньядан күп сорамыйм мин тагын да:
Тик син генә, тик син генә бул янымда.
Күзләреңдә сөю нуры балкып торсын:
Күңелемдә мәңге сүнмәс ялкын булсын.

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

# КОЯШЛЫ ИҖАТ



*Үзенең бөтен гомерен милли матбугатка, әдәбиятка багышлаган гүзәл шәхесләр бар. Бу айда үзенең олы юбилеен билгеләп үтүче Кояш Тимбикова да әнә шундый якты язмышлы әдипләребездән берсе.*

*Кояш Закир кызы Тимбикова 1937 елның 16 ноябрендә Татарстанның Чистай районы Наратлы Елга авылында укытучы гаиләсендә туган. Шул ук районның Иске Роман һәм Каргалы авылы мәктәпләрендә укып ун класс тәмамланганнан соң, 1954—1959 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә югары белем ала, аннары егерме елга якын (1959—1979) «Азат хатын» журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире һәм журналның җаваплы секретаре булып эшли. 1979—1982 елларда ул — «Казан утлары» журналының җаваплы секретаре хезмәтендә, 1983 елдан бирле шул ук журнал редакциясендә бүлек редакторы вазифасын башкара.*

*К. Тимбикова үзенең беренче иҗат тәҗрибәләре — очерк характерындагы журналистик язмалар һәм хикәяләре белән көндәлек матбугатта 1959 елдан күренә башлый. Алтмышынчы елларда Татарстан, Башкортстан газета-журналларында, Татарстан китап нәшрияты чыгарган «Кояш безгә елмая» (1962), «Тылсымлы таяк» (1964) кебек күмәк җыентыкларда аның күп кенә очерклары, хикәяләре басыла, ә 1969 елда «Зәңгәр күлмәк» исемле хикәяләр һәм «Күңелләргә күләгә төшмәсен» исемле очерк китаплары дөнья күрә. Тагы бераздан, 1971 елда, «Инешләр Иделгә коя» исемле күмәк җыентыкка яшь авторның күләмле беренче әсәре — «Синең өчен» дигән повесте урнаштырыла.*

*Аннан соңгы елларда ул авылның хезмәт кешеләрен, бигрәк тә хатын-кыз образларын шактый нечкә психологик алымнар белән гәүдәләндергән бер төркем хикәяләр («Сөлге булсын бүләгем», «Шикәр Гайшә», «Таяныч», «Ут» һ. б.), КамАЗ төзүче яшьләр тормышына багышланган «Агым уртасында», археологлар турында «Тәңкәле тау» һәм мораль-этик проблемаларны күтәргән «Кышкы талпыну», «Ярлар биек» һ. б. исемле повестьларын иҗат итә.*

*К. Тимбикованың очерк, хикәя һәм повестьлары тупланган ике дистәгә якын китабы басылып чыкты. Аның аерым әсәрләре рус һәм башка кайбер милли телләргә дә тәрҗемә ителгән.*

*Без Кояш ханымны олы юбилее уңаеннан кайнар котлыйбыз һәм укучыларга әдибәнең яңа әсәрен тәкъдим итәбез.*

## Кояш Тимбикова

# НӘФЕСЛЕ НӘФИСӘ

хикәя

*Нәфесенә кол булса, солтан да — колның колы;*
*Нәфесенә хуҗа булса, кол да солтаннан олы.*

Халык сүзе.

Жанындагы яңа талпынышның ни икәнлегенә Нәфисә, һич көтмәгәндә, трамвайда гапләшеп баручы хатыннар сүзен ишеткәч кенә төшенде. Арадан берсе ап-ачык әйтте: «...үлемтеккә, дигән булып, акчаңны кассага сала күрмә! Хәзер бөтен кеше ни бар байлыгын йорт-мазар, гараж, кибет шикелле корылмалар сатып алуга кертә».

Ул кысан бүлмәләренә кайтып егылганда көн караңгыланган, тамак ачыккан, хәл беткән, әмма күңел дигәне көр иде. Ире Габделбәр, гадәтенчә, кәнәфидә йокы симертә. Нәфисә каударланып чишенә башлаган иде, түшеннән саллы гына төен дөреллдәп идәнгә төште. Шул тавыш, кирәкмәгәнгә, Габделбәрне уятты да инде. Җитмәсә, акча төене нәкъ аның борын төбенә барып туктаган иде. Ир кеше күзен ачып җибәрүгә:

— Бусы ни тагы? — дип сорап куйды.

— Акча! — диде Нәфисә.— Бөтен кассалардан каердым да алдым. Без генә, сарыклар кебек, берни белми ятабыз икән бит. Халык саклык акчаларын барлап, кирәкмәгән нәрсәләрен сатып, кузгалмый торган әйбер җыя икән. Акчаларны алмаштырырга, кассаларны банкротлыкка чыгарып бетерергә торалар икән.

— Син бит әле безнең ул саклык акчаларны үлемтеккә дип тота идең?..

Габделбәрнең сораулары һавада эләгеп калды.

— Сиңа сөйләп торган мин җүләр! — дип чәпченә-чәпченә, Нәфисә коридорга чыгып китте.

Алар шушы, өй дисәң, өй түгел, фатир дисәң, аңа да охшамаган — әлеге ун-унбиш метрлы бүлмәдә егерме еллап бергә яшәделәр. Башта тулай торакка дип кенә урнашканнар иде.

Ул елларда Казанга төзүчеләр бик кирәк булды. Төзелешкә килгән кешене кире бормадылар. Тулай торакка да кертәләр, паспортка мөһер дә сугалар. Шулай да торакның бер ягы — кызларныкы, икенчесе егетләрнеке иттереп бүленгән. Кереп-чыгып йөрергә рөхсәт юк. Алай-болай өйләнешүчесе табылса, аңа тулай торакта яшәргә рөхсәт ителми иде.

Язмыш дигәнең гел канунда күрсәтелгәнчә генә барып чыкмый икән. Бу торактагылар да акрынлап тәмам буталып беттеләр: кызлар янына яраткан егетләре кереп куна башлады, аннары өйләнештеләр, балалар таптылар. Гаиләләләр янында яшәүне өнәмәгән буйдаклар мондый бүлмәләрдән китә торды. Шул рәвешле Нәфисә белән Габделбәр дә, башкалар да, рөхсәтле-рөхсәтсез дигәндәй, яшьлек бүлмәләрендә картаеп та баралар инде. Кайсылары — бер, кайсылары ишле үк балалар үстерделәр. Инде алары да кайсы-кай тарафка китеп урнашты. Хәзер яшьлек бүлмәләрендә пенсия яшендәгеләр боегып утыра...

Ире белән сөйләшүне мәгънәсезгә чыгарып, Нәфисә күрше бүлмәдәге Разыя янына керде. Ул да монда бер кыз үстереп, аны кияүгә озатты. Үзе ялгыз гына яшәп ята.

— Синең бүлмә җәннәт кебек, Разыя! — дип килеп керде Нәфисә.— Безнең Габделбәр, каравылыннан кайтуга, сузылып ятып йоклый башлый да, сулыш алырлык та һава калдырмый.

— Соң, форточканы ачып ал! — Разыя күршесен алга уздырды. — Әйдә, вакытың булса, чәй куям!

— Куярсың куюын. Мин әле сиңа зур киңәш бирергә кердем: кассалардагы акчалар яна икән. Халыклар кузгалмый торган мал алырга керешкән.

— Анысы ни тагын?

— Җиргә береккән мал: йортлар, бакчалар, мунчалар, кибетләр, акчаң җитәрлек булса, хәтта завод-фабрикалар...

— Ә-ә, алай икән! Аңладым. Әйдә, ала бирсеннәр! Бездә андый акча юк бит. Әнә шул айлык пенсиягә карап торам инде. Бер яктан керә, икенче якта чыга — биргәненә мең шөкер!

— Кешеләр фатирларын да саталар, ди.

— Артыгы булган кеше сатадыр инде. Минем, бу бүлмәне саткач, нием кала?

— И-и, гомергә томана булдың! Соң, безгә шул шае эшләп, мондый гына бүлмә тиешме?

— Нишләдең син, Нәфисә? Әле бит шушы бүлмәләрдә бишәр-алтышар кыз гөрләп, шатланышып яши идек. Аннары, үзебезгә генә калгач, ирләребез белән торырга рөхсәт бирелгәч, сөенечтән нишләргә белми йөрдек. Хәзер менә берүзем калдым. Миңа тагы ни кирәк?

— Син әллә телевизордан дөньядагы адәм балаларының ничегрәк көн күргән бер дә карамыйсыңмы? Кеше булган кеше, шушы коридорлардан үтеп, сыңар бүлмәгә кайтып керергә тиешме? Ә?

— Тауга карап тау булып булмый, диләр, күршекәем. Мин үзем әүвәлдә күргән нужаларымны уйлап ятам да, бүгенгесенә шөкерана кылып тик йөрим.

Бу томана хатынны үз ягына аудара алмаячагына өмете өзелә барганны сизгәч, Нәфисә соңгысын әйтеп салды:

— Бергәләп йөрү җайлы ул, әллә аерым фатирлар сорыйкмы, дигән идем. Ул башлыклар каршында, япа-ялгыз калчаеп басып торганчы, береңне-береӊ куәтли-куәтли талашуы җиңелрәк ул.

— Әнә, ирең белән йөр! — диде Разыя. — Миңа бу бүлмәм җәннәт белән бер. Сәламәтлек кенә булсын. Инде алтмышка барганда йорт-җир алмаштыруны йорт иясе дә өнәмәс, Алла сакласын, картлык көнендә яңа өй сайлап йөри, дип кеше көләр. Миңа теге якка — мәңгелеккә әзерләнергә вакыт. Балалар да шушы тирәдә генә, киләләр-китәләр. Өем җылы, якты — биргәнеңә мең шөкер!

Разыяның кайнар чәен дә эчмичә, дулап чыгып китте Нәфисә. Туры килгәндә Габделбәрен дә җитәкләп, ул киреләнгәндә, ялгызы гына да фатирлар бүлә торган башлыклар янына сукмак салды ул. Кайчак бик тузынып:

— Ордер алмыйча бүлмәгездән чыкмыйм, карт башым белән яшьләр тулай торагында яшәр тәкатем калмады, аерым фатир бирегез! — дип, бик яман кыланды.

Кешесенә карап тәмле теллеләнергә дә өйрәнеп китте:

— Бер җаен тапсагыз, буш итмәс идем, минем Әстерхан ягында туганнарым бар, балыкчылар, кара уылдык җибәрәләр...

«Җибәрәләр» дигәне — көлке инде, әллә каян килеп чыккан бер очраклы хәл генә. Казанда кунар урын тапмагач, «чыбык очы — тал башы» дигәндәй бер хатын көзен боларга кереп яшәгән иде. Казанда сатарга алып килгән уылдыгыннан «чеметеп» кенә күчтәнәч биреп калдырды. Нәфисә шул сәер ризыкны, үзе авыз итәргә дә кыймыйча, суыткычында саклый.

Андый затлы ризыкларны «зур урындагылар» өстәлләреннән төшермәскә тырышалар икән. Тик Казан кибетләрендә уылдыкның карасы сирәк була, замана гадәтеннән төшеп калмаска теләүче «бөек» затлар исә аны, мең бәясенә төшереп булса да кулдан алырга әзерләр, ди. Нәфисәгә бит ул нәмәрсә бөтенләй бушка килеп керде — фатир алырга ярдәм

итсәләр, һич кызганып торасы түгел. Кайсысына тәртергә икәнен чамаларга гына кирәк, ялгышмаска! Хата җибәрмәс өчен исә күбрәк йөрергә, сорашырга, киңәшергә, күбрәк кеше белән аралашырга туры килә. Иренеп ятсаң, яңа фатир алу түгел, яшәп ятканыңнан сөреп чыгарулары да бик ихтимал. Хәзер шундый замана.

Төрледән-төрле башлыкларның ишекләре төбендә йөри башлавының беренче баскычында Нәфисә әнә шундый нәтиҗәләр ясады. Иртәдән кичкә кадәр чабып, арып-талып кайтып керә дә төннәр буе йоклый алмый ята. Ишеткәннәреннән йомгаклаулар чыгара, икенче мәртәбә очрашуында кемгә, нинди сүзләр әйтәчәген, нинди рәк язулар әзерләп барачагын билгели. Таң беленүгә, Нәфисә трамвай тукталышына ашыга, фатирлар өләшә торган оешмалар ягына китеп югала.

Ни булса — шул: уылдык савыты да бушады Нәфисәнең, акча төене дә шиңде, шулай да аңа тел-теш тидерерлек түгел, кулында җәһәннәм чокырында яңа салынган йорттан бер бүлмәле фатир кәгазе бар. Бу беренче тырышлыгының, әллә ни озак көттермичә, шатлыклы нәтиҗә бирүе аны тагын да зуррак табышлар артыннан йөрергә канатландырып җибәрде. Фатир чиратындагылардан ишеткән хәбәрләре дә Нәфисәнең җанын өр-яңа тырышлыкка дәртләндерә иде. Әйтик, бер ир үз машинасында чуашлар ягына барып арзанлы бәрәңге җыеп кайта икән дә, бәрәңге уңмаган якта, өчләтә файда калдырып, сатып йөри.

Һәр әйләнеше 6—7 миллион саф табыш бирә, ди. Ул чүпрәк-чапрак сатып баручылар кыйссаларының очына да чыгарлык түгел, алары тәмам череп баеп, шәһәрнең әллә нинди кибетләрен, гаражларын үзләренеке иткәннәр дә шулардан һәрдаим миллион-миллион мал савып яталар икән.

Нәфисә бу хәлләрнең һәммәсеннән гыйбрәт алды: бер бүлмәле фатирга сөенеп яшәр чак түгел, ул өйне җиһазлыйсы да бар бит әле. Өр-яңа бүлмәгә яшьләр тулай торагына тыгынчыклап тутырылган шаламаларны илтеп куймассың бит! Димәк, акча табарга, дистә миллионнар белән генә исәпләнә торган җиһазлар булдырырга кирәк! Бу хакта уйлыйуйлый Нәфисәнең башлары чатный башлады. Яңа табылган бер сердәше әйтте: «Башың чыдамаганны аяклар тарта. Аптырама, әйдә минем белән Төркиягә!..»

Чит илгә чыгу өчен әүвәл махсус паспорт кирәк икән, анысын булдырырга — акча. Моңарчы җыелганы очкан инде, пенсияне вакытында китермиләр, ирнең хезмәт хакын көттереп кенә бирәләр. Нишләргә? Ул ашар өчен бүлеп куелган акчаны янга калдыру әмәлен эзләргә тотынды. Моңа да өйрәттеләр. Корсагына май үсүчән кешеләрне ашаудан биздерә торган дару чыккан икән. Бу хәбәр Нәфисәгә дә ярап куйды. Габделбәрнең эчендә, шөт, бер пот артык май бардыр. Үзе дә авырсына. Мөгаен, теге даруны гына эчеп, ашарга дигәнне янга калдырырга әллә ни кирәкмәс.

— Ярар соң! — диде Габделбәр.— Алай бик кирәк булгачыннан...

— Анын иң кирәге — сәламәтлек! — дигән булды Нәфисә.— Әнә әмерикәннәр муен чокырларына каз йомыркасы куеп карыйлар, ди. Чокырда каз йомыркасы тормый башласа, симергәннән санала, ди дә тиз-тиз әлеге даруны гына эчеп, ашамыйча яши башлыйлар, ди.

Иренә бу тәкъдимне ясаганчы Нәфисә янга күпме акча каласын да исәпләгән иде инде: ябыктыра торган дару 200 000 сум тора, ә Габделбәрне ашатырга 300 000 сум китә. Ай саен — чип-чиста йөз мең тәңкә җыелып барачак.

Тәвәккәлләп тотындылар. Беренче көнне Габделбәр аны-моны әйтми генә ятып йоклады. Икенче көнне дә, ябыктыргыч сыеклыкка ризалашып, кәнәфигә янтайган иде, бер-ике минуттан торып, суыткыч янына китте:

— Син нәрсә: берни дә пешермәдеңмени? — дип бакырды.— Бир әле акча, тавык-фәлән булса да алып керим, ул тиз пешә.

— Ничек инде? Ябыгырга тиеш бит син?!

— Умырып-умырып ит ашыйсым килсә дәме? Ач торып үләр хәл юк!

— Соң, мин бит синең сүзгә ышанып, ике йөз меңлек дару алып куйдым.

— Куйсаң, эч үзең!..

Янга калдырырга дигән акча икеләтә чыгым ясауга китереп, Габделбәр элеккегә караганда да күбрәк ит сорый, сыра эчә, теге дару исә исраф мал булып баксып утыра. Аны бит кире илтеп тапшыра алмыйсың инде!

Гарьлеген кая куярга белмичә Нәфисә тагын шул Разыя бүлмәсенең ишеген шакый, аһ-зарын аңа түгә:

— Кара инде син минем алашага: нинди затлы даруны әрәм итте! — ди.

— И-и Нәфисә, сез киткәч, миңа күңелсез калыр инде,— Разыяның үз хәсрәте хәсрәт.— Егерме ел бергә туганнар кебек яшәдек. Сезнең бүлмәгә нindирәк кеше китерерләр инде тагын?..

— Мин әле аны башкага бирү ягында түгел, артыгы булмас. Безнең яшьтә ике кешегә — бер бүлмәле квартир — әллә ни зур мал түгел. Кешеләр әнә өчәр катлы ташпулатлар салалар! — Нәфисә, әйтергәме-юкмы, дип уйлап алды да тагын өстәде: — Әле мин дә Яшел Үзән ягына чыгып киткән юл өстеннән бер урын карап кайттым. Теге фатирны алгалаганчы, шуннан йорт салырлык җир дә эләктереп калам, алла боерган булса! Нигә? Әллә без кеше түгелме?..

Разыя аны-моны аңлап та җитмәде, сорарга да өлгермәде, коридорда: «Әй, кайсыгыз — Нәфисә? Әйдә, киттек!» — дигән тавыш ишетелде. Теге чуаш бәрәңгесе җыеп йөрүче ир-ат икән. Нәфисәне ярдәмче итеп алган. Аның тавышын ишетүгә, Нәфисә чыгып чапты: «Уф-ф, оныта язганмын! Хә-әзер, хәзер!» — дигәне генә ишетелеп калды. Шул чыгып китүеннән соң шактый көннәр күзгә-башка күренми торган иде.

Нәфисәнең бәрәңге сатып кайтуы — тагын бер мәзәк. Ул ишеген ачканда, ире өйдә юк иде. Буш бүлмәдә үзалдына сөйләнеп бераз йөргәләнде дә тагын күршесенә кагылды. Разыя аны, гадәтенчә, ачык йөз белән каршылады: «Әйдә, әйдә, уз! — диде.— Чәем дә әзер, үзеңне дә бик юксынган идем әле. Ходаем, башка якта яши башласагыз, бик сагынырмын инде...»

Чәй табынында Нәфисәнең теле чишелеп китте. Сәүдәләренең ничек узуын әкият итеп сөйләде.

— Аллага шөкер, сигезәр миллион саф табыш керде керүен,— дип башлап китте дә тагын өстәде.— Алай да теге шуфир-мөртәт алдады мине. Бер поселокта танышларына алып керде. Мине мунчага кыстадылар. Һәйбәт мунчадан баш тарта аламмы инде мин?! Кереп киттем пуфылдап, шәт ике сәгатьләп маташканмын. Күңелем булды, бөтенләй изрәп киттем. Алай да мунчадан чыга- чыгышлый ук ишегалдындагы машинабызның әрҗәсенә күз салдым: малай, телсез калам дип торам. Бушаган да калган әрҗә! Төбендә генә бәрәңгесе. Мин юк арада, кимендә, дүрт-биш тоннаны шуыткан теге кабахәт.

— Әстәгъфирулла! — Разыя куллары белән кирегә ымлап куйды.— Булмас ла, канатым! Үзеңне шундый эшкә алып чыккан кеше турында алай яман уйлама, булмас!

— Ә-әй! Сиңа аңлатып буламыни ул сәүдә юлын. Акчаның иманы юк, диләр сәүдәгәрләр. Ул синең кебек намаз иясенә дә хезмәт итә, кеше үтерүченең кесәсенә дә лып ята. Акча ул, җаныем, иманыңнан яздыра.

— Алла ярдәм бирсен инде! Берүк сакланыбрак йөр! Бу юлга чыкканыңнан бирле үзең дә бик талчыгып-үзгәреп киттең әле... Әллә, булмаса, ташлыйсыңмы соң?

— Юк инде, малай, ни калган гомеремне дә хәерчелектә үткәрер хәлем юк! Бөтен тишек-тошыкларымны чыштырдап торган акча белән дыңгычлап тутырмыйча туктамыйм!

— Ярар, ярар! Күңелең тартып тора икән, сабырлыгың җитә икән — бирсен Ходай!

— Әйдә, җуләр, син дә! Чакырып торучысы булганда, кем баюдан баш тарта инде? Әйдә, киләсе атнада тагын чуашлар ягына чыгып китәбез. Миңа иптәш тә булырсың. Гел ир-ат арасында туйдыра. Сүгенәләр, аракы эчәләр... Эчкәндә мине дә кыстыйлар. Салкын кичтә кунар урын булмаса, авыл читендә генә кунабыз, җылыныр өчен әзрәк капмый да булмый...

— И-и Нәфисәкәем, анысыннан саклана күр! Җылынырга киемнәреңә бетмәгән, калынрак киемнәр алып чык юлга! — Разыя күршесенең төп соравын җавапсыз калдырмас өчен «кырт» кисте.— Мине кыстама, ике аягымның берсен дә атламыйм. Ни булганы җитәр: балалар үзләренә-үзләре таба, миңа пенсиям җитеп ашкан, ни барына — бәрәкәт бирсен!

Шул чәйләреннән соң Нәфисә шактый күзгә-башка күренми торды. Аның коридордан ашыгып узып йөрүләрен генә ишетеп кала иде Разыя. Аңлашыла: яңа фатирга күчү мәшәкате артыннан да йөрергә кирәк, сату-алуларын да туктатмый инде ул, өстәвенә, утарлык җир эләктерергә, бу бүлмәне дә үзләрендә калдырырга җай эзли бит әле ул. Кемнедер таба, кайсындыр көтеп тора, башкасының өенә барып күчтәнәчен-фәләнен бирә — бөтенесе артыннан гел үзе генә йөгерә. Габделбәргә, каравылыннан кайткач, ашарга булсын да, ятып йокларга булсын — башкасында кайгысы юк.

Язга таба Нәфисәнең эшләре тагын да арта төште. Беренчедән, өй салу өчен дип, каерып алган ун сутыйлы җиргә бәрәңге утыртырга кирәк иде. Бу зур мәшәкатьләр турында ишеткәч, Разыя «аһ» итте:

— И-и Аллам, ничекләр казып, утыртып бетерерсең аны? Яшь чакта да арып хәлдән тая торган идек, алтмышка барганда, ник яңарттың ул бәлане?

— Казып йөрмәм әле! Акчаң булса, ярты сәгать эчендә әйләндереп бирәләр аны,— диде Нәфисә.

— Әй Ходаем, аның бит әле утавы, өюләре дә бар. Ничек очлап чыгарсың? Икегезгә ике капчык бәрәңге җитә. Казучыга биргән акчаңа әзер бәрәңге генә сатып алсаң соң!?

— Бәрәңге быел гына утыртам мин. Көзен сатармын да, җәен җыйган материаллардан йорт салдыруга тотынырмын! Үзебезгә салып өлгертә алмасам да курыкмыйм: аз гына урыныннан кузгатып куйсам, төзелеп бетмәгән килеш тә сатып җибәрергә була. Нигез ташын гына куйганнар да йөзәр миллионга сатып җибәрәләр — беләнеңме?!

Башта бик батыраеп тотынган булса да, Нәфисә утыртылган бәрәңгесен вакытында тәрбияли алмады. Әле, Әстерханга барып уылдык алып кайтты, әле Мәскәүдән чүпрәк-чапрак ташыды — сәүдәне туктатмады. Бушаган арада бакчасына күз салган иде, аны ерып чыккысыз алабута баскан, өяргә җай калмаган булып чыкты. «Ярар инде, ни булганын көзен казып алырмын!» дип ният кылып куйды ул. Әмма көзен дә җир аны шатландырмады — бер рәт буенча казып чыкты Нәфисә — ник бер генә бәрәңге күренсен! Бары да сапка үсеп, кыргыйланып беткән. Калганын казып та тормады.

Ярар. Зур эшләр артыннан йөргәндә, бәрәңгенең уңмавы өчен генә кайгырып утырып булмый. Нәфисәгә аннан зуррак, баш белән эшли торган мәшәкатьләр дә җитәрлек. Элек яшәгән бүлмәне дә үзләрендә калдырыр өчен аңа гомер иткән иреннән юри генә аерылып торырга киңәш бирделәр. Габделбәре кычкырып караган иде дә, кечкенә ашка бер яртыны алып кайтып, әйбәтләп сыйлагач, ризалашты тагы. Хөкем залларына йөреп-нитеп тормыйча ансат кына аерылдылар. Ул кәгазьне алганда да Нәфисәгә шактый гына «төртергә» туры килде. Ә-әй! Олы эш хакына бер-ике миллион төртү — әллә ни түгел инде. Хәзер ул акчага бүлмәне ала аласыңмы соң? Юк! Ә сатарга теләсәң — йөз миллион бирәчәкләр!

Бу четерекле эшне түгәрәкләгәч, Нәфисә җиңел сулап куйды.

— Мин хәзер — азат хатын! — диде ул Разыя бүлмәсенә кереп утыргач.— Уф-ф! Әйдә, чәеңне куй әле. Тыныч кына чәйләп утырыйк! Минем

бит хәзер ярты хуҗалыгым — теге фатирда, Габдебәрем — монда, әйберләребез дә кайсы-кая таралышып ята. Тегендә дә, монда да төенчекләр өстендә яшибез...

— И-и, әйдә, күрше, уз, утыр, рәхәтләнеп ял ит! — Разыя аны ачык йөз белән каршылады. Түрдән урынын бирде. Әнә, башымны куеп торыйм, дисәң, кәнәфигә сузылып ят! Әле генә үтүкләп япмасын ябып куйдым, мендәр тышымның да чип-чистасы, шикләнмә! Ят, ял ит! Бик арыгансың, сизелеп тора.

Сузылды да ятты Нәфисә. Разыя бүлмәсенең саф һавасы, чиста кашагалары, йомшак ятагы — һәммәсе җанга әйтеп кенә аңлаталмаслык тынычлык иңдерә кебек. Нәфисә соклануын яшереп тә тормады:

— Җәннәттә менә шушындый бер бүлмә бирсәләр, мин бик риза булыр идем, Разыя, — диде.

— И-и Нәфисә-күршекәем! Ул җәннәт дигәненә ирешер өчен, кыямәт көннәрен кичерәселәр бар бит әле. Өлкәннәр әйткәннәр: үлем үзеннән әүвәлге хәлләргә караганда авыр вә үзеннән соңгы хәлләргә караганда җиңелдер, дигәннәр. Бу фанилыкта кылганнарыбызга имтихан тотасылар бар...

— Ярар, алай бик тирәнгә алып китмә әле син! — Нәфисә яткан җиреннән Разыяның кер кунмаган пәрдәләрен, тузан тимәгән җиһазларын күзәтеп чыкты. — Кара әле, минем сиңа бер сүз бар: беләсеңме, миңа тиздән Әстерхан хатыны килә. Шулай сөйләшкән идек. Уылдык алып килә ул, сатарга. Тик, уйлап-уйлап торам да — мин аны кайда асрармын соң? Мондагы бүлмәне Габделбәр ат абзарына әйләндереп бетерде, яңа фатирны бөтенләй җиһазлаганыбыз юк, өстәл дә, урындыклар да алмаган, караватын әйтмим дә инде. Йозагын гына алмаштырган идек — шул килештән тик тора. Гел теге утар ягына кирпеч ташыйм, такта, шифер юнәтеп йөрим.

— Мин ничек ярдәм итә алам? — дип сорады Разыя.

— Әнә шул Әстерхан хатынын синең янга кертеп торсак, ачуың чыкмасмы?

— И-и, ник аны сорап утырасың инде, — диде Разыя. — Тартынмагыз, барыгыз да килегез дә керегез, канатым. Кулымнан килгәнчә сыйлармын, теләсә, әнә, караватыма ук ятсын, анысын ошатмаса, кәнәфине көйләрмен...

Нәкъ шулай булып та чыкты. Күтәрә алган кадәр уылдык алып килгән Әстерхан хатыны кайтты да егылды, кайтты да егылды Разыя кәнәфиенә:

— Уф-ф арыдым! — дигән сүзе теленнән төшеп тормады. Көннәр буе кара уылдык алучы бай гаиләләр эзләп йөрде. — Чеметеп-чеметеп кенә алалар, бер завод директоры гына өч килолы тәргәкне берьюлы алды. Казаныгызда байлар аз икән, — дип зарланды.

— Бәлки ул ризыкны өнәп бетермиләрдер? — дип тә сорап карады Разыя. — Татлымы соң ул, тозлымы?

— Тозлы, — диде сәүдәгәр хатын. — Мин сиңа бирәр йөз граммлы банка калдырырмын дип ниятләгән идем дә-ә... Алучысы очрады, каһәре. Алучы барында тагын тыелып кала алмадым инде, авыз иттергән булыр идем югыйсә.

Бу «кунак»тан соң тагын берничә тапкыр Нәфисә кешеләрен кундырып-кундырып чыгарды әле Разыя. Барысы да аның бүлмәсенең җылы, якты, саф һавалы, чиста, рәхәт булуына сокланып, рәхмәтләрен укып киттеләр. Әй шатланды Разыя, әй сөенде: күршесенең шундый мәшәкатьле чагында кулыннан ярдәм күрсәтә алу — аңа җан рәхәте иде.

Тик монда кунак-төшемле көннәр еш булып тормый, сәүдәгәр халкы — ут белән бер, кичтән килеп керәләр дә таң беленмәстә чыгып китәләр. Аларга синең тәүлек буе өф-өф иттереп кенә кабарткан камырың ни дә, тавык шулпасына гына белбелдәтеп-күпертеп алган токмачың ни?! Хаптор-хоптыр капкалыйлар да чыгып йөгерәләр. Сөйләшеп утыру

түгел, әйткән рәхмәтләре дә ишек ярыгына кысылып кала. Корбан гаете көнне, Разыяга мәчеткә бергә йөрүче хатын мул гына иттереп сарык ите китергәч, һәйбәт пылау пешереп, Нәфисәне дә чәйгә чакырырга ният-ләде.

— Әйдә, бәйрәм көнне бераз ял ит! Корбан итеннән генә затлы ризыклар әзерләдем,— диде.— Кермәсәң, риза-бәхил түгелмен...

— Ярар, әйтүеңә рәхмәт, хәзер керәм,— диде Нәфисә.

Тик табын янындагы сөйләшүләре Разыя күңеленә ошап җитмәде. Башта матур гына башлап та җибәрделәр, Разыя белгәннәрен укып, әрвахлар рухына догалар да багышладылар. Нәфисә дә битен сыпырып ыспай гына утырды. Тик чәй эчүгә, пылау ашауга күчкәч, сүзләре тагын Нәфисәнең адәм акылы җитмәслек мәшәкатьләренә барып тоташты.

— Эшем күп,— дип гадәти генә сөйләп киткән иде Нәфисә.— Әле менә теге аерым фатирга күчкәнче аңа бераз үзгәреш кертергә булдым: аның бәдрәфе белән юыну бүлмәләре аерым-аерым ясалган. Уйлап-уйлап тордым да, миңа ни пычагыма аерым бәдрәф?! Юыну урынына гына кыстырып куям да теге унитазны — өстәмә бер бүлмә ясыйм. Анысы янында караңгы бер бүлемтек бар, икесен бергә кушсаң, кечкенә генә сәке әмәлләргә була. Менә дигән йокы бүлмәсе дигән сүз бит бу! Аннан да узыбрак уйласаң, миңа бирелгән бер бүлмәле фатир ике бүлмәлегә әйләнде дигән сүз! Менә бит ул, Разыя-малай, башыңны эшләтсәң!

— И-и канатым! Ничекләр бу кадәр остарып киттең син, ә?

— Йокыларым качты инде качуын, гел әле анысын, әле монысын исәпләп, шуны булдыру турында баш ватам.

— И-и канатым, зиһенеңне чуалта күрмә инде, Алла сакласын.

— Чуалмый, акча белән вакыт кына таррак, әле тагын теге утар җиренә сугыласы бар, берәү шифер ышандырды: әгәр сүзендә торалса, ярты бәясенә генә төшә, боерган булса!

— Ходай җиңеллекләр бирсен! Ничекләр иттереп ерып чыгарсың? Габделбәр булыша күрсен инде?

— Юк, малай-җаным, ул хайван бөтенләй баш тартты: миңа шушы бүлмә җитеп ашкан, ди. Берәүгә дә ышанырга калмады, үзем бар да, акча бар. Ну, Разыя-малакаем, бу юлга бер кергәч, аңладым: акчага бөтен нәрсәне булдырып була икән. Эрерәк сан сугылган кәгазеңне күрсәтсәң, министрның үзе шифереңне ташып куяр кебек тоела хәзер миңа, валлаһи менә!

— И-и, мин бер дә алай яшәмәдем шул.

— Син үзеңне яшәгәнгә санама да инде, малайкаем, юк ул, син кешенең ничекләр иттереп рәхәт яши алганын башыңа да китерә алмый-сың. Аны сөйләп, аңлатып та булмый. Яшәү рәхәтен тояр өчен күпме кирәк, шул хәтле акчаң булсын! Акчаны санап тормыйча гына, аның бетүеннән курыкмыйча гына көн итәргә!..— Аннары ул тагын сүзне үз-гәртте.— Кара, онытып торам, бу татлы ризыкларың белән зиһенем томаланды. Әле чакырмасаң да, кереп, киңәш итәсем бар иде бит: теге Әстерхан хатыны килә...

— Килсе-е-ен, килсен! — диде Разыя.— Әйдә, әнә аның урыны — гел түрдә! Ашыгуын ашыгучан ул, барыбер миңа бер күңеллелек ясап ала. Кыстыбыйлар пешерермен, алла теләсә, токмач басармын. Килсен, син бер дә борчылма!

— Бу юлы бик озак тормас. Мин сөйләшеп куйдым монда. Бөтен уылдыгын үзем генә сатып алам да, аныкыннан да арттырыбрак баш-каларга озатам.

Разыя төшенмичәрәк торды:

— И-и, тагын үз өстеңә мәшәкать алып каласың икән инде?!

— Ахмак булма: файдасын аңа белдермим ич мин, акчасы үземә кала!

— Әстәгъфирулла!

— Мин сиңа кайчан әйттем бит: акчаның иманы юк!

— И Нәфисә, шул сүзеңне бер дә яратмыйм. Теге юлы ишетмәмешкә салышып үткәргән идем инде, бусында килешеп куйыйк әле: шаяртып та әйтмә бүтән, яме?! Иман кадәр иманны алыштырырлык нәрсә юк бу дөньяда!

— Ярар, ярар!— дигән булды Нәфисә.— Мин бит шаяртып кына. Күпме тырышуымны күреп торасың, һаман җитәр чиге күренми бит каһәр сукканның. Теге утар өе салынып ята, аңа йөрер өчен машинасы да кирәк бит инде аның. Алам, боерган булса. Арзанлысы да бар аның, бераз тотыла төшкәнен алсаң, арзангарак төшә икән. Алам, алам. Теге Әстерхан хатынын да машина белән барып каршылармын әле. Өлгерә алсам...

Разыяга бусы бөтенләй көтелмәгән яңалык иде:

— Кара, син машина йөртә беләсеңмени?— дип сорады.

— Әй, беркатлы да инде син, күрше! Әйттем бит: акчаң булса, әллә ниләр майтарып була. Мин бит кышын курска йөреп алдым. Бөтен хикмәтләренә төшенү юк инде ул, иллә мәгәр, акча төрткәч, тиешле документын ялт иттереп кулыңа тоттыралар. Азапланып укып йөрүчеләр тиешлесен генә түләделәр, мин — ике миллион чамасы тоттым.

Машина алган көнне Нәфисә Разыя бүлмәсенә уттан качучы җәнлек кебек елдырып килеп керде. Сәламен бирергә дә онытты:

— Разыя, карале, ни дип аңлатырга да белмим, миңа акча кирәк булып чыкты бит әле,— дип шаккатырды.

Ике сүзнең берендә: «Акчага теләсә кайсы министрны сатып алам!»— дип йөрүче Нәфисәнең пенсиягә генә яшәүче Разыядан ярдәм соравына сәер иде сәерлеккә. Тик, ни дисәң дә, дөнья бит бу, нинди кеше башына ни генә төшми. Разыя бер дә аптырамады.

— Сиңа бит миндәге ише вак-төяк кенә җитмидер инде, Ходаем,— дип, борчыла ук башлады.— Менә янымдагысы...

Бичара пенсионерның ике-өч йөзлек тотып торуын күргәч, Нәфисәнең йөзе яктырып китте:

— Җитә-җитә! Миңа бит бу алай-болай кәгазен яздырганда кирәге чыкса, дип кенә буш йөрергә ярамый. Машинаның үзе өчен түләдем. Башка акчам әмерикән долларына әйләндерелгән. Ишек саен «төрткәләп» йөргәндә дә доллар әрәм итеп булмый бит.

— Ә-ә, ярый, үзең беләсеңдер.— Разыя, ниһаять, күршесенә акчалата да ярдәм итә алганлыгына сөенеп бетә алмады.— Мин әле кичә генә алып кайтып куйган идем. Бу айда пенсияне вакытында күчергәннәр, рәхмәт төшкерләре! Шул сиңа насыйп акча булгандыр.

— Мин аны озак тотмыйм. Әле, шул долларга тимәс өчен генә соравым. Әстерхан хатынын озаткач, тагын чуашлар ягына барып кайтабыз, капчыклап акча булырга тора.

— Бирсен Ходай! Рәхәте белән, бәрәкәте белән керсен!

— Бәрәкәте-ние шушында инде, малайкаем! Әле менә утар өенә җитәрлек бүлеп куйган идем дә тагын артырга тора: йорт салучылар мунчаны өйгә үк тоташтырып салырга, җылылык торбасын мунча аша үткәрергә киңәш бирделәр. Киңәшләре бик акыллы, бик кирәкле. Алай иткәндә торбалар күбрәк кирәк. Анысы бик кыйбат. Белми идем: метрлап-фәлән йөртелми, малайкаем, килолап исәплиләр. Ул бит тимер дә чуен. Шуннан чамала инде аның бәясе күпме артканын.

Разыя кара кайгыга батты:

— И-и Аллам, ничекләр табыштырып бетерерсең? Кем күтәрешер, кем табышыр?

— Акча! Башка берәүгә дә ышаныч юк, бөтенесен акча эшли. Габделбәренә дә ялынмыйм, малайга да, киленгә дә «мунча як әле!»— дип ялынасылары алда, боерган булса! Борыннарына борыч сибәм әле барысының да!

— И-и Нәфисә, Ходай ярдәменнән ташламасын инде, уйламаганда, әллә нинди мәшәкатькә чумдың да куйдың — ничек ерып чыгарсың? Габделбәрне ризалаштырырга тырышып кара әле? Мин дә әйткәләрмен.

— Жүләр булма! Ике поты — бер тиен. Ул бөтенләй алкашлыкка чыгып бара инде: миңа ачуланган була, хайван! Имеш, карт көнендә мин аны буйдаклыкка чыгарганмын, имеш, миңа гына күп кирәк. Нәселләрендә күренмәгән байлык кулга керергә торганда, әллә нинди изгелеккә чыкмакчы, имеш, аңа акча кирәкми, имеш, аның байлыгы — күңелендә. Имеш, мин барыбер хәерче, күңелем ярлы, имеш, минем.— Нәфисә бик ямьсез иттереп хахылдады.— Бай булса, ятсын инде шул иске кәнәфигә капланып, минем, әнә, долларларны салырга яңа чемодан кирәк!

— Әстәгъфирулла! Ходаем, рәхмәтеңнән ташлама бәндәләреңне! Нәфисәкәем, алдыңны-артыңны карап йөри күр! Акчалы кешеләрне үтереп тә киткәлиләр икән бит, Алла сакласын! Әйтмәгәнем булсын!

— Бары да мин дигәнчә булыр, күрше, кайгырма. Габделбәрнең дә каршыма килеп инәлер чаклары — алда! Әле менә паспортка пичәтләр суктырасы бар: теге яңа фатирга теркәлүне дә, утар җирен дә тәртәсенә кертеп куярга кирәк. Кайсын алдан ясарга гына белмим: өй салырга җирне бушка алдым бит мин, өйсез кешеләр рәтеннән. Әгәр яңа гына фатир алганымны белсәләр, тарталар да алалар. Торыр урыны булганнарга бик кыйммәткә сатып кына бирәләр җирне. Теге уылдык алган хатыннан киңәш сорыйсым бар, тик аның янына буш кул белән барып булмый. Әстерхан кунагы килсен инде!..

Нәфисә бу сүзләрен, Разыяга аңлатудан бигрәк, үзе өчен, алда торган эшләрен барлау йөзеннәнрәк сөйләнде кебек. Аннары, ничек килеп кергән булса, шундый ук каударлану белән чыгып та китте:

— Ну, малайкаем, кулың җиңел була күрсен! Машинага китәм бит!— диде.— Алып, теге ачык мәйдандагы машина саклагычларга илтеп куям да, гараж артыннан йөрергә тотынам, боерган булса. Үз гаражы булмаган кешенең машина асрап ятуын яратмыйм мин.

— Хәерле сәгатьтә!— диде Разыя.— Рәхәтен күрергә язган!..

Волгоград поезды килеп җитәргә тиешле сәгатьтә Разыяның өч кияү бүлмәсе кебек җыештырылган, өсталенә кершәндәй ак эскәтер җәелгән, ашы кайнап чыккан, токмач салуны гына көтеп утыра, газ мичендә үрдәк бәлеше хуш ис бөрки иде. Бары да әзер, рәхим итегез, сәүдәгәр кардәшләр! Кунак-төшемне, таныш-белешне шушылай иттереп әзерлек белән каршылау Разыя канына сөйләп кенә аңлатып булмый торган бер ләззәт бирә. Аңардагы бу күтәренкелек әллә каян сизелеп үк тора: хәрәкәтләр җитез, күзләре ялтырап яна, йөзен елмаю балкыткан.

Аларның торагында аш-су әзерләү бүлмәсе коридорга бер генә. Үз бүлмәсе белән аш-су ягын мең генә урамагандыр ул. Шунсыз булмый да бит: итле шулпаны ашарлык хәлгә китергәнче генә дә күпме караштырырга туры килә?! Бәлешне дә, нәкъ Разыя теләгәнчә, кояш нурында кызартып алгандай иттереп пешерергә теләсәң, мич капкачын мең ачып, мең дә бер ябасың. Менә Разыя да шулпа астындагы утын басып, мичендәге бәлеш өстенә дымлы чүпрәк ябып, инде эшләрен тәмам түгәрәкләгәндәй итеп, кабат коридорга чыкты. Бүлмәсенә җитәм дигәндә генә күрше ишектән Габделбәр күренде.

— Нихәл, күрше, исәнлек-саулыкмы?

— Ярый, Разыя, үзең ни эшләр бетерәсең?— Гел сер бирмәскә тырышса да, Габделбәрнең өстенә карауга Разыя аны кызганып куйды. Элекке гайрәтле ир-атның эзе дә калмаган.

— И-и Габделбәр! Алланың биргәненә мең шөкер укып тик ятам инде мин. Ходай сәламәтлектән генә аера күрмәсен!

— Анысы шула-ай,— дип сузды Габделбәр. Аның үтеп китәргә дә исәбе бар иде дә, Разыя сорап калырга булды:

— Карале, Габделбәр, Нәфисә сәгать ничәләрдә кайтырга булды ул?

Габделбәргә хатыны турында сөйләшүдән дә авыррак хәл юк. Шулай да гомер буе телгә килешми, бик тату яшәгән бу күршегә орды-бәрде генә җавап та кайтарып булмый. Ул эчендәге ихластан ачып салды.

— Уфф Аллам!— дип тирән сулады да тезеп тә китте:— Син барын да белеп бетермисеңдер шул: безнең тормышның яме китте бит, Разыя. Миңа кайчан кайтуларын әйтеп тормый ул хәзер. Аннан-моннан әйткәләсә дә, дөрес булмый:йә ялганлый, йә чамасына туры китереп бетерә алмый. Ул бит хәзер мең җирдә мең кешегә бәйләнгән. Берсеннән ала, икенчесенә сата, каршылый, озата, төзетә, төзәттертә —ниләр генә кыланмый бит ул?!

Сүзнең озынгарак китүен сизенеп, Разыя күршесен бүлмәгә алып керде:

— Монда басып тормыйк, әйдә, бераз хәл алырсың,— дип, түренә уздырды.

Габделбәр анаң җылы, якты бүлмәсендә, чыннан да, иркен сулыш алып җибәрде. Сүзләре дә җанлырак яңгырый иде:

— Менә бит! Күз тимәсен, гөлләр кебек яшәп ятасың! Син безнең бүлмәне кереп күр: эт оясы да аннан ягымлырак булыр иде, валлаһи! Ә-әй, бүлмә генәме соң?! Үземне карт көнемдә буйдаклыкка чыгарды. Гарьлегемнән кая барып бәрелергә белмим хәзер. Аерылсаң-нитсәң дә яшь чакта кирәк икән ул.

— Алай ук әйтмә әле,— Разыя аны бүлдерми булдыра алмады.— Мин бит сезнең юри-малый гына аерылуыгызны беләм. Аны, зурдан кубып, телгә алма инде син, Габделбәр! Санаулы көн тиз үтә ул, яңадан да язылышырсыз...

— Язылышуда гына да түгел бит хикмәт. Син анаң ниләр кылануын күр: тормышны уйлау юк, өйне җыештыру юк, аш-су пешерү юк, бөтенләй әллә нишләде бит ул. Тышкы кыяфәтенә кадәр үзгәрде, өстенә карарга чиркангыч. Кем инде, шушы яшендә, чит илнеке, кыйммәтле, дип, киндер чалбар белән күн тужурка киеп йөри, йә? Нәфислеге нәфескә әйләнде.

— И-и Габделбәр, без бит гомер буе — төзелештә, гел генә теге комбинезон дигәнне киеп йөрдек. Шуңа күрә минем аңа бер дә исем китми. Аннары чалбар ул юл кешесенә бик җайлы, бөгелсәң-сыгылсаң да, чабуым күтәрелгәндер, дип, кайгырып тормыйсың.

— Кем кушкан аңа юл йөрергә, ә? Ние җитмәгән? Эт чаба, дип, бет чабамы?

— Бераз сабыр ит инде, Габделбәр. Әйдә, замана рәхәтен күреп калсын! Кулыннан килгәч, теләге булгач, тик тырышсын. Үтәр авырлыклар, үзеңә дә рәхәте тияр, Алла теләсә! Әле менә теге Әстерхан хатыны килә, дигән иде, шуны машина белән каршы алам, дип, канатланып йөри. «Үзем төшәм вокзалга! Машинамны күрсә, күзе шар була инде!»— дип, кош тоткандай шатланып сөйләгән иде.— Разыя, бу сүзен әйткәндә, шуңа бәйләнеп, хатыннарның кайчанрак кайтачагын белеп булмасмы, дип тә өметләнгән иде. Тик нәтиҗә бөтенләй башкача килеп чыкты. Хатынының машина сатып алуын, инде аңа үзе утырып та йөри башлаганын ишеткәч, Габделбәрнең сөмсере тәмам коелды.

— Алганмыни? Йөртә дә башлаганмыни?— Ул бу сорауларны Разыяга бирми, үзалдына гына кабатлый иде.— Булмады болай булгач, булмады...— Ул агарынып китте. Куллары, иреннәре калтыранырга тотынды. Кире якка борылып, чыгу ягын карады.

Аш-су әзерләүнең ләззәтен тоеп яшәүче хатыннарның иң зур бер теләге — пешкән ризыгының вакытында табынга куелуы, тәмләп, иплә кабул ителүе. Бары да әзер булгач, аш-суың суынуын тоеп тору — пешекчегә иң зур газап. Минут саен ризыкның тәме китә, бәрәкәте кача сыман. Разыя да бу минутларда шул хәлдә калды. Аңа мичтән алып, йомшарыр өчен тастымалга томалап куелган бәлеше дә, белбелдәп утыручы токмачы да, чәй янына куела торган татлы ризыклары да рәнҗидер кебек. Аларны Разыя кешеләргә, җан ияләренә тиң күрә. Аларның үзләрен адәмнәрдән татыттырып карыйсылары, мактатасылары килеп торадыр. Күпме көтәргә мөмкин? Табынны күпме зарыктырырга була?

Ул сабыр хәрәкәтләр белән, үзе өчен булса да, аш бүлә башлады. Матур итеп тездә дә куйды. Аннары иплән кенә өстәл янына килеп утырды:

— Аллаһүмә бәрыкъ ләнә, фимә ризык данә вә кыйнә газабәннар!— дип, аш догасын укыды. Һәрвакыттагыча анысын үз сүзләре белән дә кабатлады.— Ходаем, ашаган ризыкларыма бәрәкәт бир, ачлык газапларыннан саклый күр, раббым!— Шулпа кабып куйды. Аның тәмен татып торды да, гадәтенчә, шөкер итте:— Һай, тәмле булган! Сөбханалла! Һай, таман булган!.. Аннары бәлеш телемен мактарга тотынды:— Күр син аның камырының матур булып кызарып чыгуын — Кояшның үзе кыздырган, диярсең! Әй бу үрдәк итенең хуш исләре! Ходаем, үстерүченә саулык-сәламәтлекләр бир! Уч төбенә сыешлы кукәйдән шушындый да ләззәтле ит хәленә китергәнче ул үрдәккә күпме тәрбия бирергә кирәк бит! Күз алдыма авылыбызның киң Чирмешәне, шунда йөзеп симергән кошлар килеп басты, әй яшьлек, әй ул су буйлары, әй шул иркенлектә уйнап-шаярып узган балачак!..

Разыя бу үрдәк түшкәсен базардан сатып алган иде югыйсә, үзе барыбер дә шул ризыкны булдырган кешегә рәхмәт укыды, иң изге теләкләрен теләде:

— Ходаем, киләсе елларда да кош-кортларыгыз мул булып, зыянзәрәт кичермичә үссеннәр, кулларыгыздан куаныгыз! Мине шулай ризыклы иткәнегез өчен Аллаһы тәгалә мене белән кайтарсын. Мин түләгән акча — берни түгел. Акчаның алтыныннан да мондый бәлешнең бер телемен дә пешереп булмый...

Күңеленнән иң матур теләкләр тели-тели, ара-тирә үзалдына сөйләнәсөйләнә, ризыклардан ләззәт җыя-җыя шактый утырды Разыя. Өрекйөзем, кара җимеш салып кайнатылган ширбәтен йотып куйгач, ике кулын күтәреп шөкер итәргә, дога кылырга тотынды:

— Әлхәмделиллаһи ләди әтәгамәнә, вә сәканә, вә җәгаләнә мин әлмәслимин бирахмәтикә йә әрхамән рәхимин — Ходаем, минс туендырганың, сусавымны басканың өчен, үземне мөэмин-мөселман өммәтеннән яратканың өчен бихисап рәхмәтләремне кабул кылсынчы! Биргәнеңә мең шөкер, ашаган-эчкәннәрем әти-әниләрем, ата-бабаларым, мөэмин-мөселман әрвахларның һәммәсенең өлеше булсын, Раббем!..

Шулчак коридорда аяк тавышлары ишетелде. Разыя үз коридорында яшәүчеләрне аяк тавышларыннан ук таный. Кайсының кайчан кайтып керүен дә белә. Болар — аңа таныш түгел. Үзләре ишлегә дә охшаган, сөйләшүләре дә ят, кычкырып, тәшвишләнеп сөйләшәләр. Азактан арадан бер хатын, барысының да тавышын бастырырлык иттереп өзеп салды.

— Әйттем бит инде: уң якта, сул кулдагы өченче ишек! Дүртенчесендә — ире! Кертеп салыгыз шунда! Күпме интектерергә була, ә?!

Бөтен коридорның моңлы тынычлыгын алган бу тавышларга өйдәгеләрнең күбесе, ишекләрен ачып, башларын тыктылар. Разыя чыкканда, Габделбәр дә ишегеннән күренде. Тыштан керүчеләр төркеме исә туптуры нәкъ менә аңа — Габделбәргә таба киләләр. Аларның икесе милиция киеме кигән, берсе ак халатлы, тагын икесе авыру хәлендәгегә охшаш. Ник дисәң, табак кебек түгәрәк битлесенең йөзен аркылы-торкылы марляга ураганнар, икенчесенең бер аягы ап-акка төрелгән, үзен ике яктан җитәкләгәннәр.

Разыя иң әүвәл табак битле хатынны таныды:

— И-и канатым, Әстерхан хатыны бит син, әйеме?!— дип, аңа каршы атылып чыкты.

— Ие, ие!— диде тегесе.— Әйт әле, аңлат әле шул милициягә! Безне гел чит кеше итеп калдырды. Нәфисәгә дә ышанмый, имеш, ул да Казанныкы түгел, имеш, пропискасы юк...

Хәлне иң беренче Габделбәр аңлап алды. Барына да тиз төшенде дә, коридорны яңгыратып көлеп җибәрде, өзлексез бер сүзне кабатларга тотынды:

— Кертмим, кертмим, кертмим! Валлаһи-билләһи кертмим. Миңа бу чатан хатын ни пычагыма кирәк! Күрегез сез аның кыяфәтен генә, күрегез: дуңгыз көтүчесе дә болай киенеп йөрми, каштор-коштыр киндер чалбар, шыгыр-шагыр күн тужурка. Татар хатыны шулай йөрер идеме, ә? Иманыннан язган нәмәрсә! Әле монда кайткан! Бар, әнә, «бөтен уңайлыклары» булган яңа фатирыңа кит! Йәисә, әнә, байлар утарындагы өч катлы йортыңа барып ят!— Габделбәр, Разыядан хатынының машина алганлыгын ишеткәч, бик гарьләнеп, бер стакан аракы җибәргән иде. Теле-телгә йокмады:— Инде йортларың гына тар тоелса, әнә, машинаң эченә кереп ят!

— Юк бит инде ул машина,— диде Әстерхан хатыны.— Бетте, яньчелде, харап кына итте!

— Яхшы булган!— диде Габделбәр.— Шуңа ашкынды инде ул.

Габделбәр бүлмәсенә кереп бикләнгәч, Нәфисә телгә килде:

— Разыя, күршекәем!..

— И-и, әйдәгез, әйдәгез! Сөйләп торма! Хәлең китәр, әйдәгез!..

Машинада биртелгән хатыннарны йомшак урын-җиргә кертеп салгач, милиция кешеләре дә, ак халатлы шәфкать туташы да үзләренә кирәкле сорауларга җавап табарга дип, Разыяны уратып алдылар: «Бу хатыннарны беләме?», «Кемнәр болар?», «Ник берсе — Әстерханныкы? Ул нишләп йөри?», «Икенчесенең ник пропискасы юк?»— мең дә бер сорау инде. Шактый талкыгач, ниндидер кәгазьләренә кирәкле сүзләрен язып бетергәч, киттеләр.

Разыя, Нәфисәне бимазалаудан тыелып, Әстерхан хатыны ягына борылды. Анысының битендә шардай ике күз генә ялтырый да иләктәй авызы күренә. Әллә елмаерга тырыша инде, Ходаем! Ул елмая да, җүнләп сөйләшә дә алмый икән: бөтен бите бәйләнгән. Шулай да, тырыша торгач, Разыяга аңлатты:

— Бар, ишек төбендәге теге яньчек машинадан минем төенне алып кер! Мин бит шуның эчендә килгән кеше. Багажникта. Ачкычы монау!— Ул учын җәеп җибәрде.— Берәүгә дә бирмәдем. Анда бит ун миллионлык уылдык!..

Кунагының гыжлый-гыжлый акча санавын ишеткәч, Нәфисә ыңгырашып куйды. Разыя, әллә анысы да берәр күрсәтмә бирерме, дип, күршесе ягына омтылды. Тик анысы һаман күзен ачмаган иде әле, ыңгырашуында гына булды. Ул күңеленнән үзе кичергән хәлләрне уйлап ята иде. Уйлый да уйлый, бер нәтиҗәгә килә алмый иде әле: шактый эш башкарылган бит инде, шуңа үкенергәме?! Юктыр, үкенергә кирәкмәстер. Баш исән! Машинаны төзәттереп тә була, яңасы да әллә ни еракта түгелдер... Нәфисә тырыша-тырыша үз гамәлләрен дәвам итәрлек юллар эзләде. Башындагы кечкенә генә бер кузәнәк аның бөтен уйларына каршы торып маташа: «И-и Нәфисә, бу юлы исән калдың. Шуңа шөкер ит тә акылыңа кил! Үлгән булсаң, кем җирләр иде, үлемтеккә дигән акчаңны да туздырып бетердең, әле Разыяның пенсия акчасын да алган идең бит...» Бу уй аңа үз фикере кебек түгел, Разыя сүзләре кебек тоелды. Әйтә куйды:

— Минем бит долларлар бар, Разыя, курыкма!..

— И-и ходаем, саташасыңмы соң, Нәфисә! Тукта, борчылма, белгәннәремне укыйм әле. Ходаем ишетсә, җиңеллек бирер: «Йәси-ин, вәлкорьәнен хәким»...

Аның моңлы мәкаме авазыннан ике яктагы ике сәүдәгәр тынычланып калды. Шуны гына көткән Разыя, ахшам намазы җитүен тоеп, аулак якка узды, намазлыгына басты. «И Раббем ният кылдым...»

Нурлы бүлмәнең өч тарафындагы өч хатынның өчесе өч нияттә иделәр, алда кайсыныкы тормышка ашар?

*Март, 1997 ел.*

## ҖАВАПЛЫЛЫК ТОЙГЫСЫ



*Шагыйрьнең шагыйрьлеге чыгарган китапларының исәбе белән түгел, ә аерым-аерым шигырьләре белән билгеләнә. Чын шагыйрьнең исеме бер-ике шигыре белән дә шигърияттә, тарихта калуы бик мөмкин.*

*Башкорт шагыйре Хәсән Назар, илллене тутыруына карамастан, бары тик юка-юка гына өч китапның авторы. Бу, бәлки, шагыйрьнең шигърияткә: «...дөньяның гөнаһсыз бер сабые бит ул» дип каравыннан да, гомерем буе «Гамәлдә мин бер китапны язам» дип раславыннан да килә торгандыр.*

*Безнең арада: «Сай елгалар шаулы булалар» дигән әйтем яши. Хәсән Назарның шигърият елгасы тирән, ләкин тыныч та, шаусыз да түгел. Мондый күренеш чын шигърияткә хас нәрсә, чөнки аның тынлыгы да, шавы да ясалма түгел. Бу инде һәр кылган эшендә самими, үз фикерле, үз сүзле булуыннан да һәм үзүзеңне үз иҗатың, талантың, иманың белән саклый алуыңнан да килә.*

*Без башкорт һәм татар телләрен тәрҗемәсез телләр, дип әйтергә яратабыз, ләкин телләр тәрҗемәсез булмаса да, шигырьләрне тәрҗемә итәргә кирәк икән. Мәсәлән, без күпләребез шигырьләрне башкорт телендә язсак, ә Хәсән Назар башкортча яза дияр идем — бу аермалыкны тоя белү бик мөһим нәрсә.*

*Хәсән Назар үз шигырьләренә карата бик тә таләпчән шагыйрь һәм алар алдында җаваплылык тойгысы аны һич тә читләтеп үтми. Шигырьләренең татар укучыларына тәкъдим ителәчәген белгәч, аның: «Бу бик мактаулы, ләкин бик җаваплы әйбер», дип борчылуы юкка түгел. Әйе, җаваплылык — иң мөкатдәс тойгы.*

**Нажар НӘҖМИ,**
Башкортстанның халык шагыйре.

## Хәсән Назар,
башкорт шагыйре

### Кардәшлек

Башкортстан! Син — кардәшлек иле,
Миндә — асабалар улында —
Бер дөньябыз моңы. Ваклану юк
Уйнап җанның милли кылында.

Тарих риза Урал куеныннан,
Ә кемгә соң тарих кадерсез?
Нәфес белән тарлык түбәнлеге,
Үрли алмассыз һич хәзер сез!

Вак җаннармы масайсыннар өчен
Каһарманнар рухны көчәйтте?
Айкала да җаным чайкала тик,
Ишеткәндә «Сибелә чәчәк»не.

Сибелмик без! Төс тә, көч тә безгә
Изге дуслык — Ватан терәге.
Мәңге типсен күкрәкләрдә безнең
Салават һәм Тукай йөрәге.

Башкортстан! Син — кардәшлек иле,
Миндә — асабалар улында —
Бер дөньябыз моңы. Җаным фида
Туганлык һәм иман юлында.

## Җыр хакында

Сарылып килеп керә күңеленә,
Гүзәл заттан — җыры татарның.
Тәрәзәдән карап кала бит ул,
Иярләгән чакта атларны.

Мин тауларда әмма, далаларда
Ил тойгысы белән чапканда,
Җиремне һәм гомеремне уйлап,
Җиңелеп йә җиңеп кайтканда,

Онытылып китеп, әсәрләнеп,
Асыл җырын сузам башкортның.
Язмышыма терәк булды җырым,
Күккә ашты, таулар яңратты.

Адәмнәрдә гөнаһ булса да ул,
Җыр-гөнаһсыз, кеше аермый.
Яратам мин татар җырларын да,
Җырлы җанда кояш баемый.

## Тере зират

Бу авылда туй күлмәге
Тегелмидер.
Бармакларга көмеш балдак
Киелмидер.
Курай да юк, кубыз да юк
Бу авылда.
Бәбиләрне сикертүләр
Юктыр монда.
Калган бары картлар гына
Бу авылда.
Яшь-җилкенчәк таралышкан —

«Җиңел» юлда.
Кайтсалар, кояш чагылмый
Бу чыкларда.
Чагыла буш шешәдән калган
Ярчыкларда.
Корый нигез... Җирләр ятим,
Сулар боек.
Сүнә ай да зәгыйфь кенә
Нурлар коеп.

## Танырмын туганымны

Әй, сихри авыл көйләре!..
Сезсез мин ул минме соң?
Сарылды сездән күңелгә
Нечкә зәвык, тирән моң.

Сез шундый — җырларга сезне
Кирәкми күкрәк көче.
Җан сулышын салган сезгә
Гомернең таңы, киче.

Янганда ял алам көйләп
Үземә күрә генә:
«Ефәкләр булып уралдың
Яшь кенә йөрәгемә».

Яшьме йөрәк, яшь түгелме,
Онытам сезне көйләп.
Хәлләремә керәсез сез,
Булмый һәркемгә сөйләп.

«Таң атканда», «Озатканда»,
«Сибелә чәчәк»... «Исле гөл»...
Тормыш «Шахта»сында, «Рәйхан»,
Үзең аңла, үзең бел.

Әй, сихри авыл көйләре!
Сезсез мин ул минме соң?
Үтте минем дә йөрәктән,
Фани дөнья, синең моң.

...Әйтмә син кем икәнеңне,
Нинди юл куганыңны.
Көйләп җибәр авыл көен,
Танырмын туганымны.

## Идел бит ул...

*(«Су буйлап»)*

«Идел бит ул, Идел бит ул,
Тирән бит ул, киң бит ул...»

Мәңге агар Идел төсле,
Мәңге калыр көй бит ул.

Хәсрәтле, сабыр йөрәкнең
Дөньяга моңы калган.
Әллә Иделдән алган ул,
Әллә Иделгә салган.

Әйтче, Идел, болыннарың
Күпме аралар икән?
Уелып китер уйлар өчен
Җаным яралган икән.

«Суларга сусап йөредем,
Үзем су буйларында...»
Миннән дә калыр дулкыннар
Идел ятуларында.

## Фәридә Кудашевага

Булыр да икән шул кадәр
Фани дөньяда сагыш!
Өзә бит үзәкләремне
Фидакарь, моңлы тавыш.

«Сәлимәкәй», «Илче Гайса»...
Башкорт тыны җиткән көй.
Татар бәгыреннән саркый
«Сибелә чәчәк», «Әллүки»...

Милләт — мөлкәтлектән өстен,
Мөлкәтле тик һәр милләт.
Күтәрә җырны — халыкның
Үз аһәңендә көйләп.

Булмас кабат мондый тавыш!..
Тансык — ихлас йөрәктер,
Кардәшлекне кадерләргә
Ул әле бик кирәктер.

Рәхмәт, җырчы! Күңелләрдә
Эретеп, гүя, бозны,
Саклаштың авыр елларда
Милли асылыбызны.

Әле дә бит газиз илем
Кайгыларсыз ил түгел.
Чын җырләр һәм җырчыларда
Таяныч таба күңел.

...Сарыла җанга, сарыла
Аңлатып булмас сагыш.

Өзә бит үзәкләремне
Фидакарь, моңлы тавыш.

## Уртаклык

Рухиятне билгелидер җырлар,
Күк белән Җир шулай кушкандыр.
Җырның милләте юк диючеләр —
Алар бит ул уртак куштандыр.

Хасиятен җырның санламаучы
Кадерләсен ничек милләтне?
Күзеңне ач! Рухбасарлар, әнә,
Әзер тота гомум келәтне.

Аермалык һәм берлектә көчен,
Башкорт белән татар мохите.
Бер-беребезнең куенында кемдер
Таба икән, тапсын бәхетне.

Югалмый ул беркем — мөмкин түгел
Ай белән Җир бергә кушылу.
Бер-береңне күтәрешү җырда —
Ул бит бездә язмыш кушуы.

Тугры җанда — бер табигать, монда
Юк батырлык, юк һәм куркаклык.
Йөрәк белән җыр ул булмый уртак,
Яратуда бары уртаклык.

## Ишек

Шигырь эзләп йөрисе дә юк бит,
Үзе килеп керә ишектән.
Шигырь түгелмени, бер уйласаң,
Шушы ишек күргән, ишеткән.

Йомшак кулга, каты кулга да ул —
Барысына күнгән, пешеккән.
Сөенчеләп шатлык килеп керә,
Ябырыла кайгы ишектән.

Әти булу бәхетләрем минем
Узармы, дип, юкмы бишектән,
Уйламадым түгел... Үскәч, күтәп
Күз алмадым кайчак ишектән.

Тик рәхәттән тормый өй эчләре,
Бардыр янган, бардыр күшеккән.
Ташка күпме терәп була башны,
Кайтып керәм шушы ишектән.

Капшамыймын килгән кешене мин
Ишектәге «күзле» тишектән.

Кыяматтән өстен зиннәт, зәхмәт
Kереп чыкмый һич бер ишектән.

Дога да юк миндә, бәддога да,
Гомер-дөнья ул бер төш икән.
Өзелер төш. Мәңгелеккә мине
Озатырлар шушы ишектән.

* * *

Аралаучы бәхетсезлекләрдән,
Аеручы яки бәхеттән
Күп нәрсәләр миндә — табигатьтән,
Күп нәрсәләр миндә мөхиттән.

Зурлыкларга ашсам, әйтәчәкләр:
«Безнең заттан, безнең токымнан!»
Күздән төшсәм әгәр, күрәчәкләр
Тик үземнең генә холкымнан.

* * *

Сызылып кына аткан илаһи таң...
Уелып кына аккан су чыңнары...
Аларга бит зәвыксезлек хилаф,
Җырларның да шулай бит чыннары.

Күкләргә ул астыртынлык хилаф,
Яшьни яшен — нәфрәт асыллары.
Ирмәк өчен генә атмый яшен...
Җырларның да шулай бит чыннары.



# *Юныс Сафиуллинга 50 яшь*



*Юныс Сафиуллин 1947 елның 18 октябрендә Татарстанның Зеленодол (Яшел Үзән) районы, Бакырчы авылында туган. Мәскәү Дәүләт театр сәнгате институтының (ГИТИС) режиссерлар әзерләүче икееллык Югары курсларын тәмамлаган. 1981 елдан бирле Г. Камал исемендәге Татар Дәүләт академия театрында: әүвәле — артист, аннары хәзерге көнгә кадәр — әдәби бүлек мөдире.*

*Ю. Сафиуллин — өч дистәләп пьеса авторы. Шуларның байтагы төрле театрларда сәхнәләштерелгән. Соңгы иң танылган әсәре — «Идегәй» трагедиясе Г. Камал исемендәге Татар Дәүләт академия театрында куелды һәм зур уңыш казанды.*

*Драматургны күпсанлы укучыларыбыз исеменнән 50 яшьлек бәйрәме белән котлап, иҗади уңышлар телибез һәм остазларыннан берсе, Татарстанның халык язучысы, Россия һәм Татарстан Дәүләт бүләкләре лауреаты Аяз Гыйләҗевның аның хакындагы җылы тәбрикләү сүзен тәкъдим итәбез.*

## Пакь кеше, ак кеше...

*Юныс Сафиуллин быелның 16 июнендә миңа юллап Зәй шәһәренә хат җибәргән. Хатына өстәп, «Йөзек һәм хәнҗәр» исемле яңа пьесасын да салган. Укыдым да, тәэсирләнеп, шактый еракта калган елларга әйләнеп кайттым...*

*Юныс яшьлегендә дөньяда беркемгә дә яраша белмәгән әүлиядәй егет иде. Аракы капмады, тәмәке тартмады, хатын-кыз артыннан сөйрәлмәде, һәркемгә дә ихлас, кешелекле мөнәсәбәттә булды ул. Сәнгать әһелләренә еллар бер чакта да җиңел булмаган, Юныс та тормышын авыр корды, кыен елларда, тәлинкә тотып, хакимият алдында тез чүкмәде, ихтыярны изә торган елларда күңеле һәм вөҗданы бөтен калды. Исемдә: ул бер ара Казан Кремленең Спасс манарасында (анда Татар күчмә театры урнашкан иде) яшәп алды. Калын дивардагы бер куентыкта, кысан гына мәгарәдә иде аның «фатиры». Миңа да анда булырга туры килде. Бурсык өне кадәр генә базга башымны тыгып карагач, чак кына егылып китмәдем. Бишкә сынган Юныснын авызы ерык, ә янәшәсендә — печән чүмәләсе хәтле булыр, матрастанмы тегелгән буй-буй капчыкта китаплар. «Бөтен мал-мөлкәтем шушы...»— дип күрсәтте Юныс. Шунда яшәде егет, шул Әбугалисина мәгарәсеннән драматургиягә килеп керде. Аннан соң да Юныснын җәйсыз тормышы тиз генә көйләнеп китмәде. Берәү булса, хәлле-хәлсез яшәткән театрга төкереп, җиде чакрымга качар иде. Әмма Юныс Аллаһы тәгалә биргән талантына, язмышына язылган иманына хыянәт итмәде. Төрлесен кичерде, иллә мәгәр каләмен ташламады, әдәбият дип аталган көрәш мәйданыннан китмәде.*

*Әйе, драматургиягә юл сикәлтәле, борылыш саен чоңгыллар, су асты бусагалары сагалап тора. Юныс Сафиуллинның дөнья шаулатырдай пьесалары өлгерде: «Әллә өйләнергә инде?», «Менә без дә үсеп җиттек...», «Ни булган бу ирләргә?», «Алмазбулат», «Ләйсән ире Хәсән»...*

*Юныс Сафиуллин, драматург һәм гражданин буларак, җанын борчыган зур мәсьәләләрне, аларның да иң авырларын, җитдиләрен ике иңенә күтәреп татар тамашачысы каршысына әнә шул әсәрләре белән чыгып басты. Уйлары пакь, йөзе ак иде аның. Кайберәүләр сәхнәгә талымсыз тамашалар, алама адәмнәр меңгереп тамашачыны аңгырайткан бер вакытта Юныс Сафиуллин бик җитди, тирән мәгънәле «Идегәй» трагедиясен язды. Тарихи трагедия, татар милләтенең фаҗигасы... Бу әсәре драматургның тагын да җитлеккәнлегенә якты мисал булды.*

*Соңгы елларда төрледән-төрле театрлар, төрле зәвыклы режиссерлар Юныс Сафиуллин пьесаларына мөрәҗәгать итәләр һәм ялгышмыйлар. Акыллы сүзгә, кыю фикерләргә, милли геройларга сусаган тамашачылар аның пьесаларын яратып кабул итәләр, аңа ышаналар, сәхнә аша тансык рухи азык та алалар. Әмма драматург Юныс Сафиуллинның үсеш баскычлары, ул яулаган үрләр бер дә эзлекле итеп өйрәнелмәгән әле. Берәүне күтәреп, аның ак пинжәгенә тагылган кара төймәләрнең шыксызлыгын күрмәс хәлгә килеп җиткән чакта, башкаларны күләгәдәрәк калдырып киләбез... Әйе, танырга кирәк: Юнысның башлангыч чорындагы абстрактрак драматургиясе (ялгышмасам, унга якын пьеса!) халык күзеннән генә түгел, белгечләр игътибарыннан да бөтенләй читтә калды. Якын елларда арадан Юнысның үзе шикелле сәеррәк режиссер табылыр, аның егетчәк әсәрләре дә сәхнәдә лаеклы урынын табар, дип ышанасы килә.*

*Юныс Сафиуллинның олуг талант иясе Мәхмүт Галәү әсәрләренә таянып өр-яңа пьеса язып ятуын белә идем. Мөнә һич көтмәгәндә «Йөзек һәм хәнҗәр» исемле пьесасы белән таныштым. Бик катлаулы, фаҗигале күп язмышларны эченә алган бу әсәр Рәсәйнең чираттагы хурлыгы — Чечня сугышы турында. Чечня сугышы турыдан-туры татар халкына да китереп бәрде, без шуның трагик мисалларын бу пьесада да күрәбез. Шушы әсәрен язып Юныс Сафиуллин тагын бер егетлек эшләгән.*

*Алда да егетлекләрең ишәя торсын, Юныс энекәш, талантлы каләмдәш!*

**Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ.**

# Юныс Сафиуллин

# ЙӨЗЕК ҺӘМ ХӘНҖӘР

ФАҖИГА, ИКЕ ПӘРДӘДӘ

Катнашалар:

Линар.
Рәсим — аның дусты.
Мөслимә — Линарның әнисе, илле яшьләрдә.
Фәрһад абзый, алтмышларда.
Разия, Хания — Фәрһад абзыйның кызлары.
Йосыф — күрше малае, ун яшьләрдә.

**Вакыйга безнең көннәрдә бара.**

## Беренче пәрдә

### Беренче күренеш

**Казан шәһәрендәге бистәләрнең берсе. Монда күпчелек кеше үз йортлары белән яши. Йорт янәрында кечкенә генә бакчалары да бар. Бистәдә кош-корт тотучылар да шактый. Йорт һәм бакча тирәләре нык коймалар белән уратып алынган. Ишек аллары иркен, капкалары биек һәм берсеннән-берсе матур. Язның чәчәкле-кояшлы көннәре. Вакыт кичкә таба.**

**Магнитофонда чиченнәрнең зекер әйтүләре, куркыныч сугыш шау-шуы, шартлау-ату тавышы бистә өстен шомландырып ала да**

**кинәт кенә тына. Шундук капка артында тавыш-гауга күтәрелә. Шап та шоп ишекләр ачыла-ябыла. Орыш-тиргәш сүзләре ишетелә, өй алдындагы чиләкләр шалтыр-шолтыр тәгәрәшергә тотына. Боларга тирә-күршедәге этләрнең өреп-чинап куйганнары кушыла. Капка артындагы сөйләшүләр дә ачыграк ишетелә башлый.**

Линар. Тимә магнитофонга!

Мәслимә. Җибәрмим!

Линар. Бир! Бир, диләр бит сиңа! Ну!

Мәслимә. Беркая да китмисең! Җибәрмим! Бар, кер өйгә!

Линар. Мам, давай по хорошему! Бир магнитофонны!

Мәслимә. Каерма кулны! Акылдан яздыңмы әллә? Җибәрмим! Сиңа ярамый! Улым, бәгырь пәрам! Китмә!

Линар. Барыбер китәм! Бир кассетасын!

Мәслимә. Мә сәнә, чукын әйдә! Бет, дөмек инде алайса!

**Урам якка кассета очып төшә. Тавышлар якыная.**

Линар. Үзең бет, үзең дөмек! Ну! К черту!

Мәслимә. Ай, бетерде, сволочь! Нишләттең чебеш анасын! Канаты сынды! Ай, бер чебешемне дә изгән, фашист!

**Дөбердәтеп ачылган капкадан зур гына чемодан белән магнитофон күтәргән Линар чыга. Аның артында әнисе. Аның кулында үлгән чебеш. Линар җирдән кассетасын алып магнитофонына урнаштыра.**

Линар. Подумаешь, чебеш! Тьфу!

Мәслимә. Үтерүче! Әйдә, үтергәч, инде мине дә үтер! Сиңа бит ул берни тормый!

Линар. Молчи, ради бога! Бер сүз әйтмә! Ты меня раздражаешь!

Мәслимә. Кара син язгы кичне! Дөньяны күр, нинди матур!..

Линар *(магнитофонга баса, анда кабат чиченнәрнең зекерләре, сугышның дәһшәтле авазлары)*. Дөнья бетә! Ахырзаман житте!

Мәслимә. Бетте ул сугыш, балам, бетте!

Линар. Сугыш бетми, без бетәбез! Их, син, чебеш анасы!

Мәслимә. Кит, әйдә, кит! Барыбер артыңнан барып табам!

Линар. Табып кара! *(Китә башлый)*.

Мәслимә. Ичкериялардән алып кайтканны, авылдан гына алып кайтырмын аны-сы! Синең өчен гомердә түләп бетермәслек бурычларга баттым!

Линар. Эта твоя проблема!

Мәслимә. Өйлән, зинһар! Бетәсең бит!

Линар. Тагын башладыңмы? Хватит! Надоело!

Мәслимә. Күршеләр ишетә, акырма шул чаклы!

Линар *(акыра)*. Надоело! Больше өстермә миңа проституткаларыңны!

Мәслимә. Өйлән, улым, телсез булырмын!

Линар. Не дождешься! Все, башка күрешмәсеннәр! Тебе хуже будет!

Мәслимә. Барыбер өйләндерәм! *(Барып чемоданга ябыша)*. Чыксын иде әле син котырган эткә бирәр кыз...

Линар. Отпусти! Калган чебешләрне дә изәм!

Мәслимә. Из, тик өйлән генә! Төннәр буе саташып, акырып-бакырып, елап чыгасың! Бер генә төн дә күземә йокы кергәне юк! Бәлкем, өйләнсәң терелер идең! Сиңа иптәш кирәк! Хатын-кыз назы! Ул гына котkара ала сине бу бәладән!

Линар. Ул үзе бәла!

Мәслимә. Ә син фәрештә яса! Икәү эзлик! Ант әгәр, табабыз без сиңа ул фәрештәне! Үзең әйт. Әйдә, кемне алып кайтыйм?

Линар. Кемне генә алып кайтсаң да, мин аны төнлә суеп үтерәм! *(Җүләрләрчә көлеп, аптырашта калган анасыннан чемоданын тартып ала да китеп бара. Урамның икенче башыннан Рәсимнең «Ә-һә-әй, Линар!» диюен ишеткәч, сискәнеп борыла)*.

Мәслимә *(мыскыллы)*. Әнә, барып та торасы булмады — авылыннан үзе килде Рәсимҗаның!

Линар *(каршылап)*. Ник килдең? Казанга күчәсең, что-ли Рәсимҗан Каримович?

Рәсим *(өч-дүртләп чемодан төялгән велосипедын җитәкләп керә)*. Әссәламәгаләйкем, Линар Иванович!

Линар. Иванович түгел, Николаевич!

Рәсим. Мин дә Каримович түгел, Кәримович!

Мәслимә. Гашыйклар да болай булмас... Йә-йә, килештереп бетерегез... кочаклашып өч тапкыр үбешегез!..

Линар. Чәй куй!

Рәсим. Исәнме, Мәслимә апа!..

Мәслимә *(Рәсимгә)*. Телемә басма! *(Линарга.)* Маман хәзер артыкмыни, улым? Хатын-кызны сөймәгән кешегә мама да кирәкмиме?

Линар? Мам булсаң, арып килгән дусны монда тотма...

Мәслимә. Чакырган кунагым түгел әле. Ул да синең ише, өйләнергә теләми торган шалтыравык!

Рәсим. Мин сезнең кебек университет белән институтлар бетермәгән инде, Мәслимә апа. Шулай да исәнләшик... Исәнмесез!

Мәслимә. Исән... үлмәгән! И сезне өйләндерми торып үлмим дә!..

Линар. Инде аны да талыйсыңмы? Улың түгел ул!

Мәслимә. Улым түгелмени?! Улым булмаса — киленем! Әнә, бирнәләрен дә төяп килгән! Әйдә, килен, төкле аягың белән!

Линар. Ник котырасың? Бөтен күршеләр җыела бит!

Мәслимә. Туй булгач, туй була инде ул! Әй, күршеләр, ниһаять, минем малай да өйләнде! Горько! Горько!

Линар. Дура ты, ояла да белмисең!

Мәслимә. Үзегез оялыгыз! Сез өйләнә алмыйсыз!..

Рәсим. Уйлашыйк, Мәслимә апа... *(Велосипедын капкага сөяи)*

Мәслимә. Уйлашкан! Ничә сугышында булганнарны өйләнә алмый торган итеп кайтаралар дигәннәр иде. *(Киселгән хәрәкәт ясый.)*

Рәсим. Аңламагансың шул. Өйләнергә була, тик кемгә?..

Линар. Вот в чем вопрос...

Рәсим. Табигать ир-атны гашыйк булгач кына өйләнә ала торган итеп яраткан. Йә, кемгә гашыйк булырга? Йөгәнсез давалкаларгамы? Юк. Коръәндә ап-ачык әйтелгән: иренә, баласына тугъры буласы хатынкыз, дип. Ислам дине йөгәнләп тормаган безнең заманга каян килсен андыйлар? Бүгенге бозык заманның кызларын гаепләп тә булмый, яратып та...

Линар. Ленин әйткән: бер стакан су эчәр өчен кое казып тормагыз, дигән!

Мөслимә. Балаң булыр! Бер тамчы су кебек үзеңә охшаган бала!

Рәсим. Сугышка җибәртеп үтертер өченме? Юк, өйләнү безгә берни бирми. Хатын-кызга хәзер күп акча кирәк. Акча өчен аңа иренә мөгез кую кирәк. Бу кирәкләр өстенә башка кирәкләр дә өстәлә. Чөнки татар кызының да чит ил киноларындагыча күңелле яшисе килә. Аракысын да чөмерә башлады ул, тәмәкесен дә пыскыта. Ул кемнән ким? Се-ля-ви!

Линар. Хватит! Әйт тә бетер: на братских могилах не ставят крестов! Бездән кабер дә калмаячак!

Рәсим. Чөнки заман ахыры җитте. Табигатьне генә ал...

Мөслимә *(бүлдереп)*. Рәсим! Яхшы чакта бар, кайтып кит авылыңа! Син генә котыртасың минем улымны!..

Рәсим. Кайтам-кайтам. Миңа барыбер. Ярый, хушыгыз!

Линар. Стой! Мам, сожгу все, көл генә калачак өеңнән!..

Мөслимә. Мин мам гына түгел, папаң да — бик сикертмәм!..

Линар. Папаны кугансың, мин дә китәм!..

Мөслимә. Папаң үзе кайтып китте. Мәскәү урысы нишләсен...

Линар. Миңа да нечу делать, мин дә кайтып китәм...

Мөслимә. Син яртылаш татар! Урыс ярты-йортыны гына яратмый. Аның колачы киң!

Линар. Минме ярты-йорты? Мин — гражданин мира! *(Кулына чемодан белән магнитофонын ала.)* Рәсим, утыр велосипедыңа...

Рәсим *(төшенке)*. Әтием үлде бит, Мөслимә апа. Авылда ирләрдән соңгы кеше...

Мөслимә. Мескен, иллегә дә җитмәгән килеш... Кырыла да соң ирләр... Синең дә гаебең зур, Рәсим. Атаң өйләнә дип көтте. Оныгын кулына тотып сөясе килгән иде, бичараның. Ю-ук, мине алай гына җыеп тыгалмассыз! Мин әле яшим... яшим!

Линар. Мәет син! Без дә тере мәетләр! *(Әнисен уртәргә теләгәндәй магнитофон төймәсенә баса һәм Рәсим каршысына килә.)* Кайчан үлде? Ходай җинеллек бирсен!

**Магнитофонда көчле булып чичен кешеләренең зекер әйтүләре ишетелә. Егетләр, үзләре дә сизмәстән, чичәннәр булып кыланып түгәрәк буенча бер алга, бер артка йөреп таптана, нидер укынып кычкыра башлыйлар: Лә-иллаһы-илла-илла-аллах! Мөслимәгә болар сәер дә, көлке дә, шомлы да булып тоела.**

Мөслимә. Җитте! Йөрәкне бозмагыз! *(Магнитофонны сүндерә.)* Чечняда күреп тә туйган бу галәмәтне! Рәсим, әтиеңне ничекләр җирләдең? Бер ялгызың бит...

Рәсим. Безнең җирләр «Ильич» колхозында. Шундагы яшь мулла белән мөәзин бабай килде. Кешеләр дә алып килделәр. Аллага шөкер, бик зурлап күмдек. Коръәннән аятьләр укып... Кичә җидесен дә укыттым.

Линар *(җиргә тезләнә)*. Әнналлаһ вә әнналәйһү рәҗигун!

Мөслимә. Жигун-жигун! Нишли бит, ә! Юри кылана бит. Ярты урыс малае муллалардан да уздырып дога укый, диме?..

Линар. Сиңа да фарыз. Гөнаһларың кимер азрак!

Мөслимә. Үзеннекен бел! Әнә, чебеш үтердең!

Линар. Синең аркада үлде!

Рәсим. Линар! Ул — әниең! Битәрләргә хакың юк!

Линар. Бар! Мин яхшырак беләм! Сугышка сине көчләп җибәргәннәр, ә мин — аңардан качып!.. Пух-пах, та-та-та!

Мөслимә *(капканы ача)*. Рәсим, акыллым, керегез өйгә!

Линар. Качма, барыбер беләләр! Икебез дә үтерүче!

Рәсим. Линар кеше көлдермә! *(Алып керә башлый.)*

Линар. Нәселдән килә! Татар әбиемне мам үтергән иде...

Мөслимә *(Линарга суккалый)*. Әнкәй бик ярата иде сине. Шуңа гел Мәскәүгә килә иде. Ә син аны чукындырдың! Кечкенә идең шул. Муенында тәре. Без сине Коля белән чиркәүгә алып барган идек. Коляның апалары шулай теләгәч... әбиең мөселман иде!..

Линар. Әби Мәскәүдә түгел, Казанда үлде!

Мөслимә. Рәсим! Әни авыр эшләрдә эшләп бик беткән, тузган иде.

Рәсим. Линар, артык ярсыгансың... керик!

Линар. Теләмим... яшисем килми!

Рәсим. Ә минем... Барыбыз да шул хәзер. Барыбыз да ходайдан ярдәм сорарга тиешбез! Безгә шул кирәк хәзер!

**Егетләр эчкә узалар. Мөслимә ялгыз кала. Капка төбендәге киң итеп эшләнгән утыргычка башта Линарның магнитофоны белән чемоданын китереп куя, алар янына үзе дә утыра.**

Мөслимә. Алдымда тагын ярык тагарак кына... Газраил килеп, әйдә җыен дисә, шатланып риза булыр идем... күрәсен күрми, гүргә кереп булмый шул. Ә ничек шаклар катканнар иде. Хәлимәнең юлдан язган кызы башта университетка барып керде, аннары бер дигән Мәскәү егетенә кияүгә чыкты. Әнкәен дә Мәскәү кодагые ясады! Күпме бүләк, посылка салдым мин әнкәемә! Инде ни? Тагын теге әкияттәгечә ярык тагарак кына! Нишләтим соң бу баланы?! Бердәнбер мөтем шул бит... *(Почта әрҗәсендәге телеграмманы күреп ала.)* Телеграмма килгән. Кемнән булырга мөмкин? Фәрһад абыйдан? Чечняның иң зур бае минем янга киләме? Ант — ышанмыйм! Поезды ничәдә

дигән? Аһ, килгәненә ярты сәгать! Көтәр микән? Әгәр көтмәсә! Линар! *(Чемодан белән магнитофонны капка артына кертә.)* Линар, чык! *(Велосипедка ябыша. Кулын селтәп).* Әй! Линар! Чык, дим! Тфү! *(Йөгереп китеп бара.)*

Линар *(тавышы өйдән ишетелә).* Мине чакырасыңмы, мам?

**Искиткеч зәвык белән киенгән ике кыз күренә. Кулларында җиңел генә сумкалары да бар.**

Хания. Шушы йорттыр... *(Сумкасын утыргычка куя).*

Разия. Номеры юк? Тегеләрен барып карыйм... *(Китә.)*

Хания. Бетте аяк... *(Туфлясын салып урындыкка менеп утыра.)*

**Капкадан Линар чыга. Хания аңа борылып карый. Исәнләшә.**

Линар *(кызга нәфрәт белән).* Кого ждешь? Убирайся!..

Хания. Нәрсә? Алкаш, что ли?

Линар. А ты кто? Валютная, да? А где наша сутенерша?

Хания *(шаккатып).* Вот идиот!..

Линар. А-а, понятно. Хочешь замуж?!..

Хания. Иди отсюда!

Линар. Не нравлюсь, да? Тогда иди. Ну че ждешь? Даже такому рада?.. Ну, давай же, тогда... *(Мыскыллап)* Надо проверить! Целуй! Давай, давай! *(Кызны кочкалп убә)* Че ломаешься? Валютная, что ли? *(Хания аның яңагына суккач, Линар да, кызны яңаклый).* Ах, тебе так нравится!.. Мне тоже! *(Чалкан авып төшкән кызның итәген кайтарып ташлый. Изүләрен йолкып ача. Өстенә ава.)* Тебе как нравится? Скажи!..

**Тавышка өйдән Рәсим йөгереп чыга. Разия да әйләнеп килә.**

Рәсим. Линар!

Разия. Җибәр!

Рәсим. Нишлисең син? Төш дим кыз өстеннән!

Линар. Үзе шулай тели!

Хания. Сволочь! Хакъ!

**Рәсим белән Разия Линарны читкә алып ташлыйлар.**

Разия *(апасына туфляларын кияргә булыша).* Ни булды соң монда? Кемнәр болар?

Хания *(вайнах телендә).* Бөех хум! Хакъ![1] Маньяк!

Разия. Тынычлан, апа! Без моны болай гына калдырмабыз!

**Кызлар китә.**

Рәсим. Линар, нишләдең син?

Линар. Мамадан уч алдым! Сутенерша кебек гел проституткалар җибәрә!

Рәсим. Саташма. Кызлар вайнах телендә сөйләштеләр. Чичен кызлары болар! «Хакъ» диде. «Дуңгыз» дигән сүз бит. Бөех хумы...

Линар. Искә төште — грязная скотина ул.

Рәсим. Менә-менә, Россия солдатларын шулай дип сүгә иде алар. Ярый, мин артларыннан куып җитеп гафу үтеним, юкса алар милиция белән киләчәкләр!

Линар. Килсеннәр! Боевиклары белән дә килсеннәр! Суйсыннар! *(Кинәт башын Рәсимнең күкрәгенә куеп бала кебек үкси).* Туйдым! Болай яшәгәнче...

Рәсим. Ашыкма! Син өйгә кер, мин барсын да җайлыйм... *(Линарны капкадан кертеп җибәрә).*

Линар *(кире чыга).* Мин дә барам, мин дә гафу үтенәм! Мин беркайчан да кешене зерә рәнҗетмим!

**Егетләр китәләр. Якында гына такси тавышы. Фәрһад абзый керә. Капка каршына туктап йортның номерын караштыра. Кыңгырауга басып та, өйдән беркем чыкмагач, ары китеп бара. Озакламый Мөслимә кайтып керә. Тирләп, яныл-пешеп беткән. Ял итәргә дип утыргычка утыра.**

Мөслимә *(кычкыра).* Линар! Улым! Дәшмә, алайса, дәшмә! Рәсим! Әллә өйдә беркем дә юк инде? Таш юлдан такси менеп киткән кебек булган иде. Күземә генә күренде микән? Фәрһад абый...

Фәрһад *(әйләнеп килә).* Әү, Мөслимә? Тәки табыштык...

Мөслимә. Мин гаепле. Телеграмманы соң күреп алдым, шуңа каршыларга да соңардым.

Фәрһад. Гаеп эзләргә, мин кунак булып кайтмадым, качак кына... Әйт, Мөслимә, тыгызласам, өеңә кереп тә тормыйм, Ичкериягә кайтып китәм.

Мөслимә. Качак та, кунак та түгел син. Онытылган булса, исеңә төшерим: мин сине Казаныбызга үзем чакырган идем. Менә өем, түре сиңа!

Фәрһад. Рәхмәт. *(Кулын күтәреп.)* Йә, бер дога! *(Укый. Битен сыпыргач.)* Халык телендә бистәгезне Нахальный диләр икән. Шәп яшиләр. Алайса бу йорт синеке?

Мөслимә. Минеке синекедәй өч катлы ташпулат түгел шул. Ай, менә хәзер дә күз алдымда тора... Бездә дә коттедж-моттеджлар салган булып маташалар, әмма кая инде аларга...

Фәрһад. Ташпулатларым юк инде хәзер, Мөслимә.

Мөслимә. Сатып кайттыңмыни? Дөрес эшләгәнсең.

Фәрһад. Грозныйдагысын син барында ук җир белән тигезләгәннәр иде... Улың ничек соң? Бөтен Ичкерияне айкадык бит эзләп...

Мөслимә. Бала күңеле далада... Әй, сөйли торганмыни?..

Фәрһад. Шулайдыр. Сугыш үзгәртте кешеләрне... Өйдәме үзе?

Мөслимә. Өйдә. Эшләми дә... өйдә ята.

Фәрһад. Шуңа өйгә чакырмыйсыңмы? Сиңа кыенга килә торган булса, тәртәне кире борыйм. Казанда дусларым күп...

---

[1] Бөех хум! Хакъ (Вайнах-чичен телендә) — Шакшы хайван! Дуңгыз!

Мөслимә. Юк, аны син генә кеше итә аласың. Хәзер керәбез. Тукта, чак кына сөйләшеп алыйк башта... Утыр. Мин хатынкыз гына шул.

Фәрһад. Һаман кияүгә чыкмадыңмы?

Мөслимә. Кемгә чыгыйм инде?..

Фәрһад. Улыңның атасы урыс бугай?.. Исәнме ул?

Мөслимә. Исән. Каян белдең? Сезнең Чечняда урыска чыкмыйлар, ә бездә бит атлаган саен. Гаепләмә инде. Ниме?.. Уңайсыз булса да сорыйм, ул чаклы байлыкны ничек тупладың? Бездәге яңа байлар кебек, кеше таладыңмы?

Фәрһад. Андыйлар нәселебездә юк. Бабай егерме беренче елдагы ачлыктан качып Паратскидан Кырымга килгән. Кырык дүртенче елны безне Кырымнан Казакъстанга сөрделәр. Әйе, Казан татарлары да байтак иде сөргәндә. Миңа унбиш яшьләр иде. Халыкның ничек изаланганын гомер буе күреп яшим. Шахтада күмер чаптым. Алинәмнең әтисе белән бергә идек. Минем бабай мәрхүм — чичен кешесе, вакытында Ичкериясенә кайта алмады. Шуның васыятен үтәп кенә кайттык Ичкериягә. Алинәм дә монда кайтырга каршы түгел иде. Үзе дә бит татар кызына охшаган иде.

Мөслимә. Ә ни булды? Алинә апа турында «иде» диден?

Фәрһад. Сөйләрмен... Әйе, бабай: «Үлгәч, мине туган илемә алып кайтып җирләгез»,— дигән иде. Син сокланган байлыкларга килсәк, алар соңгы ун елда гына тупланган байлыклар.

Мөслимә. Син бит горурлыгыбыз, Фәрһад абый! Ичкериядә һәркем сине «иң зур баебыз» дия иде. Чиченнәр үзләре бик чая булып та безнең татардан уздыра алмаганнар. Югыйсә аларны бөтен СССРны таладылар дип сөйләделәр телевизордан.

Фәрһад. Кем кемне талагандыр — анысы шул телевизорга гына билгеле, ә мәнә минем үземне бер көндә бернисез калдырулары хак!

Мөслимә. Бер юлын белгән кеше тагын да баер анысы. Без генә мәнә — тилмерәбез! Ул Чечняларга барулар мине гомер түләп бетермәслек бурычка батырды. И, Фәрһад абый, өйрәт безне дә яшәргә. Гомер буе кеше күңелен күрдем, гомер буе һәркемгә яхшы булырга тырыштым. Бүген мин хәтта улыма да кирәкмим. Баярак «татар әбиемне үтердең» диде. *(Йөзен каплый)*. Әнкәем үлемендә тамчы да гаебем юк! Иң кадерле кешем иде. Әти авариягә эләккәч, әни бер үзе шушы йортны торгызды. Мине ялгыз башы карап үстерде. Кешедән кимхур яшәмик дип, башта хәрби заводта изаланды, аннары ашказаннары беткән килеш — асфальт заводында. Мин ялгыз үстем. Яклаучыларым юк. Үзем дә җебегәнрәк нәрсә идем. Әйе, алданган кызны ул чакларда кем алсын? Бар Нахальный бистәсе күреп, белеп тора... Әнкәй шунда бер өзгәләнгән иде. Шуны төзәтәм дип икенче ялгыш эшләп ташладым. Бер урыс малае Мәскәүдән килеп университетта укып йөри иде.

Фәрһад. Чыктыңмы шуңа?

Мөслимә. Алгач, чыктым инде. Алар безнең кебек вакчыл да түгел!..

Фәрһад. Иярдең дә киттең инде, чирле әнкәеңне ялгыз калдырып?

Мөслимә. Исәп үз яныма алдырырга иде. Миннән көлеп йөргәннәрнең күзләрен акайттырырмын дигән идем.

Фәрһад. Акайдымы соң?

Мөслимә. Ирониян урынсыз, Фәрһад абый!

Фәрһад. Тыңлавым шулай...

Мөслимә. Тыңлау түгел, бу — көлү. Беркемгә дә сөйләмәс идем — сиңа ачылдым. Миңа ярдәм итә ала торган бердәнбер кеше син... Бәлкем, кирәкмәс, үзеңнең дә кайгың башыңнан ашкан...

Фәрһад. Бер кайгыны бишкә бүләек... Сөйлә, сөйлә...

Мөслимә. Мәскәүдә иремнең туганнары мине чиркәүгә алып бардылар.

Фәрһад. Чукындыңмы?

Мөслимә. Чукынасың инде, яраткач!.. Коля да бик шатланды...

Фәрһад. Шуннан?

Мөслимә. Барсы да Линардан башланды. Әнкәй кунакка килгән иде. Бик ярата иде Линарны. Исемне дә ул кушты бит. Линар бик кечкенә, әбисенә тәресен күрсәтеп мактанды. Әнкәй барысын да аңлады. Җитмәсә, улым аны да чукындыра башлады. Намаз өстенә утырган карчык өчен бик авыр булды. Әнкәй авырый башлагач Казанга кучеп кайттык... Их, мәнә хәзер булса, Линар белән әнкәй парлашып намаз укып йөрерләр иде дә... Ник тынып калдың, Фәрһад абый? Нигә сукмисең? Мәнә шундый инде без хатын-кызлар... яңалыклардан курыкмыйбыз. Гаҗәпләнәсеңме?

Фәрһад. Бу дөньяда мин инде бернигә дә гаҗәпләнми башладым.

Мөслимә. Бай кеше шул син! Бөтен дөньяны айкап чыккансыңдыр!.. Чит илләрдә генә ял итәсеңдер?

Фәрһад. Юк, ял итәргә өлгермәдем. Ә байлыкка килгәндә, аның нигезендә урланган маллар түгел, шахтада эшләп тапкан маллар ята. Шуларга тире эшкәртү цехлары ачып җибәргән идем.

Мөслимә. Ә өегездәге байлык ничә йөз меңлек, ә?!. Андагы мебель, паласлар, әллә ниткән аппаратуралар?

Фәрһад. Нишләмәк кирәк, байлык бер айлык. Рәсәй миноборонасы мине кимендә миллион долларга бөлдерде. Байлык кына бер хәл, ул мине ярты мәет ясады. Кызларны Дагстанга илтә киттем. Алинә йорт саклап калды. Бер полковник белән сверхсрочниклар килгәннәр дә өйдәге бар нәрсәне төйи башлаганнар. Күршеләр әйтте, ике автомобиль белән бер КамАЗга ярты көн ташыганнар. «Урал» машинасының сары төстә булуын да хәтерләп калганнар. Алинәм аларны тиргәп, оялтып, комачаулап йөргән. Видеотасмаларга төшергән. Тегеләр киткәндә йортны шартлатканнар...

Мөслимә. Ничек түздең, Фәрһад абый? Ничекләр үлмәдең?

Фәрһад. Син дә түзәсең бит әнә...

Мөслимә. Минме түзәм? Мин күптән үлгән инде. Малай әйтмешли, тере мәет!

Фәрһад. Бәлкем, мин дә үлгәнмендер? Үлгәнемне белмәгәнгә күрә генә исән килеш йөримдер?!.

**Мөслимә.** Минем малай да үлгән, ахры, Фәрһад абый?

**Фәрһад.** Яшь кеше тиз үлми... Әле менә без дә, әлхәмделиллаһи шөкер, аякта. Халкымның тамырлары нык, бернигә карамый яши бирәбез.

**Мөслимә.** Менә минем улымны да тормышка кайтарасы иде. Өйләндерә алмый интегәм. Җитмәсә икәү булдылар...

**Фәрһад.** Анысы кем тагын?. Икәүләп эчәләрмени?

**Мөслимә.** Эчәләр димим, күңелләрендә ахырзаман. Аның икенчесе дә син табышкан малай. Пленнан икесен бергә йолып алган идең ич әле. Рәсим исемле. Минеке Линар, авылдан килгәне Рәсим. Миңа көн бетте хәзер өйдә. Ярдәм итә алырсыңмы, Фәрһад абый? Гомерем буена бурычлы булыр идем.

**Фәрһад.** Бурычларың болай да бик күп бит.

**Мөслимә.** Колың булырга да риза!

**Фәрһад.** Кирәкми. Мин сине бурычлы ясарга да, кол итәргә дә кайтмадым.

**Мөслимә.** Бәлкем, син бөтенләйгә дип тә кайтмагансыңдыр? Ярый алайса, калганнарын өйдә сөйләшербез. Болай да инде теге хәсрәт төенчекләре аркасында кешечә каршылый алмадым.

**Капкадан эчкә узалар. Урам буйлап Разия белән Хания килә.**

**Разия.** Булды, дим, елама! Хәзер табабыз. Кайдарак диден әле?

**Хания.** Әнә шунда. Теге маньяк миңа менә бу җирдә ябышты.

**Разия.** Ничек җир күтәрә икән аларны? Милициягә әйтәсе калган.

**Хания.** Абрекның бердәнбер бүләге иде. Шуның төсе итеп күз карасыдай саклый идем. *(Иелеп нәрсәдер эзләнә.)*

**Егетләр күренә. Кызлар янына килергә кыймый посып торалар.**

**Разия.** Яшел кашлы шул ул. Монда чирәмдә табуы авыр булыр.

**Хания.** Йөз ел эзләргә дә риза. Абрегым гына каберендә рәнҗеп ятмасын.

**Разия.** Күренми. Бәлкем теге маньяктадыр? Милиция чакырмый булмас.

**Хания.** Кайсы илдә яшәвеңне онытма! Беркемгә дә кирәкмибез без. Тере килеш кабергә тыга торган заман бит бу... Әтигә каршы килеп булса да, барыбер Ичкериямә китәм. Минекеләр анда ятып калды.

**Капкадан Фәрһад абзый чыга.**

**Фәрһад.** Кайда йөрисез соң сез? Өчдүрт тел белә торып, адашып йөрмәгәнсездер бит?

**Хания.** Без белүдән ни файда, мондагылар алама булгач!

**Фәрһад.** Син ни диярсең, Разия кызым?

**Разия.** Апа хаклы.

**Фәрһад.** Ә табигатенә күз салдыгызмы соң сез? Нинди назлы ул.

**Хания.** Табигате белән нишләп була, кешеләре ерткыч булгач.

**Фәрһад.** Сез инде бигрәк... Килеп житәргә өлгермәдегез... Юк, карагыз сез яхшылап... Далада тудыгыз, тауларда үстегез, инде ходай сезгә оҗмах кебек бакча бүләк итте!

**Хания.** Әгәр безне анда маньяклар тотып көчли икән, нигә кирәк безгә ул бакча?!

**Фәрһад.** Берәү дә көчли алмас. Без бабаларыбыз туфрагында. Без, ниһаять, үз җиребездә.

**Разия.** Әти, чыннан да, китик моннан...

**Хания.** Әти, зинһар, тыңла. Син бит мине беләсең... Абрек үлгәннән бирле минем берәүгә дә күтәрелеп караганым юк. Әмма мине менә шушы урында көпә-көндез көчли башладылар. Кычкыргач та беркем ярдәмгә килмәде.

**Разия.** Безгә Төркиядә дә, Ичкериядә дә фәрештәләргә караган кебек хөрмәт белән карыйлар иде.

**Линар Рәсим кулыннан ычкынып аларга таба килә башлый.**

**Фәрһад.** Ант итеп әйтәм, мин ул маньякны табып...

**Линар.** Аны табасы юк! Менә ул! Йә, нишләтәсен, Фәрһад абзый? Атып үтерәсеңме? Ат! Үлемнән курыкмыйм! Үзем булышам! Пистолетың бармы соң? Көт, алып чыгам! Әнә, Чыңгыз урманына алып керерсең дә — маньякка маньяк үлеме, диярсең... *(Юлына тошәргә маташкан Рәсимне читкә этеп ишегалдына уза.)*

**Рәсим.** Кызлар! Фәрһад абый! Гафу итегез безне! Фәрһад абый, син безне үлемнән алып калдың, ә без... Телисезме, тезләнәм! Аңлашыйк! *(Тезләнә.)* Гафу итегез!

**Фәрһад.** Сине ни өчен, Рәсим?

**Рәсим.** Шушы хәлгә төшүегездә минем дә өлешем бар! Илегезне туздырдык! Без бит Ичкериягә бармый кала ала идек. Күп кеше бармады. Төрмәләргә утыртсалар да... Ә менә без — бардык!

**Хания.** Бөех хум! Ничек оялмыйсың?! Кеше үтерүче! Палач! Үзе теләп бит...

**Рәсим.** Палач түгел! Үтерергә бармадым мин, үзем үләсе килгәнгә бардым! Ходай шаһит!

**Хания.** Ялган! Сугышта йә үзең үтерәсең, йә үзеңне үтерәләр. Син — тере! Бәлкем минем Абрегым да синең кулдан шәһит киткәндер?

**Рәсим.** Мин гөнаһсыз, ышанмасагыз, гөнаһысы үзегезгә булсын!

**Фәрһад.** Балалар, тынычланыгыз! Сез дошманнар түгел! Сез якын кардәшләр!

*Пәрдә*

## Икенче күренеш

**Мөслимәләрнең ишегалды. Кайдадыр гармун тавышы ишетелә. Ишегалдында Мөслимә үзе генә. Көлә-көлә чеби аулый.**

**Мөслимә.** И, рәхмәт төшкере! Ничек чыктың соң әле син? Әнә анаң ду куба! Ай, җитез дә соң. Тоттым дигәндә генә качты да китте. Чеп-чеп-чеп-чеп! Кара ничек элдертә! Уф! Әнием янына кертәм! Кай төштән чык-

ты икән бу? Әй, кем бар анда, тотышыгыз әле! *(Урам якка карап.)* Исләрендә дә юк. Дүртенче көн инде йөзек эзлиләр. Бөтен тезләре яшелләнеп беткән. Чеп-чеп-чеп-чеп! Сары томшыгым! Усалым, кил инде! Рәсим! Чык әле шул сараеңнан! Иртәдән бирле акыртып туймадыңмыни? Юк инде, беркемгә дә кирәге юк чебиләрнең. Рәсим, синең якка йөгерде! Колагына да элми. Тәмам композитор булган! Каян килгән Салих Сәйдәшев! *(Чебине кабат ауларга китә.)* Ай, сине, җүнсез, апаңны кара тиргә батырдың. Аркамнан сулар ага. Тимим! Чеп-чеп-чеп... а-ап-па! Менә эләктенме! Әбиең әйтмешли «мәэ-мәэ» итәм мин сине! Карале, йөрәге ничек дөп-дөп тибә! Йомшак йомгагым минем! *(Көйли.)* Чеп-чеп, чебиләрем,

*Йомры-йомшак йомгакларым,*
*Минем нәни елакларым!*

**Йорттан Фәрһад абзый чыга. Өстендә затлы киемнәр. Кулында сотовый телефон.**

Фәрһад *(Мөслимәгә кушылып җырлый).*

*Бер көн килер сез үсәрсез,*
*Йомырка бүләк итәрсез!..*

Мөслимә. Менә ичмасам! Танырлык та түгел! Новый русский!
Фәрһад. Улың кайда?
Мөслимә. Синең кызларга йөзек эзләшә.
Фәрһад. Күпкә китте бит инде. Шул гынадыр кайгылары... Дүрт көн буе юкны бушка аударалар. Хания кызым!
Хания *(керә.)* Монда мин!
Фәрһад. Йөзегең табылдымы?
Хания. Комачаулый бит әнә!..
Фәрһад. Кем?
Хания. Линар. Әйткәч тә аңламый. Тапсаң да, ул йөзекне синнән алмыйм, дим. Телсез кебек...
Фәрһад. Спирт заводлары белән эшне бетердеңме?
Хания. Разия шалтыратып бетерде бугай...
Фәрһад. Разия! Кер әле, кызым!
Разия. *(Керә. Кулында сотовый телефон.)* Әти яшәреп китте. Казан һавасы чыннан да шифалы, ахры...
Фәрһад. Кызым, ни хәлләр анда?
Разия. Сине һәр заводта беләләр. Кичә Чистайга барып килдем. Син сораган 140 тонна әзер. Озатырга да булышырбыз, диләр.
Фәрһад. Мөслимә, алайса Линарны да чакыр. *(Сотовый телефоннан номер җыя.)*
Мөслимә. Улым! Линар, Фәрһад абыең чакыра! *(Урамнан улын ияртеп керә.)*
Фәрһад *(телефонда сөйләшә.)* Ринат әфәнде! Бу тагын мин! Теге йортны тәки сатып алдым. Биш сутый җире дә бар. Мөслимәдә ике сутый. Җәмгысе җиделән артык. Шулай, әлбәттә. Өч катлы коттедж салырбыз. Ике гараж белән.
Линар *(мыскыллы).* Ә нигә ике генә? Булгач-булгач, дүрт булсын!
Фәрһад *(бүленеп).* Ни дидең, Линар?
Мөслимә. Улым, комачауламa! Сүзләре бик җитди. Инде композиторы тотынды... Рәсим! *(Гармун тавышы килгән якка барып).* Туктат ул гармуныңны! Телефоннан сөйләшәбез!

**Гармун тына. Бераздан Рәсим үзе дә күренә.**

Фәрһад *(телефонга).* Аңладым. Алла боерса! Металлны Биектауга — беренче чиратта... Беләләрдер шул. Көтсен! Әйт, бу юлы тагын да шәбрәген алып кайтырга тырышачакмын. Договормы? Әйе, хәбәрләштеләр. Договорда спирт күрсәтелгән. Казакъ дусларга бездән — 140 тонна спирт, алардан — металл. Әйе, алар белән аңлаштык. Сугыш бит. Договор аңа чаклы ук төзелгән иде. Мин инде алар сораган 140 тонна «Экстра» спиртын Украинадан сатып алып Ичкериягә кайтарткан да идем. Соң, шуны әйтеп торам. Әйе, тамчысына чаклы юк иттеләр. Кемнәр барырмы? Үзем озатам. Соңрак, яме! Амин, шулай булсын!
Рәсим. 140 тонна спирт! Кызлар, бу чаклы спирт ничә туйны үткәрергә җитә?
Разия. Безнең туйларыбызга аракы кирәк булмас, Рәсим.
Мөслимә. Фәрһад абый, бу коттедж дигәнен озак салырсызмы?
Фәрһад. Төзүчеләрдән тора. Дөресе, аларны кайчан чакыруыбыздан.
Мөслимә. Миңа димәгәе, хет иртәгә чакыр. Өй, урын-җир иркен. Әнә верандабыз да бик зур. Юкса син Казакъстанга китеп барсаң...
Фәрһад. Анысы да кирәк. Казакъстан заводлары — спирт, безнекеләр металл көтә. Верандага күз салыйк әле, Мөслимә.

**Мөслимә белән Фәрһад верандага кереп китәләр.**

Хания. Әйдә, Разия!..
Разия. Кайда?
Хания. Эзләшмисеңмени йөзекне?
Разия. Күпме эзләргә була? *(Хания чыга башлагач.)* Ярар, апа, тик соңгы тапкыр. Болай да тезләрем суелып бетте. *(Ханиягә ияреп урамга чыгып китә.)*
Рәсим *(беседкада яткан сотовый телефонны алып).* Әйт, кая шалтыратыйм?
Линар. Иди к черту. Ничек шаяртасың килә...
Рәсим. Ә син шаяртма! Давай шалтыратабыз. Әйт тизрәк...
Линар. Теге дөньяга шалтырат!
Рәсим *(номер җыя).* Алло! Теге дөньямы бу. Зират дисезме? Ә юк, башта аллаһы тәгалә белән сөйләшәсем бар. Ә-ә, үзе тыңлыймыни? Әй, раббебез! Иң мәрхәмәтлеләрнең дә мәрхәмәтлесе! Газраилеңне җибәрсәң иде. Әйе, бик көтәбез! Нинди чират, нинди чират — без бит чиченнәр! Безгә льгота юкмыни? Әфган белән чиченнәргә льгота тиеш! Льгота! Телефонны куйды...
Линар. Алласына да ышаныч юк. Кешесе нинди, ул да шундый.
Рәсим. Дөрес түгел! Тәүбә ит, ахмак, ходайга тел тидердең!
Линар. Пошел ты! Син үзең тел тидердең!
Рәсим. Ничек итеп?

Линар. Газраилне чакырып!

Рәсим. Чакырсам соң, мин бит аны әни белән үги әтигә чакырдым. Ходай дошманнары алар! Зиначылар! Әти үлде дип телеграмма суктым — кайтмадылар!

Линар. Син аларны эзләп таптыңмыни?

Рәсим. Их, акча кирәк миңа, акча!

Линар. Әнә, Фәрһад абыйга яллан. Новый русскийлар булырсыз!

Рәсим. Новый татарин, диң.

Линар. Чепуха! Әйдә теге балдакны эзлик!

Рәсим. Балдак түгел, йөзек! Кашы бар аның!

Линар. Ну и что? Әйдә, главно — табыйк!

Рәсим. Аңлат башта, үлгән кеше йөзеге тере кешегә нигә?

Линар. Безгә то что. Кочып йокласын! Зато бер кайгысын киметәбез. Бәхетсез кыз ул.

Рәсим. Син бәхетлеме? Синең үз кайгың юкмы?

Линар. Вот шуның өчен эзләшәбез дә. Ну! Тор! Эзләшик!

Рәсим. Эзләштем мин...

Линар. Тапмадык бит. Ну, давай, тор!

Рәсим. Син командирмыни — туктаусыз боера башладың?

Линар. Ә син? Синең командаларга мин түзәм бит.

Рәсим. Ошамый икән — түзмә!

Линар. Ошамаса да түзәм. И син дә түз!

Рәсим. Түзмим. Боерыкларсыз да сөйләшеп була...

Линар. Балдакны табыйк та...

Рәсим. Балдак түгел, анаңның малае, йөзек! Абрек биргән йөзек. Һаман аңламый. Бәлкем, ул Абрекны син үтергәнсеңдер?!

Линар. Мин үтердем. Шуңа йөзеген булса да кайтарыйк.

Рәсим. Безнең авылда синдәйләрне «керәле дә чыгалы» диләр.

Линар. Беткән авылыңдамы?

Рәсим. Карале, Линар, әйдә авылга кайтып безнең өйне сатабыз. Мунчасы да әр-яңа! Аларны сүтеп алып килсәк, акча булыр!

Линар. Да ну тебя, куркуль! *(Чыга башлый.)*

Рәсим. Линар! *(Кесәсеннән йөзек алып)*. Йөрмә, менә ул йөзек!

Линар. Ничек? Шул үземе? Кайчан таптың? И бирмәдең? Кем син? Алар анда дүрт көн буе абаланып эзләделәр. Ә тебе хоть бы что!

Рәсим. Сиңа ул: арпа — талкан, тизәк — шалкан! Балдак, имеш. Балдакны өйләнгәч бирәләр! Ә бу — вәгъдә йөзеге!

Линар. Төкерәм мин синең сөйләшә белүеңә! Бир монда!

Рәсим. Кычкырма миңа!

Линар. Карак! Мародер!

Рәсим. Ак эт баласе кара эткәме? Ханияны көчләде дә, хәзер мине гаепли, маньяк! Менә шундый булганга сине бирәү дә яратмый иде. Бирәүгә дә кирәгең юк иде.

Линар. Син ярата сың бит — житкән! Илтеп бир балдакны кызга!

Рәсим! Тот! Гашыйк булгансың икән, мә, үзең чыгар да бир! Лакейлар юк! Бәлкем зур борынлы Абрегын да онытыр!

Линар. Үлгән кешедән көнләшәсең, ә?

Рәсим. Мин аны хәтта тересеннән дә көнләшмим. Потыгыз бер тиен!

Линар. Ә-ә, син дигәнчә булмый башлады, ие?

Рәсим. Мин дигәнчә булу-булмавы вак нәрсә. Син иң мөһимен оныта башладың...

Линар. Онытмадым!

Рәсим. Оныттың!

Линар. Юк, дим! Мин син түгел. Мине берни дә үзгәртә алмый. Шуңа әйтәм: илт Ханияга балдакны! Син алып тыкмасаң, ул аны күптән табар иде.

Рәсим. Минем намусыма кагылма! Габеңне юасың киләме? Мә, үзең тапшыр!

Линар. Һаман аңламадың, ие? Ни кирәк сиңа?

Рәсим. Үзеңә ни кирәген дә белмисеңмени? Ярар, әйтәм, тизләп! *(Үзе тизләнә.)* Син үтергән балалар рухына багышлап дога кылабыз!

Линар. Хватит! Танкны син алып бардың!

Рәсим. Танкны боерык алып барды! Приказ!

Линар. Ә миңа: «Боевикларга — огонь!» дигән приказ булмадымы?

Рәсим. Нинди боевиклар? «Балалар бакчасы» иде ул. Балалар иде анда. Чичен, әзербайҗан, урыс балалары! Боевикларга да атарга хакың юк иде! Алар үз өендә! Пленда чакта күрдек бит. Нинди саф күңелләләр! Үзе ашамаса да әсирне ашата! Шәригать кушканча яши алар! Син аларның аналарын күреп үтергәндә, алар сиңа рәхмәт әйтеп торсыннармы? Алар без түгел! Алар өчен Ана — изге! Син генә ул әниеңне бар дип тә белмисең!..

Линар. Син үзеңне бел!

Рәсим. Әгәр минем әни синеке кебек булса, мин аны кулларымда күтәреп йөртер идем. Юк, минем дә әниемә Газраил чакырырга хакым юк! Кеше гафу да итә белергә тиеш! Әйе, мин үзем дә миранус сарык! Тизләп әйдә! Ходайдан гөнаһларыбызны ярлыкауны сорыйк! Егерме биш кәррә сөйдел-истигъфарны укыйбыз! Әстәгъфируллаһәллэзи лә иләһә илла... *(Линарга.)* Ник катып калдың?! Укы!

Линар. Укырбыз, мең тапкыр да укырбыз! Бар, бир башта кызга балдагын!

Рәсим. Бирдем, әнә! Маньяк! *(Йөзекне бакча эченә тондыра.)* Бар, кызыңнан рәхмәт сорарга онытма!

Линар. Мин сине убью, сволочь!

Рәсим *(мыскыллы)*. Убей, сволочь!

Линар. Еще как убью! *(Сугып җибәрә)*.

Рәсим *(каршылык күрсәтми, һаман да мыскыллы тонда)*. Юк, үлмәдем әле. Живой әле!

Линар. Заткнись, заткнись, зараза! *(Кабат-кабат суга.)*

Рәсим. Зараза исән әле, исән! *(Киләт авып төшә.)*

Линар *(ярсыган хәлдә типкәләргә тотына)*. Ну, понял! Әйт, акыл кердеме?

Рәсим *(канлы иренен сөртеп торып утыра)*. Керде, рәхмәт бик шәп керттең!

Спасибо, друг, не забуду твою заботу до гроба!

Линар *(үзе дә сизмичә Рәсимгә ташлана, аны күтәреп аягына бастыра. Башын үз күкрәгенә салып кульяулыгы белән иреннәрен сөртә).* Нишләп каршы сукмадың? Әйдә сук, җәлләмә, син хаклы, мин сволочь! Маньяк мин! Әйдә киттек... китик моннан...

Рәсим. Кая?

Линар. Хоть куда!

Рәсим. Акча кирәк безгә. Әйдә авылга, сатыйк йортларны...

Линар. Әйдә... *(Магнитофонын ала).*

*Пәрдә*

## Өченче күренеш

**Рәсимнең авылдагы таш йорты һәм зур гына мунчасы күренә. Ишегалды буйлап Фәрһад абзый йөренеп тора. Мөслимә мунча янындагы бүкәндә күзләрен сөртеп утыра.**

Фәрһад *(сотовый телефонда номер җыя).* Алло, Андрей Петрович, это ты дорогой? Ах, еще не вернулся? Хорошо, подожду...

Мөслимә *(елый).* Ну, бу Рәсим, ашый бит малайның башын!..

Фәрһад. Тынычлан, Мөслимә. Еларга сәбәп юк. Аларның бергә булулары әйбәт кенә...

Мөслимә. Һаман күренмиләр... Безне күреп качмадылар микән?..

Фәрһад. Булды, сөрт күз яшьләреңне. Син бит көчсез хатын түгел. Иң мөһиме — исәннәр. Качып та китмәгәннәр. Ничек күрсен алар безне, машинаны наратлыкка яшереп төштек.

Мөслимә. Ә соңрак? Безнең кызларны күреп качканнардыр...

Фәрһад. Кызларга сак булырга киңәш иттек.

Мөслимә. Шул гомердән бирле кайтмауларына аптырыйм. Күпме котәргә була? Кара, мунча да яккан булганнар. Тәмам өлгерүе җиткән, ут бөркеп утыра. *(Торып өйнең тәрәзәсенә бара.)*

Фәрһад. Кечкенә булса да, авылы нык булган. Клубларына кадәр таштан салынган. Берничә бик шәп йортлары бар...

Мөслимә *(тәрәзәдән өй эчен күзәтә).* Гармун белән магнитофоннары да монда. Их, шушы Рәсиме булмаса, болай йөрмәс иде... Аерасы иде үзләрен, Фәрһад абый!

Фәрһад. Линарны үзем белән Казакъстанга алмак булам...

Мөслимә. Рәсиме дә сезгә ияреп китәчәк. Аннары Казакъстанда синнән качып калулары да бик мөмкин. Аннан инде кабат табып кайтулары икеле.

Фәрһад. Алайса, тәвәккәллим... Кайткач башларбыз дип тора идем.

Мөслимә. Ни-нәрсә эшләргә җыенасың, Фәрһад абый?

Фәрһад. Карале, Мөслимә, менә бу авылны күргәч башыма бер уй керде. Бу авылны бит кабат тергезергә була.

Мөслимә. Әйе шул, Фәрһад абый, Рәсимгә дә бер эш табылыр иде.

**Разия керә.**

Разия. Әти, егетләрне беркайдан да таба алмадык!

Мөслимә. Апаң кайда калды соң?

Разия. Зират ягына китте. Әрвахларны кызганам, авылларында дога укырлык кешеләре дә калмаган, диде. Карале, әти, авылның теге очында ирле-хатынлы кемнәрдер җир казый. Ел саен Казаннан кайтып бәрәңге утыртабыз, ди. Рәсимне дә беләләр. Бергә укыдык, диләр. Шулар әйтә: Рәсим белән Линар да бәрәңге утыртмакчы булалар, диләр.

**Мөслимә шатланып көлеп җибәрә. Аңа Фәрһад абый да кушыла.**

Мөслимә. Әллә минем малай да бәрәңге үстермәкче? Ай, күрәселәр бар икән.

Фәрһад. Көлдерден әле, кызым.

Разия. Чын, әти, чын. Әнә, кара, ярты бакчалары казылган.

Мөслимә. Кай арада казыдылар икән?.. Әйтәм мунча яккannар, кара тиргә батканнардыр шул, мескеннәр.

Разия. Мунча якканнармыни? Бигрәк матур мунча. *(Эчкә уза.)*

Фәрһад. Алайса, син дә бу уемны хуплыйсың, Мөслимә?

Мөслимә. Бик, Фәрһад абый. Төп авылларында да булганым бар. Ерак түгел. Колхозны җитәкләүчесе дә акыллы. Яшь үзе.

Фәрһад. Иң мөһиме — тимер юл якын. Казаннан кайтып йөрүчеләрне дә үгетләп булыр дип уйлыйм. Төп авылларында газ булгач...

Мөслимә. Бар, бар, былтыр ук кертеп яталар иде.

Фәрһад. Алайса, шулай итәбез дә, Мөслимә. Шушы авылда кече предприятиебезне ачабыз. Рәисләре янына барып килим әле. Мин — тиз. Телефонны сиңа калдырам. Бәлкем, Хания шалтыратыр. *(Китә.)*

Разия *(мунчадан атылып чыга).* Абау, тәмугтыр бу.

Мөслимә. Җылы башлап чыктыңмы әллә?

Разия. Аждаһа кебек бу мунча — башны да тыгарлык түгел!

Мөслимә. Карале, бу нәрсә пипелди башлады.

Разия. Ханиядыр. Әти үзе кайда соң?

Мөслимә. Күрше авылга китте.

Разия *(телефоннан сөйләшә).* Әйе, апа, синмени? Әллә? Менә бит. Эзләгән табар, ди. Нишлиләр?

Мөслимә. Улым табылдымыни? Аллага шөкер! Сорале, зиратта нишлиләр икән?

Разия. Урманнан каен ботаклары җыеп төштеләр, ди.

Мөслимә. Себеркегәдер. Мунча өчен иң шифалысы май аенда җыелганы, ди иде мәрхүмә әнкәй.

Разия *(телефонда).* Аңламадым? Нишлиләр, дисең?

Мөслимә. Әйт, зинһар, күренә күрмәсен, йә качарлар.

Разия *(Мөслимәгә).* Зиратка кердeләр, ди. Тезләнеп дога укыйлар, ди.

Мөслимә. Рәсимнең атасы күмелгәндер анда. Авыр туфрагы җиңел булсын Кәримнең.

Разия. Линар остарак укый, ди.

Мөслимә. Китче? Ничек алай? Татарчасын да рәтләп белми, гарәпчәгә ничек теле әйләнә икән?

Разия. Аңа карамый ул.

Мөслимә. И, бу Рәсимне... өйрәткән була минем малайны... ә үзе әле Линардан да начаррак укый икән. Татар бит әле ул. Минем малай яртылаш урыс. Карале, Разыя кызым, син укый беләсең бит әле...

Разия. Беләм, Мөслимә апа.

Мөслимә. Мине дә шул белгәннәреңне укырга өйрәтче!

Разия. Аллаһы боерса!

Мөслимә. Менә рәхмәт, Разия. Безгә бит өйрәтүче булмады. Шулай да бик күптән уйлап йөри идем. Чечняда әнә ничек матур итеп укый беләләр. Әнә Төркия кебек бай илләргә барып чыксаң да кирәк... Гомер узып бара, берәр чит илне дә күргән юк.

Разия. Чит илгә чыгу өчен генә намазга өйрәнү гөнаһ бит...

Мөслимә. Әлбәттә, гөнаһ. Менә шул гөнаһлардан арыныр өчен өйрәнәсем килә дә. Үзем белми эшләгән гөнаһларым да күптер әле. Белеп эшләгәннәре дә җитәрлек. Өйрәтә күр, кызым. Соң булса да уң булсын!

*Пәрдә*

## Дүртенче күренеш

**Шул ук авыл. Шул ук ишегалды. Кичке эңгер-меңгер. Разия белән Мөслимә намазлык өстендә утыралар. Линар белән Рәсим күтәренеп кайтып керәләр. Алар белән бер үк вакытта Хания да кайта. Машина тавышы ишетелә. Озакламый ишегалдына Фәрһад абзый да керә.**

Фәрһад. Җыелышып беттекме? Менә шул, егетләр, сез бездән башка да яши аласыздыр, ә безгә сездән башка яшәве бик читен.

Рәсим. Ник соң ул алай?

Фәрһад. «Ана күңеле — балада, бала күңеле — далада» дигәннәрен ишеткәнегез бардыр. Ходай тәгалә тарафыннан әйтелгән: ата-аналардан баш тарту, аларны рәнҗетү иң зур гөнаһ диелгән...

Линар. Изге ата-аналар хакындадыр ул.

Фәрһад. Кемнең изге булуы бер ходайга гына мәгълүм. Ана сиңа ходайдан бирелгән. Шулай ук өлкәннәрне хөрмәтләү һәм кирәк чакта ярдәм итү бездә элек-электән иң гүзәл сыйфат булып саналган.

Рәсим. Фәрһад абый, мин авыл малае. Ачык кына итеп әйтеп бир инде, сиңа бездән ни кирәк?

Линар. Сорама — әйтәм: безне пленнан коткардымы — коткарды. Безнең рәхмәтне ишетер өчен коткарды дип уйласаң, ялгышасың. Ул бизнесмен. Бер тиен салып ун тиен алырга тырыша.

Фәрһад. Ә бар тапканыбыз уртак булыр, дисәм?.. Шартнамә төзербез.

Рәсим. Таныш нәрсә бу! Коммунизмда шулай булсын ие.

Линар. Мафияда да шулай сайрыйлар...

Рәсим. Алайса, былтыргы «а» була инде бу, әйеме, Линар?

Линар. Чечняда булганнарга коммунизм мундиры да, мафия фраклары да кысанрак.

Фәрһад. Мафияда озак булдыңмы соң?

Линар. Бер ай.

Фәрһад. Нигә кергәнеңне аңлыйм, нинди сәбәп китәргә мәҗбүр итте?

Линар. Киллер итәргә теләделәр. Ялланган үтерүче...

Фәрһад. Менә упкынга төртеп төшерү шулай була. Ә минем тәкъдим, шулай ук мин үзем дә...

Рәсим. Байларның барсын да упкын көтә. Димәк, синең тәкъдимең дә бәхет китерә алмый.

Линар. Чечнядагы коттеджларыннан шартлаткан кебек, безнең өй урынына корачак коттеджың да ике гаражы белән күккә очачак!

Фәрһад. Аңлатып бир!

Хания. Сез безнең Ичкериядә шартлаган коттеджларыбыз өчен шатланасызмы?

Рәсим. Кайгырмыйбыз да. Хәләл акчага андый коттеджлар салып булмый.

Фәрһад. Була, балалар, була!

Хания. Әти, синме бу? Зинһар Ичкериябезгә китик!

Фәрһад. Кызым, сиңа тагын ни булды?

Хания. Дебильныйлар бит болар!

Фәрһад. Ә менә миңа ошыйлар.

Хания. Шушы булдыксызлармы? Шушы наданнармы? Бая котыра-котыра дога укыган булдылар. Шуны да рәтләп белмиләр. Ә укыйлар.

Фәрһад. Чын күңелдән укыса, кабул була. Егетләр, сез дошман күргән коттедж кәеф-сафа ача торган җир генә түгел, ул ныгытма! Ныгытма гына да түгел, безне күмә, батыра торган туфан афәтеннән саклап калачак Нух пәйгамбәр көймәсе! Моннан унике ел элек шахтада җыйган акчаларга Чечняда мин тире эшкәртү цехлары ачып җибәргән идем. Кызганыч, әлегә минем андый ук мөмкинлекләрем юк. Шуңа аз биреп, күп ала торган төшемле эшләрдән башлыйм да. Әмма алар законлы эшләр. Бераз мая туплагач, уртак эш сайларбыз. Тәҗрибәм җитәрлек. Ярдәмчеләрем дә ышанычлы. Олы кызым юрист, кечесе финансист.

Линар. Зато без никто!

Рәсим. Булдыксыз белән надан!

Мөслимә. Ничек инде никто? Кара ничек мескенләнә. Җиңел промышленность техникумын бетердең. «Мелита»дагы валютный цехка закройщик итеп бер сине алганнар иде.

Линар. Мунча әзерме, Рәсим?

Фәрһад. Егетләр, тыңлап бетерегез башта...

Линар. Миңа берни дә кирәкми.

Фәрһад. Ә сезнең сугышчан дусларыгызга?.. Нигә сез аларның тормышлары белән кызыксынмыйсыз? Аларны да монда чакырып була бит!

Рәсим. Ничек алай? Беткән авылгамы?

Фәрһад. Ә без кече предприятие ачабыз! Председатель риза. Аның да эче пошып йөргән. Хәтта газ кертергә булышам, ди. Таш клубны әнә бушка бирде. Шуннан ук Ринат әфәнде белән бәйләнешкә кердем. Кыскасы, ярты айдан беренче продукция...

Линар. Булыр. Шикләнмим. Тик, нигә кирәк болар сиңа?

Фәрһад. Миңа нигә кирәкме? Гомерем буена тизләндерергә тырыштылар. Хәзер дә шулай. Ә минем тизләнәсем килми. Кеше булып кала алу — бәхет. Әгәр мин башлаган эшне сез күтәреп алсагыз, ул чакта мине беркайчан да тизләндерә алмаслар.

Линар. Мин «новый русский» түгел дияргә телисеңме?

Фәрһад. Эштә күрерсез.

Рәсим. Сиңа да байлык кирәк, Фәрһад абый...

Фәрһад. Кирәк. Ул — азатлык! Сез нигәдер байлыкны кәеф-сафа корыр өчен җыялар дип уйлыйсыз. Мин дә бай идем. Шул байлыгым аркасында җанга якын кешеләр белән аралаштым. Иң зур бәхетсезлек — түбән җанлы кеше каршында баш ию. Линар сүзе дөрес, андыйларның урыны мафияда. Ә миңа сезнең кебек горур җанлы, талантлы яшьләр кирәк. Шуларны үз яныма җыясым, кешеләрне, законнарны чүпкә дә санамый торган бу каһәрле илдә дә чын кеше булып кала алу серләренә төшендәресем килә. Ризамы сез шуңа?

Рәсим. Кызык сорау бу? Җавабын соңрак бирсәк, ничек?

Фәрһад. Уйларга кирәк, әлбәттә. Әмма иртәгә юлга чыгасы бар. Безне Карагандада көтәләр. Кайсыгыз бара ала?

Линар. Карагандагамы?

Фәрһад. Шунда түгелме сезнең белән бергә хезмәт иткән егет?..

Рәсим. Игорь исемле. Игорь Иваницын.

Фәрһад. Игорьны да монда алып кайта аласыз! Хәзергә бер унлап кеше җыя алсак...

Рәсим. Линар, ишетәсеңме?..

Фәрһад. Эш башларга җитеп тора. Йә, кайсыгыз иртәгә минем белән ерак сәфәргә чыга?

Линар. Икебез дә.

Фәрһад. Ә кем мондагы эшләрне башлап җибәрер? Кем сезнең кебек егетләрне монда чакырып китерер? Азык-төлек туплар? Белгечләрне кабул итәр? Бер очтан цехлар да аякка басарга тиеш. Әнә, колхоз рәисе дә ашыктыра...

Линар. Колхозны Рәсим яхшы белә.

Фәрһад. Алайса җыена башла, Линар.

Линар. Җыяр әйберем юк. Миңа сүзең бармы, Рәсим?

Рәсим. Бар. *(Линарны читкә алып китә.)*

Разия *(өйдән гармун алып чыга)*. Әти, уйна әле.

Фәрһад. Караңгы төште бит, ишетәсезме, сандугачлар сайрый.

Хания. Уйна, әти! Искә төшер әле бергә җыелышып утырган бәхетле көннәрне!

Фәрһад. Өйгә керик алайса. Рәсим, без керәбез...

Рәсим. Урыныгыз түрдә булсын! Мөслимә апа, нигә чакырмыйсың?

Мөслимә *(тәрәзәне ачып)*. Әйдәгез, әйдә, табын күптән әзер!

**Фәрһад кызыннан гармунны алып өйгә таба атлый һәм сыздырып «Шахта» көен уйнап җибәрә. Мөслимә аңа кушылып җырлый башлый. Рәсим белән Линардан калганнар өйгә узалар.**

Рәсим. Китәсеңме?

Линар. Китимме соң?

Рәсим. Фәрһад абый дөрес чамалый. Игорьны күрү кирәк.

Линар. И алып та кайтырга...

Рәсим. Чыннан да... ул бит детдом малае. Аның анда беркеме юк.

Линар. Булды, кайтты дип уйла.

Рәсим. Унны җыя аласың, ди. Мин ул чаклы белмим.

Линар. Табылыр. *(Кесәсеннән куен дәфтәре алып суза.)*

Рәсим *(карый)*. Болар барысы да килсә, колхоз булып яшибез икән...

Линар. Какой колхоз? Казарма, дин!

Рәсим. Казарма? Кызык бит бу! «Тукта, гүзәл мизгел» була!

Линар. Әйе. Бер җан, бер тән булып яшәрбез. В душу никто не полезет! Казарманың үз законы!

Рәсим. Тот бишне!

Линар. Ун булсын! Ха-ха! Игорьны әйтәм. Командовать итәчәк...

**Рәхәтләнеп көлешәләр.**

Рәсим *(көтмәгәндә)*. Огонь слева! *(Җиргә ташлана.)*

**Линар да аның янына ята. Менә алар пластунча шуарга тотыналар. Башларын күтәреп нидер тыңлыйлар. Күрәсең, өздереп сайраган сандугач тавышлары да аларның шаулап торган колакларында автомат тавышлары, миналарның чинап очып килүләре, яралыларның кычкырып сүгенүләре, үлеп ятучыларның елап ыңгырашулары булып ишетелә. Менә алар аягүрә басып, чиченнәр кебек «Аллаһы әкбәр! Ля-иләһы-илла-аллаһ!» дип, бер урында бөтерелә башлыйлар.**

*Пәрдә*

# Икенче пәрдә

## Бишенче күренеш

**Мөслимәләр бистәсендәге ишегалды. Ай ярымлап вакыт үтеп киткән. Иске йорт артыннан өч катлы коттеджның сокланып туймаслык нәкышләр белән бизәлгән таш диварлары күренеп тора. Алар асылда татар орнаментларына нигезләп ясалсалар да, коттедж үзе ни беләндер Кавказ якларында яшәүче төрки халыклар төзегән биналарны хәтерләтә. Ишегалдында кая карама пөхтә генә каплап куелган төзелеш материаллары, төзелеш кирәк-яраклары. Болдыр каршына өелеп куелган идән такталары өстендә Мөслимә басып тора. Бер урам якка, бер коттедж ягына карап сукрана. Хания күренә.**

**Мөслимә.** Рәсимнәр ник котыра соң анда?

**Хания.** Әллә тагын. Разия белән өченче катта алар.

**Мөслимә.** Авылда йөреп кайттылар да, ни эшләгәннәрен белмиләр!

**Хания.** Линар һаман күренмиме?

**Мөслимә.** Тәмам аптырадым. Куып калган, ахры, Рәсиме монда булса да...

**Хания.** Ичмасам, әти дә кайтып житәлмый.

**Мөслимә.** Төнлә Биектаудан шалтыратты, ахры?..

**Хания.** Төнлә кайтып булмас, металлны урнаштырып бетерәсе бар, диде.

**Мөслимә.** Линар турында тагын ни диде?

**Хания.** Сөйләшергә бик теләми, аргандырмы, әллә Линар белән сүзгә килгәннәрме...

**Мөслимә.** Линарны шуңа поезддан сикереп төшеп калган дисеңмени? Юктыр, Рәсимен сагынгандыр. Кирәк бит, аягым сынар дип тә тормаган, полный ход барган товарныйдан станцыда сикереп калган. Рәсимнәр авылына ерак түгел аннан...

**Хания.** Сагынган гына булса, ярый... әти белән сүзгә килгәннәр кебек...

**Мөслимә.** Ни житми бу жан көегенә!.. Их, Хания, ал әле улымны порукага! Син күпне күргән... Юкса бездә беркем аңламый аны!

**Хания.** Ичкериядә сугышканнар барысы да бер иш. Авылга барып шаккатып кайттым. Рәсимнең өен тәмам казарма итеп бетергәннәр!

**Мөслимә.** Автоматлары да бармыни?

**Хания.** Булмаса да, чын казарма. Сөйләп аңлата торган түгел.

**Мөслимә.** Разия әйтте. Сабыйлар кебек, ди.

**Хания.** Анысы шулай. Альфред дигәннәре болар янына больницадан качып килгән. Ашказанында язва... кан коса, ә врач белән Казанга кайтырга теләми. Братаннар янында үләм, ди. Этләренә кадәр Самашки кушканнар.

**Мөслимә.** Самашки дигәннәре Линар тәмугта булган авыл бит.

**Хания.** Ичкериядә андый кара күмергә әйләнгән авыллар бик күп!

**Мөслимә.** Тагын нишлиләр инде? Ишәләр бит коттеджны! Чыркылдап та карый, сеңлең! Бер дә сиңа охшамаган! Рәсимен карале син... Бутау калагы булды чистый!

**Хания.** Бер-берсен ошатканнардыр. Тәртипле кыз ул. Әйдә, теләсә нишләсеннәр!

**Мөслимә.** Теләсә нишләсеннәр, имеш! Улым әнә, дусны дус иткәч, бар көчкә барган товарняктан да сикереп калган. Ә Рәсиме нишли? Туктале... и, ходаем, улым имгәнеп ятмый микән?..

**Хания.** Алла сакласын! Хәер, әти әйтте бит: гитарасын барып алды да авыл ягына китте, диде.

**Мөслимә.** Бердәнберем бит ул минем. Әх, өйләнсә болай йөрмәс иде... Хатынкызга ияләштереп булмый. Яратмый хатын-кызны...

**Хания.** Хатын-кызны яратмаудан түгелдер ул.

**Мөслимә.** Ә соң... кызлар аңа күрү белән сөлек кебек сылана... Берәүгә булса да күз салыр иде...

**Хания.** Сугыш гаепле, Мөслимә апа. Әнә теге казарма ясап ятучылары да шундый. Күрше авылларындагы рәисләре килгән иде, ул да әйтеп торды. Шулчаклы өйләндерергә тырышып карадым үзләрен, бер-ике атна кызлар белән йөреп караган булалар да, аралары боз кебек суына, ди.

**Мөслимә.** Ә соң Рәсим нигә алай? Айдан артып китте бит...

**Хания.** Врач әйтә: чечня синдромы аларда, ди. Дәвалап булмый икән Ичкерия сугышыннан кайтканнарны. Сеңлем кызганыч, Рәсиме дә шулай булачак...

**Мөслимә.** Әйтмә дә... ниндидер бер авыл малаена кызыкмаса — Казанда егет беткәндер.

**Хания.** Врач әйтә: Чечняда булганнарның урыны йә психушкада, йә төрмәдә, ди.

**Мөслимә.** Аның үзен төрмәгә тыгарга кирәк! Ансат кына. Элек врачлар үзләре үлсә үлгән, әмма авыруны коткарган. Ә моның бар белгәне — төрмә белән дурдом! Заманы нинди, врачы да шундый. Инде ярар, ирләре шулай да булсын, аның бит хәзер хатын-кызлары да шундый! Көт син хәзерге таш йөрәкләрдән ярдәм!

**Хания.** Синеңчә ничек, мин таш йөрәкмени, Мөслимә апа?

**Мөслимә.** Сине белмим, син аллага ышанасың...

**Хания.** Кирәкми, Мөслимә апа, алланың монда катнашы юк.

**Мөслимә.** Ник булмасын. Ходай корбан биргәнне ярата, диләр.

**Хания.** Шул үтерүче өчен мин корбан бирергә тиешме?

**Мөслимә.** Үтерүче түгел ул! Мафия аңа миллионнар тәкъдим итте. Ул акчалар миңа ярты бурычымны түләргә житәр иде.

**Хания.** Акча өчен улыңны кеше үтерергә жибәрер идеңме?

**Мөслимә.** Мин түгел, мафия жибәрә. Кешене дә түгел, буржуйны! Үзләре ише үк мафияне! Шул жулик байлар аркасында ач утырабыз!

**Хания.** Кит, яхшы чакта, Мөслимә апа!

**Мөслимә.** Тукта, хәзер аңлатам. Элегрәк дим бит мин... Хәзер инде алай уйламыйм. Бер ходай тәгаләгә ялварам. Түземлек бир, дим. Эшләгән гөнаһларыбыз күптер...

**Хания.** Амин, барыбызга да түземлек кирәк. *(Өйгә юнәлә.)*

**Мөслимә.** Әтиеңә шалтыратып карыйк әле, Хания! Кайтасы булса ашарга әзерләп торыр идем.

**Өйгә кереп китәләр. Коттедж ягыннан Разия килеп чыга. Рәсиме дә күренә.**

**Рәсим.** Инде качасыңмыни? Жиңелдеңмени? Йә, ярый, тагын берне әйтеп карыйм. Инде бусын да белмәсәң, жиңелгән буласың! *(Шигырь укый).*

*Иртәгесе көнгә каршы төндә*
*Сабантуйга жәймә тегәбез,*
*Жәймә уртасына олы итеп*
*«Батырга» дип чигү чигәбез!*

Разия. Бусы да Такташ.

Рәсим. Такташта сабантуй диләрмени? Җәймә тегәләрмени? Байрак тегәләр анда. Булды, шартны үтә.

Разия. Көлдермә!

Рәсим. Шартны үтәгәч, көләрсең!

Разия. Әй, кит әле! Син мине тәмам бутап бетердең.

Рәсим. Ә син буталма! Вәгъдә — иман!

Разия. Ялганлый, ялганлый да, иман, ди. Иблис иманы бу!

Рәсим. Чү! Үтәмисең икән, кирәкми! Гөнаһы үзеңә...

Разия. Тагын гөнаһ, ди. Йә, ярар, кил!

Рәсим. Юк, син үзең кил!

Разия. Килде, ди. Икмәк корсак артыннан йөрми!

Рәсим. Минме корсак? Мин — җиңүче. Син дә икмәк түгел — җиңелүче! Димәк, шартны үтәргә тиеш!

Разия. Йә, ярар, туйдырдың тәмам! *(Рәсим янына килә. Бит очына иренен тидереп китеп бара.)*

Рәсим. Нишлисең?

Разия. Үптем бит.

Рәсим. Биттәнме? Иреннән үбәргә сөйләштек бит.

Разия. Мыскыл итәсеңме?! Сүз үбү турында гына булды. Шарт үтәлде.

Рәсим. Хәрәмләшәсең инде, әй!

Разия. Ник кенә бәйләндем мин синең белән? Йә, ярый, башы-ахыры шул булсын! *(Тиз генә Рәсимнең ирен очыннан үбеп китә.)*

Рәсим. Син нишлисең?

Разия. Иренеңнән үптем. Әллә тагын «дөрес үпмәдең» дип әйтергә телисеңме?

Рәсим. Үбүен дөрес үптең.

Разия. Шулай булгач...

Рәсим. Ә ни өчен үбешәсең?

Разия. Үзең «үп» дип сорадың.

Рәсим. Сораучы күп булыр ул.

Разия. Кара инде моны. Ай буе артымнан җанны ашап теләнеп йөрде дә...

Рәсим. Теләнгән өчен генә үбешә башласаң...

Разия. Теләнгәнең өчен генә үбешмәдем. Син җиңдең!

Рәсим. Җиңсәм соң! Ә син җиңелмә!

Разия. Йә, бар! Мин шартны гына үтәдем.

Рәсим. Син чичен кызы. Чиченнәр җиңелүне белми!

Разия. Мин татар кызы да... Яртылаш кына җиңелдем.

Рәсим. Разия, әйдә чынлап сөйләшәбез.

Разия. Ә син әле чынлап та сөйләшә беләсеңме?

Рәсим. Әгәр үзең җитди сүзне тыңлый белсәң...

Разия. Беләм. Иртәгә Казан сабантуенда да көрәшергә чыгасыңмы?

Рәсим. Чыгам.

Разия. Тагын батырга чыгасыңмы?

Рәсим. Әлбәттә. Чыккан-чыккан — батырга чыгарга кирәк.

Разия. Авыл сабантуенда да батырга чыктың, үләсең дип торам. Бер сәгать яттың бит тора алмыйча.

Рәсим. Ятсам соң.

Разия. Аңламыйм. Көрәшә белмәгәч, нигә көрәшкә чыгарга. Җитмәсә батырга чыга бит. Рәсим, ходай сине көрәшче итеп яратмаган, ә оештыручы итеп тудырган. Әнә, Линар гел синең программаңны үти!

Рәсим. Сез килгәнче бәлкем шулай булгандыр, ә хәзер юк.

Разия. Валлаһи, дип әйтәм, син даһи оештыручы. Хәтта теге котырган фашист та сиңа берсүзсез буйсына.

Рәсим. Тагын Романга каныгасыңмы? Нишләп фашист булсын ул!

Разия. Үзе үк әйтеп тора. Сугышта да фашист булган!

Рәсим. Мин синең белән бәхәсләшергә дә теләмим. Башта син ул сугышта булып кара... аннары бәхәсләшербез! *(Коттеджга китә).*

Разия. Тагын үпкәләде. Ярый, шулай булсын... Тукта, мине дә көт, Рәсим! *(Артыннан китә.)*

**Урам яктан Линар кайтып керә. Коттеджга сынап карап торгач, такталар өеменә утырып тынып кала. Аннары гитарасын чирткәли башлый. Өйдән Хания чыгып Линар уйнаган көйне сәерсенеп тыңларга тотына. Әфган окопларында туган бу көйдән күңелгә шом тула. Капка төбенә таксида килеп туктаганнары ишетелә.**

Линар *(әлеге көйгә Ичкериядә урыс солдатлары чыгарган җырларны кушып җырлый башлый).*

*О будь ты проклята, чеченская земля.*
*Твои сады взойдут на русской крови.*
*Твои воронками испаханы поля*
*И пролегла солдатская тропа*
*дорогой к горю.*
*Грозный, Аргун, Гудермес...*
*Благословение небес —*
*За черным роком нас судьба послала.*
*Ведет людей на эшафот их царь и бог —*
*Святой пророк*
*Ведет людей — чеченцев, ингушей!*

**Ярсып яңгыраган бу усал җырны ишетеп өйдән Мөслимә йөгереп чыга. Урам яктан ашыгып Фәрһад абзый керә. Җыр үсә бара. Линарга кушылып аны башка солдатлар да хор белән җырлыйлардыр шикелле.**

Линар *(җырлый).*
*Потом мы встретимся с друзьями.*
*В бокалы полные шампанского нальем*
*И вспомним, как холодными чеченскими*
*ночами*
*Друг-друга прикрыли мы огнем!*

Хания *(талпынып Линар каршына килеп баса. Кулын гитарага сала. Линар уйнаудан туктагач, гитараны үз кулына ала да әфган окопларында дөньяга килеп чичен җиренә күчеп яңгыраган әлеге көйгә Ичкерия халкы чыгарган җырларны җырлый башлый).*

*Сугыш җиле кабат кабатланды:*
*Танклары белән изге җиребезне*
*Таптап йөри урыс солдатлары —*
*Ил намусын салып таптаулары!*
*Ата алар азатлыкка төбәп,*
*Карт-корыны стенага терәп,*
*Бала-чага, хатыннарга төзәп,*
*Җир йөзеннән юк итәргә теләп!*

**Фәрһад.** Кызым, Хания!

**Хания** *(күз яшьләрен сыпырып ала да кабат уйный башлый).*

*Тәмуг алып килде илбасарлар...*

**Фәрһад** *(аны туктата).* Кызым, икенче вакытта... Тынычлан...

**Хания.** Юк, әти, ишетсен! Патриот җырларын гына түгел, менә без — чичен бандитлары җырларын да ишетсен!

**Нәкъ шул мәлне Рәсим белән Разия килеп чыга. Рәсим Линарга карап гармунда туш уйный башлый. Әмма нидер сизенеп туктап кала. Хания кулындагы гитарага карап тора башлый.**

**Хания** *(җырлый).*

*Тәмуг алып килде илбасарлар:*
*Җир чайкала, үлә бар тереклек,*
*Газаватка дәшеп инри таулар,*
*Өч йөз елда шәһит киткән җаннар*
*Безнең сафка баса терелеп!*
*Таулар булып суга алар набат,*
*Россиядән ирек даулап кабат,*
*Мәңге рәхәт күрмәс илбасарлар —*
*Газаватка дәшеп инри таулар!*

**Фәрһад абзый белән Разия Ханияны култыклап читкә китәргә мәҗбүр итәләр.**

**Линар** *(Рәсимгә мыскыллап).* О! Новому русскому большой привет!

**Рәсим** *(шулай ук).* Карт урыска да күп сәлам!

**Линар.** Йә, ничек соң, деревянный белән түлиме, әллә зелененькийлар белән аласыңмы?

**Рәсим.** Авылга шуны белер өчен бардыңмыни?

**Мөслимә.** Улым, Линар! *(Кулларын сузып исәнләшергә килә.)* Инде ай ярым күрешкәнебез юк бит.

**Линар** *(күрешә).* Исәнме, мам!

**Мөслимә.** Казакъстан ошадымы соң?

**Линар.** Юк.

**Мөслимә.** Ул хәлләр дөресмени? Ачтан кырылалар, дигәннәр ие. Этләрне дә ашап бетергәннәр икән? Фәрһад абый, нишләптер гел читтә торасың? Син бит чит кеше түгел. Исән-сау кайтуларыгыз белән. Аллага шөкер, металлны да урнаштырып бетергәнсең. Менә, кара, нинди коттедж салдырып куйды Ханиян! Кайбер кешенең уллары да мондый эшне эшли алмый. Әйдә, Фәрһад абый, шушы коттеджның болын кебек болдырына утырып кызың Разия тәмле итеп пешергән гөбәдияне ашап утырыйк әле!

**Фәрһад.** Рәхмәт, Мөслимә. Бу сүзләрең белән син мине шундый куандырдың, ходай тәгалә сине дә шулай куандырсын!

**Мөслимә.** Улым, уян, син бит хуҗа кеше. Җебеп торма, чакыр табынга!...

**Линар.** Нинди хуҗа? Аңламадым...

**Мөслимә.** Кунакларны өйгә чакыр дим, өйгә...

**Линар** *(кычкыра).* Өем юк минем! Мин үзем кунак! Әнә хуҗагыз!

**Рәсим** *(Линарның җилкәсеннән коча).* Линар! Тынычлан!

**Линар** *(Рәсимне этеп җибәрә).* Кит, продажная штука! Сатлык җан!

**Рәсим.** Котыр, әйдә, котыр! Тик белмичә котырма! Башта бел!

**Линар.** Әллә сатмадыңмы?

**Разия.** Нишлисең син, Линар? Роман котыртып җибәрдеме?

**Линар.** Романга тел тидермә! Он настоящий мужчина!

**Хания.** Романыгыз фашист! Ул сездән дә фашистлар ясаячак!

**Фәрһад.** Кызым, тукта! Бу нинди ахмаклык!

**Разия.** Әти, апа хаклы! Мин дә ишеттем. Роман әйтте: ун чиченне дөмектердем, кабат барсам меңне дөмектерәм, ди.

**Рәсим.** Юк, сүзне зурга җибәрмик! Аның да энекәшен үтерделәр! Карарлык түгел иде. Колак-борыны чабылган, авызында... Ярар, зинһар, бетерик... Нигә кирәк безгә үткән хакында сөйләшү?.. Болай да бугазга килә...

**Хания.** Дөреслектән алай гына качып булмый. Кем кача, димәк, ул җинаятьче!

**Линар.** Аһ, суд оештырасыңмыни, иптәш прокурорша?! Давай, давай! Рәсим, утыр әйдә, утыр җинаятьчеләр скамьясына! *(Такта күтәреп сала. Аңа Рәсимне күтәреп утырта. Үзе дә такта өстенә чүгәли.)* Нюрнбергский процесс башланды. Фашистлар хөкем карары көтә. Хайль Гитлер! Абрек — капут!

**Разия.** Нигә маймылланасыз инде, егетләр? Мин үзем күргәнне әйттем. Роман тумыштан явыз җан.

**Линар** *(Рәсимгә).* Роман, ишетәсеңме? Син тумыштан явыз җан.

**Рәсим.** Куй, инде, Линар. Болай да болганчык...

**Линар.** Ярый алайса үзем Роман булам. Сөйлә, туташ.

**Разия.** Юкка син Романны яклыйсың. Эчсә дә башкалар кебек кенә эчми иде. Братаннарын да котырганчы эчертә. Ике стакан белән генә туктарга бирми, көчләп өенчесен дә авызларына коя.

**Рәсим.** Йоласы шул. Сугыштан калган йола.

**Линар** *(Роман булып).* Братаны мои! *(Образга ук кереп китә. Рәсим кулына стакан тоттыра. Шешә ачкан кебек хәрәкәт ясый. Рәсимне дә үзе белән уйнарга мәҗбүр итә. Менә алар күренмәгән стаканнарын күтәреп куялар. Икенчесен дә чәкештереп күтәргәч, өченче тапкырын чәкештерми генә эчәләр.)* За погибших братьев.

**Разия.** Ярар, йола икән йола. Шуннан нигә бакчага алып чыга ул аларны? Бәрәңгеләрне таптап кына калмыйлар, суырып алып тәрәзәләргә ата башлыйлар. Алмагачларны корыталар! Нигә?

**Хания.** Чичен егетләрен куып җибәрергә телиләр.

**Разия.** Дөрес, туктаусыз, «Смерть чеченцам!» дип улыйлар. Белмим, егетләр ничек түзәләрдер. Алар да бит сугышта янган. Кайберләре сугышта әтисен дә, әнисен дә, абыйсын да югалткан.

**Фәрһад.** Ярый, борчылмагыз, анда мин бүген үк китәм.

**Хания.** Әгәр өлгермәсәң... менә хәзер пычакка-пычак килеп сугышып ятсалар...

Фәрһад. Мин рәискә шалтыраттым. Ул бар нәрсәдән хәбәрдәр.

Мөслимә. Түзегез, балалар! Сез дә чичен егетләре кебек түземле булыгыз!

Линар. Безне атарга дип хөкем чыгардылар, ә без түзәргә тиешме? Фәрһад абыйның түзүе дә җиткән. Хәер, түзсә дә түзмәсә дә, кызы аны хөкем итмәячәк. Кешене гаепләү җиңелрәк бит.

Хания. Әти, ни сөйли ул? Ни булды сезнең арада?

Фәрһад. Ашыкма, кызым, мине дә ашыктырма!..

Линар *(гитараны Рәсимгә суза)*. Таныйсыңмы, Рәсим?

Рәсим. Әйе шул, үзем дә сорамакчы идем, Игорь гитарасы ничек синдә? Игорь бит аны йоклаганда да кочып йоклый иде. Шул гитарасы аркасында чак үлми калды. Разия, сөйләдем бит мин сиңа. Безнең танк колоннасын тар урамда ике яклап кысып грузовиклар белән бикләделәр дә водометлардан бензин сиптерделәр. Аннары гранотометлардан атып танкларны яндырдылар. Без җиргә сикердек. Игорь гитарасын алырга дип кабат танкка менде. Төшеп килгәндә аякларына «калашник»тан очередь бирделәр! *(Гитарага күрсәтә)*. Менә гитарада да пуля эзләре...

Фәрһад. Әнә шул егетегез үз-үзенә кул салды, Рәсим.

Рәсим. Ничек алай? Булмас! Андый түгел ул!

Линар. Фәрһад абый булдырмый торган нәрсә юк ул! Нәрсә кирәк, шуны бирә. Сорамасаң да бирә!

Рәсим. Без Игорьны БТРга утыртып «тизрәк терел» дип озатканда, «мин әле сезнең туегызда биермен» дип кычкырды!

Фәрһад. Аяксыз килеш ничек биесен ул туйда? Аның бит ике аягын да кискән иделәр!

Линар *(кинәт җиргә утыра. Аяклары булмаган кешеләр кебек ике кулында гына йөри башлый. Гәүдәсен дә биегән кешенекедәй итеп як-якка ташлый)*. Новым русским привет! Әйдәгез күңел ачабыз! Типтереп калыйк дөньясында! Ах, сез миңа акча бирәсезмени? Протезга акчам җитми иде, вот молодцы! Мине шушы хәлдә күреп шатландыгызмы? Инде, әйдә, аттырыгыз моннан!

Хания. Бу ява! Саташу! Линар, иң кабәхәт кеше дә әтигә мондый яла яга алмас иде. Аның ягында сез бер гөнаһсызга өзгән гомерләр, сез канга батырган Ичкерия халкы!

Линар. Ә Игорь кем? Попрашайкамы? Проституткамы? Кемгә акча биргәнен дә аңламый башладымы әллә атаң? Аңлый ул аны. Янәсе, менә сез безне җир белән тигезләдегез, ә без сезгә барыбер ярдәм итәбез, чөнки без сезнең кебек берни аңламый торган хайваннар түгел!

Фәрһад. Мин дә кеше! Ике аяксыз япяшь малайны ничек кызганмыйсың? Инде беркемгә дә кирәге калмаган малайга ярдәм итү дә җинаять була башласа...

Линар. Күрдегезме, ничек боргалана карт төлке!..

Фәрһад. Булды, җитәр, Игорьның язуын тыңлат!

Линар. Миңа язу кирәкми! Игорьның тавышы әле дә колагымда яңгырап тора. Безне күргәч ничек шатланган иде. Әле ярый, килдегез, диде. Быть униженным надоело, диде.

Фәрһад. Шулай булгач...

Линар. Ә син кайтыр вакыт җиткәч кенә аңа акча биргәнсең!

Фәрһад. Мария Швецова — солдат аналары комитетыннан килүче,— Игорьның бурычлары күп, диде. Тагын шунсын да бел, үз-үзенә кул салган солдатлардан Игорь егерме беренчесе, диде.

Линар. Безне алдавы кыен булганга шулай ул! Йә син безгә бөтен җир шарын бирәсең, йә өч аршын җир!

Фәрһад. Әкият белән яшисез! Коммунизм әкияте!

Мөслимә. Мин синең әниең, Линар. Аңладым мин сине. Әмма син башкаларны да аңларга тырыш. Аяксыз инвалидка ярдәм иткән кеше хәзергесе көндә иң изге кеше! Кемгә кирәк соң сез, балам?! Бу беткән, дөмеккән илнең җитәкчеләре мәет кортлары гына. Алар сезне тәмугка илтеп тыктылар. Сез анда яндыгыз, көйдегез, кара күмергә калдыгыз! Йә, шуның өчен ни алдыгыз? Алар бит сезне хәтта сугыш ветераннары дип тә таныргы теләмиләр. Янәсе, бернинди сугыш булмаган, ә бандитлар белән качыш-качыш уены уйналган. Шуңа сезгә Ватан сугышы ветераннары ала торган льготалар да каралмаган. Өстәвенә әле сезне эте дә, бете дә гаепли. Кызыл фашистлар сезне — җиңелүчеләр, сатлык җаннар, диләр, дерьмократлар өчен сез — палач!

Хания. Палач дип аларны мин дә әйтәм. Ичкериядәге нәсел-нәсәбе белән корытылган, җире, авыллары белән юк ителгәннәр исеменнән әйтәм. Линарлар шул дәрәслекне белеп торганга акланалар да... Игорьлар шуны белеп торганга үз-үзләрен үтерәләр дә...

Рәсим *(акрын гына килеп Линарның иңенә кулын сала)*. Линар, бәлкем, Игорь язуын миңа да укытырсың?

**Линар кассетаны Рәсимгә суза да болдырга юнәлә. Аннан магнитофонын алып чыга. Рәсим кассетаны магнитофонга куя. Игорь тавышы: «Никто не виноват. Только я. Все из-за Чечни. Я завидую всем, кто погиб там». Барысы да тын торалар. Линар магнитофонны кулына ала.**

Линар. А я завидую Игорю... *(Сугыш авазлары яңгырый башлаган магнитофонын һәм дә гитарасын ала да коттедж ягына юнәлә.)*

**Фәрһад белән Рәсим дә аның артыннан китәләр.**

Мөслимә. Их! Тегеләй барсаң да, юл ябык, болайга китсәң дә, юл юк! Хания, сугыш барыбызның да бәгырьләрен көйдерде. Әмма без бит хатын-кызлар. Әгәр улым теге Игорь кебек үзен-үзе үтерсә, син шатланыр идеңме?

Хания. Дога кылыр идем!

Мөслимә. Дога түгел, дәва кирәк аңа. Улымны алып кайткан елны ук чәчләрем

ап-ак булды. Төнлә шабыр тиргә батып уянып китәм, стена аша мат-перемат ишетәм. Икенче тапкыр уянам, Линар елый-елый «Аллаһ әкбәр!» дип кычкыра.

Хания. Елама, Мөслимә апа, сина хәзер ялгызлыктан котылу кирәк. Чык этигә, кайгыларыгызны бергә күтәрерсез.

Мөслимә. Ә улыма килгән кайгыны кем күтәрешер? Юк, улыма хыянәт итмәм. *(Китә.)*

*Пәрдә*

## Җиденче күренеш

**Шул ук ишегалды. Линар койманың арьягында йөзек эзли.**

Хания *(өйдән чыга)*. Кем ул анда?
Линар. Мин.
Хания. Сабантуйга бармадыңмыни? Ни эзлисең?
Линар. Кичәге көнне.
Хания. Эзләшимме соң?
Линар. Эзләш.
Хания. Өлгермәдем. Әнә, әтиләр сабантуйдан кайттылар. *(Кире өйгә кереп китә.)*

**Фәрһад белән Мөслимә кайтып керә.**

Фәрһад. Ни булды соң сиңа бүген?
Мөслимә. Үз-үземә урын табалмыйм.
Фәрһад. Минем дә күңелем тыныч түгел.
Мөслимә. Элек шушы сабантуйларга барам дип йөрәк әллә ничә көн алдан ашкына башлый иде. Бигрәк тиз картайдым. Һич булмаса оныгым булсын иде.
Хания *(чыга)*. Нишләп бик иртә кайттыгыз?
Мөслимә. Никтер арып торам.
Хания. Чәй кайнады. Чәй эчеп алгач үтәр әле. Әти, бар син дә. *(Мөслимә белән әтисен өйгә кертеп җибәрә дә койма янына килә.)* Кем белән сөйләшәсең?
Линар *(малайны күтәреп Ханиягә күрсәтә.)* Йосиф бу!
Хания. Йосыф диген.
Линар. Түгел. Йосиф... Джугашвили. Нигә куркып калдың?
Хания. Алай батыр булгач, ахырын да әйтеп бетер инде. Бу, сезне кабат Казакъстанга сөрәчәк Йосыф Виссарионович Сталин булачак, диң.
Линар. Ярар, мин шаярттым гына. Бу чыннан да, син әйткәнчә, Йосыф. Атасы Әфганда сугышкан.
Хания *(койма аша үрелеп малайга эндәшә)*. Йосыф, әйдә дуслашабызмы? Ни күрсәтәсең син миңа? Аһ, бу йөзек бит — Абрек йөзеге!
Линар. Йосыф, бир син аны апага! Бир!
Йосыф тавышы. Бирмим. Ул минеке!
Линар. Тукта. Давай алмашабыз. Күрдең. Хәнҗәр бу! Чеченныкы!
Йосыф тавышы. О-о! Бир! Хәнҗәр минеке булсын!
Хания. Йа, хода, хәнҗәрен кайдан алган тагын? Бу бит чыннан да безнең егетләр хәнҗәре! Йосыф, карыйм әле, дустым! Бир әле!
Йосыф тавышы. Юк, бирмим.
Хания. Линар, кайдан алдың син аны? Нишләптер бик таныш...
Линар. Йосыф, бир хәзер үк апага!.. Балдакны түгел, хәнҗәрне!
Йосыф тавышы. Кит. Бирмим! *(Елый ук башлый.)* Ул миңа кирәк!
Хания. Язуын гына укыйм да бирәм!
Йосыф тавышы. Укыма!
Линар *(хәнҗәрне малайдан тартып алып Ханиягә бирә. Малай елый-елый йөгереп китә)*. Мә, тот! *(Койма аша ишегалдына сикерә.)*
Хания. Вайнах теленДә язылган. Ничек соң бу алай? «Хания» дигән! Бу бит минем исемем. «Сун һо еза! Абрек!» *(Өзгәләнеп кычкыра.)* Абрек! Һо сун дукъ вез! Әйе, мин дә сине ярата идем! Әйт, кем башыңа житте? *(Хәнҗәрне сабый баладай тибрәтә.)* Нигә син хуҗаңны саклый алмадың? Кайда синең хуҗаң? Нинди хәйлә белән жиңделәр алар сезне? Абрек, кем кулыннан шәһит киттең? *(Линарга.)* Линар, әйт, кем син? Палачмы? Әллә мародер гынамы? Кайда үлеп ята иде ул минем Абрегым?
Линар *(горур карап ала)*. Ялгышма, Хания, мин мародер түгел.
Хания. Димәк, үтерүче?
Линар. Әйе, мин үтерүче!
Хания. Тукта! Әйтеп бетер! Абрекны да син үтердеңме?
Линар. Мин! *(Ханияга аркасы белән борыла.)*
Хания *(елан чаккандай кычкырып җибәрә)*. Кара миңа! Күзләремә кара, палач! *(Линар борылмагач, үзе аның карашына чыгып баса да хәнҗәрен Линарның күкрәгенә батыра.)*
Линар. Рәхмәт, Хания! *(Акрын гына җиргә чүгә башлый.)* Коткардың, мең рәхмәт! Мин дә цоны һа еза! Ходай тәгаләгә сәламеңне җиткерермен! *(Чалкан килеп төшә.)*
Хания. Үтердем, Линарны үтердем! *(Кычкыра.)* Мин үтерүче!

**Барысы да йөгерешеп чыгалар. Сабантуйдан Рәсим белән Разия да кайтып керә.**

Мөслимә. Ни булды монда? Аһ, балакаем! Харaплар гына булган!
Хания. Аны мин үтердем!
Мөслимә. Сугышлардан исән чыктың, улым... үз өеңдә үлдең... *(Линар өстенә каплана.)*
Фәрһад. Кызым, нинди хәнҗәр ул кулыңда, бир миңа!
Хания. Бирә алмыйм. Ул Абрекныкы! Минем Абрегым Линар кулыннан шәһит киткән.
Рәсим. Ни сөйлисең син? Шаштыңмы әллә? Ялган бу, чеп-чи ялган!
Хания. Үзе әйтте.
Рәсим. Разия, әйт апаңа, син бит хәнҗәрне күрдең...
Разия. Әйе, апа, мин бу хәнҗәрне Романда күрдем.
Фәрһад. Соң, Романда күргән хәнҗәрегез ничек Линар кулына килеп кергән?
Рәсим. Бүләк иткәндер. Мөгаен шулайдыр. Роман юмарт ул.
Мөслимә. Кызым, Хания, ник үтердең син минем улымны? Мин бит синнән аны

кабат кеше итәргә булыш дип сорадым. Син бит аңа ярдәм итә ала идең. Савап урынына өстеңә тау кадәрле гөнаһ алдың! Бел, кызым, син минем улымны гына түгел, син мине дә үтердең!

Фәрһад. Мөслимә, гаепнең зурысы миндә. Мине карга. Миңа монда кайтмаска иде. Ә мин, карт җүләр, ике баламны да туган җиргә, туган илгә дип алып кайттым.

Мөслимә. Гаепләргә соң шул инде. Линар улым кайтып булмый торган җиргә китеп барды.

Хания. Линар, ходай шаһит, мин инде сине аңлый башлаган идем. Йөрәгемдә сиңа дуслык хисе дә уянган иде. Нигә соң син үлемне үзең сорап алдың? Мин гаепле, әмма син дә гаепсез түгел.

Рәсим. Линарны монда яткырмыйк.

Разия. Тимәгез!

Хания. Ярый, Линар, мине дә көт... мин соңламам! *(Китә.)*

Рәсим. Фәрһад абый, булыш әле. Әнә анда кечкенә малай йөри!

Разия. Аңа кагылырга ярамый! Ярамый! *(Яулыгын салып Линарны каплый.)*

Мөслимә. Кирәгеннән артык яраттым шул мин сине, балам! Ходай үзе көнләшерлек итеп яраттым.

Разия. Ходайга тел тидермә, Мөслимә апа. Әйдә җиңеллек телик.

**Чүгәләп дога кыла башлыйлар. Коттедж янында ап-ак киемле Хания күренә. Кулында хәнҗәр.**

Хания. Әти! Разия! Мөслимә апа! Рәсим! Бәхил булыгыз! Мин Линар янына күчәм. Безне бергә җирләгез!

**Барысы да сискәнеп сикереп торалар. Кайдадыр ерак-еракта чиченнәрнең зикер әйтүләре ишетелгән кебек була.**

Рәсим *(шыпырт кына)*. Күрәсезме? Хания кулында Абрек хәнҗәре!

Разия. Апа, бәгърем, кирәкми! Ходайга каршы барасың! Үз-үзеңә кул салу бик зур җинаять!

**Разия белән Рәсим Хания ягына йөгерәләр. Ут сүнә. Караңгылыкта мулланың җеназа чыкканда укыла торган догасы ишетелә. Күк йөзендә ай калкып чыга. Саран ай яктысы Фәрһад белән Мөслимәнең йөзләрен яктырта.**

Фәрһад. Үлгәннәр артыннан үлеп булмый, Мөслимә. Аллаһ хозурына барырга кайчан да өлгерербез. Синең улың шәһит китте, ә минем кызым бик зур гөнаһ алып китте. Шуңа да ходайдан ялварам, минем үлемемне азга гына булса да кичектерсәче, сәдакалар бирәсем, изгелекләр кыласым бар. Бәлкем, кызымның гөнаһысын җиңеләйтермен.

Мөслимә. Әле синең икенче кызың да бар, Фәрһад абый.

Фәрһад. Минем кызым булса, синең дә кайгыртыр кешең бар бит, Мөслимә. Әнә күр! Улыңның иң якын дусты Рәсим бар. Ул да бер ятим!

**Яктылык Рәсим белән Разияга күчә.**

Рәсим. Разия, гел уйда син. Ни булса да әйт инде.

Разия. Кем уйлаган шушы каһәр суккан сугыш безне Татарстан җирендә дә эзләп табар дип...

Рәсим. Мөслимә апа — бер кызганыч, Фәрһад абый — ике кызганыч. Синең өчен дә үзәкләр өзелеп куя. Бу сугыш безне әллә шулай гомер буе эзәрлекләр микән?

Разия. Сугышларның барысы да шулай... Чичән җирендәге сугыш иң-иң яманы булды!

**Яшьләр янына кечкенә Йосыф килеп баса. Алга сузылган кулын ача. Учында йөзек.**

Йосыф. Менә алыгыз!

Рәсим. Нәрсә соң ул?

Йосыф. Йөзек.

Разия. Йөзек?

Йосыф. Әйе, Абрек йөзеге!

Разия. Син аны кайдан алдың?

Йосыф. Линар абый бирде.

Рәсим. Тәки тапкан икән, Йосыф, бир аны монда. Беркем дә табалмаслык җиргә ташлыйк әле шуны!

Разия. Юк, Рәсим, ташлама! Хатирә булып саклансын! Фаҗига онытылса, ул кабат әйләнеп кайта!

Рәсим. Мә алайса, сакла! Кайтмасын да, кабатланмасын да! Шулай бит, энекәш!

Йосыф. Линар абый кайда? Мин аны бик сагындым!

Рәсим. Без дә сагындык аны, Йосыф!

Йосыф. Хания апаны да яратам мин. Миңа хәнҗәр кирәкми!

Рәсим. Безгә дә кирәкми ул, Йосыф! *(Йосыфны кочагына кыса.)*

*Пәрдә.*

# ШИГЪРИЯТ



## Ямаш Игәнәй

### СОҢГЫ ШИГЫРЬЛӘРЕННӘН

* * *

*Арпаң-көрпәң ач булсын,*
*Тамагыңа таш торсын!..*
Борынгы әйтемнән.

Җәлләди Дәүләт башыңны
Ашый бит, ашый бакчы!
Тән генә түгел, җаныңа
Тешләрен батырмакчы...

Сөяк бул, үтмә тамактан,
Күрсәт Җан, кодрәт көчең!..
...Яшенташка әүрелгән үч
Сындырган Залим тешен...

* * *

Авылның сау әле табигате,
Җире-суы түгел әле хаста.
Яшәү олы бәхет, сагынып-җирсеп
Хет бер кайту өчен туган якка,
Яшәү — бәхет, и Җир, шушы хакка!..

Җире-суы түгел әле хаста:
Күкрәкләрне киереп, монда шөкер,
Рәхәтләнеп сулыш алып була.

---

Ямаш ИГӘНӘЙ (Ананий Несторович Малов) — *«Сәфәр чыгам», «Йолдыз булып ян», «Хәзинәләр иле» һ. б. шигырь, публицистика китаплары авторы. Ул 1938 елда Сарман районы Ләке авылында туган; Чаллыда яшәде, 1997 елның язында вафат булды.*

Үпкә, жанга корым-сөрем түгел,
Яңа сауган сөттәй һава тула!..

Гади кешеләре арасында
Бар шагыйрьләр, галим, философлар.
Табигатьнең үзе кебек бөек,
Самими һәм гали асыл затлар,
Бик арттырмыйм бугай, авылдашлар?..

Сөйли белмәсә дә трибунадан,
Язмаса да гыйльми трактатлар,
Иген игә. Туган тел сафлыгын
Җуймас, мәңге гүзәл килеш саклар,
Килер буыннарга бары алар...

Балкып ята монда ачылмаган
Асыл хәзинәдәй гадәт-йола.
Һәр яңа көн — язылмаган роман,
Күңел күзең салып укы гына!..
...Авылның сау әле табигате...

## Зиначы монологы

Яктыга — дан! — диеп сөрән салабыз,
Караңгыда рәхәт чигеп калабыз.
Берәрсе шәм генә кабызсын әле —
Уңлы-суллы яңагына чабабыз!..

* * *

Һәр нурдан җиде төрле төс
Асылташ кайтара, имеш...
Җиде мәгънә һәрбер төсмер —
Аңлата шигырь-шедевр...

## Барыбер Таң атар

— Кайда синең изгең —
Кайда нигезең, татар?
— Изге нигезем Болгар,
Җимерделәр ятлар...

— Кайда газиз Илең,
Кайда Туган телең?
Көнгәме тиң төнең,
Төнгәме тиң көнең?..

— Җимереп, чәчеп-түгеп
Бетерсә дә ятлар,
Җаным-рухым тар-мар
Итәлмәде алар.

Исән-имин калды,
Чын фидакарь җаннар.
Ден-иманын хаклар,
Яклар асыл затлар.

— Иртәгәндә, хакмы,
Нур чагыла, татар?
— Төн — мәңгелек түгел,
Барыбер Таң атар!..

* * *

Мәңгелектән илаһи моң иңә,
Чаң авазы булып җанга дәшә:
«Бу дөньяга Иман белән килдең,
Иман белән берүк, Кешем, яшә!

Авызың ач һәрчак Иман белән,
Иман китермичә бер сүз дәшмә.
Илаһи нур иңдер күңелләргә,
Җакты Кояш булып Җирдә җәшнә!..»

Мәңгелектән якты аваз килә,
Изге Иман булып, җыру булып:
«Изге булсын Кешем, һәр исәбең».

Илаһи Нур булып күңелемә
Мәңгелектән изге Аваз иңә:
«Ходаеңнан алган игелекне
Тарата күр, Кешем, син дә җиргә!..»

Илаһи Ут Җанда саумы, Кешем,
Савап булып иңәрлекме Көчең?
Уең Изге, Ару, Таза икән —
Имлә бу Дөньяның бозык төшен!..»

## Карендәшкә

*Җир йөзендә купме керәшен бар,*
*Илдә-көндә купме исәбе?*
*Кем әйтәлә, нәсел-нәсәбенең*
*Сау-тазамы тамыры, үзәге?..*

Карлы-бозлы яңгыр, заман җиле
Бәгыреңне өтеп исәме?
Яман телләр җанга салган яра
Үзәгеңне, әрнеп, өзәме?

Ирек ачып бер утырыйк әле,
Эчең бушар, зарың сөйләрсең.
Синдәй эчкерсез зат бүтән юк бит,
Карендәшем, асыл керәшен.

Инде ару гына яшә берүк,
Келәүләрең кирләп китмәсен.

Имәндәй нык, таза нәсәбеңнең
Бөреләрен кырау өтмәсен.

Илдә-көндә күпме керәшен бар —
Беркем белми төгәл исәбен.
...Керәшенгә көн килерме бер, дип,
Өзгәләнә бары үзәгем...

## Ходайга инәлү

Бу дөньяның фани һәрбер минутында
Тау кадәрле язык кыла адәм заты.
Син бит аны Бәхет өчен ераткансың,
Инде берүк языкларын ярлыкачы.

Ил башында торгач явыз, залим җаннар,
Бозыклыкка батты тоташ бар дөньясы.
Тый аларны явызлыктан, азгынлыктан,
Бу җир йөзен көл-күмергә калдырганчы!..

## Аллам, дисәң...

Аллам диген, Аллам, дисәң —
Яктырып китәр бар Җаның.
Һәм языклардан арынып,
Сафланыр Рухың, Вөҗданың.

Аллам диген, Аллам, дисәң —
Куәт иңәр Җанга изге.
Күңелеңнән гел кабатлап
Тор иң олы шушы сүзне

Аллам, диген, Аллам, дисәң —
Булыр Ул һәрчак Җаныңда.
Уең, эшең изге итәр,
Кичерер языкларың да...

Аллам, диген, и ярлыка,
Кылган бөтен гөнаһымны.
Кабул итче, чын күңелдән
Китергән бу Иманымны.

Юлым якты, кылганнарым
Гел игелек булса иде.
Шул игелек һәрбер Җанга
Мөлдерәмә тулса иде.

И Ходаем, кыласымны
Гел изгелек язсаң иде.
Иман белән торсам иде,
Иман белән ятсам иде...

Илаһи Зат, мәңге шулай
Гел Җанымда торсаң иде.
Изге эшкә куәт биреп,
Яманлыктан тыйсаң иде...

* * *

Суга баксаң — мәңгелекне күреп була,
Мәңгелек дип, бәхетеңне салма суга...

## Уртак сер...


И төнем! Олы әманәт
Тапшырдым куеныңа:
Бер сылуның сөю серен
Ачканын ничек миңа.

Әй, татыдык ул сөюнең
Тылсымлы серен, назын!
Һәм сиңа, сердәш буларак,
Яшердек аның барын...

Нык ышанам, аны мәңге,
Беркемгә дә ачмассың.
Чөнки бар ич бу «гөнаһта»
Үзеңнең дә катнашың...

Син үзең бит ят күзләрдән
Яшереп тордың безне.
Шулай булгач, әйт, ни файда,
Ачудан уртак серне?..

И төнем! Олы әманәт
Яшердем куеныңа.
Сылу хакына, ачмаска,
Вәгъдә ит, зинһар, миңа...



Әхәт Сафиуллин

# ҮКЕНҮ

хикәя

Бүген март кояшы иртәдән үк хәйран кыздыра иде, шуңа күрә аңа туры карау да мөмкин түгел — күзләр камаша. Хәтта чана эзләре дә ялтырап тора. Әйтерсең, аны кемдер беләү белән ышкып шомарткан. Тик юл уртасындагы тапталган кар гына шикәр комы сыман ярмаланып калган. Авыл читендәге иксез-чиксез җәелеп яткан күз камаштыргыч ап-ак карларда да, инде урыны-урыны белән эреп, каралып калган тау башларында да үзенә бертөрле ниндидер тантаналы моңсулык бардыр кебек тоела. Тирә-яктагы һәр нәрсәдән, хәтта һаваның үзеннән дә яз исе килә!

Авыл эченнән икәү атлый. Берсе — талчыбыгы шикелле төз буйлы, унбиш-уналты яшьләрдәгесе, авыл җирендә яшәүче һәр бала кебек үк, бик тере, бик җанлы малай. Тик бүгенге күңелсез йомыш кына аның бөтен халәтенә, бөтен тән-тамырына кадәр сеңгән иде бугай — бүген ул да шаянлыгын, җорлыгын югалтып, сабыр иңгән картлардай, сүзсез генә атлый. Чыннан да, гомер белмәгән-күрмәгән, әллә кайдан килеп чыккан ниндидер кешегә әниеңнең бертуган сеңлесе каберен күрсәтергә дип бар әле син!.. Уен-көлке эшмени?! Кино яисә концерт карарга клубка барулары булса бер хәл иде. Ә монда... Инде ничә еллар элек гүр иясе булган Алмапасының каберен күрергә дип зиратка барулары. Әлбәттә, бүгенге кебек ялтырап торган кояшлы көндә дә ялгызы гына барып йөрмәс иде ул монда: ни әйтсәң дә, аяк тарта торган җир түгел.

«Гаҗәп, бу чит-ят кешегә нигә кирәк булды икән Алмапаның кабере?! Алай кирәк булгач, нишләп элегрәк килмәгән? Ә нишләп күмәргә кайтмаган? Хәзер кабер кирәк булган аңа! — дип, ниндидер бер үпкә белән уйлап алды бер-ике адым алда атлаган малай. — Сигез елдан соң исенә төшкән!.. Белмим, элек ни карагандыр... Таныш булса да бер хәл ие. Бөтенләй ишетмәгән-күрмәгән бәндә бит. Хәер, туктале! Әнине белә икән лә бит ул! Өйгә килеп кергәч: «Исәнме, Таһирә апа!» — дип килеп күреште ич. Әйе, әнигә исеме белән дәште. Әни дә аны таныды түгелме соң?! Таныды шул! Дөрес, бик озак карап торганнан соң гына — алай да таныды. Хәтта исеме белән әйтте бит! Ничек диде әле ул бу абыйга? Әйе, Мөхәммәтнур энем, дип дәште. Танышгач, нигәдер күзеннән яшь чыкты, елап алды. Аңламассың бу олыларны, валлаһи. Кешегә карап-карап тор да, танышгач кына елап җибәр, имеш. Димәк?.. Димәк, бу Мөхәммәтнур абый дигәннәре әнине генә түгел, Алмапаны да белгән?! Ә нишләп соң ул... Әй, аңламассың аларны! Әллә нәрсәләр беләләр, әллә нинди серләре бар...»

Вәгыйз исемле шушы малай артыннан салмак кына атлаучы, инде чәченә чал кергән, аяк атлавында, бөтен хәрәкәтендә сабырлык сизелгән, шул ук вакытта нindидер бер билгесез көч әйдәвенә бирелеп алга ашкынган Мөхәммәтнурның тинтерәп калган башында үз уйлары иде. «И-и гомер! Нинди катлаулы нәрсә син, гомер!..— дип әсәрләнде аның күңеле. Бу минутларда «гомер» төшенчәсе аның өчен шулкадәр чиксез, шулкадәр зур мәгънәгә ия иде ки: хәтта күзенә яшьләр бәреп чыкты һәм ул, үзенең болай туарылып китүеннән оялып, тиз генә кесәсеннән кульяулыгын чыгарды да, битен сыпыргандай итенеп, аларны тиз генә сөртеп алды.— Нигә шул тамаша катлаулы икән син, гомер? Нигә һаман үзеңнекен итәсең? Нигә синең кануннарың үзең өчен генә язылган да, ник алар безнең уй-теләкләрне, хыялларны искә алмый? И-и гомер... И-и тормыш...»

Ул тагын ни әйтергә, гомер-тормышка булган зур үпкәсен нинди сүзләр белән җиткерергә белми туктап калды. Аның бу соңгы сүзләрендә ничәмә-ничә еллар буе күңелен-җанын борчыган, аңа тынгы бирмәгән, аның җанын ашап килгән моң-зары да, үкенү һәм офтанулар да чагыла кебек иде. Аңлатып та бирә алмаслык нindидер көчсезлек, ирексездән язмыш ирке белән килешү дә бар иде аларда. Бу сүзләрдә нindидер ачыну да, гомернең инде теләсәң дә мәңге кире кайтарып булмаслык хәлләре, мизгелләре өчен офтану да бар иде шикелле.

Авыр уйларыннан арыну өченме, әллә инде сабырсызлыгы хәттин ашкан идеме, Мөхәммәтнур, айнып киткәндәй, нигәдер калтыраган, карлыгып калган тавышы белән, ләкин нык булырга тырышып:

— Еракмы әле, Вәгыйз энем?— дип сорады.

— Юк, ерак калмады инде,— дип җавап кайтарды малай.

Чыннан да, күп тә үтмәде, авылдан чыктылар да, шундук өстәрәк, авылдан әллә ни ерак булмаган бер калкулыктагы зират та күренде. Дөресрәге, коймa белән әйләндереп алынган кечкенә бер урман иде ул. Әлбәттә, аның зират икәнен Мөхәммәтнур тиз төсмерләп алды. Шуны күрүгә бөтен тәне көчсезләнеп, нигәдер калтыранып куйды. Гәрчә инде менә шушында ничә еллар буе омтылып, бу очрашуны зарыгып көтсә дә, менә хәзер, инде менә-менә килеп җитәбез дигәндә генә әллә нишләп каушап, хәтта куркып калды бугай ул. Әйтерсең, менә шушы зиратны, андагы үзе өчен кадерле, изге булган таучыкны күрергә ничә еллар буе омтылмаган да, шушында килүне соңгы гомеренең иң зур максатларының берсе итеп куймаган!..

Мөхәммәтнур кинәт кенә тамак төбенә килеп тыгылган төерне авырлык белән генә йотып җибәрә алды. Әйтерсең, инде әллә ни гомер күрмәгән танышы белән очрашырга җыена, үзе дә аңламаган хәрәкәтләр белән муенындагы галстугын, пальто якасын рәтләп куйгандай итенде, ирексездән адымын тизләтте, кинәт бөтен тәненә нindидер салкын тир бәреп чыкты.

Ниһаять, менә килеп тә җиттеләр. Юлдан читкә борылып, карга бата-чума зират эченә атладылар.

— Алмапаның кабере өстендә шомырт агачы үсә,— диде алдан атлаган Вәгыйз бу авыр тынлыкны бозарга теләп бугай. Болай берсүзсез баруы кыен иде аңа.— Язын шундый матур чәчәк ата ул шомырт!

— Кем утыртты?— дип сорады Мөхәммәтнур, бераз атлый торгач. Анысы да сөйләшмичә барудан уңайсызланып кына бугай, чөнки менә хәзер, менә шушы минутта аның өчен моның бер генә дә әһәмияте юк иде. Уе бөтенләй анда түгел. Хәзер нәрсә инде, кем утыртса да барыбер түгелмени?

— Әти белән әни утыртты,— диде малай һәм өстәп куярга кирәк дип санады бугай:— Абый белән без дә шундаек.

Беравык дәшми генә бардылар. Һәм кинәт Вәгыйз, бик озак эзләгән нәрсәсен тапкандай, нindидер бер басымчак тавыш белән:

— Менә ул! Менә Алмапаның кабере! — дип куйды. Алай да бу тавышта сөенү-шатланудан бигрәк сагыш күбрәк иде шикелле.— Менә нинди матур аның шомырты! Чәчәк аткач, яфраклары да күренми — гел ап-ак чәчәк!

Мөхәммәтнур бу сүзләрне ишетмәде дә бугай. Кабер өстенә менә шулай кинәт кенә килеп чыгуларын көтмәгән идеме ул, әллә инде күп еллар ахырында бер генә тапкыр булса да шушында килеп китәргә омтылышының менә шулай кинәт кенә тормышка ашырылуыннан каушап калдымы, әллә Флюра белән бу очрашуы бөтенләй икенче төрле, бөтенләй башкача булыр дип уйлаган идеме, Мөхәммәтнур — берьялгызы урманда адашып калган кешедәй, аптырап, гаҗиз булып, башына авыр күсәк белән китереп суккан шикелле тинтерәп, кисәк кенә туктап калды. Бер аягын атлаган, ә икенчесе әле карга батып калган килеш иде. Нигәдер тирә-ягына каранып алды һәм күзе кабер өстендә үсеп утырган шомыртка төште. Чыннан да, бик җыйнак, шул ук вакытта учарлы, матур гына агач иде ул. Үзе агачка карады, үзе ачылыр-ачылмас иреннәре белән: «Исәнме, Флюра! Исәнме, бәгырем!» — дип пышылдады. Һәм шул ук секундта, сүзләрен Вәгыйз ишетмиме дип куркып бугай, уңайсызланып, тиз генә аңа карап алды. Юк, юк, малай берни дә ишетмәгән, аның гаме бөтенләй башкада иде — Алмапасының каберенә карап тын калган. Мөхәммәтнур тынычлана төште һәм кабер янына ук атлап, куллары белән инде бераз эреп кар астыннан чыккан салкын, юеш җиргә кагылды...

«Килдем мин, Флюра,— дип пышылдады ул эченнән, җирнең салкынлыгын да тоймыйча.— Соңарып булса да гафу үтенергә килдем мин сиңа, Флюра! Син гафу итмичә яшәве авыр миңа, авыр, Флюра...»

Мөхәммәтнур яңадан малай ягына табан күз ташлады. Уйларын, хисләрен сизмиме, әйткәннәрен ишетмиме, янәсе. Юк, булмый бу болай, шикләнә-шикләнә ничек сөйләшсен ул Флюрасы белән?! Менә шушылай курка-курка пышылдашырга гына килдемени ул монда?! Ничә еллар буе җыенып килгән икән, рәхәтләнеп сөйләшеп утырасы иде бер... Ул үзе белә ич: моннан соң ул монда бүтән беркайчан да килә алмаячак. Беркайчан да! Бу юлы да авылларына кайткан җирдән генә килде...

— Наным, бар, син кайта тор! Мин калам әле,— диде ул малайга.

— Әни аннары сезне безгә апкайтырга кушты ич! — диде Вәгыйз, аның бу сүзләренә каршы.— Бергә кайтырбыз инде.

— Юк, син бар... Хәзер мин дә кайтып җитәм. Миңа үземә генә калырга кирәк әле...

Малай, кирәк икән, кала бир дигәндәй, иңнәрен җыерып куйды да, чак кына урынында таптанып торганнан соң, кергән эзләренә баса-баса кайту юлына борылды. «Миңа үземә генә калырга кирәк» дигән сүзләр кузгатты бугай аны. Алай да, ун-унбиш адым атлагач, артына борылып:

— Сез соңга калмагыз инде, абый, әни аш пешереп көтеп торачак,— диде дә борынын тартып куйды һәм юлында булды. Бик тиз генә зират капкасына җитеп, күздән дә югалды. Мөгаен, ул үзе өчен җиңел булмаган бу күңелсез эшне өстеннән алуларына чиксез шат иде. Нишлисең, бала ич әле ул.

Мөхәммәтнур кабер белән икәүдән-икәү генә калгач, башта моңа сөенергәме, юкмы икәнен дә белмәде. Бәлки, ул аны ир туганы алдында тизрәк кичерер иде?..

«Исәнме, саумы, Флюра! — диде ул, ике кулы белән салкын кабер өстен сыйпый-сыйпый. Тик үзенең кайда утыруын, ни өчен килүен хәтерләп бугай, кинәт айнып киткәндәй булды.— Йә хода, ни сөйлим соң мин?! — дип үз-үзен ачуланып куйды.— Нинди саулык, нинди исәнлек турында сорыйм соң мин инде сигез ел шушында яткан кешедән?! Аның саулыгы турында авырып Казан больницасында яткан чагында сорарга кирәк иде! Элегрәк сорарга иде бу турыда, элегрәк! Ә син ничә елдан соң гына: «Исәнме-саумы, Флюра!» — Әйтерсең, менә хәзер

язгы кояш нурлары астында аз-азлап кына кардан арына барган шушы кабер янында ике Мөхәммәтнур утыра иде.— Ләкин мин синең авыруың турында да, больницада ятуыңны да белмәдем бит, Флюра, валлаһи, белмәдем!..— дип акланды чал чәчле Мөхәммәтнурның берсе.— Әгәр алдасам, менә шушында җир йотсын! Әгәр Казанда икәнеңне белсәм, килми калыр идеммени мин янына, ә, Флюра? Үзең беләсең ич син: килү хәбәрең булуга бөтен эшне ташлап чаба идем бит янына. Йә, әйт, беләсең бит, беләсең? — Кинәт бу Мөхәммәтнурның күзләреннән эре-эре яшьләр тәгәрәде.— Иң соңгы очрашуыбызны хәтерлисеңдер ич син, ә, Флюра?»

«Барысына да әнә шул очрашу сәбәп булды да инде...— дип авырткан җиргә төрттерде икенче Мөхәммәтнур.— Шул очрашу кеше шикелле генә бетсә, араны бозган теге хат та булмый иде...»

«Дөрес анысы,— дип аның белән килеште беренче Мөхәммәтнур.— Ара шуннан бозылды бугай шул. Соңгы очрашуыбыз булды ул. Иң соңгысы...»

«Ә бит барысына да синең хатың гаепле, хатың,— дип үзенекен итте икенче Мөхәммәтнур.— Хәер, хат нәрсә ул... Хат — сүз язылган кәгазь генә. Монда хатның бер тиенлек тә гаебе юк. Гаеп — синең үзеңдә! Арагызны кылыч белән кискәндәй өзгән ул хатны син яздың бит. Үз кулларың белән яздың! Курыктың!! Син аңа хыянәт иттең! Язмаска иде сиңа ул хатны, ассалар да, киссәләр дә язмаска иде!.. Ир булып кала алмадың!..»

«Әйтүе генә ансат...— диде беренче Мөхәммәтнур, күз яшьләрен сөртеп.— Мин бит гаиләне саклап калу өчен... Балалар хакына... Үзебезнең хакка!..»

«Ә-ә шулаймы, балалар хакынамы? Гаиләне саклап калыр өченме? — дип усал көлде икенче Мөхәммәтнур.— Алай булгач, бу турыда алданрак уйларга кирәк түгел идеме? Нигә очрашуларыгызны дәвам иттегез соң?! Ул бит кияүгә сиңа түгел, ә башкага чыкты! Горур булырга кирәк иде сиңа. Берәү булса, мондый хәлдән соң аның белән яшерен очрашу түгел, күргән чакта сәлам дә бирмәс иде! Ә син... Аннары барысын үзең үк боздың да...»

«Мин аны өзелеп ярата идем шул. Бик яраттым мин аны! — дип өзгәләнде Мөхәммәтнурларның беренчесе, акланырга тырышкандай.— Хәер, моны аңлавы авыр сиңа... Сөюнең ни икәнен үз башыннан кичергән кеше генә аңлый моны. Әйдә, бетерик бу әйткәләшүне. Аның өчен килмәдем мин монда! Үткәннәрне актарып, нигә ярага тоз сибәргә?! Мин бит кайчан һәм кайда ялгышканлыгымны үзем дә аңлыйм хәзер... Ләкин моннан ни файда? Ул кичерсә генә җан тынычлыгы табачакмын мин. Шуның өчен килдем мин монда...»

Инде көндезге кояш шактый ук кыздыра иде. Мөхәммәтнур як-ягына күз төшерде. Әйе, зиратта. Флюра кабере өстендә бит ул! Мөхәммәтнур айнып китте, янәдән кабергә текәлде. Кояш кабер өстендәге кар читләрен челтәрли-челтәрли гаҗәеп бизәкләр ясаган. Шушы гаҗәеп бизәкләрдән, күз яшьләре сыман, тып-тып итеп, кабер өстенә язгы тамчылар тама. Нәкъ күз яшьләре! Тик кем яшьләре алар? Кемнекеләр?.. Тып-тып, тып-тып...

«Кем уйлаган бит, кем уйлаган!..— диде Мөхәммәтнур, йөрәген өзгәләп инде болай да юешләнгән таучык өстенә тамган шул тамчыларга карап.— Вафат хәбәреңне дә биш-алты айдан соң гына, анда да очраклы рәвештә генә ишеттем бит, Флюра».

Тып-тып... Тып-тып... Бу кечкенә генә тамчылар тавышы үзәккә үтә, йөрәген өзгәли, башка бәрә, күңелдә ташкын булып кайный. Күңелдәге бу ташкыннар бер-беренә өелә-өелә һаман үткәннәргә агыла, һаман үткәннәрне хәтерләтә. Нишләп гел үткәннәрне актарып, шулай җанны ашый икән бу тамчылар?!

...Мөхәммәтнур белән Флюра икесе ике авылдан булып, аларның язмыш юллары сигезенче класста укыганда очрашты. Үзләрендә урта мәктәп булмау сәбәпле, икесе дә өченче бер авылга йөреп укыдылар. Шунда танышып, дуслашып киттеләр. Бу дуслык соңыннан мәхәббәткә әйләнде. Унны бетергәч, Флюра Казан сәүдә техникумында, ә Мөхәммәтнур техник училищеда укыды. Алар монда бик еш очрашалар иде һәм инде мәхәббәтләре дә мәңге сүнмәслек булып береккән шикелле тоела иде. Хәтта каникул вакытында Мөхәммәтнурның алар авылына кайтканы да бар иде. (Менә кайдан белә иде аны Флюраның апасы Таһирә).

Укуын тәмамлагач, Мөхәммәтнурны армиягә алдылар, ә Флюра Татарстанның бер районына эшкә китеп барды. Өч ел буена җылы-җылы хатлар алышып тордылар. Дөрес, инде икенче елын хезмәт иткәндә үзенең хатларына җавапларның элеккегә караганда соңаргалап килгәләве генә Мөхәммәтнурны әллә ниткән кайнар утларга салган чаклар да булмады түгел. Күңелдә: «Ә, бәлки, ул анда башканы сөядер? Бәлки, миңа булган хисләре суынырга да өлгергәндер?» кебек ямьсез уйлар давылы да купкалады.

«Сирәк язасың, дип син миңа алай бик ачуланма инде, Мөхәммәтнур җаныем! Эшем дә бик тыгыз чаклар күп, арыла да...» Флюрасының мондый җавапларын укыгач, аның бу күңелсез уйлары тагын юкка чыга.

Армиядән соң да сирәгрәк очрашырга туры килде, чөнки икесе ике җирдә иделәр. Район юлы көн дә кайтып-килеп йөри торган ара түгел. Ярый әле, эше буенча Флюра үзе Казанга еш килгәли, ул чакта күрешмичә калмыйлар иде.

Аннары... Аннары Мөхәммәтнур өчен аңлавы да, хәтта күз алдына китерүе дә авыр булган көтелмәгән хәл килеп чыкты: Флюрасыннан аның кияүгә чыгуы турында хәбәре килде...

Бу ямьсез хәбәрне, бу аерылышуны бик авыр кичерде ул. Тормышының, дөньясының яме бетте сыман булып калды. Шулай булмый соң! Инде өйләнешү турында сөйләшеп йөриләр иде ич! Ай-яй, нинди кырыс чаклары да була икән бу язмыш дигән нәрсәнең!..

«Мин теге вакытта дөрес сизенгәнмен икән бит!..— дип аптырады Мөхәммәтнур бу хәлгә.— Димәк, ул инде шул чакта ук башка берәү белән йөргән... Әй, сукыр да инде мин!»

Ел артыннан еллар үтте. Аннары матур гына бер кызга Мөхәммәтнур да өйләнде. Беренче балалары дөньяга килде, икенчесе... Инде үткәннәр онытылды, яралар төзәлде дип йөргәндә, алар көтмәгәндә Казан урамында очраштылар. Озак кына сөйләшеп тордылар. Шунда, теге вакытта кинәт кенә башкага кияүгә чыгуының сәбәбен сорагач, Флюра:

— Алданган идем мин, Мөхәммәтнур... Арабызга кер кундырдым...— дип ике генә җөмлә белән җавап бирде.

Кайчан? Ничек? Кем алдаган? Нигә соң алдын-артын карап йөрмәгән? Мөхәммәтнур бу турыда сорашмады да, сорашырга теләге дә булмады. Инде хәзер барыбер түгелмени?!

— Мин сине генә чынлап яратканмын икән, Мөхәммәтнур,— диде бераздан Флюра, күз яшен сөртеп.— Һаман сине генә уйлап яшим...

— Соң инде, соң! Син миңа арттан пычак белән кадагандай иттең,— дип көрсенде Мөхәммәтнур.— Синең ирең, минем хатыным бар...

— Беләм мин... Аңлыйм... Алай да гел күрәсем килә. Синнән миңа берни дә кирәкми, күрәсем генә килә. Ә ирем белән без аерылыштык...

Йә хода, инде менә шушы сөйләшүгә дә күпме гомер үтте! Ул чакта...

Ул чакта үзләренең бу очрашуларына эченнән генә булса да Мөхәммәтнур үзе дә сөенде бугай. Әлбәттә, ул моны күрсәтмәде дә, сиздермәде дә. Алай да күңеленең бер почмагында ниндидер җылылык уянды, йөрәге тыпырчынып алды. Әйткәч тә, алдында аның элеккеге сөйгән яры, вакытында аны утларга-суларга салган бәгырь кисәге басып тора ич!

Шушы көннән башлап Мөхәммәтнурга әллә нәрсә булды. Инде сүнеп-сүрелеп беткән элеккеге хисләре яңара төштеме, әллә аның өчен менә

шундый кыска гына очрашу да бетмәс-төкәнмәс бәхет идеме, моны ул үзе дә аңлата алмас иде бугай.

Кыскасы, Флюра Казанга килгән чакларда алар яңадан очрашкалый торган булдылар...

Кем белә, бәлки, Мөхәммәтнурга инде бу өзелгән араны ялгамаска, горурлык, ныклык күрсәтергә, ирлеген итәргә, шундый зур хыянәт иткән, бәгыренә тоз сипкән кешегә әйләнеп тә карамаска кирәк булгандыр? Ләкин әйтүе генә ансат... Дөрес, аның шулай уйлаган чаклары да аз булмады түгел. Бигрәк тә Флюраның бер мәртәбә телефоннан алар фатирына шалтыратуыннан соң...

Шулай беркөн — апендицитына операция ясатып, Мөхәммәтнурның больницадан гына чыккан көне иде — хатыны белән сөйләшә-сөйләшә телевизор алдында утырганда, кинәт бик озын-озын итеп телефоннары шалтырады. Беләләр: шәһәрара телефон иде бу, димәк, кемдер аларга башка җирдән шалтырата. Трубканы хатыны Фәүзия алды. «Әйе, Мөхәммәтнурлар фатиры,— диде ул һәм шундук чырае бозылып, төсе китте.— Мә, сиңа! — диде аннары, трубканы аңа биреп.— Теге нәрсәң...»

Ул эсселе-суыклы булып китте. Алса да алды трубканы, алмаса да.

Шулай итеп, алар аның белән беренче мәртәбә шәһәрара телефоннан сөйләштеләр. Мөхәммәтнурның хатыны алдында!.. Әлбәттә, юк-бар нәрсә турында гына. «Исәнме-саумы? Эшләр ничек? Балалар үсәме?» кебек гомуми сүзләр генә.

Мөхәммәтнур трубканы куеп өлгермәде, күз яшьләренә тыгылып, хатынып елап та җибәрде.

«Тагын ни кирәк булган ул йөгәнсезгә? Монда килгәч очрашуыгыз гына җитмәгән, оялмыйча, инде өйгә үк шалтыраты башлады!.. Туймас нәрсә булыр икән шул тамаша...»

— Фәүзия! Ни сөйлисең син?! — дип йөзен җыерды Мөхәммәтнур.— Нигә тузга язмаганны сөйлисең икән! Нинди очрашу ди?! Нинди йөгәнсезлек?! Беләсең бит: безнең арада хәзер берни дә юк. Минем өчен хәзер ул — бары тик классташым гына. Син үзең хатын-кыз... Нигә кешегә пычрак атасың?

— «Классташ» диеп җүләргә санап йөрмәгез мине! Җүләр түгел мин сезгә. Очрашуыгызны да беләм! Карап-түзеп торам әле: кайчанга тикле дәвам итәрсез икән? Гаҗәпләнәм: нишләп болай йөрергә?! Тотыгыз да өйләнешегез! Үлмәбез әле, алла боерса, яшәрбез ничек булса да... Кара аны, Мөхәммәтнур, балалар белән ант итеп әйтәм — тагын бер генә сүз ишетием бу турыда! Чыгасың да китәсең!! Әйтте диярсең...

Менә шундый авыр сөйләшү булып алган иде ул чакта алар арасында. Каты тузынды хатыны, әй, каты тузынды! Атна буе ачу саклап, кырлы-мырлы гына сөйләшеп йөрде.

Шул чакта Мөхәммәтнур бу турыда беренче мәртәбә бик нык уйланды бугай. Бер караганда, чыннан да, кая алып барыр аларның Флюра белән бу мөнәсәбәтләре? Шунысы кызык: беренче булып ул аны ташлады бит, ул!.. Димәк, аннан да яратыбрак йөргән башка кешесе булган Флюраның? Кем белә, бәлки, Флюра инде аны кияүгә чыкканчы ук, әйтик, ул армиядә хезмәт иткәндә үк алдалап йөргәндер? Моңа каршы кем ышанычлы итеп: «Юк!» дип әйтә ала? Беркем дә! Бу нәрсә бары тик Флюра намусында гына, моны тик ул гына, ул гына белә. Юк, бетерергә кирәк бу көрешү, очрашуларны. Яхшыга илтмәс болар! Аннан соң, тирәнрәк уйлап карасаң, хәзер моннан ни файда? Ул — иреннән аерылган инде, ә мин — хатынымнан аерылышып, өйләнешәчәкбезме? Юк, әлбәттә! Белмим, Флюраның уй-теләкләре ничектер, монысы минем өчен караңгы, ә үзем гомердә дә андый адым ясаячак түгелмен бит. Инде бер мәртәбә хыянәт иткән кеше хакына гаиләмне, балаларымны сатаммы соң! Аларны ятим калдыраммы?! Юк һәм юк! Беркайчан да!!

Менә бу телефоннан шалтырату кемгә һәм ни өчен, нигә кирәк булды тагын?! Ни өчен шалтыратты Флюра? Безнең номерны каян белгән?

Хәер, анысы гаҗәп тә түгел. Телефон белешмәсендә дә бар ич ул. Эш анда түгел. Өйгә шалтыратырга ничек батырчылык иткән? Кизү торганда эч пошудан гынамы, әллә моның минем баш җитмәслек башка бер астыртын сәбәбе бармы? Белмәссең...

Ничек кенә булмасын, бу юлы Мөхәммәтнурның бик ачуы килде. Бүтән аның белән очрашмаска, сөйләшмәскә үз-үзенә сүз бирде. Ләкин «Вакыт бар яраны да төзәтә», дип юкка гына әйтмиләр, күрәсең...

Инде яралар төзәлде, барысы да онытылды дип йөргәндә генә ниндидер семинарга дип Казанга килүе турындагы хәбәрне ишертен генә ирештергәч, Мөхәммәтнурның йөрәге тагын тузынып-җилкенеп куйды, әллә нишләп китте ул. Бер яктан, шушы хәбәрне ишетүгә үк, кырык эшен кырык якка ташлап, яшьлегенә, Флюрасы янына йөгерергә теләде. Ләкин шул ук вакытта бу мәсьәләгә инде тулы ачыклык кертелеп, «Бармаска! Йөрмәскә! Очрашмаска!» дигән сүзләр дә бар. Нишләргә соң, нишләргә? Бармаска!? Әлбәттә, бармаска! Ни калган ди аңа анда? Килгән икән, семинары беткәч, китәр дә барыр! Мине бала-чагага санамасын! Җитте! Күпкә китте бугай бу эш!

Мөхәммәтнур бер сәгать сүзендә торды, ике сәгать, бер көн түзде, бер төн түзде... Ә икенче көнне... эштән соң берниндн сүзен дә тыңларга теләмәгән аяклары аны ирексездән Флюрасы янына алып килделәр. «Күреш, бер-берегезгә карашып кына алырсыз да кайтырсың,— дип тукыды аңа миенең ниндидер бер ноктасы.— Ир була бел, курыкма! Хатының белми дә калыр. Әллә нигә бер шундый бәхет тәтегәндә — нигә файдаланмаска?! Күреп торам, сизәм бит: барыбер түзә алмаячаксың. Азапланма, йөгер, кош булып оч! Элеккеге шикелле, чәчләреннән сыйпа, коңгырт күзләренә кара!..»

Мөхәммәтнурның калганын хәтерлисе дә килми...

Шул барудан, кунып, өенә икенче көнне генә кайтты ул. Кайтса, өендә — кыямәт көне! Дулый хатыны — чыдар хәл юк. «Теге нәрсәң белән күрештегезме? Кара син аларга! Күрешү генә аз аларга... Инде кунып-төнеп ятырга кирәк! Рәхәтләндегез бугай, оятсызлар! Син, җүләр, шуны аңламыйсың: җүнле хатын булса, кеше ире белән себерелеп тә йөрми ул... Ире була торып! Күземә дә күренмә, чыгып кит!! Әнә әйберләрең, җыелган...

Караса — Мөхәммәтнурның өстенә салкын су койдылармыни! — ишек катында ике чемодан, моңаеп, аны көтеп утыра.

— Син нәрсә, Фәүзия?! Ни сөйлисең?! — дип гаҗәпләнгән булды Мөхәммәтнур.— Нинди нахак бәла ягасың син миңа?! Нинди очрашу, нинди куну-төнү ди ул?! Мин бит икенче сменага калдым!

— Менә бу нәрсә ни өчен? — дип елый-елый телефонга күрсәтте хатыны.— Алайса, нишләп өйгә шалтыратмадың?

«Беткән баш беткән!» — дип уйлады Мөхәммәтнур һәм ни булса шул булыр, дип теленә ни килсә шуны сипте:

— Шалтыраттым мин, валлаһи, шалтыраттым! — дип хатынының күзенә карап ялганлады ул.— Әллә безнең телефон эшләми, әллә шунда...

— Әкият сөйләмә миңа! — диде Фәүзиясе, үксеп елый-елый.— Нишләп эшләмәсен ул?..

— Эшләсә, юкка минем җанны телгәләмә, әнә трубканы күтәр дә эшемә шалтырат! — дип әйтергә дә көч тапты Мөхәммәтнур.— Әйтерләр анда минем кайда булганны...

— Шул гына җитмәгәнме... Кирәгие!.. Әнә Флюраңа әйт, ул шалтыратсын синең эшкә. Хәер, инде өйгә шалтыратканны, анда күптән өлгерә торгандыр...

— Фәүзия!! — дип кычкырды Мөхәммәтнур.— Нинди гадәт ул кешегә һаман яла ягу?! Кешенең бер гаебе дә юк, ул бу турыда белми дә, ә син аңа пычрак атасың. Ал трубканы, шалтырат эшкә! Туйдырды мине синең бу шикләнүләрең, адым саен гаепләүләрең. Күпме түзәргә мөмкин?! — Ул бик җитез хәрәкәтләр белән телефон янына атлады.—

Мә, шалтырат! — Йә алла... Әгәр шунда хатыны чыннан да шалтыратып караса, бетте дигән сүз бит инде! Ул трубканы алып, колагына куйды, тик — минә алланың рәхмәте! — анда бернинди тавыш та юк иде. — Әйттем бит мин сиңа, безнең телефон эшләми, дип! Ә син һаман минем җанны кыйныйсың...

Хатыны, иренең әйтүенә ышанмыйча, әллә гаҗәпләнепме, килеп трубканы алды. Дөрестән дә телефон эшләми иде.

— Син миңа әкият сөйләмә! — дип үзенекен итте Фәүзиясе. Күп тыңладым инде мин синең мондый әкиятләреңне! Гарык! Син эштә булмадың, өйгә шалтыратмадың, син аның белән булдың. Бу миңа көн кебек ачык. Әйттемме — чыгасың да китәсең, Мөхәммәтнур! Җыен дигәч, җыен! Бар, аның янына бар. Бер сүзем юк. Матур гына яшисең килми икән, бар әнә...

Мөхәммәтнур бөтен җаны-тәне белән сизде: бу юлы хатыны шаярырга җыенмый бугай. Чемоданнарына тикле әзерләп-җыеп куйгач инде... Ә кая барсын ди ул? Кемгә сыенсын?! Мондый хәл әнисенә, туган-тумачаларга ишетелсә нишләр? Таныш-белешләренә ни дияр? Тормышларының менә шулай кисәк кенә чәлпәрәмә килүен ни дип аңлатыр ул кешеләргә? Сорарлар бит аннан. Әлбәттә, беренче чиратта әнисе сораячак! «Әле моңарчы сөекле булган хатыныңны, ике балаңны ташлап китәргә ничек кодрәтең җитте, намусың кайда?» — дияр.

«Мине хатыным үзе куып чыгарды», — дип бар, аңлатып кара син! Аңлаганнар ди... «Ике балалы хатын да яшәргә теләмәгән икән, димәк, син бөтенләй кеше түгел ул чагында!» — диеп авызыңны шып каплап куярлар. Их, менә бит тормыш дигәнең ничек... Юкка гына: «Бер алдын, бер артын күрсәтә», дип әйтмиләр икән. Чыны шулай икән. Тик аерылышу дигән хәлне әлегә күз алдына да китергәне булмады бит. Хатынын да, балаларын да ярата ич ул! Сөя!!

— Җитәр, җүләрләнмә, Фәүзия! — диде Мөхәммәтнур. — Турысын әйт, тавыш күтәрү өчен юри сәбәп эзләвеңме? Һич аңламыйм мин сине: ышанмыйсың да, тикшереп карарага да теләмисең. Димәк, сиңа тавыш кына кирәк?!

— Менә күрерсең, бер төшәр әле минем күз яшьләрем шул зинага, — дип, аны ишетмәгәндәй, Фәүзиясе үзенекен дәвам итте. Һәм кинәт кырт кына Мөхәммәтнурга таба борылды. — Ә син, хәзер сөйләгән әкиятеңнең дөреслеген раслыйсың килсә, менә шушы минутта ук аңа хат яз! Моннан соң Казанда эзе дә булмасын! Күргәндә дә дәшмичә узып китәрлек итеп яз! Хәзер үк!!

Мөхәммәтнурның хәле мөшкел иде.

«Менә нинди чиккә китереп җиткерде бу очрашулар, — дип эчтән сыззы ул. — Әйткән иде аны хатын, яхшылыкка алып бармас бу нәрсә, дип. Үзем дә инде... Гаепле, әлбәттә, гаепле. Хәер, мин нәрсә... Монда гаепнең зур өлеше синең өскә төшә, Флюра. Хатын-кыз буларак, син мондый нәрсәне белергә, аңларга, әгәр мине чынлап яраткан булсаң, шул ратуның, шул сөюең хакына мине бу хәлдән сакларга, бу хәлнең мөмкинлеге турында кисәтергә тиеш идең. Сакларга тиеш идең син мине, Флюра! Син: «Кун инде, ашалмассың!..» дип чатыр ябышмаган булсаң, мин кунарга калмый идем ич! Ә хәзер, күрәсең, моннан нәрсә килеп чыкты... Син мине гафу ит, ләкин гаиләм хакына, балаларым хакына мин андый хатны язарга мәҗбүрмен, Флюра. Аңла, хәзерге минутта, хәзерге көндә башка чарам юк... Мин сиңа барысын да аңлатып, аннары, соңыннан аерым бер хат язармын. Син мине аңларсың, Флюра. Аңларсың һәм гафу итәрсең».

— Ярар, синеңчә булсын, — диде Мөхәммәтнур кисәк кенә. — Тик юкка рәнҗеткән өчен ул да сине каһәрләргә мөмкин бит. Кеше каргышына юлыгу яхшы нәрсә түгел...

— Гаепле икәнмен, каргышы түгел, әллә нәрсәсе төшсен, — диде хатыны. — Ләкин мин хаклы. Мин моны беләм!

Мөхәммәтнур бер бит кәгазь алды да нindидер бер ачу белән язды: «Фәнүзә! Син башка минем белән беркайчан да, бернинди очрашу да эзләмә! Мин моны тормышыма, гаиләм тынычлыгына кул сузуын дип бәяләячәкмен. Хуш! Мөхәммәтнур».

— Мә, тынычлан! — диде ул, шушы кыска гына хатын Фәүзиясенә сузып.— Шулаймы? Әллә икенче төрлерәк кирәкме?

— Бара, тик исемен Фәнүзә дип түгел, ә Флюра дип куй инде син. Мине җүләргә санама!

— Тьфу! Исеме дә онытылган инде,— дигән булды Мөхәммәтнур.— Ничек дисең әле? Әйе, дөрес, Флюра бугай шул...

Ул хатын яңадан күчереп язды һәм тагын хатынына сузды.

— Гафу итәсең, адресын белмим,— диде ул.

— Аның каравы мин беләм,— дип көлде Фәүзия һәм язуны алып, кесәсенә салды.— Миңа моның үз кулың белән язылуы мөһим. Ул синең кулны таныйдыр дип ышанам...

Мөхәммәтнур дәшмәде.

Ә теге хат, чыннан да, кирәкле җиренә җибәрелгән булып чыкты бугай, шуннан соң ничә еллар буе Флюрадан ник бер хәбәр килсен!.. Алды бугай ул хатны, алды бугай...

Алар тора-бара хатыны белән тагын килештеләр, бу хәл турында тәмам оныттылар.

Мөхәммәтнур теге хат артыннан ук Флюрага аерым бер аңлатмалы хат язарга дип күңеленә беркетеп куйса да, дөнья мәшәкатьләренә биреләпме, яисә бу хәлнең шулай матур гына бетүенә шатланып тәмам тынычландымы — ни генә булмасын, ул аңа бернинди хат та язмады.

Берничә елдан ул Флюраның вафаты турындагы хәбәрне ишетте. Әйтүләренчә, ашказаны авыртып үлгән. Мөхәммәтнур моңа ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Аны тагын да тетрәндергәне шул булды: Флюра озак кына Казан больницасында яткан икән! Казанда! Янәшәдә!! Ә ул бу турыда белмәде дә! Нишләп беркем дә белгертмәде икән?! Әллә шул хат җиттеме аның башына? Әллә хатынының каргышы төштеме? Казанда больницада ятуы турында хәбәр итмичә ничек түзде икән Флюра?! Ул барган булыр иде, хәлен белешер иде. Ул килсә, аңа җиңел булыр иде ул... Их, димәк, теге хатны алган ул, алган... Алмаса, аны күрмичә генә үләр идемени...

Мөхәммәтнурның бәгырен кырыкмаса кырык сорау телгәләде. Флюраның үлемендә ул нигәдер гел үзен гаепләде, «теге хат кына харап итте аны!» дип уйлады ул. Һәм ничәмә-ничә еллар буена шундый уй белән үкенеп, үзен битәрләп яшәде, үзенә беркайда да тынычлык таба алмады...

«Кичер мине, зинһар, кичерә күр, Флюра-а-а!! — дип куллары белән кабер өстен төйде Мөхәммәтнур.— Гафу ит мине. Гаепле мин синең алдыңда, бик гаепле. Мин сине саттым, элеккеге мәхәббәтебезгә хыянәт иттем... Кем белгән бит, кемнәр белгә-ә-ә-н! Бәхиллә син мине, Флюра! Бәхилли алырсыңмы?»

Кинәт ул, шашкан кешедәй ашыга-ашыга, ялан куллары белән кабер өстендәге карны көрәргә тотынды. Кабалана-кабалана, суыктан туңган бармаклары суелып канга батканчы көрәде ул бу бозлы карны. Әйтерсең, ул ишетергә теләгән сүзләр бик аста, шул кар астында иде. Әйтерсең, аның җанына тынычлык бирердәй ул сүзләр Флюрасы белән бергә күмелгән иде...

Бераздан Мөхәммәтнур, үзенең көчсезлегеннән гаҗиз булып, туктап калды, пычрак, канлы куллары белән битен сөртеп алды. Айныды. Аңлады: көткән җавабын барыбер алалмаячак бит ул. Монда сораучы булса да, җавап бирүче юк бит... Монда дәшмиләр... Мәңгелеккә киткәннәр әйтелми калган сүзләрен дә үзләре белән алып китәләр...

Гаҗәеп моңсу тынлык иде дөньяда. Бу тынлыкны тып-тып тамган тамчылар гына боза иде...

# ПУБЛИЦИСТИКА

## Әсрар Гали

# КИЗЛӘҮ

ОЧЕРК

Элфәт Салахов туып-үскән Елховой авылының урам уртасында бу Кизләү. Авыл башыннан тау төшә. Шул тау итәгендә Кизләү тибә. Еллар буе. Тирә-як авылларда аңа тиңе булмаган шифалы, сихәтле, үзгә бер аерым тәмле, күкертле салкын су бу. Эсседә-салкында эч, беркемнең дә тамагына тими. «Бака» калыктырмый, ә аны төзәтә-дәвалый иде. Шунлыктан, аны халык: «Изге Кизләү» дип тә йөртә. Кизләү авызы кечерәк кенә агач бура белән буралган иде. Уртасында кара елларда киселгән мәчет манарасы сурәтен хәтерләткән (чынында ул шул мәчет манарасының күчермә варианты иде!) юан багана. Ул, элегрәк, зур шан уртасында иде. Шан астыннан чыгып чишмә суы ага иде.

«Чишмә» программасы белән эшләр җәелгәч тә, Элфәт Салахов Елховой кизләвен әледән-әле уйлап, бер дә күңеленә урын-тынгы тапмый йөрде. Ничек тә яңартырга иде бит аны! Бу уен ул «Ямашнефть» идарәсендә дә, «Татнефть»тә дә әйтте. Һәм, бу җаваплы эшне «Ямашнефть»нең технологик транспорт идарәсе башлыгы Элфәт Хәертдиновичның үзенә үк йөкләделәр дә.

«Кизләү» проектын төзү өчен архитекторны авылга үзе алып кайтты. Урынны, авылны күрсәтте. Кизләү мәйданы өчен үзе баш ватып йөргән бар вариантларны да төкми-чәчми сөйләде.

Проект кулга кергәнче үк төзелешкә кирәк материалларны ташыту эшенә кереште. Кирпеч, цемент, алебастр, ком; колач житкесез юан торбаны урталай буйга ярып кискән улаклар; тутыкмый-күгәрми торган ак калайлар; төрле-төрле буяулар; тимер баганалар һ. б. Аерым осталар бригадасы билгеләде. Аларга җаваплы кеше куйды.

Проектны алуга төзелеш эшләре башланды.

Кизләү авызындагы агач бураны сүтеп, аның уртасындагы «манара»ны кирпечләп төзелгән бина өстенә беркеттеләр. Кизләү бинасын рәссамнар милли бизәкләргә баетып, нәкышлап сурәтләде. Әйтерсең лә теге мәчет манарасының игезәк күчермәсе. Манара ялтырап торган ак калайга тышланды. Үр төшкән саен авышлык сөзәкләнә барган урыннарга баскыч-баскыч ясап, су агу улаклары суздылар. Тагын да түбәнрәк (ерак түгел!) Кизләү суы өстенә мәчет гөмбәзе сыман ак калай белән бизәкләп, колхозның сөт суыткычын төзеделәр (анда, элегрәк тә агачтан, череп авышкан бу урын бар иде!). Моны хәзер эссе җәй айларында, колхоз һәм шул тирә урам йортларда яшәүчеләр дә сөт ачымас өчен суыткыч итеп файдаланалар.

Кизләү тирәсен тотарга бизәкле рәшәткәләрне Түбән Камадан эшләтеп кайтарды Элфәт. Йорт эченә, урманның чәчәкле урыныннан кәзләр кисеп, аны йорт мәйданына җәйдерде. Кеше еш йөри торган буш урыннарга чуерташ кайтарып түшәтте. Кәзләргә көн саен су сиптеләр. Алардан яшел үләннәр һәм чәчәк кыяклары бөртеп чыкты. Бик тиз яфракка җәелделәр.

«Елховой Кизләве» күкертле суны җир өстендәге улакларга бәреп тора. Төзелеш эшләре бетәсе көнне генә, мәрмәр тактага бер рәссам: «Бу Кизләү суы архитектура сәнгатен «Ямашнефть» УТТсы житәкчесе, авылдашыбыз Салахов Элфәт Хәертдинович төзетте», дип язып куйды.

Шул ук көнне Кизләүне ачу тантанасы булды.

Чыгыш ясаучы авылдашлары «Элфәт чишмәсе», дип сөйләделәр.

Элфәт Салахов исә үзе әйтте: «Гасырлар буе челтерәп аккан изге чишмә бу, авылдашларым. Аннан минем Салах бабай су эчкән. Әтием Хәертдин һәм әнием Гайшә. Мин һәм безнең-сезнең һәрберебез дә... Шуңа күрә, элеккечә: «Кизләү» генә булып калсын»,— диде.

— Ә шулай да, яңа «Кизләү!» — кизләү генә булып калыр микән?!

Һәммәсе дә:

— Юк! — диделәр.— Без инде аны төзелеш башлануга: «Элфәт чишмәсе» дия башлаган идек. Бөтен авыл шулай ди хәзер... Бу кадәре гөлбакчаны исемсез калдырабыз, димени...

Халык шулай атый икән, димәк, бу хак төшенчә.

Ә мин шул мизгелдә Элфәт Салаховның гомер чишмәсенең кайсы кизләүләрдән башлануы, нинди тау-ташларны тишеп, өскә үрләве, ниһаять, кешеләргә эссе чакта бер йотым су кебек кирәкле вә кадерлегә әверелүе турында уйландым.

...География укытучысы Кояш тирәсендә Җир һәм тагын әллә ничә планета әйләнүен мисаллар китереп аңлаткач, малай уйга калды. Алар арасында көмеш Ай да бар, ди. Ләкин, якты Ай планета түгел, безнең Җир шарының иярчене икән. Галәм киңлеге, Галактика иксез-чиксез, ди. Очы-кырые юк. Анда мең вә миллионнарча кояшлар, планеталар, ди. Кайсында безнең кебек һәм төрле сурәттәге «кешеләр» яшәве дә ихтимал, кайберләрендә тереклек юк, ди. Нурлы Ай да кислородсыз, һавасыз, буш күк җисеме икән ләбаса. Кап-кара төннәрне су кебек яктырта алучы тулган Айның бу хикмәтен аңлый алмыйча аптырады малай. Аяз күктә чуп-чуар алтын йолдызлар күз нурын иркәләп җемелди. Киек каз юлы бу! Шулар арасында якты йолдыз булып түгел, түм-түгәрәк куашна кадәре Ай балкый. Нинди сихри көчләр аны шулай итә икән...

Әнә шундый хыялый Элфәт исемле малай Елховой авылында туып үсте. Бу авыл башта 1-Май районына керә иде. Район үзәге Чирмешән иде. Хәзер нефтьчеләр төбәге Әлмәткә берегеп калды. Зур авыл. Дүрт йөз йортлы Елховойны, шул кадәре хуҗалыклы Түбән Абдул авылын бер исемдә атап: «Елховой», дип йөриләр. Телдә генә: «Елховой ягы!», «Түбән Абдул ягы!» дип әйтелә. Бу ике авыл бер колхоз иде. Араны бары тик Шушма елгасы гына аерып тора. Анда өч агач күпер иде.

Елховойның урыны, табигате, әкиятләрдә сөйләрлек биниһая ямьле, матур җирлек. Чиялек болыны, Сазлы күл, Түбән болын, Мукшы әрәмәсе, Югары әрәмә, Шушма елгасы, Кизләү, куаклык-таллыклар, тау һәм үзәннәр, чәчәкле тау битләре... Шул җирлектә, шул туфракта үсте Элфәт. Ләкин, шатлыклы балачактан битәр, кайгы-хәсрәтләре күбрәк иде. Өйдә биш бала иде алар. Абыйсы Рәшит, Элфәт үзе, сеңелләре Фәния белән Фидания, энесе — Ирек. Берсеннән-берсе кечкенә балалар. Әтиләре Хәертдин сугышта. Бичара тол хатын Гайшә апа бу биш баланы ачлыктан һәм суыктан ничек саклап кала алгандыр. Сугыш һәм сугыштан соңгы ачлык-ялангачлык, черек бәрәңге, алабута, кычыткан, ат кузгалагы ашап туену... Бөтенесен баштан кичерде Элфәтләр гаиләсе.

Елховойның иске мәчете бинасындагы мәктәптә башлангычны укып бетергәч тә, Түбән Абдул урта мәктәбенә йөреп гыйлем эстәде Элфәт. Җәйләрен үгез җигеп Элфәт колхозда эшли дә иде инде. Олаудагы капчыклар артына утырса, гәүдәсе күренми. Камыт бавын бәйләрлек буе һәм көче юк. Шул көе алтмыш чакрымлы Шонталы станцасына ашлык-бөртек ташый. Чыгымчы үгез кире беткән. Йомшак кулны тыңламый. Теләсә, су эчәргә борылып төшә. Кигәвен, озынборын сырып ябыша үзенә. Тибенә. Башын чайкый. Коерыгын болгый. Тәртәне сындыра язып, киреләнеп, куаклыкка кереп китә. Йә, туктап ашый башлый... Шул рәвешчә, малай үзенә ыштан-күлмәклек хезмәт көннәре эшли. Ә ярлы колхоз көзен акча да, ашлык та бирми иде...

Сигездә укыганда Элфәт башына яңа бер яман уй төшә: ул зур егет инде, янәсе. Һәрхәлдә, зур күренәсе килә. Үгез җигә белә. Эшкә ярый. Укуны ташлыйсы да, ел әйләнәсе үгез җигеп эшли, янәсе.

Читләтеп кенә моны әти-әнисенә дә сиздерә. Тегеләр дәшми...

Кышкы каникулда Элфәт үгез җигеп, урман ташырга китә. Үзләренә. Урман Елховойга җиде чакрым. Көн кыска. Суык. Буран. Җил. Үгез мәнсез. Чана начар. Авышлык-кыелмаларда олау ава. Кайчак, икешәр, өчәр мәртәбә олауны яңадан төяргә туры килә. Көч җитми, дими, тәки төйи. Сигезенче класс малае бит Элфәт. Менә, бүген, үзегезнең шул яшьтәге малаегыз белән чагыштырып карагыз. Ул, мөгаен, авызына кабарга кашык күтәрергә дә иренәдер. Әзергә бәзердер.

Әнә шундыйрак ич бүгенге замана баласы. Элфәт исә утынга иртә караңгыда китә, төнлә кайта: шакыр-шокыр катып. Каникул буе шулай эшли. Әнисе бу юлы, теге чакны искә төшереп әйтә:

— Ничек, Элфәт, улым! — ди.— Урман ташуны дәвам итәсеңме, әллә укырга уйлыйсыңмы?!

— Укыйм, әни, укырга барам! Бу үгез белән генә әллә ни ерак китеп булмас...

Кирәк чакта үзенә дөрес юнәлеш бирүләре өчен Элфәт гомере буена ата-анасына рәхмәт укыячак әле.

...Урта мәктәпне «дүрт» һәм «биш»ле билгеләренә генә тәмамлый яшь егет.

Казанга, институтка, барып карамады түгел Элфәт Салахов. Карады. Барды. Авыл хуҗалыгы институтында аның язуларын барлап:

— Әтиең бар икән,— диделәр.— Сиңа стипендия түләнмәячәк. Тулай торак та бирә алмабыз.

Авылга кире кайта ул.

Очраклы рәвештә Әлмәт район газетасында бер белдерү күзенә чалына. «Лениногорскиның Икенче техник училищесы укырга егетләр-кызлар кабул итә. Урта белем белән!»

Элфәт шунда ашыга.

Бәхеткә, аттестатында дүртле-бишлеләр генә булгач, Элфәт Салаховны механиклар курсына кабул итәләр.

Тулай торак. Ап-ак җәймәле караватлар. Суы шунда. Күршедә ашханә.

— Авылдан беренче чыгып киткән безнең ишеләр өчен оҗмах урыны иде бу,— дип бүген дә яратып сөйли Элфәт.— Аннан да бигрәк укытучылар яхшы иде. Училище директоры — Крушвиц Иван Иванович! Милләте буенча немец. Тарихтан укытты. Татар мәктәпләрендәге дәреслектә, ни әдәбиятта, ни тарихта язылмаган, билгеле булмаган татар һәм төрки халыклар тарихын, Тын океаннан алып Атлантика океанына кадәр җәелгән борынгы һәм укучылар өчен ул вакыттагы яңа дөньяны безгә сөйләп укыта иде. Ә без, әти-әни сөйләгәннән тыш, башкасын белми идек. Моның белән Крушвиц әфәнде башка милләт балаларын да татар халкын хөрмәт итәргә өйрәтте. Икенче укытучым — Петр Николаевич Головин! Ләм-мим бер сүз урысча белмәгән, авылдан килгән минем ише яшь егетләрне урыс теленнән укыта иде. «Татарча да яхшы бел, урысча да яхшы бел!» — фикере белән укытты.

Элфәт житкән егет инде. Уртача буй-сын. Киң күкрәк. Юан муен. Көр тавыш. Карасу-соргылт бөдрә чәч. Килешле кашлар. Түгәрәк ачык йөз. Үзе ягымлы. Инсафлы. Тәмле телле. Теләсә кайсы матур кызны гашыйк итәрлек чибәр егет училищены бик яхшы билгеләренә генә тәмамлый. Механик дипломын кесәгә салып куя.

— Безне,— дип сөйли Элфәт Салахов,— иң яхшы укыган тәртипле егетләрне, Лениногорскиның үзендә калдырдылар. Чит-яры җибәрмәделәр...

«Лениногорскнефтестрой» трестының «Төзелешне механикалаштыру базасы» идарәсенә, ул вакыттагы иң зур разряд — алтынчы разрядлы слесарь итеп эш бирәләр үзенә.

Хәлләр яхшыра бара...

— Ә, мине,— ди Элфәт,— торган саен Әлмәт үзенә тарта иде...

Һәм теләгенә ирешә дә!

«Әлмәтнефть» тресты автохуҗалыгына слесарь булып эшкә күчә.

Һаман тулай торак тормышы. Өйләнәсе дә булыр. Фатир алырга чиратка гариза яза. Чираты житә. Бирәләр. Буйдак егет булгач, үзе алмый. Гаиләле кешегә бирә фатирны. Чиратны янә чигерәләр. Берничә тапкыр шулай була. Гомерләр уза. Элфәтне механик ясап билгелиләр. Тракторлар буенча...

Күршедә генә кызлар тулай торагы. Элфәт өздереп гармун сайрата.

— Кичләрен кызлар янына кереп йөри идем,— ди ул.— Тормыш юлыма Нурия исемле бик матур һәм бик акыллы бер кыз килеп керде...

Алар саф мәхәббәт белән яратышып өйләнешәләр.

Яшь килен авырга уза. Озак та үтмәс, ул бәбиләр дә. Торырга фатир юк. Терсәк якын да, Элфәтнең, тешләп булмый. Үз чиратына тигән фатирларны юмартланып кешегә өләшә барды ич.

Нурия дә үз эш урынында фатирга чиратка язылган икән.

Шуны чамалап, яшь парлар, Әлмәт шәһәр партия комитетының ул чактагы беренче секретаре кабинетына киләләр. Хәлне сөйләп аңлаталар. Нуриянең көмәне сизелеп тора. Күрсәтәсе юк. Телефонны ала да секретарь, кемгәдер шалтырата.

— Фәлән-фәлән иптәшләр миндә... Чиратны чигергәннәр... Үзе... Шәфкатьл
затлар... Хатынының беренче чират... Иртәгә үк Салаховларга фатир бирегез,—
ди беренче секретарь.

Элфәт белән Нурия, үз-үзләрен онытып, тизрәк теге фатирга ордер бирүч
иптәш янына чабалар.

Ордерны бирә бу. Бирми кая барсын. Беренче үзе кушкач.

Чехов урамындагы фәлән йорт, фәлән фатир...

Мышнап, уфылдап, бу фатирга килеп керсәләр, монда инде ремонт бара. Таш
ваталар. Измә чәпиләр...

Элфәт кулындагы ордерны күрсәтә.

— Безнең фатир булырга тиеш иде бит бу! — ди.

— Әй, Алла! — дип елый башлый Нурия кебек авырлы яшь хатын.— Үзебез
неке дип белеп, стенага хәтле үзгәртеп, бизәп ясарга керешкән идек...

— Чүгегез, чү, елама! — ди Элфәт сабыр гына.— Бәлки сезнең фатир башкадыр...

Тегеләрнең ордерын карасалар, Чехов түгел, Чернышевский урамы, дип языл-
ган. «Ч» булгач, буталып килгәннәр дә кергәннәр икән.

Элфәтләр Чернышевскийга килсәләр, бусы тегесеннән дә әйбәтрәк урында.
Шулай ук ике бүлмәле... Тулай торактагы әйберләрне төйниләр дә, шундук бу
фатирга күченәләр. Ике як та риза. Алганчы алмашу килеп чыга. Хәерле сәгатьтә
булсын, Илаһым! Балалар ишле булсын бу йортта...



*Элфәт һәм аның хатыны — тормыш юлдашы Нурия Салаховлар. 1959 елның
маенда төшкән бу фоторәсем артына Нурия ханым болай дип язып куйган:
«Әтисе! Менә бит мин синең ничек кадерлең. Киләчәктә дә шундый пар күгәрченнәр
булып калсак иде...»*

Беренче балага Илшат исеме куштылар. Бу чакта Элфәт Мәскәү нефть ин-
ститутының Әлмәт филиалында укый иде инде. Кичке бүлектә. Дүртенче курста
укыганда икенче малае Ринат туды.

— Бу чакта мин,— ди Элфәт,— Әлмәтнең иң зур автохуҗалыгында производ-
ство-техник бүлекнең башлыгы идем... Ике елдан соң, җәмгысы алты курсны
кичен укып, институтны бетердем.

...Балаларны үстерү белән мавыгу иң кызыклы чор икән. Уларына кушылып
чаңгы шуулар. Хоккей уйнаулар. Дәресләр әзерләшү. Баш кашырга вакыт юк
иде. Көннәр үтә дә китә. Сизелми дә...

Малайлар икесе дә аталары башлаган нефтьчеләр юлын сайлый. Илшат — Мәскәү нефтьчеләр институтына, Ринат — Самара политехник институтына керә.

— Ике улынны берьюлы биш ел буе стационарда укыту бер дә җинел түгел икән,— дип искә ала Элфәт.— Кулга кергән барлык акча аларга китеп бетә иде. Ашарга кирәк. Кием-салым. Кино-театрлар, юл йөрү, һ. б. Аларның да кешечә яшиселәре килә ич... Яшьлек.

Хәзер инде Илшат Салахов — «Татнефть» акционерлык җәмгыятендә үзләштерү бүлегенең өлкән инженеры.

Ринат Салахов — Төмәндә! «Ноябрьскнефтегаз» акционерлык җәмгыятендә «Сутармынскнефть» идарәсе башлыгы урынбасары. Рәсәйдә иң эре, иң зур идарәләрнең берсе.

Болар — Салаховлар токымының, Хәертдин бабай нәселенең, үз аталарына Элфәтнең алга таба дәвамчылары.

Элфәт Хәертдин улы үзе гел сафта. Ул, малайлары укыганда да, аннан соң да нефть һәм газ чыгаручы «Ямашнефть» идарәсенең технологик транспорт идарәсе (УТТ) башлыгы булудан өзелгәне юк. Нефть чыгаручыларга даими рәвештә хезмәт күрсәтәләр. Биредә 570 автомашина гына. Трактор, калган техника күпме... Тугыз йөзгә якын нефтьче-транспортчы. Аларны эшләт. Тамакларын туйдыр. Өстен бөтен ит. Фатир бир. Балаларын ясле-бакчага урнаштыр. Акчаны үзвакытында биреп баруның бүгенге чорда никадәр читенлеге мәгълүм. Технологик транспорт житәкчелеге моңа ничек тә ирешергә тырышып яши. Чөнки нефтьчеләр чыгарган еллык «кара алтынның» илле проценты чамасы диярлек нефтьче-транспортчылар өлешенә туры килә...

УТТы базаларының дүртесе дә аякка басты. Зур төзелешләр бетте сыман. Ә Элфәт Салаховның үз конторы һаман иске бүрәнә йорт иде. Әлмәт базасында җыелыш уздырды.

— Бүген апрель башы,— диде ул,— Октябрь бәйрәменә идарәнең яңа бинасы өлгерәчәк...

Күпләр ышанмады.

Ничәмә еллардан бирле, бу кадәре төзелеш эшләрендә азау ярган Элфәт Хәертдинович үз конторын биш айда төзетеп бетерде. Җыелма тимер-бетоннан. Ике катлы. Һәм... үз кабинетына Әлмәт мулласы чакырып Коръән укытты! Ул чорда, Брежнев, Суслов кебек илбашлыклары идеологиясе хөкем сөргәндә, урыстан кала башка милләтләрнең динен, телен, гореф-гадәтен һ. б. бетерүнең чәчәк аткан чорында бу. Моның өчен коммунист кешене партиядән чыгаруларын, житәкче кешене эштән кууларын, аннары җүнле эш бирмәячәкләрен белгән өстенә.

...Бүгенгә кадәр Элфәт Хәертдинович күз алдында «Ямашнефть» НГДУсының өч житәкчесе алышынды. Алар: Мордвинцев Александр Васильевич, Чернышов Игорь Николаевич (мәрхүм!), хәзергесе — Смыков Виктор Васильевичлар. Өчесе дә, күз генә тимәсен дип әйтерлек, бик яхшы эшләделәр. Шул өч характердагы өч житәкче белән дә УТТ идарәсе башлыгы Элфәт Салахов бер телдә, бер сулышта эшли белде. Килешеп яшәделәр.

— Бигрәк тә Виктор Васильевич татар җанлы булып чыкты,— ди Элфәт Хәертдинович.— Башта татар авылларында мәдәни учаклар тергезү, юлларны асфальтлау, газ-су кертү белән мавыкса, соңгы елларда авылларны төзекләндереп саклау, мәчетләр төзү эшенә җиң сызганып булыша. Балаларны татарча укытуга җаны-тәне белән үзе башлап йөри... Безнең дүрт филиалга да бертигез карый. Аның белән эшләве үзе бер рәхәт.

Мәсьәлә нефть промыселларында гына эшләү булса иде икән. Үзе авыл малае булгач, Элфәт Салахов урып-җыю чорында ел саен бик теләп авылга ярдәмгә катнаша килә. Ул житәкләгән УТТ Минзәлә, Аксубай, Чирмешән, Норлат, Азнакай, Яңа Чишмә районнарында һәм елның-елында Әлмәт районы колхоз-совхозларында эшли. Район саен аңа «Мактау грамоталары» килеп тора.

Бер елны, октябрь аенда иртән-иртүк аны партиянең Әлмәт шәһәр комитеты беренче секретаре Ринат Галиев үз кабинетына чакырып алды. «Райком кушса, ялангач артың белән чәнечкеле керпе тиресе өстенә дә утырырсың», дип йөри торган, коммунистлар партиясенең иң дәрәҗәле чагы иде.

Барып керде Элфәт Салахов. Күрештеләр.

— Салахов! — диде Элфәт.

— Утырыгыз! Сөйләшик. Гаиләң хәлләре, УТТ хәлләрен...

«Үз гаиләң хәлләре белән дә кызыксынучы шундый зур житәкчеләр бар күрәмсең дөньяда», дип уйлап өлгерде Элфәт. Юкса, кайбер райком секретарьларын өстәл сугып кычкыра, яный, эштән куа, дип сөйлиләр иде район үзәкләрендә. Ишетә белә иде.

Кыска гына сөйләде.

— Менә нәрсә, Элфәт, дустым! — диде секретарь йомшак тавыш белән.— Бүген булмаса иртәгә кырау төшәр. Безнең Ямаш авылындагы «Җиңүче» колхозында сиксән гектар кукуруз сабакта утыра. Кырау сукса, үзең беләсең...

— Силоска ярарлыгы калмый инде! Кадере бетә.

— Менә шул-шул! Бу чималны ничек тә җыеп аласы иде...

Беренче секретарьның бу кадәре дә тыныч, мөлаем-итле сөйләшүенә ул таң калды. Боермый. Куркытмый. Бу эшнең бик мөһим икәнен, күзенә карап, күңеленә сала. Аның бу җылы сүзен үтәмәскә мөмкинме соң?

— Ярый! — диде Элфәт Салахов, утырган урыныннан кузгалып.— Эшләрбез...

Алар күзгә-күз карап, җылы гына саубуллаштылар.

УТТ башлыгы турыдан-туры эш урынына кайтты. Базадагы кирәкле кешеләрне үзенә чакырды. Алар җыелгач та, сүз башлыйсы урында, телефон трубкасын алды да Ямаш базасына шалтыратты.

— Кукуруз уру, силослауда нинди әзер техникаң бар, һәммәсен Ямаш кукуруз басуына каула... Әйе... Ну... Кешеләрне дә... Кирәк кадәресе һәрнәрсәне дә мин моннан үзем алып барам...

Трубканы куйды да коңгырт күзләре белән кабинеттагыларга ышанып карады.

— Ишеттегезме? — диде — Әзерләнегез. Унбиш минуттан юлга чыгабыз...

Алар, бер көтү кеше, машина, техника белән Ямаш кукуруз кырына килеп төштеләр. Көз булса да, алар бәхетенә яңгырсыз, кояшлы, салкынча коры һава. Кукуруз мәйданын кишәрлекләргә бүлделәр. Комбайн янәшәсендә туралган кукурузны әрҗәсенә төяп, автомашина бара. Бер минутка да туктап торыш юк. Бер машина төяп силос базына элдерттеме, аның урынын икенчесе били. Өченче... унынчы... егерме-утызынчылар... Әллә ничә кишәрлек. Кукуруз басуы белән силос базлары арасында тоташтан машиналар агымы. Траншеяга салынган силосны да тракторлар таптап дыңгычлый...

Икенче көнне уракта катнашучы барлык җитәкче кадрлар горкомга җыелдылар. Аларга, кичә, көндез, телефонограмма бирелгән икән. Элфәт кукуруз силослады ич. Нииндидер зур сөйләшү, ди.

Киңәшмә башлануга, үз исемен Беренче авызыннан ишеткәч, Элфәт Салахов торып басты. Сорыймы? Сөйләтәме? Бер-бер гаеп償 бармы?

— Менә, иптәшләр, Элфәт Хәертдинович кебек эшләгез! — диде беренче секретарь Ринат Гыймаделисламович, пауза ясап тормый гына.— Бер көндә сиксән гектар кукурузны урып бетереп, силос базына салып кайтты...

Өстәл артыннан чыкты һәм туры аның янына килде.

— Рәхмәт, дустым! — дип, кулын кысты, аңа шәһәр комитетының «Мактау грамотасы»н тапшырды.

Эчкә җылы кереп китте. Беренче теленнән рәхмәтләр ишетү шәһәр һәм районлагы иптәшләр алдында бу зур дәрәҗә иде.

Шул тантанадан соң гына киңәшмә төп эшкә күчте.

...Нефть районнарында һәр НГДУ идарәсе каршында берәр УТТы идарәсе эшли. Алар турыдан-туры НГДУга (нефть-газ чыгаручы идарәгә) буйсыналар. Элфәт Салахов җитәкләгән «Ямашнефть» технологик транспорт идарәсенең эш-гамәлләре, даны, нефтьчеләр арасында тиз таралып өлгерде. Ярдәм итү йөзеннән Һиндстанга да нефтьче-транспортчылар бик кирәк иде. Сайлап алганда, Элфәт Хәертдинович кандидатурасы алга чыкты.

...Элфәтләр самолеттан төшү белән машинага утырып, Гуджарат штатының Потан шәһәренә юнәлделәр. Шуның янында «Совет нефтьчеләре поселогы» бар иде. Анда килеп житкәнче, юлда күрделәр: тоташтан ком сахрасы. Ярым чүл! Урыны-урыны белән берни үсми дияр идең, дөя генә чәйнәп ашый ала торган чәнечке төймәле, каты куралы бер үсемлек күренгәли иде. Ә күрше штат тоташтан чүл. Анда «Дөя чәнечкесе» дә үсми. Бу, анда, икенче кабатка урак беткән чор иде.

«Нефтьчеләр поселогы» матур иде. Зур түгел. Җыйнак ак йортлар, Коттеджлар! Дүрт ягында дүрт фатир ишеге. Икешәр бүлмәле. Элфәт берүзе шуларның берсенә урнашты. Шундук: «Нигә хатыннарны китермиләр икән?» дип уйлап өлгерде ул. Урын җитә. Кыр хәтле. Поселокта: бораулаучылар, промыселчылар (газ-нефть чыгаручылар!), нефтьче-транспортчылар һ. б.— барысы бергә яши, барысы бергә-бергә бүленеп эшли иде. Элфәт Салахов — Төньяк бораулау контрактның (анда Көньяк контракт та бар иде!) транспорт цехы башлыгы. Татарстаннан килгән (күпчелеге татарлар! Ул үзе шулай туплады) утыз биш транспор-

тчыга — утыз биш һиндстан егете парлашып эшлиләр иде. Татарстандагыча гына түгел, буровойда, промыселда, юлда, цехта, машина-тракторда — нинди эш бар, бөтенесен үзләре башкаралар. Төп эш — нефть эзләү! Бораулау. Скважиналарны җиһазлау. Аларны эш кирәк-яраклары белән тәэмин итү иде. Автотранспорт, цемент һәм изма ташу агрегатлары, тракторлардан башка бер эш тә бармый иде. Элфәт Салахов биредә транспортчы гына түгел, буровойда да эшләп йөри...

Иң кызыгы җирле халык белән аралашу иде. Мөселманнар. Ислам динендәге халык. Итагатьлеләр. Ачык йөзлеләр. Матурлар. Дин һәм тел, миллилек, үз гореф-гадәтләре, миллиардка якын халыкны мәдәниятле итеп яшәтә. Бергәлек, дуслык, миллилек — аларны милләт буларак саклый икән.

Ашханәгә кереп, тавык ите сорасаң, өстәл янына барып утырасың. Бик тиз китерәләр. Анда ипи юк. Бик тәмле калын ак җәймә! Ипи бер якта торсын. Бодай онына нәрсәләрдер кушып. Ашап туйгысыз.

— Мин бит тавык ите генә сораган идем,— ди Элфәт, аларча исемен атап,— минем өстәлгә тагын алты-сигез төр тәмләткечләр китерделәр. Болары бушлай гына икән. Тавык итенә өстәп. Әз-әз генә. Арада әрем кебек ачы тәмлеләре дә бар. Куйгач, ашадым. Рәхмәтләр әйтеп амин иттем. Шунда ит китерүче кыз: «Ашадың. Рәхмәт! — диде.— Инглизләр дә шул азыкларны ашап кына Һиндстанда исән калганнар...» Баксаң, бу тәм-томнар дару шикелле үк могҗизалы нәрсәкәйләр икән...

Һиндстан Премьер-Министры Раджив Ганди парламентка шушы Гуджарат штатыннан депутат итеп сайланган. Егерме биш штаттан нибары бер Гуджарат штатында гына «коры закон» кертқән. Халыкны саклар өчен. Монда аракы юк. Эчмиләр. Күрше штаттан килгәннәрне дә тикшереп кертәләр. Исерткеч, миңгерәткеч матдәләр юкмы, ягъни. Ә Һиндстанда иң үтемле товар: урыс аракысы (беренче урында!), кул сәгате, фотоаппарат, ди. Ләкин, бер исерекне дә күрмәссең анда.

Раджив Ганди власть башына менгәч, Һиндстан халкының авылларда яшәүче һәр дүрт йортка бер кое казыткан. Кул-көрәк белән түгел, әлбәттә. Скважиналар бораулаткан. Дүрт йорттагы дүрт гаилә тәүлекләп дежур торып, комлы сахра җиренә арыклар буенча су агызалар.

— Моны кеше үзе күрмәгәч,— ди Элфәт Салахов,— барыбер аңламас кебек... Менә, ком дәрьясы бит. Шул ком өстенә тоташтан өстәл кебек тип-тигез су элпәсе. Сай гына. Тып-тыныч су. Өстән кояш карый. Җирдә көзгемени, су яктылыгы. Шунда өч төрле уңыш: бодай, кишер, горчица үсә. Соңгысыннан май ясап, чит илләргә дә саталар. Бодай гектардан сиксән центнер уңыш бирә. Елына ике мәртәбә урып-җыялар. Миллиардка якын халыкка ашарга, терлек, кош-корт асрарга, буйволларга (сөтенең майлылыгы җиде-сигез процент. Ите бик тәмле!), фуражга да җитә. Беркадәре бодайны чит дәүләтләргә сата...

Гаҗәп шул. Безнең Рәсәй халкы кара туфраклы, уңдырышлы мәйданнарда ярты Аурупа, Азияне биләп торса да, бүгенгәчә ипигә тиенме әле. Бер бөтен ипи кибеттә бүген өч мең сум! Минималь пенсия житмеш сигез мең. Шул акчага туйганчы ашап кара. Ә ил буенча өчәр ел буена сукыр бер тиен алмаган авыллар күпме?! Тегенди ярымчүлгә, чүлнең үзенә үк юлыкса, әллә кайчан, бер елда үк кырылып бетәр иде Рәсәй халкы.

Өч айдан соң Һиндстанга Нурия килә.

Ашау-эчү ягы иркен. Халык белемле. Укымышлы. Яши беләләр. Чүлдә иген үсә. Авыллар, бистәләр, шәһәрләр: алма, чия, хөрмә, апельсин яшеллеккә төренеп утыра. Чүл өстендә киң асфальт юллар...

...Рәсәйдән нефтьчеләр делегациясе киләсен Элфәтләр бер көнгә алдан сизенәләр. Машиналар кайтып җитүгә, ни күрсен Элфәт: ишектән Ринат Гыймаделисламович Галиев килеп чыга. Кояшлы Һиндстанга аксыл костюмнан, ак эшләпә киеп килгән. Анысын да алдан белгән. Ачык йөзе шат елмаюлы. Элфәтне күрүгә:

— Син монда эләктеңмени! — дип, килеп күрешә.

Алар якын туганнарча кул кысыштылар да аннары түзмәделәр, кочак җәеп бер-берсен кочаклап ук алдылар. Ринат Галиев бит инде «Татнефть» акционерлык җәмгыятенең генераль директоры иде. Делегациянең эш графигы алдан төзелгән. Берни сорашыр, сөйләшер ара юк. Элфәт тизрәк үз адресын бирде.

— Кичкә килегез!

— Киләбез! — диде Ринат Гыймаделисламович. Ул әйттеме, бетте! Таш яуса да, үз вәгъдәсендә торачак.

Һәм, кичен алар Элфәтләргә өчәүләп килделәр. Ринатның урынбасарлары: Энәс Кыямович Гыйматдинов — тормыш-көнкүреш, коммуналь торак һәм

кадрлар буенча урынбасары (бүген дә шул ук вазифаны башкара). Рашат Хәсәневич Фәтхуллин — бораулау эшләре буенча урынбасары.

Һәр ике яктан да сүзләр күп булды. Сөйләшү кызык иде. Һәрбер кунак күнелгә ифрат якын иде.

Нурия ханым бик матур, бик бай табын әзерләде. Буйвол ите салып пешергән бәлешне, төрле тәм-томны мактый-мактый ашадылар. Һиндстан чәен куе ясап эчтеләр. Ике-өч сәгать буе күңелле мәҗлес барды. Татар җырлары язылган магнитофон тасмалары Элфәтләрдә байтак иде. Илһам Шакировка, Әлфия Авзаловага кушылып, үзләре дә җырладылар. Туган як моңы чит илдә әйтеп бетергесез якын, кадерле иде.

...Контракт буенча Элфәт Салаховлар егерме нокта борауларга тиеш иделәр. Шуны бораулап бетерделәр. Бер ноктадан гына нефть чыкты. Калганнарына су агып торырлык итеп скважиналарны монтажладылар.

Контракт бетү белән бер көн дә тоткарламадылар. Аларны Туган илгә кайтарып җибәрделәр...

...Кайткан атнада ук Элфәт Салахов үз эшенә чыкты.

Тегендә киткәндә ничек ашкынып барган булса, монда ялкынланып «Ямашнефть» УТТысының үзе төзегән дүрт базасын да тәүлекләр буе җентекләп карап йөрде. Шуннан соң дәртле эш янә кайнады.

...Берничә еллар үткәч, НГДУ башлыгы Виктор Васильевич Смыков аннан сорады:

— Синең соң былтыргы өчен ял ителмәгән түгелме?

— Эшләр тыгыз... Ничек ял сорыйсың, ди. Яхшы түгел...

— Мин сиңа Берләшкән Гарәп Әмиратларына ялга барырга юллама бирәм. Аннан кайткач эшләрсең...

Рәхмәт кенә инде. Элфәт Салахов янә чит илгә чыкты.

...Бу ил тоташтан ком һәм нефть өстендә утыра икән. Яшеллеккә күмелгән таза-төзек авыллар, ап-ак мәрмәр шәһәрләр. Асфальт киң юллары Америка, Япония генә түгел, дөнья стандартында. Ике миллион ярым чамасы халык яши. Бары да диярлек югары белемлеләр. Төп халкы — җирле гарәпләр. Бөтен шәһәр-авыллар автоматлашкан. Компьютерлашкан. Илнең теге башы да, бу чите дә телевизордагы кебек күренеп тора. Телефон аласың да шул якты экрандагы кешегә карап сөйләшәсең. Гарәпләр һәр эшкә контрольлек кенә итә. Нефтьне безнең Татарстандагы кебек, чимал көенә ташу аккан кебек шаулатып торба буенча Көнбатыш Аурупага кумыйлар. Бу эштә дә Рәсәй безнең Татарстанны төп башына утыртты. Әле кайчан гына елына йөз дә биш миллион тонна нефть биргән скважиналардан быел Татарстан егерме биш миллион тонна гына нефть чыгарачак. Ә утыз биш-кырык елдан соң бездә нефть чыгару бетәчәк, ди. Әгәр, акча булып, яңа технологик алымнар эзләп тапмасалар. Ә Гарәп Әмиратларында нефтьнең бер тамчысын да әрәм итмичә үз заводларында йөз төрлегә эшкәртәләр һәм аны сатып, мең тапкыр оталар. Менә шуңа күрә дә Татарстан сыман нефть өстендә утырган бу халык, әллә кайчан без кызыгып хыялланган зәңгәр томаннар артындагы коммунизмда яши. Чөнки, тулысынча, һичкемнән бәйсез дәүләт! Үзләренә-үзләре хуҗа...

— Анда Рәсәйдән бер автотранспорт, техника юк,— ди Элфәт Салахов.

— КамАЗлар дамы?

— Юк... Бары да дөнья стандартындагы беренче класслы, күзгә кебек ялт иткән Америка, Япония, Көнбатыш Аурупа автомашиналары, һәртөрле техника...

Һиндстанда эшләгәндә дә, Гарәп Әмиратларында якты Ил карап йөргәндә дә, Элфәт Салаховны берсеннән-берсе тирәнрәк уйлар борчый иде. Әйтик, нигә нефтьче-транспортчыларны җир өстенә берәр катлы гына аерым өйләр — коттеджлар төзеп яшәтмәскә, ди. Шунда җире-бакчасы булыр иде. Җиләк-җимеш, яшелчә, бәрәңге, алма-чияләрне эштән кайткач та рәхәтләнеп үзе үстерер иде. Үзе файдаланыр иде. Үзе ял итәр иде. Мунчасы йортта... Терлек-туар асраса... Әлбәттә, бүгенге кебек арып эштән кайтуга, ашыга-ашыга шәһәр читендәге ерак бакчасына чапмас иде. Рәхәтләнеп ял итәр иде кеше...

Һич югы, Элфәтнең үзе җитәкли торган: Әлмәт, Ямаш, Сәрән, Архангельск кебек УТТның дүрт базасында булса да барлык эшне компьютер системасына куясы иде...

Һәм башка бик күп уйлар Әлмәткә кайткач та Элфәт Хәертдиновичка һич тынгы бирми баш миен үтәли боргычлыйлар иде. Ник без татар халкы, рәсәйлеләр, нефть-газ, күмер-бакыр, алтын-көмеш, якут-алмаз, иксез-чиксез зур җир-

урман, тау-елгалар, диңгез-күлләр, океаннар камалышында булып та, арттa калган ил, хәерче ил булып яшәргә тиеш, ди.

...Дөрес (моңа күз йомарга һич ярамый!), «Татнефть» берләшмәсенә генераль директор булып яңа җитәкче, Әлмәт районының үз авылында туып үскән Ринат Галиев килгәч, хәлләр яхшы якка күпләп үзгәрде. «Татнефть» җитәкчелеге дә, Әлмәт шәһәре һәм район хакимияте дә, үткәндәге кимчелекләрне барлап-анлап, дөньяга яңача караштa алга таба омтылдылар.

Советлар Союзы чорында Татарстан нефтенең сиксән процентын союз суыра иде. Унсигез процентын — Рәсәй. Нибары ике процент керем акчасы, куян шулпасының-шулпасы Татарстан файдасына кала иде... Шул акчага яшәп, баеп кара менә. Тарихта билгеле шәхесләр: Чыңгыз хан, Батый хан да, үзләре яулаган халыктан ун процент кына ясак түләткәннәр. Татарстан Президенты М. Ш. Шәймиев, Югары Совет Рәисе Ф. Х. Мөхәммәтшин (Әлмәт туфрагында туып-үскән егет!), элекке Премьер-министр М. Г. Сабиров яклавы белән, «Татнефть» берләшмәсе әлегәчә күрелмәгән зур колачлы эшләр башкаруга керeште. Нефтьнең күпмедер күләмдә үзебездә артыграк калдырылуына ирешт. Әлмәттә, беренче, нефть эшкәртү заводы төзелде. Нефть продуктларын халык файдасына тота башладык. Чит илләр белән килешүләр төзелде. Дөнья базарында «кара алтын» — халык хуҗалыгында сары алтынның үзеннән дә кыйммәтрәк хәзер. Электр көче, атом энергиясе белән эшләүдән тыш, Җир шарындагы барлык машина, трактор, самолетлар, ракета, поезд, пароход, кораблар, һәммә техника, нефть продуктлары белән эшли. Нефть битумыннан башка бик эссе якта да, бик салкын кыйтгаларда да төзелеш эшләре бармый. Үзебездәге эре панельле йортларның плитә араларын ябыштыруны гына карагыз... Эсседә — эреми битум, салкында — туңмый. Табигый үзенчәлеген саклый.

«Татнефть» җитәкчелеге көче белән «Чишмә» программасы соңгы елларда бик зур эшләр башкарып килә. Нефтькә баткан, пычранган, күпме иген басулары, елга-күлләр, йөзләрчә кое-чишмәләр нефтьтән чистартылып, яңартып халык хуҗалыгына кире кайтарылды. Болар арасында «Елховой Кизләве» дә бар.

**Редакциядән.**

«Ватаным Татарстан» газетенең 16 август, 1997 ел санында куанычлы хәбәр басылып чыкты.

Россия Федерациясе Президентының 1997 ел, 7 август Указы нигезендә, нефть-газ комплексын үстерүгә зур өлеш керткән һәм күп еллар буена намуслы эшләгән өчен «Татнефть» акционерлык җәмгыятенең «Ямашнефть» идарәсенә кергән Ямаш технологик транспорт идарәсе начальнигы Элфәт Хәертдин улы Салахов-ка «Россия Федерациясенең атказанган транспорт хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

Котлы булсын!

## Г. Газиз

# ЭЧКЕ ЭМИГРАНТ

### I

Мимозалар да чәчәк атып, диңгезнең кырые сап-сары чәчәк белән тулды. Тауларда ап-ак булып миндаль агачлары да бизәлделәр. Әле генә кар астыннан чыгып, мөлдерәп утырган гөл чәчәкләре дә явуы ихтимал булган салкын карлардан котылдылар. Еракта күренеп торган карлы тауларның тирәләре дә эреп, сорылана башладылар. Әле бер атна элек кенә котырып гөрелдәгән Кара диңгез дә ике көннән бирле көлә башлады; төннәр дә ай яктысы белән балкыды, елмайды, чырайлары ачылды. Таулардан иртәләрдә хуш исләр килеп, сулышларны киңәйтә башлады. Мин дә санаторийдан күбрәк чыгып йөри торган булып, аллеяларда яшәреп утырган тузгак башлы пальмаларга сокланып, магнолияләрнең чәчәккә бөреләнә башлаганнарын карап йөри башладым.

Беркөнне Черняев тавына әкрен-әкрен генә, көчем-хәлем артканга исем-акылым китеп, менеп барадыр идем, юлда, якшәмбе булганга, күп кеше очрый башлагач, тауның бер читенә барып, ике тау арасыннан ачылган яйладагы[1] өйләргә карап утыру өчен, бер сап-сары булып чәчәккә төрелгән мимоза агачы астына барып утырдым. Гаҗәеп бу шәфкатьле җирнең җылы кояшы! Йөрәкләрне рәхәт типтерә, күңелләрне күтәрә, бары шул кояш астында гына дөньяда торуның нинди рәхәт, нинди бәхет икәнен тойдыра! Уйланып утырганда, өч бала ияртеән бер марҗа бик нәзек аваз белән:

— Саша, Саша! Без монда! — дип кычкырып җибәрде.

Нindидер миңа таныш булган бер тавыш:

— Маман, мин монда! — дип җавап бирде.

Мин бу авазның кем тавышы булганын тиз генә белә алмадым, әмма күңелемә хәзер ялт итеп, машиналь бер формада, Казанның 1909—10 нчы еллары, минем фатирымдагы тәмәке төтене эчендәге озын-озын мәҗлесләр килеп төште. Башым картиналар белән тулды. Үземнең биография бер-бер артлы күз алдыма килә башлады...

Бу вакытта дүрт-биш сажень ераклыкта яр астыннан иске генә кепка кигән бер кеше үсеп чыгып, балалар янына килә башлады... Бу кешенең камыт аягы, чыгып торган яңагы, нервлы йөреше чынлап та миңа бик таныш иде; ләкин мин аны танымадым. Чал кергән кара сакал аның яңак вә иякләрен бик ямьсез итеп каплаган иде. Ул да миңа борылып карады, бер күрешәм дип, кепкасына да кулын тидергән иде, тагын төшерде, адымнарын тизләтте, мин дә машиналь күрешә яздым...

«Кем иде соң бу? Кем соң бу? Кара әле, бу кем булырга кирәк? Бик таныш кеше ләбаса бу!» — дип уйладым. Ләкин тиз җавап таба алмадым.

«Бу камыт аяклар миңа таныш лабаса!» — дип уйладым мин. Аягүрә басып карап тордым да тагын утырдым. Тагын карадым. Бу кеше дә ялт

---

[1] Яйла — уйсулык.

итеп миңа әйләнеп карады, кырык саженьнан күзләребез бер-берләренә очрашты. Шулай итеп, без аерылыштык. Ләкин «Бу кем соң бу?» дигән сөаль мине санаторийга кайтканчы ташламады.

## II

Тыныч бер төндә, яфраклар да ярып беткән бер чакта, яп-якты ялтыравыклы чебеннәр һавада кечкенә йолдызлар кебек очканда, кичке аштан соң, верандага чыгып утырып, уйларга керештем. Инде мин, санаторийдан чыгып, бер айга тагын бу шәһәрдә ял итәргә калган идем. Әлеге киң яңак, камыт аяклар минем фикеремә килделәр...

Кем иде соң ул? 1909—10 нчы елның студент түгәрәге һәм аның әгъзалары хакында мин күп уйлана башладым. Һәрбер иптәшнең биографиясен хәтерләп, төсләрен дә күз алдыма китереп чыктым. Ничә еллар үткән бит! Егерме ел, әйтергә генә ансат! Бер кешенең бөтен бер гомере... Фатих Кәримнең «Мирза кызы Фатыйма»сын тәнкыйть иткән юрист Сафа, «Думадагы мөселман фракциясенең эшләре» турысында доклад ясаган медик Кәрим... Шуларны уйлаганда, «Милләтнең киләчәге» хакында бер озын доклад ясаган Искәндәр Салихов та күңелемә килде. Хәзер миңа теге мимоза астында күргән өч бала, бер маржалы кешенең яңаклары, камыт аягы хәтеремә килеп төште...

«Әллә шул микән? Неужели Искәндәр?»

Искәндәр, Искәндәр! Әлеге февраль революциясе чорында бик күп сөйләүче оратор, бик күп язучы мөхәррир, Учредительное собрание, Милләт мәҗлесе, Предпарламент әгъзасы, соңыннан Октябрь революциясе дәверендә безне: «Мөртәт булдылар, большевикка сатылдылар, демократиягә хыянәт кылдылар»,— дип сүккән, чехлардан соң кызыллар гаскәре керер алдыннан качкан, соңра Уфада Государственное совещаниедә бер халыкның вәкиле булып комедия уйнаган, соңыннан Себергә качкан Искәндәр...

«Үлмәгән микәнни ул?» — дигән фикер кылт итеп минем хәтеремә килде.

Һәм ничек булса да, миңа бу кешене эзләп табарга, маржасын белергә кирәк иде. Ләкин ничек табарга? Мин болай уйладым: балалары, хатыны белән бу кеше якшәмбе көн йөрергә чыккан, димәк, ул бер учреждениедә хезмәт итә. Ләкин ничек итеп аны табарга?

Ике якшәмбе чыгып, мин моны эзләдем. Тәмам гаҗиз булдым, таба алмадым. Ахыры бара торгач, адресный столга барып, Искәндәр Салиховны карадым. Юк...

Шунда утырган бер абхаз миңа бозык русча тел белән:

— Менә монда бер Салихов бар, әмма Александр Гайфуллович Салихов,— диде.

Мин шаккаттым. Күз алдымда утлар күренде.

«Булмас ла... булмас ла,— дидем үз-үземә.— Шул бит әле генә, революция алдыннан гына, үзен Салихов урынына Салихи дип йөргән, «ов» — урыс формасы, кирәкмәс, безгә иске «милли» исемнәребезне кире кайтарырга кирәк; әүвәлдә никах мәҗлесләренә чапан киеп барган төсле, «Шәрык клубы»на йөргәндә дә шул иске күркәм гадәтне терелтергә кирәк, дип безнең газеталарда, мәҗлесләрдә гайрәт орган «Салихи»ме? Булмас!»

Шулай да мин моның кайда эшләгәнен сорап, язып алдым. Салихов бер кооперативта делопроизводитель булып хезмәт итә икән... Туп-туры шунда киттем. Тар бер пычрак урамда, бер грузин шашлычные каршысында ике катлы өйнең тәрәзәсеннән карап йөри башладым. Аскы катта колагына папирос кыстырган, бармагына балдак кигән, сакалга төрелгән, чал кергән чәчле Салихов «Александр», башын кыегайтып, ара-тирә телен чыгарып алып, ордер яза. Алдына ясап

куелган стакандагы чәен дә эчеп ала. Моны күрүгә, минем күз алдыма минем нәни чакта первый частьтагы делопроизводитель Гайфулла морза килеп басты да мин уйландым.

Менә элегантный киенгән, ике тарафы кайтарылып торган ак якага яшел галстук бәйләгән, күзенә, важный күренер өчен, пенсне кигән, ямь-яшел тужуркалы, соңыннан революциядән элек юллы чалбар белән якасына университет бетергән знак таккан Салихов килеп басты...

«Сез большевик чиновнигы булырга йөрисез, революциянең зинадан туган уллары, сезнең муеныгызга җеп хәзер, милләткә хыянәт, милләт юлыннан чыккан өчен, пыр туздырырбыз»,— дип мине сүккәне, чехлар кергәч, гайрәткә кереп, мәйданда речь тотуы минем күз алдымнан уза башлады...

«Керимме, кермимме?»

Күңелемә ниндидер бер кызгану килде. «Керим, сөйләшим!— дидем.— Юк, сәгать өчтә әйләнеп килеп, урамда тоту тагын да яхшы булыр»,— дип уйладым.

Бер ресторанга барып, бик ныклап ашап чыгып килдем. Күп хезмәтчеләр чыгып беткәч, бу да, шомарып беткән таягын тотып, чыгып киләдер иде. Мин дә бераз киткәч, артыннан килеп, искечә:

— Искәндәр әфәнде!— дидем.

Искәндәр агарып китте. Белмәмешкә салынды, адымнарын кызулата төште. Мин артыннан киттем. Ялт итеп икенче бер чатка борылып китте. Мин дә борылдым.

— Искәндәр әфәнде, исәнмесез, әллә танымыйсызмы?— дидем, тәмам янына килеп җиттем.

Нишләргә дә белмәде. Курыкканы, өреккәне әллә кайдан мәгълүм иде, ләкин сынатмады, бик горурлы тавыш белән:

— Исәнмесез, сез — Гомәр Шәриф бугай! Ни йомышыгыз бар?— диде русча. Мин татарча:

— Йомышым юк, Искәндәр әфәнде, менә ни, монда ял итәргә килгән идем!— дидем.

Ул бик бозык тел белән, сүзләрне эзләп табып:

— Сез әле татарча сөйләшәсез, татар бармыни әле дөньяда?— диде.

— Сөйләшү генә түгел, язабыз, язу гына түгел, сөйлибез, сөйлибез генә түгел, укытабыз, укыта гына түгел, лекция укыйбыз!— дидем.

— Гаҗәп, сезнең тел яхшы сохраниться иткән!— диде ул миңа. Шунда ук үзенең иске сүзгә осталыгын күрсәтеп:— Соң сез кайда? Большевикның бик зур чиновнигы булдыгызмы?— диде.

Мин дә:

— Сез ничек кечкенә чиновник булган булсагыз, без дә шундый ук зур булдык, әмма чиновник түгел, Педтехникум, ягъни «Дарелмөгаллимин» мөдире — директоры булдык!— дидем...

Шулай «сер бирмәс өчен» миңа төртелгән инәләргә мин сәнәк белән җавап биреп бара-бара, без бульварга җиттек. Бер сәкегә барып утырдык. Салихов, бераз сөйләшкәч, үзен нә атачак, нә асачак, нә диңгезгә атачак түгел икәнемә ышана башлады бугай. Сөйләгәндә мөмкин кадәр, иске Сәетгәрәй морза кебек, сүзне русчага борадыр иде.

Бара торгач, мин моны дачама чакырдым.

— Әгәр килмәсәң, үзем мин сине эзләп табармын, килми калма!— дидем.

Иртәгә миңа ашарга килмәк булып, миннән аерылды.

### III

Иптәшләр, менә минем хикәямнең иң татлы җиренә килдек. Бу — XX йөзнең Робинзон Крузо хикәясенең бер сәхифәсе. Бу Робинзон нә дә, ялгыз атауга барып урнашып, вәхшиләнгән, нә дә ям-ямнар

белән сугышкан. Бу Робинзон — «психологический» Робинзон. Бу Робинзон, күңелендә большевиклар белән милләт өчен көрәшә-көрәшә, үзенең телен онытkan, морзалашкан, үлгән, беткән, бетерелгән вә, тарихның сәхнәсеннән югалып, тарихи бер сыйныф булып калган татар буржуазиясенең мәнфәгатен күңеленнән яклый-яклый, пролетариатны вәхши дип сүгә-сүгә, үзе «пролетарлашкан» бер Робинзон. Бу — революция эчендә унике ел яшәп тә, бернәрсә өйрәнмәгән, әмма һәммә нәрсәне дә онытkan бер Робинзон. Бу шундый бер җанвардыр ки, аларны геологлар бары җир астыннан, таш булып каткан килеш казып чыгаралар. Бу — бер турыдан-туры анохронизм! Менә мин шуның хикәясен сезгә сөйләмәк булам. Күңелләренә авыр булса, Робинзоннар укымаслар!

Магнолияләрнең җеп йомгагы кебек аллы-ак чәчәкләре тәмле исләрен чыгарып торган бер заманда, ямь-яшел сәрви агачлары туп-туры шәм шикелле булып күккә таба күтәрелеп торган, җиңелчә генә апрель җиле белән минем терраса алдындагы бакчадагы миләүшәләр мөлдерәп утырган чакта, террасадагы самовар янында, миңа Искәндәр әфәнде, зәпзәңгәр диңгезгә төртеп күрсәтеп, үзенең маҗараларын шулай сөйләргә башлады:

— Менә шул диңгезнең артына чыгып котылыйм, дип мин монда килеп төшкән идем, ләкин алып китмәделәр, семья да булып китте, шулай утырып калдык... Безнең идеал — демократия иде. Без кансыз революциягә чын-чынлап ышанган идек. Шунда каһәр суккан Октябрь килеп, бөтен нәрсәне җимерде. Без татарга мәктәпләр, гимназияләр, дарелмөгаллиминнәр ачмакчы идек...

— Бит инде алар ачылды лабаса, кирәгеннән артык ачылды, сезнең бер-ике гимназиягез урынына утыз ачылды... — дидем.

Салихов кызып:

— Юк, безнең теләгебез ул түгел! Без аны үзебез ачмакчы идек! — диде.

Мин дә түзмәдем.

— Әле дә үзебез ачтык лабаса... — Шул вакытта минем күңелемә бер анекдот килде; сүзне бүлеп булса да сөйләп узмый хәл юк, ахры:

— Бар иде, ди, бер мулла. Бар иде, ди, аның бер юан абыстае. Менә хәзрәтнең нәфесе аза башлаган, ди; Әмма чит хатыннар белән йөрергә ярамый, ди. Шуннан ул менә карчыгына шундый бер мәслихәт биргән, ди: син бакча эчендә беседкада ят. Мин, төнлә белән шыпырт кына тәрәзәдән кереп, синең яныңа ятармын, дигән, имеш, ди. Менә «Робинзоннар»ның, революция вакытында алынган «ирешү — достижение»ләрне аңламыйча, ләззәтле булсын өчен, тагын тарихның чыгырын артка тартып, либерализм, национализм уеннары уйнау белән хыялланулары да шуңар охшап китте...

Салихов сүзен шулай дәвам иттерде:

— Без крестьянга җир-су бирмәкче идек, Учредительное собраниегә барып, мохтарият[1] алмакчы идек...

— Боларның һәммәсе дә булды лабаса! — дидем мин.

Ләкин Салихов кызды:

— Большевик биргән җир-су кирәк түгел безгә! Сезнең ул әллә ниткән имлаларыгыз белән... — ди башлаган иде, мин аңарга латин хәрефе мәсьәләсен хәтта Төркиядә дә кабул кылганнарын сөйләдем.

— Харап эш, урыс булгансыз, Ильминскийның шәкертләре сез. Төркиядә андый эш булмас, бары большевикның ялганчы газитәләре генә язалар. Мин аларны унике елдан бирле укыганым юк; менә мин революциядән вөҗданым саф килеш саклап чыгачакмын дип монда торам! — диде.

Минем котым чыкты, мантыйк хакында уйлый башладым. Булдермичә сөйләтеп бетерергә карар кылдым.

[1] Мохтарият — автономия.

— Менә мин, чехлар кергәч, Самара правительствосына барып, аннан Колчак чыккач, бераз тартышып маташтым, соңыннан мобилизовать ителеп, аның гаскәрендә продовольственный отделда бераз эшләп, «Сәфарәт һәйяте» белән Япониягә, аннан Истамбулга барып, инглизләрнең Деникинга корал китерә торган бер пароходына утырып, тагын Россиягә килеп төштем. Бервакыт тәмам аптыраштa калдым. Күңелемә шөбһә дә килә башлды, чөнки Деникинның да, Колчакның да һәм башка «правительстволарның» да «безгә» начар караганлыкларын күрдем. Ләкин үземне көчләп тыйдым. Элек бер дошманны бетереп, соңра икенчесенә ябышырга кирәк икәнен «демократия» сөйләп торадыр иде. Шуннан мин каты рәвештә тиф белән авырып киттем. Бары Деникинның бөтен гаскәре тар-мар килеп чиккәндә, мин дә чигеп, бу шәһәргә кадәр ач-ялангач, җәяүләп килдем. Бу эшләр һәммәсе дә милләт өчен иде. Әмма бу шәһәргә кызыллар якынлаша башлагач, бөтен офицер, солдат, казак пароходларга менделәр, киттеләр... Мине, Учредительное собрание членын да, алмадылар... Менә мин шунда калдым. Шул ыгы-зыгы булып торган чакта, актык пароход киткәндә, бульварда елап утырган бер кызны күрдем. Янына бардым. Кулында бер сумкадан башка нәрсә юк. Бу кыз безнең Казан помещикларыннан мәшһүр епископ Алексейның сеңелесенең кызы, имеш. Анасы пароходка менә алган, әмма бу керә алмаган, пароход киткән дә барган.

— Менә тәкъдирнең ирониясе! — дидем мин.

— Да, ирония! Белештем, таныштым. Фатирыма алып кайттым... Өйләндем. То есть, чиркәү никахы түгел, чөнки мин — принцип кешесе. Ул да мөселман булырга риза булмады... Балалар булды... Менә мин шул көннән бирле монда торам... Үзем монда торам, әмма йөрәгем тегендә... Мин хәзер һаман искене һәм киләчәкне уйлап торам, көтеп торам. Мин асла татар гәзитен, синең большевик гәзитләреңне укымыйм, укырга да теләмим... Мин милли сафлыкны саклыйм; сезнең кебек сатлыклар хакында да уйламыйм, күрәсем дә, күрешәсем дә килми. Сафлык, вөҗдан саклыйм.

— Алай булгач, син чын-чынлап эчтән рухани эмигрант икәнсең,— дидем.

— Вот-вот. Мин бервакытта да үземне Советская Россиядә дип хисап кылмыйм. Иске урыс китапларын укыйм. Яңалардан бары Шульгин, Витте, Родзянколарның мемуарларын укыдым.

— Соң синең идеалың нәрсә? — дидем.

Миңа шулай җавап бирде:

— Яңадан башлау. Элек менә тарихның көпчәген бер артка таба әйләндереп җибәреп, тагын бер хәрәкәт ясау, үзебезнең Беренче, Икенче мөселман съезды, голәмә «нәдвәсе»[1] карарларын җиренә җиткерү. Менә безнең милләт каршында бурычыбыз! Безнең идеал — һәр авылда бер мәчет, бер мәктәп! Ләкин акрынлык белән. Казанда, Уфада, Кырымда берәр гимназия; хөкүмәткә министрлар правосында бер вәзир сайлау ки, турыдан-туры җөмһүрият башлыгы яисә патша белән сөйләшә алсын... Инде ул форма правлениене Учредительное собрание тәгаен кылыр. Әгәр мөмкин булса, милли-мәдәни мохтарият, әгәр мөмкин булмаса, широкое земство, солдатларга дуңгыз ите ашатмасыннар һәм, намаз укырга ансат булсын өчен, аерым мөселман полклары ясау; байларыбызны милләткә иганә кылырга өйрәтү; бер милли банк ачып җибәрү. Әле синең белән сөйләшкәч, рәхәтләнеп киттем... Ә, аны да оныткaнмын икән әле: имланы боза башлаганнар иде... Без һичбер вакыт мөселманнарны берберсеннән аера торган имлага разый түгел; инде һаи-рәсмия кергән иде, аны чыгарып булмас! Безгә театр салырга да акча җыярга кирәк булыр... Булмаса, Казан, Уфа, Оренбур кебек шәһәрләрдә берәр театр арендовать итеп торырга кирәк булыр. Ул попларга да ирек бирмәскә кирәк: без

[1] Нәдвә — киңәшмә, җыелыш, съезд.

миссионерлар, «Святой Гурий обществосы» белән дә көрәшүне алып барачакбыз...— дип үзенең сәяси программасын озак итеп сөйләде.

Моңарга ни әйтмәк кирәк инде..

**ИСКӘРМӘ**

Г. Газиз (Газиз Салих улы Гобәйдуллин) татар дөньясында кыска хикәяләр остасы һәм күренекле галим булып танылды. Беренче рус революциясеннән соңгы елларда аның күлке хикәяләре матбугатта бик еш басыла. Алар тормыштагы тискәре күренешләрне, нигездә, әхлаксызлыкны «көйдерәләр». Бу җәһәттән аның «Исерек» һәм «Җомга көн» исемле кыска әсәрләрен күрсәтү дә җитә.

Татар, гомумән, төрки халыклар тарихын һәм Русия тарихын, татар әдәбиятын һәм аның тарихын Г. Газиз (1887—1938) Казан университетында укыганда ук тирәнтен өйрәнә. Аның тарихи хезмәтләренең бер өлешен 1989 елда Татарстан китап нәшрияты «Тарихи сәхифәләр ачылганда» исемендә аерым китап итеп бастырды.

Язучының гадәти көнкүрешнең вак мәсьәләләре турындагы хикәяләрендә дә җәмгыятьтәге тискәрелекләргә ишарә бар. Кайчакта мондый кинаяләрне укучы үзе уйланып аңларга тиеш була.

Заманчалыгын бүген дә югалтмаган «Эчке эмигрант» исемле хикәя 1929 елда Бакуда языла, Г. Газизнең 1930 елгы җыентыгында басыла. Әсәр язучының 1958 елда Татарстан китап нәшрияты чыгарган «Хикәяләр» исемле җыентыгына (төзүчесе Рашат Гайнанов) кертелә. Журнал өчен текст шушы китаптан алынды. Телгә сак караучы Г. Газиз «Эчке эмигрант»та, башка хикәяләреннән аермалы буларак, русча сүзләрне шактый куллана. Моның исә геройның кемлеген ачу өчен кирәклеге ансат аңлашыла. Димәк, әлеге сүзләрне алыштырырга кирәкми, ә төп нөсхәдәгечә калдыру дөрес.

Әсәрне журналда бастыруга
**Мәгъсум ХУҖИН** әзерләде.



**Рашат Низами**

# ПРОЗА ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

Бүгенге прозабыз ни хәлдә?

Бик зур һәм житди сорау бу, билгеле. Моңа тулырак, тәфсиллерәк җавап бирер өчен тулы бер махсус фәнни хезмәт язу сораладыр, мөгаен. Мин бу кадәр үк зур җаваплылыкны үз өстемә алырга җыенмыйм. Ләкин кайбер фикерләрне, күзәтүләремне әдипләр белән дә, әдәбият сөючеләр белән дә ихластан уртаклашасым килә. Чөнки бу җәһәттән куанычлы тойгылар да, борчылырлык мәсьәләләр дә җитәрлек.

Әдәбият ул — тормыш көзгезе, дибез. Дөреслеккә шактый гына туры килеп тора бу билгеләмә. Чынын язсак та, күпмедер дәрәҗәдә хыял-сурәтләр катламын китереп кушсак та, ахыр чиктә барыбер безнең реалистик заман, безнең сулышъяшәеш, безнең уй-гамьнәребез ак кәгазь битләренә кайтарылып төшә. Табигатьтә талант һәм сизгерлек дигән нәрсә сирәк, бик сирәк кешеләргә генә бирелә — моны аңларга кирәк. Хакыйкать бар ул һәм һәрвакыт булачак. Аны халыкка кемдер әйтергә, җиткерергә, аңлатырга тиеш. Әдипләр җилкәсенә әнә шундый мактаулы һәм җаваплы миссия салынган. Бу очракта ул иң әүвәл художестволы сурәтләү көченә, аның могҗизалы серләренә, шәхси тәҗрибәсенә таяна ала.

Тормыш һәм әдәбият — аерылгысыз. Илдә нинди җилләр исеп торса — татар, урыс яисә дөнья әдәбиятымы ул — һәммәсе, тормыш елъязмасы булып, язучылар иҗатына бәреп-саркып керә. Әллә кайларга китмичә, Джек Лондон әсәрләрен, Шолоховның «Тын Дон»ын яисә Галимҗан Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр»ен генә хәтерлик. Никадәрле язмышлар, бәрелешләр, фаҗигаләр, дәверләр давылы!..

Хаклы рәвештә горурланырга мөмкин: татар әдәбиятының тарихы бик еракларга барып тоташа. Поэзия исә чәчмә әсәрләрдән булсын, төрки халыклар арасында менә дигән классик җәүһәрләребез белән без инде әллә кайчан үзебезнең мәртәбәле урынны яуладык. Болар бит — үткәндәге хәзинәләр. Ә бүгенге татар прозасы үзенең өр-яңа үрнәкләре белән мактана алмыймени соң? Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев, Нурихан Фәттах кебек әдипләребезнең соңгы ун-унбиш елда иҗат иткән әсәрләре — вакыт сынавын узган, тарихта калырлык, картаймаслык әдәби сәхифәләр.

Яшерен-батырын түгел: күпмедер дәрәҗәдә өстән кушылганча, совет заманында күп кенә әдипләребез, нигездә, социалистик реализм дигән метод белән эш иттеләр. Хәзер инде моны кайберәүләр гаепләргә тырышалар... Җиз иләктән үткәрик әйдә — шул заманның көчле, затлы, художестволы әсәрләре рухи яшәешебез мәйданында үз урыннарын таптылар лабаса. Фатих Хөснинең «Йөзек кашы», Габдрахман Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр», Аяз Гыйләҗевнең «Өч аршын җир», Гариф Ахуновның «Идел кызы», Мәхмүт Хәсәновның «Язгы аҗаган» әсәрләрен искә алу гына да җитәдер. Димәк, хикмәт нинди метод белән язуда түгел, ә бәлки әсәрнең эстетик-художество тәэсир итү көчендә, аның халык күңеленә, халык язмышына никадәр якын торуында икән.

Заманнар үзгәрде, җилләр дә бүтәнчәрәк исә башлады бер заманны...

Гаҗәп хәл бит: әдипләрнең кул-аягын бәйләп торган цензура бетерелде көннәрнең берендә! Сталин режимы тегермәнендә татарның да бик күп әдәбиятсәнгать әһелләре кырылганнан соң менә сиңа хөррият — яз, иҗат ит, күңелеңдәге

сызлануларны ачыктан-ачык әйтеп бир, туганкай! Тоталитар система, демократия дигән битлек киеп, йөзен үзгәртте: алга таба синең бер генә хәрефеңне дә, бер кәррә сулышыңны да бизмәнгә салып үлчәмәячәкләр. Әйдә язып кара, уй-фикерләреңне теләгәнеңчә чәчеп сал, янәсе...

Фатих Әмирхан сүзләрен бераз үзгәртебрәк әйтсәк, никадәр контраст: күңелләргә ирек килде, ләкин кулдан каләм төште!

Ни өчен шулай булды соң?

Моның житди генә сәбәпләре бар.

Беренчедән, тыелган ризык татлы дигәндәй, тыелган темалар һәркем өчен дәррәү ачылып китте. Монда инде яңа сүз әйтер өчен ифрат дәрәҗәдә сизгерлек, зур, ачы тәҗрибә кирәк иде. М. Мәһдиев, А. Гыйләҗев, И. Салахов кебек мөхтәрәм әдипләр, шөкер, әйтәсе сүзләрен вакытында әйтеп өлгерделәр. Тормыш тәҗрибәсе ягыннан кайтышрак, ягъни яшьрәк буынга исә әлләни әйтер сүз калмады шикелле.

Икенчедән, кача-поса гына дигәндәй, читләтеп кенә сүз әйтүгә, кинаяле фикер уйнатуларга урын калмады. Каләм әһелләре өчен элегрәк моның үзенә күрә бер сере-тылсымы бар иде ул чакта (хәтта рухи оппозиция дип әйтергә мөмкиндер...) Ә инде уй-фикерләреңне ачыктан-ачык маңгайга бәреп әйтү — бер караганда, әдәбият өчен күңелсезрк нәрсә. Менә шуңа да беренче елларда күп кенә язучылар җыйналып килгән «пар»ны дөньяга публицистик мәкаләләр аша бушаттылар.

Өченчедән, капитализм ясыйбыз дигән булып, безнең әйле-шәйле җәмгыятебез күз ачып йомган арада кыргый базар мөнәсәбәтләре җәтмәсенә килеп эләкте! Социализмга хас яхшы мәгънәсендә тигезлек (уравниловка) бетте. Кем ничек, нәрсә булдыра ала — үзенә күрә кыргый бер иркенлеккә, эшмәкәрлеккә юл ачылды. Билгеле ки, мондый чакта, талантлар белән бергә, әрсезләр, графоманнар да күкрәк ерып алга бәреп чыга. Спонсорларын да бик оста таба беләләр. Менә шушы җирлектә байтак кына калын-калын китаплар да чыгып өлгерде. Талантларның күбесе исә куркып-каушап калды: язар идең, язган әйбереңеллар буе тозланып, тузан җыеп ятарга мөмкин. Ә яшәргә, гаиләң була, аның арбасын тартып барырга кирәк.

Дүртенчедән... Бишенчедән...

Саный китсәң, тагын әллә ничаклы эреле-ваклы сәбәпләр табарга мөмкин.

Ләкин зарланырга, моңаерга ашыкмыйк әле, дусларым.

Халык, милләт бар чагында аның әдәбияты беркайчан да сүнми, югалмый. Татарның озын гомерле, төп калын журналы «Казан утлары»нда унбиш еллап эшләү тәҗрибәсеннән чыгып әйтә алам: әдәби журналыбызда проза әсәрләренә элегрәк тә, хәзер дә беркайчан кытлык булмады! Дөрес, художество-эстетик кыйммәте тиешенчә булмаганлыктан, аларның байтагы дөнья күрмичә дә калды. Ләкин, авторының кем булуына карамастан, иң яхшы, иң саллы дигәннәре укучылар хөкеменә һәрвакыт тәкъдим ителә килде. Бу очракта исем-фамилияләр санау белән мавыгасым килми, әдәбият сөюче дусларыбыз моны үзләре болай да яхшы хәтерлиләрдер. Шулай да, прозабыздагы яшь һәм яңа автор буларак, Зөлфәт Хәким исемен әйтеп китми мөмкин түгел. Ул «Гөнаһ» дигән романы белән укучылар арасында шактый зур популярлык казанды. Фәлсәфи уйланулар, психологик эзләнүләр җәһәтеннән кызыклы әсәр. Детектив жанрга да тартым үзе. Хәер, моннан күпкә алдарак Ринат Мөхәммәдиев «Кенәри — читлек кошы», Тәлгать Галиуллин «Тәүбә» дигән романнары белән татар укучысына детектив жанрның нәрсә икәнлеген уңышлы рәвештә танытып өлгергәннәр иде инде.

Шиксездер ки, прозаның колачы киң булырга тиеш. Халык язмышын, ил язмышын бигрәк тә эпик әсәрләр тирәнрәк чагылдыру мөмкин. Татар прозасында, һәрхәлдә, татарның ачы язмышы ярылып ята. Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Ш. Камал, Г. Ибраһимов әсәрләрен генә искә төшерик... Алар үз чорын, шул заман кешеләрен художество чаралары ярдәмендә теркәп-тасвирлап калдырганнар.

Ни генә әйтсәң дә, тарихта татар дигән гайрәтле халык бар.

Гайрәте сүнгәнме, юкмы аның, әмма татар бүгенге көндә дә яшәп ята, эшли, төзи, иген ура, әүкәтле заманнарын кайтармак була. Төрле сәбәпләр аркасында заманында дәүләтчелеген югалткан ул, сынган-сындырылган, әллә ничаклы сират күперләрен кичкән. Арада сатылучылар, коллыкка, манкортлыкка риза булучылар да табылган. Ләкин тамыр таза икән: татар бүген дә бар, исән! Ул әнә суверенитет игълан итә, мөстәкыйльлек даулый, килер көннәр күкрәгенә чакыру ташлый...

Без бит күбебез, бик күпләребез шушы вакыйгаларның, кайнар көннәрнең шаһите булдык.

Татар уяна... Инде дә йомшаграк итеп әйтсәк, күп гасырлык йокысыннан уяныргa тырышмакчы була.

Һәрхәлдә, милләтебез өчен бик тә җаваплы, тарихи мизгел килде.

— Менә шушы кузгалыш-күтәрелеш ни өчен хәзергә кадәр безнең прозабызда чагылыш тапмый соң? Юкса бик тә вакыт иде шикелле. Дөрес, милли хәрәкәттә, татар халкының язмышын тирәнтен аңлауда шәхси тәҗрибәсе бик аз булган яшьрәк автор Мансур Шаһимәрданов «Кеше күңеле — карурман» дигән повестендә ничектер шушы мәсьәләләрне күтәрмәкче, тасвирламакчы була. Нишлисең бит, өстән-өстәнрәк шуып уза, күңел сизгерлеге һәм тасвир кодрәте җитенкерәми егетнең бу өлкәдә.

Безнең халык сибелгән, чәчелгән, дибез... Моны талант иясе Мәхмүт Галәү «Мөһаҗирләр» романы аша бик оста күрсәтеп-тасвирлап биргән иде инде заманында. Сибелү-чәчелү фаҗигасе бүген дә дәвам итә. Бармы бүген әдәбиятта моны тасвирлаучы, бармы бу хакта борчылып чаң кагучы? Хәзергә мисаллар китерү кыен.

Тарихта татар язмышы фаҗигале, канлы сәхифәләрдән тора. Табулар да, югалтулар да бихисап безнең. Дәүләтчелегебезне кайчандыр югалткансың икән, хәзер аны сагынып, тезеңне кочаклап утырудан ни файда? Эш, хәрәкәт, гамәл, шуларга өстәп иң мөһиме — бердәмлек кирәк. Соңгы елларда милли хәрәкәтебезнең бик көчәйгән чаклары булды. Әмма хәзер ул сүрелеп, сүлпәнәеп калды. Боларны анализлау — максатым түгел. Ә шулай да иң зур сәбәпне әйтми китми мөмкин түгел: без — татар халкы, Татарстан Республикасы — гомер буе сугышып, талауга, басып алу психологиясенә, шовинизм сөременә баткан Россиянең «ашказаны»на, геополитик яктан кыл уртасына килеп эләккәнбез. Хәлебез аяныч: тик торсаң — бер читен, чын-чынлап ирек даулый башласаң, тагын да зуррак кыенлыклар, киртәләр калкып чыга алдыбызда...

Менә шушы фаҗигане художестволы, панорамалы рәвештә яктырткан милли романны бик тә сусап көтеп тора татар хәяте! Оят булса да әйтик, бездән, безнең буыннан булмады бу. Бәлки, киләчәк буын талантлары менә шушы изге эшне башкарып чыга алырлар? Ркаил Зәйдулла әнә «Салават күпере» журналында балаларга татар хәяте, татар ханнары хакында нәни генә язмалар биргәләп куя. Ләкин болар — диңгездән бер тамчы гына.

Прозабызның киләчәге дигәндә, мине борчыган тагын ике нәрсә бар әле. Берсе — прозаның юашлыгы, үшәнлеге. Өр-яңа уйлар, фикер кылычларының ялтырап-чәкәшеп китүләре әлләни күренми. Юкса, минем уйлавымча, әдәбият тормышның үзенә караганда бер адым алдарак атлап барырга тиешле. Гаяз Исхакый әнә үзенең «ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәре белән безнең бүгенге вәзгыятебезне әллә кайчан кычкырып әйтеп бирә белгән! Шуңа Исхакый атлы олпат шәхес, талант иясе бит ул.Икенче мәсьәлә — татар әдәбиятына чит өлкәләрдән килүче яшьләрнең сирәкләнүе. Такташ — Тамбовтан, Муса Җәлил — Оренбурдан, Кави Нәҗми — Сембер өлкәсеннән һ. б. Хәзер исә мондый да киң географик «агым»ны күз алдына китерү дә кыен. Чөнки коммунистик совет заманында милли мәктәпләр, бу очракта татар мәктәпләре дип әйтик, төбеңәчә ябылды. Урыс телендә укыту мәҗбүри төс, өстенлек алды. Туган телендә укымаган, сөйләшмәгән бала ничек инде ана телендә шигырь яисә хикәяләр язсын да, ничек инде татар әдибе булып китә алсын икән! Саный китсәң, тагын әллә ничаклы сәбәпләрне өстәргә мөмкин.

Югалтуларның тамыры әнә кайларга барып тоташкан.

Әмма...

Халкыбыз бар, аның бай традицияле әдәбияты бар. Уйлап карыйк әле: әгәр татар әдәбиятының вакыт сынавын узган кайбер классик әсәрләрен Европа яисә Америкада бастырып чыгарсалар, алар безнең чәчмә әсәрләрне ничегрәк кабул итәрләр иде икән? Шикләнмим, һәрхәлдә, тәэсирләр бары тик «әйбәт» дигән мөһер белән бәяләнер иде.

Ике-өч елдан без инде Яңа гасырга — 2000 нче елга аяк басачакбыз. Бөтен галәм белән. Кешелекнең шушы ташкынында, шөкер, татар халкы да бар, туган телебез бар. Менә шушы чынбарлык безнең күңелләргә ышаныч һәм иман нуры иңдерә.

Татар әле яшәр!

Без яшәргә һәм сынатмаска тиеш...

## БАТЫР ЯУДА БЕЛЕНӘ



*Кемнең кем булганын вакыт кына билгели ала. Оренбург өлкә дәүләт архивында бер вакыт кызык хатка юлыккан идем. Г. Ибрагимовның революциягә кадәрге бер хатының жандарм бүлеге фондында саклана торган русчага тәрҗемәсе ул. Сабакташ дусты, фикердәше Хәлим Искәндәревкә язган, үзенчәлекле фетнәчелек хаты. Алар «Йолдыз» газетын кулга төшерү турында киңәшләшәләр. Г. Ибрагимов дустын Казанга чакыра. «Йолдыз»ны Һади абзыйдан (Максудидан) тартып алып, үз гәзитебез итәбез. Син — тәнкыйть бүлеген җитәкләрсең,— ди,— әнә, «Вакыт»та Җәләй (Җамал Вәлиди) ничек үсеп китте. Син бит Җәләй ише генә түгел...»*

*Әйе, Җамал Вәлидине «Вакыт» үстерә. Ф. Кәрими, Р. Фәхретдиновлар даирәсе. Оренбургны мәдәни тормышыбызның Казан дәрәҗәсендәге матбугат һәм иҗат учагына әйләндергән Дәрмәнд «академия»се.*

*Ә кемнең «кем ише генә» булуы каршылыклар утлы күмерендә ялкынландырылып, вакыт сандалына салып чүкеп сынала. Мәдрәсәдән чыккач, хәерле язмыш Җ. Вәлидине дә Дәрмәндләр, Ф. Кәрими, Риза Фәхретдиннәр даирәсенә китереп кертә. Ул «Вакыт» гәзитендә эшли башлый. Җитди әдәби-тәнкыйть мәкаләләре белән чыгышлар ясап, күренекле тәнкыйтьче булып җитешә. Яңа татар әдәбиятында беренчеләрдән буларак, әдәбият тарихын язу юнәлешендә җитди адым ясый: 1912 елда инде «Татар әдәбиятының барышы» дигән китап чыгара. Әдәбият хәзинәсе, әдәби мирас турында хуҗаларча борчыла белә. Г. Тукай вафат булганнан соң, аңардан калган барлык язмаларны саклап калып, әзерләп матбугатта чыгарырга дип, ул, «Вакыт»тагы күнегелгән һәм дәрәҗәле эшен ташлап, Казанга күчеп килә. Әмма, шундый актив тырышлыклар күрсәтүгә дә карамастан, Тукай мирасы да татар кульязма әдәбиятының гомуми фаҗигасыннан котылып кала алмый. Сугыш, революция аларны матбугатта бастыру мөмкинлеген юкка чыгара, соңрак Җ. Вәлиди үзе кулга алына. Караңгылык көче йокламый,— шул конъюнктурадан файдаланып, Тукай мирасының дә күлен күккә очыра.*

*...Әйе, революцияләр тормышның астын-өскә китерә. Гражданнар сугышы, хокуксызлык, хәрби коммунизм... Күз алдына китерү дә мөмкин булмаган бәлгенлекләр... Дәһшәтле ачлык... Ләкин бу дәһшәтле давыллар да Җ. Вәлидине какшата алмый. Ә менә кайбер талант ияләре үз талантының күзен бәйләп, хакимияткә ярарга тырышып, эпигонлык юлына баса.*

*Түбәндә укучылар игътибарына тәкъдим ителә торган мәкаләләрдә Җ. Вәлиди Совет хөкүмәтендә (Милләтләр эшләре Халык комиссариатында), В. И. Ленин тирәсендә, Сталин янында эшләгән, шуның белән гавам һәм ул чор җәмәгатьчелек карашында, революция һәм Совет хакимиятенең гәүдәләнеше диярлек булып калган Г. Ибрагимовның үзенә каршы аваз күтәрә. Җ. Вәлиди аның ялгыш карашмөнәсәбәтләрен кире кагып, тулаем әдәби мирасыбызны һәм аерым алганда Г. Исхакыйлар әдәби мирасын саклау, яшәтү өчен көрәш сызыгына баса. Бүгенге ераклыктан караганда без нәкъ менә Җ. Вәлидинең бу бәхәстә хак булганын, дөреслек ягында торганын күрәбез. Тәнкыйтьченең бу чыгышын гражданлык батырлыгы дип бәяләп була.*

**Мәсгуд ГАЙНЕТДИН.**

# ӘДӘБИ МӨСӘХӘБӘ

*Защитник вольности и прав*
*в сем случае совсм не прав.*
*Пушкин.*

Галимҗан иптәш Ибраһимовның Рәшит казый хакында язылган мәкаләсен укыдым. Галимҗан иптәш бабай хакында бик матур вә бик туры бер характеристика биргән. Ләкин ул актыкка таба үзенең яза торган төп зур юлыннан әллә кая читкә кереп китеп, шактый гына адашып алган. Менә монда безне туктата торган нокта да шушы адашудадыр.

Галимҗан иптәш бик аз бер мөнәсәбәт белән «Мулла бабай», «Тормышмы бу?» кеби әдәби әсәрләргә тукталып, аларны «Фазаиле шөһүр», «Кызыл алма»лар белән бер рәттән санап китә, «Бәдәвам»ны укучы карчыклар бетмәгән кебек, бәлки «Тормышмы бу?»дан мәгънә эзләүче карт хәлфәләр әле дә андамонда бардыр, ди.

Мин үзем дә шул «Тормышмы бу?»лардан мәгънә эзләүче бер «карт хәлфә» булганлыктан, бу турыда үз фикеремне әйтеп китәргә мөнасип күрдем. «Карт хәлфә»нең фикерендә, әлбәттә, яшьләр өчен шул кеенчә үрнәк булырлык фикерләр булмас, ләкин ул, һич булмаганда, бу мәсьәләнең күтәрелүенә, иләнүенә, бу хакта тәнкыйть вә мөхәкәмәгә юл ачар. Юкса мондый бер мөһим мәсьәләнең болай сүз арасында кузгалып калуы белән генә канәгатьләнеп калырга ярамый. Бу — татар әдәбиятының хаят, мәмат мәсьәләсе.

Мин уйлыймын ки «Тормышмы бу?»лардан мәгънә эзләп маташучылар арасында безнең кебек «карт хәлфә»ләр генә түгел, бәлки бәгъзы яшь мөгаллимнәр, яшь шәкертләр дә бардыр. Бәлки аларны да Галимҗан иптәшнең язганнары беркадәр аптыраштa калдыргандыр.

«Тормышмы бу?», минем үз карашымда Гаязның әсәрләре арасында иң өстен торганнарыннандыр. Монда реальный тормыш гаять куәтле вә ялкынлы бер шәхси тойгы белән яктыртып мәйданга чыгадыр. Шуның өчен моны «Фазаиле шөһүр»лар белән бер рәттән йөртү татар әдәбияты мөхибләренең йөрәкләрен әрнетәчәк вә аларны шашырып калдырачак бер хәлдер. Садә күңелле бер әхлакчылык белән язылган «Кәләпүшче кыз» һәм «Өч хатын белән тормыш» хакында сүз барса, тагын бер хәл иде. Әмма «Тормышмы бу?» кеби тирән мәгънәле, матур телле, бай тасвирлы, чын мәгънәсе белән современный булган бер әсәр хакында мондый сүзләр әйтеп ташлауга нинди мәгънә бирергә кирәк? Әгәр «Тормышмы бу?» вакыты үткән мәгънәсез бер нәрсә булса, Толстойның «Исповедь» һәм «Воскресение»ләренең дә рус әдәбиятындагы мәгънәләре шулай булырга тиеш иде. Аннан соң әле матбугатка чыгып бетәргә дә өлгермәгән «Мулла бабай» кай арада модадан чыгып, мәгънәсез бер нәрсә булып киткән? «Мулла бабай» кеби татар иске тормышының бөтен ягын кочаклаган, һәр төрле типларга, табигать тасвирларына гаять дәрәҗәдә бай булган татар әдәбиятының мәңгелек кыйммәтле хәзинәсе булган олуг бер диңгез хакында мондый сүзләр язу, минем карашымда, татар әдәбиятын бөтенләй инкарь белән бәрабәрдер. «Шәкерт абый» «порнография» икән, моның бу җәһәттән яңа гына «Ярдәм» мәҗмугасында чыккан «Гайния»дән нинди аермасы бар? Тегенең ни өчен мәгънәсе калмаган да, бу бик мәгънәле булган?

Әдәбиятка бер төрле караш, газетага яки календарьга караган шикелле бер караш була түгелме соң? Теге начар, чөнки былтыр язылган, ә бу шәп, чөнки быел гына чыккан: юкса Гаязның соңгы татар әдәбиятының нәмунәсе булырлык әсәрләрен «Кызыл алма» китаплары белән бер рәттән санауның мәгънәсе нәрсә? Галимҗан иптәш кеби үзен игътибарлы бер тәнкыйтьче итеп танытхан кешенең тар фикерлекне бу дәрәҗәгә җиткерүе соң дәрәҗәдә көенечле бер хәлдер. Өсләренә яшьләрне тәрбия кеби мөһим бер вазифа йөкләнгән икән, әдәби Извращение белән шөгыльләнүдер.

Галимҗан иптәш шаят бу мәсьәләне болай кузгатып кына калдырмас, бу тугрыда әтрафлы изахәт бирер вә безне хәйран булып торудан коткарыр.

**Җамал ВӘЛИДИ.**

*«Татарстан хәбәрләре», 5/III — 1922, № 54 (431)*

# Аңларга тырыштык, аңлый алмадык

*(Галимҗан иптәш Ибраһимовка җавап)*

Галимҗан иптәшнең «Татарстан»да, № 56, миңа җавап буларак язган «Аңларга тырышыгыз» дигән мәкаләсе чыкты. Укып мәмнүн булдым. Мәсьәлә торган саен киңәя. Миңа да бу мөһим мәсьәлә турысында әйтелеп бетмәгән фикерләрне әйтергә юл ачыла.

Иң элек Галимҗан иптәшнең мәкаләсендә дикъкатьне җәлеп иткән нәрсә әдәбиятны дәверләргә аеру турысында булган шаблончылыктыр. Ысулы җәдидә дәверендә чыккан әдәбиятның һәммәсен бергә куеп, аларны, бер яктан, иске «Бәдәвам», «Тәки гаҗәп»ләргә, икенче яктан соңгы революция дәвере әдәбиятына каршы кую, мәсьәләне аз гына җентекләп караганда да әсассызлыгы күренеп тора торган бер нәрсәдер.

Галимҗан иптәшнең җәдит дәвере әдәбиятына мисал итеп китергән әсәрләре арасында әдәби кыйммәтләре җәһәтеннән генә түгел, шәкел вә стилләре һәм рух вә мәгънәләре ягыннан да бер-берсеннән шул кадәр ерак нәрсәләр бардыр ки, аларны «җәдит әдәбияты» дип кенә бер почмакка ыргытуга аз гына әдәби зәүкы булган кеше дә разый булмас. Мәсәлән, Фатыйх Әмирханның әсәрләре Риза казый хикәяләренә караганда революция дәвере әдәбиятында булган Галимҗан Ибраһимов әсәрләренә күп якын торадыр.

Бу җәһәттән Гаяз үзе дә икегә бүленәдер ки, аның башта төче әхлакчылык рухында язылган «Тәгаллимдә сәгадәт», «Кәләпүшче кыз» һәм «Бай углы» кеби әсәрләре белән соңгы вакытта чыгарган «Тормышмы бу?», «Мулла бабай», «Сөннәтче бабай»лары кеби реальный тормышны тасвир иткән әсәрләре арасында җир белән күк аермасы кадәр аерма күренәдер. Бу соңгыларда нинди булса да мәгълүм бер фикер, фәлсәфә сатылмый, тормыш шул булган көйгә тасвир ителә. Аларның әдәби кыйммәтләре дә шунда һәм аларның бер дәвердә мәгънәле булып та, икенче дәвердә мәгънәсез булулары мөмкин түгел. Риазиаттәге (математикадагы) хакикәтләр фикер үзгәртүгә карап үзгәрмәгән ике җирдә ике революционер каршында да, революционер булмаган кеше каршында да һаман дүрт булган кебек, әдәбиятның мондый ялангач хакикәтләрдән гыйбарәт булганнары, фикерләре, дөньяга карашлар үзгәрүгә карап үзенең иске кыйммәтен, мәгънәсен югалтмыйдыр. Әгәр дә бу мисалда ифратка кителгән дисәгез, тагын да якынрак бер мисал китерик.

Мәсәлән, бер шагыйрь иртәнге таң ату манзарасын тасвир итеп бер шигырь язды яки бер рәссам шуның рәсемен төшерде.

Менә боларга бер бәһа куйганда һичбер кеше бу әсәрләрнең революционныймы, түгелме икәнлеген тикшермичә, фәкать сәнгать таләпләрен үтәгәнме, юкмы икәнлеген генә күздә тотачагы бик билгеле бер хакыйкатьтер.

Әдәбиятта сәнгать өченме, түгелме дигән бик иске бер бәхәс бар. Монда без хәзер шул мәсьәләгә килеп төртеләбез.

Мин бу кечкенә мәкаләдә бу турыда үземнән бер нәрсә дә әйтмичә, Галимҗан иптәшнең бу турыда үзен тыңлауны муафыйк күрәм. Ул үзенең «Аң альбом»ында нәшер ителгән бик мөһим мәкаләсендә бу турыда шушы мәфһүмдә бер нәрсә яза:

«Сәнгать сәнгать өчен түгелме? бәхәсе үзе мәгънәсез бер бәхәс булып, мәсьәләгә һичбер болай килергә ярамый. Әдәби әсәрләрнең кыйммәте монда түгел, бәлки хакикәтне дөрес иттереп, матур иттереп күрсәтүдер» ди.

Шулай итеп Галимҗан иптәш реализмны үзенең соң чигенә житкерә торган бер фикер әйтә.

Аннан соң шул ук Галимҗан иптәш бер вакыт кайдадыр, хәтеремдә калмаган, Гаяз хакында язган бер мәкаләсендә «Ике йөз елдан соң инкыйраз»га зур әдәби кыйммәт биргәннән соң, Гаязның соңгы вакытта «Солдат», «Алдымбирдем» кеби революция тәэсирендә язган нәрсәләрен яратмаган, Гаяз үзенең чын сәнгатькәрлеген югалтты, вакытлы фикерләргә бирелеп, агитация эшенә кереште» мазмунында язган иде.

Хәзер шул Галимҗан иптәш шуңа капма-каршы булган фикерләр белән мәйданга чыга. Дөрес, Галимҗан иптәш монда үзен йоларга тырышачак, мин «Мулла бабай»ларны бөтенләй кыйммәте беткән нәрсәләр дип әйтмим, алар үзләренең тарихи әһәмиятләрен югалтмыйлар, алар хрестоматияләргә керәләр диячәк. Ләкин мәсьәлә шунда, иң элек боларда нинди мәгънә югалсын? Тукайның «Таң» шигыре миңге искерми, миңге мәгънәсен югалтмый торган бер әсәр булган кебек, Гаязның мәзкүр әсәрләре дә андый югала торган бер нәрсәгә малик түгелләр. Болар публицистика түгел, гыйльми әсәрләр түгел. Шуның өчен Рәшит

казыйның вакыйган дә артта калган, вакыты үткән фикерләрен сөйләгәндә татар әдәбиятының мәңгелек хәзинәсе буларак әдәби, шигъри әсәрләрне китереп кыстыруның мәгънәсе нәрсә?

Бу чагыштыруның аз гына әсасы бармы?

Аннан соң бу әсәрләрне «Фазаиле шәһүр»ләргә чагыштыру мәсьәләне бөтенләй чыгырыннан чыгара. Галимҗан иптәш «Бәдәвам», «Фазаиле шәһүр»ләрне без җәүһәр дип таныйбыз, ди. (Аннан соң китерә дә, боларны хәзер карчыклар гына укый ди).

Ә мин әйтәм: болар берсе дә җәүһәр түгел һәм боларның җәүһәр булмаулары бик борынгы заманда язылуларыннан яки иске фикерләр тәлкыйм кылуларыннан түгел, бәлки әдәби кыйммәтләре булмаудандыр. Юкса юнаннарның миладтан күп элек язылган «Илиада»лары, әллә кайчан эштән чыккан игътикадлар, хорафатлар белән тулы булган хәлдә, бу замандагы бөтен мәдәни телләргә тәрҗемә ителеп, бөтен дөнья халкы тарафыннан укыла. Безнең «Фазаиле шәһүр», «Бәдәвам»нарның исә әдәби дәрәҗәләре — ноль, алар — чүп. Аларның «Тормышмы бу?»лар белән бергә кую, хакикатән дә, чүп белән энҗене бергә өеп куюдыр.

Әгәр «Мулла бабай» искергән, мәгънәсез бер нәрсә булса, Галимҗан Ибраһимовның әсәрләре арасында, һич шөбһәсез, иң беренче урынны тоткан «Табигать балалары» да искергән, мәгънәсез бер нәрсә булырга тиеш. «Мулла бабай»ның бер урынындагы «Шәкертләрнең хозурга чыгуы» дигән бабы «Табигать балалары» белән янәшә куелырга тиеш бер нәрсәдер. Хәлбуки профессор Гордлевский тарафыннан русчага тәрҗемә ителеп «Загородное гуляние шакирдов» исеме белән аерым бер китап хәлендә нәшер ителгән «Хозурга чыгу» «Мулла бабай»дагы шундый хисапсыз күп матур сәхнәләр арасында бер сәхнә вә бу бай картиналар залында бер картина гынадыр.

В. Либкнехт үзенең дусты Карл Маркс хакында язган хатирәсендә «Марксның һәр көнне укый торган әсәрләренең берсе Данте әсәрләре иде» ди. Соң бу Данте кем? Данте коруне вастедан (урта гасырдан) килгән бер Италия шагыйре булып, аның язган әсәрләреннән иң мәшһүре «Илаһи комедия» дә дөньяда явызлык кылган кешеләрнең ахирәт көнендә ничек газап кылынганлыкларын тасвир итәдер. Данте үзе дингә ышанучы, католиклар ноктасында торучы бер кеше. Әмма Маркс булса, яңа материализмны нигезләүче бер кеше булганлыктан, боларның арасында фикердә аз гына да якынлык булуы мөмкин түгел.

Шулай булгач, Марксның Дантега кызыккан җире кайда иде? Шул ук Либкнехтның бәянына күрә, Маркс хакыйки тасвирның, тугры вә матур стилнең гашыйкы иде. Инде Маркс кебек бер даһи үзеннән 700 ел элек килгән бер шагыйрьнең әсәрен һәр көнне укыгач, без ничек итеп аның бүгенге шәкертләрен әле жүзләре чыгып тә җитмәгән әсәрләрне, иске, мәгънәсез нәрсәләр дип тәкъдим вә аларны укыган кешеләрне «карт хәлфә» дип атау дәрәҗәсенә ирештек. Революция дәверендә бер-ике ел эчендә берничә гасыр алга китү шулай буламы?

«Бәдәвам»ны хәзер карчыклар гына укый, яки тарих язучылар гына укый. Бу турыда Галимҗан иптәш белән безнең арада низаг юк. Ләкин «Тормышмы бу?», «Мулла бабай»ларны фәләннар гына укырга тиеш, фәләннар укымаска тиеш дияргә булмый. Боларны һәркем укырга тиеш. Һәм аларны һәркем укый. Монда картлык, яшьлек, хәлфәлек, шәкертлек юк. Руслар Толстойны, Гогольны укыган мөддәттә, татарлар да Гаязны укыячак. Монда мәгънә эзләп уку, мәгънә эзләмичә уку дигән ике нәрсә булырга мөмкин түгел.

Сүз ахырыда шуны да әйтеп китәргә кирәк ки, минемчә, Галимҗан иптәш белән безнең арада булган низаг милләтчелек-коммунистлык, яки консерваторлык-революционерлык, вә гомумән сәяси карашта булган бер аермадан килеп чыккан бер нәрсә түгел. Галимҗан иптәш моны юкка шул почвага тартырга азаплана. Бу чеп-чи әдәби бер бәхәстер.

Шуның өчен Галимҗан иптәш салкын канлылыкны саклый төшеп, «Лат» «Мәнат»ларны, «Абуҗәһелләрне» ходка куймый торса, тагы да күңеллерәк булыр иде. Галимҗан иптәшнең үзенең хосусый, бик артык хосусый булган фикерен бөтен яшь буын укучыларның карашы итеп тәкъдим итүе дә кирәгеннән артык бер җөрьәттер.

**Җамал ВӘЛИДИ.** *Казан. 7 март*

*«Татарстан хәбәрләре» 10 март 1922, № 59(436)*

«Очерк истории образованности и литературы волжских татар» исемле әсәремә «Безнең байрак»ның 11 номерында Галимҗан Ибраһимовның тәнкыйде басылып чыкты. Тәнкыйтьче минем китапны басылганчы ук күргән һәм «Безнең байрак»та язган сүзләрен артыгы белән әйтеп миңа мәктүпләр язган, ләкин мин, аның бер фикеренә дә кушылмаганлыктан, аңа карап, китабымны аз гына да үзгәртмичә калдырган вә аңа хосусый мәктүпләр белән тиешле җавапларны биргән идем.

Менә шуның өчен вә, аннан соң, гомумән, тәнкыйтькә каршы тәнкыйть язу сөйгән бер эшем булмаганлыктан, мин Г. Ибраһимовка каршы тәфсилле җавап бирергә теләмим. Тик китабымда күзгә бик нык бәрелеп торган бер кимчелек бар: ул мокаддимәсез, сүз башсыз чыккан. Хәлбуки мин аны язган идем, ничектер ул басылмыйча калган. Анда китапның төзелеше хакында байтак изахлар бирелгән иде. Менә шуның өчен мин монда мокаддимәдә әйтелгән аерым мөһим бер ноктаны искә төшереп үтәргә тиеш күрдем.

Китапның әлегә кадәр бездә чыккан тарих һәм әдәбият тарихы китапларыннан бер аермасы — анда бездәге иске гыйлем-схоластика дөньясына артык күп урын бирүдер.

Бу хәл Г. Ибраһимовка да ошамаган: «Иске дәвернең дәреслекләрен, схоластикаларын тикшереп, Тәфтазаниләрнең «Гакаикыл әшья сабитән» дигән назарияләре хакында озак-озак тукталган хәлдә, ул өч гасыр буенча дәвам иткән борынгы әдәби-шигъри хәрәкәт турында бер нәрсә әйтми».

Менә тәнкыйтьченең бер сүзендә мәсьәләне чынлап тикшереп карамау һәм китапка өстән генә карау күренеп тора.

Һәрбер дәвернең әдәбияты була, гыйльме була. Гыйлем турысында язган, әдәбият турында язмаган.

Бу, әлбәттә, бик мантыйкый бер фикер: гыйлем булгач, әдәбият та булырга тиеш, нигә берсен язган да, икенчесен калдырган?

Ләкин тарихта мондый мантыйклар белән әллә кая китеп булмый. Анда бигрәк факт белән хисаплашырга туры килә.

Гыйлем белән әдәбият, дөрес, бергә баралар. Ләкин тарихның мәгълүм дәверләрендә, мәгълүм урыннарында бу икенең берсе, яки шуларның берәр төрлесе иң алга чыгып, икенчеләрен капларга, хәтта аларның шул дәвердә торган урынын ноль дәрәҗәсенә төшерергә мөмкин. Мәсәлән, борынгы Юнанстанда әдәбият иң югары дәрәҗәсенә ирешкәндә, фән әле яңа баш күтәреп килә иде. Фәнгә зур хезмәтләр иткән гарәпләрдә, рәссамлык һәм һәйкәлтарашлык сәнгате бөтенләй юк иде. Иранлыларны искә төшергәндә безнең күз алдыбызга аның Хафиз, Фирдәүси кебек шагыйрьләре килеп басса, америкалыларны хәтергә китергәндә һәр нәрсәдән элек аларның техникасы, машинасы күз алдына килә. Безнең яңгаруга (19 гасырның ахырына) кадәр булган дәверебездә нә гыйлем вә нә әдәбият мәйданында һичбер иҗатыбыз булмады. Бу чын мәгънәсе белән фикри торгынлык дәвере иде. Ләкин иҗадтан каттый назар, халкыбызның шул дәвердәге фикри хәятенә күз салсак, монда гыйлем белән әдәбиятның тоткан урыннары арасындагы зур аерманы күрмичә мөмкин түгел.

Бу дәвер безнең өчен фәкать гыйльми бер дәвер булып, анда әдәби хәят бөтенләй юк дип әйтерлек иде. Ул вакытның тар, туң гыйльме әдәбиятны бөтенләй таптап сүндергән иде. Бу дәвердә әдәбият дигән нәрсә, как таковой, һичбер гыйлем йортында урын алмый, һичбер кеше әдәбият юлында үзенә карьера эзләми, һичбер кем әдип вә шагыйрь булырга омтылмый иде. Ул вакытта бер генә идеал бар: йә галим булу, дәмелла, мөдәррис яки ишан булу.

Бу заманда бездә хәтта әдәбият дигән истилах та юк иде. Әдәбият кына түгел, телнең үзенә дә ихтыяр юк, татар теле хакында сүз дә булырга мөмкин түгел, хәтта һәрбер төрек теле голама тарафыннан хур вә фәкыйрь күрелә иде.

Авыл мәктәпләрендә укучы яшьүсмерләрдә әдәби хәят, баш күтәрер-күтәрмәс, ничек итеп хәзрәтнең, хәлфәнең киез катасы астында тапталып изелгәнлеге хакында мин китабымда шактый озын тукталдым.

Дөрес, бездә бу дәвердә Һибатулла ишан, Шәмсетдин суфый, Кандалый, Чокрый кебек шагыйрьләр чыккалады. Ләкин болар шул кадәр аз, хезмәтләре шул кадәр чикле һәм иттифакый (очраклы) һәм аларның популярносте шул кадәр юк иде ки, боларга карап бездә бер әдәби хәят булуга хөкем итү — мәсьәләне аңламау булыр иде.

Әйе, бу дәвердә анда-монда күренгән әдипләр бар, әмма бер әдәби хәят юк иде; бездә, Төркиядә вә хәтта Төркестанда булган профессиональ әдипләр, шагыйрь-

лек юк иде. Моның бик күп сәбәпләре булып, ләкин бу сәбәпләрнең берсе, минемчә, ул дәвердә бездә патшалык вә аристократия сыйныфының булмавыдыр. (Мин моны китабымда да әйтеп киттем). Бездә мирза аталган бер кечкенә груһ булса да, алар, ярым урыслашкан хәлдә, халыктан бөтенләй аерым яшиләр иде. Мәгълүмдер ки, элек заманнарда укучы гамма булмаганлыктан һәм матбагачылык та таралып җитмәгәнлектән, әдәбият бигрәк сарайлар тирәсендә, падишаһ, вәзирләр һимаясында туып үсә иде. Аннан соң, схоластика һәм дини ортодокслык үзе, табигате белән шигырьгә, әдәбиятка дошман бер нәрсә. Без шуның өчен ислам Шәркының зур шагыйрь вә әдипләрен могтәзилләр (сектант) һәм тәсәвыфчылар (суфилар) арасында күрәбез. Бездә исә боларның бере дә юк иде. Гәрчә бездә суфый вә ишан аталган затлар булса да, боларның Шәрыктагы дәрвишлек вә тәркы дөньялык (тормыштан йөз чөерү) белән һичбер мөнәсәбәте юк, болар артык җисманый вә дөньяви кешеләр булып, тәсавыфны алар күбесенчә үзләренең дөньяларын төзәтү өчен кәсеп итеп алган кешеләр була иде. Хасил, борынгы ислам Шәркында без бигрәк ике төрле шигъри әдәбият күрәбез: берсе — сарайлар тирәсендә, хөкемдарлар һимаясында житешкән мәдхи «панегерический» әдәбият, икенчесе — бөтенләй моның киресенчә ханакәһларда, мәгарәләрдә туып-үскән суфыйлык вә сектантлык әдәбияты. Бездә исә, сарайлар булмаган шикелле, ханакәһлар да юк иде. Тик схоластика кошы торган мәдрәсәләр генә бар иде. Шуның өчен бездә чын мәгънәсе белән әдәби хәят иске тормышның җимерелүе, схоластика ояларының тузуы белән берлектә генә баш күтәрде. Инде моның туып үсүе өчен сарайларның да, ханакәһларның да кирәге юк, ул инде укымышлы халык гаммасына таяна, үзенә кирәкле материалны халыктан алып, шул ук халыкка эшләп кире кайтарып бирә иде. 1905 елларда матбугат баш күтәрү белән бездә әдәбият белән шөгыльләнү шул кадәр модага кереп китте ки, монда инде тегендәгенең тәмам киресенчә, әдәбият иң беренче сафта тора, һәрбер яшь егет әдип булырга омтыла, һәрбер шәкерт, ничек кенә булса да, шагыйрь булырга катыша иде. Гүя бу — иске дәвернең бер реакциясе иде. Бу тарих мәсьәләсендә дә шулай булды. Бездә хәзер һәркем әдәбият тарихы чыкканын көтә, бик күп кешеләр шуны язарга хәзерләнәләр, яки язалар, әмма бездәге гыйлем тарихын һичбер искә төшергән кеше юк, аны язарга хәзерләнгән, хәтта кирәксенгән кеше дә күренми. Менә шуның өчен дә тәнкыйтьче дә «Хакаикел әшъяэ сабитән»ләрнең тарихын язуны килештерми. Әмма мин мәсьәләгә бөтенләй башка төрле карыйм. Безнең өчен, үзебездәге гыйлем тарихының әһәмияте әдәбият тарихыныкыннан артык булмаса, бер дә ким түгел. Әмма иске дәвергә килгәндә, монда инде гыйлем төп юл булып тора. Моның янында әдәбият зәгыйфь бер шәүлә булып кына кала.

Гәрчә без схоластика дәверен яңа гына үткәрсәк тә, гәрчә иске мәдрәсәнең ишеген ябып чыгучылар әле 25—30 яшьләрендә генә булсалар да, бу дәвер мәгънәви яктан гаять ераклашты, гүя инде ул бездән гасырлар белән аерылды. Хәзер ул безнең үсеп килә торган яшьләребез өчен Европаның коруне вәстәсе булып калды. Менә шуның өчен әле хәтерләр саф чакта ысулы иске дәверне яза башларга вакыт. Мин китабымны язган вакытта төп юл белән генә яздым, әмма вак тармакларга ишарә кылып кына киттем. Шуның өчен мин беренче дәверне язган вакытта, бигрәк андагы гыйлемгә туктадым. Әдәбиятыбызны исә соңгы дәвердән яза башладым. Һәм чын мәгънәсе белән татар әдәбиятының тууы шул вакыттан башлаптыр. Монда бер дә, тәнкыйтьче әйткәнчә, яңа әдәбиятның атасыз-анасыз уйнаштан туганлыгы күренми. Моның өчен әсәрнең «Поэзия» дигән бүлеменең башын укып карарга кирәк. Монда бездә иң элек шигырьнең нинди юл белән барганлыгы хакында бик ачык мәгълүмат бирелә. Тик андагы шагыйрьләр исемнәре белән әйтелмиләр. Минем «Исабәт» хакында язуым да шул ук әсастан чыгыптыр. Ул дәвердә төп юл дингә каршы көрәш түгел, бәлки динне мәдәнияткә тәтбикъ иде. Болар арасында «Исабәт» бик кечкенә, бик җөзъи нәрсә булып кала. Минем максадым аерым кешеләр, аерым әсәрләр хакында сөйләү түгел, бәлки заманның характерын күрсәтү иде. Ул дәвердә әле бездә социализм да башлангыч (зачаток) хәлендә иде. Шуның өчен мин аның төрле тармакларын аерып күрсәтмәдем. Затән, бу тармакларны татарлар арасында социализм хәрәкәтенең тарихын язучы берәм-берәм тикшерергә тиеш. Сүз ахырында тагын шуны әйтеп китим: мин моны Г. Ибраһимовка җавап итеп язмадым, чөнки аның боларга канәгатьләнү ихтималы юк. Ул, үзенең әйтүенчә, минем китаптагы хаталарның меңнән берсен генә күрсәткән, әгәр аңар, минем хаталарымны чынлап саный башласа, тагы шуның кадәр 999 мәкалә язарга кирәк булыр, аңарга мондый авыр эшне йөкләтергә, әлбәттә, берәү дә теләмәс.

**Җ. ВӘЛИДИ**

*«Безнең байрак» 8 май 1923, № 16(36)*

**Равил Әмирхан**

# КАЗАНЛЫ ӘМИРХАННАР

## Кереш сүз

*Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, «Чистайлы Әмирханнар» китабын язганнан соң, көн тәртибенә котылгысыз рәвештә дип әйтерлек «Казанлы Әмирханнар» мәсьәләсе килеп баса. Чистай төбәгенә баглы яшәеш-хәятне никадәр киң шифаһи (словесный) һәм вәсикый (документаль) җирлектә яктыртсаң да, бу әле куәтле, зур нәселнең бер «өземтә»сен тасвирлауга гына кайтып кала. Шуңа күрә мәшһүр токымның тирәнрәк «катлам»нарына үтеп керү, бердән, Чистай Әмирханнарының гамәли офыкларын киңәйтсә, икенчедән, бу нәселнең элек-электән татарның милли-мәдәни тормышында уйнаган ролен билгеле бер эзлеклелек белән ачыкларга, күзәтергә мөмкинлек бирә. Чыннан да, Ш. Рәхмәтуллин, Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдин кебек олпат мәгърифәтчеләрнең, тикшеренүчеләрнең әсәрләрендә күренекле шәхесләр сыйфатында теркәлгән «борынгы чор» Әмирханнар милләт кенә түгел, мәмләкәт тарихында да сизелерлек эз калдырганнар икән. Бу җәһәттән безнең игътибарны беренче нәүбәттә Мөрад, Сәфәр, Әмирхан, Хөсәен, Мөхәммәдзариф хәзрәтләрнең киңкырлы эшчәнлеге җәлеп итәр. Аннары игътибарыбыз нәселнең шанын тагын бер баскычка күтәргән Фатыйх Әмирхан дөньясына юнәлер.*

*Казанлы Әмирханнарның Фатыйхка чаклы булган буынын өйрәнү өчен чыганаклар даирәсенең әлегә шактый тарлыгын да әйтеп китәргә кирәктер. Ләкин бу мәсьәлә белән махсус һәм җентекле шөгыльләнгән тәкъдирдә, уебызча, әле күп кенә ак тапларны бетерергә мөмкинлек бар. Моның өчен, беренче чиратта, XIX йөздә нәшер ителгән барлык төр татарча календарьларны, басма әдәбиятны күздән кичерү, аннары берничә йөз еллык тарихы булган кульязма әсәрләрне җәлеп итү сорала. Шуннан соң инде Мәскәүнең Борынгы актлар Үзәк дәүләт архивы (ЦГАДА) фондларында сакланган чыганакларга мөрәҗәгать кылу, бу нәселгә кагылышлы мәгълүматларны бөртекләп җыю таләп ителә. Санкт-Петербургның һәм Мәскәүнең башка үзәк архивлары киштәләрендә дә (әлбәттә, Казанныкында, Уфаныкында һәм башка шәһәрләрнекендә дә) безне кызыксындырган мәсьәлә буенча төрле характердагы документларның саклануы бик ихтимал. Бу бигрәк тә узган гасыр метрика кәгазьләре фондларына карый. Сәфәр, Әмирхан, Хөсәен, Зариф хәзрәтләрнең һәм башкаларның язма әсәрләре язмышын ачыклау өчен ел саен чыккан китаплар исемлеген барлау да шарт.*

*«Казанлы Әмирханнар» исемле хезмәтне язу процессында без Ш. Рәхмәтуллин, Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдин хезмәтләренә, Ф. Әмирханның замандашлары истәлекләренә, соңгырак буын Әмирханнарда сакланып калган риваять-мәгълүматларга, язмаларга таяндык, иске гәзит-журнал тегелмәләренә, архив материалларына мөрәҗәгать иттек, өлешчә Х. Хисмәтуллин, И. Нуруллин, М. Мәһдиев хезмәтләреннән һәм башка төр чыганаклардан файдаландык. Әлбәттә, Әмирханнар нәселен «чистайлы»ларга һәм «казанлы»ларга бүлүне бик шартлы рәвештә генә кабул итәргә мөмкин. Ихтимал ки, киләчәктә әлеге ике китапны берләштереп, «Әмирханнар» дигән гомуми исемдәге хезмәт иҗат кылырбыз. Чистай төбәгендә тәрәккый тапкан Әмирханнарның бүгенге буыны хәзер нигездә Казанда һәм Чаллыда (өлешчә Бакуда) тупланган вә аның берничә «җәбе» шушы шәһәрләрдә тереклек итә.*

*Бу хезмәттә без үтә популяр һәм «йөгерек» фасылда Әмирханнар токымының XVI—XX йөзләргә нисбәтле хәятына тукталдык. Рәсми документларга (бигрәк тә борынгырак чорларга караганнарына кытлык кичерсәк тә, без иҗади фантазияне эшкә җигүдән сак булдык, аерым шәхесләрнең гамәлләрен тасвирлагандагы бушлыкны ясалма рәвештә тутыру юлына басмадык. Шуңа күрә, кайбер урыннары ярлырак, кайтышрак килеп чыкса да, хезмәтебезнең документаль-хакыйкый җирлектә иҗат ителүе күңелебезгә мәгълүм дәрәҗәдә рухи канәгатьләнү хисе бирә.*

*27 октябрь 1995 ел.*

## Тарихта мәгълүм бабайлар

Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдин хезмәтләрендә, Ф. Әмирханның әтисе Мөхәммәдзариф 1903 елда төзегән шәҗәрәдә Әмирханнар нәселенең әдип буынына кадәрге өлеше түбәндәге сызык буенча тасвир кылына: Гәрәй мирза — Җәлмәт (Җөлмәт) — Әхмәд — Кадермәт — Морад хәзрәт — Исмәгыйль — Габделмәннән — Әмирхан — Хөсәен — Мөхәммәдзариф — Фатыйх.

Гәрәй мирза турында мәгълүматыбыз әлегә юк дәрәҗәсендә аз. Кайбер риваятьләргә күрә, ул Кырым ханлыгының мәшһүр Гәрәйләр нәселенә карый һәм Казан тарафларына шуннан килеп җирләшкән, имеш. Гәрәй мирза, чама белән алганда, Казанны Мәдһиш Иван вәйран иткән һәм ханлык җирләрен колонизацияләү үзенең югары ноктасына житкән чорда яшәгән.

Аксөяк мирза, күрәсең, Иван патшага баш бирергә теләмәүче, ул үткәргән сәясәткә, христианлаштыруга каршы торучы шәхесләрнең берсе булган. Малмөлкәтен, аксөяклеген (дворянлыгын) саклап калу өчен диненнән, иманыннан язарга теләмәгән, шуңа күрә аның нәселе дә ислам, милләт рухында гамәл кылган шәхесләрдән гыйбарәт.

Мирзалыгыннан, җир-суыннан, мөлкәтеннән колак каккач, Гәрәйнең төп оясы да туздырылган булырга кирәк.

Аның улы Җәлмәт (Җөлмәт) турында мәгълүмат аз гына күбрәк. Р. Фәхретдин «Асар» дигән мәшһүр био-библиографик хезмәтендә искәрткәнчә, Җәлмәт бине Гәрәй, Сембер тарафыннан күчеп килеп, Чистай төбәгендәге Чирүле Шонталы авылында төпләнгән[1]. Хәзер бу авыл (Кыр Шонталасы) Алексеевск районына керә. Җәлмәтнең бiредә ни белән шөгыльләнүе мәгълүм түгел.

Җәлмәтнең улы Әхмәд, Әхмәднең улы Кадермәт (Кадермөхәммәд) тә, мөгаен, шушы авылда гомер сөргәннәрдер. Ләкин алар хакында искә алырлык мәгълүмат сакланмаган.

Кадермәтнең улы Морад хәзрәт — тарихта шактый мәгълүм шәхес. Моның эшчәнлеге инде XVIII гасырның илленче-алтмышынчы елларына карый. Алтмышынчы еллардагы «Мулла Морад хәрәкәте» аңа нисбәтле вакыйга булса кирәк, кайбер риваятьләр моңа ишарә кыла. Әйтик, мулла Мораднын яңа тәгълимат уйлап чыгаруы һәм «Болгар чорын кайтарырга вакыт житеп килә» («возобновить Булгар время поспевает») дигән шигарен (лозунгысын) алга сөрүе мәгълүм[2]. Ул «гомуми дин», гаделлек, халыкларның үзара аңлашуы өчен көрәшкә чакыра, игенчеләр җыеннарында үз тәгълиматын пропагандалый. Халык арасында «коткы таратуы» өчен, тарафдарлары белән берлектә, 1769 елда кулга алына һәм С.-Петербургка озатыла[3]. Ләкин аңа Әби патша зинданыннан котылырга насыйп булган, ахры, чөнки чыганаклар имамның шул ук Чирүле Шонтала авылында күмелүен күрсәтә[4].


---

[1] Фәхретдин Ризаэтдин. Асар, III жөзьә. Оренбург, 1903. 155 б.

[2] Алишев С. Х. Татары Среднего Поволжья в Пугачевском восстании. Таткнигоиздат, 1973. б. 51; Алишев С. Х. Исторические судьбы народов Среднего Поволжья XVI — начало XIX в. М., Наука, 1990, б. 252.

[3] Алишев С. Х. Исторические судьбы... б. 252.

[4] Фәхретдин Ризаэтдин. Асар, III жөзьә. Оренбург, 1903. 155 б.




*Әмирханнарның Мөхәммәдзариф бине Хөсәен бине Әмирхан төзегән нәсел шәҗәрәсе.*

Морад Әмирханнар нәселендәге беренче мулла булганга охшый. Хәер, атасы Кадермәтнең дә имам булуы бик мөмкин. Морад хәзрәт тереклегендә зур шөһрәт казанган булса кирәк. Р. Фәхретдин билгеләп үткәнчә, аның каберенә халыкның юлы өзелми[1].

Классик әдибебез Г. Исхакый да әнисе Камәрия ягыннан үз нәселенең Морад хәзрәткә барып тоташуын билгеләп үтә. Ул үзенең «Сөннәтче бабай» дигән хикәясендә (1911) мондый искәрмә биреп китә: «Мулла Морад бабай — Кырым ханнары Гәрәйләрнең угылларыннан. Ни сәбәптәндер, Русиянең уртасына күчеп килеп, гыйлем юлында хезмәт иткән. Чистай вә Бөгелмә уездларында зур исеме

[1] Фәхретдин Ризаэтдин. Асар, III җөзьә. Оренбург, 1903. 155 б.

бар. Шонталы авылында, Чистай уездында күмелгән»[1]. Дөрес, без күрсәткән нәсел сызыгы белән Исхакый телгә алган буыннар чылбыры белән туры килеп бетми, ләкин, кем белә, бәлки алар бер-берсен тулыландыра гына торганнардыр. Ә сүз, һичшиксез, бер үк шәхес хакында бара, чөнки Р. Фәхретдин безнең Гәрәй мирзага нисбәтле Морад хәзрәтнең җирләнү урынын ап-ачык итеп «Шонталы» дип күрсәтә.

Морад хәзрәтнең улы Исмәгыйль хакында мәгълүмат чиклерәк. Атасыннан аермалы буларак, ул Шонталыда түгел, бәлки Талкыш авылында (хәзер Чистай районына керә торган Татар Талкышы булырга тиеш) гомер сөрә. Муллалык белән шөгыльләнгәнме-юкмы, билгеле түгел. Р. Фәхретдин язуы буенча, Исмәгыйль бине Морад Талкышта зирагать, ягъни авыл хуҗалыгы, игенчелек белән шөгыльләнә[2]. Безнең уебызча, Исмәгыйль, авыл хуҗалыгы белән беррәттән, имамлык та кылган булырга тиеш. Хәзрәт улы (мәхдүм) Исмәгыйльне талкышлылар Шонталыдан үзләренә мулла итеп чакырулары бик мөмкин. Аның мулла булу ихтималын тагын бер факт куәтли: бер «Сәфәр хәзрәт» дигән исем белән шөһрәт казана.

Шунысын аерым билгеләп үтик: Әмирханнар нәселенең Җәлмәт бине Гәрәйдән соңгы дәвере Чистай төбәге, аның Чирүле Шонталы һәм Талкыш авыллары белән тыгыз бәйле.

Исмәгыйльнең улы Сәфәр — тарихта шулай ук мәгълүм эз калдырган зат. Талкышта туып-үскән малай Малмыж өязенең Югары Сасна авылында (хәзерге Балтач районына керә) укый, соңыннан шул ук авылның икенче мәхәлләсендә имам һәм мөдәррис була, ягъни муллалык итү белән бергә мәдрәсәсендә балалар укыта. Ун ел чамасы имамлык кылганнан соң, Сасна байлары белән тыныша алмыйча, туган җире Талкышка кайтып имамлык итә. Ихтимал, атасы Исмәгыйль урынынадыр. Бик укымышлы, гайрәтле һәм булдыклы зат саналган Сәфәр хәзрәт күп сөннәтләрне, ягъни ислам гадәтләрен тергезә, гыйльми китаплар яза (кызганычка каршы, алар еш кабатланган янгыннарда харап була), дәресе бик куәтле, шәкертләре күп була[3].

Сәфәр хәзрәт 1821 елда Талкышта үлә. Заманының бик күренекле заты саналган шәех Габдула бине Җәгъфәр әл-Кизләви аны искә алу өчен Талкышка махсус килгән һәм вафаты өчен гадәттән тыш кайгырган[4]. XIX йөз азагында Р. Фәхретдиннең үтенече буенча Талкышның ул замандагы имамы Шамил бине Фәхретдин бөтен халык Сәфәр хәзрәтнеке дип таныган кабер ташының җиде юллык язуын, бик искергәнлеге сәбәпле, авырлык белән укый. Шунысы кызык, ташбилгенең бишенче юлы «тарих хан Җуҗи» дигән сүзләрдән гыйбарәт. Шамил мулла фикеренчә, таш иясе Җуҗи нәселеннән (Җуҗи — Чыңгыз ханның өлкән улы) бер хан булып, 1290 еллар тирәсендә вафат[5]. Җуҗи токымына нисбәтле бу ташбилгенең нәкъ менә Сәфәр хәзрәт каберенә куелуы хәзрәтнең Чыңгыз хан нәселеннән килүенә ишарәләмимe икән, дигән сорау да китереп чыгара. Гәрәйләрнең шул тамырдан килүе исә шик уятмый диярлек.

Сәфәр хәзрәт вафатыннан соң, аның урынына имам булып Мөхәммәд бине Сәфәр кала, үзенең белемлелеге белән беркадәр шөһрәт казана.

Бүгенге Әмирханнар нәселенә турыдан-туры караган Габделмәннән бине Исмәгыйль (Сәфәр хәзрәтнең бертуган абыйсы яки энесе) хакында мәгълүматлар сакланмаган, безгә билгеле чыганаклар аны читләтеп уза. Ләкин аның да мулла булуына шикләнмәскә мөмкин.

## Әмирхан хәзрәт

Габделмәннәннең улы Әмирхан (1771—1828) турында без инде, кем әйтмешли, авыз тутырып сөйли алабыз. Бу шәхес бүгенге фамилиябезгә «этәргеч» биргән кеше. Ул чордагы урыс администрациясенең җиңел кулы белән

[1] Исхакый Гаяз. Зиндан/Сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре. Казан, Таткитнәшр., 1991. 206 б.
[2] Фәхретдин Ризаэтдин. Асар, III җөзьә. Оренбург, 1903. 155 б.
[3] Фәхретдин Ризаэтдин. Асар, III җөзьә. Оренбург, 1903. 155 б.
[4] Шунда ук.
[5] Фәхретдин Ризаэтдин. Асар, III җөзьә. Оренбург, 1903, 156 б.

аның токымына -ов койрыгы (суффиксы) тагылып, берничә буын Әмирханнар «Амирханов»лар булып киткән. Гәрәй нәселеннән килгән, Әмирхан чорындагы башка затлардан (Әмир, Әхмәд, Мөхәммәд, Бикмөхәммәд һ. б.), мәгълүм инде, «Амировлар, Ахметовлар, Мухамедовлар, Бикмухамедов»лар барлыкка килгән. Сәфәр хәзрәттән дә «Сафаровлар» үрчегәндер, мөгаен. Хәзер аларның кардәшлеген исбатлау, бер җепкә теркәү практик яктан мөмкин эш түгелдер.

Ш. Рәхмәтулин мәгълүматларына караганда, Әмирхан хәзрәт әлеге дә баягы Талкыш авылында дөньяга килгән[1]. Туу елы — 1771. Моннан чыгып, без аның атасы Габделмәннәннең дә Талкышта имамлык, һичьюгы тереклек итүен чамалый алабыз. Башта Әмирхан Сасна имамы, абзасы (әтисенең абыйсы яки энесе) Сәфәр хәзрәттә, аннары Мәчкәрәдә Мөхәммәдрәхим бине Йосыф әл-Ашытида укый. Шуннан соң белемен тирәнәйтү йөзеннн ул заманда гыйльми үзәк саналган Бохарага юл тота, анда берничә ел тырышып укый. Биредә ислам дөньясында мәшһүр Сахибзадә ишанның хәлифәләреннән (дәвамчы — преемник) санала. Бохара гыйлемле Әмирхан, заманы өчен зур укымышлы кеше, Казан төбәгендәге Югары Курса, Тимершык, Төрек («Көек», дигән язылыш та очрый) авылларында имамлык кыла[2]. Еш авыл алмаштыруның сәбәпләре билгесез. Шундагы надан байлар белән «борчагы пешмәгән» булуы ихтимал, чөнки Әмирхан хәзрәт үтә горур, туры сүзле, хөр фикерле кешеләрдән булган. Бабабыз үзенең остазы Мөхәммәдрәхим ахунның Газизә исемле кызына өйләнә, шуннан беренче баласы Ибраһим дөньяга килгән булырга кирәк.




*Гәрәй мирзалар гасыры шаһиты Сөембикә манарасы. XIX йөз башындагы күренеше. Э. Турнерелли эше.*

1809 мы — 1810 нчымы елда (1815 елга да ишарәләр бар) Әмирхан хәзрәт Казанга күчеп килә, Яңа Бистәнең соңрак 9 нчы дип йөртелә башлаган мәчетендә

[1] Календарь 1894 ел өчен. Шиһабетдин бине мулла Габдегазиз Рәхмәтулла угылының тәэлифе. Казан, типо-литография импер. ун-та 1893, 47 б.

[2] Фәхретдин Ризаэтдин. Асар. V җөзьә. Оренбург, 1904, 250 б.

имамлык кыла башлый. Шул вакыттан нәселебезнең «Казанлы Әмирханнар» тармагына ныклы нигез салына. Әйтергә кирәк, бу «Иске таш мәчет» (тарихи атамасы шундый) 1803 елда Мәчкәрә бае Габдулла бине Габделислам Үтәмишев акчасына салынган (М. Гафури урамы, 34а). Малмыж өязенең Мәчкәрә авылында (хәзерге Кукмара районына керә) укыган, җәмәгате Газизә һәм бигрәк тә абруйлы остазы Мөхәммәдрәхим әл-Ашыти шуннан булган укымышлы мулланы Мәчкәрә бае салдырган мәчеткә чакырмыйча, кая чакырсыннар ди инде! Ни әйтсәң дә, Мәчкәрә кияве бит ул. Шунысы да бар, мәхәллә халкы Әмирханны үзләренә имам итеп чакырганда барыннан да элек аның унышлы мөдәррислегенә, ягъни шәкертләргә дәрес әйтүенә өмет баглаган. Әүвәлге мулла заманында бу мәхәлләдә сабак бирү ягы нык аксый торган булган, имеш. Бистә халкының бу ышанычы акланган: Әмирхан хәзрәт укыту-тәрбия эшләрен җайга салып, тиешле югарылыкка күтәргән, шуның нәтиҗәсендә абруе нык арткан, уку йорты исә мөдәррисенә бәйле рәвештә «Әмирхания мәдрәсәсе» дип аталып киткән.

Казан мулласына өйләнгән хәзрәтнең тора-бара яңадан Фатыйма исемле кызы (?—1855), Хәсән һәм Хөсәен (1816—1893) исемле ике улы дөньяга килә. Гыйлем иясе, талантлы мөдәррис Әмирхан хәзрәт мәдрәсәсендә үрнәк төстә дәрес әйтү, тәрбия эше белән генә шөгыльләнмәгән, бәлки рухи мәдәниятнең төрле тармакларына караган хезмәтләр дә иҗат иткән. Шуларның берсе — «Хаҗи Әмирхан әсәре» (димәк, хаҗда да булган икән) диярәк мәгълүм булган гарәпчә «Шәрхел-викаят», ягъни «Саклануны ачыклау» китабы. Өч йөз биттән артык күләмле бу кульязманы хәзрәт үзе исән вакытта бастырып чыгара алмаган, күрәсең. Татарстан Фәннәр Академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты фәнни архивында саклана торган бу хезмәтнең өстенә 1879 елның 8 октябрендә цензор мөһере сугылып, «позволено цензурой» дип язылган[1]. Ул шул ук елда нәшер дә ителгән. Әмма бу эшне инде хәзрәт үзе түгел, бәлки улы Хөсәен иясә оныгы Мөхәммәдзариф башкарып чыккан.

Әмирхан бине Габделмәннән 1828 елда илле яшендә вафат булган һәм Яңа Бистә зиратына җирләнгән. Тарихта танылганрак шәкертләреннән Фәхретдин бине Мостай ән-Норлатый сукырны, Җарулла бине Бикмөхәммәд әс-Сатышыйны, Мифтахетдин бине Сәлим — Җәүһәр әл-Калмашыйны күрсәтергә мөмкин[2].

## Хөсәен мулла

Әмирхан хәзрәтнең өч улы арасыннан иң зур шөһрәт казанганы, һичшиксез, Хөсәен. Гомумән, XIX гасыр Әмирханнары арасында, мөгаен, ул иң күренекле фигурадыр. Гыйлем иясе, философ, олпат дин әһеле, тарихчы, мәгърифәтче Хөсәен хәзрәтнең исеме заманында күп кенә китапларга, әсәрләргә кергән. Бу шәхеснең исеме, аерым алганда, Ш. Рәхмәтуллинның абруйлы календаренда, Ш. Мәрҗанинең «Мөстафадел-әхбар»ында, Р. Фәхретдиннең «Асар»ында зурлап телгә алына. Мәсәлән, Ш. Рәхмәтуллин Хөсәен Хәзрәтне «һәр фәндә мөтәбәххир», ягъни диңгез кебек тирән гыйлемле зат дип бәяли[3].

Хөсәен бине Әмирханның туу датасын төрлечә күрсәтүләр очрый: 1814 һәм 1816. Ш. Мәрҗанигә таянсак, икенче вариантка тукталырга тиеш булабыз. Ләкин Казанда тууы шик уятмый, бу хакта чыганакларда каршылык юк. Атасы Әмирхан хәзрәттән унике яшендә ятим калган малайның тормыш күге бик үк аяз булмый, аңа кечкенәдән үк байтак кыенлыклар кичерергә туры килә.

Ш. Мәрҗани мәгълүматлары буенча, ул башта Чистай шәһәрендә һәм Казанда мулла Исхак бине Сәгыйть, аннары анасының туган авылындагы Мәчкәрә мәдрәсәсендә шөһрәтле мөдәррис Габдулла бине Яхъя әл-Чиртүшидән дәрес ала[4]. Ләкин мондагы белемнәр белән генә канәгатьләнмичә, сәләтле шәкерт, атасы кебек үк, кырыгынчы елларда Бохарага юл тота һәм анда берничә ел дәвамында (Мәрҗани белән бер чордарак) мәшһүр уку йортларында гыйлемен арттыра. 1846 елда укымышлы егет Казанга кайта. Озак та үтми, ул Баймөрад мулла кызы Бәдриҗамалга өйләнә. Инде көн тәртибенә имамлык мәсьәләсе

---


[1] ТӘСИ Фәнни архивы. Коллекция 39, саклау берәмлеге 157.

[2] Фәхретдин Ризаэтдин. Асар, V җөзьә. Оренбург, 1904, 250 б.; Мәрҗани Шиһабетдин. Мөстәфадел-әхбар... II җөзьә. Казань, типо-литография имп. ун-та. 1900, 101 б.

[3] Календарь 1894 ел өчен. Шиһабетдин... Рәхмәтула угылының тәэлифе..., 47 б.

[4] Мәрҗани Шиһабетдин. Мөстәфадел-әхбар... Казан, Таткитнәшр., 1989, 323 б., Фәхретдин Ризаэтдин. Асар. Кульязма. III җөзьә, XII җилд. Уфа, 1930, 174 б.

килеп баса. 1848 елда ул указ ала һәм мәрхүм атасы мәчетенә бабасы (хатынының атасы) Байморад янына иптәш мулла булып урнаша[1]. Карт хәзрәт 1849 елда алтмыш җиде яшендә вафат иткәч, Хөсәен төп имамлык дилбегәсен үз кулына ала.



*Шушы язманың соңгы юлларында теркәлгәнчә, мәшһүр «Мөхәммәдия» китабының әлеге нөсхәсен Әмирханнарның берсе — Мөхәммәдҗан бине Бикмөхәммәд бине Сәйфулла бине Исмәгыйль бине Морад бине Кадермәт бине Акъмәт бине Җәлмәт бине Гәрәй күчергән. 1825 ел.*

Яңачарак фикер йөртүче, ачык зиһенле, еракларга йөреп шомарган Хөсәен хәзрәткә искелек тарафдары руханилар һәм фанатик кәсепче-сәүдәгәрләр һөҗүменә дә каршы торырга туры килгән. Диния нәзарәте архивында Хөсәен мулла өстеннән 1857 һәм 1862 елларда язылган әләк-шикаятьләрнең теркәлеп калуы шул турыда сөйли. Әйтик, 1857 елда Яңа Бистәнең 3 нче гильдия сәүдәгәре Муса Пономарев Диния нәзарәтенә, Хөсәен мулла Коръән һәм шәригать кануннарын тәгәл үтәми, дип шикаять кыла. Конфликтның үзәгендә заманы өчен шактый четерекле — уразаның тәмамлану көнен төгәл билгеләү, яна айны күрү мәсьәләсе торган икән. Таза бәдәнле, мәһабәт һәм арыслandaй гайрәтле Хөсәен хәзрәт, шушы әләккә караганда, «белмәгән эшенә кысылган өчен» Муса Пономаревны дөмбәсләп ташлау белән куркыткан, имеш[2].

1867 елгы ураза ахырында да шул типтагы низагъ килеп чыга. Монысында гаед мәсьәләсендә Мөхәммәдкәрим мулла белән Ш. Мәрҗани бәхәскә керә. Мөхәммәдкәрим «гаедкә иртәрәк» дигән фикерне алга сөрсә, Мәрҗани «вакыт» ди икән. Күпчелек имамнар Мөхәммәдкәрим ягын каерганнар. Мәрҗанине Хөсәен хәзрәт кенә яклап чыккан[3]. Бәлки, аларның рухи-иҗтимагый яктан «бердәм фронт» тота башлаулары да шул чорга карыйдыр. Һәрхәлдә гомеренең ахырына таба Хөсәен Мәрҗанинең тарафдары булып китә.

Идел буе ислам рухани дөньясында Хөсәен хәзрәтнең абруе кечкенәдән булмаган, күрәсең. Дини идарә тарафыннан һәр елны традицион Мәкәрҗә ярминкәсенә Казанның мәшһүр голямасыннан игътибарлы һәм танылган бер имам җибәрелә торган булган. Мәрҗани мәгълүматларына караганда, Хөсәен бине Әмирхани анда ике тапкыр, 1852 һәм 1865 елларда барган[4].

Указлы мулла буларак, Хөсәен хәзрәт, билгеле инде, шәкертләргә дә дәрес әйткән, башта үзе житәкләгән ибтидаи (башлангыч) мәктәптә, аннары рөшдия дәрәҗәсендәге мәдрәсәдә, ягъни урта белем бирүче уку йортында — атасына нисбәт ителгән «Әмирхания» мәдрәсәсендә укыткан.

Әмма Бохара гыйлеменә ия, киң карашлы Хөсәен хәзрәт имамлык вә мөдәррислек белән генә канәгатьләнмәгән. Атасы хаҗи Әмирханның юнәлешен дәвам итеп һәм Ш. Мәрҗани, Байморад мулла кебек олуг шәхесләрнең йогынтысын тоеп, ул үзенең табигый сәләтен һәм алган гыйлемнәрен каләм көче белән раслый башлаган, дини-фәлсәфи һәм тарихи язучылык эшенә керешкән. Төрле төр чыганаклар белән эш башлап, әдәбият даирәсен торган саен киңәйтә барып, ул бер-бер артлы берничә тарихи-библиографик әсәр иҗат иткән. Боларны искә

[1] Мәрҗани Шиһабетдин. Мөстәфадел-әхбар... Казан, 1989, 323 б.
[2] Нурулин Ибраһим. Фатих Әмирхан (1886—1926). Казан, Таткитнәшр, 1988, 6—7 б.
[3] Шунда ук, 7 б.
[4] Мәрҗани Шиһабетдин. Мөстәфадел-әхбар..., ИИ җөзьэ, 1900.

алып, Ш. Рәхмәтуллин, «Хөсәен хәзрәтнең тәрҗемә вә хәварис вә рәсаильдән тәэлифаты күптер»[1], ягъни аны, био-библиографияне, төрле вакыйгаларны эченә алган күп брошюра-китаплар язган кеше, дип атаган.

Бу хезмәтләрнең иң мәшһүрләреннән берсе — «Тәварихе Болгария...» («Болгар тарихы...») 1883 елда Казанда басылып чыга. Җирле чыганакларга, халык риваятьләренә киң таянып язылган бу китап үзенең практик әһәмиятен әле дә булса югалтканы юк. Аның шактый гына вакытлар мәдрәсәләрдә дәреслек булып йөрүе дә мәгълүм. Бу әсәрдә Мөхәммәдхан Әбелгазый, Баһадир хан Хәрәзми, Чыңгыз хан кыйссалары, Болгар, Казан, Кабан күле, урысның Казанны алуы, Иске Бистә, Яңа Бистә, Черек күл кыйссалары, шәехләр, мәшһүр шәхесләр тормышы һ. б. бик күп тарихи вакыйгалар сурәтләнгән, шуның өстенә бай топономик мәгълүматлар бирелгән.

1884 елда С.-Петербургта Хөсәен бине Әмирханның «Нөҗүмел-тәварих» («Тарихлар йолдызы») исемле хезмәте дөнья күрә. Китап пәйгамбәрләр турындагы кыйссалар белән башланып, сәхәбәләр, хәлифәләр, патшалар, солтаннар, шаһлар, шаһзадәләр, аларның кылган эшләре һ. б. турында киң мәгълүмат бирә, күп кенә ислам дәүләтләренә, аларда булып үткән тарихи вакыйгаларга, Чыңгыз хан, Аксак Тимер, Наполеон һ. б. шуның кебек шәхесләргә, яулап алу походларына, Кырымның Русия тарафыннан басып алынуына, вәһһабиләр хәрәкәтенә һ. б. гыйбрәтле хәлләргә туктала.




*Габделмәннән бине Исмәгыйль яшәгән чорда Казанда бина кылынган (1770) Апанай мәчете. Э. Турнерелли рәсеме. XIX йөз башы.*

Шул ук 1884 елда Казанда Хөсәен хәзрәтнең «Шәҗәрәи галия фи бәян әл-әнсаб» («Нәсел-нәсәпләрне бәян иткән бөек шәҗәрә китабы») исемле яңа хезмәте дөнья күрә. Ул әүвәлгесенең дәвамы сыйфатындарак, Адәм галәйһиссәламнан башлап, төрек солтаны Габделхәмидкәчә булган пәйгамбәрләрнең, патшаларның, зур дәүләт эшлеклеләренең, олуг галимнәрнең биографияләрен анализлауга, аерым төрки һәм ислам дәүләтләре тарихына багышланган.

[1] Календарь 1894 ел өчен. Шиһабетдин... Рәхмәтулла угылының тәэлифе ..., 47 б.

Соңгы вакытта гына олуг дин әһеленең һәм тарихының тагын бер күләмле (91 бит) әсәре барлыгы ачыкланды. Хезмәтнең тулы исеме — «Тәварихе биладә рәбига, ягъни Мәккә вә Мәдинә вә Бәйтелмөкаддәс вә мөкам Хәлили-әр-рахманның фиһристе». Бүгенге телгә күчерсәк, болай: «Дүрт шәһәр тарихы, ягъни Мәккә, Мәдинә, Иерусалимдагы (Кодс) изге гыйбадәт йорты һәм пәйгамбәр яшәгән урынның эчтәлеге». Хөсәен хәзрәтнең бу китабы тарихи, географик һәм дини-рухани мәгълүматларны гомумиләштерү ягыннан игътибарга лаек һәм галимнең киң фәнни-фәлсәфи җирлектә эшләгәнлеген күрсәтә.

Әлеге хезмәтләр үз чоры өчен бик фәнни саналган, зур әһәмияткә ия булган. Алар Хөсәен хәзрәтне заманының атаклы тарихчысы итеп күрсәтә. Ш. Мәрҗанинең «Вафыйател-әслаф», «Мөстәфадел-әхбар» кебк мәшһүр китаплары белән беррәттән Х. Әмирханинең дә күрсәтелгән әсәрләре татар тарихы фәне үсүгә җитди этәргеч бирә. Әлеге китаплар үрнәгендә аларның турыдан-туры йогынтысы астында Р. Фәхретдин дә үзенең мәшһүр «Асар»ын иҗат иткән булырга тиеш.

Шул ук чорларда тарихчы-галим «Әл-Фәваид» («Файдалар») исемендә «тәркичә», ягъни татарча Коръән тәфсире язып бастыра. Ш. Рәхмәтуллин тәфсир турында, «даирәмез лисанында (җирле телдә) булдыкыннан гаять файдалыдыр»[1], дип яза.

Кайбер мәгълүматларга караганда, Хөсәен хәзрәт мөнәҗҗим (астролог) булган, ягъни йолдызларга карап күрәзәлек тә иткән икән. Мәсәлән, йолдызларның торышына карап, ул ана карынындагы баланың җенесен алдан билгели торган булган, имеш.

Хөсәен хәзрәт Әмирхани — үзеннән соң янә берничә басма китап (мәрхүм галимебез Рашат ага Гайнанов аның 14 исемдә хезмәтләрен ачыклавы хакында әйткән иде), тәрҗемәләр, аңлатмалар, төрле күләмдәге рисаләләр (брошюралар) һәм кульъязмалар калдырган, шигърият өлкәсендә дә каләмен сынаган шәхес. Ул рациональ фикер йөртүче дин эшлеклесе, мөдәррис, философ кына түгел, бәлки татар милли тарихи фәненең нигез ташларын салучылардан берсе дә. Кызганыч ки, бу олуг милләт хадименең тәрҗемәи хәле һәм игелекле эшчәнлеге практик яктан бөтенләй өйрәнелмәгән, мирасы барланмаган диярлек.

Р. Фәхретдин үзенең кульъязма «Асар»ында Хөсәен хәзрәтне Уфа шәһәрендә Диния нәзарәтендә күрүен теркәп калдырган. Бу йә 1891, йә 1892 елда булырга тиеш. Риза казый аның турында: «Картлыгы камил булса да, бөтен әгъзасы сәламәт иде, шикаяте ишетелмәде»[2], — дип язып куйган. Ләкин күп тә үтми, 1893 елның 17 гыйнварында (башка мәгълүматлар буенча, 15 гыйнварда) мәшһүр тарихчы, галим һәм дин эшлеклесенең йөрәге тибүдән туктый. Хөсәен хәзрәт Казанның Яңа Бистә зиратына күмелә.

Ислам һәм милли мәдәниятебез тарихында якты эз калдырган, яңа буын милләтпәрвәрләргә рухи этәргеч биргән бу затның эшчәнлеген җентекләп тикшерү — көн тәртибендәге мәсьәләләрнең берсе.

Хөсәен бине Әмирхан, кайбер мәгълүматлар буенча, беренче җәмәгате вафат булганның соңында икенче хатынга өйләнгән. Ике хәләл җефетеннән безгә мәгълүм алты баласы дөньяга килгән: Мөхәммәдзариф, Әүхәдетдин, Мөхәммәдхарис, Мөхәммәдгариф, Мөхәммәднәҗип һәм Мәрьямбану. Тәгаен шунысы билгеле, Мөхәммәдзариф белән Мөхәммәднәҗипнең әтиләре дә, әниләре дә уртак.

## Классик әдипнең әти-әнисе

Мөхәммәдзариф 1853 елның 10 гыйнварында дөньяга килә. Үз кул астында күпмедер укыткач, Хөсәен хәзрәт улын Курса мәдрәсәсенә урнаштыра. Аннары, Сары Тау губернасы Хвалыйн өязеннән килеп, «Әмирхания»дә укый башлаган Сәгъдетдин исемле шәкерт белән икесен бергә Норлат мәдрәсәсенә илтеп, бер бүлмәгә куя[3]. Егет булып җиткән Зариф 1872—1874 елларда шунда укып, тәпле гене гыйлем ала.


Норлат мәдрәсәсе, күрәсең, заманына күрә алдынгы уку йорты хисапланган. Аннары Зарифның биредә укуының тагын бер җитди сәбәбе булуы мөмкин:

[1] Календарь 1894 ел өчен. Шиһабетдин ... Рәхмәтулла угылының тәэлифе ... 47 б.
[2] Фәхретдин Ризаэтдин. Асар. Кульъязма. III җөзьэ, XII җилд. Уфа, 1930. 174 б.
[3] Нуруллин Ибраһим. Фатих Әмирхан... 8 б.

мәдрәсәне бабасы Әмирханның талантлы шәкерте Фәхретдин бине Мостай эн-Норлатый җитәкләгән. Тумыштан ук бик зирәк һәм сәләтле мәхдүм, әлбәттә, алдынгы шәкертләрдән саналган. Сәгъдетдин мулланың күп еллардан соң биргән белешмәсенә караганда, Мөхәммәдзариф мәдрәсәдә чакта ук «Коръәнхафиз» булган, ягъни Коръәнне яттан белгән[1]. «Сәнгатьле» уку остасы да икән. Калын бәрхет тавыш, мул интонация дә хас үзенә. Норлат мәчетендә дә, Казанныкында да мөэмин-мөселман моның матур тавышына мөкиббән киткән.

Шулай да мәхдүм дини гыйлемгә генә ябышып яткан адәм булмаган. Риватьләргә күрә, таза һәм дәртле егет дөньяны да сөйгән, тормыш ләззәтләреннән дә баш тартмаган, дөнья хәлләре һәм иҗтимагый мәсьәләләрдән дә читтә тормаган.

Мөхәммәдзарифның Норлат чорыннан калган калын көндәлек дәфтәре сакланган. Җитмешенче еллар азагында аны, кайдандыр кулга төшереп, миңа күренекле галимебез Марсель Әхмәтҗанов бүләк иткән иде. Ибраһим ага Нуруллинның бик кызып Фатыйх Әмирхан турында китап язарга йөргән чагында әтиебез аны, миңа сиздермичә генә, мәшһүр профессорыбызга «шудырган» булып чыкты. Инде Ибраһим ага да вафат, көндәлек дәфтәре, мөгаен, аның гаилә архивындадыр хәзер... Зариф мәхдүм анда, дәфтәр битенең ике ягын буш калдырып, кыска юллар белән «Исагуҗи»ны («Исагоги») күчергән, аннары шул



*Әмирхан хәзрәтнең кульъязма «Шәрхел вакаят» («Саклануны ачыклау») китабының цензор мөһере сугылган бите.*

чиста урыннарга үзеннән шәрех, ягъни аңлатма язарга керешкән. Хәер, никтер очына чыгып җитмәгән. Шушы дәфтәргә ул, төгәл датасын күрсәтеп, кайбер вакыйгаларны һәм фактларны теркәп барган. Язмалар булачак мулланың юмор вә сарказмнан да мәхрүм булмаганлыгын күрсәтә.

---

[1] Шунда ук, 9 б.

1874 елда мәдрәсә тәмамлаган егерме бер яшьлек егетнең үсеш перспективалары, әлбәттә, муллалык белән бәйле инде. Казан губерна идарәсе 1875 елның 1 февралендә Диния нәзарәтенә хәбәр итүенчә, Яңа Бистәнең җамигъ мәчет мәхәлләсе (ягъни Хөсәен Әмирхан җитәкләгән мәхәллә) кешеләре Мөхәммәдзарифны мәрхүм Мөхәммәдсафа хәзрәт урынына әтисе Хөсәенгә иптәш мулла итеп сайлаганнар. Идарә булачак муллага әйбәт кенә характеристика бирә һәм тиешле имтихан алуларын үтенә. Мәхдүм Уфага юнәлә һәм, 1875 елның маенда имтихан тотып, имам хатыйп һәм мөдәррис исеменә лаек була. Шулай итеп, егерме ике яшьтә әтисенә юлдаш сыйфатында имам булып китә бу. Ләкин Мөхәммәдзариф, күрәсең, Норлат мәдрәсәсеннән соң да белем арттыруын дәвам иткән. Чөнки Ш. Рәхмәтуллин болай дип яза: «Хөсәен хәзрәт 1875 елда угылы Мөхәммәдзарифны үзенә шәриклеккә куйды. (Зариф) казанлы дәмолла Сәлахетдин хәзрәттә тәхсыйль голүм итеп (гыйлемнәр алып) һәм Кәлимулланың хафизы бәгъдендә (Коръәнне яттан белгәннән соң) имам булды»[1]. Хәер, Ш. Рәхмәтуллинның бу ике җөмләнең урыннарын буташтырган булуы да мөмкин.

1875 елның җәендә Әмирханиләрнең күршесендә генә булган Шаһиәхмәд Иманколый хәзрәт өендә ут чыгып, йорт бөтен каралтылары белән кисәүгә әйләнә. Мулланың җиһазларын, кирәк-яракларын, авыр-авыр сандыкларын чыгаручылар арасында беләкләрендә көч, күңелендә дәрт уйнап торган яшь хәзрәт Зариф та булган. Бәлага тарган Иманколыйлар гаиләсе, шул исәптән биш яшьлек Садыйк та, вакытлыча Хөсәен Әмирхан йортына күчә[2].

Мөхәммәдзариф үзенең белеме, үткенлеге, көр тавышы белән дә, җинел мәҗлесле (табигатьле) кеше булуы белән дә Яңа Бистә мөселманнары гына түгел, бөтен Казан татарлары арасында да зур абруй казанган, Ш. Мәрҗанинең якын тарафдары булып киткән. Боларны искә алып, Р. Фәхретдин үзенең кульязма «Асар»ында (1930) хәзрәткә мондый бәя биргән: «Зәки (үткен, зиһенле) вә фәтыйн (зирәк), гакыйль вә мөдбәр (акыл иясе), сәлим-әс-садыр (турылыкны башлаучы), Коръәнхафиз (Коръәнне яттан белүче) вә хуш авазлы (матур тавышлы) иде, Мәрҗани сохбәтенә дәвам итте (юлдаш булды) вә истифадә кыйлды (файда кылды)»[3].

Әтисенең һәм бабасы Хөсәеннең Мәрҗани мәсләге тарафдарлары булуын, Мәрҗани исеменең Әмирханнар гаиләсендә бик олылап телгә алынуын Ф. Әмирхан үзенең «Безнең хыялларда Мәрҗани күләгәсе» исемле мәкаләсендә (1915) билгеләп үткән иде: «Казан имамнарының, ике бер-берсенә дошман фиркаларгә (төркемнәргә) аерылышып, Мәрҗани исеме вә мәсләге тирәсендә мөҗадәлә кылышкан (бәхәсләшкән) вакытларда минем атам вә соңрак таба бабам да Мәрҗани тарафдары фиркага мәнсүб (мөнәсәбәтле) булганнар. Шунар күрә безнең гаиләдә Мәрҗани исеме, олуг бер галим, бер мөтәфәккир (фикер иясе) исеме буларак, зур бер ихтирам белән ял ителеп (искә алынып) килә иде. Әтиемнең аның исемен һәрвакыт ихтирам белән зикер итеп (искә алып) торганын ишетеп килгәнгә күрә, мин кечкенәдән үк Мәрҗани хакында сөйләнгән сүзләргә зур игътибар биргән булсам кирәк ки, шул хәбәрләр минем зиһенемдә Мәрҗанины мин күргән муллаларга охшамый торган бер кеше сымак итеп ясап калдырганнар»[4].

1881 елда булырга кирәк, егерме сигез яшьлек Мөхәммәдзариф Бибирабига бинте Зиннәтуллага никахлана. 1882 елның 1 гыйнварында аларның кызлары дөньяга килә. Исемен Бибисәгадәтбану дип куялар. Тагын дүрт елдан соң, 1886 елның шул ук 1 гыйнварында булачак бөек әдип һәм җәмәгать эшлеклесе Фатыйх Әмирхан җиһанга аваз сала. 1889 елның 5 сентбрендә аларга булачак дипломат һәм югары дәрәҗәле юстиция хезмәткәре Ибраһим өстәлә...

Яңачарак уйлый, яңачарак гамәл кыла торган, күрәсең, дөнья ләззәтләрен сөю «чир»еннән дә бик үк азат булмаган Зариф мулланың тормышы майлангандай гына бармаган, билгеле. Дус бар, дошман бар, дигәндәй, иске фикерле муллаларның Мәрҗани тарафдары булган Мөхәммәдзарифны өнәмәүләре табигый. Атасы Хөсәен дә бик картайгач, аның көнкүреше тагын да катлауланa. 1889 елда карт хәзрәт үз «постын» икенче улы Мөхәммәднәҗипкә калдырып, мәчет вә мәхәллә эшләреннән бөтенләй диярлек читләшә, күбрәк ахирәт турында уйлый

---

[1] Календарь 1894 ел өчен. Шиһабетдин... Рәхмәтулла угылының тәэлифе.., 47 б.
[2] Нуруллин Ибраһим. Фатих Әмирхан.., 10 б.
[3] Фәхретдин Ризаэтдин. Асар. Кульязма. III җөзьэ, XII җилд. Уфа, 1930, 174 б.
[4] Әмирхан Фатих. Әсәрләр. Дүрт томда. Т. 4, Казан, Таткитнәшр, 1986, 132 б.

башлый. Бер үк мәчеттә ике бертуганның имамлык итүе кайбер йогынтылы затларга бик үк ошап та бетмәгән булыр. Шуңа күрә өч бала атасы Зарифка юл куебрак, Нәҗип үзенә муллалыкны башка җирдән эзләргә керешкән, ахры. Һәм 1893 елда, Чистай ишаны Мөхәммәдзакир Габделваһапов-Камалов кызы Камиләтеннисага өйләнеп, икенче мулла сыйфатында Чулман буендагы шәһәргә күчеп киткән[1]. Мөхәммәдзарифка иптәш мулла булып Бохарада укып кайткан күршесе (теге янгын вакытында әле биш кенә яшьлек булган) Мөхәммәдсадыйк бине Шаһиәхмәд Иманколый (1870—1932) сайланган.

Казанның консерватив байларыннан һәм муллаларыннан байтак җәфа күргән Мөхәммәдзариф бервакытны энесе Мөхәммәднәҗип имамлык иткән Чистайга күчеп китәргә дә ниятләнгән булган икән. Чистайның икенче мәхәллә мулласы Мөхәммәдзакир Хәйретдинов 1893 елда вафат иткәч, аның урынына яңа имам кирәк була. Бирегә Зариф хәзрәтне чакыру турында да сүз кузгатыла, әмма ни өчендер бу «пост»ка Чистай өязе Яуширмә авылы кешесе Шиһабетдин Шәрәфетдинов сайлана. Зариф бине Хөсәен Чистай имамы булып киткән тәкъдирдә Ф. Әмирханның язмышы, мөгаен, икенче юнәлеш алган булыр иде.

Ул арада Мөхәммәдзариф өстендә болытлар куергалап ала. Әйтик, 1896 елда хәрби мулла Гариф бине Габделвәли, аның өстенә ике гаеп ташлап, Уфа Диния нәзаратына шикаять язып җибәргән. Беренчесе — яше җитми торган үсмер егеткә никах укыган икән. Икенчесе — Федор Никифоров дигән керәшен егете белән Бибисаҗидә исемле мөселман кызын рәсми төстә кавыштырган. Шикаятьне җентекләп тикшерәләр. Нәтиҗәдә икенче әләк чеп-чи ялган булып чыга, ә беренчесе раслана. Никах укытырга үтенүчеләр арасында Әхмәтҗан Апаковның, шаһитләр арасында хәзрәтнең кияве (сеңлесе Мәрьямбануның ире) Габделшәкүр Апаковның булуы мәсьәләгә беркадәр ачыклык кертә. Бәхетенә, Зариф мулла ниндидер манифест аркасында хөкемнән котылып калган[2].

Ш. Мәрҗани тарафдары, атасы Хөсәен кебек үк «үзсүзле», нык ихтыярлы Мөхәммәдзариф, билгеле инде, радикаль карашлы кеше булган, патша хөкүмәтенең милли-колониаль сәясәтен өнәмәгән, аңа каршы кадәри хәл көрәшкән. Аның азатлык, гаделлек идеяләренә теләктәшлек итүе бигрәк тә XX йөз башларына карый. Менә берничә мисал. 1905 елның 16 ноябрендә Казанның «Сарай» номерларында гамәлдә булган сәяси партияләрнең программалары тикшерелә. Бәхәс башлана. Әйтик, бирелә катнашкан социал-демократлар, «мөселманнар өчен аерым бер партия булырга мөмкин түгел, чөнки байлар белән эшчеләр бер фиркадә уртак тел таба алмаячаклар», дип белдерәләр. Әлеге җыелышта, башка радикаль зыялылар белән берлектә, Зариф Әмирхани дә катнаша, һәм бу хакта яшерен төстә жандарм идарәсенә хәбәр итеlә[3].

Шул ук идарәгә 1908 елда икенче документ килеп керә. Охранканың ышанычлы бер агенты (исеме теркәлмәгән) Казан губерна жандарм идарәсенең (КГЖУ) күрсәтмәсе буенча татарлар арасындагы настроениеләрне ачыклау максатында иң зур авылларны йөреп чыга һәм тиешле справка төзи. Бу белешмәдә «ышанычлы кеше», татарлар арасында хөкүмәтнең урыслаштыру сәясәтенә каршы оешкан панисламчыл хәрәкәт бар, дип күрсәтә һәм хәрәкәтнең җитәкчеләре арасында Зариф Әмирхани исемен дә атый[4]. Казан кәсепче-фабриканты Якуб Козлов («Кәҗә Якуб») та хәзрәтне «иң сул карашлы» кеше итеп сурәтли. Жандармериянең ышанычлы хәбәрчесе, Казан шәһәре хәрби мулласы Фәсах Мөхетдинов (Әминә Мөхетдинованың атасы) КГЖУга Яңа Бистә имамының «сәяси яктан ышанычсыз»лыгын раслый. Үзенең биргән күрсәтмәсендә ул болай дип яза: «Зариф Амирханов ведет антиправительственную пропаганду очень осторожно и очень секретно»[5].

1908 елда ук Казанның уникe мулласы Эчке эшләр министрлыгына Зариф Әмирхан һәм Шәһретдин Шәрәф өстеннән шикаять яза, аларның «хөкүмәткә каршы» эш алып баруы хакында белешмә бирә[6]. Әлеге һәм башка әләкләр нигезендә КГЖУ башлыгы 1910 елның 12 июнендә мондый карар чыгара: Мөхәммәдзариф Әмирхани белән Шәһретдин Шәрәф өстеннән яшерен күзәтү («негласное наблюдение») оештырырга[7].

---

[1] Бу хакта тулырак итеп безнең «Чистайлы Әмирханнар» дигән әсәрдә язылган.

[2] Нуруллин Ибраһим. Фатих Әмирхан... 10 б.


[3] Мәһдиев Мөхәммәт. Фатих Әмирхан (Тормышы һәм иҗат юлы турында кыскача очерк. Казан, Таткитнәшр, 1986. 49 б.; Магдеев М. С. Социальные корни таланта. Изд-во Казанск. ун-та, 1990, с. 92.

[4] Магдеев М. С. Социальные корни таланта, 92 б.

[5] Шунда ук.

[6] Шунда ук.

[7] ТРМА, 199 — ф., 1 — тасв., 1715 — эш, 156 документ.




*Казан кальгасының XIX гасыр башындагы күренеше. Э. Турнерелли буенча.*

1911 елның 27 гыйнварында Казанның Галиев мәчетендә (Г. Баруди имамлык иткән мәчет) Мөхәммәд галәйһис-сәламнең туу көне (мәүлид) уңае белән тантана намазы укыла. С. Зәбири дигән провокатор-мулла бу хакта Русиянең Эчке эшләр министры Макаровның үзенә хәбәр бирә һәм, намаз вакытында Зариф Әмирхани хәзрәт белән берничә кеше патша әгъзам хәзрәтләренә бәддога укыдылар, дип күрсәтә. Билгеле, тиз арада бу «эш» буенча тикшерү башлана. Ләкин бәддоганың патша хәзрәтләренә түгел, ә әләкче-шымчыларга адреслануы ачыклана[1].

«Сәяси яктан ышанычсыз» хәзрәткә, мәгълүм инде, идарәче даирәләр, карагруһчылар тарафыннан гел киртәләр куелып килә. Әйтик, 1908 елда яхшы ук эшлекле (практичный) Мөхәммәдзариф китап сәүдәсе белән шөгыльләнү максатында әллә кибет, әллә ширкәт сыманрак бер нәрсә ачарга ниятли, әмма, рәсми рөхсәт алса да, теләген тормышка ашыра алмый, кемнәрдер аяк чала.

1913 елның мартында указлы имам-хатыйп һәм мөдәррис Зариф хәзрәт, «потомственный почетный гражданин»нар Габдулла Апанаев, Мөхәммәдрәхим Казаков, Шакир Апанаев, Мөхәммәдрәхим Юнысов, Габделвәли Юнысов, «статский советник» Ибраһим Терегулов, сәүдәгәрләр Салих Гобәйдуллин һәм Шәрифҗан Кәримов губерна идарәсенә оештыручылар (учредительләр) сыйфатында бер культура-агарту җәмгыяте төзү турында үтенеч белән мөрәҗәгать итәләр. Җәмгыятьнең рәсми исеме болай була: «Казанское культурно-просветительское общество распространения образования среди мусульман»[2]. Әлбәттә, бу абруйлы шәхесләр Романовлар сөяләсенең (династия) 300 еллыгы бәйрәменә һәм шуңа бәйләнешле «шәфкать адымнары»на өмет баглый.

Ләкин юкка гына. КГЖУ башлыгы ротмистр Кирсанов биргән мәгълүматлар буенча, 1911 елда И. Терегулов Уфа губернасы земство идарәсенең рөхсәт ителмәгән съездында катнашкан (ә анда мөселманнарны гомуми укыту мәсьәләсе дә күтәрелгән), Ш. Кәримовның өендә шул ук елда тентү үткәрелгән һәм ул хөкемгә тартылган булган. Зариф хәзрәтнең «гөнаһлары» тагын да борынгырак булып чыккан: ул 1909 елда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөгаллимнәренең сәяси ышанычлылык мәсьәләсен тикшергәндә «кармакка эләккән», өстеннән хөкем эше кузгатылган, аннары артыннан яшерен күзәтү оештырылган булган икән (бу хакта югарыда да телгә алынды). Шуңа күрә эшне кыска тоталар. 29 апрельдә Русиянең Эчке эшләр министрлыгына мондый яшерен рапорт юллана: әлеге исемлектәге

[1] ТРМА, 199-ф., 1-тасв., 2269 эш, 189, 199 документлар.
[2] ТРМА, 1-ф., 4-тасв., 5445 — эш, 1 б.

кайбер шәхесләрнең сәяси яктан ышанычсызлыгы бу оешманы төзү турындагы үтенечне канәгатьләндерергә мөмкинлек бирми[1].



*Әмирханнар 1810—1921 елларда имамлык кылган «Иске таш мәчет». Яңа Бистә. М. Гафури ур., 34а.*

Ата-бабаларының юлын тоткан, ачык зиһенле Мөхәммәдзариф, традиция буенча дип әйтикме, мәгърифәт, дини тәрбия җирлегендә хезмәтләр дә иҗат иткән шәхес. Шуларның безгә иң мәгълүмнәре болар: «Әхадисе нәбәвыядән (пәйгамбәрләрнең хәдисләреннән.— Р. Ә.) беренче кисәк». Казанда «Юл» китапханәсе нәшриятында 1909 елда басылган, күләме 15 бит. Шул ук елда «Үрнәк» матбагасында тегесенең дәвамы булып унике битле «Әхадисе кодсия. Икенче кисәк», ягъни «Изге хәдисләр»нең икенче өлеше дөнья күргән. Янә шул ук 1909 елда «Әхадисе кодсия»нең («тәрҗемәсе илә») тулырак егерме ике битле варианты нәшер ителгән. Бу китаплар, бер тезмә тәшкил итеп, мәдрәсәләрнең рөшдия (урта) сыйныфлары өчен төзелгән, заманында абруйлылардан саналган.

Аннары шунысы да бар: әтисенең югарыда телгә алынган «Тәварихе Болгария...» китабына аның да беркадәр өлеше кергән, чөнки мәдрәсәләрдә дәреслек-кулланма сыйфатында йөргән бу хезмәт Мөхәммәдзариф хәражаты белән, ягъни акчасына, чыгарылган.

Зариф хәзрәт—1913 елның апрелендә сөекле шагыйребез Тукайның җеназасын укыган кеше. Әлбәттә, мондый зур вазифаны аңа ышанып тапшыру—З. Әмирханигә ышаныч, олуг ихтирам билгесе. Гомерендә рәсемгә төшмәгән, бу гамәлне өендә дә өнәмәгән мулланы Тукай җеназасы вакытында гына төшереп калганнар. Бу аның үз гомерендә «теркәлеп» калган бердәнбер фотосурәте, анда да төркем эчендәгесе әле.

Мөхәммәдзариф заманында «Әмирхания» мәдрәсәсе дә сизелерлек уңышка ирешкән, Казан мөселман уку йортлары арасында мактаулы урын тоткан. Анда төрле вакытларда сиксәннән алып бер йөз егермегә кадәр шәкерт белем алган.

Зариф мулла замандашлары хәтерендә киң күңелле, кунакчыл, мәзәк сүз яратучан, Миргазиз Укмасый истәлекләренә караганда исә, «итәгенә ут капса да» пошаманга төшмәс бер зат булып уелып калган. Госман Әмирхани белән Хаува Әмирхания-Ахундова хәтерләве буенча, бервакыт, Чистайга кунакка килгән чагында, Мөхәммәдзариф Мөхәммәднәҗип өе тирәсендәге тугайда чабыш ярышы оештыра. Малайларның олысы-кечесе йөгергәннән соң, ул ярышка Чистайның абруйлы имамы булган энесен чакыра. Нәҗип хәзрәт баш тартмакчы булса да, Зариф мулла аны, ай-ваена куймыйча, йөгерергә күндерә. Башта бу ике «сакаллы сабый» тигез йөгерсәләр дә, бераздан алты яшькә өлкән, бераз юантыграк Зариф калыша башлый. Алай да сер бирәсе килмичә, «ат буйлады» диган булып, кырыйга чабып кереп китә, ягъни аты хуҗасына буйсынмаган, янәсе. Мөгаен, нәкъ менә аның шушы мәзәкчеллеге, күңел көрлеге, нәселдән килгән аерым бер сыйфат буларак, улы Фатыйхка да күчкән булгандыр, чөнки мәзәк сүз сөйләү, сүз уйнату өлкәсендә әдип әтисеннән дә уздырып җибәрә торган үткен телле кеше була.

Истәлекләрдә Зариф мулла бик мәһабәт кыяфәтле, ачык-мөлаем йөзле, кешеләрнең күңелен тиз җәлеп итүчән зат буларак гәүдәләнә. Күршесе Сафия Зыя кызы Ваһапова-Локманова (1904—1996), хәзрәтнең килеш-килбәтен, чыраен күздә тотып, урысча «было на что посмотреть» дип әйткән иде.

Туганнары белән бик йөрешә-аралаша, бүләк бирергә ярата торган кеше була ул. Әтиебезнең тугыз-ун яшьлек вакытыннан калган хатирәсе буенча, бервакыт «дәү әтисе» (Нәҗип балалары аны «дәү әти» дип йөрткәннәр) Казанга кунакка

---

[1] ТРМА, 1 ф., 4 тасв., 5445 эш, 12 б.

килгән Госманны жырлатып ала, башыннан сыйпый, аннары унбиш тиенлек көмеш биреп, малайны төшенә дә кермәгән «байлыкка күмә». Бертуган сеңлесе Мәрьямбану гаиләсенә дә капчык-капчык әйбер алып килүе мәгълүм могтәбәр хәзрәтнең.

Мөхәммәдзариф бине Хөсәен 1921 елның 24 июнендә ваба хәстәсеннән көтмәгәндә диярлек үлеп китә. Фатыйх Әмирханга сүз бирәбез. Әтисенең ахирәт дусты, үзенең остазы дамелла (инде мөфти) Галимҗан Барудига 28 июльдә язган кайгы хатында ул, аерым алганда, болай ди: «Әтинең вафаты безнең өчен бик көтмәгәнемез бер вакытта булып китте: бу ел кышны ул нисбәтән (чагыштырмача) таза һәм сәламәт уздырган иде. Авыру мөддәте (вакыты) бөтенләе утыз сәгать микъдарыннан артмады. Иң ахыр дәкыйкасенә (минутына) кадәр мин аның хәятыннан өмид кисми килдем: менә-менә терелеп китәр шикелле тоела иде. Соңгы елларда инде әти миңа бер ата гына түгел, бәлки һәм бер иптәш һәм бер дуст та иде: берничә көннәр өйдә булмый торсам, мин аны сагынып, кечкенә балалар шикелле сагынып кайта идем. Менә шунлыктан әтинең вафаты миңа ике катлы бер зыягъ (югалту), мөрәббәгъ (бөтен яктан) бер хәсрәт булды. Юаныч бер генә: иннә Аллаһе вә иннә илайһи раҗигун (Алладан килгән — Аллага кайта)»[1].

Инде Мөхәммәдзарифның хәләл җефете, остазбикә Бибирабига Зиннәтулла кызы Абдуллина-Әмирхания (1852—1918) турында берничә сүз. Рабига Балтач төбәгендә туган, 1881 елда Зариф хәзрәткә никахланып, остазбикә булып киткән. Бик купшы һәм пөхтә киенергә яраткан ул. Кунакка барырга җыенганда, күзгә каршысына басып, кара күзләренә сөрмә тартуны үзенә бер гадәт иткән. Чандыр гына, кечерәк буйлы, бик хәрәкәтчән, озын кара чәчле бу хатын үзенең зирәклеге һәм булдыклылыгы белән аерылып торган. Ул һәр көнне кич Зариф хәзрәт янына килеп, гарәп теленнән һәм грамматикасыннан дәрес алган, иртә белән бар кешедән иртүк торган, кешегә эш тапшырырга яратмаганлыктан, сыерын савып, өй



*XIX йөз башында бина ителгән «Әмирхания» мәдрәсәсе. Бүгенге күренеше. Зайцев ур., 4. Алгы планда Равил һәм Гөлназ Әмирханнар. 13 апрель 1997 ел.*

эшләрен караган, аннары үзләренең ишегалдына гына урнашкан мәктәбенә килеп китә торган булган. Үзенең мөстәкыйль хәзерләнүеннән һәм картыннан алган консультацияләрдән файдаланып, кыз балаларга дәрес биргән. Үләренә берничә генә ел калганда ул улы Фатыйхтан һәм оныгы Разиядан урысча укырга-язарга өйрәнгән. Күрәсең, бу белеменнән балалар укытканда да файдалангандыр.

---

[1] Әмирхан Фатих. Әсәрләр. Дүрт томда. Т. 4, 297 б.

Бибирабига, бик тырыш остазбикә буларак, балалар укытып кына калмаган, бәлки укыту өчен кулланмалар да язган икән. Шундый хезмәтләрнең берсе — «Нәҗател-мөкәлләфин» («Җаваплылыктан котылу») 1910 елда «Юл» нәшриятында басылган. Егерме җиде битле китапчык башлангыч мәктәпнең икенче-дүртенче сыйныфларына тәгаенләнгән.

1982 елда миңа заманында Бибирабига Әмирхания мәктәбендә укыган җитмеш алты яшьлек Хәдичә апа Шәрипова-Гобәйдуллина белән әңгәмә корырга насыйп булган иде. Аннан язып алган мәгълүматларны монарчы матбугатка чыгарырга туры килмәгәнлектән, кызлар укытуга кагылган өлешен бирәдә тулысынча китерү мәгъкуль булыр. Шуны гына искәртәм: Хәдичә апа остазбикәнең укыту урынын, башка чыганаклардан аермалы буларак, үзе торган өй (олы як), дип күрсәтә. Ихтимал, бу чорда төп йортта да дәрес әйтелгәндер. Хәдичә апаның сөйләвенчә болай:

— Фатыйх абыйның әнисе Рабига абыстай, остазбикә буларак, гомер-гомергә өендә кызлар җыеп укытты. Мин — аңардан сабак алган кешеләрнең берсе. Абыстай кызларны безгә кадәр инде байтак укытып килгән, ул вакытта әле парталар да булмаган. Без укыган чорда ул үз тәшәббесе (инициативасы) белән тәбәнәк кенә парталар ясаткан һәм аларда утырып уку тезләнеп утыруга караганда күп тапкыр уңайрак иде. Абыстай дәресләрне гел олы якта алып барды, дәрес вакытларында ул бүлмәгә кемнең дә булса кереп-чыгып йөрүен мин хәтерләмим.

Алган сабагыбыз кадимчә дә, җәдитчә дә булмады. Әмма дөньяви предметларга артык зур игътибар бирелмәде кебек. Укыган китапларыбыз «Мөгаллим әүвәл», «Мөгаллим сани», фарсыча «Кодурилар», шулай ук «Хәдисләр» булды. Тагын борынгы тарих укыганыбыз хәтеремдә. Абыстай китаплардан безне аерым-аерым да, хор белән дә укытты, төрле, мәсәлән, «Шатлык бу, шатлык» дип башлана торган җырлар җырлатты. Рабига абыстай шигырьләргә дә зур әһәмият бирде. Г. Тукай, С. Рәмиев, М. Гафури әсәрләре безнең аерылмас юлдашларыбыз иде. Еш кына инша (изложение) язуыбыз хәтеремдә.

Абыстай безгә таләпчән булды. Күп укыта һәм күп сорый торган иде ул. Җавапларга билгеләр куела, иң зур дәрәҗә «9» яки «10» булып, ул безгә бик сирәк эләкте бугай. Миңа «9» яки «10» билгеләре алырга да насыйп булгалады, кайвакыт «афәрин», «тәхсин», «имтияз»лардан да (мактауның төрле дәрәҗәләре) өлеш чыга торган иде.

Сабак атна буе дәвам итә. Ә җомга көн — ял. Кече атнаның дәрестән соңгы вакыты безнең өчен үзенә күрә бер кичәгә әйләнә: анда без шигырьләр сөйли, җырлар җырлый, күмәкләшеп төрле уеннар уйный торган идек.

Рабига абыстай мәктәбендә ел саен имтиханнар булуы хәтеремдә. Анда үзенә күрә комиссия вазифасын үтәгән ниндидер кешеләр чакырыла. Аларның кем булуы хакында ачык әйтә алмыйм. Имтиханга хәзерләнеп керә торган идек. Абыстай укытып сөйләтеп карый, сораулар бирә, билгеләр куя. Имтихан соңында безгә шәһадәтнамәләр (таныклык яки ведомость) тапшырыла. Һәр елны, имтихан вакытлары җиткәч, шушы Яңа Бистәдәге Габдрахман бай хәраҗаты белән (акчасына) безгә, бик үк күркәм булмаса да, күлмәклекләр бирелә. Без Рабига абыстай җитәкчелеге астында һәммәбез пардан күлмәкләр тегеп киябез, һәм бу безнең өчен үзе бер бәйрәм була торган иде.

Кайвакытта мөгаллимәбез безнең арадагы чиста-пөхтә, уңганрак кызларны, бер бүлмәгә алып, кухня эшенә куша. Бу безгә үзенә күрә бер йорт эшләре мәктәбе дә булгандыр, дип уйлыйм. Коляскага береккән инвалид Фатыйх абый аеруча түгәрәкләп ясалган ит (бифштекска охшаган нәрсә) ярата иде. Абыстай, аның бу ихтыяҗын үтәү йөзеннән, шушындый ит әзерләргә безне дә ярдәмгә чакыра, шул ысул белән дә эшкә өйрәтә иде.

Өендә бер-ике ел укытканнан соң, Рабига абыстай безне мамык фабрикасы каршындагы «Әмирхания» мәдрәсәсенә, ягъни таш мәктәпкә алып килде. Ул безгә: «Балалар, без аерылышабыз, сез инде хәзер шушында укырсыз»,— диде. Абыстайдан аерылу һәммәбезгә бик кыен булды, без инде аңа тәмам ияләнеп беткән, аны яратып өлгергән идек...

Бибирабига Әмирхания 1918 елның 18 апрелендә алтмыш алты яшендә иреннән өч ел элек тифтан вафат була һәм Яңа Бистә зиратында дәфен кылына (җирләнә).

Бергә кырык еллап гомер иткән хәләл җефетен югалтуны Мөхәммәдзариф бик авыр кичерә, бу кайгы аның рухын шактый ук сындыра, сәламәтлеген какшата. Мулла кешегә җәмәгатьсез тору шәригатькә хилаф бер нәрсә булса да,


تواريخ بلغاريه
انتخب من التواريخ
المتعددة

*Хөсәен Әмирханның атаклы «Тәварихе Болгария» («Болгар тарихы») китабының титул бите. 1883 ел.*

хәзрәт үзенә икенче юлдаш табуны һаман сузып-кичектереп килә. Ике ел дәвамында дип әйтерлек аңа төрле яктан яңа хатын димлиләр. Заманының гадәте буенча, хәзрәт һәр очракта истихарә кылып карый, ягъни ниятли, әмма истихарәсе туры килми: чираттагы абыстай аңа хатынлыкка ярамый дигән сүз була бу. Ахыр чиктә, 1921 елның башында булса кирәк, димче-арадашчылар аркылы Зариф муллага тагын бер хат килеп ирешә. Инде аңа алтмыш бер яшьлек Хәдичә карчыкны димлиләр. Хәзрәт янадан ниятли, бу юлы инде истихарәсе әйбәт күренә. Һәм Әмирхани, хатынның үзен күреп белмәсә дә, аңа никахланырга ризалыгын белдерә.

Хәдичә карчык, димәктән, аның хакында да берничә юл язып үтү урынлы булыр. Бу турыдагы кыскача мәгълүматны без Хәдичәнең оныгы, 1909 елның 19 декабрендә туган, бүгенгәчә Габдулла урамындагы 37 йортта яшәүче (димәк, йортлары Зариф хәзрәт өенә терәлеп тора) Сара апа Мәҗитовадан алдык (1995 елның 6 сентябре). Заманында Хәдичәне (Күчеш авылы Хәким хәзрәт кызын) Шырдан мулласының улы Гыйльфанга кияүгә биргән булалар. Аның бу никахтан Мөхәммәднәкыйп (1885—1946, Сара апаның әтисе) һәм Ишмөхәммәд исемле уллары туа. Ире вакытсыз дөнья куйгач, Хәдичә, ике баласын ияртеп, Казанга күчеп килә. Тол хатын бераздан каты авырып китә һәм туганнары ике малайны да приютка урнаштыра. Беркадәр тернәкләнгәч, Хәдичә ниндидер Галимулла исемле байга (тегүче булган, имеш) бишенче хатын буларак никахлана, әмма бер ай да торырга өлгерми, тагын авырып китә (Сара апа сүзе буенча, «юләрләнә»). Савыккач, утыз өч яшьлек хатын улларын, приюттан алып, үзе тәрбияли башлый, икесен дә үстереп, башлы-күзле итә. Инде алтмышларын тутырып килгән карчыкның шәхси җәһәттән әлләни зур планнары булмый. 1918 елда Бибирабиганың кинәттән үлеп китүе аның тормышында кискен борылыш ясауга сәбәп була.

Хәдичә Зариф хәзрәтне электән үк яхшы белгән һәм аңа күңел куйган булса кирәк. Остазбикәнең вафатыннан соң, хатын күңелендә хәзрәтнең җәмәгате булу теләге бермә-бер көчәеп китә. Һәм ул «Йа Раббым, шуның никахында булсам иде» дип атна саен Коръән-рәхим укый, иртәле-кичле Аллаһе Тәгаләгә ялвара башлый. Тәкъдирнең язганы булгандыр инде, нәкъ шул вакытта, уңай истихарәсе тәэсирендә, Зариф хәзрәт димче хаҗига (Сара апа әйтмешли, «хаҗианигә») Хәдичә турында хат юллый. Хаҗи, хатны алу белән, тол хатын янына юнәлә һәм болай ди:

— Хәдичә, миңа Зариф мулладан хат килде, аңа барырга ризалыгың юкмы?

Хатын, әлбәттә, риза. Зариф хәзрәткә күптән күңел куюы өстенә, аның Яңа Бистә остазбикәсе буласы килә. Кем белә, бәлки, бу Хәдичәнең гомерлек хыялы булгандыр. «Байлыгым юк, әмма мәхәллә халкын кулда тотарлык рәтем бар»,— ди икән үзе. Ләкин әш әле Хәдичә ризалыгы белән генә бетми. Уллары Мөхәммәднәкыйп белән Ишмөхәммәд әниләрен «акылга килергә» өндиләр, янәсе, утыз өч яшьтән бирле ирсез утырып, картаймыш көнеңдә адәм көлдермә, килене Мәрфуга белән тыныша алмаган, шуңа күрә чыккан икән, диярләр. Әмма остазбикәлек перспективасы алдында тол хатын улларының һәм киленнәренең үгетләвенә бирешми.

Эшне кызу тоталар. Фатыйхның да катнашы-арадашлыгы белән, никахны 1921 елның гыйнварында җомга көн укыйлар, ике арада кунакка йөрешәләр, нәсел-нәсәп кодалаша. «Яшь» остазбикәгә подноска салып Бибирабиганың затлы күлмәген, казакиен, калфагын, балдагын һәм башка әйберләрен тәкъдим итәләр. Шулай итеп, алтмыш бер яшьлек Хәдичә, өченче мәртәбә кияүгә чыгып, гомерлек хыялына


ирешә — бердән, Зариф хәзрәт хатыны, икенчедән, Яңа Бистә остазбикәсе булып китә.

Кызганыч, яңа гаиләнең гомере бик кыска булып чыга. Хәзрәт белән остазбикә февральнең буранлы бер көнендә Бишбалтага (бәлки, мәрхүмә Сәгадәтнең ире Габдулла хәзрәткәдер) кунакка баралар. Шуннан кайтышлый Хәдичә бик нык салкын тидерә һәм, үпкәләренең ике яклап шешеп ялкынсынуы аркасында, өч атна да үтмәстән, февраль азагында үлеп китә (1860—1921).

Зариф хәзрәт гомер юлдашыннан икенче тапкыр мәхрүм кала һәм моннан соң инде үзе дә озак яшәми. Хәер, тарих өчен монысын да теркәп куйыйк. Сафия апа Локманова ничектер бервакыт хәзрәтнең өч мәртәбә өйләнүе хакында әйткән иде. Бу хәбәр дөрес булса (XIX гасыр метрикаларын карыйсы бар), Зариф мулла әле Бибирабигага хәтле үк башка бер хатынга никахланган, дигән сүз (балалары булмавы мөмкин).

* * *

Хөсәен Әмирханинең Әүхәдетдин, Мөхәммәдхарис, Мөхәммәдгариф исемле угыллары хакында мәгълүматыбыз юк, мөгаен, алар кече яшьтә вафат булганнардыр. Ә кызы Мәрьямбану (икенче никахтан туган булырга тиеш) турында бернічә сүз әйтергә мөмкинлегебез бар. Мәрьямбану 1876 елда дөньяга килгән. Кыяфәтендә дә, гамәлендә дә гүзәл кызны уналты яшендә үзеннән уналты яшькә өлкән уртакул сәүдәгәр Габделшәкүр Мортаза улы Апаковка (1860—1923) кияүгә бирәләр. Хәзерге Тукай урамындагы «чат» йортка (анысы янганнан соң икенчесен салып керәләр) ике сыер белән (бирнә булгандыр инде) килен булып төшкән. Әхлак, әдәп, миһербанлык җәһәтеннән замандашларына үрнәк бу ханым җиде балага җан өргән (икесе сабый чакта дөнья куйган). Атасы Хөсәен хәзрәт Төркиядән китаплар, гәзит-журналлар алдырып укыганлыктан, кызын да төрекчәгә өйрәткән. Мәрьямбану бу телдә укыган гына түгел, иркен сөйләшкән дә. Балаларына шәфкатьле ана, уңган хуҗабикә 1919 елда кырык өч яшендә үпкә чиреннән вакытсыз вафат булган һәм Яңа Бистә зиратында күмелгән.


بو كتاب باصمه اولنمشدر قزانده چيركوف خاتوننك طبعخانه سنده
طبع ... ١٣٠١ نچى سنه
* من الهجريه وماه ذو الحجه *

بو كتابنك باصمه سنه رخصت بيرلدى سانكت
پيتربورغده ٣ نچى آپريل ١٨٨٤ نچى يلده

* ( تيپوگراف وول گوكووين اسمنده ايدى ) *
* ( ايندى بابل چيركوف خاتوننك اسمنده ) *

*Мөхәммәдзариф бине Хөсәен бине Әмирханның «Мин әл-һиҗрия вә маh зөлхиҗҗә» («Һиҗридән һәм зөлхиҗҗә аеннан») китабының тыш бите. 1884 ел.*

## Кыска гомерле мөгаллимә

Инде Казанлы Әмирханнарның яңа буыны турындагы фасылга күчәбез. Яшь ягыннан алганда, безнең игътибарны беренче чиратта Зариф хәзрәт кызы Бибисәгадәтбану (1882—1911) җәлеп итәр. Бик мөлаем һәм уңган бу кызны унҗиде яшендә (1899 елда) Бишбалта мулласы, үзеннән унбер яшькә олы Габдулла Насретдин улы Әмирханигә (1871—1933) кияүгә бирәләр. Бер нәселдән булмаса да, фамилияләренең тәңгәл килүе — бик кызыклы күренеш. Әмирхания, никахланганнан соң, фамилиясен шул ук Әмирханиягә «алыштыра». Өч баласы (ике малай, бер кыз), мантый алмыйча, сабый чакта ук вафат була. Ниһаять, 1904 елда туган Разия исемле кызы, тернәкләнеп китеп, байтак кына гомер сөрә (1904—1968). Ике улы да үсеп, үз көннәрен үзләре күрә торган ир-егетләргә әверелә: Мәхмүд (1906—1975), Зәкәрия-Закир (1909—1984).

Башлангыч белемен әнисе Бибирабигадан һәм әтисе Мөхәммәдзарифтан алган Сәгадәт, күрәсең, тагын кайда да булса укыгандыр яисә мөстәкыйль рәвештә күп шөгыльләнгәндер. Мулла Габдулланың хәләл җефете, остазбикә булып киткәч, бик тырышып Бишбалтаның «Әмирхания» кызлар мәктәбендә укытырга керешә. Кем белә, бәлки, ул бу шөгылен әнисенә ярдәм итешеп, Яңа Бистәдә үк башлап җибәргән булгандыр. Сәгадәт Әмирхания мәктәбенең даны шактый киң тарала. Аның хакында көндәлек татар матбугатында күп укырга мөмкин. Биредә «Әл-Ислах» гәзитендә 1908 елда басылган ике генә хәбәр китерәбез:

1) «21 апрельдә Бишбалтада Сәгадәт Әмирхания кызлар мәктәбендә имтиханнар башланачак. Имтихан күрергә теләгән ханымнар 9—13 сәгатькә кадәр мулла Габдулла Әмирхани йортына тәшриф итсеннәр (килсеннәр). Имтиханнар өч көнгә сузылачак»[1].

2) «21 апрельдә Бишбалтада Сәгадәт ханым Әмирхания мәктәбендә сәнәви (еллык) имтихан булды. Имтихан гүзәл сурәттә үтте. Имтихан тыңларга килгән ханымнарның кайсыберләре укучы кызларга бүләкләр дә алып килгәннәр иде»[2].

Әмма ни аяныч, мөгаллимә буларак абруе көннән-көн күтәрелә барган Бибисәгадәтбануның гомере озын булмый. Чираттагы баласын таба алмыйча, тулгак вакытында егерме тугыз яшьлек ханым дөньядан үтә. Ике яштән җиде яшькәчә булган өч сабые (дүртенчесе бик аз яши), ана назыннан мәхрүм булып, ятим кала. Татар матбугаты, бу югалтуны зур бер фаҗигагә тиңләп, аһ ора. Бигрәк тә тәэсирле, үзәк өзгеч материаллар «Нур», «Йолдыз», «Вакыт» гәзитләрендә басыла.

Тирән кайгы белдерүнең типик бер мисалы сыйфатында «Йолдыз» гәзитендә басылган һәм «Сәгадәт ханым вафаты»[3] дип исемләнгән мәрасимгә урын бирәбез. Бу язмага мәрхүмә мөгаллимәнең укучылары Мәсфуфә Габидуллина, Гөлчәһрә Әхтәмова, Рабига Зәбирова, Гөлчәһрә Усинова, Диләфрүз Усинова, Мәрьям Гобәева, Асия Усинова, Мәрьям Әхмәтова, Сара Бикчәнтәева, Маһруй-Шакир кызы, Нурелбанат Ибраһим кызы, Сара Шиһабетдин кызы, Сара Биктаһир кызы, Камилә Мифтахетдин кызы, Фатыйма Әхмәтҗан кызы, Хәйрелбанат Миргазиз кызы — барлыгы уналты кеше кул куйган.

«Бу ел зөлхиҗҗәнең 10 ынчы көнендә, 18 ноябрьдә остазымыз Сәгадәт ханым 29 яшендә вилядәт мәрзыннан (тулгак чиреннән) вафат идеп, безләре, тугрысы, бөтен әүляде милләте (милләт балаларын) фәукыйльгадә мәхзүн вә мөтәәссиф кыйлды (чиктән тыш кайгылы һәм көенечле итте). Мәрхүмә галимә, фәукыйльгадә (гадәттән тыш) иҗтиһадлы (тырыш), мисалы аз булырлык дәрәҗәдә хөсне (күркәм) холыклы, тәрбия вә тәгълимгә (гыйлем бирүгә) оста, чын яхшы мөгаллимәләрдән улдыкыннан, әлбәттә, мондай бер хадимәтел-милләтнең (милләткә хезмәт итүченең) вакытсыз безнең арадан югалуы бөтен әүляде милләт өчен дә бөек заегатьтән (югалтудан) хисап иделергә тиештер.

Ун ел кәнде ханәсене (үз өен) әүляды өчен мәҗанә (түләүсез) мәктәп идеп, 4 сыйныф ибтидаи (башлангыч), 2 сыйныф рөшди (урта) фәннәрене һәм кул һөнәрләрене иҗтиһад илә тәгълим кыйлды (тырышып укытты). Милләте өчен ихтыярында улан (булган) бар кадәр гайрәтене кызганмай, сыйххәтене (исәнлеген) дә милләте юлына фида кыйлды.

Җеназасында хазир булган (катнашкан) җәмәгатьнең күплеге, аларның күзләрендә улан яшь, йөзләрендә улан изтыйраб (көенү) вә хәсрәт галәмәтләре дә мәрхүмәнең бер надирәтелвөҗүд (сирәк очрый торган) вә хезмәте миллиясе (милләткә хезмәте) һәркем тарафыннан тәкъдир иделерлек галиятелҗәнаб (олуг зат) улдыкын ап-ачык күрсәтә иде. Мәрхүмә Казан шәһәрендә дамолла Зариф хәзрәт Әмирхановның бердәнбер кызы улып, Бишбалта Габдулла хәзрәт Әмирхановның зәүҗәсе (хатыны) иде. Вафатыннан соң дүрт сабый балалары һәм зәүҗе (ире) Габдулла хәзрәт калып, Аллаһе Тәгалә хәзрәтләре анларга (аларга) сабыр җәмил (күп сабырлык) вә остазымыз Сәгадәт ханым хәзрәтләренә дә әҗер җәзил (күп савап) ихсан кыйлсын. Амин».

Бу фаҗигадән соң күп тә үтми, Габдулла мулла Гайшә Йосыф кызы Мишкинага (1888—1960) никахлана. Яңа остазбикә Сәгадәтнең эшен дәвам итеп, аның мәктәбендә дәрес әйтә, өч ятимгә ана булып китә. Үзенең дә ике баласы дөньяга килә: Мәсгуд һәм Әнәс. 1923 елда туган Әнәс Габдулла улы Әмирханов — җөмһүриятебездә танылган профессиональ рәссам. Ә Мәсгуд Свердловск шәһәрендә заводта алган җәрәхәтеннән вафат була.

*Ахыры киләсе санда.*

---

[1] Әл-Ислах, 1908, 19 апрель.
[2] Әл-Ислах, 1908, 4 май.
[3] Йолдыз, 1911, 6 декабрь.

Әмирхан Еники

# ГӨМБӘГӘ БАРУ

...Сентябрь ахырлары иде бугай — көннәр тын, талгын, җәйгечә җылы гына... Әбиләр чугы диләр мондый көннәрне... Менә шундый бер көнне миндә кинәт кенә кая да булса барып йөреп кайту теләге туды. Иртәнге чәйдән соң бераз эшләп тә утырган идем, ләкин вакыт җитәрлек иде әле... Тик кая барырга — билгеле инде, урманга! Көзге урманның үзенә генә хас хозурлыгы була бит, күреп калырга кирәк. Аннары гөмбә вакыты — аны эзләү дә бик күңелле. Акларын тапсаң — хәзинә тапкандай буласың...

Ләкин ялгыз баруның кызыгы аз — кемне чакырырга? Тоттым да Фатихка (Хөснигә) чылтыраттым.

— Фатих, сәлам!.. Көн бик әйбәт, әйдә, якын тирәдәге берәр урманга барып йөреп кайтыйк әле, булмаса!

— Һе...— дип куйды Фатих.— Кая, парккамы?

— Парк урманмени... Ераккарак, чын урманга!

— Шулай да кайсы тарафдарга?..

— Ну, Биектауга табарак...

Фатих кыска гына көлеп куйды да:

— Тиле! — диде.— Көн үтеп бара ич инде...

— Борчылма! — дидем сүзен бүлеп.— Вакыт җитәрлек әле. Безне минем кияү машинада илтеп ташлар.

...Шуннан соң телефон трубкасы шактый тынып торды.

— Йә, ник дәшмисең? — дидем ахырда.

— Сагыз булдың син дә... Мәрфуга бикәдән рөхсәт сорадым...

— Соң?..

— Фатихасын бирде... Тик синең белән миңа гына ышанып бетми... Тагын бер тәүфикълы кеше дә кирәк. Кемне ияртәбез?..

— Кемне, кемне? — дидем әз генә уйланып.— Хәсән абзый белән сөйләшеп кара. Ул урманда йөрергә ярата бугай...

— Дөрес. Чын тәүфыйк иясе... Сөйләшермен. Кайда очрашырбыз?

— Капка төбегезгә чыгып торыгыз, шуннан алып китәрмен, тик зинһар озак юанмагыз! — дидем сүзне бетереп... Гөмбә турында хәзергә әйтеп тормадым. Йә тагын киреләнә башлар — Фатихныкын белмәссең... Ә машина турында әйтүем дөрес. Кодаларның «москвичы» бар, безнең ишек алдында ук тора... Фатихка чылтыратканчы ук мин инде кияү белән сөйләшеп куйган идем.

Тиз генә әзерләнә башладым. Урманга бару — нәшриятка бару түгел. Шуңа күрә искерәк чалбар белән кирза итегемне, өстемә кыска курткамны кидем. Карчык әзерләгән ризыкны, термос белән чәйне җыйнак кына түгәрәк кәрзингә салып, пәке белән таягымны да онытмыйча, чыгып утырдым. Кияү инде капканы ачып, машинасында көтеп утыра иде... Кузгалдык — киттек. Сәгатемә карадым — бер тулып килә икән шул... Зарар юк, икегә барып җитсәк, караңгы төшкәнче йөрергә 4—5 сәгать вакытыбыз бар әле.

...Маяковский урамына барып та җиттек. Тегеләр капка төбендә күренмиләр бит әле... Хәер, озак көттермәделәр — әнә ике шәһрәт иясе кулларын кесәләренә тыгып, ашыкмыйча гына чыгып та киләләр... Гулятькә чыккандай икесе дә костюм өстеннән плащ кигәннәр, галстукларын да такканнар, башларында — берсендә кепка, икенчесендә эшләпә... (Хәсән абзый бер вакытта да эшләпә, Фатих исә кепка кимәде.)

Болар машинага кереп утыргач кына, мин борылып үзләренә әйттем:
— Гөмбәгә шулай киенеп баралармыни?..
— Тукта, тукта,— диде Фатих шунда ук кабаланып — нинди гөмбә ул тагын?..
— Соң, бу вакытта ерак урманга ни өчен баралар... Нәкъ сезоны бит...
— Юк инде, бигайбә!.. Гөмбәне син үзең җыярсың, ә без көзге урманда бер хозурланып йөрер өчен барабыз...
Ләкин Хәсән абзыйны гөмбә куркытмады. Киресенчә:
— Җыябыз — ник җыймаска! — диде ул җанланып.— Әмирханнын кәрзинкәсен тотырырга кирәк ләсә!
— Сабый! — дип куйды Фатих.— Син, Хәсән абзый, Әмирханнан элек үзеңне кайгырт... Урманда бит кырын ятып, бераз капкалап та алырга кирәк булыр... Ә как же!
— Минем термос белән чәем бар.
— Чәй белән кытай, беләсеңме, кулын гына юа... Ә безгә әйбәтләп тамакны юарга кирәк... Давай, берер кибет алдында туктыйк әле.
— Мәйле!
Дербышки аша узганда, чаттагы гастрономга туктадык. Өчебез дә кердек... Нәрсә алырга?.. Сайлар нәрсә күп түгел. Шүрлектә тезелеп торган шешәләр арасында коньяк та бар икән — Фатихның күзе ин элек шуңа төште.
— Әнә шул биш йолдызлыны алыйм әле мин, каян килеп, кая китмәгән безнеке,— диде ул, үз алдына гына сөйләнгән булып.— Калганын үзегез карарсыз.
Калганын миңа карарга туры килде. Бер генә төрле колбаса ята, төргән сыр, янә балык консервалары бар... Шуларның һәркайсын кирәк кадәр алырга булдык, ә икмәк миндә житәрлек иде.
— Консерва нигә, ничек ачабыз аны? — диде Фатих.
— Пәкенең үткере бар миндә,— диде Хәсән абзый.
Фатих кинәт кеткелдәп көләргә тотынды:
— Мөселман пәкесеме?
Мин дә көлдем, Хәсән абзый үзе дә кызара төшеп көлгән булды. Аның пәке турында сөйли торган бер анекдоты бар иде, шуны искә төшердек.



*Фатих Хөсни белән Хәсән Туфан. Житмешенче еллар.*

...Инде бүтән бер жирдә дә тукталмыйча туп-туры гына Биектауга элдерттек. Кызу гына бара торгач, тиздән аны да узып киттек. Тагын күпмедер барып, Рөстәм кияү безне Казанка буендагы урман кырыена илтеп төшерде... Машинадан чыккач бер сәгатькә, бер кояшка карадык. Өч тулып килә икән шул инде...

Кияүне кайтарып җибәрдек — ул бүтән килмәячәк. Мин юлдашларыма «маршрутны» аңлаттым: урман эченнән без әкренләп кенә килгән якка таба барабыз, Биектау турысына җиткәч, станциягә чыгабыз... Вакыт әле җитәрлек, капкалап алырга да өлгерербез... «Ярый, синенчә булсын» диделәр юлдашлар. ...Урман эченә тирәнрәк кереп кайтыр якка таба атладык. Артымнан сабыр гына иярүчеләргә мин кулыгызга таяк алыгыз, куак асларын караштырып барыгыз, гөмбәнең шәбе шунда посып ята дидем. Тыңладылар әйткәнне тагын. Хәер, беләм гөмбәчеләр бу урманны аркылысына-буена сөреп чыкканнар инде — юк монда гөмбә! Бөтен Казан гөмбәгә ташланды — чәчеп үстергәне дә җитмәячәк. Ләкин барыбер эзлисең, ялгыш кына яшеренеп калганы табылмасмы дип эзлисең! Гөмбә эзләү кешене беткәнче йота торган бер чир ул — хәтта әнә Фатих та таяк тоткан, эзләнеп бара...

Ә урман тын, буш, әкрен генә яфракларын коя... Нигәдер монсу — боек ул — арган, өшәнгән җан иясен хәтерләтә... Бик тапталган, бик чүпләнгән —ниләр генә аунап ятмый монда!.. Кадере юк бездә урманның...

...Шулай да каранып йөри торгач, мин каен төбеннән берничә гөмбә табып алдым (подберезник дип атала ул). Хәсән абзый да ашарга ярарлык өч-дүрт гөмбә табып китерде. Ә Фатих дус гөмбәне бөтенләй танымый икән... Җыеп китергән гөмбәләре барысы да поганка иде.

— Син, иптәш, боларны кулың белән өзеп йөрмә! — дидем мин аңа.

— Аяк белән генә тибеп өзәм мин аларны! — диде ул, эре генә.

Гөмбә эзләгәндә вакытның үтүе сизелми дә кала... Күтәрелеп карасак, кояш агач башларына кунган икән инде... Бу аның соңгы юмарт яктыртуы... Тагын әзрәк баргач, без иркен генә түгәрәк бер аланлыкка килеп чыктык...

— Туктыйк шушында,— диде Фатих.— Җитеп торыр морза артыннан ияреп йөрү... аякларга да ял кирәк.

Килештек. Аланлыкның тапталмаган чиста уртасында тукталдык... Хәсән абзый көтелмәгәндә бездән сорады:

— Егетләр, мин сезгә учак ягып күрсәтимме?

Фатих шунда ук аның сүзен күтәреп алды.

— Давай, Хәсән абый, давай, күрсәт осталыгыңны!

— Алайса, коры-сары җыеп китерегез... Берәр юанрак ботак та...

...Без коры-сарыны тиз генә җыеп, бер юан ботакны да сөйрәп китердек. Хәсән абзый тезләнеп эшкә дә керешге... Җыйнак кына итеп коры-сарыны аркылы-торкылы салды, озын ботакның юан башы белән бастырып та куйды... Бисмилласын әйтеп, кабызып җибәрүенә учак дәртле генә янып та китте. Безнең дә кәефләр күтәрелеп китте... Тик Хәсән абзый гына учагына карап, уйланып калган иде. Ихтимал, ул Себердә көтү көткәндә кабызган учакларын исенә төшергәндер... Әйтергә кирәк, төрмәдә һәм сөргендә күргәннәрен ул сөйләргә яратмый иде. Минем үземә аңардан ишетергә туры килмәде.

Ярый, учак күңелле генә яна торсын, ә без аның тирәсенә кырын ятып, үз эшебезгә керешик әле булмаса... Кәрзиннән азык-төлекне чыгарып, җәйгән гәзиткә тездек. Әйбәт кенә табын булды... Шешәне дә ачтык... Фатих белән минем «салуның» түмен яхшы белгән чагыбыз, ә Хәсән абзый, билгеле, сакланып кына эчә, ләкин үзе әйтмешли «арыслан тотарлык» кына төшерергә ярата... Үзем китергән сырлы стаканга яртылаш кына салып, мин иң элек аңа суздым.

— Тот әле, Хәсән абзый!

Ул бераз уңайсызланыбрак калды.

— Нигә миннән?..

— Яшькә карап, иң элек сезгә, аннары Фатихка...

— Йә, йә, Хәсән абый, көттермә, безгә үрнәк күрсәт! — диде Фатих та.

— Кем хөрмәтенә соң? — диде Хәсән абзый, стаканны кулына алып.

— Бөек партиябез хөрмәтенә! — диде Фатих, бик җитди итеп, үзе шунда ук кеткелди дә башлады.

Аңа ияреп без дә ирексездән көлеп җибәрдек. Күреп торам, Хәсән абзыйның җитди буласы килә, ләкин көлүеннән тыела алмый гына... «Ну, Фатих теленә шайтан төкергән!» дип тә куйды, аннары тынычлангач:

— Иң әйбәте — исәнлеккә-саулыкка! — диде дә стаканын күтәрде — төбенә төшмичә генә...

Шулай башланып китте безнең бу бик хозур мәҗлесебез. Монда, дөрләп янган учак яктысында, ашау да, эчү дә, рәхәтләнеп көлү дә җан теләп торган зарури гамәл иде. (Саваплы дисәм дә артык булмас)... Без бит бер Алла бәндәләре, бер-беребезне бик күптәннән беләбез, дөньябыз бер, эшебез бер, димәк рухи якынлык та бар — өчебез — өч төрле булсак та... Шуңа күрә дә без

менә хәзер тормыш ваклыкларыннан тәмам азат булып, чын күңел хөрлеге тоеп, телебезгә ни килсә шуны сөйләп, көзге тын урманда кырын ятабыз түгелме соң?!..

...Бер тын әйбәт кенә капкалап алдык. Телләр дә тик тормады... Учагыбызга да коры-сарыны Хәсән абзый һаман өстәп торды... Фатих нәүбәттәгесен әзрәк йоткач, аңардан сорап куйды:

— Хәсән абый, яшермичә генә әйт әле, сине Себер маржалары бик яраткан-нар имеш... Дөресме?

Җавапны Хәсән абзый, әз генә тынып торганнан соң, башкачарак итеп бирде:

— Беләсезме, мәрхәмәтле кешеләрне мин төрмәдә һәм сөргендә күбрәк очраттым.

Ләкин шәрехләп тормады. Хәер болай да бик аңлашыла. Сүз бит үзе кебек төрмәдә утыручы зыялы кешеләр турында бара. Андыйлар арасында бер-берсенең хәлен аңлаучы мәрхәмәтлеләре дә аз булмагандыр... Ә сөргендә авыл сыерларын көткәндә, гади халык аңа һичшиксез җылы карагандыр... Йомшак күңелле маржалар бәлки җәлләп тә... Хәсән абзый бит ул бөтен килеш-килбәте белән бик ягымлы кеше. Әмма аның уе-күңеле бары туган якларына тартылган... «Агыла да болыт агыла» сөргендә язылган шигырь... Һәр сүзендә бәгырьләргә төшәрлек тирән сагыш!.. Әмма иң гаҗәбе — шагыйрьнең ачы, фаҗигале язмышыннан туган шигырьләрен кайберәүләр оялмыйча «төрмә лирикасы» дип атадылар. (Шундый гаепне аңа Союзның идарә утырышында такканнар иде.) Әгәр шагыйрь шул фаҗигале язмышын йөрәк каны белән язмаса, ул Туфан да булмас иде.

Мин аңа сак кына әйттем: — Хәсән абзый, «төрмә лирикасы»ннан берәр шигыреңне укып та күрсәтсәң иде.

Ул чал башын игән килеш, янган утка карап күпмедер тынып торды да, моңарчы мин ишетмәгән шигырен кемнәргәдер мөрәҗәгать иткәндәй әкрен генә укый башлады. Без шылт та итмичә тыңлап тордык.

Азмыни ишләр? Тик алар
Гамьсез дә җансыз.
Көннәрем ил белән дә бит,
Төннәрем ялгыз.

Кайда сез, безне еракта
Таный алганнар,—
Без офыкка күмелгәнче
Озатып калганнар?
Кайда сез?

Адашсам язмышта әгәр
Давыллы төндә,
Кемне соң, кемне дәшим мин?
Эндәшим кемгә?

Урлады юлдашны язмыш,
Талады, каһәр!
Сердәшем — китап та дәфтәр
Таңнарга кадәр...

Тырнагын, тутык тырнагын
Иңемнән алды.
Ярасы ләкин озакка
Үзәктә калды.

Кайда сез
Безне юлларда
Таный белгәннәр?
Яраларны бәйләгәннәр
Сулар биргәннәр
Кайда сез?

Давылга әгәр юлыксам
Болытлы төндә,
Эндәшим фонарь сорап мин
Кемгә соң?
Кемгә?

Бусы инде кайткач язылган шигырь... Без шактый телгә килә алмыйча тордык. Шигырь үзе дә, Хәсән абзыйның укуы да бик тирән үтте безгә... Ахырда Фатих дулкынлануыннан калкына биреп:

— Гамьсез-җансызлар гына түгел, без дә бар бит әле, черт возьми! — диде.— Без башка, Хәсән абый, үзең дә сизә торгансыңдыр... («Абый» килешкәндәй елмаеп кына башын кагып куйды) — Ягез, бер күтәрик әле чын талант, чын шигырь өчен!.. һәм... минем өчен дә! — Әмирхан өчен дә! — дип кыстырды Хәсән абзый...

— Ягез алайса Фатих Әмирхан өчен! — диде Фатих миңа хәйләкәр генә күз кысып.

Ихластан көлештек тә, чиратлашып күтәрдек соңгысын... Бушаган стаканга мин термостан чәй салып, Хәсән абзыйга бирдем — шигырен сөйләгәч тә ул чәй сораган иде.

...Сүз әлбәттә күп булды, кыю фикерләр дә әйтелде, кайбер кадерле кешеләрне дә искә төшердек... Такташ турында сүз чыккач, Хәсән абзый аның нинди чирдән үлүен сөйләде. Без моңарчы тифтән дип йөри идек — шулай хәтердә калган. Юк, тифтән түгел, менингиттән икән... Алар, ике дус шагыйрь, ноябрьнең каты суык бер көнендә Болак буендагы мунчага барганнар. Такташ гадәтенчә яланбаш... Мунчадан чыккач әле алар бер киоск алдына туктап сыра да эчкәннәр... Күрәсең, шул көнне Такташның кибеп житмәгән юеш башына салкын тигән булган. Икенче көнне үк инде аның хәле бик авырая. Зур докторларны чакыралар. Башта алар тиф дип уйлыйлар. Ә Һади ут эчендә ята, башын кая куярга белми. Салкын тиюдән менингит башлана, һәм шул яман чир аны алып та китә.

Сүзнең ахырында Хәсән абзый Такташка багышланган шигыреннән бер өзеген исенә төшерде:

Нидер яна аның йөрәгендә,
Нидер кайный аның җанында!
Ничек аны
Ялгыз калдырыйм да
Ташлап китим шундый чагында?!

Әйе, фаҗигалы язмышлар күп безнең тарихыбызда... Мәгәр бик иркен сөйләшү белән мавыгып без вакыт чамасын бөтенләй онытып җибәргәнбез. Кайчан кояш баеп, кай арада төн булганын да сизмәгәнбез. Учагыбыз янып беткәч, дөм караңгылык эчендә калдык... Һичнәрсәне күреп тә, шәйләп тә булырлык түгел. Кайсы якка китәргә белмичә аланлык уртасында басып торабыз. Безгә бит Биектауга чыгарга кирәк, шуның станциясенә... Кайда ул Биектау — дөм караңгыда түгел, көпә-көндез дә урманнан туры гына чыгуы читен... Бердәнбер чара — поезд тавышын ишетү... Шул тавышка карап кына кузгалырга мөмкин. Менә берәр поездның Биектауга шаулап килгәнен яки кычкыртканын көтеп торабыз да торабыз... Эшләр шәптән түгел — кайчан кычкырта ул, җен орган поезд?!..

— Болай булмый бит, егетләр! — диде Фатих, түземсезләнеп.— Беренче әтәчләр кычкырганын көтергәме әллә... Кайсы якта синең ул Биектауың?..

— Сул тарафта булырга тиеш...

— Киттек сул тарафка... Кая да булса барып чыгарбыз.

— Берәр юлны, сукмакны табасы иде,— ди Хәсән абзый — юл алып чыга кирәк җиргә.

...Без кузгалгач кына шаулап килгән поезд тавышы да ишетелде. Ерак та түгел кебек... Арча ягыннан килә бугай...

— Әнә, ишеттегезме?..

— Ишеттек, ишеттек, давай атлавыңны бел! — ди Фатих, мине ашыктырып.

...Күзләр инде караңгылыкка бераз ияләшкән иде.

Агачларны аерып була... Миңа, ияртеп китерүче буларак, алдан барырга кирәк. Куак-чытырман арасына кермәскә тырышып, сак кына атлыйм. Ә каты юлны, яки сукмакны аяк белән капшап эзләргә туры килә. Тик ничек тә юнәлешне югалтмаска кирәк. Төнге урманда мөмкинме бу?.. Шулай да капшанып атлый торгач, аяклар каты җиргә басты... Юлмы бу?.. Юл икән шул, рәхмәт төшкере!.. Инде киттек сул тарафка кыю гына!.. Ә бер егерме минуттан Биектауның үзенә дә килеп чыктык. Урман аңа терәлеп кенә түгел, эченә үк кереп тора. Билгеле, сүз тимер юл буендагы поселок турында бара... Станциянең кайдарак икәнен якты утларыннан чамалап, туры шунда киттек. Вакыт шактый соң булса кирәк —

ашыгабыз. Бераздан вокзал бинасына барып кердек. Уртача зурлыктагы буш бүлмә — шунын уртасында ике кеше сөйләшеп тора. Поезд мәсьәләсен белергә кирәк. Касса тәрәзәсенә сугылдык — ябык, ике яктагы ике ишеккә тәртелдек — бикле!.. Дежурные кайда утыра соң монын?.. Ләкин Фатих башта теге сөйләшеп торучыларга мөрәҗәгать итте:

— Сез белмисезме, Казанга электричка кайчанрак булыр икән?

Тегеләрнең озын буйлы яшьрәге җавап бирде:

— Казанга бүген поезд юк инде, абый!..

— Нишләп алай, Арчадан килергә тиештер бит әле?

— Китеп беттеләр шул, соңгысын янарак үзем озаттым.

— Вәт сиңа мә!.. Ишеттегезме, әфәнделәр? — диде Фатих, безгә борылып. Без ни әйтергә белмичә, җилкәләрне генә җыердык. Фатих миңа текәлде:

— Син, гөмбәче, расписание белергә тиеш идең бит!

— Сәгатькә карарга онытканбыз! — дип акланган булдым.

Фатих янә озын егеткә дәште:

— Соң, пассажир поездлары... алар да шушы юлдан үтә торгандыр бит?!..

— Үтәләр, ләкин туктамыйлар...

— Берсе дәме?

— Берсе дә!

— Нәләт икән... Ә Арчаныкы кайчан булачак?

— Иртәнге алтыда!

Сәгатьләребезгә карадык — ун тулып киткән...

— Тәмле булсын йокыгыз! — диде Фатих безгә — сигез сәгать шушында аунарга туры киләчәк. Бер скәмия дә юк бит, йә, ни дисез?

Хәсән абзый бер дә исе китмичә:

— Идәне чиста, үзе такта, төн үткәреп була монда — диде.

— Их, Хәсән абый! — диде Фатих, ачынып. — Өйрәнгән инде синең газиз башкайларың түшәк-мендәрсез йокларга... Юк, миннән булмый, миңа Мәрфуганың ястыгы кирәк. (Хәсән абзый башын селкә-селкә көлә генә) Әллә машина юлына чыгып карыйбызмы?.. Кайтмый калсам, Сафура бураннары кубачак бит, беләсезме сез шуны?!

Ә бездән күзен алмыйча карап торган егет ахырда кыюланып сорады:

— Сез кемнәр буласыз соң?!

Фатих аңа сынаулы гына карап алды:

— Чынлап сорыйсынмы, туган?.. Чынлап сорасаң, рәхим итеп таныштырам: менә бу дәү абыең Хәсән Туфан булыр, ишеткәнең бармы?

Егет телсез калгандай авызын гына ачты.

— ...Ә бусы гөмбәче — әдип Әмирхан Еники әфәнде! Ә мин инде шушы ике тилегә ияреп йөрүче... — Фатих Хөсни җәнапләре! — дип өстәдем мин.

Шуннан соң егетебез әллә нишләде. Бер кызарды, бер елмайды, тынычлыгын җуйгандай таптанып та алды... Ахырда катгый рәвештә:

— Алайса, киттек безгә! — диде.

Инде без ни әйтергә белмичә бер-беребезгә караштык. Шик юк, егет чын ихластан чакыра иде. Ләкин без бит аңа җиде ят — ансат кына ияреп китү ярыймы, килешәме соң?!

— Рәхмәт инде, туган! — диде Фатих аңа. — Хатының бардыр ич, төн уртасында өч мужикны ияртеп кайтуыңа ул ни әйтер?

— Бер дә борчылма, Фатих абый! — диде егет ашыгып — хатын да бер сүз дә әйтмәс, мин белеп чакырам, валлаһи менә!

Фатих янә безгә карады:

— Йә, нишлибез, союз әгъзалары?.. Әллә егетнең ихлас чакыруын кабул итәбезме?

Хәсән абзый бер сүз дә әйтмәде. Мин дә икеләнеп калдым: кешегә мәшәкать ясавы уңайсыз, йокысыз төн үткәрүе дә читен булачак — нишләргә?.. Мәсьәләне Фатих үзе хәл итте:

— Ярый, туган, килештек, әмма бер шарт белән: безнең өчен берәүне дә борчымаска — баш куярга урын булса, безгә шул җиткән.

— Урын җитәрлек, яңа гына апаны Казанга озаттым,— диде егет, мәсьәләгә ачыклык кертеп.

Шулай итеп, без аңа ияреп киттек... Поселок йоклый иде инде. Читтәге тып-тын урамга җитеп, бер агач йортның капка төбендә тукталдык. Урамга караган өч тәрәзәсендә дә ут яна иде әле...

Егет капканың кечесен ачып:

— Әйдәгез, әйдә! — диде, нигә тукталдыгыз дигән шикелле...

Кердек, егет ишек алдына караган тәрәзәгә чиртте, әй ишегенә килдек... Аз гына көттереп ишек ачылды. Озын күлмәк кигән, яланбаш яшь хатын куркып киткәндәй артка чигенеп куйды.

— Әстә! — диде әкрен генә.

— Менә кунак урынына кунаклар сиңа! — диде егет шаулап, куанычлы хәбәр җиткергәндәй.

Яшь хатын чигенә-чигенә ачык ишектән кереп китте... Без дә егет артыннан башларны иеп кенә өйгә уздык... Керү белән хуҗабыз безне телсез калган хатынына берәмләп күрсәтә дә башлады:

— Менә бу дәү абый Хәсән Туфан, бусы Фатих абый Хөсни, бусы...— егет әз генә тотлыгып калды. (Миңа чират җитте исә нигәдер гел шулай була.)

— Әмирхан абый!.. («Еники» дигәнен Фатих өстәде.)

— Әйе, әйе, Әмирхан абый Еники,— дип шаулый бирде егет — беләсеңме, кемнәр алар?

— Белмәгән кая инде, белмәгән кая!! — диде яшь хатын, ниһаять, исенә килеп һәм яктыра башлап.

Шулай итеп без, өч шөһрәт иясе, һич көтелмәгәндә, һич белмәгән кешеләрнең төнге мөхтәрәм кунаклары булдык. Исемнәрен дә бераздан гына сорап белдек: егет — Наил, яшь хатын — Зәйтүнә икән... Билгеле, без һәртөрле сыйдан баш тарттык. (Югыйсә, Зәйтүнә тиз генә самоварга да тотынган иде.) Безнең өчен иң кадерле сый — таңга хәтле баш куеп тору, дидек.

— Ник ашыгасыз?— дип сузды яшь ханым,— әйбәтләп йоклагыз... бездә тыныч, бала-чага юк...

— Рәхмәт инде, бик мәшәкатьләдек сезне...

— Берни түгел, берни түгел...

Сизгәнсездер, баштан ук инициатива Фатихка күчте, сөйләшүне дә гел ул алып бара. Мин ничектер югалыбрак калдым. Хәсән абый да сүзсез, тын гына тора — бу тамашаны уйчан гына читтән күзәтә иде.

Хуҗалар безгә «баш куяр» өчен урынны да бик әйбәт әзерләделәр. Хәсән абзыйны түр баштагы сиртмәле йомшак караватка яткыздылар, ә Фатих белән икебезгә кече яктагы киң генә агач караватка урын җәеп бирделәр. Баш астында ике зур мендәр, өстә сырган юрган — рәхәтләнеп йоклыйсы гына!.. Үзләре өй алдындагы чоланга күчтеләр. Татарның борыннан килгән күркәм гадәте инде бу — һәр җире чиста, һәркемгә урын җитәрлек.

Тәмле йокының очкан коштай үтеп киткәнен сизми дә калдык. Хәсән абзый безне төртеп уятты. Фатих сукранып алды:

— Йокы сиңа бер дә кадерле түгелмени?

— Аның кадерен мин белгән кадәр кайсыгыз белә икән,— диде Хәсән абзый.

Урыннарыннан торып яшь хуҗа үзе дә, артыннан хатыны да чыкты... Безнең киенеп беткәнне күреп гаҗәпләнә калдылар: нигә ашыгасыз, чәй эчеп китәрсез, беренче поездга булмаса, икенчесенә өлгерерсез дип кыстый башладылар. Ләкин без җылы урыннары өчен кат-кат рәхмәтебезне әйтеп, чыгып китәргә ашыктык... Беренче Арча поездына да өлгердек...

...Хуш, кемнәр булды соң ул безне төн уртасында ияртеп кайткан яшь егет һәм йомшак урыннар җәеп биргән яшь кенә хатыны?.. Әлбәттә, алар урта татар мәктәбен бетергән, шуңа күрә безне ишетеп тә, күпмедер укып та белгән чын-саф татар яшьләре иде... Һәм аларның үзләре өчен дә тере язучыларны күрү, җитмәсә, өйләрендә кундырып чыгару исләренә төшереп сөйләрлек онытылмас бер вакыйга булгандыр, билгеле... Безнең өчен дә гөмбәгә баруның иң зур куанычы — әнә шундый саф татар җанлы яшьләрне очратуыбыз булды.

* * *

Бу әдәбиләштерелгән истәлек. Ягъни хыялда туган бизәкләр белән баетып, кешеләрне җанлы итәргә тырышып, беркадәр арттырып — күпертеп тә — кыскасы, хикәя язгандай тәфсилләп язу... Истәлекләрне болай язу бик таралган әдәби алым... Бездә дә аның үрнәкләре җитәрлек. Мәсәлән, мәрхүм Мөхәммәт Мәһдиевнең «Ачы тәҗрибә»се чын мәгънәсендә әдәбиләштерелгән истәлекләрдән гыйбарәт. Мин дә менә беренче тәҗрибә рәвешендә шулай язып карадым. Әмма төп вакыйгалар — Биектау урманына бару, гөмбә эзләп йөрү, учак ягып сөйләшеп утыру, поездга соңга калу, ниһаять бер егетнең чакыруы буенча аңарда кунып чыгу — болар барсы да чын, булган вакыйгалар... Калганы — хикәячедән.

* * *

Инде шушы истәлеккә өстәп, бер уңайдан Хәсән абзый Туфан турында әйтәсем килгәнне язып бетерәсем килә. Хикмәт шунда, Туфан ул һәркемне уйландыра торган шәхес. Аңа битараф калу мөмкин түгел — фаҗигале язмышы гүя бездән «Кем соң син?» дип сорый кебек. Шушы сорау аның кешеләргә мөнәсәбәтен билгели дә булса кирәк.

Ни сәбәптер, минем күңелгә кайчагында сәер генә уй килә торган иде: даһи шагыйрьләр каты бәгырьле булалар түгелме икән?!.. Бу шигемне мин бик танылган зур бер шагыйрьгә әйтеп тә карадым. Ул бик тиз килешеп «әйе, бөек шагыйрьләрнең андый яклары бар» диде. Ләкин нидән икәнлеген аңлатып тормады.

Шулай да нидән килә ул — каты бәгырьле булу?.. Артык таләпчән булуданмы?.. Үзләрен һәртөрле түбәнлектән, ваклыктан, бозыклыктан өстен санап, башкалардан да бары шуны таләп итүдәнме? (Ләкин кимчелексез кем генә бар икән бу дөньяда?!)

Хәсән абзыйның да кешеләргә таләбе каты иде. Әхлакъ ягыннан аныңча түбән яки бозык булганны ул күтәрә алмый, нәфрәтләнә, читләшә, андый кешегә рәхимсез дә була ала иде. Аның шундый икәнен без шагыйрь Мәхмүт Хөсәенгә һәм язучы Хәсән Сарьянга карата булган мөнәсәбәтендә күрдек... Өчесе дә мәрхүмнәр, өчесе дә безнең күңелләрдә һәм әдәбиятыбызда лаеклы урыннарын алган шәхесләр — бәлки аларның рухларына кагылмаска да кирәктер... Ләкин күптән мине уйландырган вә борчыган бер мәсьәлә булганга күрә, кагылмыйча да кала алмыйм.

...Ике шагыйрь — Хәсән Туфан һәм Мәхмүт Хөсәен... Кайсы яктан гына килеп карасаң да, алар бер-берсеннән бик ерак, бернинди охшашлык юк, мәгәр икесе дә шигърият дигән мөкатдәс эшкә хезмәт итәләр. Әмма ни өчен соң Хәсән абзый Мәхмүт Хөсәенне кеше итеп тә, шагыйрь итеп тә танырга теләмәде?.. Бу — сер түгел, күпләр моны беләләр иде. Ләкин бит кешене танырга теләмәү, аңардан тәмам бизү өчен бик җитди бер төп сәбәп булырга тиештер, мөгаен... Менә шул төп сәбәп миңа ачылмаган бер табышмак булып калды да хәзергә кадәр...

...Хәсән Сарьянга карата Хәсән абзыйның тискәре карашы нәрсәдән икәнлеген күпләр беләләр. Моңа Сарьянның татар теле турында язган сатирик әсәре сәбәп булды. Ни өчендер Хәсән абзый шул әсәрне телебезне бетерергә юнәлдерелгән бер пасквиль дип кабул итте. Шуңа күрә ул Сарьян турында бик начар фикергә килеп, аңардан йөз чөерде... Әмма кем генә белми Сарьянның туган телебез өчен Туфан шикелле үк җан атып торганын, телебезне бик тирәнтен белгәнен һәм аның сафлыгы өчен соңгы сулышына кадәр көрәшкәнен... Сатирик әсәре дә телебезне бозучыларга (опошлять итүчеләргә) каршы язылган... Хәсән абзый шуны ничектер ялгыш аңлап, авторына карата тискәре хөкемен чыгара да. Сарьян мәрхүм олы шагыйрьнең нахак хөкемен һәм үзенә булган начар карашын бик авыр кичерде, чынлап рәнҗегән чаклары да булды. Мин моны күреп һәм белеп әйтәм.

Әйе, даһиларның караш-мөнәсәбәте белән бик нык хисаплашырга туры килә. Яхшы карашлары сөендерә, начары — көендерә. Менә мин дә шул турыда уйланырга мәҗбүр идем.

Шагыйрь Хәсән Туфанны мин бик күптән — 26—27 еллардан ук беләм. Җыелышларда очрашып таныштык, сүз алышкан чакларыбыз да булды, ләкин якынлашу булмады. Яшь аермасы да шактый, дәрәҗәләр дә бер түгел. Ул инде татар әдәбияты күгендәге биш йолдызның берсе иде... Ә утызынчы елларның башыннан алып миңа инде аның белән очрашырга да, аралашырга да туры килмәде. Шуңа күрә сүз дә Туфанның сөргеннән кайткач башланган еллары турында гына барырга мөмкин.

Ул үзенең 16 ел бушап торган урынына кайтты. Әдәбият дөньясы аны бик куанып каршы алды. Бик тиз ул язучылар арасына керде, элекке замандашларын очрату белән бергә, яңа дуслар да бик тиз табылды. Хәсән абзыйда кешене үзенә тарту куәсе бик көчле иде... Аның тирәсендә инде җыен тәүфикълы кешеләрдән гыйбарәт аерым бер даирә дә хасил булды. Шул даирә аны үзенең канаты астына да алды. Моңа ихтимал аларның бер тирәдәрәк яшәүләре, җәйләрен «Аккош күле»ндә гел бергә булулары да ярдәм иткәндер... Мин үзем ул даирәгә керә алмадым, чөнки өем дә читтә, бакчам да читтә, үзем дә бер читтәрәк... Дөрес, Хәсән абзый белән очрашулар, сөйләшүләр, утырдаш булулар әледән-әле булгалап

торды... Мөнәсәбәтебез дә дусларча гына кебек иде... Ләкин шулай да мин үземне Хәсән абзыйга якын кешеләрнең берсе идем дип әйтә алмыйм.

...Миңа калса, дусларча нормаль мөнәсәбәт нигезендә кешегә карата ныклы бер фикер-караш та ятарга тиеш... Үземнекен әйтеп тә тормыйм — бөек шагыйрьгә тирән хөрмәттән гыйбарәт ул!.. Ә менә Хәсән абзыйда минем турыда нинди фикер, әйбәт кенә мөнәсәбәте артында нәрсә — нинди караш ята?.. Мин моны сизәргә, чамаларга тиеш түгелмени?.. Бер уйлаганда борчылырга сәбәп тә юк кебек... Элек тә, хәзер дә, бер кайчан да минем Хәсән абзыйга бер төрле дә зыяным тимәде. Ул җәһәттән җан тыныч... Ә шулай да борчылам. Сүз бит һәр җәһәттән өстен олы шәхеснең фикер-карашы турында бара... Үзе ул бик таләпчән дә... Борчылуымның төп сәбәбе — гайбәттән курку. Мин яшеренеп яшәүчеләрдән түгел идем. Ә гайбәтне аны гадәттә үз гөнаһларын оста яшерә белүче көнчеләр тарата. Күләгәң шикелле артыңнан ияреп йөри ул гайбәт дигән мәлгунь!..

Әмма ләкин Хәсән абзый колагына минем хакта нинди генә сүз кермәсен, аның миңа карашы асылда начар булмаска тиеш дигән ышану бар иде миндә. Шуның кайбер дәлилләрен искә төшермәкче булам.

Алтмышынчы елның урталарында булса кирәк, Ташкенттан кайткан Шакир Мөхәммәдьяров белән сөйләшеп утырыр өчен Хәсән абзый мине дә үзенә чакырды. Бүтән бер кешене дә... Хикмәт шунда, Шакир Мөхәммәдьяров ул Гаяз Исхакый замандашы, фикердәше, аңа бик якын торган, бергә эшләгән, Гаязның «Ил» гәзитәсендә язышкан кеше... Бөтен кич буена мөхтәрәм карт исемен телгә алырга да куркыныч Исхакый турында безгә сөйләп утырды... Тукайның «Мөхәррирго» дигән шигыре нәкъ менә Гаязга багышланган булуын да исбатлап аңлатты... Югыйсә ул шигырьнең кем турында икәнлеге Тукай томнарының берсендә дә моңарчы әйтелмичә килде.

Кыскасы, Гаязлар заманыннан калып, читтә кагылып-сугылып яшәргә мәҗбүр булган карт бер зыялы янына Хәсән абзыйның бары мине генә чакыруы — бу, әлбәттә, аның миңа ышану билгесе иде... Мин аны шулай кабул да иттем... («Мирас» журналында бу хакта язганым басылып та чыкты.)

Икенче дәлил. Хәсән абзыйга минем «Туган туфрак» һәм «Әйтелмәгән васыять» дигән хикәяләрем бик ошаган икән... Шулар һәм башка әсәрләрем беренче мәртәбә Тукай бүләгенә тәкъдим ителгәч, Хәсән абзый обком секретаре Табеев янына кереп минем бүләккә лаек язучы булуым турында сөйләшергә дә уйлап караган... Мәгәр ни сәбәптер керә алмаган. Моны миңа белгән кешеләр әйттеләр... Шулай да аның Тукай комитеты утырышында минем әсәрләрне яклап сөйләве мәгълүм.

...Өченчесе. Җәйге озын көннәрнең бик җылы бер кичендә без өчәү — Хәсән абзый, Гомәр абзый вә мин нинди дер бер мәҗлестән чыгып, әкрен генә өйләребезгә кайтып барабыз. Маяковский чатына житкәч туктадык. Белмим, әллә кызыклы сүзебез бетмәгән идеме, әллә җәйге төн бик хозур булганга күрәме, нидер житмәгәндәй урам чатында таралып китә алмыйча торабыз... Шул чакта мин бу ике абзыйга әйттем: әйдәгез миңа киттек, аулакта сөйләшеп утырырбыз, дидем... Һәм ни гаҗәп, абзыйлар жиңел генә риза да булдылар. Җәяүләп кенә минем шәһәр читендәге бакчалы өемә киттек. Төнлә дус-ишне ияртеп кайту гадәтемне өйдәгеләр беләләр иде инде. Беренче тапкыр гына түгел... Кайтып житүгә абзыйлар беркемне дә борчымаска куштылар... Җәмәгатем Гөлсем минем ияртеп кайткан кунакларымны бик яхшы белә иде — шунда ук безгә чәй әзерләмәкче булды, ләкин абзыйларым: «Зинһар, мәшәкатьләнә күрмәгез, тиздән без китәбез», — диделәр.

...Мин аларны үземнең эшләп утыра торган бүлмәмә алып кердем. Бакчага караган тәрәзәне дә ачып жибәрдем... Язу өстәле тирәсенә утырышып, әкрен генә сөйләшүне дәвам иттек... Нәрсә турында, нинди мәсьәләләр тирәсендә, кем нәрсә диде, ни сөйләде — хәзер инде бугазымнан алсагыз да, һич берсен хәтерли алмыйм. Билгеле инде, кирәкмәс сөйләшү булмагандыр, кешеләре бит юкны бушка аударып утыручылардан түгел. Сүзнең төрлесе — әһәмиятлесе дә, кызыклысы да булгандыр — мавыгып китеп, күпме вакыт узганын да сизмәдек... Кыска төн үтеп тә бара икән... Агарып кына таң да ата башлады. Шул чакта гына без өзелмәс-бетмәс сүздән туктадык. Әңгәмәдәшләрем китәргә ашыктылар. Мин аларны озата чыгып артларыннан карап калдым. Мөхтәрәм абзыйлар әле беркем дә күренмәгән буш урам буйлап, икәү генә үзләренә таба атладылар...

...Менә шундый сәер генә бер мажара!.. Ничек моны аңларга?.. Ул абзыйлар төн уртасында теләсә кемгә барып утыра торган кешеләр түгел бит инде... Әле быел гына Гомәр абзый белән очрашкач, шул вакыйганы искә төшердек.

Онытмаган икән туксан биш яшьлек картым: әз генә елмая биреп «ийе, бар иде шул безнең дә дуамал егет чаклар», дип куйды...

Соңгысы... Минем дә «түгәрәк даталарым» булып узды — шау-шусыз гына... Җитмеш тугызынчы елның мартында Актерлар йортында миңа 70 яшь тулу көнен бәйрәм иттек. Бәйрәм кичәсенә Хәсән абзый үзе килә алмады — күрәсең, авырып торган чагы булгандыр. Ләкин шигъри котлавын Нәҗибә ханым аша җибәргән иде... Кичәне алып баручы Гөлсем ханым Исәнгулова аны залда утыручыларга укып та күрсәтте. Соңыннан минем үземә бирде. Машинкада басылган, яшел кара белән шагыйрьнең кулы куелган ике строфалы гына шигырь ул... Матбугатта чыкканы юк — үземдә саклана. Беренче тапкыр шуны бирредә күчереп язарга җөрьәт итәм.

Башына: Кадерлебез Әмирхан! дип куелган.

Тик без генә түгел, энем,
Безнең белән бергә бүген
Котлый сине, Әмирхан:
— Ялалардан коткарылган
һәм халыкка кайтарылган
Ибраһимов Галимҗан
Котлый сине, Әмирхан!
— Хәлләр ничек, Хәсән абый?
Сездә ниләр бар? — дисең
— Төннәр буе йокы бирми,
Тынгы бирми һич тә миңа
Синең «Туган туфрагың» да
Сурәтләнгән Саниян!

Сәлам белән Х. Туфан. *16.03.79*

Бу котлау мине борчыган мәсьәләгә ачыклык кертә бугай. Башта бит мин Хәсән абзыйның кайберәүләргә карата каты бәгырьле булуын да әйткән идем. Менә шуның сәбәбен беләсем килә иде: нидән икән бу?.. Кайдан килгән аңа бу бөтен иҗатына һәм табигатенә ят сыйфат?.. Ә сәбәбен шагыйрь үзе үк әйтеп бирә түгелме соң?!.

Бирде дөнья кирәкне,
Еламаска өйрәтте
Кайсыгызның кулы җылы? —
Бәйлисе бар йөрәкне...

Ә йөрәктә тирән яра... Ялгыш кына кагылуны да күтәрә алмый ул. Җылы кулга бик мохтаҗ булып кайткан шагыйрь... Мәгәр моны киң мәгънәдә аңларга кирәктер, минемчә. Сүз ялалы йөрәкне бәйләү турында гына түгел, тапталган иманны тергезү турында да барырга мөмкин бит... Шушы күзлектән караганда, ихтимал минем кайбер хикәяләремнән дә тапкандыр Хәсән абзый үзенә кирәкле җылыны... Һәрхәлдә аның туган көнемә онытмыйча шигъри котлау җибәрүе миңа зур сөенеч һәм тынычлану китерде... Гүя без сөйләшмичә генә аңлаштык. Болай аңлашуны — хисләр очрашуы дип атаган иде мәрхүм Сибгат Хәким.

*Май, 1997*

# МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВКӘ ХАТЛАР

*Хатларны байтак яздым мин үз гомеремдә... Арада үзем өчен үк бик кадерле булганнары бар. Шулардан бүген Мөхәммәт Мәһдиевкә язылганнарыннан дүртесен аерып алып, укучыларга тәкъдим итәргә уйладым.*

**Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ**

*26 октябрь 1986 ел, Пицунда.*

*«Ирләр азына, егетләр котырына, малайлар күлмәкләренә сыймыйлар — илдә озак вакыттан бирле сугыш булмаганга ул. Тыныч заман озакка сузылса, ирләр тимер кимерә башлый».*

(Ишетелгәннәрдән. «Куен дәфтәре»).

Мөхәммәт!

Мин монда әле, Кара диңгез ярында. Һәммәсе искечә: диңгез дә, дулкыннар да, кызарып кояш чыккач, юаш кына бөкрәеп күктә калган бичара ай да, Рица юлындагы тирән таш ялгаш-упкыннар да үзгәрмәгән. Люкс балконыннан миңа «Классик!» дип көлемсерәп кычкыручы син юк та, бүлмәм икенче катта, нәкъ ишек өстендә. Кичләрен, берара һава тынгач, шап та шоп колак төбен төяләр... Сине сагынам! Былтыр, ачу китергән чак булгандырмы, уртак бер дуска сине «пешекләбрәк» хат юллаган идем, сиңа җиткергәндерме, юктырмы, белмим. Әмма быел язын, Тукай бүләкләрен Гариф Ахунов өләшеп бетергәч, идарәдәге күңелсезлекләрдән соң, уртак бер танышыбыз: «Ничек?! Эләкмәдеме Мәһдиегезгә премия!» дип мыскыллагач ук сиңа бик якын итеп, яратып, дусларча хат язармын дип ниятләп куйган идем... Тукай көннәрендә синең язмаларны укып куандым, чын рухи ләззәт алдым, сизәм — яратып язасың, чын күңелдән, моңарчы, сиңа кадәр мин Тукайның әнкәсе хакында уйланмый идем, язмаларыңнан соң, «бу дөньяга кемне китергәнен дә белмичә үлеп киткән бөек ана» турында мин еш, бик еш, дулкынланып, әсәренеп, сокланып уйлыйм. Гомумән, соңгы елларда Тукайга мөнәсәбәтем тагын да ачыклана, хөрмәтем тагын да арта, апасына бүләк иткән рәсеменең артына язылган истәлек язуын укыгач, ирексездән күз яшем тама башлый, Тукайның «Мөшфика апам!» дигән сүзләренең моңын, музыкасын, эчке бер калтыравын тулаем ишетәм... Гаҗәп кешеләр булган, гаҗәеп мөнәсәбәтләр яшәгән... Син шуларны аңлап эш итәсең, яратып, белеп. Димәк, бу фактлар сине дә дулкынландыра, яхшырта, вак-төякләрдән өстен итә. Тукайны аңлавым белән мин бары тик бер кешегә — Якуб Агишевка бурычлымын. Була бит, һәр укытучының яраткан бер «аты» була. Ул шуңа атланып кына чабышка чыга ала. Югары курсларда чит ил әдәбияты укыткан А. А. Исбахның чабыш аты А. Экзюпери иде. Мин бу ике кешегә — укытучыларыма гомерем буе рәхмәтле. Тукайны, әлбәттә, а ч а р г а кирәк, аның бар тирәнлеген ярдәмчесез ачып булмый әле, аның катламнарына төшеп җитәр өчен юл күрсәткеч кирәк. Мин яздан бирле уйлыйм: нигә син Тукай турында роман язмыйсың? Беләм, Ә. Фәйзи язып караган, хәзер дә Тукай турында күп язалар, мәгәр аларның берсендә дә әле мәгърур, олы Тукай юк. Рәссамнәр бу җәһәттән безне уздырды, Хаҗи-Морат Казаковның нәни Тукаен карап, сокланып туеп булмый. Туфанның Тукай турындагы пьесасы сабыйларча фикер йөртү. Акчуриннарны Мостафа Кемель Ататөрек хөкүмәтендә вәзир булуга ирешкән, Сорбонна университетын тәмамлаган Йосыф Акчурадан башка язу гөнаһ. Аннары, Акчуриннар җүләр, ә алар заводында эшләүче һәр кеше алардан акыллы, хәтта асрау кыз да Акчуриннарның сеңелләренә караганда зирәк акылга ия итеп бирелү — бу социаль схема, җүләр схема. Бары тик капиталисты булган милләт кенә өлгергән, җитлеккән, игътибарга лаеклы милләт булып санала алганда, Акчуриннарны болай хакарә итү — җиңеләйтеп әйткәндә — ахмаклык. Дөрес,

мин бу турыда Туфанга да, Марсельгә дә әйтмәдем, алар яратмаслар иде, аңламаслар дип тә куркам. Сина язам. Тукайны белгән кеше санап язам. Тукайны сөйгән әдип, галим булганга язам. Әгәр без Тукай турында чын роман биреп калдырмасак — безнең буын үз миссиясен үтәмәгән булып чыга. Мин шулай уйлыйм...

Көннәр үтте, уникенче июньдә мин төпчек улым Рәшатны армиягә озаттым. Моңарчы туганнар арасыннан байтак егет армиягә барып кайткан иде. Дөрес, алар арасында күпчелеге авырлыкка күнеккән авыл егетләре иде, әмма мин бер чакта да армиягә улы киткән әти кеше булмаганмын икән әле моңарчы! Ул, моңа кадәр татылмаган бөтенләй әр-яңа халәт икән. Әр-яңа! Мин сиңе, син соңгы очрашуларда өзек-өзек кенә әйтеп узган хәлләрне, бары тик үз улым киткәч кенә йөрәк түренә үткәрә алдым. Воистину «кеше хәлен кеше белми, үз башына төшмичә!» Бигрәк тә соңгы сөйләшү, «төрмә тәртипләренең армиягә керүе» турындагы аңлашулар мине тетрәндерде... Именно, «төрмә тәртипләренең армиягә керүе!» Шуннан бирле мин гел уйлап йөрим. Ни өчен армиядә генә?.. Берәүнең чикләнмәгән властька ия булып, башкаларның һич карышусыз, зарсыз буйсынып, «ләббәйкә» дип басып торуы, бер төркемнең яки бер катламның бөтен җәмгатьчелек эшләп тапканны умырып ашап ятуы, бирсәләр биреп, бирмәсәләр талап алуы, кабахәт катылык, шәфкатьсезлек, тагын бер тапкыр катылык — төрмәнең гомер буе яшәп килгән атрибутлары бер армиядә генә мени?.. Ил буенча шушы шомлы закон яшәмәдеме әллә? Хәзер чагыштырып карыйм да шундый нәтиҗәгә киләм — шул закон яшәгән, төрмә кануннары өстенлек иткән, шулар кеше каныша үтеп кергән... Очраклы кешеләрнең өстенлеген билгеле торган, очраклы кешеләр кулына чиксез-чамасыз власть бирә торган куркыныч заманны кичеп үттек шул...

Мин еш кына Достоевскийның «Записки из Мертвого дома» әсәрен укыйм, үзем булган төрмәләр, лагерьлардагы хәлләр белән чагыштырып укыйм. Достоевскийда — үтерүчеләр, талаучылар, караклар, җинаятьчеләр... Ә без утырган лагерьлар «сәяси» дип аталалар иде. Достоевский персонажларында әле кешелеклелек бар, олыны олы итү бар, үзара хөрмәт булган, үзара аз булса да җылылык сакланган. Без утырган лагерь кешеләре бер-берсенең бугазын чәйнәргә әзер торган җанварлардан гына тора иде диярлек була. Күпчелек шулар! Замана, җәмгыять җимешләре... Рәшат сорагач, без хатларда кәгазь арасына кыстырып, бер сум, өч сумлык кәгазь акчалар җибәргәләдек, барып житмиләр, кемдер хатларны ача да, акчасын алып, ябып җибәрә. Янсә хатны ертып ташлыйлар. Улыбыз хат ала алмый башлады! Һәр җирдә, тормышның һәр баскычында эреме, вакмы талаучылар утыра. Беркемдә беркемгә шәфкать, мәрхәмәт, җылылык юк. Менә нәрсә куркыныч... Хәзер әз-мәз искә төшеп, искә килеп «үзгәрешләр» кертергә тырышып карыйбыз, үзгәрешләрнең тиз булуын да бик телибез. Ай-һай, агач череп беткән икән, аның тамырына су сибүдән ни файда? Агачны аударып яңасын утыртырга, яңасы үскәнне көтәргә кала. Безнең буын бозылып беткән буын, өметне бары тик яшьләргә юнәлтергә кирәк. Ләкин яшьләр күңеленә юл салу әмәлләрен без онытып бетердек, алар алдында ышанычны югалттык. «ЛГ» бу хакта бик әрнеп яза, соңгы номерларга игътибар иткәнсеңдер? Картлыкны алдап булса да, яшьлекне алдап булмый: яшьлекнең күзе үткен, колагы сак...

Көннәр төрлечә. Җылы да булып ала, суыта да, алмаш-тилмәш. Чувашлардан берәү бар, тик үтә дә «сул», куркак кеше, берни турында да сөйләшмибез диярлек. Очрашсак, шара-бара, шырдый-бырдый. Замананың үзгәрәчәген, үзгәртергә кирәклеген, үзгәрергә тиешлеген аңламый әле ул бичара. Күк Чабаксар өстендә дә күкри! Мин әйтеп карыйм, «мендәр белән колакны томаларбыз!» дигән сымаграк көлеп кенә куя...

Үтте гомер, Мөхәммәт дус, үтте! Өндә түгел, төштә генә хәрәкәт итә торган чак житте. Төштә әллә кайларда булам, әллә кайларга барам, очам, сикерәм, җиңәм. Ә өндә... Диабет, күз төпләре сызлый, баш илереп авырта, аяклар күп йөри алмый. Ике-өч тапкыр, эт чаба дип бет чаба, мин дә диңгез суына гәүдәмне аткан идем — суык тиде. Тиз-тиз чыгып ычкындым... Кеше эше белән акча сугып утырам. Инде тәмамлыйм шикелле. Бусы соңгысы, моннан болай кеше эшенә тотынып җанымны акчага сатмыйм... 3 ендә юлга. Поезд белән кайтам. Хәзер хат салырга чыгам да, ишек алды буйлап китәм, колак төбендә люкс балконыннан, байның чарлагыннан «Классик!» дигән ярым шук авазны ишетермен кебек.

Яз әле! Яз әле шәп бер әсәр! Әдәбиятыбыз чүпләнеп, вакланып, букка батып бетте бит! Укучыны югалтабыз, ихлас татарларны югалтабыз, халык үзенә хыянәт иткән әдәбиятны үз итмәячәк, кичермәс ул безне, кичермәс. Кичермәсләр! Шундый җыр бармы? Юкмы? Булмаса, язасы иде шундый бер җыр, ә!..

Хуш булып тор. Яшә! Яшик әле!
Ихлас сагынып **Аяз.**

30 сакавика (белорусча март, матур сүз) 1989 ел, Переделкино

> *«Но горе той нации, у которой литература прерывается вмешательством силы: это не просто нарушение свободы печати, это замкнутие национального сердца, иссечение национальной памяти. Нация не помнит себя, нация лишается духовного единства. Отживают и умирают немые поколения, не рассказавшие ни самим себе, ни потомкам»*
>
> А. И. Солженицын

Мөхәммәт дус!

Сайлаулар кызык үтте! Дөнья, Мәскәү шуның белән яши! Ниһаять, халык ярата, ышана торган лидер барлыкка килде. Ул — Ельцин. Без Минскидан кайтып төшкәч, үз күзләребезгә ышанмадык. Йортлар, капкалар, баганалар халык авазы белән тулган. «Әгәр... теләсәгез, Ельцинга гына тавыш бирегез!» Урам чатларына, почмакларга, мәйданнарга халык җыелган, а в ы з  т у т ы р ы п, курыкмыйча үз фикерләрен яклыйлар. Бик ашыгып кына барган идем Горький урамы тирәсенә, туктап-туктап тыңлап, сокланып карап тордым. Әллә Дарвин хаклы инде: без мәгарә маймыллары да кешегә әйләнергә җыенабызмы?! Ходаем, мин әдәбиятка сталинчыл заманнан килдем, гомерем буе гади кешеләрнең үзләренә җан тавышымны юлладым: «Сез бит кешеләр! Кеше булып яшәгезче!» дип инандым. Бөтен әсәрләремдә шул монсу үтенеч ярылып ятмыймыни?!.. Һәм ниһаять, ниһаять! Моссовет рәисе Сайкинны чукындырып төшерәләр! Күпме обком секретарьлары йомычка урынына оча! ЦК секретарьләре дә тәгәрәп кенә төшә! Һәм, гаҗәп кызык хәлләр бар, әй! Минскида чакта бөтен халык горкомның беренче секретаре Галконы каһәрли иде, әйләндереп кенә салганнар тегене. Аның белән рәттән, бер округта неформаллар кандидаты бар иде, сайланганмы, юкмы — шунысын язмаганнар. Сайлангандыр, үткәндер, югыйсә газетачылар дәшми калмаслар иде. Ә Юрий Бондарев?! Яна Сталинград таләп иткән кара җан! Масоннар, сионистлар дип лаф орыр иде, үзенә сөйкемле Волгоградта сырт сөяген сындырганнар кабахәтнең!.. Менә Олжас Сөләймановның үтә алмавы пошындырды. Димәк, халык бер төрле генә түгел әле, аның ни уйлаганын бер сайлауда гына белеп бетереп булмый икән. Кар өненнән язын уянып чыккан аю нишли? Аны кем белә?! Бөкреев бабай: «Сайлаулар күрсәтер, житәкченең абруе юк икән — отставкага китсен!» дигән иде. Сүзендә торырмы? Иртәгесен, броняланган «Чайка»сына утырып, киерелеп Сайкинның эшкә килүен күз алдына китерәм... Обком-мобком секретаре булып селкенеп йөргән тар маңгайлы, таш йөрәкле агач коммунистларны уемнан үткәрәм... Әле халык бар икән, бар! Әгәр сайлау көне житкәнче үк депутатлык мандатларын эләктереп калмасалар, сөрсегән Зайковлар, Лигачевлар очмас иде дисеңме?.. Тарих аяусыз, мондый формадагы «сайлаулар» фашистик Италиядә Муссолини заманында ук булган икән, диләр. Төрле төркемнәр, үз араларыннан вәкилләрне тыныч кына, майлап кына парламентка кертеп бетергәч, сайлаулар башлана: шатлан, халык!

Минск кайный дип шаккатып кайткан идем: Мәскәү хәлләрен әз-мәз белгәч, телсез калдым. Мәскәү шаша, атыла, бәргәләнә. Дөберди! «Язучылар союзы бу рәвешле Сталин заманында, аның таләпләренә туры китереп төзелгән иде. Ул талантларны изү, намуслы каләм осталарын таптау коралы булып хезмәт итте, без хәзер аннан баш тартабыз һәм хәзерендә язучыларның бәйсез фронтын оештырабыз», дип чыга мәскәүлеләр. «Апрель» дип исемләнгән комитет төзелгән, җирле газеталарда манифесты һәм резолюцияләре игълан ителгән. «Торгынлык елларын, аның закончалыгын әллә кайчаннан тар-мар итеп килгән Ан. Стрелянныйны «Совпис» нәшриятының директоры итеп сайлауга нигә каршы чыгалар?! Александр Исаевич Солженицынның үзен һәм әсәрләрен илгә кире кайтарырга!» һәм башкалар, һәм башкалар...

«Илдә ниләр бар икән, яңгыр микән, кар микән?!» Әллә безнең күкләр һаман аязмы? Күптәннән беркемнән хәбәр алган юк. Син, өлгер һәм житез дус, бәндәгезнең «Яра»сын укымый калмагансыңдыр. Сыңар сүз белән фикереңне язып салсаң да, юк...

Ап-ак яшь кар каплаган кара урманда «Балта кем кулында?» дигән нәмәрсә язып ятам. Шуның белән көн-төн саташып яшим. Рәхәт!

Миргазиян монда, йөрәгенә авыр операция кичергән, юашланган, «язарга көч-дәрт юк әлегә» дип торды. Кыска-кыска гына очрашабыз. Ходай аңа дәрт-дәрман бирсен, кызыклы шәхес, сандыгы буш түгел, әле аның үз сүзен әйтеп тәмамлаганы юк, бүгенге кискен үзгәрешләр аның авызына да яңа сүзләр индерсен! Кулымнан килгән кадәр мин аны дәртләндерергә тырышам. Бүтәннәр белән аралашмый диярлек. «Дом творчества түгел бу, дом старчества» дип көлдерде кемдер. Шулайдыр, хактыр...

Башкортстаннан Рәшит Солтангәрәев монда, «Әдәбиятыбызның киләчәге юк, яшьләр бөтенләй килми, сан өчен һаман карт-корыны тутырабыз», дип зарланды. Кызык әй, соңгы елларда бездә дә ул җәһәттән кешеләр кими диярлек. Татарны башкорт дип ышандыра-ышандыра, без анда үсәсе талантларны да кабак башка әйләндермәдек микән?! Әдәбиятның югарысы бары тик милли нигездә генә үсә шул!

Әмирхан аганың сиксән еллыгы бик шәп үткән икән дип ишетелде. Бирсен ходай! Безнең иң гадел кешеләребезнең берсе, күңелендәге байлыгын тулысынча ачып бетерергә җөрьәт итмәсә дә, бер чакта да ярашмаган җаны әдәбиятта изге сүзләр калдырды. «Матурлык», «Тауларга карап» хикәяләрен генә ал! Аның повестьларында чагылыш тапкан тормыш күренешләренә дә безнең житди караш ташлый алганыбыз моңарчы юк иде. Аңа да без стандарт кайчы тотып якынайдык, үзебез аңлата алмаган мотивларны кыркып-кыркып ташладык, әйтер сүзләрен ярым-йорты гына тыңладык. Еники иҗаты турында әле чын сүз әйтелмәгән. Һәм кем әйтер?..

Сүз башыма Александр Исаевичның, бөек замандашыбызның, сүзләрен китердем. Сискәндерә торган фикерләр! Кайтачак бит, кайтачак. Андр. Сахаров белән Алек. Солженицын — Россиянең без яшәгән чорындагы милли геройлары булып тарихта мәңге калачак... Икърар итик, бездә дә булды куштанлыклар, Брежнев китапларын яклап чыгышлар ясадык, куллар чаптык, аягүрә бастык. Әгәр соңга калмаган булсак, без дә җанны яңартып яшик. Әле бездә намус та, оят та калгандыр бит?! Сау бул. Дусларга сәлам. Сагынып **Аяз.**

*9 ноябрь 1991 ел, Переделкино, таң белән*

Мөхәммәт!

Хәтерлисеңме Кызыл Яр авылын? Кич. Тулган ай. Урамнар буп-буш. Фән Вәлиәхмәтовны уртага алып, авылча тальян гармун сыкратып, урамны иңләп, киң урамга сыймыйча өчәү барабыз. Фән белән син җырлыйсың... Кызыл Яр урамнарында тальян кайчан шулай өздерер икән? Әллә без бу җәһәттән дә соңгыларммы? Моң өрә башлаган этләрне дә туктата, тыя... Һәм без, синең белән урам иңләп тагын йөри алырбызмы? Татар моңын сыйдырыр урамнар җирдә күп калганмы әле?.. Әнә ич, мәйдан уртасына чыгып бастык. Ибраһим ага мәйдан тирәли кулын йөртеп: «Монда фәлән бай йорты иде, тегендә фәлән бай, арырак сәүдәгәр татар, биредәрәк фәлән бай нигезе иде», дип елгыр татарларның исемен тезеп китте. Булганнар, беткәннәр, йорт урыннарында мәйдан ясалган, мәйдан уртасына егерменче гасырның гына түгел, кешелек тарихының иң явыз кешесе Ленинны бастырып куйганнар.

Яңа заманга кереп барабыз, капитализмга. Тормыш үзгәрер, яхшырыр, сәүдәгәрләр кайтыр, эшмәкәрләр, кайтырмы татар? Иманыбыз кайтырмы? Рухи бергәлек, җан уйгынлыгы кайтырмы татарга?..

Кичә тетрәнеп Ельцинның указын тыңлаган идек, иртәнге радио чеченнарның указга баш бирмәүләрен, халык сайлаган президентлары Дудаевның Ельцинга буйсынмавын хәбәр итә. Чеченнарны тыңлыйм, татарларны уйлыйм. Президентны якларга чечен авылларыннан коралды отрядлар Грозныйга таргыла икән. Чечен халкын аңлап та була, алар әлерәк кенә тулаем халык буларак геноцид татыган, бердәм халык. Аларны алай ансат кына бөгә алмаслар. Чечен җире — Карабах та, Сумгаит та, Яңа Узен да түгел. Чечен кешесе ул — бер йомарлам нервалар, ул ныгытып тарттырып куйган пружина, чечен ул — мылтык көпшәсендәге патрон. Кызу халык, горур халык, тәкәббер халык. Лагерьда иң нык кырылган халык чеченнар булды. Хәзер чечен авылларын күз алдыма китерәм... «Кал!» дип сыктамыйча, «бар!» дип дәртләндереп, чечен хатыннары ирләрен, улларын юлга, сугыш юлына әзерлиләр. Үсмерләр, утлы күмердәй күзле терекөмеш малайлар, алар янында булаша. Олысы — олы, кечесе — кече чеченнарның...

Ходам шаһит: чеченнарны төрле рәвешләрдә күз алдына китереп була, чечен характеры әдәбиятта нык яктыртылган, кылган гамәлләреннән чыгып ул халыкның рухын, жанын аңлап була... Үз халкым — татарлар турында уйлыйм да... моңаеп, тыелып, тукталып калам. Уй агышым каядыр килеп бәрелә, күзгә сыман уала. Халык язмышын, яшәү рәвешен тоташ бер, зур язмыш көзгесендә түгел, жиргә чәчелгән вак-вак аерым кисәкләрдә генә күрәм. Кисәкләрнең берсендә — татарның йөзе, икенчесендә — колагы, өченчесендә — күзе ияге һ. б.

Былтыр октябрьдә, Хәтер көнендә Ирек мәйданыннан тыгыз рәтләр булып Кремльгә таба барабыз. Тәкъбир әйтәләр, шигарьләр яңгырый, беренче тапкыр татар колоннасында барам. Мине куып житкән бер төркем яшьрәкләр арасыннан Роберт Миңнуллин аркама сорау белән төртте: «Аяз абый ни уйлап бара икән, шуны беләсе иде!» «Минем ни уйлаганымны белү кыен түгел ...» дип сүз башладым да тыелып калдым... Сүземнең дәвамы «халык ни уйлый икән? Шушы татар сафларында баручы татар ни уйлый икән?!» дигән сүз авызымда йомылып сүнде. Кем ул бүгенге татар? Нинди ул? Татарларны бүген ни берләштерә? Гасыр башы татарларын әле аңлап була. Мәжит Гафури аларны бер төрле күргән. Татарның иң ялкау, иң булдыксыз, иң зәгыйфь катлавыннан өскә күтәрелә алмаган Гафури. Мәдрәсәләрдә ахмак фәннәр генә укытыла. (Хәтерем алдамаса «Тормыш баскычлары» әсәре. Мәнжәныйк дигән коралга таң калып утыручы аңгыра шәкертләр), мыек төртеп чыккан күсәк-күсәк татарлар! «Ярлылар яки өйдәш хатын» һ. б. Фатих Әмирхан яңарып килгән яңа буынны — европалашкан, фәнгә, сәнгатькә, хөрлеккә омтылган буынны күңеленә якын иткән. Гаяз Исхакый исә татарны аякка баскан, уйлы, фикерле, чын кеше, жир баласы итеп күргән, башка милләтләрдә булган барлык сыйфатларны эзләп тапкан. Дәреслекләр төзергә алынган Альберт Яхин бик кызыклы бер фикер әйтте: «Булдыра алган кадәр Исхакый әсәрләре белән таныштым, мәгәр берсен дә мәктәп дәреслекләренә кертә алмадым», диде. Мин Альбертка ышандым һәм чиксез сөендем. Дәреслекләргә кертерлек гадәти әсәрләрне жиңел табарбыз, мәктәп кысаларына сыймый торган хөр әсәрләр табу кыен! Гаяз Исхакый татарның традицион тарлыгыннан югарырак менә алган язучы, ул татарда гомумкешелек сыйфатларын тапкан. Бер генә өлкәгә, четерекле мәхәббәт өлкәсенә генә күз салыйк. Гаяз Исхакыйда кеше инде ирекле, аның таләпләре үскән. Ул маржа белән рәхәтләнеп Финляндиядә хөр кешечә яшәп ята. Яшь мулланың кулы хезмәтче хатынның тәне буйлап иркен сәяхәт итә һәм бу хәрәкәт чиркандырмый...Яшь күрше Миңлесафаның да абыстай ашка киткән мәлләрдә мулла абзый янына йомылып кереп житүе дә сискәндерми. Исхакый татар хатыннарыннан пәрәнжәне, ирләреннән икейөзлелек битлеген салдыра, аның геройлары гадәти жир кешеләре. Алар бердәй гөнаһлы да, бердәй сафлар да. Гомумән, Исхакый татарның милли вәкилләрен бер баскычка өскә күтәрә һәм сәхнәгә менгерә. Мәхмүт Галәү татарлары хакында безнең әле фикер йөртә алганыбыз юк. Үз хәзинәбезне барларга безнең кул житми. Татарның эчен-тышын кыю рәвештә ача алган әдипләрне без яратмыйбыз да бугай... Большевик Галимжан Ибраһимов татарны берчакта да яратмаган. «Кызыл чәчәкләр» романына керешне генә ал! Мисаллар китереп тормыйм, мин Г. Ибраһимовны укып, ул багышлаган елларда чын татарны күрә алганым юк... Аннан китә Ә. Еники, М. Әмир, Ф. Хөсни, И. Гази һ. б. һәм әдәбиятта «Мөхәммәт Мәһдиев чоры татарлары» дигән зур бер чор булып ала. Якты чор, хәтерле чор. Бай күңелле шат татарлар, моңсу татарлар, үзләренең татар булулары турында уйламаулары белән бәхетле, рыясыз татарлар... Мин аларның бик күп исемнәрен бүген тезеп китә алар идем. Мөхәммәт Мәһдиев чоры татарлары — әле милли каршылыклардан читтәрәк торалар, аларга ихласлык, гадилек бәхете хас. Син шул бер чор татарларын татар әдәбиятына беркетеп зур батырлык эшләдең. Үзем турында язып тормыйм, без синең белән тиң кешеләр. Ике арадагы арадашлыкны да, аерманы да син чамалыйсың дип ышанам...

«Матурлык» хикәясендәге татарлар чәчрәп күзгә кереп тора. «Торналар төшкән» Масра кырында, Кесмәс үзәнендә алтмышынчы, сиксәненче ел татарлары сыннарын калкытып, аягүрә каршыңа килеп басалар.

Ш. Камалның «Сәмруг кош», Ф. Әмирханның «Сәмигулла абзый», К. Тинчуринның «Ак чибрик» хикәяләре дә мәгълүм дәрәжәдә татар характерын аңларга ярдәм итәләр...

Ә кем ул бүгенге татар?! Татарның бишеге — авыл. Бишек-силәләрнең бавы өзелгән, татар ул-кызлары елдан-ел кими бара, артым юк дәрәжәсендә. Авыллар нигездә таркалган, сирәк-сорак кына, аерым шәхесләрнең кодрәте белән генә егәрле авыллар сакланып калган. Татарлар — илдә шәһәрдә яшәүче милләт

вәкилләре ягыннан — беренче урында. Яһүдләрне санамыйм. Хәзерге татарларны берләштерүче милли тәсмерләр бармы? Рух ягыннан аларны ни берләштерә? Авыл татары да хәзер сигез-ун класс бетергән, ир-атлар армиядә булган, Әфганда, чит илләрдәге оккупация гаскәрләрендә. Сумгаитта, Ферганәдә... Авыл татарының өч баласы икән, кызларының икесе урыста кияүдә, килен дә мукшы иленнән. Авылларда теләсә кайсы иргә биреп йөргән, табаннарына ут кабынган татар кызыкайлары һәммәсе чит җирләргә китеп, башка милләт вәкилләренә кияүгә чыгып, үз хурлыкларын яшергәннәр. Андыйлар меңәрләгән. Бер безнең авылдан гына ничә кыз шулай китте. Газеталарда ата-бабаларны юбилейлары белән котлаган хатларга кул куйган кияү-киленнәрнең, онык-нәбәрәләрнең исемнәрен күреп икебез дә каушап калганбыз... Димәк, кияү-киленнәр, хәзер җирдә яшәп ятучы татар оныклары-нәбәрәләре булып саналган бөтен бер буын милләттән ераклашкан гына түгел, аерылган. Мәңге кайтмаска аерылган... Динебез берләштерәме? Хәзерендә мәчеткә йөрүче картларны күзәткәндә тагын ун еллык запасыбыз бар. XXI гасыр башында әле диннән әз-мәз авыз итәргә өлгергән картлар отряды фани дөньядан китеп барачак. Хәзерге гопниклардан, авылларда калырга мәҗбүр ителгән, гариб-горәбәләрдән, алкашлардан туган кабакбашлар Корьән хикмәтләренә рухларын куша алыр дип көтәбезме?.. Һич юк. Шәһәр халкының аңын мал-туар, байлык эстәү каплап тора. Менә ни өчен театрлар репертуарларын ачыктан-ачык кәмиткә генә кора башладылар.

Ни ялынып өндәсәк тә газета-журналларның таралу мәйданы тарая бара. Мәшһүр Әмирхан Еникинең «Сайланмалар»ын 15 мең тираж белән чыгардык. Бәндәгезнең «Сайланмалар»ын да шундый кыска язмыш көтә... Әдәбиятка, сәнгатькә, матбугатка мөнәсәбәт — безнең кулыбыздагы бердәнбер социологик таяныч. Татарны татар иткән сыйфатларны җыючы, фәнни анализ ясап чыгармалар ясаучы оешма юк. Без — бүгенге татарлар — татарча ярым-йорты гына белүчеләр, тарихи тәрбия алмаган наданнар, милли горурлык хисеннән тулаем мәхрүм ителгәннәр. ХӘТЕР КӨНЕН билгеләргә нинди уй-теләкләр белән чыктык икән без? Ни йөртә безне бу юлларда? Геннарда буыннан-буынга күчеп килгән кан авазымы? Бармы ул? Әллә татар каны болганчык кара суга әйләнеп беткәнме?.. Ал безнең татар әдипләрен генә. Каюсы татарча белә аларның? Кайсыларыннан җирдә татар кала? Мин гади генә бер сорау бирер идем: әдипләр яшәгән һәр подъездда татар гаиләләре бар. Шулардан бер булса да татар баласы каламы?..

Урысны аңлау кыен түгел. Аларның милли сыйфатлары ярылып ята. Иң актыккы, әмма саллы һәм җитди мисал. Кичә Ельцинның указы игълан ителгәч, Ризван биллиардныйга керә. Тоташ урыслар. Язучылар бар, күпчелек иҗат йорты тирәсендә ялманучы «кунаклар». Авызларда бер генә сүз: «Власть йомшак, чеченнарны танклар белән таптатып кына узарга иде. Нигә алар белән кәнфитләнеп торырга?!» Арадан берәү: «Чеченнәрдә корал күп!» — дип ачыклый. Урыс шагыйре Алексей Марков: «Самолетлар беткәнме? Бомбага тотарга, җир белән тигезләргә... Огнеметлар белән яндырырга кирәк!» — дип акыра. И бичара, рак белән авырый, ай ярым гомере калган, үзе сөйләп торды, утыз биш килога кимегән... Кан сорый — иреккә чыгарга омтылган, 44 тә иленнән-җиреннән мәхрүм ителгән милләтнең хатын-кызларын, бала-чагаларын танклар астында калдырып җир белән тигезләргә ашкына! Сүзенең дәвамын кара әле син: «Большевиклар йомшаклык күрсәтмәсә, Польша белән Финляндияне дә кулдан ычкындырмый идек без!» Йа хода, форсат булса Финляндияне дә бәхетле коммунизм юлыннан алып барачаклар икән! Менә чын империячел урысның тулы характеристикасы. Бөтен урыс та алай уйламый, әлбәттә, шөкер Андрей Сахаровлар бар. Виктор Астафьевлар яши. Урыс — бай милләт, алар арасында әллә кемнәр мәйданга чыгарга әзерләнә торгандыр әле... Хәзер күз уртасында чеченнар. ОМОН, КГБ гаскәрләре аларны изеп керсә, дөнья агышы кай якка үзгәрер? Чеченнәр — Татарстанга кисәтү ул. «Әгәр артыгын кылансагыз, ни-ни, сезгә дә шул булачак». Әгәр чеченнәр үз сүзләрен итә калсалар, бусы да безгә акыл. Ләкин татар язмышын хәл итүне үз җилкәләренә күтәрерлек шәхес бармы бездә? Калганмы? Чеченнәрдәге кебек кискенлек туса, кемнәр күкрәкләрен штыкларга терәп алга узачак? Акыллылармы? Тилеләрме?.. Күз алдына китерү кыен...

Менә, Мөхәммәт, әсәр язасы урынга шушы авыр Гордей төеннәрен чишә алмыйча баш ватам. Беләм, син моряк, егерме ике төен төйни беләм дип горурланганың бар, серле төеннәргә тап булдым исә, сиңа — төеннәр академигына мөрәҗәгать итәм. «Сезгә эндәшми... мин кемгә?..» Авыр туфрагы җиңел булсын, Сибгат ага безгә бер дога калдырды...

Ризван монда. Аралашабыз. Үзем соңгы сүз язган җыентыгын укып чыктым. Ничәнче мәртәбә?! Шөкер, уйлы егетебез барлыгына тагын бер кат инандым. Ялгыз түгел без, Мөхәммәт. Без Шәриф Хөсәенов белән Ризван Хәмид исемнәренә көч бирмичә үз сферабызны тарайтабыз шикелле. Татар милләте, милли театры яшәсә әле Ризван әсәрләренә әйләнеп кайтачаклар. Һичшиксез.

Сабыр тормыш итәбез, мәй капмыйбыз, анда-монда чыгып йөргән юк, юллар начар, көннәр дымлы, күкләр черегән — әле юеш кайгы, әле су тамчыларыннан гыйбарәт хәсрәт ява. Сүзлекләрдән «матурлык», «ямь», «рәхәт», «сафлык» дигән сүзләрне сызып ташларга микән әллә? Боерган булса, мин 27 сендә кайтып төшәм. Сау булып тор.

Ихлас сагынып **Аяз.**

*16 февраль 1992 ел. Казан. Таң белән.*

Мөхәммәт, хәерле иртә!

Мөгаен, мин тар, чикләнгән вә кысан тормыш белән яшимдер... Күр инде: илләр Кара диңгез өчен тарткалаша, Кырымны тагын бер кат чәйнәп ыргытырга әзерләнә — ә миңа хет бы хны! Университет ишеген бүрәнәләр белән бастырып Россия демократларын Казаннан кудылар! Булганы бар идеме мондый «тәкый гаҗәп» хәлнең?.. Ә мин «ошбу тарихи бүрәнәләрне татар элдереп ала алмас, урыс йә яһүд эләктерер!» дип уйлап утырам... Дөньяга бик тә киң таралган, татарлыгыннан мәңге ваз кичмәс татар яшьләренең янә бер корылтае җыела икән, янә президент сайламакчы булалар, дигән хәбәрләр дүрт аяклап Казан — Чиләбе, Уфа — Ырынбур араларында мүкәләп йөри, минем колак артым да кычытмый ичмасам!... Һәммәсенә битарафмын! XX гасыр азагы татарларының «бөек узаманнары» милләтне кайсы упкынга илтеп җиткерерләр икән, дип халаек бәхәсләшә — сыңар чәчем дә селкенми. Язганны күрербез, мин тормышымны шундый «калай әтәчләр»гә караганда, тәңремә теләбрәк бирәм.

Уен — бер, ус...к — ике, дигән татар сүз арасында. Хәзер житди сүзгә күчәм. Инде йөрәгем туң күчәнгә әйләнеп бара икән дип уйлап өлгермәдем, дерт итеп сискәнеп киттем. Син «архивымны мәгълүм бер оешмага ташый башладым» — дидең дә, аяктан ектың, һәм: «Нурихан Фәттах тапшырып бетергән инде», дип өстәдең. Нуриханны алдан күрүчән зирәк җан дип санадыңмы, әллә бу эшне шәхсән үзең кирәк таптыңмы? Минем беләсең, зирәклегем, алдан күрүчәнлегем бөтенләй юк, теләсә кая капка ватып кереп китә торган яман гадәтем бар, шуңамы, әллә сиңа ышанганнан-ышана баруым сәбәпме, һәр гамәлеңнән үзем өчен дә яраклы тирән мәгънә эзлим, бу юлы, әйткәнемчә, аптырап киттем.

Нурихан турында сүз кыска. Эшкә тотынганчы ук максатын, барыр юлын билгеләде, борынгы хикмәт ияләре кебек мәгарәдә яшәде, ашамады-эчмәде, тау-тау китаплар укыды, сүзлек актарды, ял итмәде. Тәүге мәлләрдә без барыбыз да карап соклана идек. «Фест дисбесе» дигән хезмәте аңа дан, бөеклек китерергә һәм алсыз-ялсыз үткән зәхмәтле еллары өчен җан тынычлыгы бүләк итәргә тиеш иде. Иллене узды, алтмышны тутырды — дан, ул өметләнгән шөһрәт килмәде. Киресенчә, ул үзенең балта сабы белән мең яшәр имәнне аударырга маташканын ап-ачык аңлады. Кеше — үз гомеренең бушка үткәнен, кылган хезмәтенең нәтиҗәсез тәмамлануын аңлаган мизгелдә — ерткыч-җанварга, күкъял бүрегә әйләнә. Күзе кемгә төшсә,ул ырлап аңа ябыша, эләктерә алса — бугазын чәйнәкләп ата, явызлана! «Татарстан яшьләре»ндәге мәкаләсе исеңдәдер?

Нуриханның артка адымын аңлап була! Гаҗәбе шул: татар җанын тарихка урап учында йомарлап тотучы баһадир СИН юлдаш-кәгазьләреңне салкын складка, архивка илтеп тапшырырга булгансың? Иртә түгелме? Ашыкмыйсынмы? Архивың — синең тылың, таянычың... Менә мин лагерьга кагылышлы хатларымны барлап утырам. Нинди кыйммәтле документлар бар арада! Лена Иваненконың гаҗәеп акыллы хатларыннан берничәсе саклана. Ул, 13 ел утырып, 1954 елның мартында Актас лагереннан азат ителде һәм сөргенгә китте. Сөргеннән килгән хатлары сакланмаган, ә мин аңа 5 көн эчендә 17 хат язган идем. Мин аның белән 1951 нче елда ук язышa башлаганмын икән... С. С. Козлов-Куманскийның мин котылып чыккач җибәргән хатлары... (Иң якын дусларымның берсе иде!) И. С. Велягурскийның хатлары... «Укы!» дип миңа акча салып тордылар. Козлов-Куманский посылкалар җибәрде... Хатлар аша кемлегемне, тормышымны белешергә була ич!.. Хатлар, кисәк-кисәк, кочак-кочак хатирәләр, моңга манчылып синең вафатыңны, вафатыңнан соң чит кулларның кагылганын, чит

күзләрнең карманганын көтеп суык киштәләрдә үксезлектән борсаланып ятсыннармы?..

Их, Мөхәммәт дустым! Бәлки сиңа, син тудырган җәүһәрләргә мөнәсәбәт бүтән булыр, вафатыңнан соң да аларга озак онытылып ятырга туры килмәс, татар зарыгыр, сине юксыныр, тиз-тиз эзләп табарлар, сиңа сукмак өзелмәс... Ә өзелсә?! Бүген, син һәр тарафта кайнап-гөрләп торганда,сине пәйгамбәр дип игълан иткән гавам бармы? Үзем хакында әйткәнем дә юк. Халкым белән аркадаш була алмадым, мин моны күптәннән беләм, белгән хәлдә җәфаланам. Туры атмадым, тидермәдем, яшьрәк чакта өмет белән алдандым, олыгайгач — җәфаланам.

Синең-минем газапларымны кем белә? Әдәби әсәр — әдипнең җан газапларының җыелмасы түгелмени?! Бу очракта синең янәшәңә — мичәүгә басуыма үпкәләмә — минме татар дип җан атмаган? Минме милли җаныбыз, милли хәтеребез, милли бердәмлек дип сөрән салмаган?! Чордашлар кичерсен, бу җәһәттән мин икебезне рәттән куям, дөресен әйтим. Икебездән башка шул газиз югарылыкта замандашлардан бер Әмирхан Еникине генә күрәм. Син безнең бөегебез! Үземә-үзем шактый затлы тамгалар сугып уйласам да, гомернең йомгагы тәгәри-тәгәри барып, караңгы диварга килеп терәлә дигәндә, Нурихан хәленә калам. Мөхәммәт, Мөхәммәт! Яшәдек, яндык, тырыштык кебек тә иттек — ә нәтиҗә?! Татарларда тормышка мәхәббәт, ватанпәрвәрлек, милли мәхәббәт уяттыммы? Мондый сорау каршында мин җәһәт-җәһәт синең яннан шылам, син — бүтән, син халыкның күңел кырын яулап алган әдип, чәчкәнеңне үзең урдың, син татарның күңел пәрдәсен дүрт ягында да ача алдың, татарны тулаем тоеп, аның агы-карасы белән янәшә бара алдың. Син бер чакта да миндәй Ялгыз булмадың, кая карасаң да синең жете күз карашың җылыткан җирдә татар мәйданы ясалды, халык сиңа килеп сәҗдә кылды. Бәрәкәт иясе кулларыңнан эш төшкәне юк, торгынлыкны, сүзеңнең кадере кимүен синең татыганың юк. Иң кызыгы — мин, гидай, халыкның сиңа булган мәхәббәтенә җылынып яшәп ятам. Татарның сиңа булган эчкерсез мәхәббәте — минем өчен дә куаныч!

Архивыңнан аерылу — нәрсә бу, аңлат! Син үткәннәреңә кайтырга уйламыйсыңмыни? Алар синең таянып ял итә торган талларың түгелмени?!

Мәсьәләнең төбе, үзәге, иң мөһиме... Синең сөекле улың бар. Әсәрләрең, авызыңнан чыккан мең-мең сагыну сүзләре аша улыңны да жаныма якын иттем. Мин аны синең законлы варисың, дәвамчы фикердәшең, көрәштәш-укучың итеп санарга күнеккән. Улың — синең күңел хәзинәңә т ө п х у җ а булып калырдай егет түгелме әллә? Аңа ышанып тапшырып булмыймы хәзинәңне! Уллар атаның хәзинәсе аша үзләре дә үтеп китәргә тиеш түгелләрме?! Беләм, том-том кәгазьләр арасына чумып, кереп утырырга балаларның егәре дә, вакыты да житмәс. Ә шул тау-тау фикерләр арасына кермичә, аңдагы чиксез байлыкны күрмичә алар безнең хезмәтнең газаплы авырлыгын каян чамалый алырлар? Архивның нәкъ у л ы ң өлешенә багышланган кисәге юкмыни?

Улың... Улларым... Чордашлар, замандашлар. Безнең фамилияләрне XXI гасырга күчерүче егетләр. Юк, Мөхәммәт, улың исеменә шик-шөбһә төшерергә җыенмыйм, тәүбә, әстәгъфирулла. Үзалдыма гына уй йөгертәм. Улларым — якты дөньяда мин яшәп киткәнне онытмыйча, чорның мәгълүм бер дәверендә ара-тирә мине искә алырдай җаннар... Бу тарафтан мине чак кына шикләндергеч, чүт кенә икеләндергән бер вакыйга булып алды да: «Дөрес уйлыймы? Ялгышмыймы?» дигән сорау күңелне тырнап сызылып үтте.

Безнең ата-бабадан мал калмаган. Күзгә бүләк итәрлек әйбер-каралар да сакланмаган. Миңа фамилия биргән Гыйләҗетдин карт үткән гасыр азагында гаиләсен, бала-чагаларын төяп Төркиягә күченеп киткән һәм шунда төпләнгән. Баян Гыйззәтне ир иткән, яшьлегендә Сарманда яшәгән, миннән ике яшькә олырак туганым Ләйсән хәтерли: «Төркиядән, Измирдән хатлар сугышка кадәр килгәләп торды», ди. Гыйләҗетдиннең Сәхәбетдин атлы улы, минем бабам, ник күченмәгәндер, кайда калган, ни хәлдә — анысын берәү дә хәтерләми. Сәхәбетдин хәзрәт үзе утызынчы еллар башында Алабуга төрмәсендә юк ителгән. А. Л. Литвин: «Әйдә, эзләтеп карыйк», дигән иде, кулда төгәл бер факт та юк, бабамның фамилиясен дә белмим, каян төрмәгә килеп капканын әйтә алмыйм. Әти — совет режимы укытучысы, мулла баласы, гаять куркак, юаш, сак кеше булган. Әтисенең исемен берчакта да телгә алмады. Бер чакта да! Сәхәбетдин хәзрәтне мин әз-мәз әни сөйләгәннән чыгып кына беләм. Әтине гаепли алмыйм: совет чорында җиде бабаңны исеңдә тотып кара! Унҗиде бабаңны танытып, әлпиеңне укытырлар!

Әни ягыннан әби-бабамны күреп, белеп үстем. О бәхет! Әгәр миндә татарлык, әз-мәз талант, зиһен, зирәклек, житезлек бар икән — мин тулысынча сөекле әбием Зөләйха белән «мимеч» («немец») кушаматлы кадерле бабам Сөләйманга бурычлы. И, жылы җанлы әдәмнәр иде бахырлар! Фән хәзер кон-төн тукый: «Әби-бабасын күрмәгән балалар тормышта кимчелекле, яшәештә сынык рухлы булалар». (Растыр, тоташ бер-ике буынның балалары бабайларын бөтенләй күрмәде, әбиләре ятим-ялпы булып яшәп нәбәрә-оныкларына тиешлесен тапшыра алмадылар!) Пушкинның нәнәсе булган, Лермонтовның әбисе...

Ни аяныч: Сәхәбетдин хәзрәтнең дә, яшьли вафат булган Гыйлембаян әбиемнең дә сурәтләре калмаган, сакланмаган. Дөньяны кичкәннәр, әле нәсел-нәсәпләре гөрләп яшәп ятканда ук тузанга әйләнгәннәр. Сөләйман бабамның да фотосурәте юк, ул ап-ак булып, галим булып, олпат булып минем күңелемдә генә саклана. Былтыр, 91 дә, Зәйгә туганым Тәлгатьләргә кайткач, фото күбәләре арасыннан (татар фоторәсемнәрне күбә-күбә өеп саклый!) күмәк төшкән бер зәгыйфь фотода Зөләйха әбиемне танып алдым... Алып кайттым, зурайтып, чистартып эшләтеп алырга җыенып йөрим...

Моннан җиде-сигез ел элек әти-әниемнең бик матур рәсемнәрен зурайтып, рамлатып куйган идем инде. Урта Баграж авылында, үзебезнең ындыр түрендәге каеннар арасында абыем Азат төшергән фото. Каеннарын әти белән икәү утырткан идек. Әти, әниемнең яшь чакларыннан калган беренче фотоларын да эзләп таптым, ишәйттем, копияләрен алдым һәм улларымның шәхси альбомнарына багышлап куйдым. Әби-бабаларының кадерле сурәтләре! Саклансын!

Әби-бабаларының сурәтләрен үз йортларына кергәч түрләренә куярлар... Бабайлар янәшәсендә Нәкыя белән миңа да урын табылыр дип өметләндем. Безнең янга киленнәр белән улларым тезелеп басарлар да нәсел дәвамы алдагы буыннарның күз алдында ныгып барыр дип өметләндем... Кяшки!

Күчәнделәр, Искәндәр-Мансурлар үз куышларына керделәр, йортны җиһазладылар, тантаналы рәвештә Коръән укыттылар, өйләренә иман иңде, тәгәрәп бәби кызлар үсә... Әби-бабаларының үз кулларым белән тапшырган сурәтләре генә түргә үтә алмыйлар...

Аптырадым-йөдәдем, мичкә күтне терәдем... Совет дөньясы, коммунистик коткы адәм улларының аңын томалап, аңгырайтып кына калмады, ул җимеш биреп торган нәсел агачларын да төбе-тамыры белән аударды, туганлык елгаларын корытты. Нәтиҗәдә, минем гап-гади кешелекле омтылышларым әлегә күмелеп калды. Әле минем улларым шундый! Алар әзерлекле, милли тәрбия алган, телгә, татарга мәхәббәтле балалар. Яннарында авылның рухи хәзинәләрен төяп килгән изге күңелле әби яшәде! Ләкин гомум һәлакәт, тоташтан инкыйраз, милли тотрыксызлык, нигилизм алар канына да азмы-күпме үтеп кергән, ахрысы... Әлегә улларымда үткәннәргә борылыш, хәтирәләргә омтылыш дигән якты кызыксыну сизелми. Бәлки яши-яши каннары уяныр, үзләрен аңларга тырыша башлагач, әби-бабаларга борылып карарлар.

Әлегә фотоларга бармак ашарак караган балалар, кайчан-исә бер әтиләренең язмалары белән дә якыннан кызыксыныр дип мин тагын ялгышаммы? Син моны тагын миннән алдарак аңлап алдыңмы?..

Без — хәтерсез халык. Мин гел кабатлыйм бу ачы хакыйкатьне. «Татар уяна! Татар уянды!» дип язалар Рәчәйнең төрле ягыннан. Кяшки! Шулай булсачы! Телемдә бер сорау, бер булса да берәгәйле: «Татарның кеме уянды? Кайсы буыны?!» Яшеме? Картымы? Безнең күзләргә ал пәрдә бик тиз элenә, җәһәт сукыраябыз. Казанның үзәк мәйданнарына байрак болгап кемнәр чыга? Әлегә, кызганычка каршы, карт буын кузгала, дөнья белән саубуллашырга җыенган буын вәкилләре уяна. Аларның хәлсез күзәнәкләрендә татарлык әз булса да сакланган әле. Яшь буынның, урталарның, совет заманы җимеше әһелләренең үлгән күзәнәкләрен терелтер кодрәт кем кулында? Кайда? Үлгәннәрне терелтә алырлык милли табиблар кайда алар?! Иң бөек кодрәт ияләре С. Сәйдәш, Ә. Еники, И. Шакиров, Р. Яхин, Рим Хәсәнов, М. Мәһдиевләрнең милли зарурлыгын, иманын, яктылыгын кемнәргә нинди көч белән тапшырырбыз?.. Эстафетаны кайсы ышанычлы кулларга күчерербез?.. Бу сорауларга миндә бүген җавап юк. Картлар белән, тереләр белән совет чоры калыплап чыгарган берничә буын арасында әле берәү дә үтеп кереп ача алмаган терроинкогнито — бозлык ята.

Һәм син безне көткән җәһәннәм буыны вәкилләренә ашыгып-ашыгып архивыңны илтеп тапшырасыңмы?.. Синең бу көтелмәгән адымың әҗәлне ашыктыру булып тоелды да... имәнеп киттем. Мин бит яшькә синнән олырак... Җитмәсә, шикәр кимерә мине, астыртын гына чертә, йолыккалый. Кар астына ут кергән

инде, эретә, жеби... Өстән карасаң — кар, ә аста... жимерелеп беткән ямьсез авызлы караңгы баз...

«Уяна!» диләр. Шулай булсачы! Мин заманга битараф яшим, дидем. Битараф жан «күрә карау»га әйләнә. Шулай булсачы!.. Бу хаттагы күп шикләрем ялгышу булсачы, ярабби!

Нәкыя гомере буе урыс мәктәбендә татар теле өчен көрәшеп, татар балалары дип аталган йон төргәкләре белән көн туса күзгә-күз очрашып яшәгән тәжрибәле укытучы. Өч ул үстергән ана. Ул бүгенгә «мәктәп уяна!» дип аяк терәп кычкыра алмый. Бүгенгә әти-әни дәрәҗәсен алган татарларда ул үзгәрешләрне шәйли алмый. Безнең ишегалдында балалар бакчасы. Кичкырын, балалар өйгә тарал-ганда, мин шул тирәдә булам. Көнлек эштән соң күз бәйләнә, зиһен сыеклана. Ял итәм. Колагым — локатор. Шунда мин бала авызыннан татарча сыңар сүз чык-канын көтеп, сагаеп, ишетми калмагаем дип куркып локаторларымны җилгә куеп торам. Юк! Балаларның авызы урыс йозагы белән ачылмаска бикләнгән. Ник бер ана (аталарны әйтмим дә инде!) йомшак кына иркәләп баласына үзебезчә — татарча эндәшсен! Ник бер бала, туган телен зарыгып көне буе интеккән телен язып, татар дөньясын яңгыратып, татар җирен тибрәтеп: «Әни!» дип кычкыр-сын!..

Кайда күрә ул лжеоптимистлар милләтнең уянуын? Мәчетләрдәме? Мәчет-ләрдә бер буынның соңгы кыйпылчыклары... Үзем дә шул суык кыйпылчыкның бер данәсе буларак картларны аңлыйм, аңларга тырышам. Син татар гәҗитләрен күздән кичереп барасың, кемнәр күбрәк мәкалә яза гәҗитләргә? «Шәһри Казан», «Соцтатарстан»нар әллә кайчан мәчет картларының, инвалидларның, зәгыйфь-ләрнең рупорына әйләнеп бетте ләбаса! Шулмы уяну? Нигә без бер-беребезнең колагын балавызлыйбыз? Нигә бер-беребезнең күзенә төтен өрәбез? Саңгырау вә сукыр татар кем өчендер кадерлерәкме?

Һәм менә син шул мәлдә... жылы күңелеңнең кайнар сүзләрен казна йор-тының суык хезмәткәрләренең өшегән кулларына илтеп аударасың... Аңлама-дым!.. Томана зирәк шул мин, Мөхәммәт дус! Поздно созреваю.

Хуш булып тор, замандаш! Дулкынланып яздым, каушап уңга-сулга сөрлек-тем шикелле. Хатымның туры сызыгын үзең табарсың инде...

Тирән ихтирам белән **Аяз.**

# ҖАН АВАЗЫ

МӨНӘҖӘТЛӘРГӘ БЕР КҮЗӘТҮ

Мөнәҗәт — (гарәпчәдән) ялгызлыкта үз-үзең белән сөйләшү, арыну, Аллаһе Тәгаләгә мөрәҗәгать итү, ярлыкауны сорау дигән мәгънәне аңлата; дини-интим эчтәлектәге әсәр.

Мөнәҗәтләр беренче мәртәбә «Татар халык иҗаты» дигән күп томлы җыелмада киң урын алдылар. Эчтәлеге буенча алар берничә төркемгә бүленә: «Туган ил», «Ана белән бала», «Яшәү һәм үлем турында». Әмма ләкин бу томга бик күп санлы дини эчтәлекле мөнәҗәтләр («Бисмиллаһи дип башладым», «Әминә ханым — Мөхәммәт анасы», «Лә илаһе илләллаһны күп әйтегез, мәләкләр», «Исрафил сурын өргән», «Мөхәммәд пәйгамбәргә мәдхия», «И мөселман, кыл гыйбадәт», «Намә», «Вәйсиел-карани» («Вәйс әл-Карани») кертелмәгән. Бу төркемнең репертуары бик киң һәм бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән. Кызганычка каршы, үткән елларда фольклорчылар халык иҗатының мондый үрнәкләренә игътибар итмәделәр диярлек, чөнки аларны бастырып чыгару мөмкин түгел иде.

Мөнәҗәтләрнең барлык төркемнәре өчен дә, саф дини мөнәҗәтләрдән кала, хас булган төп сыйфат — ул да булса фаҗигалелек (трагизм). Ул барлык төркемнәр өчен дә уртак сыйфат. Фаҗига тулы мөнәҗәтләрне тудыручы сәбәпләр кешенең гомер юлында еш туа. Борынгы чыганакларны, уртак параллельләрне, охшаш жанрларны эзләү казакъларның көнкүреш җырларына, каракалпакларның елау-сыктауларына китерә. Мондый елау-сыктаулар төрки халыкларның язма ядкярләрендә мәңгеләштерелгән. Бу кайгы җырулары Мәхмүт Кашгарыйның «Диван лөгат-ит төрк» дигән тиңдәшсез хезмәтендә теркәлеп калган (IX гасыр):

| | |
|---|---|
| Алып эр тоңа елдиму?<br>Эсиз аңун калдыму?<br>Өзла өчен алдыму?<br>Эмди йурак йыртылур. | Алып ир Төнгә үлдеме?<br>Явыз дөнья калдымы?<br>Аның үзен алдымы?<br>Инде йөрәк өзелер. |

Казакъ язучысы Мохтар Ауэзов белән академик А. Маргулан сыктауларның иң борынгы үрнәкләрен гомумтөрки ядкярдә — Орхон-Енисей язмаларында ук табалар. Анда гасырлар катламын үткән кайгы авазы — баласын югалткан кеше сыкравы — «Кора бакмадым» (күреп туймадым) яңгырый. Әлеге сыктауның кайтавазы безнең көннәрдә иҗат ителгән «Газиз бәбкәм» дигән мөнәҗәттә ишетелә:

Газиз бәбкәм йөзләрен
Күреп һичбер туялмадым;
Газиз бәбкәм вафат булгач,
Күземдин яшь тыялмадым.

Шушыңа охшаш мотивларны «Дәдәм Коркет китабы» — борынгы төрки дастанындагы Бану Чәчәк сыктавында да табарга мөмкин.

Гарәп сәяхәтче-галиме Ибне Фазлан X гасырда ук Болгар шәһәрендә булып, анда кеше күмгәндә ирләрнең ачы тавыш белән елавын күзәтә, ә коллары үз-үзләрен камчы белән яралар дип яза. Ислам тарату вазыйфасын үтәүче Ибне-Фазланга болгарларның мәҗүси йолалары ошап житмәве гаҗәп түгел. Шулай ук каракалпакларда да, аларның борынгы йолалары буенча, үлгән кеше йортына ирләр елап киләләр, ә өй эчендә елау-сыктауны хатын-кызлар башлыйлар. Бу йола борынгы чорларда барлык төркиләргә дә хас булган дип фараз кылырга мөмкин.

Ислам дине кайгы-хәсрәт күренешләрен дини кысаларга кертте, алар тирәнгә, җанга сеңде, йомылды, ләкин бу хисләр шундый ук әрнүле, газаплы булып кала бирде һәм юату юлларын эзләде.

Н. Хисамов та мөнәҗәтләрдә йола жанры — елауларның кайтавазын күзаллый һәм аларның, жанр буларак, Казан татарларында юкка чыкканын әйтә.

Елау-сыктаулар дин йогынтысында эзсез югалды дип әйтү дөрес булмас, алар үзләренең функцияләрен, образларын мөнәҗәтләргә тапшырганнар. Бу фикерне дәлилләү өчен казакъ җоктау-сыктаулары белән параллельләр үткәрү файдалы булыр. Җоктауларның һәм мөнәҗәтләрнең эчтәлеге, темасы, сурәтләү чаралары охшаш, аларда уртаклыклар шактый күп. Казакъ галиме А. Маргулан язуынча, борынгы йолалар: костасу, өстертү, җоктау, елаулар — казакъларга, кыргызларга хас. Алар исә һун, сак кабиләләренең безнең көннәргәчә яшәп килгән нәселтамыры. Мәхмүт Кашгари язмаларыннан күренгәнчә, җоктау — борынгы төрки кабиләләрнең уртак тормышы чорында ук барлыкка килгән җырларның бер төре. Тик бер нәрсәгә игътибар итәргә кирәк, казакъларда җоктау үзгәрешсез диярлек калган, ә X гасырда ук ислам динен кабул иткән татарларда бу елаулар көчле метаморфозага дучар булганнар. Шуңа да карамастан, алар гасырлар дәвамында тема һәм сурәтләр охшашлыгын югалтмаганнар.

Җоктау — халык иҗатының иң борынгы төрләренең берсе. Мондый әсәрләрнең барлыкка килүе кабиләдәге күренекле кешеләрнең үлеменә бәйле була, аларда юксыну-кызгану хисләре яңгырый, истәлекләр янара. Бу әсәрләрнең борынгы үрнәкләрен Орхон-Енисей ядкярләрендә, Күлтәгин, Бигре язмаларында ук күрергә була. Эпоста да елаулар бар. Мәсәлән, угыз ядкяре «Дәдәм Коркет» китабында Бәмси Бәйрәк җоктавы яңгырый.

Башка төрки халыклардан аермалы буларак, казакъларның җоктагын хатыннары булган, алар ялланып өйдән-өйгә елап йөргәннәр. Мондый елау осталары борынгы заманда Мисырда һәм Грециядә, революциягә кадәр Россиядә дә булган.

Аерылу фаҗигасе барлык төр әсәрләргә дә үтеп керә. Туган ил турында булсын, ана белән бала, яшәү белән үлем, дини эчтәлекле мөнәҗәтләр булсын — аларга бу тойгылар хас. Күп кенә әсәрләрне дөньяның фанилыгын, тереклекнең котылгысыз бетүгә дучар икәнлеген аңлау сугарган. Мәсәлән, «Фани дөнья», «Аерылдым туган илемдин» дигән мөнәҗәтләрдә шул мотивлар яңгырый.

Мөнәҗәтем сезгә улсын,
Дустым-ишем дога кылсын,
Догалары кабул булсын,
Фиракъ булдым туганнардан.

*(«Аерылдым илләремдин»)*

Фиракъ уты, фиракъ уты,
Сүнәрме икән йөрәкләрдән?
Исән чакта кайту насыйп
Булырмы икән еракларда.

Өченче төр мөнәҗәтләрдә дә — «Ана белән бала» дип исемләнгән төркемдә шул ук уй-фикер чагылыш таба:

Кайгы-хәсрәт күргәннәрнең бәгъре янар,
Кайгы-хәсрәт күрмәгәне уенга санар:
Кемнең итәгенә төшсә — аныкы янар,
Фиракъ уты һич ялкынсыз янар инде.

*(«Балаларым чыкмый истән»)*

Мөнәҗәтләрнең күбесендә аерылу ялкыны — фиракъ уты төтенсез ялкынланып, бар тереклекне һәлак итә:

Кызыл гөлләр булса иде,
Сачагең коймаса иде,
Бери — үлем, бери — фиракъ,
Шул икәү булмаса иде.

*(«Исәр җилләр»)*

Бу аяусыз фиракъ сурәте икенче жанрга — бәет жанрына алып килә. Аларда башка охшашлыклар белән рәттән уртаклык — фаҗигалелек калкып чыга һәм бу мотив жанрны берләштерә. Бәетләрнең сюжетында илен, кадерле кешеләрен югалтудан туган әрнү, сыктау янгырый. Мөнәҗәтләр исә вакыйгаларны андый ук эпик характерда күрсәтмиләр. Бу жанр тар даирәдә башкарыла торган әсәрләрне үз эченә ала.

Туган ил белән хушлашуга багышланган мөнәҗәтләр типологик планда казакъларның «костасу» җырлары белән охшаш. Костасулар өчен иң хас тема, М. Ауэзов язганча, чын-чынлап халыкчан тема — туган ил, туган җир белән хушлашу: «Җирләрне тартып алу, чит җирләргә кысрыклап чыгару, сахраларга авыл һәм волостьларның куылуы даланы патша гаскәрләре тартып алгач кына түгел, ә бәлки ханнар заманында ук булган... Менә бу бәхетсезлекләр халык хәтерендә уелмас эз калдырган һәм кайгылы костасу җырлары тууга сәбәп булган».

1552 елда колонизацияләүгә дучар ителгән татар халкының үткән тарихы шулай ук кайгылы. Башта ээәрлекләүләрдән, көчләп чукындырудан качып, ахырдан җирсезлек, хәерчелектән иза чигеп, Идел буенда кабатланып торган ачлыктан котылырга теләп, татарлар Рәсәй дәүләтенең иксез-чиксез киңлекләренә таралганнар. «Бөтен ил масштабында чагыштырып карасаң, татарлар иң сибелеп (лисперсно) утырган халыкларның берсе»,— дип яза галимнәр. Туган илен, якыннарын өзелеп сагыну, югалтулар, ачы кайгы хисләре татарларын үтә дә моңлы, озын көйле җырларында, мөнәҗәтләренә сеңеп калган. Алар казакъның костасу җырларындагы тойгылар белән аваздаш;

Мөнәҗәтем минем бетмәс,
Кәгазь илә каләм җитмәс,
Туган ил исемнән китмәс,
Сабыр бирсен газиз Алла.
Туганнарым, фиракъ булдым,
Күрешергә ерак булдым.
Сезне күреп сөйләшергә
Акыллардан яза булдым.

*(«Туган ил исемнән китмәс»)*

Мөнәҗәтләрнең искиткеч моңлы көйләре дә, эчтәлеге белән берлектә, җанга үтеп керә, үзәкне өзә. Язучы Галимҗан Ибраһимов җырларыбыз, музыкаль фольклорыбыз турында болай язды:

— Чын милли музыка — халыкның йөрәгендә булган тойгыларының тудырган җимеше, җанының аһы, зарларыдыр. Татарның асыл табигате бөек, җаны мәртәбәле, йөрәге бик хәссас булып, икенче яктан, язмышы бик агыр, тарихының соңгы сәхифәләре баштанаяк көенеч вә хәсрәт илә тулыдыр. Язмыштан мәтәэсир булмавы мөмкин булмаган музыкасы да шуның өчен гел җылый, гел моңлана... Һәм халык та үзе белмичә үк, тик шундый көйләрне, шундый музыканы гына йөрәгенә алып, гасырлар буенча саклап килә. Язучы биредә җырларның да, мөнәҗәтләрнең дә көйләренең һәм эчтәлегенең чишмә башларын аныклый.

Кайбер тикшеренүчеләр мөнәҗәтләрнең килеп чыгышын поэтик яктан да, методик яктан да «Мөхәммәдия»не көйләп уку традициясенә бәйләп карыйлар. Дөрестән дә, дини һәм дөньяви әсәрләрне, шул исәптән «Кыйсса-и Йосыф»ны, «Бәдәвам»ны һәм, иң әһәмиятлесе, Коръән сүрәләрен дә көйләп башкаралар. Мөнәҗәтләрнең чишмә башын йола җырлары дип фаразласак, ә дин тора-бара ритуаль йолаларны да үз карамагына ала, димәк мөнәҗәтләрне көйләү чагыштырмача борынгырак дип фикерләргә мөмкин.

Халык иҗатының үз закончалыклары бар. Язма әдәбияттан алынган образлар фольклорда да яңгырый башлый. Кол Галинең «Кыйсса-и Йосыф» әсәрендәге образлар мөнәҗәтләргә дә килеп керә. «Өзелеп язган мөнәҗәт»тә шул образларга ишарә бар:

Сагыну хәле кыен эштер, йөзләремне сары алмыштыр;
Балалардан аерылу пигамбәрләрдән калмыштыр.

Татар хатын-кызлары гасырлар буе яратып укыган китапның каһарманын үрнәк итеп алып, үзләренең сагыну хисләрен Ягъкупның улы белән аерылганнан соңгы газаплары белән чагыштыралар. Туган иленнән аерылган, яраткан әтисен һәм туганнарын чит җирдә сагынып яшәргә мәҗбүр булган, әрнүле хисләргә, газапларга сабыр иткән һәм Аллаһе Тәгалә тарафыннан шуның өчен дә ярлыкан-

ган Йосыф образы татар халкының йөрәк түрендә яши. Чөнки халкыбыз бу сыйфатны-сабырны милли-эстетик хәзинә дип саный. «Сабыр иткән морадына җиткән», «Сабырлыкның төбе — сары алтын» кебек һәм башка шундый мәкальләр халык әхлагының нигезенә салынган.

Татар халкынын яраткан поэма-дастаны «Кыйсса-и Йосыф»ның мотивлары күп кенә мөнәҗәтләрдә урын алган... «Ялгыз агач», «Балаларым чыкмый истән», «Узды яшь гомер», «Өзелеп язган мөнәҗәтем» дигән мөнәҗәтләрдә чагыла, якыннарыннан аерылып кайгыда яшәгән кеше үз язмышын Йосыф язмышына охшата. Йосыф образы бик күп фольклор әсәрләрендә газап, хәсрәт, сабырлык символы буларак гәүдәләнә. Дастанның икенче каһарманы Зөләйха да шушы милли сыйфатка — сабырлыкка ия. Йосыфка булган мәхәббәтенә тугрылыгы, кырык ел буена сабыр итүе аңа фольклор каһарманнары арасында аерым урын бирә. Сабырлыкны милли сыйфат буларак дин тәрбияли һәм халыкның гасырлар буе коллыкка бирешми көрәшеп яшәве чыныктыра.

Дини, Коръән, темаларына язылган мөнәҗәтләрдә дә, беренче чиратта, бу илаһи сыйфатка — сабырлыкка өндәү яңгырый.

Сабыр итик, сабыр итик,
Сабыр колдан шәйтан качар,
Сабыр коллар җәннәт ишеген
Үз куллары белән ачар.

Бу сыйфат аерым мөнәҗәтләрнең бердәнбер темасына әверелә, бирелә әлеге сыйфатка ия булган пәйгамбәрләр турында сүз бара, сабыр кешеләр, Алла юлында йөрүчеләр оҗмах юлындагы сират күперен дә җиңелрәк үтәләр.

Һичшиксез, гүзәл көйләре белән бергә бу әсәрләр зур тәэсир көченә ия булып торалар.

Казакъларда ислам кабул иткәннән соң шулай ук дини характердагы җырлар туа, алар «бата», «пара-пазан» дип аталалар. Алар халык җырлары калыбына салынганнар. М. Ауэзов язуынча, исламның казакъ халкы арасына үтеп керүен тизләтер өчен, муллалар, ишаннар, хуҗалар халык җырын үз максатларында файдаланалар, әмма акыннар бу җырларны башкармыйлар, аларны муллалар башкара. Шулай да, тема, образ-сурәтләр тотрыклы килеш сакланса да, йола поэзиясе һәм йолалар үзләре дә казакъларда да элеккечә үк калмый. Аларны ислам үзгәртә. Шәригать тәэсирендә казакълар үлгәннәргә багышлап көнгә өч тапкыр елау-сыктаудан туктыйлар (бу элек I ел дәвам иткән). Дини китап образлары жоктауга, өстертүгә дә үтеп керә. «Йола поэзиясендә оҗмах, җәһәннәм, үлем фәрештәләре, кылдан нечкә сират күпере кебек образлар кулланыш таба.

Бу процессны күзәтеп торган Чокан Вәлиханов XIX гасырда болай дип яза: «Далада хәзер ике властьлылык хөкем итә». Ислам йола поэзиясен үзгәртеп, бер үк вакытта аны юкка чыгудан саклап кала. Бу үзгәрүгә дучар булган казакъ елаулары шулай булса да үзләренең йола функциясен башкарып киләләр, ә татар мөнәҗәтләре исә гасырлар дәвамында күмү йоласыннан бәйсез, мөстәкыйль жанрга әверелделәр.

Күп кенә мөнәҗәтләр өйрәнү характерында язылган, аларның эчтәлеге Изге Коръәннең төрле кагыйдәләрен халыкка, киң массаларга таратуга юнәлдерелгән. Мәсәлән, олы яшьтәге информаторлар тәһлилне күп тапкыр тәкърарлауның кирәклеген белдерүче мөнәҗәт әйтәләр:

Лә иләһә илләлаһны күп әйтегез мәләкләр,
Лә иләһә илләлаһсыз
Кабул булмый теләкләр.

Бирелә Аллаһе Тәгаләгә дан җырлау барлык теләкләрнең кабул булуына китерә диелә. Бу мактау сират күпере аша чыкканда ярдәм итәр, җиде оҗмах капкасына ачкыч булыр. Аны көненә күп тапкыр кабатлау һәм мөселман өчен зарури. Исламның төп тәртипләрен халыкта тәрбияләүче, нигытучы мондый мөнәҗәтләр халык арасында бик киң таралган.

Мин сөям ислам динен,
Ислам илә мин мактанам.
Әле дә Мөэмин исемен алган
Мин әле дип шатланам.

«Бисмиллаһи дип башладым», «Исрафил сурын өргән», «Тәңремә сәҗдә кылаек», «Бу дөньяда ничә җаннар», «Намә» һәм башка әсәрләрдә шундый

фикерләр күп. Алар, дини мәгълүматлар бирү белән беррәттән, татар халкының әдәп-әхлак нигезләрен ныгыталар, саранлык, гайбәт сөйләшү, дорфалык, әче теллелек кебек начар сыйфатларны тәнкыйтьлиләр. «Дөнья — фани, яшәү — вакытлы, ахырында кабер котә — моны һәр кеше истә тотарга тиеш»,— ди халык иҗаты. Бу турыда гел хәтерләргә кирәк: «Көн дә бер күз салып куй каберенә, сөаль өчен Мәнкир — Нәнкир юк димә».

Биредә үлем фәрештәләре сурәтләнә. Дини образлар — җәннәт, җәһәннәм, оҗмах, иман, тәкъдир, сират күпере — мөнәҗәтләрдә бик еш искә алына. Кыямәт көнне бөтен кеше үзенең кылган гамәлләре өчен җавап бирәчәк.

Уйла, бәбкәм, үләсеңне, кара җиргә керәсеңне,
Кара җир астына кергәч ни җаваплар бирәсеңне.

*(«Бисмиллаhи»дип башладым»)*

Тыйнаклык, басынкылык, үзеңнең теләкләреңне, дәртне тыю, сабырлык, күндәмлек, үтәүчәнлек — Коръәндә менә шундый сыйфатлар мактала, һәм шулар ук мөнәҗәтләрдә дә мактап сөйләнә дә, көйләнә дә.

Дини мөнәҗәтләр арасында Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормышын яктырткан тулы бер цикл бар: «Мөхәммәд пәйгамбәргә мәдхия», «Әминә ханым — Мөхәммәд анасы» һ. б. Бу әсәрләрдә Мөхәммәд пәйгамбәрнең Аллаһе Тәгаләгә, халкына тугрылыгы, үзен аямыйча бирелеп хезмәт итүе, фидакярлеге мактала.

Аллаһ белән киңәштең,
Хакыйкатьне күзләдең,
Йә, Мостафа Мөхәммәд,
Саллалаһу Галәйһә
Йә, Мостафа Мөхәммәд!
Өммәт өчен күп көйгән
Күп хәсрәтләр җыйган
Бик күп михнәтләр чиккән ул —
Мөхәммәд Мостафа!

Дини Мөнәҗәтләр аша татарлар Коръән тәгълиматенең күп якларын кабул итәләр, бу фольклор жанры аларны халыкка тизрәк, җиңелрәк илтеп җиткерә. Татарлар X гасырда ук кабул иткән Ислам халык тормышкөнкүрешенең, мәдәниятенең барлык катламнарына үтеп керә, әхлак ориентирларын билгели. Күренекле рус тарихчысы В. С. Соловьев әйтеп үткәнчә: «Мөселманнарның бер өстенлеге бар: аларның бөтен тормышы иманнарына туры килә, алар үз диннәренең кануны буенча яшиләр». Мөнәҗәтләр үгетнәсихәтне, өйрәтүләрне дини авторитетлар аша дәлилли, көчәйтә. «Муса» дигән мөнәҗәт шундыйлардан. Ул соңгы вакытта эфирда да еш яңгырый. Мөнәҗәт дөньяны яратучы Аллаһе Тәгалә һәм Муса пәйгамбәр арасындагы диалогка корылган. Муса күкләргә карап ялвара һәм нинди гамәлләр, юллар белән оҗмахка лаек булачагын сорый. Алар Коръәндә урын алган. Аллаһе Тәгалә шартларын санап күрсәтә: ата-анага ихтирам (Исра, 23, 24), балаларны кайгырту (Исра, 24), күршеләр белән дуслык, татулык. Коръән тәгълиматыннан килә торган таләпләр мөнәҗәтләрдә сурәтләнеп, яшәеш таптылар, дини һәм милли яңгыраш алдылар. Чөнки мөнәҗәтләр Ислам кануннарын аңлаешлы итеп, туган телдә — татар телендә җиткерде, аларга музыкаль яңгыраш бирде.

«Манара» — шулай ук халыкта киң таралган мөнәҗәт. Бу юлларның авторы аны 1983—1986 елларда Татарстанда да, Курган, Түбән Новгород өлкәләрендә дә язып алды.

Эфирда исә бу әсәрне бары тик 1992—1994 елларда гына башкару мөмкин булды. Ул, тексттан күренгәнчә, XX гасырның 30 нчы еларында иҗат ителгән булса кирәк. Тексттагы бер юл шушы елларга ишара итә кебек:

Бер эчәрлек хәмер өчен
Үзгәңне өзгәннәр.

Бу ямьсез күренеш — хәмер эчү татарларда революциядән соң гына көчәеп китә бит. Ә исерек мөртәтләр манараларны кисүгә 30 нчы елларда инде курыкмый керешкәннәр. Бу мөнәҗәтнең нигезе, калыбы элекке гасырларда иҗат ителгән «Сөембикә манарасы» дигән бәетнекенә охшаш, анда да манарага мөрәҗәгать итү кебек алымнар бар. Ул бәеткә таянып, Мәҗит Гафури да үз әсәрен иҗат

иткән. Ә хәзер халыкта киң таралган мөнәҗәт «Манара» мәчетләрне җимереп, манараларны кисеп, дин әһелләрен эзәрлекләгән чорда кискен протест рәвешендә иҗат ителгән әсәр. Бу чорда халыкның кадерләп күңел түрендә үк яшәткән изге манараларыннан 14 меңе юк ителә, киселә.

«Фольклорның иң әһәмиятле әсәрләре тарихның иң киеренке сәхифәләренә туры килә». Киң таралган бу мөнәҗәт исә тәэсирле эчтәлеге белән җанга үтеп керә. Моңлы көе, үзенчәлекле композициясе билгесез авторның талант иясе булганын күрсәтә. Биредә илаһияткә турыдан-туры мөрәҗәгать итү юк, әмма эчтәлеклеге буенча ул мөнәҗәт жанрына туры килә. Әсәр диалог рәвешендә язылган. «И, манара!» дигән мөрәҗәгатьтән башлана. Иң ахырда манара үзенең җавабын әйтә. Халык иҗаты әсәрләре өчен табигать күренешләренә, җансыз предметларга — вакыйгаларның шаһитенә мөрәҗәгать итү хас. Бу алым мөнәҗәтләрдә еш кулланыла. «Исмәле, җил!» дигән мөнәҗәттә — җилгә, «Ялгыз агач»та — агачка, «Газиз бәбкәм»дә — аккошка эндәшелә. Мондый шигъри алымнарны куллану «Манара» әсәрен хисле, үтемле итә. Әлеге әсәрдә халык өчен кадерле булган ядкярләрнең, изге урыннарның хурлануына әрнү чагыла:

И, манара, ничә еллар син утырдың, нур булып.
Сине кисеп төшергәннәр йөрсен инде хур булып.

М. Горький язганча, борынгыдан ук халык авыз иҗаты тарихны бик үзенчәлекле яктырта, аның турында үз фикерен әйтә. «Дин халык өчен агу» дигән рәсми күрсәтмәгә капма-каршы куеп, халык әхлаксыз гамәлләргә үз хөкемен чыгарган. Мөнәҗәтләрдә дә, прозаик риваятьләрдә дә хөкем бик кырыс. Андый явызлар йә эчеп эштән чыгалар, төзәлмәс авыруга дучар булалар, гарипләнеп яталар, йә каргыш аларның балаларына төшә. Мондый карарны халык тарих хөкеменнән күп алда чыгара. Тарих исә әлеге хаксыз эшләргә тик 60—70 елдан соң гына тиешле бәясен бирә алды, чөнки мөмкинлек 90 нчы елларда гына туды.

Соңгы вакытта бик еш башкарыла торган тагын бер мөнәҗәт бар. Анда җәмгыятьтәге әхлаксызлык, ата-ананың балалары язмышына битарафлыгы, йә балаларның өлкәннәргә мәрхәмәтсезлеге өчен кайгыру, җанның имансыз, тәннең сихәтсез булуына, яхшылыкның таянычсыз, яманлыкның киртәсез булуына ачыну хисләре тулып ята. Атасыз балалар тууы, хәмер белән мавыгу һәм тагын шундый бик күп ямьсез күренешләрне тудырган сәбәп — диннең бетүендә, намаз, дога кебек изге гамәлләрнең онытылуында:

Атасыз бала күп булыр, маллы кеше саран булыр.
Мәҗлесләрдә уен булыр, менә шундый заман җитәр.

Бу әсәрнең иҗат ителү чорын төрлечә фараз кылырга мөмкин: безнең көннәр дип тә, 17—18 еллар дип тә уйларга ярый. Яисә узган гасырларның шундый ук авыр елларыдыр? Ни генә булса да, моңар аваздаш юллар казакъ халык иҗатында да очрый:

Муннан соң килы — килы заман болар:
Заман озып, зан тозып, жаман болар.
Карагайдың башына шортан шыгып,
Балаларның дәурәни тәмам болар.

Татарчасы болай булыр:

Моннан соң шундый заман булыр:
Заман узып, тәртип бозылып, яман булыр.
Наратның башына чуртан чыгар,
Балалардан бәхет китәр.

Бу юлларның авторы XV гасырда яшәгән, татар һәм казакъ халыкларының чәчәне, эшлеклесе Асан (Хәсән) Кайгы дип санала. Гасырлар тарих тирәнлегенә сеңә барса да, еллар катламын үтеп, халык иҗаты ярдәмендәге кешеләрнең кайгыборчулары безнең көннәргә килеп җитә, елау, соктау, костасу, мөнәҗәтләрдә яңгырый.

Татар мөнәҗәтләре тарих дәвамында тирән мәгънәле эчтәлекләре һәм шигъри, музыкаль камиллекләре белән халыкта югары әхлак сыйфатлары тәрбияләп килделәр. Аларның вазифаларын, темаларын, сурәтләү системасын тугандаш казакъ каракалпак халыкларының елаулары белән чагыштыру күрсәткәнчә, жанрга хас чишмә башы төрки халыкларның борынгы елау-сыктауларына барып тоташа. Әмма татар халык иҗатында бу әсәрләр тар, ритуаль кулланышта гына калмыйча, әдәби-фольклорчыл жанрга әверелде. Алар татар халкының милли психологиясен хокын формалаштыруга зур өлеш керттеләр.

**Айсылу САДЫЙКОВА,**
филология фәннәре кандидаты.

# КАҺӘРЛЕ КАРАРЛАР

«Татарстан АССРның урта мәктәпләрендә бу дәреслектән файдалануны тыярга» — ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты 1948 елның 12 сентябрендә «Урта мәктәпнең 8 нче сыйныфы өчен татар әдәбияты дәреслеге турында» чыгарган карарында катгый рәвештә әнә шулай дип язып куелган. Беренче карашка, тыныч һәм битараф кына исемләнгән бу партия документы байтак кешеләрнең язмышларын хәл иткән, бик каты сәяси ыгы-зыгылар тудырган, берәүләрне ялагайлыкка этәргән, икенчеләрен, күз буяу өчен генә булса да, татар халкының тарихына фәнни карашлы галим булып кыланырга мәҗбүр иткән. Бу вакыйганың ерак кайтавазы, безнең көннәргә кадәр килеп җитеп, бернечә буын тарихчылар, әдәбиятчылар һәм җәмгыять белеме галимнәренең язмышларында һәм фәнни карашларында җуелмас эз калдырган. Аңарда, барлык сорауларга да бәхәссез җавап бирә торган марксистик догма һәм «Иосиф инҗиле» — «ВКП(б) тарихының кыскача курсы» кысаларыннан чыгып, милли үзаңга омтылыш ясарга тырышуларны аерым бер кырыслык белән томалапбастырып килгән авторитар режимның сәяси принциплары һәм табигате-холкы ачык чагыла.

Бу вакыйгаларга кадәр ни-нәрсәләр булган соң? Шул хакта бернечә сүз әйтеп китү кирәктер. 1944 елның 9 августында ВКП(б) Үзәк Комитеты «Татарстан партия оешмасында масса-сәяси һәм идеология эшенең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында» дигән мәгълүм карарын чыгара. Бу карар татар һәм кайбер башка халыкларның тарихын һәрьяклап гадел-дөрес итеп өйрәнү юлларын озак елларга ябып куя, аның төп фикерләре җөмһүриятебезнең барлык идеологик «уен коралларын бер көйгә көйләү өчен камертон» хезмәтен үти башлый. Казанга шул уңай белән ВКП(б) Үзәк Комитеты инструкторы Сакontиков килә (башта ҮКның агитация һәм пропаганда идарәсе башлыгы, булачак академик Александровның үзен көтәләр). Сакontиков әлеге карарны «ВКП(б) тарихының кыскача курсы» басылып чыгу уңаеннан ҮКның 1938 елда кабул иткән мәгълүм карары белән тиңләштерә. Мәгънәле тынып ясап: «Аның тексты иптәш Сталин тарафыннан карап чыгылды»,— дип өстәп тә куя. Ул елларда мондый сүзләрнең кешеләргә ничек тәэсир иткәнен сөйләп тору кирәкмидер. Шулай итеп, карарга аерым бер мөһимлек төсмере бирелә. Сүзен-сүзгә, хәрефенхәрефкә үтәми кара син аны!

Аннан соңгы бернечә ел эчендә җөмһүриятнең бөтен идеологик һәм мәдәни тормышы каты контрольгә алына, теге яки бу эш-гамәлгә бәя биргәндә август карарына ярашлымы-юкмы икәне тикшерелеп бәяләнә. Әдәбият-сәнгать өлкәсендә «Идегәй» дастаны эзәрлекләнә, аны бастырып чыгаручылар (беренче чиратта, күренекле язучы Нәкый Исәнбәт) һәртөрле кысу-җәберләүләргә дучар ителә. «Алтынчәч» операсының либреттосы Алтын Урда ханнарына каршы фикерләрне кискенләштерә төшеп, үткенләштереп кат-кат эшләтелә, хәтта «баскынчы ханнар» дигән тәгъбир-төшенчә кертелә — аның сәяси мәгънәсе һәркемгә ачык булса кирәк. «Җучы улусы» таркалганнан соң Идел буенда барлыкка килгән дәүләтләрнең тарихларын өйрәнүче галимнәр кискен тәнкыйтькә очрыйлар. Аның каравы, татар халкының совет үрнәгендәге бердәнбер лаеклы элгәре — ата-бабалары дип болгар компоненты игълан ителә. Татар халкының чыгышы мәсьәләсе җәмәгатьчелекне революциягә кадәр дә борчып торган. Әмма ул вакытларда бу хакта төрле фараз кылулар белән ризалашу яки ризалашмаукилешмәү сәяси эзәрлекләүләргә һәм, һөнәреңнән ваз кичтереп, эштән куылуларга чаклы китереп җиткермәгән. Бөек татар шагыйре Дәрдмәнд (сүз уңаеннан әйтеп үтик: 1906—1917 елларда Россия Дәүләт Думаларында бердәнбер шагыйрь-депутат), үзләренең татарлыкларыннан тулысынча ваз кичкән куркак җаннарны тамгалап, мондый шигъри юллар язып калдырган:

Татарлыктан татар һич гарь итәрме?
Кеше үз исмене инкяр итәрме?
Татарлыкта татар угълы татармын,
Татар түгел, димә — башын ватармын!

Кайбер замандашларыбызның, төрле өзек-төтек «фәнни» дәлилләр белән уйнаштыргалап, үткәндәге татарлыгын каһәрли-каһәрли, янадан «болгар оясына» кереп качарга омтылышлары әнә кайлардан ук килә икән! Татарстан Җөмһүриятенең бүген дөнья мәйданына чыга баруына эчләре пошкан рәсәй шовинистлары мондый казгануларны барыбер бәяләмәсләр дип уйлыйм. Әлбәттә, Мирфатих Зәкиев яки Әбрар Кәримуллин шикелле, үзеннән чыгышынны скифлар белән дә, хәтта индеецлар белән дә бәйләргә була. Ләкин теләсә кайсы урыснын аңында без — ышыгында урыс князьлекләре көч туплаган Алтын Урда империясе варислары, христиан диненә беркайда да булмаганча өстенлекләр биргән татарлар нәселе булып калачакбыз. Үз тарихыннан куркып качмаска кирәк. Без ничек кенә икейөзләнсәк тә, тарихта беркем дә бүген яшәүчеләргә берничек тә бурычлы түгел. Югарыда сөйләнә башлаган вакыйгалар булып узган елларда да татар галимнәрен шул ук сораулар борчыган.

Татар галимнәренең махсус күзәтү астында торганлыклары хакында күп кенә дәлилләр китерергә була. Татарстан партия оешмасының идеология өлкәсендәге ялгышлары турында үзәк матбугатта даими кабатлап, искә төшереп торулар, дисеңме, Мәскәүдә шелтәли-шелтәли үткәрелгән киңәшмәләр, дисеңме... Үзәк журналларның берсендә «Татарстан тарихчылары арасында буржуаз милләтчелек теорияләре һәм карашлары яшәп килә» дигән кисәтү дә бик шомлыкуркыныч яңгырый. ВКП(б) Үзәк Комитетының «Звезда» һәм «Ленинград» журналлары турындагы карары, Михаил Зощенко белән Анна Ахматованы мәсхәрәләүләр, космополитизмга каршы көрәш һәм башка шундый чаралар сәяси тотырыклылык булдыруга ярдәм итмиләр, билгеле. Нәкъ шул вакытларда байтак зыялыларга «пачпортсыз сукбай» («беспачпортный бродяга») дигән тамга сугыла, шундый тамгалыларның кайберләре аннары кулга алына. Сүз уңаеннан, инде күп еллар үткәч, бер дә вакытсыз-урынсыз рәвештә, хакимият алдында чын «патриот» икәнен күрсәтәсе килепме, Р. Нәфыйгов кайчандыр А. Жданов кертеп җибәргән бу ямьсез тамга белән Гаяз Исхакый, Фуад Туктаров, Гомәр Терегулов кебек күренекле зыялыларыбызны тамгалый. Әле житмәсә, үзеннән дә өстәп, аларны «үз халкына өрүчеләр, империализм ялчылары» дип, Ждановтан да уздырып җибәрә.

Илнең сәяси-рухи тормышындагы әлеге хәл-вакыйгалар Татарстан партия оешмасындагы түрәләрнең ни өчен идеология өлкәсендә «генераль линиядән» аз гына тайпылышларга да борчылып үртәлүләрен аңларга ярдәм итә. Юкса, 1944 елгы карарда күрсәтелгән барлык «хаталар» да 1948 елга кадәр инде төзәтелгән: «Идегәй» дастанына тиешле тамга сугылган, тарихчылар берсүзсез татарларның бары тик болгар варислары гына икәнлеген «таныган», ә Алтын Урда дәүләтенең «явызлык империясе» булганлыгы «исбатланган» — ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Зиннәт Моратов белән идеология секретаре Хажи Рәхмәтуллин тыныч йоклый алалар шикелле. Юк шул... Буйсынмаганнарны буйсындыру өчен идеологик көсәк яңадан күтәрелә. «Культура и жизнь» газетының 1948 елгы 11 июль санында Сталин чоры совет кешесен тәрбияләүдә мәктәпнең бурычлары турында зур мәкалә басылып чыга. Мәкаләдә, буржуаз идеологиянең яшьләрне тәрбияләүгә нинди начар йогынты ясавына ачык мисал рәвешендә, татар әдәбияты буенча 8 нче сыйныф өчен 1948 елда дөнья күргән дәреслек-хрестоматия китерелә. Газет дәреслекне төзүчеләр «әлекке әдәбиятка житәрлек дәрәжәдә тәнкыйди бәя бирмәгәннәр, кайбер язучыларның хаталары турында бер сүз дә әйтмәгәннәр, күрә торып хаталы һәм зарарлы әсәрләрне (ассызык безнеке. Б. С.) керткәннәр» дип яза. Сугып еккач, тора алмаслык итеп сугу була бу. Әле кайчан, диген?! 1944 елгы август карарын Татарстанда намус белән үтәү турында «югарыга» — иптәш Сталинның үзенә рапорт биргәннән соң! Шундый «күрәләтә хаталы һәм зарарлы әсәрләр» чыгаралар... Моннан да зур гөнаһ булуы мөмкинме? Әле шуның өстенә, күренекле татар шагыйре Муса Җәлил дә зур шик астында — «немецларга хезмәт иткән, аннары әллә җәзалап үтерелгән, әллә качкан-яшеренгән» дигән хәбәрләр йөри. Инде менә тагын монысы... Бар фетнә шул СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы Тарих, тел һәм әдәбият институтыннан чыга. Әлеге дәреслек-хрестоматияне төзүчеләр дә шунда эшлиләр. «Идегәй» дастаны белән янгач, директорын да «чәйнәгән» иделәр, күрәсең, яна директор Мөхәммәт Гайнуллин да җитәрлек уяулык күрсәтмәгән.

Партия җитәкчеләренең уй-фикерләре якынча шундыйрак булгандыр. Бер нәрсә эшләр хәлең юк — -үзәк матбугатта тәнкыйтьләнү һәм хәтта башкалар белән бергә телгә алыну да өлкә комитеты бюросында мәҗбүри тикшерүне таләп итә. Ә монда бит тулы бер абзац, җитмәсә, шундый каты формулировка-фикер белән...

Сүз уңаенда әйтеп узыйм, мин Хаҗи Рәхмәтуллин белән таныш идем. Ул бик йомшак һәм зыялы кеше иде үзе. Сөйләшүебез аның инде, партия өлкә комитетыннан алынып, мәдәният министры булып эшләгән илленче еллар башында булган иде. Үткәннәрдәге идеологик четерекле-катлаулы хәлләрне, шул исәптән, Кави Нәҗминең «Язгы җилләр» романы турында үзенең телефон аша иптәш Сталин белән сөйләшкәнен дә (бу хакта легендалар йөри иде инде) искә төшереп, ул миңа 1948 елда Мәскәүдән Александров шалтыратканын, кычкырына-җикеренә, Үзәк Комитетка чакыртып тикшерү белән янаганын сөйләгән иде. Зиннәт Моратов белән дә шундый ук ямьсез-тәмсез сөйләшү булгандыр, мөгаен.

Газетта әлеге мәкалә чыкканның икенче көнендә үк махсус коммиссия төзелә. Аңа ВКП(б) өлкә комитетының матбугат секторы мөдире Мөҗәһитов белән сектор инструкторы Ярмәкиев җитәкчелек итә. Егерменче августта инде Зиннәт Моратов өстәленә «8 нче сыйныф өчен «Татар әдәбияты буенча дәреслек-хрестоматия» китабындагы җитешсезлекләр һәм хаталар турында, авторы — филология фәннәре кандидаты Л. Җәләй» дигән доклад язуы кертеп салалар. Тыгызлап басылган биш бит кәгазьдә язма авторлары китапның хаталарын һәм кимчелекләрән тәфсилләп тикшерәләр. Игътибар әдәби мәсьәләләргә түгел, ә гомумтарихи мәсьәләләргә юнәлтелә. Гомумән, эшнең асылын белмәсәң, сүз тарих дәреслеге турында бара икән, дип уйларга була. Язмадан күренгәнчә, Латыйф Җәләй элегрәк «эшкәртүләрдән» соң кайбер нәтиҗәләр ясаган икән ясавын. Ул әлеге дәреслегендә «...Идел буе халыкларының Алтын Урда баскынчылары тарафыннан таланганлыклары, аларның мәдәни үсеше туктальш калганлыгы, хокуклары һәм намуслары тапталганлыгы» турында дәрес яза. «Шул чор язучыларының мөселман дине тарафыннан агуланулары суфичылык белән мавыгуны арттыра, чөнки мөселман дине үзе суфичылыкка нигезләнгән» икәнлеген күрсәтә. Бәйләнер урын юк шикелле — Алтын Урда баскынчыларын яманлаган, ислам динен тиргәгән, әдәби истәлекләр сакланып калмавын сылтау итеп, Казан ханлыгы чорына бөтенләй тукталып тормаган, сикертеп кенә узган. Әйбәт ич! Әмма Мәскәү газеты хаталарын тапкан икән, бер нәрсә дә эшли алмыйсың инде, син дә хаталарын табарга тиешсең. Һәм табалар... Латыйф Җәләйне урыс мәдәниятен бәяләп бетермәүдә, тарих методологиясен белмәүдә гаеплиләр. Аннары «билдән түбән» китереп сугалар. Доклад язуында Сталинның «Марксизм һәм милли мәсьәлә» дигән мәкаләсеннән озын бер өзек китерелә. Мәкаләдә Россиядәге төрки халыкларның үсеш баскычлары бик өстән-өстән генә, җинелләштерелеп кенә сыйфатлап үтелә. Ә доклад язуында мондый нәтиҗә ясала: «Татар мәдәниятен, тарихын, әдәбиятын өйрәнгәндә иптәш Сталинның бик кыйммәтле бу күрсәтмәсен онытырга ярамый. Л. Җәләй дәреслегендә без татар әдәбияты тарихының асылын шул карашлардан чыгып өйрәнүне күрмибез». Менә шулай! Бик каты әйтелгән. Латыйф Җәләй иптәш Сталинның күрсәтмәләрен онытканмы, әллә бәяләп бетермәгәнме — барыбер начар. Алга таба инде чүп өстенә чүмәлә өелә. Зарарлы әсәрләр исемлегенә Мәүлә Колый, Габдерәхим Утыз Имәни, Габделҗаббар Кандалый (без бу бөек шагыйрьнең тууына 200 еллыгын быел бик зурлап билгеләп үттек), Заһир Бигиев әсәрләре кертелә. Бу асыл затларның татар мәдәниятының горурлыгы, ә аларның әсәрләре әдәбиятыбыз җәүһәрләре икәнлеген һәркем беләдер. Ә 1948 елда алар хакында: «Автор аларга лаек булмаган югары бәяләр бирә... аларны татар әдәбиятына нигез салучы эшлеклеләр итеп карый», «аларның идея һәм сәнгатьчә җитешсезлекләрен, халык мәнфәгатьләреннән ерак торганлыкларын күрсәтергә кирәк иде, ләкин дәреслек авторы моны эшләмәгән»,— дип мөһер сугалар. Габденнасыйр Курсавига да эләгә. Аның мәдрәсәләрдә яңача укытырга тырышып йөрүләрен, реформалар ясарга омтылышын прогрессив күренеш түгел дип саныйлар, Л. Җәләйнең Г. Курсавига булган карашын «тарихи һәм сәяси тупас хата» дип бәялиләр. Шунда ук идеологиянең иң көчле коралы — ленинизм тәгълиматы эшкә җигелә: «Ленин Курсави кебекләрне халык массаларын алдаучы, аларның аңнарын агулаучы-томалаучы кешеләр дип атаган, ә менә «иптәш Җәләй моны аңлый алмаган».

Бу доклад язуы — үтергеч. Әмма тиргәүләрне артык күп куллану ул әле һәрвакытта да максатка ирешүгә ярдәм итә, дигән сүз түгел. Әгәр дә һәр гаепләүне чынга алып, гамәлгә ашыра башласаң, Латыйф Җәләйне хөкемгә

тартырга кирәк: Сталинны да, Ленинны да санга сукмый булып чыга бит. Ләкин ул вакытта шундый сорау туа: ә партия өлкә комитеты нәрсә караган? Л. Җәләй яшеренеп, астыртын гына эшләп ятмагандыр ич?! Шуңа күрә әлеге гаепләүләрнең иң авырлары карарга кертелми калдырыла.

ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты бюросы утырышы 1948 елның 2 сентябрендә үткәрелә. Утырышта Ярмәкиев, Бакиров, Кашшаф, Рәхмәтуллин, Зарубина (мәктәпләр бүлеге мөдире), Үзбәков һәм Моратов иптәшләр чыгыш ясый. Беренче өчесе аңлатмалар бирә, калганнары гаеплиләр. З. Моратов чыгышының стенограммасы сакланып калган. Ул өлкә комитеты хезмәткәрләрен дә, мәгариф министрлыгы белән нәшриятны да гамьсезлек күрсәтүләре, авторга ирек куюлары өчен шелтәли. Бу нәрсәнең үзәк матбугат битләренә эләгүе З. Моратовның бигрәк тә ачуын кабарта. Аның чыгышының азагы игътибарга лаек: «...нәтиҗәдә контрреволюцион милләтчелеккә китерүче һәр төрле агымнарны фаш итә торган чын дәреслек кирәк»,— ди ул. Өлкә комитетының әнә ни өчен «башы авырта» — Татарстанның бөтен идеологик тормышында күзгә күренмәс бүкәй булып Мирсәет Солтангалиев күләгәсе тора. «Шуның өчен,— ди З. Моратов,— һәртөрле тайпылышларга сәяси нәтиҗәләр ясарга, дәреслек материалларын өйрәнгәндә, бер уңайдан балаларда нәфрәт хисе дә тәрбияли барырга кирәк». Җөмләсе чатаграк булса да, фикере төгәл әйтелгән — дәреслек нәфрәт хисе тәрбияләргә тиеш. Һәм без, оятыбызга каршы, озак еллар нәкъ шулай эшләп килдек тә.

Утырыш беркетмәсеннән күренгәнчә, гаепләнүчеләр (Л. Җәләй бюрода булмый, аның өчен дә, үзе өчен дә җавапны дәреслекнең мөхәррире Гази Кашшаф тота) акланып тормыйлар, комиссиянең тикшерү нәтиҗәләрен шик астына алырга җыенмыйлар. Ул заманнарда алай эшләп кара әле син!

Карарның раслаучы өлешендә тарих һәм әдәбият белеме өчен төп идеологик күрсәтмә бирелә, авторларның гаепләренә йомгак ясала. Мондый нәтиҗә чыгарыла: Л. Җәләй белән Г. Кашшаф үткәннәрне бәяләүдә көчсезлек күрсәткәннәр һәм буржуаз объективлык җәтмәсенә эләккәннәр. Дәреслеккә Габделҗаббар Кандалыйның «Сәхибҗамалга», Фатих Халидинең «Рәдде бичара кыз» һ. б. шундый зарарлы әсәрләр кертелгән. Шуның өчен дәреслекне татар әдәбиятын бәяләүдә тупас хаталар һәм заралы әсәрләр белән чыккан дип танырга һәм Татарстан АССР мәктәпләрендә бу дәреслектән файдалануны тыярга. ТАССР Мәгариф министрлыгы һәм Таттосиздат җитәкчеләренең җавапсыз мөнәсәбәтләрен гаепләргә һәм аларны дүрт ай вакыт эчендә яңа дәреслек чыгарырга мәҗбүр итәргә.

Дөрес, персональ җәза-шелтәләр бу юлы беркемгә дә бирелми.

Нәтиҗәләр ясалган, дәреслекнең яңа басмасын һәртөрле «әшәкелекләрдән» арындырып чыгаралар шикелле. Әмма әлеге 8 нче сыйныф дәреслеге тагын ачы язмышка дучар була. Төгәлрәге, татар халкының 1917 елга кадәрге, бигрәк тә урта гасыр мәдәнияте тарихы белән шөгыльләнүче теләсә кайсы галимне шундый ачы язмыш көтә. Татар халкының аңына, кыскартылган-өтелгән хәлдә булса да, иҗатларыннан совет чорына яраклыракларын сайлап алып, бөек акыл ияләре, шагыйрьләр һәм әдипләрнең кайберләренең исемнәрен кайтарырга тырышулар һәрвакыт «югарыдагы» җитәкчеләрнең каттый каршылыгына очрый. Үз тарихыннан курку, татар иҗтимагый фикеренең сәяси каһәре булган «солтангалиевчелек» белән көрәш шаукымнары, ВКП(б) ҮКның 1944 елгы август карары — болар барысы да партия җитәкчеләренең каннарына сеңгән, үткән заманнарга бәяне аерым бер саклык һәм катылык белән бирергә мәҗбүр иткән. Утызынчы еллардагы репрессияләрдән соң, заман тарихында завод-фабрикаларга исемнәре бирелерлек, идеологик кабул ителерлек берничә генә эшлекленең исеме сакланып калган шикелле, татар халкының революциягә кадәрге тарихыннан да Габдулла Тукай, Каюм Насыйри һәм, кайбер искәрмәләр белән, тагын бер-ике исем генә сөйләнергә хаклы иде. Хәтта Габдулла Тукай да утызынчы еллар урталарыннан гына, иҗаты шактый өтелеп, кабул ителгән. Аңа кадәр ВКП(б) өлкә комитетының баш идеологы Абдуллин дигән берәү мәдәният хезмәткәрләре киңәшмәсендә кайбер яшь язучыларны, «вак буржуаз шагыйрь Тукаев» белән мавыгуда гаепләп, камчылап чыга.

1952 елның гыйнварында татар мәктәпләре өчен каһәрле теге дәреслек яңадан сәяси эшафотка бастырыла. Өлкә комитеты бюросының карары бу юлы 1948 елгысыннан катгыйрак була. «Татар урта мәктәпләренең 8 нче сыйныфы өчен әдәбият дәреслегендәге хаталар турында» дип атала ул. Карарның гаепләү өлешендә һаман да иҗатлары, янәсе, яшьләргә коммунистик тәрбия бирү эшенә зыян китерердәй һәм бөек урыс халкы белән дуслыкны какшатырдай чит-ят

язучыларның исемнәре кабатлана. Тагын да усалрак бәя җәдитчелеккә бирелә — аны акгвардиячеләрнең, соңыннан троцкист-бухаринчыл милләтче бандалар белән берләшеп, капиталистик разведкаларның ялланган агентурасына әверелгән союздашы дип тамгалыйлар. Нинди тәвәккәллек, ә! Хәзер инде, чит-ят әдипләрне пропагандалаганы өчен, дәреслекнең урта гасыр әдәбияты бүлеген язган Б. Яфаров, җәдитчелек өчен, дөресрәге, янәсе, җәдитчелекне мактап «Совет әдәбияты» журналында мәкаләләр бастырган өчен Г. Халит һәм «Реакционная школьная политика царизма в отношении татар Поволжья» («Идел буе татарларына карата царизмның реакцион мәктәп сәясәте») китабы авторы профессор В. Горохов тәнкыйтьләнә. Б. Яфаровка бирелгән бәя бигрәк тә хурлыклы була: «Өлкә комитеты бюросы Яфаровның дәреслектә җибәргән хаталары аның әле һаман да элекке буржуаз милләтчелек карашларыннан (ассызыклау безнеке. Б. С.) арынып җитмәгәнлеге турында сөйли дип саный». Югары даирәләр Б. Яфаровның эволюциясен, ягъни акрынлап үсеш-үзгәрешен бик җентекләп күзәтеп торганнар, ахрысы. Артыннан шымчылык итү дә оештырылган булырга мөмкин. Элгәрге карардан тиешле нәтиҗәләр ясамаган тарихчы һәм әдәбиятчы галимнәрнең барлык хаталарының төп сәбәбен өлкә комитеты партия күрсәтмәләренә формаль мөнәсәбәттә һәм фәнни эшкә дә принципсыз, ваемсыз карашта булуларында күрә. Әлбәттә, һәр карар галимнәрнең һәм физкультурачыларның якын дусты булган юлбашчының исеме белән «изгеләндерелеп» кабул ителергә тиеш. Шулай эшлиләр дә. Карарда ул болай чагылыш таба: галимнәр «иптәш Сталинның: «Фикерләр көрәше һәм тәнкыйть ирегеннән башка бернинди фән дә үсә һәм уңышка ирешә алмый»,— дигән күрсәтмәсен истә тотмаганнар», ә Татарстан тарихчылары һәм әдәбиятчыларының төп хатасы шунда — «алар үзләренең эшчәнлекләрен иптәш Сталинның «Марксизм һәм тел белеме мәсьәләләре» дигән хезмәтендә биргән күрсәтмәләре яктылыгында үзгәртеп кормаганнар».

Әйткәнебезчә, карар бу юлы 1948 елгысыннан шактый кырыс була: милләтчелек характерындагы тупас хаталары өчен Б. Яфаровны ВКП(б) сафларыннан чыгарып ыргыталар, Тарих, тел һәм әдәбият институты директоры М. Гайнуллинга шелтә белдерелә, Г. Халитнең җаваплылыгы мәсьәләсен институт партоешмасы җыелышында тикшерергә кушыла. Шуннан соң министрлык һәм нәшриятка яңа уку елына идеологик таза яңа дәреслек чыгару бурычы йөкләтелә. Күрәсең, өлкә комитетын һаман да бер дәреслек белән иза чигү туйдыргандыр, мәктәпләр бүлегенә, яңа авторлар составы туплап, аны бюрода раслатырга дигән карарга киләләр. Шундый югары дәрәҗәдә законлы авторларны обком үзе сайлап расласа, хаталардан котылу өчен ышанычлы чара булыр дип, алдан ук уйлап куялар, янәсе. Ә теге яманаты чыккан дәреслекнең укучыларга булган зарарлы йогынтысын киметү йөзеннән, кичекмәстән мәктәпләргә аның белән ничек файдалану хакында методик хат җибәрергә, уку елы беткәннән соң барлык дәреслекләрне җыеп алырга һәм юк итәргә, дигән тәкъдим кертелә. Әлбәттә, бу чара бернichә дистә исемдәге мәктәп дәреслекләрен җыеп юк иткән 1937 ел масштабы ук түгел-түгелен, шулай да шактый тәэсирле чара. Гуманитар фәннәр өлкәсендә эшләүче барлык галимнәр дә мәсьәләнең җитдилеген тойсыннар һәм киләчәктә фетнәле фикерләргә юл куймасыннар өчен өлкә комитетының идеология секретаре С. Батыевка язучылар, тарихчылар, башка фәнни хезмәткәрләрнең гомуми җыелышын җыярга, шунда әлеге карарны һәм тарих-әдәбият мәсьәләләрен өйрәнү эшен тикшереп, фикер алышырга йөкләтелә. Бу җыелыш февраль аенда үткәрелә...

Тарихыбызның кайбер сәхифәләре әнә шундый. Хәзер без заманның авырлыгыннан, демократик хакимиятнең кимчелекләреннән һәм башкалардан еш зарланабыз. Тормышыбыз зарланырга нигез бирә. Әмма шуны да онытмаска тиешбез: үткән һәм тыюлы мәсьәләләр буенча ачыктан-ачык үз фикерләребезне әйтә алабыз, бәхәсләшергә иреклебез, хакимлек итеп килгән фикер-карашлардан аермалы үз фикеребез бар. Бу, әлбәттә, демократиянең бәхәссез казанышы. Дөрес, кайвакытта без иреклелекне теләсә нәрсә сөйләргә-язарга мөмкинлек дип аңлыйбыз. Кем генә тарихыбызга тыкшынмый да, ни генә язмый! Болары инде демократиянең тулгагы шикелле нәрсәләрдер. Әмма һәр нәрсә өчен, шул исәптән, фикерләр иреклелеге өчен дә түләргә кирәк. Бу бәя артык зурдан түгел. Әле Черчилль әйтә торган булган бит: «Демократия, әлбәттә, начар һәм ачуны китерә торган нәрсә, ләкин барлык башка нәрсәләр — тагын да начаррак». Ул инде ни-нәрсә сөйләгәнен белеп сөйләгән. Шуның белән булса да юаныйк әле...

**Булат СОЛТАНБӘК**

# ĢIBRƏTLE SYZLƏR

Xörmätsez keşelärneñ süzläre — yalğan sanala, oluğ keşelärneñ yalğan süzläre — säyäsät atala.

Xıyal berlä läzzätlänü — bulğan eş berlä läzzätlänüdän läzzätleräk.

Ğaqıllı doşmannıñ ütken qılıç bulıp kiskäne sizelmi, ämma ğaqılsız doşmannıqı ütmäs qılıç bulıp kisüdän ğazaplı.

Keşeneñ axmaqlığına dälil — ber-berenä doşman bulğan ike keşene dus itep totuıdır.

Doşmansız bulu — kamillek tügel, kamillek — xaqlı urında doşman totuıdır.

Bäräkätle adäm şul keşeder: süzenä qarağanda eşe küp wä tışına qarağanda eçe yaxşı.

Dönyada iñ awır närsä — rizıq az wä ğaqıl küp bulıp, ikese bergä cıyıludır.

Ciñel sanalğan eşlärneñ axırları — küp waqıtta awır wä awır kürelgän eşlärneñ soñları küp waqıtta ciñel buladır.

Xacät waqıtında däwanı istiğmäl itü — şifa birä, xacät bulmağada istiğmäl itü — awıru tudıra.

Yaqın qarendäşlärenñe bozıq keşelärdän saqlawıñ kebek, kitaplarınnı da tieşle bulmağan keşelärdän saqla.

Açu kilü — izgeleklärne onıttıra.

Tieşle bulmağan keşene maqtau wä yamanlau — sazlıqqa öy salu misalında.

Küp fikerlä, az söylä.

Küñelne üzenä tartuçı närsä — keşeneñ yaxşı xolqı belän yaxşı ğadätläreder.

Süzlärneñ qıymmätlese — zaman ütü belän onıtılmıy torğanı.

Niqadär awır bulsa da, adäm balasının dönyada torası kilä.

Dönya ber teatr bulıp, adäm balaları şunda uynauçılar.

här kiçäneñ — köne, här qayğının şatlığı bula.

Keşe üzeneñ xatasın zamanağa yöklätä.

Yalğan dus — çın doşmannan zararlıraq.

Küp nadanğa iyärügä qarağanda az ğalimgä iyärü yaxşıraq.

Duslıq — däwam itkän waqıtında nığıy bara.

Duslıq — qayğını, şatlıqnı urtaqlaşudır.

Atañ-anañnı qabergä salğan dönyadan ni märxämät ömet itmäk kiräk!

Dönyada yäşägän waqıtlarında adäm balalarınıñ ike törle maqsatları bar: berse – baylıq, ikençese dä – baylıq.

Kürü öçen yörüçe xatınnarğa qarağanda kürelü öçen yörüçe xatınnar kübräk bula.

Ğaqıllı keşe yalğızı ğına qaludan qurıqmas.

Ozın süzlärdä qısqa ğına ber maqsat bula.

### Xatınnar xaqında

Adäm balalarınıñ bäxetläre – xatınnar qulında.

Balaların kürep, analarınıñ çistalıqqa ixtiramlı wä tärbiyäle buluların belersez.

Ber xatınnıñ qıymmätle baylığı – ireneñ mäxäbbäteder.

Maturlığı belän maqtanuçı xatın matur tügel, bälki tärbiyäle wä yaxşı xolıqlı bulu1 belän maqtanuçı xatın maturdır.

İrlär tän bulsa, xatınnar candır.

Xatınnarnıñ yılmayıp kölüläre niqadär küñelle bulsa, qıçqırıp kölüläre şul däräcädä küñelsezder.

Adäm balalarınıñ dönyağa kilülärenä säbäp bulğanlıqları öçen, xatınnarnıñ keşelär cämğıyätendäge urını bik xörmätleder.

Qıçqırıp kölüçe xatınnarğa qapma-qarşı bularaq, yılmayıp kölüçeläreneñ iñ ğaqıllı keşe ikänleklärendä şöbhä yuq.

Xatınnarnıñ adäm balaları ğalämenä itkän xezmätlären qaläm belän yazıp belderü mömkin tügel.

Paklek söygän xatınnıñ pıçraq xezmätçese bulmas.

Dönyanıñ bäxetsez adämnäre kürkäm xolıqlı xatınnan wä tärbiyäle baladan mäxrüm bulğannarıdır.

Xatınnarda üzlären söyderüçe öç törle sıyfat bar:

1) maturlıq wä güzällek, 2) ğaqıl wä tärbiyä, 3) ziräklek wä näzaqät. Oşbu öç sıyfatnıñ berençesennän mäxrüm bulğannar, ömetlären kismiçä, ikençe wä öçençelär belän faydalana alırlar.

Xatın – fäqirlekkä qarşı ber ğäskärder. Mämläkäte – öye, qoralı – qayçı belän inäse.

İrlärneñ öydä utıruı, xatınnarnıñ çittä yörüe fäqirlek qoralıdır.

Aldan kürüçän tärbiyäle häm dä ğaqıllı xatınnan mäxrüm yort – cimerek yort.

Üz-üzen zur kürü härkem öçen bozıqlıq, xatınnar öçen ul bigräk tä bozıqlıqtır.

Ber xatın yalğız ber irne genä bäxetle itügä burıçlı.

Bäxetle ir – qanäğät xatını bulğan irder.

Dönyada yaxşı tereklek kürkäm xolıqlı xatınnan başqa bulmas.

Xäzerlekläre bulğan keşelär qurqınıçlı eşlärgä dä qarşı toralar.

Xökümät başında toruçılar käcä täkäsenä genä bulsa da ğıybadät qıluçı, dinle bulsınnar.

Töşüe awır bulırlıq yuğarı urınğa menärgä qızıqma.

İrgä baraçaq qız wä xatınğa üz küzlärennän bigräk keşe süzen iğtibarğa alırğa kiräk.

Yomırqalarınnan çıqmas borın çebeşlärne sanamıylar.

Tumışında käkre bulğan närsä tärbiyä belän genä tözälmi.

Doşman belän çualu wä bulışu — anı qızdırudır.

Ömet betü — qurqaqnı da batırlandıra.

Doşmannı ciñü öçen iñ köçle qoral — aña izgelek itü.

Sin üz wazifañnı ütä dä, annan arğısın tikşermä.

İserü — üz ixtıyarıñ belän diwana buludır.

Här ike keşe dä irle-xatınlı bulmıy.

Nadan bay — ğalimnär mäclesendä telsezder.

Ütkän könnärdäge bäğze awırlıqlar bu köndä mal tügep alaçaq ciñelleklärne tudıra.

Ütkän xällärne onıtmau — axirät tormışın iskä töşerügä säbäp buladır.

Dönyanıñ qızğanıç keşeläre — ğalim uğlı nadan belän bay uğlı yuqsıldır.

Nadannarnıñ ğalimnärdän öyrängän närsälärenä qarağanda ğalimnärneñ nadannardan öyrängän närsäläre kübräk bula.

Balalarğa qaldıra torğan miraslarnıñ iñ qıymmätlese — din öyrätep qaldıru.

İserü — adämlektän çığıp, xaywanlıqqa kerüder.

Keşelärne şatlandıruıñ — üzeñne şatlandıruıñdır.

Ğaqıllı dus — arığan waqıtta utırıp bara torğan arba.

Dönyanıñ maqsatları — yaz könendäge qar kebek eri dä betä.

Ğaqıllı keşeneñ yöge — başında, axmaq keşeneñ yöge — arqasında.

Eşläp aruğa qarağanda tik torıp aru awır.

Äytkän süz, ütkän ğömer — ağıp kitkän su misalında.

Tuğrılıq — maqsatqa bara torğan yullarnıñ häm qısqası, häm yaxşısı.

Bäğze ber keşelär teşläre belän çäynilär, bäğze beräülär telläre belän çäynilär.

Bu dönyadağı qayğılar, awırlıqlar — adäm balalarınıñ imtixan birüe.

Döreslek qatnaşmağan yalğanğa qarşı torıu ciñel, qarşı toru awır bulğan närsä — döreslek qatnaşqan yalğan.

Sälamätlegeñne saqlıysıñ kilsä, här eşendä saq bul.

Keşelärneñ çın yaxşı bulularına ışanmağan keşelärneñ şul fikerläre küp waqıtta döres tä bula.

Yärdämçeläre niqadär az bulsa da, xaqlıq qayçan da ber öskä çığa.

[1] Риза Фәхретдиннең «Болгар вә Казан төрекләре» китабыннан.

## БЕРГӘ БУЛСАК, ОТТЫРМАБЫЗ!

**«Мәдәни җомга»** — татар дөньясында халкыбызның рухи елъязмасы булырлык бердәнбер махсус газет;

«Мәдәни җомга» — күләменә карата чагыштырмача иң арзан газет; **ярты елга язылу бәясе — нибары 27 мең сум;** газетның **индексы — 54129.**

«Мәдәни җомга» атналык басмасы бүгенге татар кешесен һәрьяктан канәгатьләндерер, өегезгә һәрдаим нур өстәп торыр.

Язылырга кичекмәгез, мөхтәрәм милләттәшләр!

* * *

Үз йөзен, үз укучысын тапкан **«Шәһри Казан»** газетасы киләсе ел өчен үзенең дусларын барлый. Аның белән ныклы элемтәдә булырга теләүчеләргә язылу бәяләрен искәртәбез:

— **Казанда** яшәүчеләр өчен — **54208 индексы белән: 6 айга — 35.400 сум (бер елга — 70.800 сум);**

— **Республикабыз районнарында — 54126 индексы белән: 6 айга 45.600 сум (бер елга — 91.200 сум);**

— **Предприятиеләр һәм оешмалар өчен — 54207 индексы белән: 6 айга — 79.200 сум (бер елга — 158.400 сум)**

* * *

1998 ел өчен **«Юлдаш»** газетасына һәм **«Раннур»** нәшрияты чыгарган китапларга язылу дәвам итә. Аларның һәммәсе Татарстан һәм Россия газета-журналлары каталогларына кертелгән:

— **«Юлдаш»** газетасы. Индексы — 54138. Ярты елга язылу бәясе — 13.200 сум (тулы бер елга — 26.400 сум;)

— **«Сез яраткан җырлар»** (544 битле). Индексы — 73949. Бәясе — 12.900 сум;

— **«Гаилә календаре»** (1998 ел өчен). Индексы — 78706. Бәясе — 7.900 сум;

— **«Төшләрне юрау китабы»** (352 битле). Индексы — 78706. Бәясе — 11.900 сум;

— **«Ислам дине нигезләре»** (288 битле). Индексы — 78713. Бәясе — 10.900 сум;

— **«Татар исемнәре ни сөйли?»** (Ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре алфавит тәртибендә татарча-русча язылышта бирелә.) Индексы — 78709. Язылу бәясе — 12.900 сум.

* * *

**Онытмагыз: Татарстанда 1998 ел өчен вакытлы матбугатка язылу 15 ноябрьгәчә, Җөмһүриятебездән читтә 1 ноябрьгәчә барачак.**

*РӘСМИ ХӘБӘРЛӘР*

### КАЗАХСТАН — ТАТАРСТАН ХЕЗМӘТТӘШЛЕГЕ

25—26 август көннәрендә Президент М. Шәймиев житәкчелегендәге Татарстан Республикасы рәсми делегациясе, Казахстан Республикасы Президенты Н. Назарбаев чакыруы буенча, әлеге жөмһүрияттә булды. Очрашу вакытында ике республика арасында икътисади, фәнни-техник, мәдәни бәйләнышларны тагын да ныгыту турында сөйләшенде; Казахстанга «КамАЗ» йөк автомобильләре, аларга запас частьләр жибәрү, бу машиналарны Казахстанда жыю, Татарстаннан алынган электр энергиясе хисабына безгә металлопрокат бирү, Казахстандагы нефть ятмаларын бергәләп үзләштерү һ. б. мөһим мәсьәләләр тикшерелде. Визит барышында Казахстанда Татарстан вәкиллеген ачу турында хөкүмәтара килешүгә кул куелды. Килешүдә әлеге республикада яшәүче татар диаспорасы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру да күз уңында тотыла.

### КҮРШЕЛӘР КУЛ КЫСЫША

28 августта Казан Кремлендә Татарстан белән Башкортостан Республикалары арасында «Үзара дуслыкны һәм хезмәттәшлекне ныгыту турында»гы килешүгә кул куелды. Әлеге тантанада Башкортостан ягыннан — әлеге тугандаш республиканың Президенты М. Рәхимов житәкчелегендәге хөкүмәт делегациясе, Татарстан ягыннан — Президент М. Шәймиев, Премьер-министр Ф. Мөхәммәтшин, Дәүләт Советы Рәисе В. Лихачев һ. б. рәсми кешеләр катнашты.

### МӘДӘНИ БӘЙЛӘНЫШЛАР НЫГЫЙ

29 августта Татарстан Жөмһүриятенең Милли китапханәсендә Татарстан Республикасы белән Әзәрбайжан Республикасы Мәдәният министрлыклары арасында үзара хезмәттәшлек турындагы килешүгә кул куелды. Документны Татарстан Мәдәният министры М. Таишев белән Әзәрбайжан Мәдәният министры Полад Был-Был Оглы үз имзалары белән беркеттеләр. Шулай итеп ике республика территориясендә яшәүче халыклар мәдәниятен ирекле һәм тигез хокуклы үстерү гарантиясенә нигез салынды.

*II БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ КӨННӘРЕНДӘ*

### ВОКЗАЛНЫҢ ЙӨЗ ЕЛЛЫГЫ

27 августта мәркәзебездә Казан тимер юл вокзалының йөз еллыгы зурлап билгеләп үтелде. Иртәнге якта «Мәскәү — Казан» поезды белән Татарстан башкаласына кадерле кунаклар — II Бөтендөнья татар конгрессы делегатлары һәм шулай ук Россия Федерациясенең юллар министры Н. Аксененко, «Трансстрой» акционерлык җәмгыятенең генераль директоры В. Брежнев килеп төште. Вокзалда аларны ТР Президенты М. Шәймиев, Премьер-министр Ф. Мөхәммәтшин, Казан шәһәре мэры К. Исхаков һ. б. рәсми кешеләр каршылады. Аннары яңартылган-төзекләндерелгән тимер юл вокзалын ачу тантанасы булды. Камал һәм Качалов театры артистлары тимер юл вокзалының үткәне белән бүгенгесен чагылдырган, кызыклы шәхесләребезне гәүдәләндергән мавыктыргыч тамаша да күрсәттеләр.

### КАЗАН МЕТРОСЫНА НИГЕЗ САЛЫНДЫ

Шул ук көнне Татарстан Президенты М. Шәймиев һәм килгән кунаклар, конгресс делегатлары, киң җәмәгатьчелек вәкилләре Казан метросына — аның беренче линиясенә һәм тәүге станциясенә нигез салуда катнаштылар. Свердлов урамында уздырылган тантаналы жыенда Жөмһүриятебез Илбашы шул уңайдан «Киләсе буыннарга Мөрәҗәгать» белән чыкты. Аннары әлеге «Мөрәҗәгать» салынган махсус савыт беренче станция булачак урынга урнаштырылды, метро диварының беренче тимер-бетон коелмасы жир астына төшерелде.

Казан метросы — Россиядә бүгенге көндә төзелә торган метроларның жиденчесе булачак. Тантанада чыгыш ясаган Казан шәһәре мэры К. Исхаков, халык фикерен искә алып, элеккеге Куйбышев мәйданының («Кольцо»ның) татар халкының бөек улы, шагыйрь Г. Тукай исеме белән аталып йөртелачәге турындагы шатлыклы хәбәрне ирештерде. Тагын шунысы куандыра: Казан метросының Тукай мәйданындагы беренче станциясе дә нәкъ менә аның олуг исемен йөртәчәк.

### РЕСПУБЛИКА КӨНЕ

30 августта башкалабыз Казанда һәм Татарстанның барлык районнарында Республика көненә багышланган бәйрәм тамашалары булып узды. «Татарстан Республикасының дәүләт бәйсезлеге турында» Декларация кабул ителүнең 7 еллыгы II Бөтендөнья татар конгрессы барган көннәргә туры килүе белән икеләтә истәлекле булды. Конгресс делегатлары, килгән кунаклар мәркәзебездә үткән тантаналарда бик теләп катнаштылар, рәхәтләнеп күңел ачтылар. Бәйрәм рухы һәркемнең йөрәгенә үтеп керде, милли рух һәм ялкын өстәде.

## БОЛГАРГА СӘЯХӘТ

31 август көнне конгресс делегатлары һәм кунаклар, «Метеор»ларга утырып, Идел буйлап, халкыбызның тарихи бишеге булган шәһәри Болгарга сәяхәт кылдылар. Аларны биредә Спас районы халкы һәм житәкчеләре бик жылы каршылады. Болгарда күргән һәр нәрсә — Олы манара, Мавзолей, Кара палата, Җәмигъ мәчете калдыклары, кабер ташлары һәм туган як музее — һәркемне тетрәндерде. Изге җирдә алар борынгы болгар бабаларыбыз рухына дога кылдылар.

## «СӘФӘР» КУНАКХАНӘСЕ ЧАКЫРА

Мәркәзебездәге Яшьләр үзәге белән янәшәдә 17 катлы яңа бина — «Сәфәр» кунакханәсе калкып чыкты. Ул халыкара таләпләргә җавап бирерлек итеп төзелгән һәм җиһазланган. Кунакханә 129 бүлмәле, 258 урынга исәпләнгән. Төркиянең «Одак» исемле төзелеш-сәүдә акционерлык җәмгыяте 19 августта «Сәфәр»не дәүләт комиссиясенә тапшырды һәм ул кабул ителде. Кунакханә беренче булып II Бөтендөнья татар конгрессы делегатларына хезмәт күрсәтте.

*ӘДИПЛӘР ДӨНЬЯ ГИЗӘ*

## БЕЗНЕКЕЛӘР — ШОТЛАНДИЯДӘ

«Казан утлары» журналының баш мөхәррире, шагыйрь Равил Фәйзуллин, «Идел» журналыннан язучы Нәбирә Гыйматдинова, журналист-сәясәтче Тәлгат Бариев, дипломат-публицист Вахит Юныс, Бөтендөнья ПЕН-үзәгенең чакыруы буенча, август башында Шотландиядә узган 64 нче халыкара конгресста булып кайттылар. Дөньякүләм мәртәбәле бу конгресста элеккеге СССР язучыларыннан, безнекеләр белән бергә, фәкать рус, литва, латыш халыклары вәкилләре генә бар иде. Татар язучылары Эдинбургта һәм Лондонда үткәрелгән чараларда актив катнаштылар.

## ТӨРКИ ХАЛЫКЛАР АССАМБЛЕЯСЫ КОРЫЛТАЕНДА

Татар халкының Милли Мәҗлесе рәисе — язучы Айдар Хәлим, Татар иҗтимагый үзәге, Милли Мәҗлес, «Иттифак» фиркасы әгъзалары белән берлектә, Төркиядә узган Төрки халыклар Ассамблеясының IV корылтаенда катнашты һәм «Татар халкының бөтен дөнья җәмәгатьчелегенә мөрәҗәгате»н игълан итте. Аның чыгышы делегатлар арасында зур кызыксыну уятты. Ассамблея, мөрәҗәгать уңаеннан, махсус резолюция кабул итте.

## БАШКОРТСТАНДА ОЧРАШУЛАР

Алдагы елларның уңай тәҗрибәсен искә алып һәм укучыларыбыз белән элемтәне тагын да ныгыту максатыннан чыгып, 7—14 сентябрь көннәрендә тугандаш Башкортостанның милләттәшләребез күпләп яши торган Шаран, Бакалы районнарында, Туймазы һәм Октябрьск калаларында «Казан утлары» журналы һәм «Сабантуй» газетасы атналыгы үткәрелде. Татарстанның халык шагыйре, күренекле драматург — «Сабантуй» газетасының редколлегия әгъзасы Илдар Юзеев, «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире, язучы Шаһинур Мостафин, Башкортостанның һәм Татарстанның атказанган артисты Фән Вәлиәхмәтов мәктәпләрдә, китапханәләрдә, театрларда, мәдәният йортларында, предприятиеләрдә, җирле газета редакцияләрендә, шифаханәләрдә булып, милләттәшләребез белән очраштылар, әдәби-музыкаль кичәләр үткәрделәр.

*СӘНГАТЬ ДӨНЬЯСЫНДА*

## ИЛҺАМЛЫ МУЗЕЙ


Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенә 60 ел тулу уңаеннан, биредә аның тарихи музеен ачу тантанасы булды. Музейның директоры итеп халкыбызның сөекле җырчысы — Г. Тукай бүләге лауреаты Илһам Шакиров билгеләнде.

## КҮРГӘЗМӘ ҮТКӘНГӘ ДӘШӘ

«Казан» милли мәдәният үзәгендә рәссам Нияз Хаҗиәхмәт әсәрләреннән торган күргәзмә ачылды. «Казан каласы — таш кала» дип исемләнгән әлеге күргәзмәгә аның ике дистәгә якын картинасы куелган. Рәссам үз әсәрләрендә Казан ханлыгы чорын, шул замандагы дәүләт әһелләрен чагылдыра.


### *Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** «Хәтер» — рәссам Х. Шәрипов картинасыннан фотосурәт.



**Жамал Вәлиди**
1887—1932

Индекс 73210



Шагыйрь Гарифҗан Мөхәммәтшин

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЬ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)